ISSN 0206—41

# Казан утлары

5.1984



# КАЗАН УТЛАРЫ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

5

1984

## Бу санда

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ X СЪЕЗДЫНА

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. **Якты идеалларыбыз хакына** . 4
**Казанышлар һәм бурычлар.** Иҗат секцияләрендә . 7
Ф. МИҢНУЛЛИН. **Ил белән, халык белән** . . . 15

М. МӘҺДИЕВ. **Мәңгелек яз.** Роман . . . . . . 20
Г. АФЗАЛ. **Шатланды күңел, сафланды.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Р. МИНГАЛИМ. **Кайда сез, ирләр!** Моңсу комедия . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Ш. ГАЛИЕВ. **Шигырьләр** . . . . . . . . . 90
А. ГАНИЕВ. **Габделхак.** Повесть . . . . . . . 94
Р. НИЗАМИЕВ. **Көнбагыш.** Хикәя . . . . . . . 119
Н. ИЗМАЙЛОВА. **Шигырьләр** . . . . . . . . 124

БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 40 ЕЛЛЫГЫНА

Ш. ХАММАТОВ, К. ТӘХАУ. **Фронтовик әдипләр** . 127

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

**Казанда Тукай урыннары** . . . . . . . . . . 134
Р. НӘФИКОВ. **Тукайның иптәшләре һәм танышлары** . . . . . . . . . . . . . . . . 135

КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ИЮНЬ (1983 ЕЛ) ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

К. ФАСЕЕВ. **Болганчык дулкын.** (Капитализмның рухи кризисы) . . . . . . . . . . . . . 139

АЭС — ӘДӘБИ ПОСТ

М. МОСТАФИН. **Киңәшле эш таркалмас** . . . 147

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. СВЕРИГИН. **Тормышның үзе кебек** . . . . 149

БИБЛИОГРАФИЯ

Р. ИГЪЛАМОВ. **Үрнәк булырлык хезмәт** . . . . 157

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

И. НАДИРОВ. **Шигъри өкият** . . . . . . . . 160

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

М. ЗӘКИЕВ. **Казан татарлары ни өчен марийча — суас, удмуртча — бигер!** . . . . . . . . . 161
Г. КУТУЕВА. **Якты хатирә** . . . . . . . . . . 170

КПССның ТАТАРСТАН өлкә КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА һәм ЖУРНАЛЛАР нәшрияты

КАЗАН

СӘНГАТЬ

Л. БЛИНОВ. Музыка: сәләт бөреләре ничек ачыла . . . . . . . . . . . 174

БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

Х. ГОСМАН (133), Н. ҖИҺАНОВ (146), И. ШАКИРОВ (169), М. СӘЛИМҖАНОВ . . . . . . 176

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВКА 50 ЯШЬ

М. ГОСМАНОВ. Язма мирасыбызның күтәреләсе катламнары . . . . . . . . . . . . 177

ЮМОР-САТИРА

Ә. ИСХАК. Автобус һәм Трамвай вагоны. Мәсәл . 187
Б. РАФИКОВ. Начальникны көткәндә . . . . . 188

Кызыклы хәлләр . . . . . . . . . . . . . . 189

Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары (Ф. Гыйльми, К. Кәримов, С. Маннапов) . . . . . . . . . . . . . 190

Культура тормышы көндәлеге . . . . . . . . 191

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . . . 192



*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия:*

ШАМИЛ БИКЧУРИН

МАНСУР ВӘЛИЕВ

РАЗИЛ ВӘЛИЕВ

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

РӘИС ДАУТОВ

МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ

ЗӨЛФӘТ

САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*

ТУФАН МИҢНУЛЛИН

ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*

ЗӘКИ НУРИ

РӘФЫЙК НӘФИКОВ

АТИЛЛА РАСИХ

СИБГАТ ХӘКИМ

НИЛ ЮЗИЕВ


## В НАШЕМ НОМЕРЕ


«К X съезду писателей Татарстана». Выступления секретаря партбюро Союза писателей ТАССР **Р. Мухамадиева** и зам. председателя Правления Союза писателей ТАССР **Ф. Миннуллина**. Отчет о работе творческих секций между двумя съездами.
Роман **М. Магдеева** «Вечная весна». Пьеса **Р. Мингалима** «Где вы, мужчины?» Повесть **А. Ганеева** «Абдулхак». Стихи **Г. Афзала, Ш. Галиева, Н. Измайловой**. Басня **А. Исхака** и юмористические миниатюры **Б. Рафикова**. Рассказ **Р. Низамиева** «Подсолнух».
«К 40-летию Великой победы». Статья **Ш. Хамматова** и **К. Тахау** «Писатели-фронтовики».
В рубрике «К 100-летию Тукая»: статья **Р. Нафикова** «Друзья и знакомые Тукая», рис. **Т. Зуевой** из цикла «Тукаевские места в Казани».
«Решения июньского (1983 г.) Пленума ЦК КПСС — в жизнь!» Статья **К. Фасеева** «Мутная волна» (о духовном кризисе капитализма).
«Литературный пост — АЭС». Корреспонденция **М. Мустафина**.
В библиографическом разделе журнала — рецензия **Р. Игламова** на книгу **А. Ахмадуллина** о современной драматургии и отклик **И. Надирова** на книгу сказок **Р. Батуллы**.
Статья **М. Закиева** об этнонимах «болгар, суас, бигер». Публикация **Г. Кутуевой** — дочери писателя А. Кутуя «Светлая память».
Статья **Л. Блинова** о музыкально-эстетическом воспитании детей.
Слово о М. Усманове в связи с его 50-летием и статья юбиляра «Неподнятая целина нашего письменного наследия». «Занимательные истории». «Молодые писатели, вновь принятые в Союз писателей СССР». «Дневник культуры». «На наших обложках» — творчество художника Н. Кузнецова.



Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.



Техник редакторы *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина*.

Производствога бирелде 15.3.1984 ел. Басарга кул куелды 20.4.1984 ел. ПФ 02214. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 64549. Заказ К-68. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.



© «Казан утлары», 1984 ел.

«Әдәбият эше гомуми пролетар эшнең бер өлеше булырга, бөтен эшчеләр сыйныфының бөтен аңлы авангарды тарафыннан хәрәкәткә китерелүче бер бердәм, бөек социаль-демократик механизмның «кечкенә тәгәрмәче һәм кечкенә шөребе» булырга тиеш. Әдәбият эше оешкан, планлы берләшкән социаль-демократик партия эшенең состав өлеше булырга тиеш».

В. И. Ленин. («Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» дигән мәкаләдән.)

«Производствода һәм көнкүрештә кешеләрнең үзара мөнәсәбәте, шәхеснең катлаулы эчке дөньясы, тынычсыз планетабызда аның урыны — болар һәммәсе художество эзләнүләре өчен бетмәс-төкәнмәс өлкә... Әсәрләр геройларының вак-төяк эшләр даирәсендә бикләнеп калмавы, бәлки, үз иленең мәшәкатьләре белән — киеренке хезмәт белән тулы тормыш, гаделлек һәм яхшылык тантанасы өчен ныклы көрәш белән яшәве кирәк».

КПССның XXVI съезды материалларыннан.

«Художник иҗатында аның гражданлык позициясе төп нәрсә булды һәм шулай булып кала да. Партиячел караш кына хәзерге заманның төп тенденцияләрен танып белергә ярдәм итә».

КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы материалларыннан.

«Яшь иҗат интеллигенциясенең тормыш белән элемтәсен туктаусыз ныгытырга һәм төрләндерергә, аның иҗтимагый активлыгын үстерергә, яшьләргә кызыклы эшләр тапшырырга, аларны коммунистик идеаллар өчен кыю көрәшүчеләр итеп тәрбияләргә».

КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы карарыннан.

«Социалистик реализм сәнгате өчен советча яшәү рәвешен, коммунистик әхлак нормаларын, безнең кешеләр бәхете хакына намуслы хезмәт, интернационализм, эшебезнең тарихи хаклыгына инану кебек мораль кыйммәтләребезне раслаудан да мөһимрәк бурыч юк».

КПСС Үзәк Комитетының «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән иҗади элемтәләре турында»гы карарыннан.

# ЯКТЫ ИДЕАЛЛАРЫБЫЗ ХАКЫНА

Татарстан язучыларының X съезды истәлекле көннәрдә — СССР Язучылар союзы төзелүгә 50 ел тулу алдыннан уза. Чишмә башында Галимҗан Ибраһимов һәм Шәриф Камал, Һади Такташ һәм Хәсән Туфаннар торган татар совет әдәбияты да бу көннәрдә үзенең ярты гасырлык юбилеен билгеләргә җыена.

Юк, бу көннәрдә без бер дә очраклы рәвештә генә «данлы юбилей» димибез. Күз алдына китереп карыйк, Туган ил белән һәм халкыбыз белән үтелгән ул олы юл чынлап та данлы һәм мактаулы ич! Җирдә яңа тормыш төзүчеләрнең — авыл хуҗалыгын күмәкләштерүчеләрнең, беренче бишьеллык каһарманнарының хезмәт энтузиазмын, җиңүләрдән яңа җиңүләргә алып барган ныклы рухын төкми-чәчми килер буыннарга илтеп җиткергән әдәбият ич ул! Бөек совет халкы белән бергә Бөек Ватан сугышы кырларында тиңдәшсез батырлыклар кылган, илбасарларны тар-мар итеп бөтен Европаны фашизм афәтеннән йолып калуга өлеш керткән Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Абдулла Алиш, Нур Баян кебек, иҗатта гына түгел, үлем белән күзгә-күз калганда да бирешмәгән, җиңеп алга үткән әдәбият! Шуңа күрә дә без бүген һич икеләнмичә, әдәбиятыбызның күпмилләтле һәм күп бизәкле бердәм совет әдәбиятлары гаиләсендә лаеклы урыны бар дибез. Чөнки безнең каләмдәш остазларыбыз һәм элгәреләребез нинди генә авыр сынаулар алдында торганда да шагыйрь дигән, әдип дигән зур һәм җаваплы исемгә тап төшерми килгәннәр.

Без бүген, соңгы биш ел эчендә үтелгән юлга йомгак ясаган көннәрдә, иң элек әлеге бай традицияләргә ни дәрәҗәдә лаеклы булуыбыз һәм аларны нинди яңа төсмерләр һәм бизәкләр белән баетуыбыз турында уйланабыз. Бу вакыт аралыгындагы иҗади эзләнүләргә якты нур сиркеп торган тарихи вакыйгаларның иң олысы һәм беренчесе — партиябезнең XXVI съезды булды. «Барлык укучылар, тамашачылар, тыңлаучылар совет сәнгатендә яңа дулкын күтәрелүен сизәләр. Соңгы елларда — һәм барлык республикаларда — талантлы байтак әсәрләр барлыкка килде»,— кебек, югары трибунадан әйтелгән сүзләр, табигый ки, язучыларның һәм шул җөмләдән татар әдипләренең дә рухи күтәренкелеген бермә-бер үстерә төшеп, яңа һәм тагы да җитдирәк әсәрләр язарга илһамландырды.

Чынлап та, партия съезды трибунасыннан билгеләп үтелгәнчә, әдәби хәрәкәтнең тагы да җанлана төшеп, яшь һәм урта буын әдипләренең соңгы елларда яңа бер дулкын тәшкил итеп, югары сәнгать әсәрләре тудыруы һичкемнән яшерен-батырын түгел. Моны, аерым алганда, Ч. Айтматовның «Гасырдан да озаккарак сузылган көн», Н. Думбадзенең «Мәңгелек закон» романнары, Ю. Бондарев, Ф. Абрамов, В. Распутин, Г. Матевосян, В. Быков кебек прозаикларның кыю рәвештә гаять актуаль проблемалар күтәреп, сәнгатьчә тирәнлеккә ирешкән проза

әсәрләре ачык раслап килә. Шигъриятта исә Р. Гамзатов, Е. Исаев һәм А. Преловскийларның киң эпик гомумиләштерүгә ирешкән поэмалары, Э. Межелайтис, Е. Евтушенко, О. Сулейменов, И. Драч кебек иҗат үзенчәлекләренә ия шагыйрьләрнең фәлсәфи гомумиләштерүләр белән өртелгән лирикасы да шуңарга ачык үрнәк булып тора. Драматургия, әдәби очерк һәм әдәби тәнкыйтьтә дә «яңа дулкын» булып дөньяга чыккан әсәрләр байтак. Аларның һәммәсен искә алу гына да байтак урын сорар иде. Әмма, хикмәт аңарда түгел. Вакыйга сыман билгеләп, куаныч санап бүлешә торган шатлыклы факт — ул да булса күпмилләтле совет әдәбиятларының бердәм гаилә буларак оешып, бөтендөнья әдәби хәрәкәтен әйдәп барырга сәләтле мәһабәт олы һәм мул сулы бер дәрьяга әверелүе. Һәм без үзебезнең татар әдәбиятын шушы мул сулы ташкынга койган, ярсу инешләрнең берсе дип хис итәбез.

Соңгы еллардагы әдәби хәрәкәт төрле буын әдипләребезнең талантлы вәкилләренең уртак хезмәте нәтиҗәсендә туды. И. Гази, М. Әмир, Х. Туфан, Г. Әпсәләмов, Ш. Маннур, Г. Гобәй һәм Г. Минский кебек олы әдипләр арабыздан китте. Әмма гомерләренең соңгы сәгатенә кадәр алар Ватанга һәм туган халкына хезмәт итүне, иҗат эшен намус эше дип санадылар. Революция, гражданнар сугышында чыныгу алган бу фидакарь затларның һәр яңа әсәре, алар белән булган һәр әңгәмә әдәби иҗат эшенең ни дәрәҗәдә җитди һәм җаваплы эш икәнлеген искәртеп торды. Хәер, ул буынның кайгыртучанлыгы һәм остазлыгы әле дә булса дәвам итә. Әдәбиятка килүче яңа буыннарга бүген дә үзләренә генә хас күңел киңлеге белән Г. Бәширов, Н. Исәнбәт, А. Шамов, Р. Ишморат, С. Хәким, Ә. Еники, Ф. Хөсни, Н. Арслан, Н. Дәүли һәм Х. Госманнар ярдәм кулы суза.

Әдәбиятыбызның бүгенге торышы, үсеш тенденцияләре турында уйланганда иң элек аның аерым бер жанры гына түгел, ә барлык жанрларының да чагыштырмача бер дәрәҗәдә актив үсеше игътибарны җәлеп итә. Чынлап та, поэзия һәм прозада гына түгел, әдәби очерк һәм тәнкыйтьтә дә соңгы елларда җитди җанлану сизелә. Ә инде берара сүлпәнәеп алган драматургиябезнең хәрәкәт темплары бүген аеруча куандыра. Талантлы драматург Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер җыр», «Монда тудык, монда үстек» пьесалары соңгы еллар драматургиябезнең үсеш дәрәҗәсен, иҗади эзләнүләрдәге сәнгатьчә тирәнлекне ассызыклап торган казанышлар булды. Шунда ук Р. Ишморат, Д. Вәлиев, И. Юзеев, А. Гыйләҗевның соңгы елларда иҗат ителгән яңа әсәрләре бер-бер артлы күз алдыннан уза. Бер төркем үзенчәлекле яшь драматурглар арасында Ризван Хәмид заманның актуаль проблемаларын оста күрә белеп, сәнгатьле тасвирлавы белән үзенә җәлеп итте. Р. Батулла, Р. Мингалим, Ю. Сафиуллин һәм Ф. Садриев кебек драматурглар иҗат иткән әсәрләр дә торган саен республикабыз театрлары репертуарында түрдән урын ала бара.

Поэзиянең дә заман тормышын сәнгатьле чагылдырудагы урыны игътибарга лаек. Әйтик, С. Хәкимнең «Эзлиләр Европа буйлап», «Күги», И. Юзеевның «Очты дөнья читлегеннән», Р. Харисның «Ат иярләү», Р. Мингалимнең «Ике авыл арасы», Зөлфәтнең «Йөрәкләрдә — үлмәс дастан» поэмалары чор рухын чагылдыруга, замандашыбызны борчып, җанга тынгылык бирми йөдәткән проблемаларны тасвирлауга, масштаблы уңай образ тудыруга зур өлеш керттеләр. Н. Арсланов, Г. Афзал, Ә. Баян, М. Шабаев, Р. Фәйзуллин, Г. Рәхим, Р. Гатауллин һ. б. шагыйрьләрнең яңа шигъри җыентыклары фәлсәфи һәм лирик поэзиядәге җитди эзләнүләрнең дәвам итүе турында сөйли. Торган саен бу жанрда яшьләрнең авазы көчлерәк яңгырый бара. Ф. Сафин, Н. Измайлова, Р. Низамиев, З. Мансуров, Р. Зәйдуллин, А. Минһаҗеваларның ике съезд арасында язылган әсәрләре поэзиябезнең киләчәгенә шулай ук зур ышаныч белән карарга нигез бирә.

Ике съезд арасында балалар әдәбиятында эшләүче авторларның иҗат уңышлары аеруча куандырды. Шәүкәт Галиевның Андерсен исемендәге халыкара бүләккә лаек булуы үзе генә дә бөтен әдәбиятыбыз горурлыгы саналырга лаек факт. Р. Мингалим, Р. Миңнуллиннар да балалар өчен байтак кызыклы һәм әһәмиятле яңа әсәрләр иҗат итте. Прозаиклардан Л. Ихсанова, Ш. Рәкыйпов, Ф. Яруллин, Батулла кебек язучылар күп кенә бәхетле сәгатьләр бүләк иткәндер балаларга.

Бүгенге проза. Мөгаен, бүгенге укучының күңел ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә аңар аеруча җаваплы функция йөкләнәдер. Әдәбиятыбыз ветераннары Г. Бәшировның «Сарут» һәм «Бибек нигә елый...», Ә. Еникинең «Тынычлану» хикәяләре зур художник каләменең нинди зур көчкә ия булуын кабат раслады булса кирәк. Хикәядәге уңышлар турында сүз чыккан икән, бу жанрда шулай ук тәҗрибәле каләм осталары А. Шамов, Г. Галиев һәм яшь прозаик М. Галиевларның аеруча нәтиҗәле эшләвен билгеләп үтми мөмкин түгел.

Тарихи темага караган әсәрләр арасында А. Расихның «Ямашев», И. Нуруллинның «Тукай» романнары һәм Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар»ы әдәби вакыйга буларак искә алынырга лаек.

А. Расихның әхлак проблемаларына караган «Сынау» романы, А. Гыйләҗевның «Җомга көн, кич белән», М. Мәһдиевның «Исәнме, Кәшфи абзый» повестьлары укучылар тарафыннан аеруча җылы каршы алынды. Г. Ахунов, Ә. Баянов, М. Хәбибуллин, Р. Төхфәтуллин, М. Маликова, В. Нуруллин, М. Юныс кебек прозаикларыбызның да һәр яңа проза әсәре әдәбиятыбыз барышында игътибарга лаек бер вакыйга буларак кабул ителде. Яшь прозаик Разил Вәлиевның «Яшисе килә» повесте замандашыбыз батырлыгын тасвирлаган уңышлы әсәрләрнең берсе булды. Р. Кәрами, Ә. Гаффар, К. Кәримов, А. Ганиев, Ф. Бәйрәмова һәм Н. Гыйматдиновалар да бу вакыт аралыгында өзлексез иҗат эзләнүләрендә булып, үзләрен өметле прозаиклар итеп күрсәтте.

Документаль жанрда уңышларыбыз исә барыннан да бигрәк М. Зарипов очерклары белән билгеләнде. Арча районы колхозы председателе Фәйзи Галиевның «Икмәк язмышы» дип исемләнгән документаль язмалары да әдәби җәмәгатьчелекнең югары бәясенә лаек булды.

Н. Юзиев, Ф. Мусин, Т. Галиуллин, Р. Мостафин, А. Әхмәдуллин, Ф. Миңнуллин, М. Вәлиев, С. Маннапов һәм Р. Кукушкин кебек тәҗрибәле, хәзерлекле тәнкыйтьчеләр әйдәп барган әдәби тәнкыйть тә үсештә, хәрәкәттә булды. Аның уңышлары һәм аерым кимчелекләре дә безнең әдәби процессның үсешендәге характерлы үзенчәлекләрен чагылдыра килде. Һәм бүген без тагы бер тапкыр әдәби тәнкыйть алдында әле гаять зур бурычлар торуын искәртеп, бу бурычларның үз чиратында һәр жанрда эшләүче башка әдипләребезгә дә турыдан-туры каравын онытмаска тиешле.

КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы һәм «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән иҗади бәйләнешләре турында»гы карары әдәбиятыбыз алдында яңа һәм тагы да югарырак бурычлар куйды. Бу бурычлар — заман таләбе! Коммунистик киләчәкне төзү хакына зур хезмәт батырлыклары күрсәтеп, халык хуҗалыгының төрле тармакларында якты идеалларыбыз хакына үзүзен аямый хезмәт итүче замандашыбыз таләбе! Партия чакыруын, заман таләбен күңеле, рухы белән үзенең гражданлык бурычы итеп кабул итәргә өйрәнгән совет язучысы алдында яңа иҗат үрләре тора. Республикабыз язучылары үзләренең чираттагы X съездын каршылаган көннәрдә бу олы җаваплылыкны аеруча тирәнтен тоеп, яңа иҗат планнары белән янып яши.

**Ринат МӨХӘММӘДИЕВ,**
Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре.

# КАЗАНЫШЛАР ҺӘМ БУРЫЧЛАР

ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

**— Ике съезд арасында Сез җитәкләгән иҗат секциясе жанр үсешенә йогынты ясардай нинди эшләр эшләде? Һәм киләчәктә жанрны үстерү өчен секция нинди зур өештыру эшләре эшли ала?**

**Съезд алдыннан журнал редакциясе Язучылар союзының иҗат секцияләре җитәкчеләренә әнә шундый сорау белән мөрәҗәгать иткән иде. Түбәндә аларның җавапларын урнаштырабыз.**

## Мөхәммәт Мәһдиев

**(проза секциясе җитәкчесе)**

Редакциянең соравын алган көннәрдә почта миңа зур шатлык китерде: Ч. Айтматов, И. Стаднюк һәм Ю. Бондаревка СССР Дәүләт премияләре бирелгән. Аларның романнарын мин яратып, зур тәэсирләр астында, дулкынланып укыган идем. Буранлы Идегәй, манкорт, паритетлар очышы, Ана, Каранар, Зарифа, Казангап — барысы да җанымны тетрәтеп, рухымның астын өскә китергән иде. И. Стаднюк иҗатын да яхшы беләм. Аның ике сыйфаты сокландыра мине: беренчесе — үз темаңны, яза торган чорыңны, предметыңны яхшы белү. Бу инде безнең зур әдәбиятыбызга, бер дә шиксез, Лев Толстойдан килә. Шулай, Толстойдан Горькийга, аннан Алексей Толстойга, Фадеевка, Шолоховка күчә... Бу мәктәп бездә зур, бай. Икенчесе — И. Стаднюк, моннан 40—45 ел элек булган сугыш һәм дөнья мәсьәләләрен бүгенге көнгә күпер салып тасвирлый, бүгенге буыннар язмышы өчен борчылып иҗат итә, «прицел»ны киләчәк заманга куя. И. Стаднюк — зур язучы, җитди талант. Иҗат көчен бары тик зур мәсьәләләргә генә сарыф итә.

Ю. Бондаревның «Сайлау» романы СССР Дәүләт премиясенә лаек булуы да бик табигый: бүгенге прозада Бөек Ватан сугышы темасын философларча миеннән уздыручы, солдат, офицер язмышын зур төгәллек белән тасвирлап бүгенге көнгә чыгучы, шул темадан зур нәтиҗәләр ясаучы тагын нинчә генә художник бар икән? «Сайлау» романындагы Илья Рамзин образы тәнкыйтьче, әдәбият белгече тарафыннан ачылып бетүе, анализлап бәя бирелүе үтә кыен булган бер образ. Моны тудыру өчен сугыш кырларын узу гына җитми. Моңа Толстой, Шолоховлардан килгән сыйфат — кеше рухының иң тирән төпләренә төшә һәм аңлый белү сәләте кирәк.

Журналның соравына җавап биргәндә мин әнә шулар турында уйлап утырдым. Безнең проза секциясе ике съезд арасында «Татар әдәбиятында роман жанры» дигән темага бик тә квалификацияле кешеләрне сөйләтеп бер утырыш уздырды. Роман — нәрсә ул? Бу жанрның үзенчәлекләрен без белеп бетерәбезме? Толстой, Шолохов, Фадеев, Бондарев, Абрамов романнары бар. Ш. Камал, Г. Ибраһимов, Г. Бәширов, К. Нәҗми, М. Галәү, Г. Әпсәләмов, А. Расих, М. Әмир, Ф. Хөсни романнары бар. В. Камалов, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, Ә. Баянов, Ш. Бикчурин, Н. Фәттахларның романнары бар. Инде М. Хәбибуллин да, М. Маликова да, Х. Хәйруллин да, Ә. Гаффаров та роман яза... Әдәбиятка ни соң килеп, мин дә язам. Секциядә шулай сөйләштек, борчылышып сөйләштек. Бәхәсләштек, репликалар «кычкырдык», әмма бер фикерне әйтмичә генә таралыштык. Талант кирәк бит, талант, шайтан алгыры!

Роман — башка барлык жанрларны тәрбияләп, әйдәп баручы ыруг атасы, аксакал. Роман — драматургиягә дә, поэзиягә дә тәэсир итә, бу жанрлар да шул тәэсир астында берәз гына «романлаша»лар. С. Хәкимнең сугыш турындагы поэмаларында, Т. Миңнуллин драмаларында роман жанрының тәэсире юкмыни?

Проза секциясенең утырышыннан шулайрак уй йөртеп таралыштык без, үзебезнең әдәбияттагы бу жанрның шактый сыек икәнен аңлап, башны түбән иеп таралыштык. Роман жанрын үстерүгә нинди оештыру эшләре кирәк?

— Талант, талант, талант!

Проза секциясендә без роман жанрыннан тыш бүгенге татар әдәбиятында эшчеләр сыйныфының чагылышы дигән мәсьәләне дә куйдык. Эшчеләр (Уренгой — Помары газ үткәргечен төзүчеләр) белән очраштык та. Кырда, буранда, труба салган җирдә. Җылы вагоннарга кереп сөйләштек тә.

Авыл темасын да читтә калдырмадык: колхоз председательләрен (Актаныштан «Чишмә» колхозы председателе Я. Хөсәенов, Арчадан «Чулпан» колхозы председателе Н. Сабиров) проза секциясенең утырышына чакырдык. Ни җитми? Прозаиклардан нәрсә көтәсез? Безне укыйсызмы? Без кирәкме? — Сораулар шулай конкрет куелды.

— Без эштән арып кайтып ял итәргә яткач, безне йоклатмый торган заманча әсәр җитми,— диделәр колхоз җитәкчеләре.

Әйе, мәрхүм драматург А. Вампилов хаклы булган. Ул болай дип язган иде: «Писать надо о том, от чего не спится по ночам...»

Киләчәктә секциянең эшен мин болайрак күз алдына китерәм: әлбәттә, аның утырышларында теоретик мәсьәләләр әледән-әле куелып торырга тиеш. Секция—прозаикларның теоретик семинары сыман төс алырга тиеш. Монда яңа басылып чыккан әсәрләр тикшерелергә тиеш («Казан утлары» журналын вакыт-вакыт шулай бөтен жанрлар буенча тикшерәбез бит), алар турында фикер алышырга кирәк. Кайбер әсәрләр укучыларда капма-каршы фикер уяталар, әмма ул фикерләр үзара сөйләшүдән дә ары уза алмыйлар. Бәхәснең урыны — нәкъ менә секция. Бездә проза секциясенең йөзе, функциясе ачыкланып бетмәгән. Берәүләр аны яңа гына яза башлаган яшьләрнең әлегә басылмаган әсәрләрен тикшерү урыны дип уйлыйлар. Бу — дөрес түгел. Яңа яза башлаганнар белән бездә бүтән иптәшләр эшли.

Еш кына проза секциясенә нәшрияттә яки «Казан утлары»нда кыл иләктән уза алмаган әсәрләрне юллыйлар. Минемчә, бу да проза секциясенең функциясе түгел. Ни өченме? Чөнки, нәшрияттә да, журналда да әсәрләрне квалификацияле кешеләр укый.

Һәм соңгысы: безнең прозаиклар соңгы елларда бик мөстәкыйльләнеп киттеләр: кайбер яшьләрдә бер хикәя яки повесть бастырдымы — үзен инде өлгергән талант дип, роман ук бастырса — үзен даһи дип, тере классик дәрәҗәсенә куеп йөрү нормага керә башлады. Мин элегрәк еллардагы проза секциясе утырышларын хәтерлим: анда катнашкан И. Гази, Ш. Маннур, Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов, М. Әмир, Ф. Хөсниләр теге яки бу әсәр турында бәхәсләшеп хакыйкать эзлиләр иде. Таралышканда кайберләре таблетка каба иде... Кызганычка каршы, соңгы елларда ни яхшы дип табылган әсәр турында, ни начар дип бәяләнгән әсәр турында мондый кайнар бәхәсләр булганы юк.

Ә бик кирәк иде...

## Рәдиф Гатауллин

(поэзия секциясе җитәкчесе)

Куелган мәсьәлә бик җитди: ике съезд арасындагы поэзия процессын оештыру, поэтик жанрлар үсеше турында сүз бара.

Моннан биш-алты еллар элек язучыларның күп җыелышларында поэманың азрак язылуы, хәтта артта калуы турында әйтелә иде. Бу хакта бөтенсоюз күләмендә дә дискуссияләр барды. Безнең секция дә бу мәсьәләгә җитди карады: соңгы елларда гына бу жанрга карата берничә доклад тыңланды, фикер алыштык һәм шулай ук, яңа әсәрләрне укып тикшерүләр булды. Тәнкыйть секциясе белән берлектә соңгы елларда басылган поэмалар турында кызыклы әңгәмә узды. Утырышларда поэмаларга җентекле анализ ясалып, аларның сәнгатьчә эш-

ләнешләре, яңалык, үзенчәлекләре билгеләнде. С. Хәкимнең яңа поэмалары, Ә. Баянов, И. Юзеевның шигъри трагедияләре, Р. Харис, Р. Мингалимов, Зөлфәт поэмалары китергән яңалык ачыкланды. Филология фәннәре докторлары Й. Нигъмәтуллина, Т. Галиуллин һәм әдәбият галиме Р. Усманова докладлары да безне кызыклы күзәтүләргә китерде.

Шагыйрь Ренат Харис белән очрашу вакытында исә бүгенге шигъри әсәрләр хакында зур һәм кызыклы сөйләшү булды. Югары накаллы публицистик әсәрләр, монументаль образлар кирәклеге, политик сатираны, шигъри памфлетны үстерү ихтыяҗы бу көнге аеруча басым ясап әйтелде. Шулай ук чорга, заманга якынлык, Тукай, Такташ, Җәлил традицияләренең үстерелергә тиешлеге дә игътибар үзәгендә булды.

Җыр турында да сөйләшүләр булды. Бүгенге җыр үзенчәлекләре турында докладлар тыңланды, радиокомитет редакторлары белән бергә җыр текстлары тикшерелде.

...Поэзия процессы — әдәби продукциягә, китап булып басылуга бәйле. Нәшрият белән тыгыз элемтә, секциядә нәшрият редакторларының кулъязмалар өстендә эш тәҗрибәсе белән уртаклашулары — осталык мәктәбенең бер тармагы иде.

Балалар поэзия антологиясен төзү һәм фикер алышу да шагыйрьләр секциясенең тәҗрибәсен арттырды. Нәтиҗәдә, казах, каракалпак, украин телләрендә чыгару өчен шигъри антологияләр төзелде.

Әдәби осталык мәсьәләсе. Биредә яшьләргә аксакалларыбыз конкрет булышлык күрсәтә. Н. Исәнбәт, Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслановларның секция утырышындагы чыгышлары, тәҗрибә уртаклашулары — төрле буыннарны тоташтыручы олы күпер ролен уйный.

Ике съезд арасында секциядә 30 дан артык кулъязма тикшерелде, егерменәбе китап булып басылып чыкты, уннан артык яшь шагыйрь СССР Язучылар союзы члены булды.

Бергәләп хәл итәсе мәсьәләләр дә күп әле. Поэзиянең бүгенге укучылар белән бәйләнешен ныклап өйрәнәсе бар. Бөтенсоюз укучысына җиткерәсе уңышларыбызны кайгыртып, яхшы тәрҗемә итүне оештырырга кирәк. Бүгенге шигъри публицистика, поэзиянең гражданлыгы, югары идеялелеге турында кат-кат сөйләшү сорала.

## Рөстәм Мингалимов

**(драматурглар секциясе җитәкчесе)**

Ике съезд арасы — драматургиябезнең активлашу чоры булды. Танылган драматургларыбыз Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев тагын да зуррак уңышларга ирештеләр. Туфан Миңнуллинның яңа әсәрләре илебез сәхнәләрендә менде. Ике съезд арасында аның Станиславский бүләгенә лаек булуы да безнең драматургиянең югары баскычка күтәрелүе турында сөйли.

Шушы ук елларда Аяз Гыйләҗев та яңа әсәрләр язып сәхнәгә куйдырды. Татар дәүләт академия театры Илдар Юзеевның «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз» дигән музыкаль водевилен сәхнәләштерде. Үзләренең яңа әсәрләре белән Р. Батулла, Р. Хәмид, Ә. Гаффар сәхнәләрдә ныклы урын алдылар.

Ике съезд арасында Риза Ишморат, Нәби Дәүли, һәм прозаикларыбыздан Гариф Ахунов, Нурихан Фәттах, Диас Вәлиев, шагыйрә Гөлшат Зәйнашева да, үз жанрларына тугры калган хәлдә, драматургиябезгә матур өлеш керттеләр.

Драматурглар сафы соңгы биш елда күпкә ныгыды һәм үсте. Юныс Сафиуллин, Фоат Садриев, Гәрәй Рәхим, Мөхәммәт Мәһдиев, Кашшаф Әмировлар сәхнәбездә урын алдылар. Рафкать Кәрамиев, Ренат Харис, Марсель Галиевләрнең беренче әсәрләре сәхнәләштерелде.

Әйе, ике съезд арасы — драматургиябезнең күтәрелеш еллары булды. 1982 ел-

да РСФСР Язучылар союзы идарәсендә хәзерге татар драматургиясенең торышы тикшерелеп, аның дөнья драматургиясе югарылыгында булуы әйтелде.

Безнең алда әле зур проблемалар да тора. Мәсәлән, кече яшьтәге мәктәп балаларына, яшүсмерләргә адресланган сәхнә әсәрләре иҗат итүдә активлык җитенкерәми. Бу өлкә яңадан яңа каләм осталарын көтә.

## Марсель Зарипов

(очерк һәм публицистика секциясе җитәкчесе)

Очерк һәм публицистика секциясе безнең язучылар коллективында әле иң яше. Ләкин бу жанр үзе каләм осталарына бик таныш һәм бик якын. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Җәлилләр исемен искә алып үтү генә дә күп нәрсә сөйли.

Бүгенге көн үзе үк әдәби фронтның иң кызу мәйданы булган очерк өлкәсендә тагын да күп көч куюны, оешканлыкны, активлыкны таләп итә. Театр — тамаша, поэзия — хисләр, проза — фикер, публицистика — эшләнгән эш дип юкка гына әйтмиләр бит. Моңа өстәп публицистика төшенчәсенә мин тагын шундый аңлатма бирер идем: «җәмәгатьчелек фикеренә турыдан-туры тәэсир итү максаты белән көн үзәгендә торган социаль мәсьәләләрне тикшерүгә багышланган әдәби әсәрләр».

Публицист таланты — сирәк очрый торган күренеш. Чын публицистның каләме үткен була, үзе дөньяны танып-белүдә зур эрудит, иң мөһиме, кыю характерлы булуы белән аерылып тора. Йөрәк һәм характер кичектергесез батырлык таләп иткәндә һәркемгә дә: шагыйрьгә дә, прозаикка да, драматург һәм тәнкыйтьчегә дә бу иң сугышчан жанрда үзләрен күрсәтү мөмкинлеге бирелгән. Зур эшләргә ашкыну хисе яшьләрне генә түгел, аксакалларны да, башлаган калын-калын китапларын читкәрәк куеп торып, публицистика язарга мәҗбүр итә. Моны раслау өчен газета-журналларга күз салу, радио-телевидение тапшыруларына мөрәҗәгать итү дә җитә. М. Мәһдиев, Г. Ахунов, Н. Орешина, М. Хәбибуллиннар көндәлек периодик матбугатта даими чыгыш ясап торалар. Л. Ихсанова, С. Шакир, Б. Камалов, К. Тимбикова, Р. Батулла, А. Гыйләҗевларның очерк, мәкаләләрен укучылар көтеп алалар, яратып укыйлар.

Күптән түгел әдәбиятыбыз аксакалы Р. Ишморатның җир һәм кешеләр турындагы очерклар китабы дөнья күрде. Бу куанычлы факт. Күренекле әдип Ә. Еники дә «Хәтердәге төеннәр» исемле җыентыгында очеркларга урын бирүне тиеш тапкан.

Рус әдәбияты шикелле, татар совет әдәбиятының да иң әһәмиятле үзенчәлеге шунда: ул беркайчан да күңел ачу чарасы гына булып калмады, алда торган политик, социаль һәм иҗтимагый проблемаларны ачыклауда һәм хәл итүдә халыкка, дәүләткә, җәмгыятькә һәрвакыт бик теләп булышты.

Хәзер, үткәннәрдән аермалы буларак, үткәрелгән чараларның саны түгел, китап, мәкалә, радио-телевидение чыгышларының саны да түгел, ә бәлки язучының кыю, үткен фикеренең сыйфаты аеруча әһәмиятле. Кызганычка каршы, безгә, татар публицистларына киңлек һәм тирән фикер йөртү, факт һәм күренешләрне зур фикер һәм җитди караш белән бәяләү, яңа тикшеренүләр кыюлыгы җитми. Партия, халык, дәүләт кичектергесез хәл итәргә тиешле, кешеләрне борчыган кискен проблемаларның үзәген без тиз генә таба алмыйбыз.

Бу өлкәдә үзенчәлекле бер күренеш күзәтелә. Ветераннарыбыз чыгышларына күбрәк үткәнне сагыну хас, алар гадәттә мемуар әсәрләргә тартылалар. Яшьләр исә бүгенге һәм киләчәк тормыш катлаулылыклары алдында кыюсызлар.

Безнең язучыларыбызның бәйрәм даталарына көйләнгән чыгышлары шактый. Анда авторлар үзләре язган кешеләр турында булдыра алган кадәр сүз уйнаталар. Сорау бирәсе урында еш кына өндәү билгеләре куялар, кешенең эше, хезмәттә ирешкән уңышлары турында дөресен әйтәсе яки кайбер нәрсәләрне тәнкыйтьләсе урында алар мәҗлестәге тамада кебек мактау сүзләре әйтәләр.

Публицистның югары бурычы — әдәбият, кешеләр, язучылык намусы каршындагы зур җаваплылык ул.

## Флүн Мусин

(тәнкыйть секциясе җитәкчесе)

Татарда әдәби тәнкыйть формалашып кына килгән чорда ук бөек Тукай аның «кирәкле шәйдер» икәнен яхшы аңлаган булса, безнең көннәрдә бу жанрның гомум әдәби хәрәкәттәге роле тагын да тирәнрәк күзаллана. Тар даирә белгечләр генә түгел, киң җәмәгатьчелек тә тәнкыйть белән торган саен ныграк кызыксына бара.

Партиянең соңгы съездларында, идеология мәсьәләләрен тикшергән пленумнарында, әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә багышланган карарларында тәнкыйтьнең иҗтимагый абруен үстерү турында зур кайгыртучанлык күрсәтелә. КПСС Үзәк Комитетының 1983 елгы июнь Пленумында художество иҗатына йогынты ясауның төп методы булып марксистик-ленинчыл тәнкыйть торырга тиеш дип билгеләнде.

Татарстан Язучылар союзының тәнкыйть секциясе үзенең ике съезд арасындагы эшчәнлегендә шушы бик әһәмиятле хакыйкатькә таянды. Безнең бөтен уйниятләребез һәм үткәргән чараларыбыз тәнкыйтьнең хәзерге әдәби хәрәкәттәге ролен күтәрүгә, аның бу хәрәкәттә активрак һәм нәтиҗәлерәк катнашуына ирешүгә юнәлдерелгән иде. Шушы максаттан чыгып, без секция утырышларында хәзерге әдәби үсешнең мөһим мәсьәләләрен күтәрергә тырыштык. Проза, поэзия һәм драматургиянең гомум хәле, уңыш-кимчелекләре яки аерым жанрларның торышы, үсеш тенденцияләре хакында сүз алып барылды.

Тәнкыйть фикерен активлаштыру максатында соңгы вакытта без яңа бер алымга еш мөрәҗәгать итәбез. Мин «Социалистик Татарстан» редакциясенең «түгәрәк өстәле» янында сөйләшүләр үткәрүне күздә тотам. Язучылар, тәнкыйтьчеләр, галимнәр һәм производство алдынгылары катнашында уза торган бу сөйләшүләрдә гадәттә хәзерге әдәбиятның мөһим теоретик һәм практик мәсьәләләре күтәрелә, аларга җәмәгатьчелек игътибары юнәлтелә. Әйтергә кирәк, әлеге мәсьәләләр укучылар арасында да кызыксыну уята. Секция членнары шулай ук башка әдәби сөйләшүләрдә дә актив катнашалар. Мондый чаралар тәнкыйть фикеренә йогынты ясамый калмый, әлбәттә.

Хәзерге вакытта тәнкыйтьнең фәннилегенә ирешү мөһим бурыч булып тора. Аерым әдәби фактларга һәм әсәрләргә объектив бәя бирүдән тыш, ул гомум әдәби хәрәкәтне тирәнтен күзалларга, аның үсеш тенденцияләрен һәм закончалыкларын ачыкларга, перспективаны күрә белергә тиеш. Шушы хакыйкатьне күздә тотып, без секция утырышларында әдәбият тарихын һәм агымдагы әдәби процессны өйрәнүнең мөһим теоретик һәм методологик проблемаларын тикшерәбез, тәнкыйтьчеләр һәм әдәбиятчылар игътибарын шуларга юнәлтәбез.

Шуның белән бергә, әдәби тәнкыйть заман куйган зур таләпләр югарылыгына күтәрелсен, әдәби хәрәкәттәге җаваплы ролен уңышлы башкарсын өчен бөтенесе дә эшләнә дип булмый әле. Биредә уйланасы һәм башкарасы нәрсәләр шактый. Иң әүвәл безгә бу жанрның активлыгын тагын да арттырырга, сугышчанлыгын көчәйтергә кирәк. Күп кенә яңа китаплар тәнкыйть игътибарыннан читтә кала яисә алар турында принципиаль сүз әйтелми. Матбугат битләрендә теге яки бу китапка өстән һәм күпертелгән бәя бирүләрдән дә котыла алганыбыз юк. Тәнкыйтьнең «тешсезләнү» яки аңа принципиальлек җитмәү очраклары кайвакыт язучыларга да кире тәэсир итә. Биредә мин кайбер авторларның мактауга гына күнегүләрен, тәнкыйтьне кабул итә алмауларын күздә тотам. Кызганычка каршы, соңгы вакытта мондый фактлар күбәя башлады һәм алар бик күңелсез формаларда чагылалар. Тәнкыйтьне кабул итә белмәүнең иң күңелсез нәтиҗәсе шунда ки,

андый автор үз иҗатына объектив һәм таләпчән карый алмый. Бу нәрсә ахыр чиктә аның иҗади үсешенә дә кире йогынты ясарга мөмкин.

Хәзерге тәнкыйть алдында торган тагын бик мөһим бурыч аның әдәби офыгын киңәйтүдән, фәнни анализ һәм гомумиләштерү сәләтен үстерүдән гыйбарәт. Эш шунда ки, безнең тәнкыйтьчеләр, аерым очракларны искә алмаганда, милли әдәбият кысаларында гына фикер йөртәләр, киңрәк планда, бөтенсоюз әдәбияты югарылыгыннан торып карый алмыйлар. Әдәбиятларның үзара бәйләнешләре нык үскән безнең заманда инде бу рәвешле генә фикер йөртү һич тә җитми. Үз әдәбиятың күренешләрен башкалар тәҗрибәсе белән чагыштырып өйрәнү хәзер практик ихтыяҗга әверелде. Шунсыз кайвакыт хәтта туган әдәбиятыңны да ныклап аңлый алмаска мөмкин. Икенче төрле әйткәндә, безгә бәяләү критерийларын күтәрү, камилләштерү хакында да уйланырга кирәк.

## Роберт Миңнуллин

(балалар әдәбияты секциясе җитәкчесе)

Бәхетебезгә, бүгенге көндә балалар әдәбияты зур әдәбият белән бер сафта атлап бара. Аңа булган мөнәсәбәт тә акрынлап әйбәт якка үзгәрә. Ике съезд арасында балалар әдәбияты өлкәсендә эшләүче әдипләргә ике югары бүләк тә тапшырылды. Г. Х. Андерсен исемендәге Халыкара Почетлы диплом һәм Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе. Балалар әдәбияты тарихында тагын бер зур вакыйга булды. Күптән көтелгән «Татар балалар поэзиясе антологиясе» дөнья күрде. Балалар поэзиясенең әллә ничә гасырлык хәзинәсен үз эченә алган бу уникаль басма — әдәбиятыбызның горурлыгына һәм куанычына әверелде. Балалар әдәбиятына багышланган әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә җанлану сизелә. Р. Кукушкинның 1981 елда «Шигъри бишек» исемле китабы дөнья күргән иде. Шуның дәвамы буларак күптән түгел генә «Канатлы дөнья» исемле яңа китабы чыгып җитте. Бу ике китап татар балалар поэзиясенең төп үсеш этапларын, тенденцияләрен, жанр һәм стиль үзенчәлекләрен ачыклаучы фундаменталь фәнни хезмәт. Бүгенге көндә Р. Кукушкин Мәскәүдәге «Детская литература» нәшрияты өчен «Татар балалар әдәбияты» дигән монографик хезмәт әзерли.

Өлкәннәр өчен язучы танылган әдипләребездә дә соңгы вакытта балалар дөньясы белән кызыксыну көчәйде, һәм, әйтергә кирәк, балалар әдәбиятының матур үрнәкләрен бирделәр алар. Бу күренеш, әлбәттә, элекке елларда да сизелә иде. Әйтик, Х. Туфанның «Юкмыш бабай малае», И. Гази хикәяләре, И. Юзеевның «Пони малае нәни Җирәнкәй», Г. Ахунов повестьлары... Боларга соңгы елларда Т. Миңнуллин белән Р. Харисның балалар өчен язылган пьесалары, Ә. Баянның кыска хикәяләре килеп кушылды.

Соңгы секция утырышларының берсендә без яшь шагыйрьләрнең иҗатлары белән таныштык. Күренекле әдипләр катнашында уздырылган әлеге сөйләшүдә балалар язучылары алдында торган олы бурычлар турында, балалар әдәбиятының педагогик, эстетик, әхлакый тәэсирен үстерү турында сүз барды.

Секция «Ялкын» журналы, «Яшь ленинчы» газетасы һәм Татарстан китап нәшриятының балалар-үсмерләр редакциясе белән дә тыгыз элемтәдә эшли. Мәсәлән, «Ялкын» белән берлектә уздырылган секция утырышында журналда басылып чыккан әсәрләр турында сөйләшү булды. Нәшрият белән бергәләп уздырылган утырышларның берсе балалар китабына багышланды. Татар балалар китабының бүгенге хәле, аның перспективалары турындагы җентекле сөйләшүдә язучыларыбыз үзләрен борчыган мәсьәләләрне дә күтәрделәр. Балалар китабы нинди булырга тиеш? Китапларның бизәлеше бүгенге балаларны канәгатьләндерәме? Әсәрләребезнең рус теленә тәрҗемә ителүе нинди хәлдә? Әлеге проблемаларны язучыларыбыз бик вакытлы күтәрәләр. Гомумән, бу хакта Татарстан художниклары союзы белән берлектә эшлекле сөйләшү уздырырга кирәк түгел микән?

Бездә элеграк балалар җырының артта калуы турында күп сөйләнә иде. Соңгы вакытта балалар җыры өлкәсендә җанлану сизелә башлады. Радио-телевидениедән, сәхнәләрдән балалар өчен яңа җырлар яңгырый. Татарстан композиторларының соңгы съездында да иң уңышлы концертларның берсе — балалар өчен иде. Бу үзе үк күп нәрсә турында сөйли.

Алда торган проблемаларыбыз да күп. Безне бигрәк тә балалар прозасы борчый. Бүгенге балаларның катлаулы тормышларын чагылдырган, әхлак проблемаларын күтәргән, балаларның иптәшенә, дустына әйләнерлек геройлары булган әсәрләр кирәк безгә. Язучыларга мәктәп белән элемтә дә җитми. Шуңа күрә язылган әсәрләребездән мәктәпне, классларны, пионер сборларын эзләп тә таба алмыйсың. Сәбәп нәрсәдә? Ни өчен ераклаштык? Бүгенге укучылар зур гына психологик үзгәрешләр кичергәндә, без читтән генә күзәтеп торырбызмы? Шушыларны уйлый башласаң, Г. Гобәй, Г. Мөхәммәтшин, Ф. Шәфигуллин, А. Әхмәт сагындыра башлый. Балалар өчен бүген Л. Ихсанова, А. Тимергалин, М. Хәсәнов, Ф. Яруллин яза. Соңгы вакытта балалар прозасына яшьләр килде. Алар начар да язмыйлар, ләкин яшьләр язган әсәрләрнең күбесе бер яклырак. Аерым детальләрдән, матур бизәкләрдән, вак-төяк тормыш вакыйгаларыннан гына оештырылган шикелле тәэсир кала аларны укыганда. Күп әсәрләрдәге уй-хыяллар, шатлык-борчылулар, дулкынланулар нәни геройны алга дәртләндерә алмый. Аларда пионер яки октябрят эшләре булган очракта да,ниндидер бер мәҗбүрият өчен килеп кергән шикелле. Яшь прозаиклар үз әсәрләренең вазифаларын бер яклы гына аңлыйлар түгелме? Безнең соңгы еллардагы балалар әдәбиятында уңай герой бармы? Үрнәк алырлык, һич югында сабак алырлык. Кызганыч, ике съезд арасында язылган андый әсәрләрне атавы кыен. «Татар балалар прозасы антологиясе»нең әле һаман төзелеп җитмәве дә уйландыра.

## Нонна Орешина

(рус язучылары секциясе җитәкчесе)

Бүтәннәрдән аермалы буларак, безнең секция күп жанрда иҗат итүче язучыларны берләштерә. Шуңа күрә аның эшчәнлегендә шактый гына үзенчәлек бар. Мәсәлән, без үзебезнең һәрбер утырышыбызда диярлек берәр яшь авторның кульъязмасын тикшерәбез. Аларны безгә Казандагы һәм республиканың башка зур шәһәрләрендәге, районнардагы әдәби берләшмәләр тәкъдим итә. Шул ук вакытта, әлеге әдәби берләшмәләрнең иң актив һәм иҗади яктан перспективалы членнарын үзебезнең секция утырышларында катнаштырырга тырышабыз. Бу — алар өчен бик файдалы. Яшь авторларның кульъязмаларын тәҗрибәле язучылар белән бергә яшьләрнең үзләренең дә тикшерүе аларга һәр яктан үсәргә ярдәм итә.

Соңгы елларда татар язучыларының әсәрләре рус теленә шактый күп тәрҗемә ителә башлады. Без дә үз утырышларыбызда бу тәрҗемәләрнең сыйфатына игътибар бирәбез, әлеге мәсьәләне махсус көн тәртибенә куеп тикшерәбез. Мондый очракларда инде татарча язылган әсәрнең авторы да, оригиналны яхшы белүче һәм тәрҗемәнең сыйфаты хакында төпле сүз әйтә алырдай бүтән белгечләр дә чакырыла.

Киләчәктә секция эшен ничегрәк итеп күрәсе килә?

Мин үзем хәрби-патриотик темага язучы яшь авторлар белән тагын да конкретрак һәм эшлеклерәк шөгыльләнергә кирәк дип саныйм. Һәм менә шундый бер мөмкинлек тә күрәм.

Өлкән һәм урта буын әдипләр арасында хәрби-патриотик теманың теге яки бу тармагын конкрет белүчеләр бар. Алар бик зур тәҗрибәгә ия. Безнең яшь язучыларның бу өлкәгә сәләтлеләрен нишләп әле аларга аерым-аерым беркетмәскә?! Бик яхшы шефлык эше килеп чыгар иде бит монда. Тәҗрибәле әдипләр яшьләрне хәрби-патриотик теманы ачуның бик күп серләренә өйрәтерләр иде.

Гомумән, шефлыкны тиешенчә оештыра алган тәкъдирдә — ул безнең уртак эшебезгә бик нык ярдәм итәр иде.

# Лирон Хәмидуллин

(тәрҗемә секциясе җитәкчесе)

Бүгенге көндә тәрҗемәчеләр секциясе сигез язучыны, егермедән артык башлап язучы-тәрҗемәчене берләштерә.

Ике съезд арасында Татарстан китап нәшрияты кырыклап тәрҗемә әсәр басып таратты. Ул китапларның барысы да яңа тәрҗемәләр. Күп милләтле совет әдәбияты хәзинәләренә тукталсак, бүген үз киштәбездә А. Толстой әсәрләре «Аэлита» белән «Михнәтле заман»ны (К. Миңлебаев), В. Астафьевның «Бәхилләшү» һәм «Талау» повестьларын (Т. Нурмөхәммәтов), М. Кәримнең «Озын-озак балачак», В. Распутинның «Онытма гомергә» (Н. Вәлитова), А. Лихановның «Минем генералым» (С. Сибгатуллина), А. Алексинның «Шалтыратыгыз да килегез» повестен, Ю. Бондаревның «Кайнар кар» (Я. Халитов) романын күрәбез. Язма казах әдәбиятына нигез салучыларның берсе Абай Конанбаевның шигырь һәм поэмалары, тугандаш каракалпак халкының бер гасырлык мирасына күз ташлардай «Арал дулкыннары» җыентыгы да ике съезд арасында дөнья күрделәр. Бүгенге көндә иҗат итүче казах язучыларының повестьлары тупланган «Ак дөя», чуваш хикәяләре җыентыклары да чыкты. Совет илендә яшәүче халыклар дуслыгының бер чагылышы буларак, СССР төзелүнең 60 еллыгына атап «Без яшибез совет илендә» исемле шигырь китабы да әзерләнде.

Бөек якташыбыз В. И. Ленинга багышланган зур-зур җыентыклар: «Зирәк кеше» һәм «Һәрвакыт безнең белән» басылып чыкты. Бу җыентыкларга тәрҗемәләр белән бергә татар язучыларының шигырь һәм хикәяләре дә кергән. Казанда туып үскән танылган революционер Н. Бауманның тууына йөз ун ел уңаеннан М. Новоселовның «Бауман» әсәре (В. Зәйнетдинов, Ә. Хәсәнов тәрҗемәсе) дөнья күрде.

Тәрҗемәчеләрнең тәҗрибә үрнәкләре — аерым кульъязмалар, утырышларда басылып чыккан әсәрләрнең оригиналы белән чагыштырып тикшерелде. Бу эшкә тәрҗемә мәсьәләләре белән шөгыльләнүче галимнәр тартылды. Бер утырышка Мәскәүдән СССР Язучылар союзы каршындагы Тәрҗемә советының җаваплы секретаре Вил Ганиев чакырылды.

Татар укучысы бездән ниндирәк әсәрләрнең тәрҗемә ителүен көтә соң? Әдәбиятыбызны баетырлык, әдәби офыкларыбызны киңәйтебрәк җибәрерлек нинди әйберләрне беренче чиратта эшләргә, кайсы төрләрен калдырыбрак торырга соң? Секция утырышларында, билгеле, бу хакта да күп киңәштек, күп бәхәсләштек. Утырышларның берсендә, киләчәктә тәрҗемә итсәк икән дигән өмет белән перспектив план да төзедек. Анда секция әгъзаларының ике төрле карашы да чагылыш тапкан — рус һәм чит ил классик әдәбиятына да, хәзерге заманның кызыклы шәхесләрен, вакыйгаларын эченә алган әсәрләргә дә урын бирелгән. Әлбәттә инде, милли республикаларда туып, өлгереп җиткән кайбер үзенчәлекле әдәби үрнәкләрне дә онытмаска тырыштык.

Инде тәрҗемә мәсьәләләренә кагылган иң соңгы проблема — тәрҗемә әсәргә игътибар. Бездә тәрҗемәче хезмәтен вакытында күрә белү, бәяләү гадәткә кермәгән диярлек. Дөрес, «Казан утлары» журналы Абай шигырьләре тупламасы һәм каракалпак әдәбиятына багышланган җыентык чыгу уңаеннан күләмле ике мәкалә бирде. Көндәлек матбугат битләрендә дә кечерәк күләмле мәкаләләр күренгәләде. Ә гомумән алганда, тәрҗемә эшенең торышын барларга, уңышлары белән бергә кимчелекләрен, ниһаять, юнәлешен ачыкларга булышкан зур сөйләшү әлегә булмады.

# ИЛ БЕЛӘН, ХАЛЫК БЕЛӘН

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕНЕҢ ОЕШТЫРУ ҺӘМ ИҖАТ ЭШЛӘРЕ



Татарстан Язучылар союзы 1934 елның июль аенда төзелә. Тагын берничә айдан без оешмабызның 50 еллыгын билгеләп үтәчәкбез. Табигый, мондый чакта узган юлга күз ташлыйсы, бүгенге хәлебезне элеккесе белән чагыштырып карыйсы, нәтиҗәләр ясыйсы килә.

Моннан ярты гасыр элек республиканың язучылар оешмасы егерме бер әдипне берләштергән. Татар совет язучыларының чагыштырмача аз санлы шушы беренче буыны ифрат зур һәм тарихи бурыч башкара. Язучылар миллионнарга аңлаешлы әдәби форма, чорга ярашлы сәнгать чараларын, заманга хас стиль эзлиләр — социализм төзү дәверенең үз әдәбиятын тудыру һәм үстерү өчен көрәшәләр.

Әдәбиятыбызның беренче буыны бик тә тырыш һәм эшчән, игелекле һәм озын гомерле булып чыкты. Алар ярты гасыр буе әдәби хәрәкәтне үз кулларында тоттылар, матур әдәбиятны тирәнтен аңлаучы йөз меңнәрчә укучы тәрбияләделәр. Ул чорда язылган әсәрләрнең байтагы әдәбиятыбызның алтын фондын тәшкил итә.

Хәзер безнең оешмада СССР Язучылар союзы члены булып исәпләнгән 174 әдип иҗат итә. Алар өлкән буын башлаган зур һәм җаваплы эшне, авыр һәм мактаулы миссияне уңышлы төстә алга илтәләр. Г. Бәширов, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, Х. Туфан, Ә. Еники кебек язучыларыбызның әсәрләре аша өлкән буынның — Г. Ибраһимов, Ш. Камал, К. Тинчурин, Һ. Такташ, М. Җәлилләр иҗатының уңай йогынтысы бүгенге көннәргә килеп җитте. Димәк ки, буыннар арасындагы бәйләнешләр өзелми, традицияләр дәвам итә, алар үстерелә, яңартыла бара.

Шуның белән бергә, һәр чор әдәбият-сәнгать кешеләре алдына үз таләпләрен һәм бурычларын да куя. Әдәбиятның үсеш характерын заман үзе билгели. Татар совет язучыларының беренче буыны укучыларга, хезмәт иясе массаларына *аңлаешлы* әсәрләр иҗат итүгә күп көч куйган булса, хәзер хәл шактый үзгәрде. Халкыбызның культура дәрәҗәсе күтәрелде, әдәбиятны тирәнтен аңлый һәм тоя торган укучы үсеп җитте. Язучылар алдына әнә шул укучыга, халык башкарган бөек эшләргә *лаеклы* әсәрләр иҗат итү бурычы бөтен җитдилеге белән килеп басты.

Республика язучыларының IX һәм X съездлары арасында әдәбиятыбызның идея һәм сәнгатьчә камиллеген күтәрүгә, әдәби осталык мәсьәләләренә җитди игътибар бирелде. Ил күләмендә яңгыраш алырлык, дөнья аренасына чыгарлык әсәрләр иҗат итү төп бурыч һәм иң изге максат булып торды. Соңгы еллар олы вакыйгаларга, тантаналарга бай. 1981 елның февраль ахырында Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең чираттагы XXVI съезды булып узды. Без Владимир Ильич Ленинның тууына 110 ел тулуны һәм Бөек Ватан сугышында җиңүнең 35 еллыгын билгеләп үттек, илебезнең һәм республикабызның 60 еллыгын бәйрәм иттек. Бу тарихи вакыйгалар тормышыбыз агышына тирән эз салды һәм, әлбәттә, әдәби хәрәкәткә, язучыларыбыз иҗатына да мәгълүм юнәлеш бирде. Партиябезнең XXVI съезды һәм Үзәк Комитетның шуннан соңгы Пленумнары карарлары, аерым алганда «Идеология, политик-тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы һәм «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән иҗади элемтәләре турында»гы карарлар әдәбиятыбыз үсешенә уңай йогынты ясады. Татарстан Язучылар союзындагы барлык оештыру һәм иҗат эшләре шул вакыйгаларга, шул тарихи карарларга җавап төсендә алып барылды. Әйтик, Язучылар союзы идарәсе һәм партия оешмасының

1980 елгы эшләре В. И. Ленинның тууына 110 ел, Татарстан АССР төзелүгә 60 ел тулуны, бөек җиңүнең 35 еллыгын истә тотып башкарылды. Идарә үзенең эшчәнлеген партиябезнең XXVI съезды карарларын тормышка ашыру, Азык-төлек программасын үтәү юнәлешендә алып бара, 1982 елда Язучылар союзы үткәрә торган чараларның һәммәсе диярлек СССР төзелүнең 60 еллыгына багышланган иде.

Идарә әдәбиятның тормыш белән бәйләнешен тагын да ныгытырга, язучыларның иҗат активлыгын көчәйтергә тырыша. Әдәби хәрәкәтне тагын да җанландыру максатыннан чыгып, күп төрле чаралар үткәрелде. Шуларның кайберләрен генә искә төшереп китик.

Бер ара сүрелебрәк торганнан соң, республикада яңадан әдәбият көннәре үткәрү активлашып китте. Ике съезд арасындагы биш ел вакыт эчендә республиканың 35 районында, шулай ук илебезнең 7 республика һәм өлкәсендә татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре үткәрелде. Чувашстандагы һәм Куйбышев өлкәсендәге, Татарстанның Актаныш һәм Сарман районнарында әдәбият көннәре аеруча зур хәзерлек һәм оешканлык белән узды. Казандагы культура сарайларында март-апрель айларында оештырыла торган «Казан язы» дигән әдәби-музыкаль кичәләр дә елдан-ел популярлаша бара. Хәзер Г. Тукайның туган көненә багышлап, Казан белән Арчада гына түгел, Әлмәт һәм Брежнев шәһәрендә дә, Түбән Кама һәм Алабугада да, Татарстан АЭСе төзелешендә дә һәм республиканың күп кенә башка районнарында да шигырь бәйрәмнәре үткәрелә.

Республикада тугандаш халыкларның әдәбият һәм сәнгать көннәрен оештыруга торган саен ныграк игътибар бирелә. Язучыларның IX съезды тәмамлангач та, 1979 елның 4 июленнән Татарстанда Совет әдәбияты көннәре башланды. Дуслык бәйрәмендә илнең төрле республика һәм өлкәләреннән килгән утызга якын язучы катнашты. Алар Казан, Әлмәт, Бөгелмә, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләре эшчеләре, Арча, Сарман районнары хезмәтчәннәре белән очраштылар, әдәби кичәләрдә, фәнни конференцияләрдә катнаштылар. Безнең республикада узган Совет әдәбияты көннәре тугандаш халыклар һәм әдәбиятлар дуслыгын ныгытуга зур өлеш кертте.

1980 елның җәендә Каракалпак АССРда Татарстан әдәбияты һәм сәнгате көннәре уздырылды — Аму-Дарья буйларында бер атна буе татар җырлары, татар язучыларының иң яхшы әсәрләре яңгырады. Шул ук елның декабрь аенда башкалабыз Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре зур уңыш белән үтте. 1981 елның июнь аенда Каракалпак АССР әдәбияты һәм сәнгатенең күп санлы вәкилләре безнең республикага килделәр. Каракалпак АССРдагы татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре, шулай ук Татарстандагы каракалпак әдәбияты һәм сәнгате көннәре ике тугандаш республиканың экономикасындагы, социаль прогресстагы казанышларына да үзенчәлекле смотр булды. 1981 елның октябрь аенда Ленинградта — татар әдәбияты көннәре, ә 1982 елның июль аенда Казанда Ленинград язучылары иҗатына багышланган очрашулар үткәрелде.

Географик чикләре, колачы киңәю белән бергә, әдәбият көннәренең сыйфаты да үзгәрә. Алар елдан-ел җитдирәк, эшлеклерәк төс алдылар. Хәзер әдәбият көннәренә катнашучы язучылар үз әсәрләрен уку белән генә чикләнмиләр. Очрашуларда тормышның һәм әдәбиятның иң актуаль мәсьәләләре хакында җитди фикер алышулар бара. Әйтик, Татарстанда Совет әдәбияты көннәре уздырылганда, татар язучылары һәм кунаклар катнашында фәнни-иҗади конференция дә үткәрелде. Анда КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карары яктылыгында язучыларның иҗтимагый активлыгын арттыру, әдәбиятның иң сугышчан һәм оператив саналган очерк жанрын үстерү хакында сүз барды, яшь алмаш тәрбия-

ләүгә бәйле мәсьәләләр кузгатылды. Каракалпак һәм татар язучылары, үзара очрашып, бүгенге әдәбиятның үсеш тенденцияләре, тарихи-революцион темага багышланган жанрларның торышы турында сөйләштеләр.

Ике съезд арасында республика иҗат союзларының берләштерелгән пленумнары уздырылды. Мәскәү һәм Казан галимнәре катнашында М. Горький иҗатына багышланган XX фәнни конференция (1979), Идел буе шәһәрләрендә М. Горький көннәре (1980), Казан дәүләт университетында КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»-гы мәгълүм карарының ун еллыгына багышланган конференция, «КПССның XXVI съезды карарлары яктылыгында әдәби тәнкыйтьнең актуаль мәсьәләләре» дигән темага фәнни-теоретик конференция (1981), Чаллыда, СССР төзелүнең алтмыш еллыгы уңаеннан, язучыларның «Социалистик яшәү рәвеше. Яңа калалар һәм бүгенге әдәбият» дигән темага бөтенсоюз конференциясе (1982), университетта «Әдәбият һәм сәнгатьтә сәнгатьчәлек критериенә комплекслы караш» дигән темага фәнни конференция (1983), Казанда РСФСР Язучылар союзының әдәби тәрҗемә буенча советы һәм «Современник» нәшриятының күчмә утырышы (1983), Брежнев шәһәрендә РСФСР Язучылар союзы идарәсенең яшь авторлар белән эшләү советының күчмә утырышы (1983) һәм Мәскәүдә РСФСР Язучылар союзында бүгенге татар драматургиясенә багышланган зур киңәшмә булды. Аларның һәркайсы әдәби хәрәкәткә сизелерлек өлеш кертте, аларның һәркайсын ике съезд арасындагы чорның мөһим вакыйгасы дип санарга кирәк.

Республика язучыларының IX һәм X съездлары арасындагы чор, тарихи вакыйгалардан, иҗтимагый-тарихи тантаналардан тыш, әдәби-мәдәни бәйрәмнәргә дә бай булды. Без «Казан утлары» журналының алтмыш еллыгын билгеләдек. Совет әдәбиятын үстерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм беренче саны чыга башлауга алтмыш ел тулу уңае белән журнал Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Без болгар-татар язма поэзиясенә нигез салган мәшһүр шагыйрь Кол Галинең тууына 800 ел, Н. Дурованың тууына — 200 ел, М. Акмулланың тууына — 150 ел, М. Гафури, Г. Колахметов, Х. Ямашев һәм Ш. Камалның тууларына — 100 ел; М. Җәлилнең тууына — 75 ел; Һ. Такташ, Х. Туфан, К. Нәҗми, Ә. Ерикәй, С. Әдһәмованың тууларына — 80 ел; Г. Әпсәләмовның тууына 70 ел тулуны зурлап билгеләдек; С. Радзиевскаяның —90 яшен, Г. Бәширов, Р. Ишморат һәм М. Гайнуллинның 80 яшьлекләрен, С. Хәким, Н. Арсланов, Н. Дәүли, М. Садриның 70 яшьлекләрен бәйрәм иттек. Шул уңайдан фәнни конференцияләр, төрле кичәләр үткәрелде, матбугатта тирән эчтәлекле материаллар чыкты. Язучыларыбызның иҗат бәйрәмнәрен уздыру татар әдәбиятын пропагандалау юнәлешенә борылды. Биш ел вакыт эчендә 64 язучы орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде, 35 язучыга мактаулы исем бирелде. Танылган балалар шагыйре Ш. Галиев Х. Андерсен исемендәге халыкара Почетлы диплом белән бүләкләнде. Күренекле драматургыбыз Т. Миңнуллин РСФСРның К. Станиславский исемендәге дәүләт премиясенә, А. Расих, И. Нуруллин, И. Юзеев, А. Гыйләҗев — Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясенә, Разил Вәлиев белән Р. Миңнуллин — Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясенә, М. Маликова белән К. Тимбикова республика журналистларының Х. Ямашев исемендәге премиясенә лаек булдылар.

Соңгы биш ел вакыт эчендә, очерк һәм публицистик мәкаләләр язу белән, язучыларыбыз промышленность предприятиеләрендә, колхоз-совхозларда еш рак була башладылар. 1981 елдан бирле язучыларны вакытлыча район газеталарына эшкә җибәрү гадәткә керде. Нәтиҗәдә очерк жанры активлаша төште. Республика газета-журналларында ел

саен язучылар тарафыннан язылган йөздән артык очерк һәм мәкалә басыла барды. Республика язучылары илебезнең Азык-төлек программасын тормышка ашыруга шул рәвешле өлеш керттеләр.

Оештыру эшләре иҗат мәсьәләләре белән бәйләп алып барылды. Әдипнең төп эше яңа әсәрләр язу икәнлеген идарә бер генә минутка да исеннән чыгармады. Иҗат мәсьәләләрен хәл иткәндә, без идарә каршындагы комиссия һәм секцияләрнең ярдәменә таяндык. Отчет чорында секция һәм комиссияләрнең барысы да нигездә әйбәт эшләделәр.

Әдәби хәрәкәтне җанландыруга Язучылар союзының Әлмәттәге һәм Брежневтагы сешмалары зур өлеш керттеләр. Идарә аларның эше белән даими кызыксынып, аларга җитәкчелек итеп, конкрет ярдәм күрсәтеп торды.

Язучылар союзы идарәсе «Казан утлары» журналына, шулай ук «Идел» альманахына зур игътибар бирә. Идарә утырышларында аларның эш планнары карала, әледән-әле баш редакторларның һәм бүлек мөдирләренең отчетлары тыңлана. Республика язучыларының X съездына кадәр узган биш ел вакыт эчендә журнал да альманах та эшчәнлекләрен сизелерлек яхшырттылар.

Татарстан китап нәшрияты белән дуслык элемтәләре тагын да ныгый төште. Идарә членнары, нәшриятның матур әдәбият чыгару планын төзегәндә һәм раслаганда, якыннан катнаштылар, редсовет һәм тираж комиссиясе утырышларында булдылар — шушындый юллар белән Татарстан китап нәшриятында чыга торган әдәби һәр китапның язмышын уңай хәл итәргә тырыштылар.

Ел саен безнең язучыларның 20—25 китабы Мәскәүдәге нәшриятларда дөнья күрде. Әсәрләребезне русча бастырып чыгаруда безгә «Современник», «Советская Россия» һәм «Детская литература» нәшриятлары аеруча нык ярдәм иттеләр.

Язучыларыбызның әсәрләре тугандаш халыклар һәм чит илләр телләренә дә елдан-ел күбрәк тәрҗемә ителә. Ике съезд арасында татар язучыларының 160 лап әсәре — рус телендә, 25 китабы — СССР халыклары телендә, 6 китабы чит ил телләрендә басылып чыкты.

Идарә яңа әсәрләрне газета-журнал редакцияләренә, төрле нәшриятларга тәкъдим итү белән генә түгел, яңа әсәрләр турында вакытында гыйльми тәнкыйть фикере туплау белән дә шөгыльләнде. Даими төстә әдәби ел йомгаклары уздырылды, «Казан утлары» журналының һәм «Идел» альманахының яңа саннары тикшерелде. Бу ифрат җитди эшкә тәҗрибәле тәнкыйтьчеләр дә, яшь белгечләр дә тартылды. Узган биш ел вакыт эчендә докладчылар сыйфатында 45 язучы чыгыш ясады. Һәр елны әдәби ел йомгаклары уздыру, «Казан утлары» журналының һәм «Идел» альманахының яңа саннарын тикшереп бару нәтиҗәсендә без әдәби процессны җанландыра төштек, барлык яңа әсәрләргә диярлек, үз вакытында бәя биреп баруга ирештек. Ул җыелышлар коллективтагы иҗади атмосфераның сафлануына китерде, әдәби тәнкыйтьне, аның махсус бер төре — күзәтү жанрын активлаштырып, үстереп җибәрде.

Әдәби алмаш турында кайгырту элек-электән Татарстан Язучылар союзы идарәсенең игътибар үзәгендә булып килгән. Яшьләр белән эшләүгә бездә һәрвакыт республиканың иң күренекле әдипләре катнашкан. КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы мәгълүм карарыннан соң әдәби алмаш белән эшләү яңа баскычка күтәрелде. Яшьләрнең иҗат активлыгын көчәйтү юнәлешендә конкрет чаралар күрелде, сәләтле һәм өметле яшьләрнең иҗат эшчәнлеге өчен тагын да уңайрак шартлар тудырылды.

Казанда ел саен диярлек иҗат яшьләренең республика семинарлары уздырылып килә. Комсомолның Татарстан өлкә комитеты һәм

республика иҗат союзлары оештыра торган бу семинарларга яшь язучылар, композиторлар, художниклар, архитекторлар, кинематографистлар һәм артистлар чакырыла. Семинар барган көннәрдә алар республиканың атаклы кешеләре белән очрашалар, төрле темаларга лекцияләр тыңлыйлар, иҗади бәхәсләрдә катнашалар, дөньяга карашларын киңәйтәләр, әдәби зәвыкларын нәфисләндерәләр.

Идарәнең яшь авторлар белән эшләү комиссиясе (председателе — Шәүкәт Галиев) һәм яшь авторлар белән эшләү бүлеге (мөдирләре — Илдар Юзеев белән Әхәт Мушинский) бу өлкәдә шактый бай тәҗрибә тупладылар. Аларның эзләнү колачы киңәя төште, яңа формалар, яңа алымнар табылды. Әйтик, авыл районнарында яшәүче сәләтле яшьләрнең күпчелеге республикада егермеләп әдәби берләшмәгә тупланган. Аларның эшен игътибар үзәгендә тоту максатыннан чыгып, әдәби берләшмәләргә күренекле шеф-язучылар билгеләнде. Алар, урыннарга барып, яшьләрнең кульъязмаларын тикшерүдә катнашалар, яхшы әсәрләрне матбугатка тәкъдим итәләр.

Соңгы вакытта яшь язучыларның зона конференцияләрен уздыру гадәткә кереп китте. Беренче конференция 1977 елда Апас районында булган иде. Ул шактый кызыклы һәм нәтиҗәле килеп чыкты. Шундый ук конференцияләр республиканың тагын җиде төбәгендә уздырылды. Бу чараларга Татарстандагы 38 шәһәр һәм районның яшь әдәби көчләре катнашты. Зона конференцияләре, бер яктан, ерым төбәкләрдәге яшь талантларны барлауга китерсә, икенче яктан, яшьләргә практик ярдәм дә күрсәтә. Күп кенә талантлы яшьләр СССР Язучылар союзына тәкъдим ителде, яшьләрнең кульъязма җыентыклары нәшриятка тапшырылды. 1982 елның декабренда республиканың яшь язучылары Казанга йомгаклау конференциясенә җыелдылар. Шул чагында тагын ун кеше — Язучылар союзы членлыгына, ун авторның беренче җыентыклары нәшриятка тәкъдим ителде.

1983 елның октябрь — декабрь айларында Язучылар союзының яшь авторлар белән эшләү бүлеге, Татарстан АССРның Мәгариф министрлыгы һәм ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты белән берлектә, мәктәп яшендәге авторларның зона һәм район конференцияләрен уздырган иде. Шушы елның январь урталарында Казанда аларның республика күләмендәге беренче конференциясе булды. Без моны яшь иҗат көчләре турында кайгыртуның тагын бер матур мисалыннан саныйбыз.

Кыскасы, яшьләрнең иҗат активлыгын көчәйтү юнәлешендә Язучылар союзында шактый эш башкарыла. Бездә талантлы яшь авторларның үсеп-күтәрелеп китүе өчен бөтен шартлар: даими игътибар һәм кайгыртучан мөнәсәбәт тә, аларның нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итәрлек иҗади атмосфера да, әсәрләрен дөньяга чыгарырдай мәйдан да бар. Бу урында, Татарстан Язучылар союзының яшь авторлар белән эшләү тәҗрибәсенең РСФСР Язучылар союзында һәм КПССның Татарстан өлкә комитеты бюросында каралып, уңай бәя алганлыгын да әйтергә кирәк.

Без Татарстан язучыларының чираттагы X съездына менә шушындый эшләребез, куанып сөйләрлек әсәрләребез белән килдек.

**Фәрваз МИҢНУЛЛИН,**
Татарстан Язучылар союзы идарәсенең председатель урынбасары

## Мөхәммәт Мәһдиев

# МӘҢГЕЛЕК ЯЗ

РОМАН



Адәм баласы ашыгып яши. Аны заман ашыктыра, законнар, карарлар, таләпләр ашыктыра. Ул адәм булып башта бишектә ята, әмма бик тиз генә адәмнән кеше була һәм җәмгыять кануннары буенча яшәргә тотына. Башта ул боларга каршы тора, дулый, протест белдерә... Нигә әле аны тәмле йокыдан уяталар? Нигә әле аңа тәмсез (кирәк, файдалы, имеш) ризык каптыралар, нигә әле аның беләген авырттырып яралар, кан чыгаралар — чәчәк салалар — моны да кирәк, диләр? Гел шулай. Бераздан адәм баласы күнә, тормыш кануннарына буйсына башлый, кеше булуга таба юл ала. Һәм старт алып «алдан бирелгән траектория»гә чыга. Чыктымы? Чыктыңмы? Тормыш — менә шунысы инде...

Кеше оча, оча шул траектория буенча, аның программасы бик тыгыз, ул ашыга, ул гел алга карый. Ул — бу җәмгыять, бу тарих, бу көнкүреш өчен шулкадәр кирәк, әгәр дә мәгәр, очып барышлый, туктап, бер генә минут әйләнә-тирәне күзәтсә, җәмгыятькә күпме-күпме зыян салыр иде кебек. Аның туктавы аркасында бу дөнья чылбырының бөтен рәте чуалыр, башкалар да туктар, тыгылыр, юл хезмәткәрләре теле белән әйтсәк, «бөке» ясалыр иде.

Кеше шулай яши. Шулай уйлый.

— Мин үлсәм, ничек яшәрсез икән сез? — дип карт кеше малайларына, киленнәренә кисәтү ясый.

— Мин пенсиягә чыксам, бу коллектив ничекләр итеп укмашып бара алыр? Болар ничек яшәр?

Әмма ялгышалар. Малай белән килен дә, оныклар да яшәп китә, мөнәсәбәтләр үзгәрә, әмма яшәеш тукталмый, дәвам итә. Бу — мәңгелек закон.

Соңгы елда машина рулендә үзе генә утырып йөргәндә председатель Ахияр бу турыда күп уйланды. Сәбәбе — пенсиягә китәр вакыт якынлашуы иде. Дөрес, район җитәкчелеге аңа гел әйтә килә:

— Тагын бер ун елсыз телеңә дә алма, әле синең тазалык белән салам эскерте күчереп була, — диләр.

— Шундый зур тәҗрибәң белән ял итеп ятарга оялмыйсыңмы? — дип гел кырыс сөйләшәләр.

Ләкин Ахияр авыл хуҗалыгы мәсьәләсендә генә түгел, монысында да тәҗрибәле: үз көнендә пенсиягә чыга белгән кешенең коллективта

шулкадәр абруе артып китә ки, аның, хәтта, элеккеге йомшак якларын да онытталар. Юк, Ахияр, мин киткәч болар нишләрләр икән, дип борчылып йөрмәс. Кайбер өлкәннәр кебек үзенең кирәкме яки кирәк түгелме икәнен контроль сораулар аша ачыклап та йөрмәс. Яшең житте, киттең, вәссәлам. Үзе эшләгән дәвердә «Яңа юл» колхозының идарә составыннан егерме алты ел эчендә нәкъ алты яшь кадрны югары очыртты инде ул. Кайсы председатель, кайсы совхоз директоры, кайсы партком секретаре булып күтәрелделәр. Районның кайсы почмагына барып чыкса да — үзенекеләр. Ә инде үзе урынына кадр күптәннән әзерләнә. Берәү дә, икәү дә...

Ләкин бит эш анда түгел әле. Әллә нигә менә бу язда шул турыда күп уйландыра башлады бит әле. Әллә нигә генә бу язда гомергә беррәт йомгак ясыйсы килә башлады бит әле... Нигә?.. Нәрсәгә? Язлар мәңгелек бит. Бу әле соңгы яз түгел бит...

## I

Ахиярга жиде яшь тулганда, аның әнисе фажигале төстә һәлак булды. Кафия түти — юантык, алтын тешле, көмеш калач алкалы, сәхнәдәге байбичәләр сыман бер хатын иде. Егерменче елларда ук сәүдә эшенә керешкән дә, шул һөнәрен ташлый алмады.

Кафия килен күрше-тирә авыллар белән шәһәр арасында «арадашчы» булып яшәде. Бер яктан — йомырка, май, тавык, икенче яктан — чәй, ситсы, галуш, төймә, жеп. Бер яктан — бал, гөмбә, жиләк-жимеш, мамык шәл, икенче яктан — сукно, ботинка, лампа пыяласы, күлмәкыштан резинасы, кепка... Кафия түтинең рәвеш гел шәп булды, кием яхшы, чырай якты, битләр пәрәмәч кебек. Үзе гел ашыкты, гел кабаланды. Беркайчан беркемгә тәмсез сүз әйтмәде, кешенең гозерен үтәргә тырышты, йортларына байлык та тупламады, әмма алыш-биреш итмичә яши генә алмый иде. Теге көнне дә шулай кабаланып, иртәнге пассажирскийга утырып булмасмы, дип, урман эчендәге разъездга чыгып йөгергән иде. Икеме-өчме сәгать үткәч, аучы Жәгъфәрнең үсмер малае Минһаж килеп йорт башы Гарәфи агайның капкасын какты.

— Анда разъезд урыслары сине чакыралар, Кафия апай поездга кысылган дип әйтәләр,— диде.

Малай, барысын да әйтеп бетерүдән курыккан сыман, тизрәк китеп барды.

...Төштән соң канга баткан ак жәймә капланган йөк кайтып туктады. Йорттан балаларны күрше-күлән алып чыгып китте. Тик кичен аучы Жәгъфәрләрнең сәкесендә йокыга изрәгәндә генә Ахияр ишетеп калды. Минһажның әнисе чыбылдык артында картына сөйли иде:

— Ходаем тазалык, ул ап-ак тәннәр, ул юан матур ботлар. Ул савыр итләре. Ул ап-ак матур, тулы муеннар. Ул шалкан кебек матур күкрәкләр. Ул озын толымнар...

— Ничек кысылган соң ул?— диде карты, шыгырдап әйләнеп ятып.

— Ничек кысылсын? Шул ашыгычлыгы белән. Дежур урыс бар бит әле, кызыл фуражкалы. Мөфтиев диләрме әле? Шул әйтә икән: и, дип әйтә ди, поезд туктар-туктамас аның йөгерепеп бөтерелүләре, и, дип әйтә ди, киң итәкләренә чорналып ашыгулары. Шуннан — шул. Поездның икенчеме-өченчеме вагуны итәгеннән эләктереп тә киткән, бөтереп суырып та алган. Бичараның арттан баш сөяген генә тишкән. Бүтән берни юк. Бөтен тәне ап-ак, шулкадәр матур...

Сеңелесе йоклый иде, Ахияр бу сүзләрне авыр төш буларак кабул итте. Йөрәгенә кан сауды. Йортны кара кайгы басты, йортта сүз, уенкөлке бетте.

Этисе бер ай чамасы карасына батып аш пешереп, ипи салып, мал карап йөрде дә, беркөнне сакал-мыегын рәтләп, каядыр сәфәр чыкты.

Ахияр кечкенә сеңелесе белән кичке караңгыга кадәр әтисен көтте, ишекне бикләмәгән, малларга ашарга салмаган көе сәкедәге тунга тәгәрәде. Бәләкәй кыз әллә кайчан оеган иде инде.

— Улым, кызым, торыгыз, — дигән йомшак тавышка уянып китте Ахияр. — Торыгыз. Менә мин сезгә яшь әни алып кайттым.

Ахияр күзен ачты. Кояш чыккан, кояш нуры түшәмдә уйный, йортны коймак исе баскан иде. Мич янында ялкыннан бите пәрәмәч булган юан беләкле, таза бәдәнле яшь бер хатын табагач, таба белән матавыклана. Ахиярның иң беренче уе шул булды: хәзер сикереп торырга да, әлек әнисе тоткан табагачны пычратып йөргән бу оятсыз хатынның башына шул табагач белән берне бирергә. «Чырт» итеп баш сөяге ватылсын иде бер. Аннан ул йорттан чыгып качар иде, аны беркем дә эзләп таба алмас иде... Ләкин ул айнып-торып җитә алмады.

— Шушы буламыни инде минем матур улым, — дип, юантык хатын Ахияр янына иелде дә, майлы коймак исе килеп торган йомшак куллары белән үги малайның чәчен сыпырды. Аннары арка астына йомшак җылы кулын тыгып малайны күтәрде дә шап-шоп итеп сөйде.

— Мин,— диде ул тирән елмаеп,— синең яңа әниең булам. Без дус булырбыз, улым, яме?

Малай тыштан эрсде, эчтән катты. Әтисе йортка керсп-чыгып йөри, дәшми, күзәтә генә иде.

Әмма әнисе — үз әнисе Кафия апа — болай сөйли иде: гаилә — нәкъ табигатьнең үзе кебек. Көнбагыш табагын алып карагыз. Өстеннән әллә ниләр белән уз — бер бөртек көнбагыш төшмәс. Берсен генә каезлап ал: башкалары кителеп кенә торыр. Адәм баласының тешләре дә шулай (Кафия апа тешләрен бик саклый, чөнки кечкенәдән начар тешнең нәрсә икәнен белеп үскән һәм шуңа күрәдерме, авызы тулы алтын теш иде, бәлки, шул алтын тешләре аркасындадыр, авыл киленнәре арасында гел дәрәҗәле, гел абруйлы булды); тешләрең тигез булганда — барысы да тигез. Әмма ләкин инде берсен суыртсаң, көт тә тор: шуның янындагысы да, өстәгесе дә какшар. Какшар да, төшәр дә. Кеше дә шулай. Тигез яшәгән кеше алтмышка да, сиксәнгә дә җитәр. Инде соң берсе кителсә... Тигез. яшәп өйрәнгән кеше, кителгәч, әллә кая бара алмый...

Бу фәлсәфәне яшьтән бик еш ишетеп үселгән иде.

Гарәфи агайның да хәле нәкъ шулай булды да куйды. Яшь хатын белән юньле генә тора башлауга, авырды да китте. Берәүләр көлделәр: әһә, яшь хатын китереп терәдеме? Алаймы, көчең җитмәгәнгә көчәнсәң, шулай була ул... фәлән-төгән, диделәр. Тик Ахияр боларны аңламады. Ә Гарәфи агайны көннәрнең берендә борып куйдылар: бөртек ризык капмыйча атнадан артык яткан иде.

Ахияр, шулай итеп, сеңелесе белән бергә дөм ятим калды.

Үги ананың бик әйбәтләре була. Алар турында гел яман сөйлиләр. Киресенчә, алар турында юньле сүзне күбрәк сөйләргә кирәк. Чит канга ана булырга тырыша бит ул. Мәҗбүри яратып булмый бит. Ә ул рольгә керергә, «уйнарга» тиеш. Бала исә рольгә керми, «уйнамый». Ике артистның берсе уйнап, икенчесе уйнамаса, спектакль туа алмый. Үги аналы гаиләдә әнә шуңа күрә җылы, уңай тормыш коруы бик кыен. Үги аналарны кызганырга, ихтирам итәргә кирәк.

Әмма үги аналарның бер кимчелеге була. Һәрберсендә дә. Бик гади кимчелек ул. Үги ана үги баласын уятканда беркайчан да баланың җылы, йомшак яңагыннан сөйми. Ятагыннан торып иднгә баскан үги баланың җылы гәүдәсен беркайчан да үзенең кочагына алмый. Баланың, кичтән чайкалмыйча калганлыктан, төнлә «пәри ялаган» авыз тирәсеннән, әллә нинди исләр килеп торуга да карамастан, яра-

тып бер үбеп алмый. Чөнки ул — үзенеке түгел. Әнә шул ике назны күрмәгән бала — үги бала дип атала.

Ахияр да шулай булды. Бөтен кадер-хөрмәтне күрде, әнә шул икесен күрмәде.

Ләкин утыз икенче елны колхозга читтән бер егетне председатель итеп китергәч, дөньялар, дөньяга карашлар үзгәрде. Янактан сөймәсен, сөеп уятмасын иде ул үги ана. Кочакламасын, тәмле сүз әйтмәсен иде ул. Якты чырай бирмәсен иде ул. Тик... Тик кичләрен, караңгы төшкәч, теге егет белән капка эчендә озаклап сөйләшеп тормасын иде. Ахиярның әтисе бар бит! Зиратта гына, кабердә генә бит ул! Нигә теге чибәр, таза егет белән капка эчендә озаклап сөйләшә ул? Ахияр барыбер йокламый бит. Әтисе әнә генә бит аның, авыл башында гына ята бит ул!

Ахиярны моң басты. Йөрәген телгәләп-телгәләп алган авыр хәсрәткә чыдый алмыйча ул көндезләрен, әнисе колхоз эшенә киткәч, баскыч төпләренә чыгып утыра да, җырлый иде. Ачы тавыш белән. Кат-кат бер җырны кабатлый, шуны аеруча кычкырып җырлый иде:

Агыйделне иңләп-буйлап
Йөзәсең, урдаккаем.
Бик күп хәсрәткә түздең,
Түзәрсең, йөрәккаем.

Аннары кычкырып елый иде... «Әллүки, әллүки» дип кычкыра-кычкыра чирәмдә тәгәрәп елый иде.

Ахияр бер кичне сеңелесенә хәтәр план сөйләде:

— Сеңелем,— диде ул,— Айзәрә! Мин бу йорттан качам. Ну мин теге йомры күзле председательне үтереп качам. Мин качкач син бер-ике көн күзәт. Әгәр теге мля (сеңелесе алдында аның олы кеше булып күренәсе килде) сине какмаса, яши тор. Йорт, сыер-сарык, бакча — барысы да әтинеке. Ул инде — синеке дигән сүз. Мин бер-ике ел дәшмәм. Эзләп таба алмаслар. Бер ике елдан, үскәч, мин сине алып китәрмен. Кара аны, минем турыда беркемгә берни әйтмә...

Айзәрә аңлап бетермәгән көе куркынып елады.

Малай үзенекен итте. Көзге караңгы кичләрнең берсе иде. Ахияр элекке көнне генә капка-койма аркылы ишетеп торды. Урамнан яңа председатель узып бара иде.

— Даваегыз, давай, ул нинди эш ул, пнимаетели, бу вакытта эштән кайту? Даваегыз, давай, ындыр табагына, пнимаетели! — Моңа карап, әлбәттә, берәү дә кире борылмый иде, әмма председатель ярсый бирде.

— Даваегыз, давай...

Шул вакытта, председатель узган мизгелдә генә, келт итеп капка ачылды да, аннан айның ундүртенче кичәседәй үги ана калкып чыкты. Председательнең тавышы шул мәлдә сынды, ватылды.

— Даваегыз, давай... Ниме, Факия (үги ананың исеме Ахиярның чын анасының исеменнән ике авазның урыны төрле булу белән генә аерыла иде), ниме... Иртәгә районга барам мин. Соң кайтылыр. Ниме?

Ахияр барысын да аңлады.

Ул хәтта кирәгеннән дә артыгын аңлады. Шул көннәрдә генә, очраклы рәвештә генә, күрше Шәмсениса түтинең чулак Абдул хатыны белән сөйләшкәннәрен ишеткән иде. Бала аңламаслык телдә сөйләштеләр.

— И-и, Шәмсенисатти, — диде чулак Абдул хатыны, тавышын кысып, як-ягына каранып.— Гарәфи абзый ялгышлык эшләде дә инде. Моның бит дүртенче ире, ди инде. Әле безнекенең Өчиледәге туганнары сөйләде. Бу инде Өчиледә бер картта булып кайткан икән. Аерылып киткән. Сәбәбен сораганнар икән, әйткән:

— Бүрек эләргә чөе җук, — дигән. — Туп-туры әйткән...

Ни хикмәт, кичен көтү каршы алганда Ахиярның колагына тагын бер мәртәбә шушы ике хатынның сөйләшкәне килеп керде. Һаман шул турыда, һаман чулак Абдул хатыны сөйли иде.

— И-и, Шәмсенисатти, — диде ул як-ягына каранып, тавышын кыса төшеп. — Гарәфи абзый ялгышлык эшләде дә инде. Моның бит җиткән ике баласы бар икән. Беренче ире үлгәндә бу бәхиллек сораган иреннән. Тегесе җан биреп ята, ди. Бу килгән дә тегенең янына, үзе канат белән авызына су тиерә, үзе бәхиллек сорый икән. Ни дип әйтә ди: син мине бәхиллә инде, Шәйхулла, мин, дип әйтә ди, ике бала белән калам, аның берсе күрше Гарифулладан, икенчесе хәзрәттән дип әйтә, ди...

Икенче көнне Ахияр капчык рәтләде, аңар элек урлап киптергән өч-дүрт кадак сөхари салды, бүрек, оекбаш кебек әйберләр тутырды. Капчык печәнлектә сакланды.

Менә икенче көн кич җитте. Үги ана аеруча якты чырай белән боларны ашатты, төрле кызык сүзләр сөйләде. Ахияр да сүзгә катышкан булды. Йокыга яттылар. Үги ана алгы өйдә йоклый иде. Төн җитте. Ахияр торды, киенде, түр тәрәзәне ачты. Нинди зур вакыйгалар буласын белмичә йокыга талган Айзәрәнең юрганын рәтләде дә, аның янагыннан сыпырып тәрәзәдән тышка сикерде. Өй түрендәге шомырт астында зур таш бар иде. Шул ташны капка төбәсенә менгерде. Аннан печәнлеккә барып капчыгын алып килде.

Төнге унберләр булгандыр. Капка төбәсендә утырып Ахияр инде калтырый башлаган иде. Шул вакыт Ташлытау юлыннан чатыр чабып кайткан тарантас тавышы ишетелде. Аннан ат абзарларының ишекләре ачылды. Аннан тынлык. Ахиярның йөрәге тибүенә урыс капка калтырый иде. Менә бервакыт читән буеннан кыштырдаган тавыш ишетелде. Ахияр салкын ташны кысып тотты. Капка төбәсе дер-дер килә иде. Капкага таба караңгы, күе бер шәүлә килә иде. Менә ул шәүлә Ахияр астына ук якынлашты. Менә ул капканың келәсен басты... Юк, басмады. Ахиярның йөрәге туктады да, теге таш кулдан ычкынды. Ярты пот булгандыр ул. Таш тиешле урынга төшеп җиткәндә аркасына капчык элгән Ахияр да җиргә сикерде. Һәм караңгы җылы төндә җан-фәрман чабып авылдан чыгып китте. Разъезд ерак түгел иде. Ахияр башына китермәде ул вакытта: Гәр Хутор дигән авылга бик озак еллардан соң гына әйләнеп кайтырга язган иде аңа. Теге председательгә нәрсә булган? Үги анаганиләр булган? Айзәрә ни хәлдә икән? Соликамск ягына китеп барган поездның баскычына ябышып төнге поезд җилендә башын сафландырып барган малай бу поездның кайсы шәһәргә баруын гына түгел, кайсы якка китүен дә белми иде. Дөресрәге, белергә теләми иде. Ә поезд төтен сибеп чапты да чапты. Әгәр вагон тәгәрмәчләренең такылдавы комачауламаса, Ахияр болай дип җырлар иде:

Утырмагыз машинага,
Машина алып китә ул;
Алып китеп чит җирләргә
Башны вәйран итә ул.

Җырласаң да, җырламасаң да поезд көнчыгышка — Ахияр белмәгән якка чаба иде... Ә аны кызык юллар, хикмәтле язмыш, гаҗәп хәлләр көтә иде. Яшь егет алар турында башына да китерми иде әле. Мәсәлән, берсен. Килде «куян» булып утырып, керде төзелешкә. Шәһәрнең исеме Соликамск иде. Беренче көнне үк төзелештәге егет-малайлар белән танышты. Ни хикмәт, барысы да шушы яктан киткән кешеләрнең баласы иде. Ахияр, беркатлы егет, кызыксына башлады:

— Ничек сез үзебезнең туган яктан киттегез?

Бу сорау белән ул, килгәч тә, өч-дүрт көн бик күп егетләргә мөрәҗәгать итте.

— Ничек инде сез үз теләгегез белән туган якны ташлап киттегез? Менә минем, ичмасам, сәбәбе бар.

Бер көнне ул әлеге соравына кушып бер сүз әйтте: әтиләрегез, диде, туган якны яратмаган, алар, диде, акча эзләп китканнәр. Ә тегендә — безнең якта — тормыш әлегә авыр...

Шул сүзне әйткән көннән соң Ахиярны атна буе кыйнадылар. Эш сәгате беткәндә, һәр көнне аны яңа бер егет кыйнады. Гел алмашынып. Ахияр моның сәбәбен аңламыйча җик күрде. Ниһаять, берсе, олы, алама авызлысы, әйтеп кыйнады:

— Фәлән итим,— диде ул Ахиярга берне биргәч,— кара надан! Анда авылда тик ятасыз сез! Менә сиңа шуның өчен! Әтиеңә сәлам әйт! Менә сиңа! Кулы, беләге таза булган кешегә бөек Советлар Союзында күпме эш бар! Без эшлибез и ашыйбыз! Хәерче тәреләр! Ә без — эшлибез! — Юк, Ахиярның авылында да кешеләр эшләп яши иде...

## II

...Туган ягына кайтып кергәнче Ахияр малайга әле ФЗӨ мәктәбен узарга, заводта эшләргә туры килде. Хәер, дөнья ниләр генә күрсәтмәде аңа! Иң каты сынавы — яшь-яшь көе сугышка керүе булды. Сугышта ул көн, ай исәбен югалтып торды. Нибары бер кеше — сөеклесе Айзәрә белән генә хат алышып яшәде. Көн, төн, атна, айның бәрәкәте, кадере китте — үлем гел янап торганда ничектер вакыт төшенчәсенә мөнәсәбәт үзгәрде. Шулай кырык бишенче ел җитте... Демобилизация. Аннан туган район үзәгенә кайту. Элемтә бүлеге начальнигы. Монда да вакыт йөгерде. Райондагы элемтәнең очы-кырые чуалган, телефон аппаратлары җитми, баганалар авышкан, кадрлар җитми. Элемтәче кеше генә аңлый торган бер халәт була: элемтәче өчен көн, төн, число дигән төшенчә юк. Ял көне дә юк. Чөнки хуҗалыкның төп нервысы булган элемтә белән элемтәче кешенең үз нервлары тоташып бетә...

Әмма берчак вакыт кинәт кенә туктап алды: Үзәк Комитетның 1955 ел Март пленумы карарлары нигезендә район үзәгеннән күп кенә кадрларны авыл хуҗалыгына җибәрделәр. «Утызмеңче» дигән мактаулы исем белән районның иң арттагы колхозы «Яңа юл»га килеп, надан гына председатель Сәкинәдән печатьне алганда илле бишенче елның сентябре җиткән иде. Колхозны җитәкләү буенча өч айлык стажировка узып кайткан Ахияр үзенең яшьлек дусты, сугышка бергә чыгып киткән Гыйльфан солдатның өен ачтырып керде дә, шунда яши башлады. Гыйльфанның әти-әнисе үлгән, үзе кайдадыр күмер учакларында эшләп йөри, дип сөйләделәр.

Ахияр хуҗалык эшенә авырлык белән тотынды: тыл юк иде. Хатыны Сольма бәләкәч малай Рамильне алды да шәһәргә — әти-әнисе йортына кайтып китте.

— Берәр ел эшләп кара да, шәһәргә кайтырсың,— диде.— Малайны авыл мәктәбенә бирер хәлем юк,— диде.

Ахияр беркайчан да хатын-кыз белән бәхәсләшергә ярамаганын яхшы белә иде — каршы килмәде, әмма авыр, газаплы көннәр башланганын сизде. «Вакыт» тик тора сыман тоелды аңа...

Вакыт дигән нәрсәнең конкрет сәгатьләрдән көннәргә, көннәрдән айларга әверелүен яңа председатель көзен бәрәңге алганда аңлады. Бәрәңге алу «Яңа юл»да элек-электән авырлык белән хәл ителеп килгән.

Колхозда кечкенә генә рус авылы Поник бар. Поник «Яңа юл»га Сәкинә вакытында ук кушылган, эштән күңеле кайтып, читкә таярга йөргән кешеләрдән торган хәлсез бер бригада иде. Бер елны бу брига-

даның бәрәңгесе бөтенләе белән диярлек кар астында калды. Көз буе яңгыр-кар астында бәрәңге чүпләп хатын-кыз иза чикте. Колхоз үзәге Колан Кырда, хәтта, авыз ерып, җыр да чыгардылар.

Яңгыр ява, кар ява,
Поник бәрәңге ала.
Берсен ала, берсен сала,
Берсе запаска кала.

«Запас» дигәне кар астында калуны аңлата иде. Сәкинә бу бригада кешеләре белән уртак тел таба алмады һәм каныкты: бригаданы тотып торган өердәнбер терәк — бозаулар фермасын «Яңа юл» үзәгенә күчерде. Халык эшсез калды. Югыйсә, хезмәт көненә түләү гарантияләнер алдыннан, Март пленумына бер ел кала гына иде. Эшсез калган кешеләр йорт-җирләрен сатып, сүтеп киттеләр. Авылда хәлсез карт-коры гына утырып калды. Хәер, Поникны авыл дип тә әйтерлек түгел иде инде: тәрәзәләренә такта сугылган, кычыткан-тигәнәк баскан иске мәктәп. Ямьсез булып утырып калган капка баганалары, ыржаеп утырган өй асты, баз чокырлары, өем-өем иске түбә саламнары һәм иксез-чиксез кычыткан. Дөнья гел кычытканнан, иләс-миләс өч-дүрт карчыктан һәм акылы сидрәүдән, инде үзен-үзе белмичә, татарча сөйләшә башлаган Матвей карттан тора иде. Нибары дүрт йорт һәм — кычыткан диңгезе эчендәге капка баганалары. Поник авылының, ятим калгач, каршы алган беренче җәе әнә шулай иде. Күпме оста кул, күпме механизатор бар иде бу авылда!

Шуның өстенә Сәкинә бу авыл халкының күңелен рәнҗетерлек тагын бер хата ясады: 1950 елда авыл башындагы часовняны җимерттерде. Бу эшкә яраклы кешене эзләп байтак җәфаланды ул. Моңа бер генә механизатор да риза булмады. Әмма, эзли торгач, табылды: колхоз исәбеннән алынган бер яртыга тракторчы Габдрәхим риза булды. Һәм төн уртасында кирпеч часовняны җимереп, эттереп яр астына тәгәрәтте. Икенче көнне Поник ирләре эшкә чыкмады, агачтан часовня ясадылар.

— Безнең өчен түгел, без дин тотмыйбыз, ата-бабалар төзегән әйбергә тиярга берәүнең дә хакы юк,— диделәр.

Поник — әллә нинди хикмәтле авыл иде. Утызынчы елның январь ахырында Поник мәктәбенең ике укытучысы әллә кайларга — волостьларга, кантонга, шәһәргә йөреп нинидер хикмәтле шартлаткыч алып кайттылар да, чиркәү гөмбәзен шартлатырга җыендылар. Базар көн, салкын кырыс җил исә, басу өстеннән каты кар бөртекләрен сибәрә иде. Чиркәү тирәсенә өч-дүрт авылның халкы җыелды, районнан килгән шлемлы ике-өч кеше йөгереп йөрде. Ахияр — яшь малай — бу хикмәтне карарга килде. Чиркәүгә якын торган ике йорттан бала-чага, карт-корыны чыгарып, авылның теге башына — кеше йортларына урнаштырып тордылар. Ике укытучы ир йөгереп кайнашты, чиркәү гөмбәзеннән карлы басуга шнур суздылар. Шлемлы кешеләр халыкны еракка куdылар, өч-дүрт авыл халкы кар диңгезенә чыгып таралды, басу кап-кара төрткеләр белән чуарланды. Әйттеләр: менә-менә шул шнурның башына ут төртәләр дә, шуннан соң бөтен кеше торып йөгерәсе... Һәм йөгерә дә башладылар. Әмма нәкъ шул мизгелдә бер могҗиза булды: басу өстендәге күкне каплаган ак күксел сыек болытлар эченнән юаш.кына гөрелдәү ишетелде, һәм салкын кар басуына эре-эре яңгыр тамчылары төшә башлады. Йөгерүчеләр каушап калдылар. Яңгыр чынлап ук ява иде. Халыкның январь яңгырын беренче күрүе иде. Кемнәрдер укытучы егетләргә әйттеләр: «Тимәгез, колхоз склады итәрбез, бик таза йорт бит, — диделәр. — Кирпечләре йомырка сарысы белән ябыштырылган бит...»

Укытучы егетләр шнурны өзделәр, бераздан яңгыр туктады, акрын-акрын халык та таралды. Чиркәү исән калды, хәзер аның астында склад, гөмбәз очына исә менә дигән телеантенна куеп, бөтен авыл өйләренә шуннан чыбык уздырырга кирәк булыр...

1956 елның сабантуй көннәрендә Поник авылына икс-өч гаилә кире кайтты. Сабантуйдан соң Поник авылында балта тавышы яңгырады. Бу тавыш — авылның яңадан яшәргә омтылганын белдерүче бер аваз буларак, Колан Кырга ишетелде. Татарлар җиңел сулап куйдылар: гомер иткән, алыш-биреш белән яшәгән күршеләр кайта!

Ахияр төп мәсьәлә итеп әнә шуны көн тәртибенә куйды. Идарә членнарына үпкә белдерде:

— Авыл бетерү — фашистлар эше ул, — диде. — Нигә сез күрә торып шуңа юл куйдыгыз? Ә үзегез шул хәлгә калсагыз?.. Без тегендә шуның өчен — үзебезнең авыллар бетсен өчен сугышып йөрдекмени?

Һәм Поник бригадасына сыер фермасы салырга керештеләр. Райком бу идеяне хуп күрде һәм СМУ белән сөйләшүне үз өстенә алды.

Райком тотынса, нәрсәнең булмый калганы бар соң? Ферма ун ай эчендә өлгерде. Ул җәйне-көзне Поник бригадасына Пермь, Сарапул, Соликамск, Ижевск тирәләреннән егерме гаилә кире кайтты. Мәктәпне ремонтларга, ачтырырга кирәк булды. Сентябрьнең кояшлы, җылы көне иде. Ахияр мәктәп янына килеп туктады. Кычыткан ерып ярым ябык, ярым ватык тәрәзәләр янына килде. Иске мәктәпнең бүрәнәләре җылынган, бөтен мәктәп тирәсен парлы кычыткан исе баскан иде. Ахияр тәрәзә ватыгы аша эчкә күз салды. Укытучылар бүлмәсе икән. Тушь белән ватман кәгазенә эшләнгән зур расписание сакланган: «Утверждаю. Директор школы Кондратьев». Күңелгә авыр булып китте. Идәндә глобус тәгәрәп ята, чүп-чар. Күрәсең, вак малайлар кергәләгән. Бу дөньяда ташландык мәктәп кадәр кызганыч тагын ни булыр? Кайчан гына монда балалар гөрләп торгандыр, кайчан гына бу бүлмәдә гади костюм кигән эчкерсез авыл укытучылары, алтынчы класстагы ниндидер бер Кольканың тәртибен яхшырту турында планнар корып утырганнардыр, чәчен шома тарап, артка калын толым итеп аскан сары чәчле, салмак гәүдәле марҗалар журнал, күрсәткеч таягы, акбур тотып керәп-чыгып йөргәннәрдер...

Юк, бу мәктәпне башлангыч класслар формасында гына булса да яңадан ачарга кирәк! Мәктәпсез авыл — киләчәксез авыл. Авылның мәктәбен бетерү — аңа үлемгә путевка бирү дигән сүз. Мәктәбе бетерелгән авыл яши алмый. Ул — киләчәге юк авыл.

Бер ел узуга Поник бригадасының 1—4 класс балалары үз мәктәпләренә килделәр. Авылга кыш алдыннан гына тагын биш гаилә кайтты. Кысылышып урнаштылар. Ахияр фин йортларына күп заказ биргән, һәм кайткан бер гаиләгә шундый йорт салыначак иде...

Поник бригадасында Ахияр президент дәрәҗәсендә йөрде. Авыл шулай яңадан терелде.

Поник механизаторлары «Яңа юл»ның төп кадрлары иде. Бу традицияне саклар өчен дә Ахияр күп көч куйды. Механизаторлар әзерли торган училище дирекциясе белән сөйләшеп,, Поник малайларының барысын да киң профильле механизаторлар хәзерләү бүлегенә тоткарсыз алу өчен чаралар күрде. Техника хәзер колхозның үзендә иде.

Поник бригадасындагы механизаторларның эш нәтиҗәләре һәрвакытта да Колан Кыр авылы механизаторларыныкына караганда өстенрәк, артыграк була иде. Ахияр моның белән дә кызыксынды. Дөрес, колхоз буенча беренче урында гел Кәшфи бара. Кәшфи инде республика буенча да гел алдынгы. Аны тегендә чакыралар, монда чакыралар. Кәшфи хәзер җир сөрү һөнәрен генә түгел, өстәмә профессия — речь сөйләү профессиясен дә үзләштерде. Кәшфи — башка исәптән. Әмма нигә Поник белән Колан Кыр арасында аерма бар?

Ахияр механизаторлар арасында күп булды, күп өйрәнде. Һәм аерманың сәбәбен тапты да бугай: руслар төш вакытында, сумкаларыннан ипи телеме чыгаралар да, шул телем кадәр шпигны тоз сибеп бөкләп куялар. Татарлар, бичаралар, ярты литрлы шешәдәге суынган сөтле чәй эчәләр дә, «Прибой» белән пичәтләп куялар. Бәгырең өзелерлек. Ә бит трактор эше — иң авыр хезмәт. Ир гәүдәсенә — бер телем ипи һәм суынган сөтле чәй. Бу хәлдән ничектер котылырга иде.

Идарә утырышында Ахияр карар чыгарды: Колан Кыр авылы бригадасы механизаторларына асрау өчен бушлай берәр дуңгыз баласы бирергә. Механизаторларның үзенә дә әйтте: ашатыгыз, көзгә бер центнер ит бирә ул, Поник маржаларыннан шпиг ясарга өйрәнсен хатыннарыгыз, диде. Ие шул, ие шул, дөрес, дип тыңлап утырдылар. Тик көз көне билгеле булды: хатын-кыз берәм-берәм, шыпырт кына ул дуңгыз балаларын базарга илтеп саткан. Ирләр һаман сөтле чәйдә.

Ахиярның ачуы килде һәм, идарә утырышының яңа карары нигезендә, дуңгыз балаларының бәясен механизаторларның хезмәт хакыннан тоттырып калдырды.

Әлбәттә, бу юл — мәсьәләне хәл итү түгел, Ахияр моны аңлый иде. Һәм бер ел эчендә ул колхоз үзәгенә ашханә салдыртты. Илле номерлык кечкенә телефон станциясе кайтартты. Казандагы элемтә идарәсе белән элеккеге танышлык ярдәм итте. Хәзер, колхозга кунак килсә, квартира, ашау-эчү мәсьәләләре белән Ахияр бөтенләй кызыксынмый. Ашханә көне буе эшли. Механизаторларга кырга аш илтүче штат бар. Ул — җиңел машина белән. Килгән кунаклар өчен ашханәнең аерым бүлмәсе дә бар: анда ап-ак җәймәләр (гомуми залда ак җәймә тотып булмый, шоферлар андыйны яратмый), «ЗИЛ» маркалы суыткыч, буфет, өстәлдә ак телефон. Суыткыч эчендә минераль су. Ахияр узышлый һәрвакыт шунда керә, сестра-хозяйка ул килеп туктауга алдан ук бер шешәне алып сөртеп куя. Берәр кешелек ике бүлмә (люкс!) һәм икешәр, дүртәр кешелек сигез бүлмә. Анда да дежур, юучы-чистартучы, аскы каттагы өстәлдә телефон.

Эш белән, йомыш белән «Яңа юл»га рәхәтләнеп, шатланып киләләр иде. Ахияр әнисеннән балачакта ук ишеткән бер сүзне гомер буе хәтерендә тотты:

— Капкаңнан ат өзелмәсә, казаныңнан аш өзелмәс...

Ул арада алтмышынчы еллар да килеп җитте.

Ахияр колхоз идарәсе, элемтә бүлеге, авыл советы, культура сарае, китапханә йортларын берьюлы, бердәм план буенча салдыртты. Моңа нәкъ биш ел гомер китте. Бу ансамбль каршына юкәдән аллея ясатты, бакча эченә бик күп сирень утырттылар. Хәзер машина белән килеп туктаган кешегә боларның берсе дә күренми: зур бакча, аның капкасы өстендә эре хәрефләр белән язылган: «Яңа юл» колхозы». Агач утырту буенча Колан Кырда байтак көрәш алып барырга туры килде. Халык, ни гаҗәптер, агачны кисеп утын ясарга өйрәнгән, әмма утыртырга өйрәнмәгән иде. Ахияр бу мәсьәләдә рәхимсез булды: һәркемнең өй түренә урамга чыгарып бакча ясатты, питомниктан сирень, кура, карлыган, кара миләш кайтартты, урманнан өрәңге, каен, юкә китереп аудардылар. Өй түренә бакча ясаган кешегә колхоз складыннан рәшәткә материалы бирелде. Агач утыртмаган, бакча ясамаган кешегә җәза бер генә иде: ул кешегә печән, салам һ. б. әйбер алып кайтырга машина бирелми. Бу мәсьәләдә ул бик каты булды. Агач утыртуга кирәксез, вак эш дип караган кешеләр үз артында аны «Агач Ахияр» дип йөртә башладылар.

Моңа кадәр «Яңа юл»да бер генә председательнең дә зират дип телгә алганы, анда кереп караганы юк иде. Ахияр моңа да вакыт

тапты. Зират каралмаган, агачлар сынып-авып яталар, чардуганнар чергән, авышкан, киртә-коймалар юк иде.

— Соң бит ул авыл советы карамагында, — диделәр аңа колхозның гомуми җыелышында.

— Әйе, — диде Ахияр, — адәм баласының тууы, үлүе — җәмәгать карамагында. Безнең карамакта. Мин сугыш вакытында бик күп кеше күмдем. Нинди гарасат вакытында да каберне рәтләп, өстенә язып такта куеп китәргә тырыша идек. Бу зиратта минем беркемем дә юк, әтием дә, әнием дә. Әмма анда кешеләр ята! Кешеләр! Сезгә ничек оят түгел? Менә шул: иртәгә — печәнгә төшәргә әле ике көн бар — иртәгә бөтен колхоз буенча өмә. Хәле булган бөтен кеше килә. Онытмагыз: ул йортка барыбер һәркем барачак. Әнә шуңа күрә без аны матурлап куйыйк. Авылның йөзен нәрсә билгели: зираты, коесы, чишмәсе, урамы рәтле булган авылның колхозы да алдынгы була...

Бер көн эчендә зират ялт итте — иң актив эшләүчеләрнең берсе председатель үзе иде. Аннан зиратта картлар җәй буе эшләделәр. Зират буена көз көне питомниктан китереп бер полоса сирень утыртылды. Ахияр хатын-кызны да җайлап куйды: аңа каршы әйтергә берәү дә кыючылык итми иде. Чөнки хатын-кызның гомер буе хыялланган бер эшенә игътибар күрсәтте: чишмә суы килә торган инеш өстенә кер юар өчен каралты салдырды, анда сәкеләр, эскәмияләр ясатты, тәрәзәләр куйдырды. Иң кызыгы исә шунда булды: Ахияр ел саен авыл сәхнәсендә Октябрь бәйрәменә әзерләнә торган спектакльдә үзе катнашты. Баштарак мәхәббәт героен уйнап халыкны гаҗәпләндерсә, хәзер мулла, ишан, карт рольләрендә дә уйный иде.

Поник бригадасыннан алдынгы сыер савучы Катерина авырып китте. Сугыш беткән елда тол калып, авыр эштә эшләп йончыган бу хатын врачларның иң зур игътибарына лаек иде. Ахияр чабулап аңа «Җикәнле күл» санаториесына путевка алып бирде. Җәйнең менә дигән бер көнендә, сөт сезонында, менә дигән бер савымчының чемодан күтәреп ял итәргә китүенә бераз гаҗәпләнеп караучылар да булды. Чөнки колхоз тарихында бу — беренче тапкыр иде. Шулай да Катерина китте. Ахияр аны үз машинасы белән Ташлытауга поездга озаттырды. Ә бер атнадан соң Казаннан кайтышлый «Җикәнле күл»гә килеп тә чыкты. Регистратурадан сорашып корпусын, палатасын белде дә, машина эченнән күчтәнәчләрен алып (колхоз базарыннан кыяр, помидор, алма, слива), Катерина янына китте. Керсә — палата буш. Дүрт кешелек икән. Матур гына бүлмә. Караватт башындагы табличкаларны укып чыкты. «Краморкина Катерина. Возраст — 52. Профессия — доярка. Лечение — пульсирующий душ, ежедневная прогулка до 1000 м». Мең метр... Ахияр бу хатынның биографиясен белә. Чибәр, сылу гәүдәле, матур чәчле тол хатын. Шушы төбәктә самовар төзәтеп йөрүче турында сөйләделәр. Авылга килгәч, гадәте буенча: «Самовар төзәтергә юкма-а?» — дип кычкырып йөргән. Катеринага кергән. Ирс әлегә госпитальдә ята икән. Кырык бишенче ел. Оста кул чәй эчкән, рәхмәт әйткән һәм китеп барган. Ә төн уртасында Катеринаның чолан ишеген каккан:

— Сыңар бияләем синең мич башында калган, шуны гына кереп алыйммы, — дигән.

Әмма Катеринаның ишеткәне булган: «Оста»ның тол хатыннарда самовар төзәткәч сыңар бияләй онытa торган гадәте бар икән. Катерина сыңар бияләйне аңа өйалды ишегенең песи йөри торган тишегеннән биргән.

...Ахиярның күзләре урыныннан купты. Табличканы суырып алды да (караватт никелендә нечкә тимерчыбык зыңгылдап калды) баш врач янына йөгерде. Тыны кубып барып керде. Баш врач — сылу, озын гәү-



*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

дәле, бик тә ак халат һәм крахмалда катырылган чытыр ак башлык кигән чибәр бер кыз икән. Башта Ахияр каушап калды. Чөнки ул «Главный врач» дип ишегенә пыяла табличка кадакланган бүлмә эчендә юан гәүдәле, пләш башлы, күзлекле бер карт күрермен дип уйлаган иде.

— Мин сезне тыңлыйм, — дип саф татарча елмайды кызый. Ахияр тын ала алмыйча горды.

— Ни бит, туташ... Эш бит менә болай... Минем колхоздан монда Катерина дәвалана. Уникенче корпуста.

Кыз чын күңелдән елмайды:

— Бездә бу заездда туксан процент колхозчылар.

— Юк, мине процент кызыксындырмый. Ни бит: сез аңа җәяү йөрергә дип лечение тәкъдим иткәнсез.

Кыз тагын елмайды:

— Әйе, безнең медицинада...

Ахияр калтырый башлады:

— Туташ! Медицинаны ихтирам итәм. Сезне дә иң гуманлы профессия кешесе булганыгыз өчен ихтирам итәм. Әмма мине дә тыңлагыз: Катерина гомере буе җәяү йөргән кеше. Ул җәйге утарда йөргән. Гомере буе көн саен ун чакрымнан да ким йөрмәгән ул. Ә сез аңа мең метр тәкъдим итәсез. Аның кул сөякләре сызлый. Аның биле сызлый. Гомере буе чүгәләп сыер сауган ул. Аңа аз гына ял һәм сөякләренә пиндидер дәва кирәк.

Кыз җитдиләнде. Нәрсәдер актара, эзли башлады.

— «Яңа юл»данмы? Беләбез сезнең колхозны, беләбез. Ә Краморкина мәсьәләсендә борчылмагыз. Мин аны иртәгә үзем карармын.

— Аңа грязелечение, кварцлар, тагынниләрдер кирәк түгелме?

— Мин сезнең өлкәгә кереп, сезгә, арыш чәчмәгез, аның урынына арахис чикләвеге үстерегез, дигән кебек булмыйммы соң бу?

Ахияр бер мәлгә телсез калды. Аннан тын алып:

— Минем колхозга транспорт сорап килгән баш врачка транзистор биреп җибәрү кебекме? — диде. Көлештеләр. Сүз урынлы әйтелгән иде. Баш врачның, чыннан да, үтенече бар икән:

— Сезнең колхоз пилорамасында ун фестметр агач ярдырып алып булмасмы? — дип сорады.

Ахияр бу кызга мөнәсәбәтен шундук үзгәртте. Бичара, шәһәр кызыдыр инде ул, ә менә начар завхоз туры килгән аңа, шуңа күрә ул кешеләрне дәвалыйсы урынга фестметрлар белән шөгыльләнә. Врач — һәм фестметр!

— Сез миңа Краморкинаны дәвалап, савыктырып кайтарыгыз. Ә мин — теләсәгез, бөтен «Җиканле күл» санаторийсын ярган агач белән күмә алам.

Кызый беткәнче юньле булып чыкты. Аерылганда:

— Сез мине гафу итегез. Беренче елымны эшлим, — диде. — Сезнең Катеринагызны үзем карыйм иртәгә. Мин әле яңа кеше...

Тавыш чыкмый калды, ләкин «Яңа юл» колхозы председателенең санаторийга килеп гади бер колхозчыны кайгыртып йөрүе турында шул көнне үк санаторийда матур легенда туды. Аннан ул легенда Поник бригадасына кайтып җитте.

Яфрак азык, силос әзерләү атнасында да Ахияр бөтен колхозчыны таңга калдырды. Яшел азык әзерләүдә колхоз территориясендә яшәгән бөтен кеше — укытучылар, кибетчеләр, медсестралар, ялга кайткан студентлар һәм кунаклар да катнашты. Чөнки мәҗбүри кушылмаган иде, радиодан теләгән кешеләргә катнашырга мөмкин, диделәр. Әмма иң көтелмәгәне ахырдан булды. Колхоз радиочелтәреннән беркөнне иртән болай диделәр:

— Яшел азык әзерләү буенча атналыкны уңышлы тәмамлау уңае белән иртәгә сәгать унда болында колхоздагы бөтен халыкның бергәләп ял итүе оештырыла.

«Ял итү» программасын ирләр, әлбәттә, үзләренчә баеттылар. Ахияр аларга «рәхәтләнеп ял итегез, ашагыз-эчегез» дигән иде, ирләр бу команданың соңгы сүзен зур төгәллек белән үтәделәр. Шулай да, югарыдан кушу буенча «ял итү»нең моңарчы әле булганы юк иде. «Председатель» дигән кеше халык күңелендә элек «даваегыз, давай, эшләгез» дип тукып торучы булапак кына яши иде.

Печән атнасы тәмамланганда, инде үсеп килә торган улын ияртеп, авылга Сольма кайтып төште. Ул чибәр, таза иде, ябыкча хатыннар арасыннан аны ике чакрымнан аерып алып була иде.

## III

...Ахияр теге елда Колан Кырга — «Яңа юл» үзәгенә килеп төшкән көнне үк, колхоз объектларын карап йөргән көнне үк, игътибар итте: ат абзарындагы бер бүлмәдә озын торыклы, җыйнак аяклы, озын муенлы каратуры бер ат тора. Кара маңгаенда йолдыз кашка, ни гаҗәп — дүрт аяктан берсе — бәкәл өстеннән генә терсәк буе гына — ак. Адәм баласы булса, әнисе аны күтәргәндә нәфсе кергән берәр нәрсәне ашый алмый калган да, шуның нәтиҗәсе булып миң төшкән дияр идең... Атларда да шул ук кагыйдәдер инде ул. Атның исеме — «Йолдыз», яше егерме өчтә икән. Ат өчен байтак гомер инде ул. Нигә асрыйлар, нигә сусл ит заданиесенә тапшырмыйлар?

«Йолдыз» гомере буе чабыш аты булып колхозга бик зур дан китергән икән. Аны авыр, эрсез эшкә тотмаганнар диярлек. «Йолдыз»ның төп эше — җәйге сабантуйларда чабышта катнашу һәм авылга килен алып кайту. Бу һәр ике һөнәрнең авылда нәтиҗәсе байтак. Авылда — бер Колан Кырда гына да «Йолдыз» алып кайткан егерме сигез килен бар. Бу киленнәрнең сугышта ирсез калып картайганнары, ире белән рәхәт-тигез тормыш кичергәннәре, михнәт белән яшәгәннәре һәм тагын әллә нинди язмышлылары бар. Язмышлары ничек кенә булмасын — авылдагы терлек-туар арасында алар өчен иң якыны, иң кадерлесе — «Йолдыз». Ахияр игътибар итте: чәчәкле кызыл шәлъяулык бөркәнгән, мамык шәлгә төренгән хатыннар вакыт-вакыт төенчек тотып ат абзарына киләләр. Баштарак бу хәл бик гаҗәп тоелган иде. Ахияр моны беркемнән дә сорашмыйча күзәтеп белде: «Йолдыз»га ризык илтәләр икән. Бәйрәм көнне пешергән кабартма-коймакны майламыйча, әмма кайнар көе, беренче табадан «Йолдыз»га илтәләр. Чөнки ул—аларның яшьлек таңының матур, җанлы бер шаһите. «Йолдыз» әнә шулай авылда кеше дәрәҗәсенә менгерелеп карала иде.

Ат абзарлары урнашкан чирәмлектә ялгыз бер йорт тора. Монысы — каравылчы бүлмәсе һәм өлкән ат караучының конторасы. Монда ведомостьлар, кәнсәләр счеты, кара савыты, амбар кенәгәләре. Шул бүлмәнең түрендә такта белән аерып алган, йозакка бикләнгән тагын бер бүлмә бар. «Йолдыз» музее», дип язып куелган. Моны ачтырып беренче тапкыр карарга кергәч, Ахияр таң калды. Мондый хәл бүтән бер авылда да булмас! Бүлмәнең стеналарында, пыяла шкаф эчендә, шүрлекләрдә «Йолдыз» алган призлар саклана икән. Монда медальләр төшерелгән язулы ак самавыр да, сигез телле, биш планкалы Вараксин гармуны да, көмеш поднослар, патефон, детекторлы радиоалгыч, сугыштан соңгы беренче марка радиоалгыч — «Родина-47», өчпочмаклы флаглар, бер велосипед һәм иксез-чиксез грамоталар бар иде. Монда колхозның бөтен үткән юлы язылган сыман иде. Бу тарихны халык үзе язган, үзе саклаган... Музейдан әллә нинди уйлар белән чыкты

Ахияр. Бу халык бик бай рухлы, болар белән шаярып йөрергә ярамый. Боларга юньле житәкче генә кирәк, болар юньле житәкчегә бик лаек, бик лаек! Ә син шушы бай рухлы халыкка житәкче була алырсыңмы? Син шуңа лаекмы?

«Йолдыз»ның чабышта катнашмый башлаганына өч-дүрт кенә ел икән әле.

Ахияр музейдан чыккач туп-туры ат янына керде. Шомырт кара атның зур кара ахак күзләренә җылылык йөгерде, юньле холыклы атларда гына була торган тамак тавышы белән ул яңа председательне сәламләде.

— Оһ-һы-һы, — диде.

Ахияр атның тамак астын кашыды. Инде «Йолдыз»ның рәхәтләнүен күрсәң! Ат әле куәтле, һаман гайрәтле иде. Ахияр ат караучыдан няр сорап алды да, «Йолдыз»ны абзардан алып чыкты. Һәм кырга чыккач, дымлы җәйге җилгә битен-күкрәген куйды да, йөгән сабагын бушатты. «Йолдыз», яшьлеген искә төшергәндәй, алга, җилгә каршы элдертте. Ул әллә ничек кенә, башка атларда булмаган бер хәрәкәт белән чаба иде: башта алгы ике аягын сыгылдырып чүгәләп алган сыман итә дә, кинәт зур озын сикереш ясый, шул сикереш вакытында бик җиңелдән генә арт санны суырып ала, бу вакытта атның гәүдәсе сузылып, озынаеп китә. Ахияр үз гәүдәсенең авырлыгын ат кайсы санына алганын һич чамалый алмады. Ахрысы, чапкан вакытта ат үзенең табигый осталыгы белән кеше гәүдәсенең авырлыгын югалта алу сәләтенә ирешкән. Ниндидер бер мизгелдә ат үз өстендәге авырлыкны ритм белән өскә чөя һәм бер вакытта да тулысы белән өстенә төшерми иде.

Ул көнне Ахияр гомер дә татымаган рәхәтен татыды: кырда бәрәңге чәчәге, көнбагыш чәчәге һәм билчән исе иде, җил тыгыз, баллы иде...

«Йолдыз» шулай яңа председательнең мәхәббәтен казанды. Тормышның иң борчулы вакытларында — бигрәк тә беренче елны — Ахияр гел шуңа атланып кырны әйләнеп кайта торган булды. Һәм «Йолдыз» да бу минутларны көтеп, адәм баласыдай дәртләнеп каршы ала иде.

Менә бервакыт «Йолдыз» хәлсезләнде. Бер күзенә ак та төшә башлады. Утарга чыгарганда сөртенеп бер аягының тиресен дә суйдырды. Мал врачы идарәгә килде:

— Иптәш председатель, «Йолдыз»ны суйыйк, — диде. Ахияр тетрәнеп куйды.

— Кызганыч бит. Аңа ничек кул күтәрелсен?

— Болай булса, тагы да кызганычрак.

— Яши бирсен, зыяны юк бит.

— Юк шул, яши алмый инде ул. Ул егылачак, аягын сындырачак, яки, сукыраеп җан көеге булып басып торачак. Яки, яткан урыныннан тора алмыйча, буялып, янбашлары тишелеп күз көеге булып торачак.

Ахияр авыр сулады. Фельдшер дөрес сөйли иде.

— Я, ярар, Закиржан. Ышандырдың. Ләкин бер шарт белән. Мин иртәгә районга барам. Мин югында хәл итегез. Итен дәүләт бәясеннән колхозчыларга сатарсыз, бухгалтерга әйт минем исемнән. Кара аны, мин югында булсын.

Районга китешли иртүк Ахияр «Йолдыз» янына керде. Тегесе элеккечә яратып сәламләде.

— Оһ-һы-һы, — дип кара төкле иренен Ахиярның колагына тидереп алды. Ахияр атның муеныннан сөйде дә, күзенә тыгылган яшьләрен ат сизмәсен дип куркып, кызу-кызу атлап, абзардан чыгып китте.

Пленумда утырганда да ике-өч тапкыр йөрәге ачытып, трибунадагы сүзне онытып куйды. Трибунада исә сүз житди — игеннәрне вакытында һәм югалтусыз җыеп алу турында бара, әлегә бу турыда «Сельхозтехника» директоры сөйли иде. Сүз — комбайннар, тракторлар, тагылма-

Мәңгелек яз ◆ Мөхәммәт Мәһдиев ◆

лар кебек куәтле техника турында бара, ә Ахияр борынгы заман калдыгы ат турында уйлап утыра...

Кичен идарә янында аны Закирҗан каршы алды. Ахияр аңа бер сорау да бирергә җыенмый иде. Закирҗан исә сүзне үзе башлады:

— Бөтен авылны йөреп чыктым, бер кеше дә атны суярга риза түгел, — диде ул. — Дөрес, мин аның суюын үзем суям, нү дә ләкин бит бер үзең ат егып булмый.

Идарәгә кереп, дәшми байтак утырдылар.

— Менә болай, — диде Ахияр, бу мәсьәләне онытырга тырышып. — Иртәгә атлан да, Поникка алып кит. Пониклылар суяр. Кузьмага әйтерсең. Поникта «Йолдыз»ның кем икәнен белмиләр. Итен монда кайтарып сатарсыз, Поникта алучы булмас.

Иртәгесен Закирҗан Поникка чыгып китте. Тимерче алачыгында эшләүче Кузьмага инде хәбәр ителгән иде.

Идарә яныннан арба таккан «Беларусь»лар, автомашиналар, мотоцикллар кузгалды. Колхозның гадәттәге киеренке эш көне башланып килә иде. Ахияр күпьеллык тәҗрибәдән шуны аңлады: эш иртәнге яктан ничек оештыруга карап йөри. Иртәнге якта ничек оештыру исә кичтән нинди хәзерлек күрүеңә карый — иртән уңышлы оештырылган эш көне буе уңышлы барачак эш. Бервакыт, җәйнең иң кызу эш көнендә, Ахияр болындагы әрәмәлеккә килде дә (машинаны үзе йөртә иде), су коенып, өч-дүрт сәгать ял итеп, кызынып ятты. Районнан инструктор килгән икән. Быел гына вуз бетергән егет. Бөтен кыр буйлап Ахиярны эзләгәч, узышлый гына куаклык артында председатель машинасын күреп, шунда борылды. Ахияр трусиктан гына чирәмдә кызынып ята иде. Исәнләштеләр, авыр тынлык булып алды.

Яшь инструктор әдәп белән сүз башлады.

— Менә сез мине гафу итегез, Ахияр абый,— диде.— Авыл хуҗалыгында сезнең тәҗрибә бик зур. Сезне халык та ярата, райком аппаратында да сезне ихтирам итәләр. Колхозыгыз районда беренчеләрдән. Ләкин бер сорау бирергә рөхсәт итегез: бүген сезнең кырда ун комбайн эшли. Йөк машиналарын санамадык. Күпме трактор. Ике җәйләвегездә булдым. Сез мине гафу итегез, мин бөтен җирдә бер генә сорау бирдем:

— Председателегез кайда?

Аларның барысы да беравыздан әйттеләр:

— Юк, бүген күренмәде. — Аңлыйсызмы, сезне якламыйлар. Ихтирам итәләр — ә ялган белән якламыйлар. Мин колхозларның төрлесен беләм, әле яңа кеше булсам да. Барып төшәсең, бригадирдан сорыйсың:

— Председателегез кайда?

— Менә әле генә, менә әле-әле генә, менә шушында гына иде,— дип бетерәләр, председательне «саклыйлар». Бер колхозда бухгалтер белән председатель ярдәмчесе шулай өзгәләнделәр: менә әле генә, әле генә, дип бөтерелделәр. Ә мин белә идем: председатель кичтән машинасына утырып шәһәргә китте, сеңлесенең туен уздырып йөри шәһәрдә, райкомнан рөхсәт сораган иде бер тәүлеккә. Мин юри сорадым тегеләрдән. Менә бит ничек. Ә сезнекеләр — күзләрен дә йоммыйлар, юк, күргәнебез юк, диләр.

Ахияр елмайды:

— Рәхмәт аларга, — диде. — Димәк, миңа ышаналар.

Инструктор кызды:

— Сез мине гафу итегез, Ахияр абый. Сез авыл хуҗалыгын беләсез, мин әле яшь кеше. Ялгыш сорау бирсәм, ачуланмассыз бит?

— Юк, туган, нишләп ачуланыйм. Әйдә, син инде район вәкиле буларак сөйләш. Син әйт: син, диген, иптәш Гарәфиев, диген, шушындый кызу эш өстендә ничек, нинди вөҗдан белән монда кызынып ятасың?

— Мин алай ук дип әйтергә теләмәгән идем.

— Ә шулай да шулай сорарга теләдең бит?
— Анысы шулай инде. Әйе, шулай.
— Алайса, менә нәрсә, туган: флотта болай диләр: яхшы командир кораблендә һәрчакта да була. Үзе ярдамы ул, ялдамы, курорттамы, флагман янындамы. Син нәрсә телисең? Минем менә хәзер комбайнерлар янына килеп, бункердан коелган ашлыкны учка алып, сыйфатын карап, аннан җиргә иелеп, камылның озынлыгын карап, кул изәп, комбайнерны туктатып, һәммәсенә киңәш биреп йөрүемнеме? Алар бит бу мәсьәләне миннән йөз тапкыр артыграк беләләр. Җитәкче киңәшләрен без кыш буе, яз буе, уракка төшкәнче үк бирәбез. Алар барысы да белдекле. Аннан соң, председатель киңәше белән генә эшли торган механизаторның миңа кирәге дә юк. Үз башы бар бит аның! Аннан соң, эшне шундый итеп оештырырга кирәк, мин кайда гына булсам да, ул эш барырлык булсын. Мин нигә кирәк аларга? Аннан соң: вөҗдан, намус, дисең, янәсе, кемдер эшли, кемдер ял итеп ята. Юк, мин ял итмим, туган. Менә мин уйлап ятам: Гәр Хутор бригадасында бер механизаторым' бар минем. Фронтовик. Сугышка бергә алындык.
— Габделбариевны әйтәсезме?
— Әйе, шуны. Кәшфи Габделбариев. Ике орден кавалеры. Менә шуның өендә бик тынгысыз. Малае борчый. Менә шунда мин кирәк. Бүген кич мин шунда барам. Гаилә мәсьәләсе. Мал бүлү һәм башка күңелсез эшләр. Теге, көйле комбайннарга әлегә мин кирәк түгел. Әнә Гәр Хутор бригадасындагы комбайн эштән чыккан, мин шунда кирәк. Ә Кәшфи — колхозда бер генә.
— Юк, Ахияр абый, районда, республикада.
— Менә, менә. Аңа ярдәм кирәк. Әнә мин шуны уйлап ятам...
— Шулай гаилә мәсьәләләренә кагыласызмы?
— Туры килә. Өйләнү, тормыш итү, аерылу — тегеләйме, болаймы, барысы да эшкә, хезмәткә барып тоташа. Бездә эшне ничек оештырырга өйрәтүче статьялар күп, киңәшмәләрдә дә әйтәләр, ә менә гадәттән тыш хәлләрдә ничек булырга икәнен өйрәтүче юк.
— Габделбариев гаиләсе гадәттән тышмы?
— Тышның аръягында. Шундый эшлекле нәселдән, шундый мактаулы атадан йөз процент брак туа. Ник? Моңа берәү дә әлегә җавап бирә алмый.
— Сезнең эштә көтелмәгән хәлләр булгалыймы?
— Һәр көнне. Һаман бертөсле уйласаң, бу урында ярты ел да эшли алмыйсың. Менә бер генә мисал: узган ел кыш, төн уртасы. Буран. Мин фермадан кайтам, күз ачкысыз ачы буран. Төнге дежурствоны тикшергән идем. Юлда ат сыртыннан салам төягән берәү очрый. Карак. Үзебезнең колхозчы. Уникe чакрымлы басу түреннән төяп кайта. Авылга кергәндә генә куып җиттем. Каушады. Торабыз кара-каршы. Нишләргә? Балалары җиткән, олы кызы мәктәптә пионервожатый булып эшли. Фермага бушаттырыргамы? Кеше беләчәк барыбер. Идарә янына бушаттырыргамы? Судка бирергә туры киләчәк. Кимендә, бер ел. Балалары күп. Мәктәптә әйбәт укыйлар. Алар кеше күзенә ничек күренер?
— Шулай да, нишләттегез?
— Туар атыңны, дидем. Тәртәдә түшлегең дә калмасын, дидем. Хәзер үк кайтып кит, дидем. Кайтып китте. Ул китүгә саламына ут төрттем. Чанасы-ние белән дөрләп янды. Көлен буран очырган, кар тигезләнеп киткән — иртәгесен барып карадым. Теге абзаңда шып булды. Икенче көнне пионервожатый кызы идарәгә килеп күз яшен агыза-агыза рәхмәт әйтте. Менә сиңа ситуация! Хәзер теге ничек диген? Колхозда шуннан да карусыз, намуслы кеше тагын ничәү диген!— дип сөйләде ул көнне инструкторга.

...Бүген исә йөрәк үз урынында түгел, күз гел Поник ягында иде. Идарә баскычына басып Ахияр озак тора алмады, кызу-кызу ат абзар-

ларына таба китеп барды. Һәм анда жиңел рысакны тотып атланды да, Поник юлына таба элдертте. Ялгышмады: Закирҗан «Йолдыз»га атланып акрын гына, көйгә генә бара иде, куып җитүгә, «Йолдыз» борылып Ахиярга дәште:

— Оһ-һы-һы,— диде, пошкырып борын тишекләрен чистартып алды. Закирҗан дәшмәде. Шулай рәттән атланып бардылар. Ахияр түзмәде:

— Закирҗан, ничек уйлыйсың, «Йолдыз» чаба аламы әле дә?— диде.

Закирҗан терелеп китте:

— Әйдә, сынап карыйк. Чабар төсле әле ул, әнә башны ничек күтәрде янына көндәш килгәч.

Һәм алар атларының кабыргаларына төрттеләр. Ахияр атланган рысак юл читендәге йомшакка басыбрак кына җиңел алдырып алга ыргылды. «Йолдыз», бичара, калды. Рысак аның саен дәртләнеп чаба иде. Бер чакрымнар киткәч, рысак гыжылдый башлады (аны кем чаптырып караган соң), нәкъ шул моментта артта җан тетрәткеч тавыш ишетелде:

— И-и-о-оһ!

Ахияр борылып карады: күз күреме җирдән җил уйнатып, гәүдәсен сузып-сузып кушаяклап алдырып, «Йолдыз» килә иде. Закирҗанның кепкасы очкан, ул ат ялына ябыша төшәрәк алга яткан, «Йолдыз»ның борын тишекләре йодрык сыярлык булып кызарып киңәйгән — ул җилдәй узып китте. Рысак яныннан узганда ул тагын бер тапкыр җир шарын тетрәтердәй итеп кешнәп алды.

Ахияр кычкырырга өлгерде:

— Закирҗан! Бор атыңны, бор! Бор! Булмый, туган, булмый. Моны ничекләр итеп суясың! Яшәсен, яшәсен бу...

Кире кайтканда берсе бер сүз әйтмәде, сөйләшмәделәр. Әллә икесе дә елый инде? Юктыр, ирләр еламас. Ирләр бит ул! Әмма сөйләшмәделәр.

...«Йолдыз»ны тагын ярты ел узгач кына, сөртенеп ал аягын сындыргач кына, тимерче Кузьма суйды. Тик Колан Кырдан бер генә кеше дә аның итен сатып алмады. Бер сум туксан тиеннән, диделәр. Алмадылар. Бер сум илле тиеннән, диделәр. Алучы булмады. Бушлай, күчтәнәч итеп, хуҗалык саен бишәр кило, дип радиоузелдан хәбәр иттеләр. Складка килүче булмады. Бушлай, теләгәнчә алырга мөмкин диделәр. Килүче булмады. Закирҗан кичен радиоузелдан лекция укыды, ат ите дәва ул, Франция, Голландия, Бельгия безнең илдән ат ите сатып ала, Европада тавык итеннән кыйммәтрәк ул, диде, ул — картайтмый, склерозны бетерә, дип карады — иртәгесен дә килмәделәр. Икенче көнне идарә янында да сөйләп торды, ат ите, диде, ирләрнең тонусын күтәрә ул, диде — файдасы тимәде.

...«Йолдыз»ның итен коопторгка тапшырдылар. Килосын өч сум алтмыш тиеннән.

## IV

Сольма теге елны колхозга кайтып төшкәч, ел буе үзенә эш таба алмады. Аның белгечлеге буенча колхозда эш юк иде. Идарәгә урнаштырсаң да булыр иде, билгеле, әмма Ахияр моңа бик нык каршы торды:

— Алай иткәнче, «председатель хатыны эшләми» дигән данны күтәрәм мин,— диде.

Ахияр шат, бәхетле айлар кичерде. Ул бер генә тапкыр яраткан һәм Сольмадан башка беркемне дә күңеленә кертмәгән иде. Теге вакытта авылны ошатмыйча китеп барган хатынына, ярату̇ганга күрә дә бернинди авыр сүз әйтмәде, ул елны алар икесе ике якта яшәделәр. Шәһәргә баргач, Ахияр алар янына кергәләп йөрде, ике арада салкын сугыш дәвам итте. Шулай да колхоз машинасы белән Сольмага ит, бәрәңге, кә-

бестә, кишер кебек әйберләр гел килгәләп торды. Әйе, Ахияр бер генә тапкыр яраткан иде.

Әмма теге вакытта «Җикәнле күл» санаториендагы баш врач — яшь кыз белән танышкач, Ахияр бер үзгәреп алды. Ул җәйне Ахияр шәһәргә сирәк йөрде, буш вакыты булганда машинасына утырып санаторийга чапты. Доктор кыз да, үзе дә очрашкан саен газаплы, хәсрәтле рәхәт кичерәләр иде. Доктор кыз Фирая (аны санаторийда Фира Загитовна дип йөртәләр икән) Ахияр куенында елый-елый байтак төннәр уздырды.

— Мин бит хыянәтче! Мин ике тапкыр хыянәтче,— дип елый иде ул.— Минем күрше райбольницада вәгъдә биргән кешем бар. Бергә укып бетердек. Синең улың бар. Мин шул улыңнан куркам.

Ахияр аны гел юатты:

— Соң бит минем тормыш синең белән очрашканчы ук җимерелгән иде. Мин бит улымны ташларга җыенмыйм.

Алар шулай бер-берсенә вәгъдәләр бирешмичә, алдалау кертмичә генә очраштылар, сөештеләр. Санаторий бакчасының иң читендә, карт чыршыларга терәлгән бер катлы фин йортының түрендә шулай «Газик» кунгалады. Хәер, «Газик» төн уртасында гына килә һәм санаторийда хәрәкәт башланганчы юкка чыга иде.

Ә бер көнне — очрашмыйча бик озак — ай ярым чамасы торылгач, Ахияр исеменә идарәгә хат килеп төште. Таныш кул иде, Ахияр калтыранып конвертны ачты: Фира! Җаныкаем... Синең беренче хатың бу! Мин сине никадәр сагындым. Ләкин урып-җыю вакыты бит.

«Ахияр абый!

Бу хатны алгач, синең ничек гаҗәпләнәсеңне беләм. Шулай да язарга булдым. Мин китәм, шәһәргә күчәм. Без инде синең белән беркайчан да, беркайчан да очрашмаячакбыз. Шулай булгач, мин инде бөтен әйтәсе килгән сүзләремне әйтеп бетерә алам. Мине дөрес аңла һәм гафу ит. Очрашкан вакытларда мин барыбер боларны әйтә алмас идем.

Ахияр абый, бәгырькәем! Теге вакытта Краморкина Катеринаны нигә юньләп дәваламыйсыз, дип дулап син килеп кергән минуттан минем гомеремнең икенче бер чоры башланды. Шуңар тиклесе болай гына, нәрсәгәдер әзерлек кенә булган икән. Син анда кинәт килеп кереп бүлмәне тутырдың. Юк, гәүдәң белән генә түгел (хәер, хатын-кыз синең кебек көчле ирләргә беркайчан да тыныч кына карый алмый), син үзеңнең юньлелегең, кеше кайгысын олы итеп кайгырта белүең белән бүлмәне тутырдың. Син шул вакытта: «Безнең колхоздан монда Краморкина Катерина дәвалана. Уникенче корпуста»,— дидең. Ачу белән тотындың. Синең шул тавышың мине тәмам кешелектән чыгарды. Ярабби, шундый да ягымлы, мәһабәт тавыш булыр икән. Шул секундта мин уйлап куйдым (ни арада өлгердем икән?): менә шундый ирең булсын иде дә, гел генә ачуланып торсын иде. Хатын-кыз колагы белән, ир-ат күзе белән ярата инде ул. Мин шул көнне бик күп кешеләргә рәхмәт укыдым: мине көчли-көчли медицина институтына керткән әниемә, мине, шәһәрдә калырга җыенып ятканда, елата-елата авылга җибәргән комиссия әгъзаларына, Катеринага путевка биргән профсоюз комитетына, аны начар, формально гына караган врач Прохоровка һәм, ниһаять, дөньяга сине тудырган анага рәхмәтләр әйттем. Шуңа кадәр сине белмәгән көе ничек яшәдем икән мин? Әгәр теге дөнья дөрес булса иде, анда иң беренче итеп оҗмахка сине кертерләр иде. Ни өченме? Мәхәббәтнең нәрсә икәнен дә белмичә егерме биш яшенә җиткән бер кызны бәхетле иткәнең өчен. Рәхмәт сиңа, Ахияр абый, мин бер ел буе икенче дөньяда яшәдем. Әгәр шул көнне без танышмаган булсак, мин бу дөньядан адәм баласы нинди бәхетле була ала икәнен белмичә китеп барган булыр идем. Мин тиләләрчә бәхетле булдым, мин бөтен авыруларны карадым, мин көн-төн чаптым. Безнең санаторий быел ВЦСПС-

ның Күчмә Кызыл Байрагын алды, миңа грамоталар, бүләкләр биреп бетерделәр. Алар барысы да синеке, Ахияр абый.

Инде мин китәм, ординатурага кердем. Кияүгә чыгам. Ул егет мине көтте. Мин аңа биргән вәгъдәмә турылыклы булам, ләкин аңа мин йөрәгемне бирә алмам инде. Без «язылышырга» дип вәгъдәләшкән идек, менә инде язылышабыз. Вәгъдә үтәлү шул бит инде. Мин башкасын аңа вәгъдә итмәгән идем.

Безгә барыбер аерылышырга кирәк иде синең белән, менә вакыт житте. Мин гомерем буе хыялымда синең калын көчле күкрәгеңә башымны куеп, синең аксыл көмеш керә башлаган калын чәчеңне, чәнечкеле яңакларыңны сыпырып ял итәрмен, мәңге сине сагынырмын. Ирләр халкы белеп бетерми: бу дөньяда бер генә ир дә хатын-кыз кадәр бай итеп, чын күңелдән рәхәт чигеп ярата алмый. Хуш, бәхетем, минем!

Синең бер рәсемең миндә саклана, паспортка төшкәнсең, мин аны медальон эченә тыктым. Бу — без икебез генә белгән бер сер булачак. Малай тапсам, һичшиксез, Ахияр дип исем кушачакмын. Мин синнән алда үлсәм, теге медальонны сиңа тапшырырлар. Анда минем дә шундый ук рәсемем булыр. Мәңгегә хуш, жаным минем. Ирләр ничектер, әмма хатын-кыз бер генә тапкыр бәхетле була ала. Мин бу бәхетне татыдым, инде хәзер үкенмим. Әгәр мин материалистка булмасам, көн саен бер тапкыр дога укып сиңа сәламәтлек теләр идем. Хуш, хуш!

Хат ахырында бер гайбәт сөйлим әле (мин хатын-кыз бит әле, нигә аз гына гайбәт сатмаска?). Теге вакытта Катерина сөйләде: безнең Ахиярга ди, колхозның бөтен хатын-кызлары гашыйк, ди. Яшьрәк чагым булса, мин аны үземә каратмый калмас идем, ди. Кайвакытта ул ычкынып китә, тупас сүзләр әйткәли, кычкырына да башлый, әмма хатын-кыз барысын гафу итә, чөнки аның жаны олы, ди. Катерина фермадагы бер хәлне сөйләде. Саву машинасы ватылган да, монтерны көтеп тик утыралар икән. Шунда фермага син килеп чыккансың да, сыерлар нигә савылмаган, дип жикеренә башлагансың. Бер хатын әйткән:

— Менә аппарат ватык, электромонтерны көтәбез,— дигән. Шунда син тузынып киткәнсең дә, әйтеп ташлагансың:

— Үзеңә сөт төшкәндә дә шулай машина көтеп утырасыңмы соң?— дип кычкыргансың. Хатын-кызлар оялышып читкә караганнар, аннан кул белән саварга керешкәннәр, әмма сиңа барыбер рәнжемәгәннәр, бу тупаслыгыңны гафу иткәннәр. Менә нинди куәткә ия кеше син».

Ахияр хатны укыганда Фираяның сулышын тойды. Бичара, тәмамлый алмый күпме газапланган ул. Хатны укыды, әйләндерде. Үзәк өзгеч якын сүзләр, таныш кәгазь, таныш почерк. Хаттан врачлар кабинетында гына була торган эфир исе килә иде, Ахияр күзләрен йомды. Нишләргә, нәрсә турында уйларга да, бүген нәрсә дип яшәргә?

...Кичен ул Катерина янына килде. Катеринаның озын, юан сары толымлы кызы Оля Поник мәктәбендә башлангычта укытучы иде — олы ир килеп кергәч, аналы-кызлы йөгерештеләр, маржаларча тизлек, житезлек белән салат әзерләделәр. Катерина шкаф астыннан бер шешә «Экстра» чыгарды.

Юньле, эчкерсез ике хатын-кыз янында рәхәт, жиңел булып китте...

Иртәгесен Ахияр иртүк торып фермада, механика мастерскоенда булды — аның гадәт шулай — бригадирларга кадәр үзе йөреп чыга һәм иртәнге «развод» вакытында да (армиядәге терминны ул монда да кертте), кичке сөйләшүдә дә аны беркем дә алдый алмый иде. Эш, эш, эш...

Фира шулай томан артында калды. Бераздан онытыла да башлады. Аннан Фира урынына күңелгә тагын Рамиль белән Сольма кайттылар. Аннан, күпмедер айлар узгач, Рамиль белән Сольма, чыннан да, авылга ук кайттылар.

Ахиярның ялгыз, клуб кадәрле өендә ул көнне тәрәзәләргә матур пәрдәләр эленде, чиләк-савыт шалтырады. Капка төбендәге яшел «Газик»ның өстендә дә, астында да буялып берәү рәхәт чикте: бу — Ахиярның нәкъ үзе төсле зәңгәр күзле Рамиль иде.

Катерина үз авылларында председатель өчен салынган йортта җылы, көйле тормыш башлаганга чын йөрәктән шатланды. Үзе тол калып барысын да күрде, икенче бер толларның янадан кушылуына балаларча сөенде. Тик ул көнне, ни өчендер, сәбәбен беркемгә дә әйтмичә, кичен Оленька елады. Теге кичне чәй эчеп утырганда Ахияр абыйсы аның гәрәбәдәй сары авыр толымын кулына алып болай дигән иде:

— Сеңлем! Бәхетле булсаң иде. Минем гаилә бәхетем булмады, ахрысы. Мин монда үзем гаепле бугай. Ә син бәхетле бул. Әниең синең өчен генә яши бу дөньяда. Син аны шатландыр: әйбәт кияү белән шатландыр...

Оля ул көнне дә, нигәдер, елаган иде. Югыйсә, аңа әле нибары егерме яшь иде. Егерме яшьтә кызлар елыймыни?

Күпмедер авылга ярашу газаплары кичергәч, Сольма китапханәгә урнашты. Ул акрынлап иялэнә иде, ахрысы. Бәхетле Ахияр шат булды, аз гына буш вакыты булса өйгә кайтты, узышлый гына китапханәгә керең чыга торган булды.

Ә кышның кояшка коенган, җемелдәгән карлы матур бер көнендә Ахияр аны Ташлытау больницасына илтеп куйды. Сольма юлда машина сикергән саен кычкырды, ыңгырашты. Ахияр шунда гына үзенең хатасын аңлады: кичә ул бик соң, бик арып кайткан иде. Сыер фермасында кормозапарникта авария булып, бөтен кеше — Ахияр, партком секретаре, ферма мөдире, бригадир, комсорг, монтер, тагын әллә кемнәр эт булганчы буялып, шуышып, аунап запарникны аякка бастырганнар иде, Ахияр җеп өзәр хәле калмаган көе төн уртасында өенә кайтса — Сольма тәгәрәп ята иде. Ахияр шунда әллә аңлап, әллә аңламыйча әйтте:

— Иртәгә кадәр түзеп тор инде,— диде. Һәм суык аш ашап йокыга ятты. Андый хәлдә түзеп торуның Сольма кулында түгел, бәлки дөньяга чыгарга дип «права кәчәйтә» итеп яткан яңа адәм баласында икәнен Ахияр башына да китермәде, йокыга китте. Булмаса булмый инде: барыбер йокы эләкмәде. Төнге икедә көтүче Фәхразый ишек кагып уятты. Авыл көтүчесе, гадәттә, председатель янына килергә бик яратмый. Председатель колхоз көтүчесен генә белә, шуның белән генә сөйләшә. Фәхразый машина сорады: җиденче балага тулгагы башланды, илтеп кенә кайтыйк, диде. Ахияр йокы аралаш әйтте: бар, минем исемнән куш, шофер Фәнилгә әйт, диде. Аннан тагын йокыга китте. Сольма онытылган иде... Нигә килгән инде бу Фәхразый? Йокы аралаш ул шуны уйлап интекте. Югыйсә, председатель булып килеп төшкән көнне үк утырышта, әле колхозда бер генә машина бар чагында, әйтеп куйган иде:

— Минем рөхсәттән башка колхоз машинасын ике генә очракта файдаланып була: авыру, янгын...

Ник килде бу Фәхразый?

Нәкъ сигез көннән йортка шатлык кайтты. Пычтык борынлы, касмак башлы елак кызга Резеда дип исем куштылар. Йорт иркенәеп, колхоз басулары киңәеп, ара-тирә чыгып күренгән кояш зураеп китте — бәхет бер килә башласамы?

Резедага нәкъ бер ай тулганда авыл көтүчесе Фәхразый хатыны Гасимә — председатель хатыны белән бер төнне, бер үк сәгатьтә, бер үк больницада шулай ук кыз бала тапкан Гасимә — баласын имезгәндә кинәт кычкырып җибәрде:

— Үл-ләм! Бет-тем! Бу бит Ахияр абый белән Сәлимә апа кызы! (Авыл халкы Сольманың авыр исемен шулай җиңелләштергән иде.)

Бу хәбәр шул ук көнне председатель гаиләсенә дә килеп җитте.

Сольма моны ишеткәч, башы әйләнеп, аңын югалткан сыман торды: Резеда берни белмичә тәмле итеп имә, рәхәтлектән ың-ың килә иде. Сабый! Юктыр, юктыр, ничек инде шундый гүзәл сабый кыек тешле, саргылт йонлач яңаклы, камыт аяклы Фәхразый кызы булсын! Юктыр, юктыр...

Мондый халәт, мондый шикләр кешелек җәмгыяте өчен миллион, миллиардка бер генә булуын уйлап Ахияр да, Сольма да телсез калдылар. Мондый очракта үз-үзеңне ничек тотарга икәнлеге бер китапта да язылмаган иде. Фәхразый да, Гасимә дә нәрсә эшләргә икәнен белмиләр иде. Ахияр өчен моңарчы алар тыңлаулы, әйбәт кешеләр генә иде (Гасимә — сарык караучы). Мондый хәлдә мөнәсәбәтләр ничек булырга тиеш? Ахияр бер көнне кич Фәхразыйны туктатып сөйләште. Тегесе шактый ук салмыш иде, сөйләшә торгач, йомшап китте, керле кулъяулыгы белән берөзлексез күзләрен сөртте, тавышы сыңгалап бетте.

— Ни бит, яшьти... Болай бит... Аны кем белсен инде. Медсестра ул көнне салмыш булган, ди. Искечә яңа ел бит ул. Унөченнән ундүртенә. Бутаулары мөмкин. Ни бит, яшьти. Аны хәзер ничекләр итеп алмаштырасың? Ничекләр итеп мин үз кулым белән шул матурымны — Фырадиямне — чит нигезләргә илтеп бирим? Ничекләр итеп...

Фәхразый елый иде.

Ахияр — гомер буе бу дөньяда бөтен төрле хәлләр булуы мөмкин дип яшәгән кеше — бу халәткә әзер түгел иде. Кинәт кенә аның йөрәге чәнчеп алды, күз алдыннан боҗралар йөгерде, йөрәген, тәнен курку басты. Егылам, инфаркт була дип коты чыкты. Инфаркт сүзен кешелек җәмгыятенең белә башлаганына әле күп түгел иде. 1953 елның бишенче мартында бөтен ил халкының йөрәген селкетеп Сталинның үлүе турында хәбәр бирделәр. Радио авырулар тарихында бер исем атады: инфаркт. Бу сүз шуннан бирле адәм баласының йөрәген тетрәтеп яши бирә. Ахиярда ул бер тапкыр була язган иде инде... Председатель булып эшли башлаган беренче атнасы. Элеккеге председатель Сәкинә посттан авырлык белән китте. Пичәтне, ачкычларны кара янып тапшырды. Беренче идарә утырышында ук комачау итте: үз тарафдарлары белән сүз берләшеп тегә-бу мәсьәләдә аяк чалды. Аннан һәр көнге планерка азагына идарә алдына килеп торып, аннан чыгучылардан сорашып, алай дөрес түгел, болай кирәк иде, дип коткы салып Ахиярның нервыларында уйнады. Шуның өстенә Ахияр килеп эшли башлаган җәйдә колхозда фаҗига булды. Төнге сменага укытучылар белән өлкән класс укучыларын сугуга чыгарганнар иде. Ни сәбәп беләндер, төн уртасында электр сүнде. Эш туктый. Аны-моны уйлап өлгергәнче, быел гына унынчыны тәмамлап мәктәптә лаборант итеп калдырылган бер егет трансформатор баганасына менеп тә китә. Моңа берәү дә игътибар бирми, уен-көлке сөйләшеп тик утыралар. Тик егет озак юкка чыгып торгач кына багана төбенә килеп дәшәләр. Дәшсәләр, күрәләр: ай яктысында трансформатор чыбыклары арасыннан артка кайшалып бер гәүдә асылынып тора...

Ахиярга бу фаҗига турысында иртәнге өчтә килеп әйттеләр. Төнге уникедә генә кайтып яткан иде, югыйсә. Торды, идарәгә килде. Авыл иртә уянган, фаҗигале хәлдән шомлы тынып калган иде. Менә сиңа утызменче! Сәкинә ничә ел эшләгән әнә, авылда берни дә хәвефле хәл булмаган. Ахияр башын тотып идарәдә ялгыз утырды. Аның янына керүче дә булмады, телефон да борчымады. Авыл врачлар, тикшерүче көтә иде. Өч сәгать шулай утырды. Мәктәп коллективының төнге эшкә чыгуын ул үтенгән иде. Сәкинә әнә алай эшләмәгән. Авылда әле электрның да беренче генә сезоны. Ахиярның үзе кебек.

Иртәнге җидедә идарәгә кешеләр кергәли башлады. Председатель ишеген ачып башларын тыгып караучылар да булды. Җермәделәр. Тик

җиде тулып унбиш минутта гына, почмактагы батареялы радиоалгычтан «Казан сөйли» дигән бәрхет тавыш ишетелгәндә генә, ишекне «дырт» итеп ачып шат чырайлы Сәкинә килеп керде.

— Һава хәлен ничек дип әйтер икән, бүген шәһәрдән килгән кунакларым белән урманга гөләйткә бармакчы идек, — диде.

Ахияр шул вакытта йөрәге чәнчеп алганын тойды һәм күз аллары караңгыланып идәнгә шуып төште.

Трансформатор яныннан кайтышлый врачлар машинасын ашыгыч рәвештә идарәгә бордылар. Менә ничә ел узгач тагын шул халәт...

...Алар бераздан Сольма белән бергәләп Фәхразыйларга да бардылар. Ике матур бала чат ябышып әниләрен кочаклаган килеш бер-берсенә карап тордылар. Башта көлделәр, аннан еладылар. Дүрт олы кеше бер сүз дә әйтмичә шулай аерылыштылар. Һәм шуннан соң бу мәсьәләгә кире кайтмадылар.

Авыр, газаплы көннәр, атналар, айлар узды.

Газаплы, кеше аңламаслык хәсрәтле еллар узды. Сольманың да, Гасимәнең дә йөрәгендә кан иде. Ирләр ни уйлагандыр?

Җиде ел үтте — Резеда белән Фрадия беренче класска керделәр. Мәктәпкә барганда Фрадия берни белмичә председатель капкасы яныннан уза иде, Сольма исә Резеданы киендереп, кочаклап-үбеп чоланнан озата да, тәрәзәгә йөгереп килеп теге як читтән аркасына сумка асып барган Фрадиягә карап кала. Я, алла! Тегесе дә аныкы, монысы да аныкы! Шулай, аныкылар!

Шулай газаплы көннәр узды. Сольма һәр көнне иртән үзенең кызына (үзенеке кайсысы?!) озын тәнәфестә ашарга бер алма яки бер апельсин бирә (хәзер Ахияр шәһәргә еш йөри, аннан соң, шәһәрнең үзәк ресторанны «Яңа юл» колхозыннан яшь бәрәнге, иртә өлгергән кәбестә ала, шуңа күрә, председатель, агроном, экономист өендә еш кына ысланган колбаса, кызыл балык, апельсин булуы гаҗәп түгел). Резеда ике кара толым очын тырпайтып капкадан чыгуга Фрадия белән очраша. Шунда Сольманың йөрәгенә кемдер әнә, без, пычак белән чәнчеп ала... Һәм берәр атнадан соң Сольма апельсинны да, колбаса телемен дә ике өлеш бирә башлады. Фәхразыйлар исә күп бала белән, шактый авырлык кичереп, очка-оч ялгап баралар иде. Фрадиянең киемнәре дә председатель кызыныкына караганда шактый тыйнак, тонык иде. Бер ай үтте, ике ай үтте, өч ай. Кышкы суыклар башланды, Резеда ак мех белән бизәп эшләнгән калын кара тун киде, Фрадия исә кыршылган юка көзге пальто белән йөри иде. Менә салкын бер көнне ике бала кызу-кызу атлап мәктәптән кайтып киләләр, икесенең дә авызларыннан пар чыга. Тик мич томалап, мичкә чыжылдатып ит бәлеше куйган Сольма тәрәзә аркылы күреп алды: кызыл, тук битле Резедадан пар юан ак көлтә булып, бөркелеп чыга, ә Фрадиядән сизелер-сизелмәс кенә, авыз тирәсендә бөтерелеп кенә чыга иде. Сольма түзә алмады, яланөс урамга чыгып йөгерде дә, ике баланы берьюлы этеп-төртеп капкадан кертеп җибәрде һәм йортка ашыктырды.

— Һай, балакайлар, нигә мондый көнне укыталар икән сезне, өшегәнсез бит, — диде.

Фрадиянең бу йортка беренче аяк басуы иде. Сольма балаларның икесен дә тиз генә чишендерде, үзе гадәттән тыш каушады. Чишендергән вакытта сизеп алды: аның ни өчендер, кысып-кысып Фрадияне кочаклыйсы килде, әллә ничә тапкыр аның ябык аркасыннан сөеп алды. Резеда шатланып та, әнисенең гадәттән тыш бу җиңеллегенә гаҗәпләнеп тә карады. Сольма исә аның саен каушады:

— Әйдәгез, балакайлар, кулларыгызны юыгыз да, өстәл янына утырыгыз, — диде. — Хәзер, сез килеп утырганчы мин бәлешне алам.

Шунда әллә ни генә булды. Бер секундта, юк, алай озак арада ту-

гел. Секундның уннан бер өлешендә. Юк, йөздән берендә. Югыйсә, балалар килеп кергәч тә Сольманың бөтен теләге бер генә иде:

— Ярабби ходаем,— дип үз гомерендә үзе белмәгән, моңарчы исенә дә кертеп карамаган алланы телгә алды ул, — ярабби ходаем, шушы баланың Фәхразыйлар баласы икәнлегенә ышансам иде, минем күңелемне кузгатмасын иде, шигем бетсен иде, мин дә бер тынычлап бала үстерер идем...

Дип уйлап та бетерә алмады. Кинәт... аның күзе баланың колак артына төште. Фрадиянең йомшак чәч белән капланган, инде җылынып өлгергән алсу тиресендә нәкъ җидегән йолдыз чүмече кебек урнашкан вак-вак дүрт миңе бар иде. Әйе, бу миңнәр Ахиярдан, бары тик анықы гына иде. Сольма тыны буылудан кисėлеп диванга ауды.

— Ән-нием!— дип чырылдап кычкырды Резеда һәм йөгереп килеп әнисенең битен кочаклап алды. Әнисе исә тын алуга йорт эчен селкетеп елап җибәрде. Куркынып калган сабыйлар берсүзсез басып тордылар. Сольма диван, идән селкетеп елый, кулларын мендәргә бәрә-бәрә елый иде. Бәлеш чыжылдавы һаман көчәйде, бераздан Фрадия иплəп кенә киенде дә, кайтып китте...

Ул көнне Ахияр да бәлешне кабып карамады.

Икенче көнне балалар мәктәптә вакытта, алар бергәләп Фәхразыйларга килделәр. Ирләр дәшмәде, ах та ух килделәр, тик Сольма гына елады:

— Икесен дә карыйбыз, апа җаным, Фрадиямне кайтарып бир, — диде. — Теләсәң, икесен дә карыйбыз.

Фәхразый хатыны да шиккә калды.

— Ризидә минеке булып иялəнә алырмы икән соң,— диде.— Ничекләр итеп иялəнер икән алар? — дип елады.

Аннан ике көн узгач балаларны алмаштылар. Һәр ике йорт мәет чыккандай кара кайгыга батты. Югыйсә, шатланыр өчен дип эшләнгән иде.

Аннан ел буе, урамнан Резеда узган саен Сольма елап кала торган булды. Аннан җәй җиткәч, җәй буена дип балаларын төяп шәһәргә китте. Мондый тетрәнүләрдән соң ул инде эшләми, йортта гына тора иде.

Ул җәйне Ахиярның чәчләре агарып, нык кына олаеп куйды.

Бала — бәла, диләр. Әмма боларның гаиләләрендә балалар әлегә бәла китермәгәннәр, тик газап кына китергәннәр иде.

Кем белә? Балаларда гаеп юк бит! Аналар үзләре ни караган соң? Ул дүрт миң теге вакытта ук булгандыр бит инде?

Сольма хәзер гел шул турыда уйлап газап чигә, картая...

## V

Августның егермесе җитте, яңгыр һаман күренмәде. Халык кәефсезләнде: урам буендагы тупыл яфракларына авыр тузан утырды, дөньяда күләгә бетте. Чык төшмәде. Югыйсә, иртәгә аяз буласы көтелгәндә, кичтән чык төшә иде. Җирнең җене кипте.

Сугыш узган өлкәннәр кичләрен капка төпләрендә сөйләшеп утырды. Бер көнне арадан берсе әйтә куйды:

— Егерме беренче елгы хәл була инде быел.

Аны кемдер тынычландырды:

— Хөкүмәт ач итми лә ул, тик минә дөньяның яме юк. Яшисе килми.

Арада сүз алып баручы — аксак Мәгыйзь иде. Мәгыйзь — колхоз бухгалтеры, авызында һәрвакыт төпчек. Җиде баласы бар.

— Менәтерәк, хәзер ачлык булмый, — ди ул. — Чөнки, безнең ил — социалистик.

— Аның анысын мәнди анасы да белә, — дип бүлде аны Хәсән

карт.— Кырык алты, кырык жиденче елларда социалистик түгел идекмени? Һы-ы... Оныттың мыни ат кузгалагы ашап халыкның ни иза чиккәнен? Утыз алтынчы елны атлар ачтан кырылды, ул вакытта капиталистикмыни?
Мәгыйзь сүнгән төпчеген яңарта, тамак кыра.
— Политикадан бик артта калгансың син, күрше. Утыз алтынчы елгысы нәрсәдән килеп чыкты? Колхоз — яңа күренеш иде, рәтенә төшеп бетермәделәр. Ашлама кертелми, председатель, агроном — белемсез. Чәчү әйләнешен мәҗбүри керттеләр, җиренә карап чәчү бетте.
Хәсән карт һаман каршы:
— Ә югарыда нәрсә караганнар?
— Югарыдан курс дөрес бирелгән. Әмма Сталин бөтенесен үзем хәл итәм дип инициативаны кысып бетергән. Утыз алтынчы ел безгә зур сабак булды.
Хәсән карт бирешми:
— Алайса, кырык жиде?
— Анысы да очраклы түгел. Икмәк амбары булган Украина сугыш вакытында кайда калган иде? Аны бер елда гына рәтләп буламы?
— Ул гына туйдырганмыни Рәсәйне?
— Рәсәйнең икмәк амбары икәү генә иде. Украина и һәм дә Идел буе өлкәләре. Төньяктан алып Саратов, Куйбышевка кадәр. Менә кырык жиденче ел кояшы шуңа бәрде инде.
— Хәзер дә шушы безнең якны яндыра...
— Ә безнең өченче — төп амбар бар хәзер. Чирәм җир. Кояш быел аны яндырмый. Өчесен берьюлы яндыра алмый ул аның. Күрдеңме, партиянең икмәк политикасын? Өмет өзмә, ач булмыйбыз.
Хәсән карт ризалаша. Җиде балалы Мәгыйзь ач булмыйбыз, дип торгач, карчыгы белән ялгыз яшәүче Хәсән картка нәрсә кирәк? Әңгәмә тынычлана төшә.
— Әле болай гына әйтүем. Халык өчен кайгыртып. Карчык белән безгә нәрсә? Ашка саласы тоз түгел, кияүгә барасы кыз түгел. Безнең пинсә житә. Картларның нәрсә инде? Туе узган, кием тузган...
Мәгыйзь яңа папирос кабыза.
— Менә сугыш башланганда ни хәлдә икәнне белегез инде шуннан: Украина яна, Чирәм жир әле юк. Фронтка икмәкне кем бирә? Идел буе, Урта Россия. Сөйләгәнем бармы: Гитлерның безгә бәреп кергәнен ишеткәч, Черчилль телеграмм суга Сталинга. Шулай, шулай, ди, мин ди сезнең нинди авыр хәлдә калганыгызны беләм, ди, нишлим соң, әлегә бер ярдәм дә итә алмыйм, ди. Мин, ди, алламнан (ә англичаннарның алласы бөтенләй икенче) сезгә ярдәм итүен сорап дога укыйм.
— Һе, кара син аны, ә? Үзе патша кеше, үзе намаз укый диген, ә? Үзләренчә инде, ә?Аларның да кыйбла бар диген, ә?
— Ие, шулай, дога укыйм, дигән.
Галошларын өстерәп бүрәнә өстенә тагын бер-ике ир килеп утырды. Барысы да Мәгыйзьнең авызына карап тын калдылар. Мәгыйзь юри суздьы, тагын озаклап кына утын яңартты, тәтенне тирән йотты. Хәсән карт түзмәде:
— Безнеке, безнеке нәрсә дип җавап биргән?
— Безнеке болай дигән...— Ул арада кемнеңдер тез өстендәге малаe аваз салды, ата кеше аның муен тамырына бөрне биреп тә алды, момент бик киеренке иде.
— Безнеке әйткән (тәтенне озаклап чыгарып). Болай дигән (юри тагын бер суырып): әгәр дә мәгәр, дигән, син самам диле безгә ярдәм күрсәтсәң килә икән, әйдә, дигән үзегезнең алладан сора...
Мәгыйзь шул урында туктап шырпы сызды.
— Ну, шушы Казан фабрикасын әйтерием инде, «Беломор»ны тәки боздылар бит. Ленинградның Урицкий фабрикасына чыкмый инде.

Дөрес әйтәләр шул: КТФ нәрсә дигән сүз? Болай караганда — Казанская табачная фабрика. Әнә, танысаң укы — Мәгыйзь пачкасын Хәсән картның күзенә якын китерде. — Инде күршең синең Урицкийныкын тарта икән, ул инде болай укыла: Кешенекен Тарту Файдалы. Менә шулай. Әле нәрсәдә туктап калган идек?

Хәсән карт ыңгыраша:

— Безнеке, безнеке нәрсә дип җавап биргән?

— Кемгә? — Мәгыйзь әсәренеп торган булды.

— Кемгә, кемгә? Англия патшасына...

— Ә-ә-ә.. Ул болай дигән: әгәр дә мәгәр дигән, син самам диле безгә ярдәм күрсәтәсең килә икән, әйдә, дигән, үзегезнең алладан сора...

Нәкъ шул секундта теге борчулы малайның колак төбенә тагын эләкте, чөнки нәкъ шул мизгелдә ул, сөт күп эчкәннәнме, әллә борчаклы аш ашап чыкканмы, киреаксез бер аваз чыгарды, аңа бөтен кеше нәфрәт белән карады, әмма Мәгыйзь бу юлы халыкны кызганды, сөйләп бетерде:

— Әйдә, дигән бу, безнеке, ызначит, иптәш Сталинның үзе, — әйдә, дигән үзегезнең алладан май-июнь аена Идел буена ике яңгыр сора...

Тыңлаучылар җиңел сулап куйды. Ике тапкыр яңак-колак тирәсенә алган бумази ыштанлы малай да рәхәтләнеп елап җибәрде. Сүзнең, әңгәмәнең тәмен сеңдереп, берәр минут тын утырдылар. Тынлыкны Хәсән карт бозды:

— И-и-и... Шулай дип әйткән, ә? Ну баш та булган инде үзендә дә.

— Кәнишне! — Мәгыйзь бәхетле иде. — Соравына күрә — җавабы; садакасына күрә — савабы. Безнеке бик дөрес әйткән: ни өчен шундук Гитлерга каршы сугыш ачмый ул? Алладан сорыйм... Аны мин дә сорыйм. Ну бит алла бөтен сораганны үтәп утыра алмый ул. Алайга китсә ул, Черчилльнең үз алласы, Хәсән картның үзенеке. Кем кемне тыңлап бетерә ала? Менә мин сугыштан кайткан елны...

Колан Кыр бик яхшы хәтерли Мәгыйзьнең сугыштан кайтып төшкәнен. 1947 елның июне, аяк астында үлән янган көннәр иде. Сулыш кысыла, һавада кислород юк, күе-чишмә сулары җылынган сыман иде. Авылда ачлык хуҗа һәм Сәкинә хуҗа. Мәгыйзь төнлә кайтты, кинәт, хәбәрсез кайтты. Әнисе исән, кырык беренче — кырык икенченең кышында Идел буенда оборона эшендә булган сеңлесе шул елда чирләп хәзер ян сәкедә сөяккә калып ята иде — өйдә шатлык юк. Мәгыйзь төн эчендә әнисеннән бөтен авыл хәлләрен сөйләтте. Сәкинә ничек итеп үз өендә колхоз сыерын тота; күрше Мәсгуть ничек итеп Кесмәс аръягына һәр кич торып чаба, әмма электән килгән гадәт буенча, Кесмәснең бу ягына теге кызны әтиләре бирми; кладовщик Рәхмәт ничек итеп төннәрен амбарны ача да, бәрәңге бакчасы башыннан гына өенә он алып кайта; кибетче Тәслимә ничек итеп янавыч, көрәкнең бәясен күтәреп сата, моны бөтен кеше белә, әмма — дәшмиләр. Тәслимә — председатель Сәкинәнең туганнан туган сеңлесе. Һәм башкалар... Ничек итеп йортта налог җыелган, түләп бетерү өчен әллә инде ике мең кирәк хәзер. Мәгыйзь төн йокламады. Таң атканда ул Ташлытауга чыгып китте, үзенең кайтканын берәүгә дә әйтмәскә кушты. Военкоматка «җавиться итәргә» диде. Һәм шул көнне төнлә бакча яктан гына кайтып та керде. Арыган, йончыган иде.

— Менә, әни, сугыш еллары буена минем орденнар, медальләр өчен җыелган акча, — диде. — Дүрт мең җиде йөз. — Аннан авыр сулады.— Бу акчага сеңелне берәр башкорт авылына кымызга җибәреп була. Яки Кырым тирәсенә — санаторийга. Нишлибез?

Әнисе бер кызына, бер өстәл уртасында күперенеп яткан биш кисәк төргәккә күз ташлады.

— Белмим шул, улым. Налог белән дә бик җәфаландык инде. Ниш-

лик соң? Кырык дүртенче елдан бирле җыелган нидаимкалар... Әтиегез авырып киткәч, бер дә түләп булмады шул...

— Солдат семьяларына льгота дип сөйләгәннәр иде. Сез түләп килдегезмени?

— И-и-и, улым. Башта без дә шулай дип уйлаганыек. Әтиең бит сугышта түгел. Йорт башы кеше сугышта булганнарга җиңел булды: егерме биш сутый бәрәңге, бернинди налог юк. Иллә хөкүмәт карады да инде эрмис хатыннарын. Алар ачлык күрмәде...

— Я, сун, нишлибез? — Мәгыйзьнең күзләре чыланып китте. Ян сәкедәге сеңел, сугыш алды елларында авылның бер гүзәле булган Гандәлиф кыймылдады. Хәлсез иреннәрен ялап, елмаерга тырышты. Борылып бу якка карап ятарга теләде, әнисе ярдәм итте.

— И, абый җаным, —диде сөяккә калып кипкән адәм баласы. — Налогны түләгез. Миңа соң инде. Мине бернинди кымыз, бернинди Кырым коткара алмый инде. Әнә, минем быел март аенда алдырган үпкә рәсемен кара. Сәгать артында. Рәхмәт инде, абый. Тегендә, Тәтеш районында траншея казыганда, салкынлык кырык икегә житә иде. Лом белән балчыкка төрткән саен мин сиңа ярдәм булсын дип туң кисәкләрне калынрак алып каерырга тырыша идем. Рәхмәт, абый. Син бит ул вакытта Мәскәү янында идең, мин сизеп тордым...

Мәгыйзь ишегалдына чыгып китте, бераздан өйгә тәмәке исе тартылып керде, төн болытлаган, әмма бик коры, бик коры иде әле.

... Иртәгесен налог агенты Бәгъдә дүрт мең сум акчаны санап алып, шыгырдап торган яшькелт-зәңгәр кәпитәнсәләр [1] бирде. Мең тугыз йөз кырык җиденче елның икенче кварталына кадәр Вәлиәхметова Вагыйзә (әнисе—йорт башы) гаиләсе налогны «погашать» (Бәгъдә «пагашчать» дип әйтте) итеп бетергән иде. Әмма әле авылда Мәгыйзь кайтканны берәү дә белми иде. Шулай да, Бәгъдә сорады:

— Нәрсә син, гражданка, сыерыңны саттыңмы әллә?

«Гражданка» берни дә әйтмәде, шәлъяулык почмагын бөтерә-бөтерә кәнсәләрдән [2] чыгып китте.

Ул көнне, аның каруы авылда тарихи бер хәл булды.

... Мәгыйзь сугышка кадәр җиде класс тәмамлап, Лаешта алты айлык счетоводлар курсында укып, колхозга хисапчы булып кайткан иде. Әмма күңеле гел башкада булды: Сәхнә. Төннәр йокламады, артист булу турында хыялланды. Колхоз-совхоз театры авылга килгәч, шул коллектив җитәкчесе белән танышып, сәхнә эшчесе булып ялланды да, китеп тә барды. Кырык беренче елның мартында Колан Кырга хәбәр кайтты: Мәгыйзь инде роль уйный икән. Имеш, Фатих Хөсни дигән язучының «Урманда» дигән пьесасында Баттал диме, шәйтанмы—шуны уйный ди, Галия исемле кызга гашыйк булып, шул кызның туфлиена шампанское салып эчә һәм әйтә, ди:

— Яшәсен, Галия җаным, синең сыйракларың!

Ул хәбәр матур бер дулкын булып кырык беренче елның егерме икенче июнь иртәсенә кадәр йөрде. Мәгыйзьнең сугышка китүе дә гастрольдән булды. Нинди хәлдә булгандыр ул, Галия туфлиеннән шампанское эчкәндерме, әллә балта-пычкы тотып сәхнәдә багана-киштә куеп йөргәндерме — сугыш законнары өчен болар барысы бергә җыеп алганда нуль иде. Мәгыйзь шул заманнан бирле юк булып торды, менә ул инде кайтты. Ул сугышка киткәндә өенә бер посылка салган иде, әнисе аның әйберләрен сандык төбендә изге итеп саклады, кышкы озын кичләрдә, күзге соры таңнарда сандыкны ачып шул әйберләрне кулына тотып, сыйпап, бармак тиереп карап юана иде. Болар: ике-өч тартма грим (кипкән, әмма хуш исле), ниндидер вак кыл пумала, көзге,

[1] Кәпитәнсә — квитанция, налог түләгәнлеккә документ.

[2] Кәнсәләр — колхоз идарәсен, анда финагент утырган көнне, халык шулай атый иде, «канцелярия» сүзеннән. Бу сүз латиннан үзгәртеп поляклардан безгә кергән.

кәкре кайчы, ясалма мыек, ясалма каш, клэй, чәче-ние белән баш тиресе кебек кием, тагын әллә нинди чуртымнар — әллә ниләр иде.

Сугыштан кайткан ике орденлы, дүрт медальле Мәгыйзь әнисеннән шуларны сорап алды. Озаклап бизәнде, котчыккыч үзгәреп танымаслык хәлгә килде. Әтисеннән калган утызынчы еллар чикмәнен, каткан иске эшләпәне чормадан эзләп таптылар. Мәгыйзь үз анасы да танымас хәлгә килгән иде.

...Мәгыйзь туп-туры кладовщик Рәхмәт өенә керде. Керде, сәлам бирде. Тегеләр аш ашап утыра иде, Мәгыйзь күреп алды: Рәхмәтнең уң кулында уртадан ике бармак юк, җәплекә булып калган, аны кырык икедә үк кайткан диганнәрие шул.

— Китап ачтырырга теләмисезме? -- диде чикмәнле бабай әдәп белән генә. Өйдә эссе, инде кичке эңгер-меңгер вакыты иде. Рәхмәт җәплекәсе белән авыз тирәсендәге токмач башларын сөртеп алды, аш яныннан чыкты. Кызык итеп, мыскыллы карады.

— Яле, яле, сугышта кан коеп кайткан фронтовик турында нәрсә әйтә аласың? — дип сәке кырына таба шуышты. Рәхмәтнең хатыны тастымал җәеп шуның өстенә ике йомырка куйды.

Чикмәнле карт куеныннан бәләкәй генә калын китап чыгарды. Гарәп хәрефле. Актарынды, бармак башы белән шуышты да, карлыккан тавыш белән сөйләп китте.

— Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү, алтау, җи-и-дә-әү... — Бармак өстән җиде юлны санады. — Йорт башлыгының исеме изге исем икән, алла сыйфаты исеме икән. Әмма ләкин йорт башы хәрәм ризык җыя икән. Моның киялеге тияргә мөмкин. — Рәхмәтнең авызы ачылды да калды.— Узган ел бал суырткан көнне чүннектән бер чиләк бал өенә озаткан икән... — Рәхмәт сикереп торды, утырды. Үзен-үзе белмичә тиленәрчә кычкырып көлеп җибәрде, җәплекә белән җилкәсеннән аска таба кабыргаларын сыпырып узды:

— Дөрес бит, билләһи! Дөрес!

Балалар да, хатыны да куркышып өнсез калганнар иде. Чикмән исә тамагын кырып дәвам итте:

— Хәрәм мал йортка кичләрен караңгы төшкәч бакча яктан керә икән, бу ризыкны ашаган кешеләрнең барысының да яман чир белән чирләп китү хәвефе бар.

Рәхмәт хатынының кулыннан кашыгы төшеп китте. Хуҗа үзе тагын тиленәрчә кычкырып кабыргаларын сыпырып узды:

— Дөрес бит, билләһи, дөрес...

— Хөкүмәт эшендә акча белән эш итүче бер хатынга халык байлыгыннан алып ризык озаткалавың күренә...

— Дөрес! Җитте! Карчык, кая бир әле кәчтүмне! Шунда ун тәңкә барые! Дөрес! Җитте, агайне, җитте...

Ул арада чолан баганасын кактылар. Беркемнең дә кеше каршы алырлык хәле юк иде, ул арада дык итеп өй ишеге ачылып китте, берәү кереп сәлам дә бирде.

— Ни хәлләрдә тагын? У-у, мактап йөрим икән, аш өсте — Чикмән таныды: ферма мөдире Мәсгуть. Сугыштан әле быел гына кайткан.

— Менә хәлләр бар әле монда, малай, — дип кунакны Рәхмәт шаулап каршы алды, сәке кырына утыртты. Чикмәнледән инде пар чыга иде.

— Әйдә, — диде Рәхмәт, — кызык булсын әле: бу чибәр егет турында нәрсә әйтәсең? Әйдә, карчык, тагын ике йомырка өстә...

Чикмәнле китапның икенче битен ачты, санап китте:

— Берәү, икәү... алтау, җи-и-дә-ә-ү... Зур урында эшлисең, халык байлыгын сиңа тапшырганнар икән. Әмма ләкин халык байлыгын түрәләргә таратасың икән. Дүрт аяклы малның абзардан чыгып киткәне, икенче җирдә яшәгәне күренә. Шуны урынына кайтармасаң, йортыгызга ут кабуы бар...

Рәхмәт кабыргаларын җәплекәсе белән сыпыра-сыпыра сәкедә өй селкетеп көлә иде.

— Дөрес бит, билләһи, дөрес!

Мәсгуть агарып калган иде. Чикмәнле дәвам итте:

— Моннан ерак түгел, ниндидер дәрьямы, сумы, шуның артында син яраткан бер кара кыз күренә. Шул кызның язмышы бүген кыл өстендә булуы күренә. — Мәсгуть лып итеп идәнгә төшеп утырды. Авызы соскыч булып ачылып калган иде. Чикмәнле исә тезә бирде:— Бүген аны дүрт аяклы житез мал җигелгән тарантаска утыртып икенче җиргә алып китәргә җыеналар. Бүген кич халык байлыгы булган теге малны үз абзарыңа кайтара алсаң, төн уртасына кадәр дәрья аръягына чыксаң, теге кызны урласаң, гомер буе бәхетле булачагың күренә.

Мәсгуть телсез калган, Рәхмәт исә матчалар селкенерлек итеп көлә иде.

... Иртәгесен көтү куганда авыл тынсыз калган иде. Кичә Колан Кырдан бер могҗизалы кеше узган: бөтенесен белә, ди. Кичә кич Мәсгуть йомылып кереп Сәкинә абзарыннан сыер алып чыгып киткән, — Сәкинә шаккатып карап торган, бер сүз әйтә алмаган. Бүген таңда Мәсгуть Кесмәс аръягыннан кыз алып кайткан. Бүген төннә Рәхмәтләр йокламаган, Рәхмәткә җен зәхмәте кагылган, авырып егылган, хәзер саклап утыралар, ди. Бүген көтү куар алдыннан гына олы урам буйлап Вагыйззәттинең сугыштагы улы Мәгыйзь кайткан: кулында чемодан, аркасында яшел капчык, күкрәге орден-медальдән чың-чың килә, ди... Өченче көн генә Вагыйзәтти кәнсәләргә барып дүрт еллык нидаемкасын[1] түләп кайткан, ди. Койма буйларында кызарып көйгән тавык үләнен шертләтеп таптап, кулларына чыбык тотып, көтү озатып кайтучы хатын-кыз шулай сөйләнде. Урамда кайнар туфрак, сыер тизәге, коймаларда кызган тузан исе иде. Төн салкынын җәй буе сагындылар ул чакта.

Ул еллар артта калды инде. Рәхмәт шул чирләвеннән бер елга якын ятты, аны докторларга күрсәтеп алҗып беткәч, Тәкәнеш ягына Шәдче авылы карчыгына да күрсәтеп алып кайттылар. Әмма, ни генә эшләмәсеннәр, ул бер ел ятты. Амбарны хатыны алып барып торды. Ләкин терелеп чыгуга Рәхмәт ул амбарны Мәсгутька тапшырды. Тимерчелеккә керде, җәплекәле кул чүкеч тотарга ярый иде. Сөйләделәр: терелеп чыккан көнне колхоз идарәсенә килеп ундүрт кило бал бәясен түләгән, оннар алгаладым, исәбен белмим, уңыш бирсәгез, ике дә уйламыйча ун-унбиш потны тотып калыгыз, дигән. Әмма ун-унбиш пот уңышны тотып калыр өчен башта аны бирергә кирәк бит әле, еллар узды, бирдеме ул аны, әллә Ахияр килгәч моның белән вакланып тормадымы — инде халык бу хәлне онытты.

Мәсгуть, чыннан да, теге төнне Кесмәс аръягыннан кыз урлады, башкорт чалымлы бу сылу кыз белән алар бик бәхетле булдылар, күп бала үстерделәр. Ләкин олы кызлары үзәкләрен өзде. Аны шәһәргә укырга биргәннәр иде, кызый авылда калырга бик теләсә дә, әнисе каршы төште: әнисенең энесе шәһәрдә зур фатирлы, тәэсирле кеше иде, кызый шуларда торды, сәүдә техникумында укыды. Әмма чибәр, сылу кызга бу дөньяда яшәве — газап! Җәза! Кызый авылын сагынуга чыдый алмыйча, дәрес беткәч, көн саен колхоз базарына йөрде, анда авыл халкы, авыл һавасы була. Ул кызыгып йөри: менә болар, бу түшкәне сатып бетергәч, өйләренә кайтып китәләр инде, менә авылга кайткач рәхәтләнеп бер чишенеп ишегалдындагы чирәмдә аякларын юалар, аннан өйгә кереп токмачлы аш ашыйлар да, верандага чыгып кырын яталар, телевизордан Казан концертын карыйлар. Ә монда — берни дә, берни дә юк... Шулай дүрт-биш көн базарда йөргән яшь болан баласын бервакыт алыча, груша сатып торган кара мыеклы бер егет күреп

[1] Недоимка — налогның түләнеп бетмәгән өлеше.

ала, сүз ката, шул көнне үк техникум тулай торагына килә, әрсезләнә. Аннан тагын, тагын. Ике атна дигәндә кызый юкка чыга, техникумнан эзлиләр, туганнары эзли. Мәсгуть шәһәргә килә, бөтен союз буенча розыск бирәләр. Файдасы тими. Мәсгуть бөртек ризык капмыйча атна буе кайненең фатирында телефон төбендә утыра. Коточкыч хәл була: көннәрдән бер көнне кызый телефоннан дәшә. Җиде кат җир астыннан дәшкән кебек, ерактан, өзгәләнеп. Ашыгып.

— Әт-ти! — дип өзгәләнә кызый.— Әт-ти! Әт-ти! Мин исән! Мин кайта алмыйм! Мине...— Шул чакта телефон өзелә. Мәсгутькә врач чакырталар. Чүт кенә сары йортка япмыйлар. Ике көннән тагын телефон.

— Әт-ти! Бар кайт! Әнине үтермә! Әт-ти! Минс монда... — телефон өзелә.

Менә ун еллар инде Мәсгуть белән хатыны кара кайгы эчендә. Союз буенча өченче кат эзләтү дә берни бирмәде. Кайчан, кемне рәнҗеттеләр алар? Ни өчен мондый җәза? Берәү дә белми...

Урамда тонык гөрләгән тавыш ишетелде, бераздан тузан болытына төренеп председатель машинасы килеп туктады. Тузан озаклап, кеше күңелен рәнҗетеп, авыр-вак шыбырдап койма өсләренә, багана башларына утырды, шуннан соң гына соры брезент ишекне ачып халык алдына председатель чыкты. Коры тузанга бензинның кайнар һавасы кушылды — яшисе килмәслек авыр халәт иде. Ахиярга бүрәнә өстендә урын бирделәр. Председатель туктаганын күргәч башка капкалардан да ирләр килде, авыр атлап, яланаякка кигән алтмышынчы размерлы тирән галошларын лыштырдатып тракторист Сәйяф та килде, йөз егерме килолы гәүдәгә мондый эссе, тузанлы һава аеруча авыр иде, барысы да аңа карадылар. Сүзне Мәгыйзь башлады.

— Иптәш Гарәфиев, райкомнан нинди күрсәтмә бар? Чәчәбезме арышны, әллә — юкмы?

Ахияр авыр караш белән аңа борылды. Бераздан Хәсән картка:

— Менә сез миңа аңлатыгыз, — диде ул. — Чәчәбезме, юкмы? — Авыр тынлык урнашты.

Хәсән карт ябык гәүдәсен шыгырдатып ябык йөз белән председательгә борылды.

— Егерме беренче елны, — диде ул, — шулай ук көйде. Чәчәргә орлык юк. Запаслы кешеләр искене чәчте. Коры басуга. Шулар егерме икенче елны ипиле булды. Мин гражданскидан кайтканда.

— Сабан чәчсәң суга чәч, арыш чәчсәң көлгә чәч — шул инде ул.— Мәгыйзь сүнгән төпчеген сызгырта-сызгырта суырды.

Тракторист Сәйяф исә аңа каршы чыкты:

— Ул бит элеккеге заман өчен генә яраган. Элек халык мичкә салам яккан, шуның көлен басуга чыгарган. Хәзер упшым да туры килми ул.

Хәсән карт рәнҗүле елмайды:

— Сүзең — сүз түгел,— диде.— Көлгә чәч — утын көле, салам көле дигән сүз түгел, ул — туфрак коры булса да, чәч, яңгырны көтеп торма, дигән сүз. Менә бит нәрсә...

Ахияр моңа зур игътибар бирде. Бу мәкальне күп ишеткәне бар, әмма аның тарихи тәҗрибә икәнлеге турында уйлап та караганы юк иде.

Мәгыйзь әйтте:

— Чәчик, иптәш Гарәфиев. Чәчик. Сентябрьдә бер яңгыр булмыйча калмый. Болай ятып нишлибез? Әнә теге елны — кырык җидедә — мин сугыштан кайткан елны, чәчтек. И һәм алдагы елга валовойны сигез дә алтмыштан җыйдык. Арыш алты ярымнан чыкты.

— Соң бит бераү дә чәчми! — Ахияр ыңгырашкандай итте,— әнә бөтен күршеләр — берсе дә чәчми. Гел уралар гына.

— Күңел юкка — күмер юк, — диде Мәгыйзь. — Аларның урак буенча алга чыгасылары килә, иеме, ә монысын табигатька сылтарга...

Ахияр торып басты. Бүрәнә өсте мәҗлесе тарала башлады. Авыр атлап Сәйяф та лыштыр-лыштыр китеп барды. Күрше-күлән белә иде: бүген Сәйяф председательдән машина сорап Ташлытауга кунак алмага барды. Корылык дип тормады, аның шофер малае шул көннәрдә генә өйләнде. Шулай ашыгыч кирәк булгандыр инде, шәһәр кунаклары, имеш, туйга бер көн кала — бүген үк кайтасылар икән. Җыелышып. Алдан кайтып поездын, кеше санын әйттеләр. Сәйяфка автобус бирделәр. Ун да кырык биштәге поездны көтеп, Сәйяф үзенчә кайтачак кунакларның санын барлады: ирләр нәкъ уналты кеше көтелә иде. Буфет тирәсе әлегә буш, сыра мичкәсе янында нибары ике-өч кеше, поезд кайтып төшсә, монда гарасат булачак иде. Бүген көндез эсселек күләгәдә утыз сигезгә житте. Шәһәр радиочелтәре әйтте: мондый температура моннан йөз дә ике ел элек... Фәлән-төгән... Сыра, салкынча күбекле сыра — бүген алтын бәясе булачак иде. Сәйяф алдан күреп, поезд килеп төшәргә бер-ике минут калганда гына унҗиде бокал сыра салдырып, зәңгәр пластик өстәлгә тезде. Поездны малае каршы алды. Ни гаҗәп, бер генә кунак та кайтмады. Димәк, кичкегә калганнар, берәр матавык чыккан булыр. Сыра күбекләре сүнә башлады, буфетка халык тулды, зур чират ясалды. Ул арада «бокал житми» дип низагъ чыгардылар. Нишләргә? Кечкенә чират ясап сыра сатып тора алмый бит инде Сәйяф. Җитмәсә, малай да рульдә — грамм кабарга ярамый. Сәйяф озак уйламады: пластик өстәл янына килеп басты да җиңелдән генә, бер-бер артлы өч бокалны эчеп куйды. Малае автобус янына китте. Озак торма, дип әтисен кисәтте. Беравык тын алгач Сәйяф тагын өч бокалны хәл итте. Өстәлгә шатлыклы караш ташлады. Күрше өстәл тирәләре, буфет алдындагы газон бәхетле халык белән тулды: миең кайнарлык эссе, кояш ап-ак, станциядә кызган шпал, тимер, буяу исеннән — торган кайнар һава тирбәлә — ә монда җелегенә үтәрлек салкын сыра. Станция киеренке бәхетле минутлар кичерә иде, шуны күзәтеп бераз эссене тоеп кергән Сәйяф тагын бер тын белән өч бокалны бушатты. Бәрәч! Өстәлдә нибары сигез бокал калган иде, анысын инде тоз сипкәләп, икешәрләп, түмен белеп кенә... Ул арада малай кереп житте...

Сәйяф бүген кәефле иде, кәефле вакытта исә ул Ахиярдан өркә һәм сөйләшмәскә тырыша. Капка төбендәге бүрәнә өстендә бөтен кеше сөйләшкәндә бер ул гына дәшми утырды, күзләре Ташлытау юлында булды, кичке поездга киткән автобус инде кайтып җитәргә тиеш иде.

— Хәсән абзый, нишлик? — диде Ахияр, китәр алдыннан. — Я, син өлкән кеше, бер киңәш бир? Миңа бүген йоклап алырга кирәк. Ничә төн инде йоклый алмыйм. Ми кайный, баш эшләми.

Хәсән карт үз дәрәҗәсен белеп кенә, Ахиярга карамыйча гына сөйләп китте:

— Йоклый алмасаң, үзең гаепле. Ник хатыныңны шәһәрдә тотасың? Ир кеше төнлә хатынын кочаклап йокларга тиеш. Әүвәл-әүвәлтеннән килгән бер гадәт инде ул. Аерым урында йоклаган ирнең ничек итеп башы әйбәт эшләсен?

Кешеләр көлештеләр. Хәсән карт исә үзен тыңлаганнарын тоеп кыза төште.

— Әнә кичә кина күрсәттеләр, тиливизырдан. Ни хикмәт булып бетте бер семья. Хатыны бер эфисәрдән бала тапты, аннары паравыз астына ташланды. Ни өчен? Ире белән хатыны аерым ятканлыктан. Гел шуны күрсәтәләр: ире йокыга ятар алдыннан тегенең янына кереп

«тыныч йокы» дип чыгып китә. Ә хатын яшь, таза. Аңа тыныч йокы кирәкме соң?

Шаулап көлештеләр. Хәсән карт җитдиләнде:

— Чәчәргә кирәк, — диде. — Егерме беренче елны, әнәтерәк крәшен Афанасий элеккеге запасыннан калган дүрт пот иске арыш чәчте. Туван эченә, кайнар, көйгән басуга чәчте. Әрәм итте, куырыла инде ул дип сөйләде халык. Ялгыш сөйләгән булып чыктылар: сентябрь уртасында бер яңгыр булмасынмы? Афанасийның кишәрлеге күгәрчен тамагы төсле элпе белән капланмасынмы? Менә бит ничек ул...

Идарә яныннан кызу-кызу атлап килгән хатын Ахиярны бер читкә чакырды.

— Сезне телефонга сорыйлар, әллә Обкомнан инде, — диде.

Ахияр ашыгып машинасына кереп китте, бүрәнә өсте мәҗлесе дә тарала калды.

... Телефон трубкасы шомлы кыштырдап өстәлдә ята иде. Ахияр тыны кабып аны колагына терәде.

— Гарәфиев, нихәл? — диде Өлкә секретаре тонык тавыш белән. — Яңгыр юкмы?

— Яңгыр... юк шул. — Шул мизгелдә Ахияр яңгыр юклыкка үзен гаеплесыман сизде. — Юк шул...

— Син иртәгә өйдә бул әле... Мин килеп чыгармын. Күршең кем әле синең? Евдокимов? Аңа да әйт. Байгильдеев миндә утыра. Аны эзләп мәшәкатьләнмә.

Телефон кинәт өзелде.

... Икенче көннең үзәгендә дөньяны тузан болыты басты. Кояш кызганыч кыяфәттә кызарып дөньяны көйдерүен дәвам итте. Кайдадыр урман яна, каяндыр көек торф исе килә, тән кычыттыргыч бер тынлык иде. Өлкә секретаре үз машинасына Митрий Евдокимовны утыртып ук алып килде. Ахиярның кабинет өстәлендә тирләгән зур графин белән әле генә китерелгән чишмә суы тора иде. Сусез генә күрештеләр, секретарь кара янган, тирләгән, Митрий көйгән иде. Ахияр өч стаканга чишмә суы салды.

— Мин нәрсә эшләргә тиеш быел? — диде секретарь кырыс кына.— Партия, хөкүмәт алдында, бөтен республика алдында мин нәрсә эшләргә тиеш? Сез инде, Үзәк Комитет барысына да күрсәтмә бирә, без анда югарыдан кушканны гына үтәп утырабыз дип уйлыйсыздыр? Әйдәгез, бергәләп. Сез бит республикада иң тәҗрибәлеләр. Сездәй җитәкчеләр республикада ничә генә? Ә? Ә?

Ахияр маңгаен сөртте.

— Мин иртәгә чәчә башлыйм, — диде. Секретарь шикләнеп аңа карап алды, аннан — Митрийгә.

— Мин дә шулай уйлыйм. Кырык җидедә без чәчтек. Вапше, анда да шулай көйдерде. Ну, без чәчтек...

— Сентябрьдә бер яңгыр булмый калмас, — диде Ахияр. — Чәчмәсәк нишлибез? Киләсе елда нәрсә әйтербез? Мин исәпләдем: бу елда без арыш чәчәргә тиешбез... — Ул амбар кенәгәсен ачты, цифрлар, центнерлар, гектарлар санап китте. — Чәчәбез — тәвәккәллибез, вәссәлам. Әгәр сентябрьдә дә шулай көйдерсә, димәк, фәлән-фәлән центнер симәнә югалтабыз, фәлән-фәлән гектар җирне бушка эшкәрткән булабыз. Рентабельлеккә бәрәбез. Тез астына. Бу — бер. Ә чәчмәсәк?

— Чәчмәсәк, ә менә кинәт кенә — сентябрьдә яңгыр? Чәчәргә инде соң, туфракта кырау? Ул вакытта? Юк, мин, иптәш секретарь, вапше күзне йомам да, чәчә башлыйм.

Секретарь урыныннан торды, сигарет кабызды. Идарәнең ачык форточкасыннан эссе тузан керә башлаган иде, Ахияр урамга күз ташлады, районның ГАИ машинасы йөренеп тора, урамдагы тәртипне саклый иде.

— Мин сезгә таянам, — диде секретарь. — Аңлагыз, мин мондый ситуациядә әлегә бик яңа кеше. Мондый ситуациядә—беренче тапкыр...

Чәйгә кермәде, юл өсте — Митрийне утыртты да китеп тә барды.

Ахияр җәяүләп көн үзәгендә тузанлы урамнан узды. Бөтен дөнья тын, капка күләгәсендә җыелган казлар авызларын ачып телләрен чыгарганнар, тәрәзә өсләрендә чыпчык та чыркылдамый, авылда әйтерсең тереклек туктаган иде. Хәер, тракторист Сәйяф (туй мәшәкате дип ике көнгә ял алган иде) өендә корылык афәтенең тамчы да тәэсире сизелми иде.

Марля тарттырылган ачык тәрәзәдән хәлсез, эсседән коргаксыган хромкага кушылып Сәйяф тавышы кайнар урамга агыла иде:

Сандугачым, сайрап кал,
Кисәләр талларыңны;
Сикереп утларга төшәрсең
Сөйсәләр ярларыңны...

Шуны исәпкә алмаганда авыл тын, үле иде. Көн үзәге, ындыр табагы көндезге ашка туктаган, тузанлы коймага надан киномеханик русча афиша ябыштырган: «Сегодня в клубе к. ф. «Актимистическая трагедия». Башлана 19[30] сәгатьтә», исемен, күрәсең, телефоннан гына язып алган. Хәер, бик үк надан да түгел икән: иртәгесен буласы фильмга шәрех тә язган. Һинд фильмы икән. «В этом фильме рассказывается о короле джунглей, занимающемся отловом зверей и продажей их в зоопарки. Однажды к нему в дом явилась молодая девушка — красавица...» Кызыксындыруның рәтен белүче кеше язган...

Коры, эссе урамнан койма күләгәсенә ышыкланып калын пыяла күзлекле, таяклы Камилә карчык — Хәсән картның мәңгелек юлдашы бара иде. Ахиярны күрмәде, гадәттәгечә, үзенең таягы белән сөйләшеп узды.

— Әйдә әле, әйдә әле, Камилә карчыкны Сәйяфларга таба алып бар әле. Әйдә әле, яшь киленне күрсәтеп кайтар әле Камиләгә. Әйдә әле, менә бу ташны әйләнебрәк уздыр әле Камилә карчыкны. Әйдә әле...

Ахияр киндер кепкасын салды, күккә карады: күк йөзендә өмет юк иде.

## VI

Гәр Хутор аланы яшәү өчен бик уңай иде. Соңгы елларда «Яңа юл» колхозына кергән авылларда байтак йорт кимеде, әмма Гәр Хутор шул унике санын үзгәртмәде. Нигә алай? Бу авыл ничек яши? Боларга бит электр да иң соңыннан керде. Озак еллар күзәтү нәтиҗәсендә Ахияр бер фикергә килде: Гәр Хутор халкы терлек-туарны күп асрый. Аларда печән мәсьәләсе җиңел, тавыш-гаугасыз хәл ителә. Терлек-туар күп булгач, бу авылда яшәү формасы, рух икенче. Әнә шуңа күрә Гәр Хутор халкы бердәнбер Тависның рәвеш-йөрешенә шаккатып карый. Югыйсә, Тавис кеше белән сугышмый, ут төртми, урламый. Башка зуррак авылларда аның хикмәтләре әле күзгә дә чалынмас иде. Тавис, кешеләрдән бигрәк, үзенә зарар салып йөри. Гәр Хуторга берәү инде ул.

Соңгы елларда печән хәзерләү авылларда зур проблемага әйләнде. Ахияр тәмам инанды: бетәсе хуҗалыкның беренче билгесе — хуҗалыкта иң беренче чиратта сыер сатыла. Берәр елдан сарыклар бетә һәм озак та үтми, тәрәзәгә такта сугыла. Димәк, авылны тотар өчен шәхси хуҗалыкларның терлек-туарын сакларга кирәк. Моңа ничек ирешергә?

Ахияр монысын да белә, әмма бу турыда беркемгә дә әйтми. Аны дөрес, юньле итеп аңламаслар дип уйлый. Чөнки, сугыш вакытында булган бер хәлне сөйлиләр: атлар ачтан егыла башлагач, идарә утырышында шул мәсьәләне караганнар. Ат караучы Заһир карт шунда әйткән:

— Җәмәгать, — дигән, — бер тәкъдим бар. Үзебезнең сыерлар үлми бит. Язгы чәчүгә кадәр, атларны хуҗалыкларга беркетеп торыйк. Ни әйтсәң дә хуҗалыкта аз-маз печән, бәрәңге юк түгел.

Шунда чәчрәп Сәкинә чыккан.

— Син, — дигән, — әле үзебез төзегән колхозны таратмакчымы?!

Заһир карт лып итеп урынына утырган. Иртәгесен ул ат абзарында күренмәгән. Һәм, гомумән, күренмәгән. Сәкинә бүлмәсендә телефон бар иде шул. Ул язны колхозда бик күп ат кырылган...

Ахиярга моны әллә ничә кеше, әллә ничә тапкыр сөйләде. Кызганыч хәл, бик кызганыч хәл. Менә хәзер ат проблемасы юк. Хәзер көтелмәгән мәсьәлә — шәхси хуҗалыкны саклау проблемасы туды. Әйе, «мал курмысы» мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Ничек? «Яңа юл» колхозында болыннар күптән инде беткән, аларны чәчүлеккә әйләндергәннәр. Басукырлар колхозчының бәрәңге бакчасына ук килеп терәлгәннәр. Каз, кош-корт йөртергә, бозау арканларга урын юк. Хуҗалык көтүен йөртергә урын юк. Ул көтүне көтәргә хәтта кеше юк. Шуңа күрә хуҗалык терлекләре май ае беткәнче абзарда кычкырып ята. Колхозчы колхоз эше белән түгел, үз терлеген карап иза чигә. Яшьләр әти-әниләренең абзар-курада ничек җыкланганын күреп үсәләр: юк, моннан котылырга кирәк, адәм баласы дөньяга моның өчен килмәгән. Һәм яшьләр моннан котылалар. Кайсы сыерын сата, кайсы күченеп район үзәгенә, лесхозга, шәһәргә, тимер юл станциясенә китә. Анда, ичмасам, кибеттә сөт-катык көн саен килеп тора. Каян килә? Ташлап киткән авылдан, әлегә яшәп ята торган авылдан. Юк, болай ярамый.

Сыер, сарык асраган колхозчыга ярдәм, льгота кирәк. Сыер асраган колхозчыга ындыр артыннан бер гектар җир бирергә һәм люцерна, клевер чәчтерергә, шуңа өйрәтергә кирәк. Бер гектар печәнлеге булса, колхозчы сыер, тана, бозау, ун-унбиш баш сарык асрый ала. Һәр сыер ике йөз илле килограмм ит бирә ала. Тик аның быелгы бозавын тагын бер кыш кышлатырга гына кирәк...

Урман буенда озак йөрде Ахияр. Урманның иң матур чагы бу. Көзнең үз законы, үз таләбе бар. Никадәр генә кояшлы, җылы булмасын, усак инде сап-сары. Якты сары сихри урман буеннан барганда кинәт кенә кызыл төлке булып бер ялкын бәрә. Анысы — миләш. Табигать аны усаклар сарылыгының шигъриятен күрсәтер өчен алар белән бер үк вакытта кызарткан. Чыршыларның яшеллеге җәй көне беленми, ә менә сентябрь аенда аларның буявы тагы да яктырып китә. Көрән-сары төскә кергән өрәңге яфраклары инде аяк астына төшәлә башлаганнар. Менә күп тә үтмәс, табигать алар өстенә мул гына яңгыр бирер дә, бер төнне суытып җир өстен каты кабыклы яфрак юрган белән төреп алыр, шул юрган агач орлыкларын, үлән тамырларын кышкы зәһәр салкыннардан саклар.

Күк йөзеннән пәрәвез оча, биек-биек зәңгәр күктән аксыл ефәк җепләр бара. Бәрәңге басуы саргылт кояш нурына коена, анда-санда сыек зәңгәр төтен үрмәли, янган коры билчән исе борынны кытыклый. Олы кеше, олы ир булсаң да, әллә нигә генә елыйсы килә. Сары-кызыл-яшел урманның җәй белән саубуллашуымы, күк йөзендәге ефәк җепләр очуымы, әллә коры билчән сабагыннан чыккан төтеннең күзне кытыклавымы — елыйсы килә, әйбәт итеп, кешеләргә, җиргә игелек китерерлек итеп елыйсы килә...

Әллә ничек кенә узды бу тормыш. Менә алтмышка таба бара Ахияр — шәхси тормышы булмады. Матур гына яши башлаганнар иде ке-

бек. Авыл халкы аларга сокланып карап кала иде. Нигә алай булды соң? Урман буендагы бәрәңге җире межасыннан атлаганда Ахиярның хәтеренә әлләниләр килде. Бер елны Ахиярны өлкә партия конференциясенә делегат итеп сайлаганнар иде. Ул шәһәргә хатынын, балаларын утыртып алып килде.

— Сез дә шәһәр күрерсез, бергә дә булырбыз, — диде.

Хатыны Сольма да, балалары да шатлыктан нишләргә дә белмәделәр. Дәү әти белән дәү әни дә бәхетле булдылар. Әмма барып бер кич кунуга Сольма балаларын төяде дә, Колан Кырга кайтып китте. Сәбәбен әйтмәде, Ахияр шәһәрдә калды. Сольманың әнисе, шигәеп, кияүгә болай диде:

— Аңа авылдан кемдер телефоннан чылтыратты, — диде.

Конференция эшен тәмамлаган көнне делегатлар өчен зур концерт бирелде. Ахияр иртәгесен генә авылга кайтып китте. Кайтса — Сольма елап шешенгән, кара болыт булган иде.

— Ни булды? Балалар исәндер бит?

— Исән, бик исән, — диде Сольма зәһәрләнеп.

— Соң нәрсә булды?

— Нәрсә булганын үзең беләсеңдер...

— Тукта әле, нәрсә чәпчисең?

— Чәпчеп кенә кала торган түгел монда. Кащей Бессмертный син, белдеңме шуны!

— Нинди Кащей?

— Нинди, нинди... — Сольма зәһәрләнеп сервантны ачты да, Ахиярга бер конверт тоттырды. Тышы чиста конверт эченнән дүрткә бөкләнгән шакмаклы дәфтәр бите чыкты. Дәфтәр битендә эре-эре хәрефләр белән, юри бозып язган сыман хат иде. Ул хаттагы сүзләр, карандаш белән ясалган эре хәрефләр Ахиярның әле дә күз алдында. «Сәлимә, синең гомерең әрәмгә уза. Ирең тик торучылардан түгел. Син югында санаторий юлын таптады, анда аның сөяркәсе бар иде. Анысы Ахиярдан бала төшереп кан-яшь җылап китеп барды. Хатыным юк, дип алдалап йөргән икән. Хәзер дә тик тормый, сыер савучы Катеринаның укытучы кызы белән очраша, яшь аермалары егерме булса да. Син соңга калганчы моннан китү ягын кара. Син китсәң, партия райкомы аны акылга утырта. Сиңа изгелек теләүче (...)»

Ахияр кәгазьне җирәнеп идәнгә ыргытты.

— Җәя эчендәге өч ноктаны тутырыйммы? — диде.

— Тутыр! Тутыр! — Сольма йолкына, елый, өзгәләнә иде.

— Иң ансат эш ул, белдеңме? Анда тагын өч нокта кирәк.

— Тагын нинди нокта? — Сольма ни сөйләшкәнен, нәрсә сораганын белми, аңа бары тик нәрсәдер кычкырырга, шуның белән йөрәген басарга кирәк иде.

— Тагынмы? «Сәкинә» дигән сүздә алты хәреф! Син әллә арифметикадан ун эчендә санауны оныттыңмы? Юләр син...

Ул хат шулай бер җәрәхәт ясады да, онытылгансыман булды. Әмма дошман актив иде.

Бер көнне кич Сольма өчпочмак пешереп, балаларын өстәл янына утыртып, әтиләре кайткач бергәләп ашыйбыз, дип көттереп торган. Әмма әти кеше кайтмаган. Балалар йокыга изрәгәннәр, өчпочмак суынган, Сольма караңгы урамга кара пыяла аша текәлеп тәрәзә янында басып торган. Бераздан телефон чылтыраган һәм билгесез хатын-кыз тавышы белән, русчаны ватып, аңа болай дигәннәр:

— Твой муж тебе не принадлежит. Знаешь, где он сейчас?

Ул төнне Сольма катгый карар кабул итә һәм төне буе чемоданнар тутыра. Тәрәзә пәрдәләрен сүтеп ала, серванттагы көмеш, мельхиор пычак-кашыкларны җыя, үзе төне буе елый.

Ахияр ул төнне таң атканда гына корымга батып, бөтен чәч-кашлары көйгән, балчыкка изелгән, манма су килеш кайтып керде. Аны-моны аңламыйча, өйгә кергәч әйтте:

— Бер рюмка салып бир! Мин бүген күргәнне эт тә күрмәс, — диде һәм чишенергә өйалдына чыгып китте.

Колан Кыр бригадасының сушилкасында ул төнне янгын чыккан иде. Сушилка янында, бәхетсезлеккә каршы, баклары тулы ягулык белән комбайннар калган һәм ут бер комбайнга күчте. Ташлытаудагы янгын дружинасы, һәр районда гы кебек, кешеләр янгын сүндереп эт булгач кына килеп җитте.

Аннан озаклап акт төзеделәр.

Нигәдер, бүген шулар — алтмышынчы еллар искә төште. Дөньяда очраклылык юк диген син? Сольма кайтып, тормышлар җайланып, ничәмә-ничә еллар узгач, Ахияр яңа килгән секретарь Байгильдеевкә шул элеккеге мавыгуларын сөйләргә, эчен бушатып җиңеләеп калырга уйлаган иде. Әмма, юкка гына! Нәкъ шул мәсьәләдә Ахияр аның үзенә үк эләкте. Һәм бик нык, конкрет эләкте.

...Ул җәйдә «Яңа юл» колхозында район механизаторларының слеты уздырылган иде. Ахияр шул ел эчендә байтак эш эшләтте, җиде-сигез ел буе салынып бетә алмыйча яткан мастерскойны аякка бастырды, зур комплекс төзелеп бетте. Тәҗрибә уртаклашуны әнә шундый колхозда оештырдылар, слет әйбәт кенә узды. Байгильдеев алдан әйтеп куйган иде:

— Урманың әйбәт, иң матур аланына ашау-эчү әзерлә...

Ахияр монысын да әйбәт оештырды: райпо белән сөйләшеп эшне шул дәрәҗәгә җиткерде ки, җыелышта утырып, смотрда йөреп арган агай-эне, җитәкчеләр урман аланына килгәндә аларны чытыр ак халат ак калфак кигән, моңарчы районда да күренмәгән чибәр кызлар каршы алды. Байгильдеев тә аптырабрак торды: каян килгән мондый затлылык? Ризыклар — гел шәһәрчә иде. Авылча муллыкка шәһәрчә форма, композиция кертелгән. Утыра торгач ачыкладылар: кызларны ниндидер әмәлләр табып шәһәрдәге кулинария техникумыннан китерткән икән Гарәфиев.

Ул көнне ашау-эчү, чәй мәҗлесе эшлекле, күңелле барды. Механизаторлар алдында Байгильдеев үзе дә белмәгән үзешчән сәнгать көчләре чыгыш ясады, районныкыларны, гадәттә, таныйлар иде — болар әллә ниткән, кул чаба торгач, аларын да ачыкладылар: Гарәфиев, подшефный буларак, зур заводның үзешчәннәрен чакырткан, тегеләр исә төрле ансамбльләрдәге ике-өч егет, алты-җиде чибәр артистка да ияртеп кайтканнар. Райком секретаре барында болар белән кушылып бергә җырлаудан да ары уза алмадылар. Югыйсә, берничә председатель, тагын райпо председателе, баш агроном, баш энтомолог кебек ирләр иркенләбрәк утырырга да каршы түгелләр иде.

Киткәндә Байгильдеев председательне чакырып әйтте:

— Молодец, барысын да әйбәт оештыргансың, әгәр быелгы урып-җыюны да шулай матур башкарып чыксаң, райком каршында һәрвакыт йөзең ак булыр,—диде.

Ахиярның мондый мактауны беренче ишетүе түгел иде, армиядәге гадәт буенча гәүдәсен турайтты, үкчәсен үкчәгә бәрде дә:

— Служим Советскому Союзу!— диде.

Кунаклар таралды, матур урман аланында яңа такталардан ясалган озын өстәлләр, эскәмияләр ятим калды, яңгыр була калса дип баш өстенә тарттырылган полиэтилен түбә җәйге урман җиленә лепердәп дулкынлана иде.

Унбиш көн элек кенә урманда шундый ирләрчә эшлекле бер мәҗлес булган иде. Ә бүген?

Бүген Байгильдеев, шимбә көн итеп, берәр сәгать ял итмәкче булган. Төштән соң. Шоферына әйткән:

— Әйдә әле, шул Гарәфиевнең беркөнге аланына кереп хәл алып чыгыйк әле,— дигән.— Анда каен җиләге бик күп иде. Бер сәгать ял секретарьга да ярый.

...Алар җиләк исенә оеп тын утырган теге аланга килеп керделәр. Теге өстәл, чыннан да, ятим кыяфәттә, яңа такталарыннан сагыз кайнап чыккан, түбә итеп ябылган полиэтилен бер башыннан аз гына ертылган. Җиләк һаман күп икән. Иелеп җиләк капкалап йөргәндә аларга каршы шәһәрчә чибәр киенгән ике кыз килеп чыкты. Уч төпләрендә җиләк, үзләре дә чибәрләр — җиләк кебек иде.

— Абый, сез «Яңа юл»дан түгелме? — дип сорады кызларның берсе Байгильдеевтән.

Байгильдеев кыска җиңле күлмәк, киндер кепка кигән, килешеп бетмәсә дә, кара күзлек элеп куйган иде.

— Юк,— диде ул, кызларга артык игътибар итмичә.— «Яңа юл»дан кем кирәгие соң сезгә?

Кызлар ык-мык иттеләр. Шулай да берсе саксызлык белән:

— Без әллә Гарәфиев абый килгәнме, дип торабыз,— диде. Байгильдеев сагайды:

— Гарәфиев нәрсәгә киләсе иде соң монда?

Кызлар кирәкмәс сүз ычкынганын аңладылар, икы-чыкы килеп көлештеләр дә, сүзне уенга борып аланның икенче кырына таба китеп бардылар.

Байгильдеев шунда барысын да аңлады.

— Монда ял итеп булмастыр, ахырысы,— диде ул шоферына.— Әйдә, кайтыйк.

Машина үләннәрне, чәчәкләрне җиңелчә изеп, газ белән җиңелчә лепелдәтеп, тоныкк тавыш белән аланнан чыгып китте. Урман юлын чыгып җиткәндә генә алар каршына «Яңа юл» председателенең газигы килеп чыкты. Кинәт туктады. Байгильдеев сабыр гына машинасыннан чыкты да газик каршына килде. Ахияр рульдә үзе икән. Каушаган кыяфәттә машина эченнән чыкты. Шул каушау аркасындадыр, ахырысы, ялгыш кагылып, аяк астындагы күн сумканы аударды. Байгильдеев карап торды: күн сумкадан «Менә безне күрегез» дигәндәй кыярлар тәгәрәп чыкты, ак чытырдавык кәгазьгә төрелгән кайнар тавык сүтелде, ак ике металл бөке күренде. Тын да алмыйча басып тордылар. Тынлыкны Байгильдеев бозды:

— Син бу машинаны колхозга кайтарып куй инде, — диде ул шоферына.— Аннан берәрсе сине китереп китәр райүзәккә. Ә без иптәш Гарәфиев белән райкомга барыйк әле.

Байгильдеев рульгә үзе утырды, арт урынга Ахияр сеңгән иде. Юл буе ләм-мим бер сүз сөйләшмәделәр. Байгильдеев кайтып керүгә секретарь кызга бюро членнарын җыйдыртты.

Бюро озак утырырга җыенмый иде.

— Болай, иптәшләр,— диде Байгильдеев мәсьәләне аңлатып биргәннән соң.— Без хәзер үк карар кабул итәргә тиешбез.

Бюро әгъзалары башларын түбән иделәр. Семья-әхлак мәсьәләләрендә Байгильдеевнең гадәттән тыш кырыс, таләпчән ортодокс икәнен барысы да белә иде. Байгильдеев җитәкче иптәшләрнең теләсә нинди кимчелеген гафу итә ала, әмма дәүләт милкенә кул сузу һәм әхлак мәсьәләләрендәге кимчелекләр, тайпылышларны берничек тә кичерә алмый иде.

— Кемдә нинди тәкъдимнәр булыр?

Тәкъдимнәр каты булды. Уттай кызу урак өстендә колхоз председателенең шундый әхлаксызлыкка баруын нык тәнкыйть иттеләр. Арадан берсе — прокурор дисәң прокурор инде — икенче кыз кем белән очрашырга тиеш иде, дип Ахиярның үзәгенә үтте. Ахияр иптәшенең әйберсен урлап тотылган беренче класс малае кебек тешен-тешкә бәреп утырды, үзен очкылык тотты, дәшмәде.

Бер генә тәкъдим булды:

— Партия сафыннан чыгарып, эшеннән азат итәргә.

Ахияр аклану өчен бер сүз дә әйтә алмады, ул һаман дерелдәде, бюро әгъзаларына аның саен кыен була башлады. Куллар күтәрелер алдыннан гына райисполком председателе урыныннан торды.

— Иптәшләр, миңа бу турыда сөйләве дә бик кыен,— дип башлады ул сүзен,— чөнки сүз үзебезнең арадагы житәкче кадрның мораль йөзе турында бара. Монда тәкъдим конкрет булды һәм мин уйлыйм, бу тәкъдим әлеге иптәшнең мораль җинаятенә карата тулысы белән туры килә һәм ул карар гадел булачак.—Райисполком председателе авырлык белән тамагын кырды, карашын тәрәзәгә юнәлтте. Райкомның икенче катындагы бу зур тәрәзәдән ерактагы иген басулары, елга аръягындагы тау битләре, зәңгәр күк белән сары камыл басуы тоташкан сызыктагы урман полосалары күренеп тора иде — бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Ахияр чыгыш ясаучының күзенә мөлдерәп карады...

— Инде, иптәшләр, шунысын да әйтик: мин, әлбәттә, моның мораль җинаятен аклау ягында түгел. Әмма бу иптәш белән генә эш бетми әле. Менә мин мәсьәләгә өч яклап килəм. Беренчесе. Иптәшнең колхозга килүеннән соң, берәүгә дә яшерен-батырын түгел, колхозда алга китеш күз алдында. Иптәш шәһәрдәге шефларны эшкә җигә белде. Ничә ел буена отчетларда «койрык» булып исәпләнеп йөргән мехмастерскойны торгызды. Аннан районда беренче булып зур комплекс төзеде. Субподрядчигын, материалын тапты, райком-райисполком ишеген таптамады, безгә салынып ятмады. Бүгенге көндә кайсы колхоз район-төзүче оешмаларын үзенә эшкә тарта ала? Ә иптәш Гарәфиев җәй буена районның гына түгел, шәһәр көчләрен дә үзендә тота. Инде килеп хәзер, эш фронтын җәелдереп җибәргәндә генә без кадр алыштырсак, кем ота? Кем өчен файдалы бу? Икенчедән. Билгеле, мин иптәш Гарәфиевнең мораль җинаятен аклау ягында түгел. Әмма бит, иптәшләр, колхозчы кадрлар бар. Алар алдында безнең дә отчет бирәсебез бар. Менә син хәзер алар каршына яңа председатель алып барып кара. Син нәрсә, диячәкләр алар, акылыгыздамы, юкмы? Менә дигән итеп күтәрелеп килгәндә генә, нинди ул кадр алмаштыру? Тәрбияләгез! Өченчесе: кабатлап әйтәм, мин, иптәшләр, иптәш Гарәфиевнең мораль җинаятен һич тә аклау ягында түгел, әмма шунысы бар: гаилә башлыгы бит ул! Менә мин узган атнада гына аларның өендә булдым, чәй эчеп чыктым. Гарәфиев үзе юньсез булу белән генә түгел бит әле. Аның менә дигән хатыны — алдынгы китапханәче, культуралы, әдәпле хатыны (председатель блокнотына күз салып алды) — Сольма ханым бар. Һәм, ниһаять, курчак кебек кызлары... (председатель яңадан блокнотына күз салды) кызлары бар. Ут уйнап торган бер малайлары бар. Менә сез бүген Гарәфиев ролендә булып карагыз: өегезгә кайтыгыз да, мине партия сафларыннан чыгардылар, мине эшемнән азат иттеләр, диегез. Шуннан ул ханым нишли? Ә теге гөнаһсыз сабыйларның ни гаебе бар? «Әти, нәрсә өчен»? — дип сораячак бит алар, нарасый балалар. Ә нәрсә өчен? Әниеңә хыянәт итеп, урман аланында чит-ят кызлар белән гүләйт сандырып йөргән өчен! Күрдегезме, иптәшләр, эш кая бара?

...Бөтенесе дә авыр суладылар, өстәлләргә карандаш белән бәргәләделәр, газапланып бугаз төеннәрен уйнаттылар — ситуация авыр иде. Бюро членнарыннан берсе түзә алмады, Байгильдеевкә таба борылып, «мин бер генә минутка» дигән ишарә ясады да, ишекне ачып чыгып кит-

те. Ахияр карар көтеп өстәл башында басып тора иде. Нәкъ шул минутта — киң итеп кабинет ишеге ачылганда, алгы бүлмәдән чырыйлап кычкырган бала тавышы ишетелде. Барысы да әсәрешеп ишеккә таба борылдылар. Ишек, ни өчендер, ябылмый калган иде. Бала ишеккә үк килде һәм куркынып кычкырды:

— Әтине кыйнамагыз! Әтигә сукмагыз! Кыйнамагыз!—Аннан бүлмә селкетеп елый башлады. Ишектән килеп кергән бала — ике бантиклы, кыска күлмәк кигән, елаудан шешенгән һәм бер кулы белән яннан матур зәңгәр күлмәк итәген, икенче кулының имән бармагы белән аскы иренен тоткан кыз — тып-тып басып Ахияр янына килде.

Байгильдеев урыныннан сикереп торды да алгы бүлмәгә таба барышлый секретарь кызга каты бәрелеп кычкырды:

— Кайчаннан бирле беренче секретарь бүлмәсен балалар бакчасы урынына тотасыз әле!— һәм ул атылып алгы бүлмәгә чыкты. Чыкты да, туктап калды. Алгы бүлмәдә елап куркынган бер хатын тора. Байгильдеев аны тиз таныды, бу — районның иң мактаулы китапханәчесе Сольма Гарәфиева иде.

— Исәнмесез, Байгильдеев абый,— диде ул тотлыгып.— Иремнең машинасын китереп куйдылар, үзе юк. Шоферыгыз, берни дә әйтми, күзен читкә бора. Ни булды? Ни булды?

Байгильдеев берни дә әйтә алмыйча кире эчкә кереп китте һәм кычкырына башлады:

— Син! Гарәфиев! Бар хәзер үк кайтып кит! Бар дим! Иртәгә сәгать өчтә басуыңда бул! Аңладыңмы? Без сине тәртипкә утыртырбыз! Марш, дим, колхозыңа!

«Колхозыңа» дигән сүздәге басымны аңлап барысы да җиңел сулап куйдылар.

Атна-ун көн үткәч кенә билгеле булды: Гарәфиев теге көнне шәһәрдән килгән шефны һәм ПМК начальнигын ял иттермәкче булган икән. ПМК начальнигы, имеш, әйткән:

— Комплексыңны бик ашыктырасың да бит, малай, бер дә безнең күңелне күрмисең. Кара ул, беркөнне слетта нинди-нинди генә кызлар бар иде синең...

Ул көнне Ахияр бюродан чыккач юл буе әчтән елап кайтты.

## VII

Дөньяны җил бозар, адәмне сүз бозар, дип әйтә иде Ахиярның әтисе үз заманында. Председатель булгач, бу сүзләрнең хаклыгын Ахияр көннән-көн тирәнрәк аңлый барды... Боза торган сүз — безнең заманда «анонимка» дип атала. Анонимканың икенче исеме дә бар. Аны гапгади итеп «әләк» дип атыйлар. Председатель Ахияр әләк дигән афәтнең көчен, куәтен һич тә көтмәгән яктан сизде, зыянын күрде. Председатель турындагы әләкләр эчтәлекләре буенча, гадәттә, болай бүленәләр:

Председатель колхоз хисабына үзенә йорт салды; хатыны эшләми; яки хатыны идарәдә эшли, шунда ук хатынының җизнәсе эшли; председатель колхоз чутыннан машина алды; ул машинадан үз нәселе файдалана; чүннектә бал суыртканда председатель үлчәүгә кертмичә генә бер фляга бал тутыртты һәм шәһәрдәге туганнарына озаттырды; колхозның отчет-сайлау җыелышы көнне егерме тавыкка расход акты төзелде, әмма җыелыш тәмамланганда идарә әгъзаларының алдына (Хәмдениса апайларның өендә) нибары дүрт тавык чыкты.

Әмма Ахияр турында язылган әләк район, республика тарихында әлегә күрелмәгән, ишетелмәгәнчә иде.

...Көн уртасы. Тып-тын, эссе, коры һава.

Ахияр кырдан кайтып тирләп чәй эчеп утыра. Кемдер чоланны какты. Берәрсе авырып киткәндер, я бала табу йортына барырга кирәктер. Председательнең ишеген шундый очракта гына кагалар. Ахияр шундый вак борчуга әзерләнеп чоланга чыкты.

— Мәскәүдән кеше килгән, сезне чакыра,— диде идарә җыештыручы хатын.

Районнан, гадәттә, төшке аш вакытын турылап килмиләр һәм алай чакыртмыйлар да иде.

Идарә янындагы рәшәткәле бакча эчендә райкомның беренче секретаре Байгильдеев белән таныш түгел бер егет йөри иде. Идарә җыештыручы хатын әйтмәсә дә Ахияр теге егетнең каян килгәнен белгән булыр иде: Мәскәү халкының үз чырае, үз кыяфәте була. Аларның бите үк, чәче үк аерым. Аларның һәр хәрәкәте, күрешү-сөйләшүләре үк аерым, күпме тырышсаң да аларга житә алмыйсың. Байгильдеевнең йөзендә борчу күренде, әмма мәскәүле егет Ахиярга кулын сузганда көләч елмайды.

— Нургалиев,— диде ул Ахиярның бирчәйгән каты кулын (ике көн буе кичләрен Ахияр утын ярган иде) үзенең ак, чиста куллары белән кысып.— Сезнең өстән жалоба бар, шуны ачыклыйк әле. Әйдә, бүлмәгез кайда...

Ахияр каушады. Бүлмә ишегендәге эчке йозакка ачкыч туры китерә алмый матавыкланды. Баш мие берөзлексез эзләнде, дуылдады, кайнады. Теге көнне колхоз люцернасын шактый ук салып капка төбенә кайтып туктаган Исламыйны «Беларусь» кабинасыннан суырып төшергән иде ул... Шулмы икән? Булмас, Исламый гафу үтенде, люцернаны фермага илтеп бушатты. Алайса... Ә-ә... Алайса теге рәтсез Миңлекәй кулы бу, Миңлекәй исерек килеш идарәгә килеп кергән иде. Ахияр янына ук. Нәрсәдер исбат итәргә маташкан иде, Ахияр аны якалап алды да, чыгарып җибәрде... Алай дисәң, Миңлекәй юньле егет, ул көнне аларның өйдә тавыш чыккан булган, ул хатын коткысы белән килгән булган, ахырдан Ахиярга күренергә оялып йөрде. Авылның бердәнбер электригы. Юк, ул язмас.

— Менә моны укып чыгыгыз әле,— диде көләч йөзле затлы Нургалиев, дүрткә бөкләнгән, машинкада басылган бер бит кәгазьне Ахиярга сузып. Үзе елмайды.— Үзегезне недостойно тотасыз да, безне эштән аерасыз. Жалоба туп-туры Үзәк Комитетка килде. Мин инструктор. Әйбәтләп укып чыгыгыз...

Ахиярның күз алдында булган бөтен хәреф йөгерде. Ярый әле уңнан сулга, уку җаена йөгерде. Татарча баса торган машинка каян тапканнар? Авылда юк бит ул! Идарәдә бөтен булганы бер, ул да — рус хәрефе белән. Ә монда! Бер генә хәреф хатасы булсын!

«Яңа юл» колхозы членнары бу колхозның председателе Ахияр Гарәфиевнең кайбер идеологик хаталары турында партия Үзәк Комитетына хәбәр итүне үзебезнең намус эше дип карыйбыз. Дөрес, безнең колхоз дәүләткә ит, сөт, йомырка тапшыру буенча районда беренче урынга чыкты. Әмма безнең колхоз сугыш елларында да, председателе хатын-кыз булган чорда да гел алдынгы булып килде. Хәзерге чорда исә колхозның йөзен ит, сөт, йон җитештерү генә билгеләми. Председатель кеше колхозчыларны идеологик яктан да җитәкләргә тиеш. Сугыш елларында әнә шул якка игътибар ителә иде. Менә бер мисал.

Колан Кыр авылында Фәсхетдин исемле бер кеше яши. Авылда берәр кеше үлсә — шул күмә, законсыз рәвештә муллалык итә. Әнә шундый анти кешегә карата председатель Гарәфиев нинди позициядә тора соң? Председатель Гарәфиев бу анти кешегә финский йорт салырга ярдәм итте, районара базадан бу йортны ташырга машина бирде. Алай гына да түгел, бу йортны корып бирергә колхоздан кадрлар җибәрде, бүгенгесе көндә коммунистик идеологиягә каршы актив көрәш алып ба-

ручы чит элемент, кеше күмүче анти Фәсхетдин картка ярдәм итүе белән председатель Гарәфиев тәмам үзенең авторитетын югалтты. «Яңа юл» колхозчылары хәзер сорыйлар: без кайсы чорда яшибез? Коммунизмга таба кыю рәвештә барган чордамы, әллә Столыпин, Керенскийлар заманындамы? Райком нәрсә карый?

Бер төркем намуслы колхозчылар».

Затлы егет йөзенә мөлаемлек биреп «Сельская жизнь» газетасының төпләмен актара. Байгильдеев сигарет көлен рәт-рәт итеп фикус гөле төбенә коя, бүлмәдә авыр тынлык иде.

— Бу «анти» кайда?

Авыр тынлыкны Байгильдеев бозды. Ахияр урыныннан торды, гөл яфрагына күмелгән тәрәзә янына килде. Урамга рәнҗүле караш ташлады. Гөл яфрагында яшькелт сырлы бер корт ята, Ахиярның карашын тоеп булса кирәк, шым калды. Дуга ясап атлап маташа иде,— сузылды да тынды. Дөнья тараеп калды, сулыш житми иде. Ул борылды, әле дә булса гәзит укып утырган чиста йөзле Нургалиевкә карап алды, Байгильдеев һаман фикус төбен кайгырта иде. Ахияр пластмасса тартмадан бер кисәк киселгән кәгазь алды, калтырый-калтырый язу язды:

«Фәсхетдин абзый! Өеңдә булган бөтен-бөтен документларыңны төяп тиз генә идарәгә кил әле. Тиз бул. Ахияр».

Язу киткән арада өчәүләп утырып калдылар.

— Сөтләрең ничек?— диде Байгильдеев.— Бүгенгесе әйбәт, молодец. Савымчыларда ничәшәр сыер?

— Егерме өчкә житкердек инде...— Ахияр авыр сулады.— Миңа калса...— ул әле һаман теге жалоба турында уйлый иде,— миңа калса... Кул белән савуны яңадан кертер идем.

Байгильдеев усал карап алды.

— Трактордан баш тартып ат белән жир сөрергә күчәрсең, бәлки? Бәлки, кул белән урырга кирәктер? Искелек калдыгы Фәсхетдин карт белән дә дуслыгың бик көчле икән...

Ахияр тагын авыр сулады. Нургалиев һаман гәзит актара иде.

— Юк, иптәш Байгильдеев, кул белән уруны мин сагынмыйм. Әмма дә ләкин машина белән сауганда сөтнең иң куесын савып бетерә алмыйбыз без..

— Ничек алай?

— Ә менә болай: авыл халкында, сыер сауган халыкта, «ими төбе» дигән сүз бар. Сөтнең иң куесы, иң сыйфатлысы — шул. Сыер машинага әнә шуны бирми. Аны бары тик йомшак куллы хатын-кызга гына бирә ул. Сезнең белән мин саусам — безгә дә бирми. Сыер шундый нәзберек ул.

— Соң машинадан баш тартып булмый бит инде?

— Баш тартып булмый хәзергә, әмма аны камилләштерергә мөмкин. Галимнәрнең бурычы — машинаны кеше кулы манипуляциясенә мөмкин кадәр якынайту.

Мөлаем егет тәки әңгәмәгә катнашмады.

Ул арада бүлмә ишегеи кактылар...

Фәсхетдин абзый юллы күлмәк өстеннән таушалган гына пинжәк, башына байтак еллар хезмәт иткән эшләпә кигән, бераз бөкрәя төшкән, сакалын түгәрәкләп калдырып кырган, аякларына озын башлы галошлар элэктергән иде. Керде, сәлам бирде:

— Әссәламөгаләйкем, исәннәрмесез, иптәшләр,— диде.

Кулында кечкенә генә киндер букча иде.

Нургалиев гәзит төпләмен япты, Фәсхетдин агайга сынаулы караш ташлады. Агайга урын бирделәр. Ахияр белән Байгильдеев гөлләр күмгән тәрәзә янына килеп бастылар, урамга текәлделәр. Сүзне, әңгәмәне Нургалиев алып китте. Ахияр моны колак чите белән генә тотты, хәер, бер авазны да ычкындырмады. Сүз болайрак барды.

— Абзый, сез ничә яшьтә?
— Энем, миңа быел аугустта нәкъ сиксән тула.
— Ни белән көн итәсез, Фәсхетдин абзый?
— Мин, энекәш — пенсионер. Пенсионер кеше шул пенсиясе белән көн итә инде ул.
— Күпме аласыз?
— Нәкъ алтмыш җиде тәңкә дә утыз тиен.
— Күпме, күпме?
— Нәкъ алтмыш җиде тәңкә дә утыз тиен.
— Колхозда аның кадәр пенсия буламыни?
— Ә мин инвалидлыкка алам.
— Ничек инвалидлыкка?
— Шулай, яраларым бар.
— Ник, сез бу сугышка эләктегезмени?
— Юк, башта әле мин кызылармеец. Аннан Ватан сугышында ике тапкыр яраландым.
Мөлаем егет беразга тынсыз торды. Фәсхетдин карт исә ашыкмыйча гына янчыгын чиште һәм өстәлгә бер кушуч тәңкә койды.
— Болар кемнеке?— диде Нургалиев.
Карт елмайды:
— Барысы да үземнеке, энекәш. Менә «Кызыл Йолдыз» ордены, менә — кенәгәсе.— Карт куен кесәсеннән бер пачка кәгазьләр алды.— Менә «Отечественная война» ордены — менә кенәгәсе.— Картның күзләр әйбәт күрә икән, орден кенәгәләрен төп-төгәл генә аралап бирә барды.— Менә монысы саф солдат ордены —«Слава»ның өченче дәрәҗәсе. Ә менә монысы — медальләр. Барысы да үземнеке — менә документлары. Хәзер сөйлиләр әнә: үлгән фронтовикларның орден-медальләрен тагып йөрүчеләр бар икән. Минемчә, бу — дөньяда иң зур гөнаһ.
Инструктор шаккатып бабайга карап утырды. Бабай сөйли бирде.
— Кайттым — кырык бишнең май ахырында ук кайттым. Безнеке иң кырый яшь. Туксан сигезләрдән Берлинга барып җиткән кеше күп булмагандыр. Без беренче демобилизация белән. Кайттым — хуҗалык тузган. Киттем военкоматка. Орден-медальләр өчен акча бирелә дип фронтта ук аңлатканнар иде. Күрәм — военкомат кешеләре акча исәплиләр.— Карт көлеп куйды.— Алты мең дә җиде йөз акча алып кайттым, белдегезме, шуны... Аннан ике малайга...
Инструктор аны бүлдерде:
— Нинди малайлар?
Карт йомарланган кулъяулыгын чыгарды, күзләрен сөрткәндәй итте. Тамак кырды.
— Минем икәү бетте бит.— Тагын тамагын кырды, пиджак кесәсеннән тагын бер янчык чыгарып өстәлгә бушатты. Өстәлгә дүрт-биш орден, дистәләгән медаль чәчелде.
— Берсе лейтенант иде. Өлкәне. Ә кечесе — кечкенә лейтенант булды. Бер йолдызлы. Сугышта иң авыры шул составка бит. Солдат белән бергә пуля астында да ятасың, солдат өчен җавап та бирәсең. Ә безгә нәрсә? Дөрес, мин үзем дә разведротада булдым. Малайның берсе Курск дугасында, икенчесе Шауляй янында бетте. Бөтен истәлекләре шушы...
Инструктор тирән, авыр сулады (үзенең әтисе нәкъ Шауляй янында һәлак булганын белә иде).
— Соң бит, бабай... Сезгә тагын ни җитми?
— Барысы да җитә, энем. Совет властена рәхмәт. Менә председатель Ахияр иптәшкә рәхмәт. Йорт салырга булышты. Собестан чиратсыз йорт бирделәр. Ахияр энекәш машина, кешеләр бирде. Мин әнә шул юньле кешеләр, чын коммунистларга көн саен сәламәтлек теләп яшим...
— Бабай... Туктагыз әле. Менә монда сезне законсыз рәвештә муллалык итә, дип язганнар. Ничек инде ул? Сез бит...

Фәсхетдин агай тагын ишек яныннан кире килде.

— Энем,— диде ул тамагын кырып, бераз тын торгач.— Энем... Монда бит ике әйбер турында сөйлиләр. Дин белән тормышны бутыйлар. Кеше күмү — диннәнмени ул? Сугыш вакытында иң изге бурыч нәрсә? Яралыга ярдәм күрсәтү, командирны саклау, күмү, өенә хәбәр итү. Диннән югары бит болар! Менә авылда ярый әле без бар. Киләчәк буын мәетне ничек күмәр? Хәзер бит бульдозир заманы. Искаватыр заманы. Җир йөзендә кешедән дә кыйммәт нәрсә бар? Шуның туыннан, үлүеннән дә зуррак тагын нәрсә бар? Менә мин шуларны — туу, үлү, күмү йоласын беләм. Болар миңа борынгы ата-бабадан тапшырылган. Мин үлгәч кем үтәр бу йоланы? Тагын ун, егерме елдан безнең авыл кешеләрен кем күмәр? Ничек итеп күмәрләр? Энем, син дә, мин дә, иптәш Гарәфиев тә— барыбыз да үләсе бит... Нигә әле шуны онытырга тиеш без? Ник? Кеше булып туып, кеше булып яшәп, гомер узгач җир астына да кеше төсле керергә кирәк бит. Без— фашистлар түгел бит. Кешене олылап күмү яшьләрне итагатьле итеп тәрбияләү өчен кирәк ул... Дин түгел бит ул...

Карт дулкынлана иде, моны председатель бүлмәсендәгеләр сизделәр.

— Аннан соң, энем..., Син әле яшь кеше. Динне дә сүгәргә ашыкмагыз. Заманнан, үткән тормыштан карагыз. Сәвит власте динне кысмады, рәхмәт. Сугыш вакытында колхозчылар, академиклар акчаларын танк колоннасына бирделәр. Шунда «Правда» язды. Без ул вакытта зур һөҗүмгә әзерләнеп ята идек. Дингә ышанучылар да танк колоннасына акча керткәннәр. Ватан —газиз бит ул. Шунда безнең политрук укыды. Сталин язган: «Шундый-шундый ярдәмнәре өчен,— дигән,— дингә ышанучыларга минем рәхмәтемне белдерегез». Ә ул зур сүз иде, дәүләт сүзе.

Инструктор авыр сулады.

— Бабай... Хәзер ничек яшисез?— диде ул кашларын җыерып. Фәсхетдин карт аңа таба өстәл аркылы шуышыбрак килде.

— Энем, рәхмәт. Хәлемне белгәнегез өчен рәхмәт. Мәскәү тикле җирдән килеп минем хәлемне сорашканыгыз өчен рәхмәт. Миңа пенсия түләп торган хөкүмәтебезгә рәхмәт. Телевизор карыйм бит мин. Чит илләрдәге авыр хәлләрне беләм. Менә хөкүмәт карчыгым белән миңа йорт бирде, ә председатель шуны урнаштыруга ярдәм итте. Кайсы илдә картларны шулай кадерлиләр?

Карт орден-медальләрен янчыгына тутыра-тутыра сөйләде. Инструктор егет торды, өстәл яныннан чыкты да, картның кулын кысты:

— Исән-сау яшә, бабай,— диде.— Үтенечең булганда туп-туры бу егетләр (ул Байгильдеев белән Ахиярга күрсәтте) янына кил.

— Рәхмәт, энекәшләр, рәхмәт,— диде карт һәр өчесенә борылып.— Хәлемне белгәнегез өчен рәхмәт.

Карт, идарәгә кергәндәгегә караганда, гәүдәсен турайтыбрак чыгып китте. Ахияр җиңел сулады.

— Менә Мәскәү кадәр җирдән сезне борчып йөртәләр бит юлда,— диде Ахияр уңайсызлык белән.

— Ничего, иптәш Гарәфиев. Сезгә килүем моның өчен генә түгел, башка зуррак мәсьәлә белән дә килдем мин сезнең республикага. Әмма мондый жалоба бирәү генә килгән дип уйласагыз — ялгышасыз... — Ул Байгильдеевкә карады.

Ахиярның йөрәге дерелдәп алды.

— Жалоба беркайчан да бирәү генә булмый,— дип сүзгә катнашты Байгильдеев.— Алар бер-бер артлы тезелеп йөрергә яраталар. Ә икенчесе — җитдирәк. Һәм монысында инде сине, иптәш Гарәфиев, Фәсхетдиң бабайның орден-медальләре коткара алмаячак. Монысы — минем исемгә.

Байгильдеев папкасыннан бер кәгазь чыгарды. Нәкъ шул ук форматта, нәкъ шул ук машинкада.

Ахыры киләсе санда

# Гамил Афзал

## ШАТЛАНДЫ КҮҢЕЛ, САФЛАНДЫ...

### Гомер

Эгей диңгезе ярлары сары комлы, сөзәк.
Зәңгәр күкле Иония—Гомер туган төбәк.

Кешелекнең бала чагы,— язу туган, димәк,
Фикер туган, җырлар туган, көйләр туган төбәк.

Җиде шәһәр бәхәсләште: Гомер мондә туган...
Җиде шәһәр җиде җирдә, юлларында тузан.

Җиде шәһәр юлларыннан Гомер җырлап узган,
Офыкларда ак болытлар, үрләрендә урман.

Балыкчылар, игенчеләр, һөнәрчеләр иле,
Ак сакалны җилфердәтә җылы диңгез җиле.

Җиде шәһәр бәхәсләште: Гомер — минем кеше...
Җиде шәһәр юлларында булды аның эше.

Лирасын бау белән бәйләп, иңбашына асып,
Юлны таяк белән капшап, җиргә горур басып,

Базарларда, мәйданнарда ил сулышын тыңлап,
Йөрде аэд лира уйнап, озын җырлар җырлап.

Эгей диңгезе ярлары ташы яшькелт-сары,
Яшькелт сары ярга кага Эгей дулкыннары.

Бөдрә чәчле, зәңгәр күзле, дәртле егет-ирләр
Сөлек кебек кызлар белән уйнап үскән җирләр.

Батырлар турында җырга колак сала меңнәр:
Кешеләр кебек аллалар, алла кебек ирләр.

Алиһәләр сылу йөзле, нәфесләре харап:
Көрсенәләр нык бәдәнле егетләргә карап.

Кояш алласы Гелиос күктән карап тора,
Ай алиһәсе Селена аны алмаштыра.

Йөри Гомер җырлар җырлап, сандалие күннән,
Ап-ак озын күлмәк белән кызгылт җилән кигән.

Иңбашына лира аскан, ак сакалы билдән,
Күзе күрми, җыр язалмый камыш каләм белән.

Илле ел поэма язды күзләр күргән чакта,
Җыр тыңлады, җыр җырлады моң-аһәңле чатта.

Иген үсә, кошлар сайрый — ямьле алда-артта,
Һәр кыштырдау бик кадерле изге туган якта.

Яр буенда учак яна, лира кылы чыңлый,
Батыр Одиссей турында балыкчылар тыңлый.

...Посейдон болгата суны, ярсу диңгез тынмый,—
Тапкыр Одиссей турында диңгезчеләр тыңлый.

Олимп буйлары күгелҗем, хыял күге иркен —
Аллалар һәм алиһәләр йөри төркем-төркем...

Лира чыңлый, Гомер җырлый уңыш, бәхет юрап,
Игенчеләр бәйрәмендә ул кадерле кунак.

Күңел күзен үткәннәргә хисләр җитәкләде,
Серле томанга төренгән Олимп итәкләре.

Лира чыңлый, Гомер җырлый эш кешесен зурлап,
Хезмәт халкы бәйрәмендә ул кадерле кунак.

Борей иссен, чайкалдырсын елга камышларын,
Эвр иссен, алып китсен эллен сагышларын!

Җәфалаган, сөендергән көчләр төрле-төрле,
Кешелекнең сабый чагы, бөтен нәрсә серле.

Берәр грек кунак җыя, үгез, тәкә суя,
Өстәлләргә кан төсендә кызыл шәраб куя.

Кадерле кодалар өчен мичкәләрдә сыра,
Виноград шәрабы тулы амфоралар тора.

Уенчылар кунакларның күңелләрен күрсен:
Биючеләр биесеннәр, аэд җырлап бирсен!

Чакыралар, Гомер килә, бөек шагыйрь тыйнак,
Сакалы ак, чәчләре ак, чал арслан сымак.

Җиде кыллы лирасының кылын чиртә-чиртә,
Утыз мең юл поэмасын яттан сөйләп китә.

Күрми торган зур күзләрен еракларга төбәп,
Бер өлешен сөйләп уза, бер өлешен көйләп:

...Афродита кебек кызлар кулда киндер юар,
Көлемсерәп бер караса, егет акылын җуяр.

Еленаның чибәрлеге кырык кызга җитәр,
Кем елмайса — шуның белән җир читенә китәр.

Еленага күз төшерә азгын узгынчылар,
Шул Елена аркасында тавыш-гауга чыгар.

...Ир йортына тугры, эшчән Пенелопа чибәр,
Пенелопа кебек кызлар дөньяларны бизәр.

Пенелопа киндер суга, эштә кич вә иртә,
Ят ярларга күзен салмый, Одиссейны көтә.

Эол иссен, чайкалдырсын елга камышларын,
Эвр иссен, алып китсен эллен сагышларын!

...Агамемнон трофейлары күп вә төрле-төрле,
Ул үзенә күп алды да, солдатка аз бирде.

Агамемнон каты куллы, язмышларны бора,
Явызлык һәм көч артында бәхетсезлек тора.

Агамемнон бик тәкәббер, таш бәгырьле иде,
Таш бәгырьле усал иргә хәтәр үлем килде...

Күкләр зәңгәр, кырлар яшел, тау битләре соры.
Бакыр пычак, бакыр сөңге, бакыр балта чоры.

Илион болыннарында үсә билдән үлән,
Бик күп гомерләр киселгән бакыр кылыч белән.

Гектор батыр, Ахилл батыр, ай-һай батыр ирләр,
Дәртле аэдлар аларны арсланга тиңләр.

Илион яланнарында, һай, каберләр тулы,
Кыска була батырларның данлы гомер юлы.

Борей иссен, чайкалдырсын Эгей камышларын,
Эвр иссен, алып китсен эллен сагышларын...

Таң алласы Эос калкып, көннән язмыш үрә.
Җыр патшасы Гомерне ул тагын юлда күрә:

Лирасын бау белән бәйләп, иңбашына аскан,
Шома таякка таянган, үзе тере дастан,

Мәһабәт ир китеп бара илгә-көнгә ярап,
Күрми торган күзләр белән еракларга карап.

## Дон Кихот белән әңгәмә

Тәрәзәмә галәм сере кунган,
Айга карап уйга талам мин.
Фикердәшне тарих тынлыгыннан
Әңгәмәгә чакырып алам мин.

Почмакларда серле эңгер-меңгер.
Сөңге, калкан тотып, ут йотып,
Бер сөйләшеп утыру — бер гомер, дип,
Килеп керде шулай Дон Кихот.

Үзе юаш кына, үзе усал,
Йөзе җитди — исең китәрлек.
Сәлперәйгән мыек, кәҗә сакал,
Күз карашы, ташны тишәрлек.

— Чәйдән җитеш, синьор, варенье сал,
Сервантесны укып киләбез...
Син, Дон Кихот, төскә генә усал,
Җаның алтын синең — беләбез.

Син, идальго, зирәк, күпне күргән,
Киң карашлы заман җимеше,
Ярты мең ел көлеп дөнья гизгән
Хуҗа Насретдинның энесе.

Дәверләрнең канлы зилзиләсен
Ачы нәфрәт белән күзәтеп,
Өч гасырдан артык ил гизәсең
Гаделсезлек белән көрәшеп.

Пират сатты сине, фашист атты,—
Ә син һаман исән, үлемсез.
Кешеләргә син булганда якты,
Кешеләргә синсез күңелсез.

Кешелекле акыл үләмени,
Кешелекле фикер — гомерле.
Кеше бәхете өчен чын кешеләр
Үлем лагерьларын җимерде.

Ни хәтле ил гиздең, ни хәтле җир,
Кесәгә салмадың дукатны,
Син, Дон Кихот, кыю, гайрәтле ир,
Сабый бала кебек беркатлы...

Көләч күңел саклый сафлык көчен,
Намус эшли, зиһен уяна.
Акыл һәм хис тутыкмасын өчен
Көлеп яшәү кирәк дөньяда.

❀

Әй, замандаш, бик болгавыр дөнья,
Сугыш уты яна уңда-сулда,
Бер кенең дә тыныч түгел монда,
Бу өметле, бу хәвефле юлда,
Әй, замандаш, бик болгавыр дөнья:
Бик сагаеп соңгы хәбәр тыңла,
Тынычланып гамьсез күзең йомма,
Шартлый торган үлем тонна-тонна,
Әй, замандаш, бик болгавыр дөнья!

Бер горурлык хисе белән
Халык халык булып тора,
Җыры белән, эше белән,
Иртәсе һәм киче белән
Киләчәккә план кора,
Бер яшәүчән хисе белән,
Бер горурлык хисе белән.

Шигъри сүзем, үз ел телдән төшмә,
Челтерәп аккан чишмә кебек эшлә,
Йөрәктән йөрәккә күч, кулдан кулга,
Юлдаш булып яшә озын юлда!

Һәр халыкта иң кадерле нәрсә —
Моңлы җыры, тапкыр әкиятләре,
Моңнар басып, җаны җәберләнсә,
Әкиятләре белән әйбәтләде,
    Әйбәтләнде, матурланды мизгел,
    Җырлый-җырлый түзеп була йөз ел.

Ташкын сулар тәгәрәтеп килгән,
Бозлык эзе калган йөзендә,
Болгар илен, Буләр җилен күргән
Борынгы таш ята нигездә.
Болын ягы, бөгелә-сыгыла үлән...

Ятимлекне, мескенлекне
    Үзеңнән сыгып чыгар,
Көнчеллекне, мин-минлекне
    Үзеңнән куып чыгар,
Җилфер-җилфер җилләр иссен,
    Чылтырап аксын сулар...

Иң кадерле илаһи зат булып,
Без көләргә, елмаерга тудык.
Кояшлы көн, айлы кичләр кебек
Якты чырай белән әйбәт холык.
Әйдәгез, без гөлләр кебек торыйк!

Ватан туфрагында ни үссә дә,
Безгә кагылып үсте,
Чәчәк чугын чайкап җил иссә дә,
Җанга ягылып исте,
Шуңа микән, туган җир өстендә
Без иманнәр төсле.

Борчулы җәйләр кичендә
Башыңны куйма мендәргә,
Урманлы үрләр өстендә
Нәҗәгай уйный төннәрдә.
Җиләк исе җил төсендә
Кайгылар килә кемнәргә?

Һәр көнне бер белмәгәнне белдем,
Бер уңышка күңел кинәнде.
Бер басмага югарырак мендем,
Биеклектә күңел тирбәлде.

# Рөстәм Мингалим

# КАЙДА СЕЗ, ИРЛӘР?

МОҢСУ КОМЕДИЯ

**КАТНАШАЛАР:**

Асия (калын гәүдәле ханым).
Эльза (Асиянең яшьтәше).
Луиза (яшь кыз).
Ягуар (Асиянең ире).
Арслан (Ягуарның яшьтәше).
Булат (яшь егет).
Тимер.
Тимернең дусты.

**Вакыйга шәһәрдән ерак булмаган урман-сулы урында бара. Әсәр I, II кисәкләргә шартлы рәвештә бүленә.**

**Беренче бүлек**

**Еракка сузылган кырлар күренә. Урман, елга... Алан — өч чатыр, эленгән хатын-кыз киемнәре, туп... Кайдадыр тургай сайрый, аннан сайрау тына. Хатын-кызлар су керергә әзерләнәләр. Ир-атлар бер чатыр янына җыелган, алар нидер ныгыталар-бәйлиләр.**

Булат. Мин аны яхшы бәйләгән идем кебек.

Арслан. Менә шулайрак, тартыбрак бәйләргә кирәк.

Асия. Ягуар Шахматович! Ягуар! Тизрәк бул, күгәрченем...

Ягуар. Асия! Кума син!

Луиза. Ир-атлар арыган, Асия апа! Канатлары талган.

Эльза. Талыр да шул. Алар авыр күтәргән иде ләбаса...

Асия. Хәзер ял итәрләр. Озак калмады. Алда — су, һава, үлән...

Булат. Әй, тиз дә йөрисез соң, Асия ханым, күз тимәсен үзегезгә.

Ягуар. Ул танк кебек йөри. Килгәндә мин бөтенләй шабыр тиргә баттым. Асия, алай ук ярамый бит инде.

Асия. Кадерлем! Үзеңне хәзер су кертермен, йомшак сөлге белән сөртермен...

Луиза. Бирегез әле миңа, Булат. Бирегез, Арслан абый, үзем бәйлим. Мин бик көчле. Нәрсә? Ышанмыйсызмы?

Эльза. Бирегез, бир... Булышыйк.

Асия. Кызлар, вакытны әрәм итмик!

Арслан. Без алдан йөрик. Сез — безнең арттан, шул ярдәмегез булыр.

Булат. Дөрес сүз! Әйдәгез алдан.

Ягуар. Ялгышмагыз, Булат! Өстеңә басып үтүләре бар.

Асия. Сезнең өскә басарга ярыймы соң инде! Күгәрченкәйләр!

Ягуар. Ярамый да бит... Менә булды да.

Арслан һәм Булат. Шәп булды бу. Йөз ел торырлык.

Асия. Ир-атлар! Безнең өмет, безнең таяныч, бездән калмаска! Югалмаска! *(Су буена китәләр.)*

Ир-атлар. Әйдәгез. Калмаска *(җырлый башлыйлар)*.

Алын эзләп табарбыз,
Җанкайларга кирәксә.
Гөлен эзләп табарбыз,
Җанкайларга кирәксә.

**Кушымта:**

Ир югалмас юлларда,
Безнең кебек булганда.
Ир җиңелмәс юлларда,
Безнең кебек булганда.

**Әле генә бушап калган урынга Тимер һәм аның иптәше килә.**

Тимер *(иптәшенә)*. Нәкъ үзе! Икесен күргәнем юк, өченчесе — иң яше — Луиза. Ир-атлары... Болай тәзә генә күренәләр.

Иптәше. Шулайдыр, шулайдыр, ышандым, уеңны белдем...

Тимер. Мин аларның... Кайсының тешен коярга тиеш? Шуны да белдеңме?

Иптәше. Бәлки теш коешмыйча гына... Аңсыз гына барып чыгар.

Тимер. Ничек?

Иптәше. Кулыннан тотарсың да алып китәрсең.

Тимер. Нәрсәдер... син миңа бүген ошап бетмисең. Әйттем бит, житди эш дидем. Луиза өчен... Мин үтерә дә алам!

Иптәше. Үтерә дә алам... Тагы нәрсә?!

Тимер. Үтерә дә алам, дим!

Иптәше. Алар ерак китмәс, арыганнар да... Урыннарын күрдең. Аннан — алда елга, артта син. Әйдә, машина юлга якын калды. Аны урнаштырыйк, үзебез урнашыйк. Ишетәсеңме, Тимер?!

Тимер *(ачуланып)*. Бар, олак! Машинаны урнаштыр, үзегез урнаша торыгыз. Мин калам. *(Асияләр киткән якка карап.)* Ул минем кулдан ычкынырга тиеш түгел... Минем тимер кулларда.

**Иптәше китә. Тимер кала. Ул каен ышыгына барып утыра. Арты белән сөялеп, башын каенга салып, аякларын сузып утырган килеш, горур кыяфәттә нидер көтә... Елга ягыннан көлешкән-кычкырган тавышлар ишетелә. Тавышлар якыная.**

Луиза тавышы. Билгеле, бу капкара урманда һәр ерткыч та бар: юк түгел аю, бүре; төлке — җиһан корткыч та бар.

Булат *(чатырлар ягына килә)*. Һәм дә бар монда куян, әрлән, тиен, йомран, поши...

Эльза *(килә, башкалар да килә)*.

...Очрата аучы булып урманда күп йөргән кеше.

Арслан *(шаярып Тукай шигырен укуны дәвам итә)*.

Бик куе булганга монда җен-пәриләр бар диләр...

Луиза. Төрле албасты! *(Ул кинәт Тимер каршына килеп чыга һәм аптырап, хәтта калтыранып сүзен әйтә алмый тора.)* У-у-у-у-бырлар, шүрәлеләр *(Тимергә карап бераз тын торгач)*... бар диләр...

**Луизаның бу хәленә игътибар итеп, хатын-кызлар һәм ир-атлар да аның янына килә. Тимер тыныч кына утыра бирә. Гомум аптырау, ләкин бу халәт озакка сузылмый, Тимердән көләргә керешәләр.**

Ягуар һәм башкалар *(төрлесе төрле тавыш белән)*:

— Яп-ялангач.

— Ялангач түгел, нәп-нәзек...

— Ләкин кеше төсле үзе.

— Урта бармак буйлыгы бар маңлаенда мөгезе.

— Ялтырый, ялт-йолт киләдер эчкә баткан күзләре,

— Кот очар, күрсәң әгәр төнлә түгел — көндезләре.

**Тимер сикереп тора. Горур кыяфәт белән китеп бара.**

Луиза *(шомлы, тиз)*. Кил әле син дә бераз бармак селкет, и-и-и яшь егет! Килче икәү уйныйк бераз кети-кети.

Тимер *(туктап)*. Килермен, чибәркәй. Көтсәгез-көтмәсәгез дә, мин сезнең янга килермен. Бераз күңел ачып алыгыз. Без дә күңелләрне күтәрик, аннан соң сезнең янга кайчан килергә икәнне хәл итәрбез. Безгә очрашырга кирәк.

Луиза. Кети-кети...

Башкалар *(көлешәләр)*. Кети-кети...

Тимер. Очрашырга кирәк. *(Китә.)*

Арслан. Әйтәме малай?

Ягуар. Ялгыша, яшьлеге белән...

Булат *(Тимер киткән якка таба бара)*. Уау-воу-мооу. Ә мин бу агачлар арасында аю булып бөтенләйгә калырга да риза.

Луиза! Кызлар! Күрегез! Куян чаклы аю!

Эльза. Аю чаклы куян!

Асия. Хәзер урманда аюлар да, куяннар да, арсланнар да юк.

**А р с л а н.** Бүреләр бар *(бүре булып улый).*

**Берәү мәче булып кычкыра. Кемдер — эт булып өрә. Төрле кош-корт, җанвар тавышлары көчәя.**

**А с и я.** Күгәрченнәр! Оныттыгыз бугай!

**Б у л а т.** Онытмадык *(барып сумка ала).*

**А р с л а н.** Киттек, киттек, дуслар... *(Китәләр.)*

**Л у и з а.** Ә без?

**Э л ь з а.** Без су керә торабыз. Табын әзерлибез.

**Л у и з а.** Мин куркам.

**А с и я.** Кемнән? Нәрсәдән куркасың? Суданмы?

**Л у и з а.** Сездән... Теге, киткән кешедән. Судан курыкмыйм.

**Я г у а р** *(китеп барышлый).* Без хәзер әйләнеп киләбез.

**Луиза елга ягына китә.**

**А с и я.** Ягуар Шахматович· *(Артыннан җитеп.)* Башыңны сакла! *(Башына кидерә.)*

**Я г у а р** баягы җырның кушымтасын көйләп китә.

Ир югалмас юлларда,
Безнең кебек булганда.
Ир җиңелмәс юлларда,
Безнең кебек булганда.

**А с и я.** Менә дигән урын сайлаганбыз. Узган юлы бик үк җайлы урын булмады.

**Э л ь з а.** Нигә? Минемчә, ул урын мондагыдан ким түгел иде. Шулай ук су бар иде. Тыныч иде. Менә каеннар гына... Анда каеннар юк иде.

**А с и я.** Монда *(агачларга карап)* агачлар башкарак... Су — киң, яры сөзәк: мөлдерәп, тулып тора. Авыл да ерак түгел... Ир-атлар хәзер аннан сарык ите алып кайтырлар.

**Э л ь з а.** Безнең ит бар иде бит.

**А с и я.** Кыздыру өчен — сарык ите яхшырак... Игътибар иттеңме? Ярда чирәм шундый куе, шундый йомшак. Юк, монда яхшырак.

**Э л ь з а.** Узган яңгырдан соң үлән дә куера төшкәндер. Иң мөһиме — бүген синең кәефең яхшырак.

**А с и я.** Кәефем — узган юлы да әйбәт иде. *(Барып чатырларны карый. Никтер борчылыбрак кала.)*

**Э л ь з а.** Башта әйбәт иде, аннан бераз бозылды. Син сиздермәдең, ә мин сиздем.

**А с и я.** Әз генә булды шул. Ул көнне мин Луизадан бераз шикләнеп куйдым. Һаман Ягуар Шахматович та Ягуар Шахматович, ди, янында биеп кенә йөри бит, оча. Икесе бер араны югалып та торгач, күңелгә шик килде.

**Э л ь з а** *(көлә).* Асия, алар озак тормады бит.

**А с и я.** Ул минем иремме? Ирем! Каядыр югалып тордылармы? Тордылар. Сәгатькә карамадым.

**Э л ь з а.** Кызык, ничектер, мин Луизаны әле бала гына дип уйлыйм.

**А с и я.** Күгәрченкәем, мин дә шулай уйлыйм. Шулайдыр. Мин ул көнне онытгым инде *(урман ягына карап)*... Тагы... Ягуар Шахматович белән китте бугай ул.

**Э л ь з а.** Юктыр ла... Луиза! Луиза!!! *(Пауза.)*

**Л у и з а.** Монда мин. Киләм.

**А с и я.** Китмәгән икән...

**Л у и з а** *(җырлап килә).*

Алма булып төшәр идем
Алларыңа гына.
Ал мине! Мин алма!
Мин алма гына,
Мин бит алма гына.

Алма булып тамар идем
Яннарыңа гына.
Ал мине! Мин алма!
Мин алма гына,
Мин бит алма гына.

Асия апа! Тыңлагыз әле. Ишетәсезме?

**А с и я** *(бераз тыңлап торгач).* Ишетмим.

**Л у и з а.** Эльзакаем? Ишетәсезме-е-е. Килә бит...

**Э л ь з а.** Кем килә?!

**Л у и з а.** Тыңлагыз әле! Сөям *(пауза)* дигән *(пауза)* сүзләр килә!!! Әллә килмиме? Җил генә исәме? Нур гына явамы? Бу нинди көн?! Мәңгелектән бер көн. Матурлыгы, рәхәтлеге — кулларга кагыла *(кулларын тотып карый),* тәннәргә тарала *(тәннәрен тотып карый),* эчкә үтә... җанга тула. *(Пауза.)* Тоясызмы? Башың әйләнеп китәрлек *(нидер алып җиргә җәя, аның өстенә чалкан ята).* Сизәсезме?? Ә?!

**Э л ь з а.** Аңлашыла, Луиза. Хәлең аңлашыла. *(Луиза янына утыра.)*

**А с и я.** Аңлашылды шул бу. *(Эльза белән Асия көлешеп куялар.)*

**Л у и з а.** Аңлашылса, менә шул.

**А с и я** *(Луиза янына утыра).* Нәрсә? Әллә кияүгә чыгасың киләме?

**Л у и з а** *(Асиягә).* Оятсыз!

**А с и я.** Сүзеңне кире ал. Кызларның кияүгә чыгасы килүе табигый хәл. Әнә... Эльзадан сора.

**Э л ь з а.** Алма да вакыты җиткәч өзелеп җиргә төшә дигән өлкәннәр... Синең дә ва-

кытың житкәндер. Өзелеп төшсән... Әйбәт булмас... Үрелеп алсыннар, кара аны! *(Пауза.)*

**Ася.** Аларның үрелеп алганын көтсән...

**Луиза.** Алларына егылып төшәм! Яннарына тәгәрәп барам. Җәлләмим. Сөеклем, ал мине... *(Ике кулы белән битен каплый.)* Мин ал-ма.

**Эльза белән Ася аптырашып бер-берсенә карый. Луиза җырлый.**

Алма булып ятар идем
Кулларыңа гына.
Ал мине? Мин алма!
Мин алма гына,
Мин бит алма гына!

**Ася.** Алмакай, балакай! Ач әле йөзеңне, күзеңне. *(Көчләп Луизаның битен ача.)* Ул сиңа нәрсә ди?

**Луиза.** Кем?

**Эльза.** Яратам диме, өйләнәм диме, Булат?

**Луиза** *(торып утыра).* Әллә сез миңа ышанмыйсыз инде? Булат белән безнең арада бернинди мәхәббәт тә юк. Без — иптәшләр, күптәнге танышлар. Бер чорда укыдык. Вуздан соң эшебез бер тирәгә туры килде. Бу ялда, безнең урманга барасын белгәч, Булат рөхсәт сорады. Мин дә сезнең белән чыгар идем диде. Без киңәштек. Рөхсәт иттек. Шулай бит, Ася? Эльза апа?!

**Ася** *(тора, кучеп утыра).* Белабез, белабез. Сез бергә эшләгән иптәшләр генә. Без дә менә Ягуар Шахматович белән бергә эшләгән иптәшләр генә идек. *(Пауза.)* Бервакыт минем кияүгә чыгасы килмәсенме?! Чын! Чыдар хәлләрем калмагач, мин аны үземә өйләндердем. *(Әкрен генә, хәйләкәр тавыш белән.)* Өйләнәсең миңа и вәссәлам. Мин сине бәхетле итәм. Югыйсә азау тешеңне какшатам *(кулы белән теш какшату хәрәкәтен ясап күрсәтә).* Заман безнеке, дидем. Азау теш, ягъни — авторитет. Моны Ягуар Шахматович бик яхшы аңлады. Бик ярата иде ул мине... Мин аны.

**Луиза.** Мин Булатны яратып бетермим шул. Яратсам — ул күптән минеке булыр иде.

**Ася.** Ярату өчен кешене яхшы белергә кирәк.

**Эльза.** Якыннан белергә кирәк. *(Ася янына барып утыра.)*

**Луиза.** Якыннан белдем инде.

**Ася.** Якыннан дип? Ничек? Якыннан белдең?!

**Луиза.** Бик якыннан, бөтенләй, тәмам якыннан белдем. Барыбер танышлар гына булып калдык. *(Ася белән Эльза янына бара.)*

**Ася.** Менә сиңа — исәнме кодача? Алай булгач, күгәрченкәем, яратырсың әле, яратасың аны... Яраттыра ул.

**Луиза.** Табигый булмаса, яраттырмый.

**Эльза** *(Асиягә. Луизаны истә тотып).* Ул, минемчә, бу өлкәдә надан түгел.

**Ася.** Шулай булып чыкты шул. Ә без... Ә без, карт тиләләр.

**Луиза.** Надан калырга ярамый. Сезнең кебек өйрәтүчеләр барында. *(Утыра.)*

**Эльза** *(Асиягә).* Ишеттеңме?

**Ася.** Ишетмәгән кая?!

**Эльза** *(Асиягә).* Луизаның сиңа охшаган яклары бар дип әйтимме? *(Пауза.)* Баштарак мин сезне туганнар дип уйлый идем.

**Ася.** Миңа гына охшап калмаган. Бу мине үтеп киткән кебек күренә. Бигрәк тә мәхәббәт мәсьәләсендә.

**Луиза.** Ася апа?! Алай ук түгел инде.

**Ася.** Алай ук булсын, күгәрченкәем. Булсын. Хәзер ирләргә шулай булу кирәк. Алармы?! Алар... өйрәтмәсәң ни эшләргә белмиләр. Өйрәтсәң дә белмиләр. Белсәләр — хәлләреннән килми. Әйтәм бит... «Әйдә бергә яшибез! Килештекме? Мәңгелек мәхәббәтем минем!»— дидем мин Ягуар Шахматовичка. Килешмәгән кая? Өйләнде. Соңрак ул юньсез миннән ычкынырга да чамалаган иде. Кыймылдатмадым да тегене *(пауза).* Хәзер — бөтенләй кыймылдамый. Кайта да ята, кайта да йоклый, уянса газета укый, күгәрченкәем. Укый да укый, кашы-күзе җимерелгән: Гарәбстандагы хәлләр өчен янә, космос өчен борчыла, айга менә алмаганы өчен кайгыра... Ә миңа *(пауза, бер бармагын югары күтәрә)* тагы бер кыз кирәк. Шушы бармак хәтле генә кыз... Юк, булмый... Булмый дигәч тә... Мин аның кызын табар идем: куркыта, үстерүе кыен булыр кебек. Мәшәкатем муеннан. Чиләк белән иләк эзләүдән тормыш башладым. Бүгенгә хәтле кирәк-яракны җыеп бетерә алганым юк *(пауза).* Мин килгәндә Ягуар Шахматовичның өе шыр-ялангач иде. Ялангач өйнең идәнендә ялгыз телефон көне-төне шалтырап утыра.

**Эльза** *(куаклар ягына карап).* Анда кемдер бар бугай.

**Луиза.** Ягуар Шахматович тыңлап тора.

**Ася.** Ягуа-ар! Күгәрчен! Мине ишетәсеңме? *(Кызларга.)* Сезгә анда кеше бар кебек тоелган гына, кайда калдым әле.

**Луиза.** Идәндә, телефон янында.

Асия. Ул телефонда... өй өчен... бер тиенлек тә файдалы сүз юк *(пауза)*. Ә безнең эшләребез өчен, гүзәл шәһәребез, суларыбыз, шушы кырларыбыз, шушы як халкы өчен файдалы сүз күп булды микән?! Бусын төгәл әйтә алмыйм. Ләкин анда безнең хакта сүз юк. Анда болайрак: «Алло! Марста фәлән нәрсә тапканнар, ишеттеңме? Алло! Японниядә фәлән хәл, алло! Египетта гигант Асуан плотинасы төзелеп беткән... Грециядә, Португалиядә дәүләт перевороты... Алло!» *(Шунда Асия кулы белән чирәмне капшый, телефон трубкасы итеп файдаланыр әйбер эзли башлый.)* Кая соң, бер телефон трубкасы кебек нәрсә кирәк. Шунсыз сөйли алмыйм. Дөрес сүземә ышандыра белмим.

Луиза. Ышанырбыз, Асия апа.

Эльза. Ышанабыз, ышанабыз.

Асия. «Англиядә забастовка... Бельгиядә забастовка. Алло, Ирландиядә демонстрантларны аталар... Оккупацияләнгән гарәп илләрендә террорлык... Атаклы җырчы негр Поль Робсон үлгән. Алло!.. Көнбатыш Германиядә корылык. Франциядә корылык... Алло!» «Да!»— дидем берсенә бервакыт. «Слушаю Вас», дидем. «Гафу итегез, Ягуар Шахматович кирәк иде», ди. «Ул өйдә юк? Минем белән сөйләшегез. Юкса гафу итмим», дидем. «Минем сезнең белән сөйләшәсем килә, икәү сөйләшик», дидем. Көлгән була тегеc. «Мин сезнең белән сөйләшергә һәрвакыт әзер. Сезнең тавышыгыз шундый ягымлы, хәтта әле каушап калдым... Ничегрәк... Ни хакында сөйләшербез икән», ди. «Үзебезнең хакта сөйләшик, дим. Үзебезнең хакта сөйләшик. ФРГ хакында түгел. Негрлар хакында да түгел. *(Тагы трубка урынына файдаланырлык әйбер эзләп чирәм капшый башлый.)* Безгә үзебезнең хакта сөйләшергә кирәк. *(Пауза.)* Кичекмәстән, хәзер үк безгә үзебезнең хакта сөйләшергә кирәк! Юкса соң була *(чирәм капшый)*. Ишетәсезме? Соң була!» *(Асия кинәт куркынычтавыш белән кычкырып җибәрә.)* А-а-а-а! *(Кычкырган уңайга торып баса.)*

Луиза белән Эльза *(кинәт торып)*. Асия?!

Эльза. Нәрсә булды?!

Луиза. Асия апа?!

Асия *(йөрәген тотып, хәлсез калып тора)*. Уф! Йөрәгем ярыла язды.

Эльза. Әйт тизрәк. Нәрсә?..

Асия *(әкрен генә)*. Бака... тоттым.

**Кызлар иркен сулап, елмаешып куялар.**

Эльза. А-ася! Шулай ярыймы соң? Куркыттың бит?! *(Пауза.)* Йә! Шуннан үзебезнең хакта сөйләшик дигәч?..

Луиза. Очрашу билгеләмәдеме?

Асия (ирония белән). Билгеләде. Хәзер, кызлар! Кулымны гына юып килим. Бөтен уемны таратты бу бака. Кулымда эзе калган кебек. *(Китә.)*

Луиза *(Эльзага)*. Ягуар Шахматович зур кеше. Дусларытанышлары да үзе кебек зур кешеләр. Шуңа күрә зур проблемалар, Җир, Дөнья, Планета турында уйлыйлар, шул хакта сөйләшәләрдер. Минемчә, аларны моның өчен гаепләп булмый. Шулай инде, түбәндәрәк яткан — ваграк мәсьәләләрнең үз кешеләре була. Алар шуларны хәл итә, күбрәк шул хакта сөйләшә. Аларын да гаепләп булмый.

Эльза. Бу очракта Асия ганлә тормышыннан, бүгенге хәлләрдән, бүгенге көннәрдән алган тәэсирен уртаклаша *(пауза)*. Бөтенләй үк ялгыш сөйләми кебек ул.

Луиза *(уйланып тора)*. Сез күбрәк яшәгән, күбрәкне күргән кешеләр. Миңа сезгә ышанырга гына кала. *(Пауза.)*

Эльза. Ышанырга ашыкмасаң да була... Безнең сүзләр турында уйлап карарга ярый. *(Пауза.)* Ни әйтсәң дә, гаиләләрне, балаларны юатып, рухландырып, саклап баручы, алдан юл яручы итеп ир-атлар кабул ителгән. Алар турында уйлану ярый *(пауза)*. Ир-атларның бераүләре, син әйткәнчә, вак мәсьәләләрне генә кайгыртып, дөньяның вак мәсьәләләренә кереп бата, икенчеләре зур мәсьәләләргә кереп китеп югала бармыйлармы? Гаиләләр нигезендә, уртада, зур һәм вак мәсьәләләрнең тоташкан урынында, кемнәр кала? Син дә, мин дә, Асияме? Уртада — мәйдан. Анда эшләр күп. Көрәшәсе бар. Мәйдан уртасына ирләр кирәк.

Асия *(су буеннан килеп җитә һәм Эльзаны ишетеп кала.)* Дөрес, күгәрченкәйләрем. Уртага ирләр кирәк. Алар һаман кырыйда. Уртагарак, уртагарак!— дип кырыйсың,— һаман аңламыйлар. Төртеп кертәсеңмени?! Гомер буе тормыш кырыенда йөреп, без тормышның үзәгендә кайнадык дип, җан биргәчәк хәзерге ирләр. Киләселәре дә шулай булачак! Аннан арылар, күз алдына китереп карасаң, кызганыч. Ул чордагы хатын-кызларны уйласаң — күңел тула. Алар нишләр?! *(Пауза.)*

Луиза. Сез ир-атны ник шул кадәр яратмыйсыз?

Эльза. Яратмасак, урманга ялгыз килгән булыр идек.

Асия. Алар юк.

Л у и з а. Килеп житүләре, ишетеп торулары мөмкин.

А с и я. Ишетсәләрме? Безне ишетсәләр, ир-атлар үз хәлләрен аңлый башларлар иде. Югыйсә алар...

Л у и з а. Югыйсә алар *(космоска ишарәли)*, тегендә, югарыда кораблар тоташтыралар.

Э л ь з а. Корабларында тоташа торган урын булгач, программаларында шул каралгач, тоташтыралар инде аны, сеңлем.

Л у и з а. Ә Бөек Ватан сугышы вакытында? Карбышев! Җәлил! Газинур! Алар да программа буенчамы?

Э л ь з а. Беләсең килсә, ил өчен кирәк булганда *(пауза)*...

А с и я. Ил өчен кирәк булганда Асия апаң менә шушы күкрәге белән ике амбразураны капларга әзер *(пауза)*. Берне каплый да каплый. Эльза апаң да...

Л у и з а. Мин дә сездән калышмам...

Э л ь з а. Сугышның, сеңлем, үз программасы. Анда бер генә сүз — җиңәргә! Сугышта, чынлап уйласаң, ир-ат та, хатын-кыз да юк, анда солдат кына бар. *(Пауза.)* Асылда, сугыш ирләр эше. Борынгыдан ирләр дәүләтләрне җимергәннәр, төзегәннәр, кушканнар, бүлгәннәр, алганнар *(пауза)*. Безнең эш — борынгыдан хатын-кыз эше булган...

А с и я. Тудыру, үстерү...

Л у и з а. Сез... бүгенге хатын-кызның тормыштагы ролен кечерәйтергә телисез.

А с и я *(Луизага)*. Син зурайтырга телисең. Ашыкма, күгәрчен. Заман үзе зурайтыр, тик кирәгеннән артык зурайтып куймасын!

Э л ь з а. Җирдә чын хатын-кызлар калырга тиеш. Ир-атлар — космоста да, өйдә дә, бүген һәм киләчәктә дә чын мәгънәсендә ир-ат, гайрәтле, нык, сәламәт булырга тиешләр.

А с и я *(Луизага)*. Чынлап та, карале, врач кеше! *(Пауза.)* Бер кечкенә, ләкин, дөрес булса, житди фактка игътибар иткәнең булмадымы? Медицинага мөрәҗәгать итүче ирләр саны елдан ел арта, имеш. Күрер күзгә таза ир-атлар врачларга хәлсезлектән зарлана икән?!

Л у и з а. Үз көченә ышанып житмәве аркасында үзен хәлсез тойган — врачларга ялгыш! күренеп йөргән ирләр була. Ә чире булмый...

Э л ь з а. Ялгыш врачка йөрү — үзе чир инде ул.

А с и я. Хәлләре булмагач, үзләренә ничек ышансыннар? Врачка йөрми кая йөрсеннәр, күгәрченкәйләр! Ныклык, булдыклылык житмәгәч...

Л у и з а... Булдыклылык ул аерым шәхесләргә күбрәк бирелә торган сыйфат, талант. *(Пауза.)* Ныклык ирләрдә житәрлек — алар суга, утка кереп тә, күктә йөреп тә дөньяны ышандырдылар. *(Пауза.)* Мин ышандым.

А с и я. Мин дә ышанган идем. *(Пауза.)*

Э л ь з а. Ышаныч та кечерәя ала.

А с и я. Минем бабай башта өч тапкыр өйләнгән, өч хатыныннан да бер көтү бала. 60 яшендә бабай дүртенче тапкыр өйләнгән, тагын бала туган. Хатыннары да, бабай үзе дә, тудырмаска кирәк димәгәннәр. Хатыннары тугрылыклы, бабай гайрәтле булган. Шул авыр заманда да үзендә балаларын үстерерлек көч тойган. Ә ул заман — бүгенге белән чагыштыргысыз авыр заман. *(Пауза.)* Авырлыкларга үч итеп яши торгач, минем бабай бик кызу канлы картка әйләнгән. Бервакыт юлда аның йөген тарта алмаган атына шундый ачуы килгән... Аны йодрыгы белән сугып үтергән. Колак төбенә суккан.

Э л ь з а *(бераз шаярып)*. Тормыш кайчак чын ирләрне дә чыгырдан чыгара. Ир исеме дә килешеп бетмәгән берәүгә тап булсаң, нишләрсең? Луиза?!

Л у и з а. Ул карт — тиле булган.

А с и я. Тиле карт туксан бер ел яшәгән, илгә хезмәт итү өчен балалар калдырган. Балалары да акыллы булган.

Э л ь з а. Тиле картның югары белеме булмаган, балалары гына күп булган. Без *(Эльзаның тавышы тагы да көчәя, ачыклана)* — югары белемле, югары акыллылар! **Өч хатын-кыз өч тарафка аерыла. Шаярып сөйләшәләр. Сүзләре — кычкыруга әйләнә бара. Тавышлар аланда яңгырый.**

Л у и з а. Тилеләрнең дә балалары күп булырга мөмкин!

А с и я. Югары белемле тиләләр дә булырга мөмкин!

Э л ь з а. Тиләләрнең балалары күп булырга тиеш түгел!

А с и я. Ярамый! Ярамый! Ярамый!

Э л ь з а. Тиледән кем тумас?

А с и я. Тиләләр күбәер, гомер узган саен тиләләр артыр!

Э л ь з а. Тормыш тиләләр кулына күчә барыр.

Л у и з а *(юри көлеп, бу сөйләшүгә ироникле мөнәсәбәтен белдерә)*. Ха-ха-ха-ха! Ерак киләчәктә... Жир тиләләр йортына әйләнер!

Асия. Җир тулы тиләләр — шәүләләр кебек йөрерләр.

Луиза *(ике кулы белән күзләрен каплый).* У-у-у-у! Мин аларны күрәм! Ти-ле-лә-ә-әр!

**Аланда яктылык кинәт зәңгәр төскә үзгәрә. Үтә заманча музыка башлана. Төсләр туктаусыз үзгәрә башлый — кызыл, зәңгәр, сары, кызыл, зәңгәр, сары. Аланга тиләләр тула. Тиләләр бии, тиләләр үбешә, көлешә. Эльза белән Асия дә тиләләр арасында...**

Асия *(кычкырып).* Җир тулы тиләләр!

Луиза. Мин аларны күрәм!

Эльза. Югары белемле тиләләр!

Луиза. Белемсез тиләләр!

Өч хатын-кыз *(шаярып, такмаклап).* Ти-ле-ләр, ти-ле-ләр. Бе-лемле ти-ле-ләр. Бе-лемсез ти-ле-ләр...

**Үтә заманча көй кинәт туктый. Аландагы яктылык элекке хәлгә кайта. Тиләләр юкка чыга.** *(Пауза).*

Эльза. Луиза!

**Луиза эндәшми.**

Асия. Әй, күгәрчен!

**Луиза эндәшми.**

Эльза. Әллә курыктыңмы?

Асия. Яшермә, яшермә йөзеңне.

Эльза. Әллә курыктыңмы?

Асия. Театр, театр ясадык.

Луиза *(йөзеннән кулларын алып, җитдиләнеп).* Дөньяда тиләләр җитәрлек. Шулай да тормыш дәвамы акыллылар кулында булырга тиеш.

Эльза. Акыллыларның акыллы балалары күбрәк булу кирәк!

Асия. Мин үземне дә акыллыга саныйм. Ягуар Шахматовичны да. Ә балабыз бер генә. Бердәнбер малай. Гомер уза тора. Яшь арта...

Эльза. Минем малаем да, кызым да юк. Ишетәсеңме, Луиза? Син моны хәтереңә салып куй. Югары белем алгансың, эшлисең. Җитте!

Асия. Сузма! Еллар тыныч. Икмәк, кием бар. Әйбәт пар гына кирәк.

Луиза. Сез минем күңелгә чынлап ук шөбһә салдыгыз әле.

Эльза. Ә мин, кызлар... оят булса да сөйлим инде, шулай бервакыт, әле кияүгә чыкканчы, герой ана булырга җыена идем...

Луиза. Ун бала тудырыргамы?

Эльза. Әйе. Шундый уй миңа кереп кенә утырды бит.

Луиза *(гаҗәпләнүдән сызгырып куя).* Бусы инде артык.

Асия. Керә ул шулай, яшь вакытта күңелгә әллә нәрсәләр керә.

Луиза. Их, кызлар! Исемә төшермәгез әле шул — әллә нәрсәләрне!

Асия. Исеңә төшсә — безгә дә сөйләрсең.

Луиза. Сезгә сөйләп булмый торганнары гына искә төшә шул. Эльза апа, гафу ит, сүзеңне бүлдердек бугай.

Эльза. Шундый уй миңа кереп утырганнан соң күп тә үтмәде, мин бер әйбәт, мөлаем гына кыяфәтле, зәңгәр күзле рус егетенә кияүгә чыктым. Авыл хуҗалыгы училищесын тәмамлаган елым иде. «Тракторист-машинист» дигән документым бар, шунда ук шоферлык документы да алган идем. Мин шәһәрдә калдым... Юл җәйгәндә таптый-тигезли торган машина күргәнегез бармы?

Луиза. Биек, зур тәгәрмәче белән асфальтны изеп, шомартып, әкрен генә бара!

Эльза. Шул инде, шул. Шуңарда эшли башладым. Ирем мин яшәгән квартирага күчеп килде. Квартир хуҗасы безгә «ишәймәсәгез генә тотам...» дигән шарт куйды.

Асия. Син бу хакта миңа сөйләгән идең, Эльза.

Эльза. Сөйләдемме? Онытканмын *(пауза).*

Асия. Мин китим. Су кереп алыйм. Аннан — табын әзерлисе булыр. Сарык тотып, безнең бүреләр кайтып җитәр. *(Китә.)*

Луиза *(Эльзага).* Сезгә яңа квартирага күчәргә кирәк булган.

Эльза *(сүзен дәвам итеп).* Әйе. Шул вакытларда мин, герой ана булырга уйлап йөргән кеше, квартир хуҗамның рөхсәтеннән башка, йөккә уздым. Без башка квартирга күчәргә булдык. Минем кызым туды. Өченче квартирга күчтек. Ничектер, ирем белән ачуланыша башладык. Мин аны булдыксызлыкта, тизрәк үзебезгә аерым квартира ала алмауда гаепләдем. Ул мине гаепләде. Алайга калса — без тигез хокуклы гражданнар, ди... Янәсе, ник мин квартира алыйм... Янәсе, күп кенә яшьләрнең хәле шулай, гаиләнешәләр — безнең кебек шулай кеше өендә торалар, түзәләр, тора-бара җайлана. *(Пауза.)* Яшьләрнең хәле җайлана күрсен. *(Пауза.)* Безнеке җайланмады... Квартираң да булмагач, гаилә кору турында уйлыйсың калмаган иде, өйләнмәскә иде, дидем мин. Хатаны төзәтергә әле дә соң түгел, балабыз бер генә, бу тормышта бик күпләр ялгыша, мин дә ялгышканмын, диде ирем.

Шулай безнең ялгышлар артты. Матур сүзләребез азайды. Яхшы сүзләребез дә яман мәгънә алды, хәтта тавышыбыз да бер-беребезне үрти, борчый башлады. Кыш көне кызыбызга салкын тиде. Моның өчен тагы мин иремне гаепләдем. Кеше өстендә, салкын квартирада, бала юындырырлык урын да юк, дим. Ирем минe гаепли, бала карый белмисең, ди. Балага ул-бу була калса, сине... кичерәсем юк, ди. *(Пауза.)* Кызыбыз терелә алмады. *(Шушы мәлдә кайдадыр тургай сайрый башлый.)* Тиздән без ирем белән аерылыштык. Шуннан соң ун ел узгач, мин бер бүлмәле квартира алдым... Өченче этажда, үзе якты, ваннасы, жылы суы бар. Ул вакытта инде мин бер татар егетен ярата башлаган идем. Икенче мәхәббәт! Анысы да инде күптән булган хәл *(пауза).* Аның белән без сәер генә аерылыштык.

Луиза. Аерылышмаска кирәк иде инде?!

Эльза. Шулай килеп чыкты. Туган көнемдә мин аны көттем. Зур бүләк кирәкми, бер чәчәк алып килсә ярый иде. Ә ул минем туган көн икәнне дә оныткан.

Луиза. Син шуңа үпкәләдеңме?

Эльза. Юк. Ул көнне мин безнең мәхәббәт җитди мәхәббәт түгел, уен гына икәнне аңладым. Бәлки ялгышканмындыр. Шушы хәлдән соң аерылыштык.

Луиза. Ул башка сезнең янга килмәдеме?

Эльза. Тагын килгән булыр иде, мин килмәскә куштым.

Луиза. Ни өчен?

Эльза. Сине ярата сыман күренгән бераү, кинәт синең туган көнеңне онытсын инде. *(Пауза.)* Димәк, ул миңа җитәрлек игътибарлы булмаган. Яки ул бигүк яратмаган. Мин шулай уйладым.

Луиза. Бәлки, бәлки, бу аның ялгышы гына булгандыр, ул ялгыш оныткандыр... Яратуы шулай гына булды микән?!

Эльза. Егет кеше үзе яратып җиткермәгән хатын-кызга карата да егетләрчә әдәпле булырга тиеш. Шуны уйладым да минем аңа карата җаным үзгәрде. Җанымда нидер югалды. Үзен һаман яраттым, ләкин аның белән бүтәнчә очрашу кирәкми дип уйладым. Аерылышкач бер шәһәрдә яшәү һәм урамда очрашу тагы да авыр булыр иде. Квартирамны алыштырып, шушында күчеп килдем.

Луиза. Эзләп килмәдеме соң?

Эльза. Эзләп килсә, ул бит инде сине чынлап яраткан, ышанычлы кеше була. Ул студент иде. Миннән яшьрәк тә иде.

Луиза. Хәзер ул егет белән күрешкәнегез юкмы соң?

Эльза. Юк.

Луиза. Аерылышкач, башта бик авыр булгандыр, әйеме, Эльза апа.

Эльза. Авыр иде. Юксындым... Мәхәббәттәге уңышсызлык — үтә. Укуда, эштә очраган уңышсызлыклар — үтә. Тормыш миңа шундый дәрес биреп маташа. Хәзер мин узган хәлләргә көлеп карый беләм. Кайчандыр тавышланып, тырышып-тырышып беренче мәхәббәтебезне таптаган чагыбызга, үземә һәм иремә көлеп карыйм. *(Пауза.)* Туган көнемә чәчәк китерергә онытканегеткә дә көлеп карый алам *(елмая).* Елмая алам...

Луиза. Ә миңа ошамый.

Эльза. Нәрсә ошамый?

Луиза. Елмаю. Елыйсы урында елмаю ошамый, Эльза апа. Тормыш дәрес бирә ул. Шулай без тормыштагы бөтен хәлләргә елмаеп, битараф кына карарга өйрәнсәк тә, Җирдә яшәү дәвам итәр, ләкин ул нинди яшәү? Мин андый яшәүне аңламыйм. Үземдә андый үзгәреш булуын теләмим... Сезнең урында булсам, мин аны югалтмас идем.

Эльза. Ә мин югалттым.

**Пауза.**

Луиза. Арслан абыйны яратасыңмы?

Эльза. Арсланнымы? Арслан Айдарович ул безнең директор ярдәмчесе. Тырыш, киләчәге бар... ул хатын аерган кеше.

Луиза. Аларын беләм.

Эльза. Асия сөйләдеме?

Луиза. Арслан Айдарович үзе сөйләде.

Эльза. Үзе сөйләде? Кайда? Кайчан?

Луиза. Шәһәрдә. Безнең аның белән очрашканыбыз, киногa кергәнебез бар, театрга...

Эльза. Шулаймыни?! Ә миңа ул турыда әйткәне юк.

Луиза. Көнләшер дип әйтми, күрәсең.

Эльза. Юк. Көнләшмим. Ул моны белә. Тик ни өчен әйтмәгәндер? Очрашкансыз — яхшы булган... Менә шул кеше — безнең хуҗаның ярдәмчесе иде. Мин институтны күптән түгел генә тәмамладым, читтән торып укыдым. Арслан Айдарович миңа укуымда ярдәм иткәләде. *(Пауза.)* Миңа мәхәббәте булуын да сиздергән иде. Мин аңа андый хисләрем юклыгын әйттем. Арслан Айдарович минe мавыктыра алмый. Яңалык була алмый. Читтән карап кайчак үзен яратсам да, якын баргач

яратмыйм. Янымда аның барлыгын тоймыйм.

**Пауза.**

Л у и з а. Кем моңа гаепле? Улмы?

Э л ь з а. Белмим.

Л у и з а. Үзегез гаепләме?

Э л ь з а. Белмим.

Л у и з а *(каеннарны күрсәтеп)*. Бәлки бу каеннар гаепледер? Менә бусы... менә бусы...

Э л ь з а *(елмаерга тырышып)*. Каеннар гаепле булмый. Бер, ике — ничек үскәннәр... Өч... Ун каен. Берсе — кечкенәрәк...

Л у и з а. Алар барысы да зурлар.

Э л ь з а *(елмаеп)*. Син аңламыйсың.

Л у и з а. Ә нәрсә аңларга тиешмен?

Э л ь з а. Мин болай гына... Кыз чагымда нинди булуымны, актан киенергә яратуымны уйладым.

Л у и з а *(Эльзаның хәзерге мәлдә ни уйлаганын аңлап җитмәгән хәлдә)*. Күрәсең, Арслан Айдарович сезнең аңа битараф икәнне сизгәндер. Шуның өчен ул минем белән очрашкан һәм очрашуын сезгә әйтеп тормагандыр. *(Пауза.)* Ә сез аны юкка яратмыйсыз.

Э л ь з а. Яратып булмый бит.

Л у и з а. Юкка, юкка. Ул йөрәкне көйрәтә ала. Ул башкаларча түгел, үзенчә. Хатын-кыз өчен ул чын яңалык. Юк, яңалык кына түгел, ул өр-яңа мавыктыргыч дөнья.

Э л ь з а. Син аңа гашыйк булдыңмы?

Л у и з а. Гашыйк булырлык кеше.

Э л ь з а. Очрашкач, очрашуыгыз хакында миңа да әйтмәгәч, Арслан Айдарович үзе дә сиңа гашыйктыр. Ул өйләнергә уйлап йөри. Шул хакта сезгә бәлки икәү уйлашырга кирәктер.

Л у и з а. Сез шулай җиңел генә аны миңа бирә аласызмы?

Э л ь з а. Аңа мөнәсәбәтемне әйттем бит.

Л у и з а. Мин сезгә ышанмыйм. Аннан аның малае зур. Зур малайлардан куркам шул мин. Үзе дә миннән күпкә өлкән. Ләкин... өлкән булса да... Ул бит, валлаһи... Янында аның барын тоймау мөмкин түгел. Сез ул барын тоймыйм дисез. Ничек ул шулай. Бу мине бик гаҗәпләндерде.

Э л ь з а. Син... янында аны тоймау мөмкин түгел дисең. *(Елмаерга тырышып.)* Мине шул гаҗәпләндерде әле.

Л у и з а *(елмаеп)*. Нәрсәсе аның гаҗәп?

Э л ь з а *(паузадан соң)*. Аның белән шундый ук якын мөнәсәбәттә булдыңмы?

Л у и з а *(бераз уртәлеп)*. Булдым. Аны аңладым. Сезне аңлап җиткермим. Сезнең буын хатын-кызларны аңламыйм. Сезне әле мин соңрак белдем, Асия апаны күптән беләм, барыбер аңламыйм... Ярый әле Ягуар Шахматович түземле кеше. Ул бит — бүген тотып менә дигән кызга өйләнерлек. Эше дисәң, эше хөрмәткә лаек. Кыяфәте — чибәр. Сүзләре — бал, куллары май дигәндәй. Шул кеше Асия апага ярап җитми. Миңа Ягуар Шахматович иркәләгәндә дөньяда башка бер ир дә юк кебек, дөнья үзе дә юк, үзем дә юк.

Э л ь з а. Луиза, туктале, ни сөйлисең син? *(Ачуланып һәм аптырап Луизаның каршына ук барып баса.)*

Л у и з а. Сөйлим. Сөйли башлагач, барын да сөйлим. Ә ник яшерим?

Э л ь з а. Сиңа — нәрсә әйтим?

Л у и з а. Бер ни дә әйтмә. Сез шундый ирләрне югалтудан курыкмыйсыз. Кадерләрен белеп җиткермисез. Әйе!

Э л ь з а. Тормыш шулайдыр күрәсең. *(Пауза.)* Рәхмәт, безнең турыда кайгыртасың. Кайгырткансың... Үзең турында ник кайгыртмыйсың, Булат турында? Аңа кияүгә чыкмыйм дисең...

Л у и з а. Безнең сәбәпләр башкарак.

Э л ь з а. Булат әйбәт егет сыман күренә. Матур пар була алырсыз кебек.

Л у и з а. Күренә. Сез бит аны белмисез: үзегез әйтмешли, якыннан белмисез.

Э л ь з а. Луиза, син бу сүзләрне Асияга сөйләмә, ярыймы? Бер вакытта да сөйләмә! *(Кызулык белән иңеннән тотып Луизаны агачка китереп тери.)* Сөйләмә! *(Бу халәтеннән айныган төсле, кинәт кулларын ала. Аларны каядыр яшерәсе килә.)*

Л у и з а *(кутәрелеп, төзәеп)*. Ә ул белә.

Э л ь з а. Ул бернәрсә дә белми.

Л у и з а. Күрмисезмени? Ягуар Шахматовичны миңа көнли? Ул юри генә минем белән шулай сөйләшә. *(Иңнәрен уа.)* Уф...

Э л ь з а. Ничек сөйләшә?

Л у и з а. Кечкенә кызлар белән сөйләшкән кебек.

Э л ь з а. Асия бер нәрсә дә белми. Белергә дә тиеш түгел. Ник икәнен аңлыйсыңдыр. Ягуар Шахматович сиңа кирәкми.

Л у и з а. Ул шулай өлкән булмаса...

Э л ь з а. Син акыллы бул, Луиза. Аның белән алай аралашма. Асия белә күрмәсен *(пауза)*. Миңа инде ярар, мин белсәм дә зыян юк.

Л у и з а. Үзегезне алай ук кимсетмәгез...

Э л ь з а. Кимсетмим. *(Пауза.)* Мин ныклы кеше. Гомер буе ирләр һәм техника арасында эшләдем... Тракторист, автослесарь, шофер.

Л у и з а. Сез инженер.

Э л ь з а *(Эчке әрну белән).* Хәзер мин шәһәр электр челтәрендә иминлек техникасы инженеры булып эшлим. Ирләрнең иркәләү сүзләренә — күнектем, сүгенүләрен — ишетмим. Елмаюларына каршы — елмая беләм. Мин ирләргә булышчы, алар миңа ярдәмче. Алар белән тигез акча алам. Яшим. Табам. Югалтам. Картая барам. Мин гашыйк була да белмим бугай хәзер.

Л у и з а. Картаю турында сөйлисез? Сез әле шундый яшь, Эльза апа... *(Эльзаны юатырга тели. Шаярып җырлый.)*

Син матур, син чибәр,
Сине күреп туймыйлар.
Син матур, син чибәр,
Сине күреп туймыйлар.

**Кушымта:** Нигә сине зоопаркка
Маймыл итеп куймыйлар?
Нигә сине зоопаркка
Маймыл итеп куймыйлар?
Нигә сине...

Э л ь з а. Син минем тышкы дөньямны гына күрәсең. Менә монда *(күкрәгенә күрсәтә)* эчке дөньям бар. *(Пауза.)* Шулай бер елны төнлә поезд көтәм, вокзал янындагы бакчада йөрим. Вокзалга керәсем килми, халык күп. Бер милиционер яныма килде. «Нишләп йөрисең?» ди. Поезд көтәм, дим. «Кая, документларың бармы?» ди. Бар мин әйтәм. Кулмәгемне күтәрә башладым. «Тфү» дип, җиргә төкерде дә бу, янымнан китеп барды. Башта аптырап калдым... Аннан аңладым — документларым трико кесәсендә иде. Бераздан соң... ир-атларга карата сизгерлегем кими башлаганын икәнне аңладым. Кими!

**Асия килеп керә. Ул Эльзаның сүзләрен ишетеп кала.**

А с и я. Миндә инде ул ир-атларга карата сизгерлек. Хет беразын башкаларга өләш... Яңалык алып килдем. Сезне шатландырмый торган яңалык.

Л у и з а. Әгәр мөмкин булса, аны безгә әйтмә. Шундый матур җирдә... Безне шатландырмый торган яңалык — кирәкми.

А с и я. Сезгә әйтмичә калырга ярамый.

Э л ь з а. Кайдан эзләп таптың син андый яңалыкны?

А с и я. Безнең тирәдә яшьләр урнашкан икән. Шуларның Вера исемле кызларын күрдем. Үзе килеп эндәште. Ялны эчемлектән башлаганнар, теле бик ачылган: «Өч чатырга урнашкан күршеләрнең берсе буласызмы әллә?» ди.

Л у и з а. Чатырларны кай арада күреп өлгергәннәр?

А с и я. Өлгергәннәр инде. Кай арада күргәннәрдер, анысын сорамадым.

Э л ь з а. Урман — колак, кыр — күз диләр бит.

А с и я. Шул яшь кенә кыз, күзгә туры карап әйтә: «Безнекеләргә сезнең ир-атлар ошамый, барып тавыш чыгарулары мөмкин, моны сезгә яхшылык теләвемнән генә әйтәм», ди.

Л у и з а. Тавыш чыгарулары?

Э л ь з а. Ни өчен? Ник алар безнең янга килергә тиеш әле? Шуны сорадыңмы?

А с и я. Сорадым. Анысын төгәл әйтми. Сезгә ул урыннан күчүегез хәерле булыр иде, ди.

Л у и з а. Тизрәк Булатлар килсен иде. Алар ни дияр?

Э л ь з а. Сезнекеләр, безнекеләр, имеш... Кемнәр икән соң алар?! Тавыш чыгаручылар?! Без бирелән беркая да күчмибез.

А с и я. Ә ир-атларга шундый күршеләребез барлыгын белгертәбезме? Әллә кирәкмәс микән?

Л у и з а. Нишлик соң? Чынлап та килеп тавыш чыгарсалар?

Э л ь з а. Яшьләр кайнар баштан мәсәеп сөйләшкәннәрдер. Кирәкми. Ир-атларга белгертмик.

А с и я. Минемчә дә шулай. Юк нәрсә өчен тынычсызланып куюлары бар. Әйдәгез, табын әзерлик...

**Нәкъ шул вакыт ирләрнең җырлап кайтуы ишетелә.**

Дәрьяларга чумарбыз,
Җанкайларга кирәксә.
Җир әйләнеп чыгарбыз,
Җанкайларга кирәксә.
Ир югалмас юлларда,
Безнең кебек булганда.
Ир җиңелмәс юлларда,
Безнең кебек булганда.

Л у и з а. Бетте баш. Тизрәк.

**Хатын-кызлар ашыгып табын әзерли һәм өчесе өч якка утырып, тын кала.**

Б у л а т. Әллә китеп югалганнармы?

А р с л а н. Йоклаганнар бугай. Уятыйк.

Я г у а р. Уяныгыз? Без кайттык, сагынган булсагыз...

Э л ь з а. Сагынмаган кая ул?!

Л у и з а. Күптән көтәбез.

Б у л а т. Беренче сортлы сарык ите!

А с и я. Ягуар Шахматович! Озак йөрисез. Безне урлый яздылар. Харап итәләр иде бит.

Я г у а р. Кемнәр килде? Нәрсә булды?

Арслан. Эльза, чынлапмы?

Эльза. Юк лә...

Булат *(кулындагы сумканы чатырга кертеп чыга).* Сөйләгез. Кемнәр килде. *(Шаярып.)* Исемем Булат булган чакта...

Арслан *(шаярып һәм кычкырып).* Кем килде? *(Җиңнәрен сызгана.)* Без хәзер аларны! *(Боксер торышы ала, рингта көчгәдер һөҗүм иткән сыман, якындагы каенга юнәлә.)*

Луиза *(Арсланга).* Арслан абый. Сезнең һөҗүм гаҗәп матур. *(Шаярып.)* Каеннар, сакланыгыз!

Асия *(Арсланга).* Каеннарга тимә!

Эльза. Алар шундый ак, шундый матурлар. Аларга тияргә ярамый.

Арслан. Мин аларга тимәдем.

Ягуар *(ирония белән).* Ә каеннар син аларга тиярсең дип белде.

Асия *(Арсланга).* Әйе. Алар сине күрә. Каеннарның кара күзе бар.

Булат. Ә минем бер вакытта да кара каен күргәнем юк.

Луиза. Минем дә. Кара каен буламы соң?

Асия. Кара каен булмаса, дөньяда «ак каен» дигән исем булмас иде. «Каен» дигән сүз генә булыр иде.

Ягуар. Бар ул, кара каен. Алар аз һәм игътибарны үзләренә артык җәлеп итми. Артык күзгә чалынмыйлар *(шаярып ир-атларга күрсәтә),* болар кебек түгел.

Луиза. Нинди була соң ул кара каен?

Булат. Чынлап та карамы?

Асия. Бөтенләй кап-кара түгел инде.

Эльза *(шаярып).* Кара каен миңа охшаган була.

Арслан *(Эльза янына килә).* Эльза, син ак каен *(каенга күрсәтә),* әнә теге каенга охшыйсың.

Эльза. Беләсең килсә, бирредә ун ак каен бар... Мин кара каен.

Ягуар. Ничек инде?!

Асия. Эльза?!

Арслан. Синең күзләрең генә кара лабаса...

Эльза. Күзләрем генә микән *(шаярып, елмаеп),* Арслан Айдарович?

Луиза *(Арсланга).* Сез яхшылап карагыз, яхшылап.

Булат. Ник әле сез үзегезне кара каен белән чагыштырасыз?

Эльза. Мин ялгыз кара каен, тегеләр ак.

Асия *(сүзгә икенче юнәлеш бирү нияте белән булса кирәк).* Сез югында безнең янга кара ир килде.

Булат. Ул ни әйтте?

Асия. Тиздән бирегә кара ирләр киләчәк диде.

Луиза. Алар безне үзләре белән алып китәчәкләр.

Ягуар. Сез нинди ирләр хакында сөйлисез?

Асия. Әһә, ышандыгыз дамы?

Арслан. Ышанмадык...

Ягуар. Ничек сезгә ышанмыйсың инде?!

Булат. Кешеләргә ышанырга кирәк!

Луиза. Килүче юк. Бар да әйбәт. Яшеллек, су, кояш... Тынычлык.

Асия *(сөйләшүне шаяруга әйләндерә).* Килүче юк шул, Ягуар Шахматович. Монда килеп безне кем тапсын. Безне табарлык ир-ат бармыни ул?

Эльза *(шаярып).* Булса кайда ул? Сез кайда, ир-атлар? А-ау-у-у! Без адаштык!

Ягуар. А-а-а-оо! Без бирредә!

Луиза. Сез кем-нә-әр!

Булат. Е-егетлә-әр!

Асия. Кызлар! Җирдә бер егет артты. *(Житди тонга күчә.)* Егет була күр, Булат. Бар бул да бер бул.

Булат. Есть, егет булырга. *(Чатырга керә.)*

Асия. Менә шул... Егетлек хәзер күп кенә егетләргә житенкерәми, ди. Дөрес булса, шундый хәбәр йөри, ди... Арслан Айдарович, ишеттегезме?

Арслан *(рюмкаларга эчемлек сала).* Салып чыгыйм әле. Берәрне... Утырыгыз. Тыңлыйм, Асия ханым. Ишетмәдем.

Асия. Хатын-кызлар тавышына саңгырау икәнсез. Ярамый!

Арслан. Ярамый, дөрес...

Асия. Әнә, Ягуар Шахматович ишеткән. Соңгы елларда без еш кына шул темага сөйләшәбез.

Арслан. Нинди тема ул, Асия ханым?

Луиза. Житди темаларга кагылмыйк, Асия апа.

Ягуар *(кәефе кырылуы сизелә).* Асия Бариевна. Мине ачуландырасың, үпкәләтәсең. Ул хакта өйдә сөйләшкәнебез дә житәрлек лабаса. Инде урманда... Кешеләр янында.

Асия. Табигать кешене үзгәртә. Көчен һәм акылын арттыра. Табигатьтә сөйләшү — дөресрәк, файдалырак булырга мөмкин?!

Луиза. Ася?!

Эльза. Ася!

Я г у а р. Мин алайса кәйтып китәм. Мин ял итәргә килдем, ә ниндидер син уйлап чыгарган проблемаларны хәл итәргә түгел.

А с и я. Ягуар Шахматович, күгәрченем, ачуланма. Мин бит хатын-кыз. Син минем белән килеш кенә. Килешергә кирәк безнең белән. Үзең беләсең бит.

Б у л а т *(кила)*. Кыяр, помидор, печенье! Колбаса һәм башкалар. Бусы бетсә, тагы бар! Рюмкаларны... Рәхим итегез! *(Ул да табын янына утыра...)*

А р с л а н. Килешәбез. Шулай бит, Ягуар Шахматович, килешик.

Б у л а т. Килешәбез, килешәбез. Шашлыкка хәтле түзәрлек итеп ашагыз. Кемгә конфет?

Я г у а р. Аның фикерен ишетсәгез, сез килешмәс идегез. Ир-ат холкында торгынлык, хәтта аларда егетлек сыйфатларының кими баруын расламакчы ул. Катастрофа! Безнең буын шул катастрофаның беренче корбаны икән! *(Пауза.)*

А р с л а н. Ничек инде алай? Асия Бариевна? Йөрибез, җиргә каты басабыз. Яшибез.

А с и я *(елмаеп)*. Җир жимертеп эшлибез.

Я г у а р. Әйе. Җир җимертеп эшлибез!

А с и я. Безнең белән бер рәткә басып эшлисезме? Күгәрченкәйләрем минем... Әйдәгез, әчик.

**Кемдер эчә, ашый.**

Я г у а р. Сезнең белән бер рәткә басып... Ләкин без эштә ирләр булып танылабыз, ирләр булып калабыз. Менә сез, хөрмәтлем Асия Бариевна, син — соңгы вакытта шаккатый үзгәрдең, ирәйдең... Нидер синеңчә түгел. Аныбы синеңчә булсын, монысы синеңчә торсын. Син генә хаклы, синдә генә акыллы уйлар, дөрес тәкъдимнәр, идеяләр, планнар. Еш кына матур урыныңны онытып җибәрәсең. Ә ул урын — хатын-кыз урыны. Ул урынга хатын-кыз кирәк, югыйсә, безгә — ирләргә кыен: акылыбыз, хисләребез, рухыбыз газаплана. Шул газап, шул психологик тәэсир безгә хәтта физик үзгәрешләр кертә! Күрәсеңме? Маңгаебызга сырлар иртәрәк сызыла, йөзебез җыерыла... Без ямьсезләнәбез. Яшәү күңелсезләнә. Шундый хәл килеп чыкмасын өчен, Асия Бариевна, моннан соң мин сине үз урыныңа утыртырга тырышырмын, ярыймы?

А с и я. Бик ярый, бик ярый, Ягуар Шахматович. Урыным югалу бәласедер, кичә чүкеч сатып алдым. Стенага кадак каккан-да бармагыма суктым. Урындыктан егылып төшеп йөгәнә яздым. Үз урыным бик җайлы булыр. Утырам гына мин аңа, булыш. Һаман шуны эшли алмадың. Әллә уйламадың, әллә вакытың җитмәде. Әллә синә кирәгем калмады... Бердәнбер малаеңны да оныта барасың кебек. Французлар каршылыйсың, инглизлар озатасың, японнар кила. Ленинградтан киләләр, Мәскәүдән киләләр. Киләләр дә киләләр, үзләре бар да яхшылар — хет кочаклап ела.

Я г у а р. Елашмыйк, Асия Бариевна! *(Пауза.)*

А р с л а н *(рюмкаларны яңадан тутыра)*. Асия Бариевна. Ягуар Шахматович җилкәсендә тау-тау эшләр. Зинһар, сезнең эш дәрәҗәсен төшерүем дип аңлый күрмәгез, Ягуар Шахматович киң масштаблы оештыручы-организатор. Үз эшен ирләрчә алып бара. *(Рюмка күтәрә.)* Сезнең өчен, Ягуар Шахматович! *(Ирләр җырын башлый. Башкалар да кушыла.)*

Алын әзләп табарбыз,
Җанкайларга кирәксә.
Гөлен әзләп табарбыз,
Җаңкайларга кирәксә.

**Кушымта:**

Ир югалмас юлларда,
Безнең кебек булганда.
Ир югалмас юлларда,
Безнең кебек булганда.

Б у л а т *(җыр беткәч)*. Ир-ат һәм хатын-кыз мәсьәләсе... Әйтергә мөмкинме?

Л у и з а. Әйтеп карагыз.

А с и я. Яшь социолог фикерен ишетү ярый.

Э л ь з а. Димәк, фәнни фикер тыңлыйбыз.

Б у л а т. Минем төп эшем бу юнәлештә түгел. Биредә туган уемны гына әйтәм. Янәшә үсеш! Шуның өчен хәзер ир-атлар хатын-кыздан әллә ни аерылып та тормыйлар. Элек ул — башкача булган. Хәзер ир-ат та, хатын-кыз да сәләтен, теләсә нинди хезмәттә көчен раслады. Барыбыз да кеше, барыбыз да зур. Уртак биеклек!

А с и я *(Булатка)*. Якынрак килегез, җиргә төшеп карагыз. Без — җирдә, өйләр җирдә, кызлар җирдә... Сез әле өйләнмәгән кеше. Шулаймы?

Б у л а т. Шулай.

А с и я. Көннәрдән бер көнне өйләнеп куйдыгыз, ди. Шулаймы?

Булат. Ничек уйлыйсың, Луиза.

Луиза. Уйламыйм.

Асия. Өйләнеп куйдың, ди. Син дә зур, хатының да... Дөнья хәлләрен беләсез. Радио тыңлыйсыз, телевизор карыйсыз. Гел зур мәсьәләләр кайгыртасыз — шуңа күрә бер генә балагыз бар. Алай да сез инде өч кеше. Яңа дәүләт башына президент кирәк дигәндәй, сезнең гаиләгә бер башлык кирәк бит инде: киңәшүләргә, сөйләшүләргә йомгак ясаучы, төп сүзне әйтүче кеше. Сезнең гаиләдә мондый кеше кем булыр, үзегезме? Хатыныгызмы?

Эльза *(Булатка карап)*. Булат үзе булачак.

Луиза. Юк, аның гаиләсендә хатыны башлык була.

Булат. Минемчә, гаиләдә икең бер дәрәҗәдә булу — матур.

Асия *(Булатка)*. Бер серия белән чыккан курчаклар кебекме? Мунчаның да директоры бар?! Бригадаларның — бригадиры. Һәр оешма башында хуҗа була... Ничек инде ул синдә генә хуҗасыз гаилә!?

Булат. Икебез дә хуҗа булабыз, тигез зурлыктагы шәхесләр.

Асия *(ирония белән)*. Тәбрик итәм!

Эльза *(шаярып, елмаеп)*. Тигез хокуклы ике патша килеп чыккан дәүләт икегә бүленә, ил таркала. Ил таркалмасын өчен кайсыдыр патша икенчесенең башын кисәргә тиеш. Бу хәл тормышка ашканнан соң, башы исән калган патшаның тегә патшадан зуррак шәхес булуы ачыклана. Ил таркалудан котыла.

Ягуар. Кирәкми. Башларны кисмик әле.

Арслан. Шулай шул.

Асия. Аларга илләр буйсынганга хәтле, алар үзләре кемгә буйсынырга тиеш? Әнигәме, әтигәме? Кемнән үрнәк алырга тиешләр?

Луиза. Кемнән телиләр, шуннан үрнәк алсыннар. Мәсәлән мин үзем балачакта ни өчендер әнидән үрнәк ала идем кебек. Әтине дә ярата идем: ул әнигә һәрвакыт «гафу ит», «ярар», «синеңчә булыр», «борчылма», «хәзер үк эшлим» дип кенә тора. «Ник хәзер үк эшлисең? Аны соңрак эшләсәң ярамыймы?» дип ачулана иде кайчак әни үзен... Безнең әнинең ачуы өермә сыман, еш кузгала, бөтерелә һәм бик тиз тына. *(Пауза.)* Әти сирәк ачулана, эштән соң, кич... Аның ачуы өермә дә түгел, давыл да түгел, кар да түгел, яңгыр да түгел, әллә нинди. Ул тыныч кына сөйли дә сөйли. Ярты сәгать сөйли, бер сәгать... Әни диванга утырган килеш йоклап китә. Минем әти шулай гаҗәп сабыр сөйләшә белә иде.

Арслан. Сабырлык безгә кирәк нәрсә инде ул.

Ягуар. Бик кирәк. Һай, сабырлык кирәк. *(Хатын-кызларга.)* Сезнең белән яшәр өчен...

Булат *(хатын-кызларга)*. Хәзерге, мәгълүматлы, культуралы ир белән хатын, минемчә, шулай сабыр гына сөйләшеп, гаиләдәге башлык мәсьәләсен тыныч кына хәл итә, ике якка да тигез булә ала. Икесе дә дәрәҗәле рольдә була.

Эльза. Икесе дә хатын-кыз ролендәме?

Арслан. Икесе дә ир ролендә!

Булат. Шаярмагыз! Һәркайсы үз ролендә. Икесе дә гаилә башлыгы. Биредә гаиләне дәүләтләр белән чагыштыру булды. Ләкин дәүләт — катлаулы. Анда халыклар. Анда төрле фикер, төрле агым, төрле юнәлешкә омтылган кешеләр табылырга мөмкин. Ә гаиләдә — өч кеше, дүрт булсын... Гаиләдә аңлашу-сөйләшү җинелрәк.

Асия *(Арсланга күрсәтеп)*. Булат, таныш булыгыз. Озакка сузылган шундый аңлашу-сөйләшүләрдән соң бу кешенең өеннән хатыны ташлап чыгып киткән. Бер баласын калдырган да киткән. Берсен үзе белән алган.

Арслан. Асия Бариевна, менә бу сүзләрнең инде биредә һич тә кирәге юк иде.

Асия. Гафу итегез. Мин... мисал итеп кенә. *(Пауза.)* Булат яшь кеше, социолог, уйлансын.

Ягуар. Ишеттеңме? Сиңа яңа эш, Булат.

Эльза *(Булатка)*. Әйе, ныграк уйланып, мәсьәләгә заманча үткен карап, аны фәнни нигезгә салыгыз. Шуңа таянып сөйләшерлек булсын.

Асия. Таяныр урын булмагач, әнә бит. Ир-атлар хакында фәнни нигезләнмәгән фикер әйттем. Ягуар Шахматович миңа фәнни нигезе булмаган сүзләр әйтте. «Үз урыныңны онытып җибәрәсең, шуңа рухым газаплана, йөзем җыерыла, ямьсезләнәм, яшәү күңелсезләнә», ди. Ә яшәү күңелле булырга тиеш!

*Пауза.*

Луиза *(туп алып, Ягуарга ыргыта)*. Туп уйнасак, яшәү күңелле була.

Ягуар. Маңгайда җыерчыклар кими. *(Арсланга ыргыта.)*

Арслан *(Эльзага)*. Яшәү күңелле!

**Туп уйный башлыйлар.**

Эльза. Яшәү матур!
Асия. Яшәү гүзәл!
Булат. Бәхәсләр беткән!

**Туп куаклар арасына оча. Булат тупны алырга йөгерә.**

Луиза. Шашлык турында уйларга вакыт түгелме безгә?
Асия. Минемчә — вакыт.
Ягуар. Ярда бик әйбәт урын бар. Учак өчен.
Арслан. Каеннардан ерак, аларга ут янамый.
Эльза. Үзебезгә янамасын.
Ягуар. Юк-юк. Бармаслык урын түгел. Җайлап кына ягарбыз. Соңыннан күмәбез...

**Булат килә, тубын хатын-кызларга ыргыта.**

Булат *(чакыра)*. Арслан Айдарович, бер минутка мөмкинме?

**Булат белән Арслан читкә китә.**

Тегендә нинди дер кешеләр бар, әллә безне күзәтәләр.
Арслан. Безне күзәтәләр?
Булат. Шуңа ошый.
Арслан. Ягуарга әйтик әле. Ягуар Шахматович!

**Ягуар килә. Хатын-кызлар туп уйный.**

Ягуар. Әйе, тыңлыйм.
Булат. Тегендә нинди дер кешеләр безне күзәтәләр шикелле... Мине күргәч, кире борылдылар.
Ягуар. Күпләрме?
Булат. Мин икесен генә күрдем. Бәлки анда тагы...

**Пауза. Ир-атлар шөбһәдә.**

Ягуар. Ялгыз бозып ташлауларын теләмәс идем.
Арслан. Шулай шул... Бәлки алар үз эшләре белән генә йөриләр.
Булат. Шикле күренәләр.
Ягуар. Монда төрлесе йөри. Әнә, авылдан килгәндә очраган кебекләре дә... Шулар түгелме икән әле?
Булат. Башкалар бугай.
Ягуар. Башкалар...
Арслан. Хатын-кызларга әйтмик.
Ягуар. Аларга әйтмибез... Ярга китәбез, анда ачыграк урын.
Арслан. Ерактан күренә.
Ягуар. Көтелмәгән очрашу булмый.
Булат. Юньле әйберләрдән — берсен дә берни дә калдырмаска.
Ягуар. Шулай дөрес булыр. *(Хатын-кызлар янына киләләр.)* Тәкъдим бар!
Асия. Киңәшмә нәтиҗә ясады!
Луиза. Ягуар Шахматович, тыңлыйбыз.
Булат. Шундый тәкъдим бар...
Ягуар. Яшәү матурлыгын раслый торган тупны култыкка кыстырып, яшәүне тагын да бизи торган эчемлек-ашамлыкларны алып, яр буена китәргә.
Арслан. Учак кабызырга!
Булат. Шашлык кыздырырга!
Ягуар. Йөзәргә, чумарга!
Хатын-кызлар. Тәкъдим кабул ителә. Бер тавыштан. Алга! Ярда һәм суда җиңүләр яуларга!
Асия. Ягуар Шахматович, күгәрченкәем, тирән җиргә чумма. Чыга алмый калсаң, мин эзләп табарлык булсын.
Ягуар. Рәхмәт, Асия Бариевна! Син һәрвакыт шулай матур шаярасың. Күңелне күтәрәсең.
Луиза. Нәрсәләр алабыз?
Ягуар. Барын да.
Эльза. Ничек — барысын да? Ник?
Арслан. Бирсә байлык калдырмаска.
Ягуар. Азмыни буталып йөрүче кара кешеләр. *(Аласы әйберләрне барлый.)* Асылда — бирсә палаткалар гына кала.
Арслан. Ит кыздыруны миңа тапшырыгыз. Дөньядагы бөтен ачларның борынын кытыкларлык итеп кыздырам. *(Шаяра.)* Уянсыннар ачлар!
Берничә тавыш берге *(шаярып)*. Ут һәм ит бнеклекләрен яулап алырга!
Арадан берәү. Гаиләдәге изүләргә каршы!
Арадан берәү. Ирләр изелүенә каршы!
Булат *(шаярып)*. Ут — гүзәлләр гүзәле! Мин учак ягам. *(Китә)*.
Луиза. Оештыру, идарә итү, әмер бирү эшләрен Ягуар Шахматовичка тапшырыйк дигән кешеләр кул күтәрегез!

**Барысы да кул күтәрә. Асия күтәрми.**

Эльза. Асия! Ник кул күтәрмәдең?
Асия. Ул эшне әгәр миңа тапшырсагыз... Күрмәгәнегезне оештырып күрсәтер идем.
Ягуар. Кызлар, савыт-саба, кашык-пычак сезнең карамакта. Ир-атлар итне ала... Менә бу авыр сумканы... Боларны...

**Хатын-кызлар ашъяулык, савыт-саба, пычак-кашык белән мәшгуль. Ир-атлар китә.**

**Луиза тәлинкәләр һәм тагы нилердер алып, ир-атлар ягына кузгала.**

Асия. Луиза!
Луиза. Нәрсә?
Асия. Кая шул хәтле атлыгасың?
Луиза. Ашыгасың дияргә кирәк.
Асия. Пә, әйт әле дөресен. Булатка кияүгә чыгу уең бармы?
Луиза. Булса?

Асия. Булса — әйбәт.

Луиза. Булмаса?

Асия. Уйларга кирәк... Берне табарга, бергә ышанырга кирәк.

Луиза. Каян табарга? Сез бит аларны бетереп үк ташладыгыз.

Асия. Без бетереп үк ташласак та, ир-ат әлегә бар. Менә шул ир-атның бер төрендә шундый гадәт тә бар. Беренче очрашуда ук синең кайдан икәнлегеңне, исемеңне сорый да сүзен дәвам итә: «Сез нигә болай ягымлы, сеңелем? Сез ягымлы булуыгыз өчен гаепле, беләсезме? Гаепле! Мин сезгә гашыйк булдым. Хәзер мин сездән башка тора алмыйм. Сезнең белән китәм. Дусларымны ташлыйм, эшемне ташлыйм, квартирамны ташлыйм», ди. Квартирасы булмаса да, шулай ди. «Шәһәремне, әти-әниемне, нәсел-нәсәбемне, хатынымны, баламны ташлыйм», ди. Әйе, баласы булмаса да шулай ди. «Теләсәң нишлә. Мине теләсәң нишләт, хет ас, хет кис, икәү торабыз», ди. «Хәзер үк китәм синең белән», ди. Китә ул... Кайбер кызлар шуңа ышана... Йөз кат шушы сүзләрне ишетсен — ышана. Инде йөз дә беренче кат ишетсә — тагы ышана. Әллә чынлап ышана, әллә юри?!

Эльза. Алай ук булмас ла инде.

Асия. Мин нәрсә сөйләгәнемне белеп сөйләшәм. Сиңа түгел, Луизага сөйлим. И-и-их, үтеп китте шул инде безнең андый чаклар... Исеңдә тот, Луиза.

Луиза. Мин алай тиз ышана торганнардан түгел.

Асия. Ышанасың шул, ышандыра ул... Күгәрченкәем, син дә икенче планетадан төшмәгәнсең, үзебезнең кеше... Әйдәгез, киттек.

## Икенче бүлек

**Алан буш. Тавышлар гына ишетелә.**

Асия. Ягуар Шах-ма-то-вич!

Булат. Ки-ле-гез!

Арслан. Учакка кояш төште. Ко-яш яна учакта!

**Тимер килеп чыга. Ул үзенең иптәше белән.**

Тимер *(иптәшенә)*. Кояш яна учакта диләр! Ишетәсеңме?

Иптәше. Ишетәм.

Тимер. Янсын, күмергә калсын кояш, көлгә әйләнсен. Әйеме?

Иптәше. Әйе.

Тимер. Безгә кояш булмаса яхшырак. Тиздән ул сүнә, бетә. Безнең сәгать җитә, шулай бит?

Иптәше. Шулай.

Тимер *(иптәшен)*. Бүкән син *(пауза)*. Әйе, ишетәм! Син нәрсә, юньләп сөйләшмисең!? *(Луизалар киткән якка күрсәтә.)* Анда Луи-и-за! Мин аны күрдем. Таныдым.

Иптәше *(чирәмгә утыра)*. Мин бүген тынычлап ял итәргә телим.

Тимер. Тынычлап?! Юк ул тынычлык! Ул сүзне ялкаулар, эшлексезләр, ялганчылар уйлап чыгарган. *(Агачлар тирәсендә йөри.)* Ничә ай элек... Бары бер генә мәртәбә сөйләштек, ә таныдым... Тукталышта идек. Автобус көттереп килде. Халык шыгрым, этәләр-төртәләр... Үч иткәндәй, машина ватылган, җәяү йөргән көн... Карале, ничек уйлыйсың, ул мине танырмы икән?

Иптәше. Сез очрашканда караңгы төшәчәк, танымыйча тагы...

Тимер. Үч иткәндәй, машина ватылган, җәяү йөргән көн...

Иптәше. Әйе.

Тимер. Беләсеңме син, Луиза минем өчен бүген ни тора?! Аңлыйсыңмы шуны. Мин аны таптым. Ул минеке булачак, бүген үк. Эх, Луиза, Луиза! Үч иткәндәй, машинам ватылган, җәяү йөргән көн. Халык шыгрым, этәләр-төртәләр...

Иптәше. Исерек син.

Тимер. Мин исерек... Син айныкмы?

Иптәше. Мин уйнамыйм. *(Луизалар ял итәргә киткән якка күрсәтә.)* Җитте. Синең Лиза, Луиза, Таня, Маняларың өчен күп сугыштым. Болары белән сугышмыйм.

Тимер *(агачлар арасына сак кына кереп, Луизалар ягын күзәтеп килә)*. Ашап утыралар. Җыелганнар.

Иптәше. Барып туздырасың киләме?

Тимер *(усалланып, айнып)*. Мин хәзер кешеләргә яктыда бәйләнмим бит. Мин үземдә яңалык ачтым. Караңгыда минем күзләр яхшырак күрә, колак яхшырак ишетә башлый. *(Ике йодрыгын күрсәтә.)* Болар авырая, буыннарым — пружина, миндә тизлек, йөрәк — корыч, миндә тимер көч, очам, изәм, ватам — мин үземне үзем шундый хәлгә китерәм. Шулай уйлыйм — шулай була.

Иптәше. Булмагае.

Тимер *(иптәше янына килә)*. Син куркак. Син елдан-ел куркакка әйләнә барасың. Синең тиздән безнең кебек дусларыңа да кергәең калмый.

Иптәше. Булмагае.

Т и м е р. Безнең кебекләр, беләсең килсә, тормышның тоткасына әверелә бара. Җирдәге игенчеләр, эшчеләр, житәкчеләр, галимнәр, бөтен акыл ияләре тудырган продукциянең төп өлеше безнең карамакка күчә. Икмәк, кием, байлык тулы кибетләрнең чын ишекләре без шакыгач кына *(елмая)* ачыла.

И п т ә ш е. Ә теге... Ачык торган ишекләре?

Т и м е р. Алары чын ишек түгел, алары сезнең ишекләргә. Рәхим итегез, керегез, алыгыз! Бездән калган *(тагы елмая)* сезгә. Сезгә күп кирәк, алыгыз, ал! Карагыз, сезгә дигән әйберләрдән киштәләр сыгыла! Безгә алай ук күп кирәкми. Без бит җир йөзендә үзебез дә сезнең кебек күп түгел. Шуңа карамастан, кайбер складларның ачкычларын учында тоткан затлы кешеләр — тыйнак кына, безгә җайлашып килә. Җайлашуларга юл куймаска билгеләнгән гайрәтле кешеләр тыныч кына, үзләре дә сизмәстән, безгә җайлашып килә. *(Пауза.)*

И п т ә ш е. Теләгәннәр җайлаша.

Т и м е р. Теләгәннәр теләп җайлаша, теләмәгәннәр мәҗбүр була. Яшь белүчеләр, зирәкләр, йөрәклеләр безнең белән аралаша, җайлаша. Бар да тәртип белән бара, бары да үз урынында, тормыш законнары гади *(пауза)*... Мин машиналы, яшәүнең рәтен белә торган Тимер булмасам, син минем белән аралашмас идең. Минем белән аралашмасаң, синең квартираң булмас иде. Күрәсеңме, дөньяда нинди тәртип? Акылың булса уйлап кара, алар эшлиләр. Җыелышлар җыялар. Планнар билгеләләр. Ярышалар. Батырланалар. Трибуналарга чыгып авызларыннан ут чәчәләр. *(Пауза.)* Соң гына җыелышлары бетә. Төнлә шәһәргә таралалар. Такси тоталар. Без үзебезнең машинада... Алар трамвай, троллейбус көтәләр, җәяү кайталар. Без үзебезнең машинада. Алар утлы һәм утсыз урамнардан кайталар. Батырлар кайта. Мин шуларның берсе каршына чыгып, юри генә «стоп!» дисәм, шунда ук теге батырның тезе калтырый башлый. Ике кулы салына — чүпрәк! Портфеле җиргә төшә. Күрәсеңме? Чөнки аның күкрәгендә җаны бар. Аның җаны безгә буйсына, ягъни безгә яраклаша. Сизәсеңме? Кешенең җаны безгә яраклаша! Ә син миннән читләшергә чамалыйсың кебек... Булмый. Әгәр бүген җирдә кемдер кыйблага карап намаз укый икән, ул ялгыша. Кыйбла хәзер безнең якта... Әллә йоклап утыра?!

И п т ә ш е. Кыйбла хәзер безнең якта.

Т и м е р. Безнең якта!

И п т ә ш е. Шулай дим ич.

Т и м е р. Син кыйблага артың белән торасың.

И п т ә ш е. Сезнең якка карап чукынырга түгелме?

Т и м е р. Безнең якка карап инде күпләр чукына.

И п т ә ш е. Чукыну гадәтемә кермәгән.

Т и м е р. Кертербез. Без һәрвакыт сезнең янда, сезнең арада. Вакыт — безнеке. Вакыттан котылып булмый.

И п т ә ш е. Син мактанчыклыгыңнан котыла алмыйсың. Әйдә, киттек *(торып китә башлый)*.

Т и м е р. Мин аларны синнән башка да туздыра алам. Һәм Луиза минеке була.

И п т ә ш е. Вакланма! Зур бит син! Хәзер генә сөйләдең. Мине шуңа ышанды дип уйла.

Т и м е р. Кирәк әйбернең вагы юк. Аны үзеңчә хәл ит, тартып ал, суырып ал да ул синеке булсын. Зурлык шуннан башлана. *(Каршысындагы каенга пычак ыргыта.)*

И п т ә ш е. Китәбезме?

Т и м е р *(пычагын барып ала, тагы ыргыта, тагы...)*. Синең кебек бер китүчене... дуслары куып җиткәннәр дә машинага утыртканнар. Кырга илтеп үзен тере килеш күмеп куйганнар. Ишеткән идеңме шул хәлне?

И п т ә ш е. Ишеттем. Аларны тоттылар.

Т и м е р. Димәк, куркасың...

И п т ә ш е *(ачулы, әкрен генә Тимер каршына бара)*. Мин синнән курыкмыйм!

Т и м е р *(сабыр гына)*. Хәзер маңгаеңа сугып артыңа утыртсам дамы?

И п т ә ш е. Алдыйсың! *(Тимергә үрелә башлый.)* Син минем куәтне беләсеңме? *(Кач белән аның иңбашына төртә... Тимер егыла.)*

Т и м е р. Син чынлапмы? Нәрсә? Син әллә чынлапмы? *(Тора, өсләрен кага.)*

И п т ә ш е *(бераз эндәшми торгач)*. Юри генә. Әйдә, югалтканнардыр.

Т и м е р. Ә соңрак... Минем белән килерсеңме?

И п т ә ш е. Югалтканнардыр.

Т и м е р. Киләсеңме?

И п т ә ш е. Аларның берсе мине таный шикелле. *(Китә.)*

Т и м е р. Ә, дус?! Туктале, тукта, дус кеше. *(Иптәше артыннан китә.)*

**Хатын-кызлар килә...**

Э л ь з а. Кешеләр диңгезгә бара. Алар анда яр буена сипкән бәрәңгеләр кебек...

Безнең тыныч елгаларда ял итүгә җитәме икән ул диңгез...

Луиза. Зәңгәр диңгез, тирән диңгез, серле диңгез. Анда яңа дуслар...

Асия. Минем Ягуар Шахматовичны диңгезгә якын йөртү куркыныч. Бөтенләй йөзә алмый. Күгәрченкәем, үзе моряк булып хезмәт иткән.

Луиза. Үлеп... Йөзәргә яратам.

Эльза. Син әйбәт йөзәсең.

Луиза. Акчарлак булсам, хәзер диңгезгә очар идем.

Эльза. Без елга акчарлаклары, шуны да онытма.

Луиза. Әллә яр чыпчыклары микән?

Асия. Яр чыпчыклары *(ир-атлар калган якка күрсәтә)* тегендә калдылар. Ягуар Шахматович җитәкчелегендә.

**Кызлар көлешеп ала.**

Эльза. Асия, карале. Күптән үзеңнән бер әйбер сорыйсым килә. Ягуар дигән исем бик сирәк исемме ул? Бер дә ишеткәнем юк кебек.

Асия. Сиңа ошамыймы әллә?

Эльза. Ошый. Чын ирләр исеме.

Луиза. Дөньяда бер генә исем!

Эльза. Каян уйлап тапканнар диген.

Асия. Кечкенә генә авылда, көннәрдән бер көнне ялгыш туган исем ул. Ягуар Шахматович дөньяга килгәч, әтисе яңа кеше исеменә документ яздырып алырга киткән. Исемне Ягъфәр дип кушарга уйлаган. Документ язып утыручы абзый татар милләтеннән түгел, үзе Ягъфәрнең әтисенә дус кеше икән. Малай туу шатлыгыннан ике дус бераз салганнар. Шуннан малайның дөньяда барлыгына документ язына башлаган. Берсе әйтеп торган, икенчесе — Ягъфәр диясе урынга Ягуар дип, Шаяхметович урынына Шахматович дип язып та куйган. Ике дус тагын бераз күтәргәннәр, озак сөйләшкәннәр. Соңыннан рәхмәтләр әйтешеп, куллар кысышып, кочаклашып, үбешеп, елашып аерылышканнар.

Луиза. Елашып ук аерылмаганнардыр ла инде. Миңа Ягуар Шахматович сөйләде ич.

Асия *(Луизага)*. Ул сиңа күбрәк тә сөйли шикелле һәм дөресен сөйләми бугай *(пауза)*. Менә шул документ язылганнан бирле дөньяда Ягуар Шахматович яши. Кайберәүләр аңа Егор Шахматович та диләр, Игорь Шахматович дип эндәшүчеләр дә бар. Ничек эндәшсәләр, шуңа җавап бирә, күгәрченкәем. Ир димәсәң, үпкәли әле.

Луиза. Асия апа. Аны алай ук төшермә инде. Бервакыт үзең шуңа ышана башларсың... Эшендә мактала, гаиләсен кайгыртучан. Аңа ир дими, ни диярсең? Андый ир һәркемгә эләкми ул.

Эльза. Ирләр — әйбәт, хатын-кызлар да әйбәт, шундый нәтиҗә ясыйк та бәхәсләшмәгез.

Луиза. Мин бәхәсләшмим.

Асия. Бәхәсләшмисең? Яклап торасың! Ягуар Шахматовичны син яхшы беләсеңме, минме?

Луиза *(паузадан соң)*. Син дә яхшы беләсең, мин дә яхшы беләм.

Эльза. Луиза!?

Асия. Күгәрченкәем, мин бит аны бөтенләй беләм.

Луиза. Соң... Мин дә бөтенләй беләм.

Асия. Туктале, тукта? *(Пауза.)* Без бит аның белән бергә йоклыйбыз.

Луиза. Без аның белән бергә — йокламыйбыз.

Асия. Шулай булгач?

**Эльза борчылып йөренә.**

Луиза. Шулай булгач, йокламагач, Ягуар Шахматовичның нинди ир икәнен беләм.

Асия. Син нәрсә сөйләгәнеңне аңлыйсыңмы?

Луиза. Аңлыйм.

Асия *(югалып кала)*. Аның ир икәнен *(пауза)* кайдан беләсең? Кайда сез аның белән йокламыйсыз?

Луиза. Шәһәрдә.

Асия. Кайчан?

Луиза. Көндез, әлбәттә.

Асия. Сәгать ничәдә?

Луиза. Төш вакытларында. Берда, икедә...

Асия. Ничә сәгать йокламыйсыз?

Луиза. Ике сәгать, өч сәгать.

Асия. Өч сәгать! *(Ире янына китә башлый.)* Ягуар Шахматович!

Эльза *(Асияның юлына төшә)*. Асия, кирәкми.

Асия. Ничек кирәкмәсен? Мин хәзер аларның. Мин хәзер! *(Пауза.)* Кайтарып җибәрәм. Китсеннәр. *(Чатырдан әйберләрен чыгарып ташлый.)*

Эльза. Асиякәем, җан кисәгем? Ул юкны сөйли.

Асия. Күңелем сизенә иде аны. Ягуар Шахматович!

Луиза. Асия апа?!

Асия. Болай калдырмыйм. *(Ире янына китмәкче.)* Мин сезне, күгәрченнәрем!

Эльза. Асия, бүген... Мондый вакытта. Зинһар өчен? Иртәгә.

Асия. Ерак бит ул — иртәгә!?

Л у и з а *(иелеп пычак ала)*. Карагыз әле, мин нәрсә таптым!

- Э л ь з а. Пычак!

Л у и з а. Ир-атлардан берсе югалткандыр.

А с и я *(якын килеп)*. Ягуарның мондый пычагы юк.

Э л ь з а. Арсланныкы, йә, Булатныкы?

Л у и з а. Ох, нинди үткен! *(Пычак тоткан кулы белән саксыз хәрәкәтләр ясый.)*

А с и я. Син, кызый, пычаклы кулың белән артык селтәнмә. Ялгыш Җир шары эленеп торган җепне *(пычакны Луизадан ала)* кисеп җибәрүең бар.

Л у и з а *(бераз шаярып)*. Беренче кат ишетәм. Кая соң ул? Җир шары эленеп торган җеп?

Э л ь з а. Чынлап та кая соң ул. Күрмим.

А с и я. Ул җеп синең муеныңа аша үтә. Минә шуннан *(пычак белән Луизага күрсәтә)*, хатын-кыз муены аша үтә. Киселсә, китәчәк түгәрәк җир түбәнгә...

Л у и з а. Сезнең шаяру сәер...

Э л ь з а. Каяле, бир миңа. *(Асиядән пычакны ала. Тынлык.)*

**Ир-атлар элеккечә җырлап киләләр.**

Я г у а р *(бераз җыр тынып торгач)*. Нәрсә шаулашасыз.

Л у и з а. Без — шаярабыз.

Б у л а т. Шаярырга ярый... Көне шәп иде, көне!

А р с л а н. Бер сәгате — елга торырлык!

Я г у а р. Иртәгә дә әйбәт көн булачак.

Л у и з а *(ир-атларга)*. Сез төнне әйләнеп узарга чамалыйсыз ахыры.

Я г у а р. Аныси ук булдырып булмас.

А с и я *(әле генә Луиза белән сөйләшкән сүзләр тәэсирендә)*. Килдегезме, күгәрченнәр?

Б у л а т. Арсланнар килде.

Я г у а р. Ягуарлар, Булатлар.

А р с л а н *(хатын-кызларга)*. Менә бит сезгә нинди көчләр буйсына.

А с и я. Шул көчләргә ышанып куна калабыз инде. Хәерлегә булсын. Ә кайсыгыз пычагын югалтты?

Я г у а р. Нинди пычак?

А с и я. Булат пычак. Эльза, күрсәт әле.

**Барысы да пычакны карыйлар.**

Б у л а т. Минем пычак түгел.

Я г у а р. Гомердә дә мондый пычагым булганы юк.

А р с л а н. Минем дә үзем белән пычак йөрткәнем юк.

Я г у а р. Каян таптың.

Э л ь з а. Әнә шуннан.

Я г у а р. Шуннан? Үлән арасыннан?

Э л ь з а. Әйе, Луиза тапты.

Я г у а р. Без монда утырдык бит, йөрдек, туп уйнадык. Күргән булыр идек.

А р с л а н. Күренерлек пычак шул бу?

Я г у а р. Көндез кояш тегендә иде *(күрсәтә)*. Шулай. Кояш күчте, түбәнгәрәк төште. Пычак ялтырый башлый һәм... сез аны тапкансыз...

**Киеренке тынычлык. Эльза пычакны ала. Тынычлык дәвам итә.**

Ярый, ни әйтергә телисез? *(Тынычлык дәвам итә.)* Сезнең сүзсез торуны ничек аңлыйк? *(Тынычлык дәвам итә.)* Сезнең сүзсез торуны мин шулай аңлыйм: беркемнең дә бередә төнгә каласы килми. Шулай гына аңлыйм.

Э л ь з а. Алай түгел түгелен.

А р с л а н. Бередә яхшы. Киту... әллә ничегрәк чыга.

**Тынычлык дәвам итә.**

Я г у а р. Яхшы. Тавышка куям. Кем дә кем бередә калмаска, кайтып китәргә дигән уйда тора, шул кулын күтәрә...

**Бер-беренә карыйлар. Кул күтәрүче юк, берсе икенчесеннән тартына...**

Димәк, калабыз.

Б у л а т. Ахыр чиктә — без бит күбәү.

Л у и з а. Ә без төннең иң караңгы, иң куркыныч чагын учак янында уздырыйк.

А с и я. Уттан бүреләр генә курка.

Э л ь з а. Бүреләр дә хәзер уттан курыкмый.

Л у и з а. Хәзер төнге урманда кочен кая куярга белмәгән яшьләр чуала, ди, мажара эзлиләр икән.

Я г у а р. Аларның мажараларын ишеткәнебез бар.

А р с л а н. Бер-берегезне куркытышмагыз. Таныш түгел чатырларга төнлә килеп тыгылырга кешенең башы ике түгел.

А с и я. Килсә, аның башсызы килеп тыгыла да инде.

Л у и з а *(шомлы тавыш белән)*. Төнлә яныбызга, бер кеше килсә, үзенең башы булмаса, үзе сөйләшсә. Исәнмесез, дисә. Көрәшергә кулын сузса, бу башсызга кайсыбыз беренче булып кул бирер?

Э л ь з а. Мин бирмәс...

Л у и з а. Ә ул бездән бередә калдырган пычагын сораса?

Я г у а р. Булды. Юкны сөйләшмибез. Якты чакта төнгә әзерләнергә кирәк.

**Хатын-кызлар төнгә әзерләнә башлый.**

Я г у а р. Төнге учакка утын караштырыйк.

Арслан. Әйдәгез, мин сезне утынның оясына илтәм.

Булат. Утынны калынын, анекдотларның нечкәсен әзерлик.

**Ир-атлар китә.**

Эльза. Аңламыйм, кая китте соң әле ул?

Асия. Кем кая китте?

Эльза. Кем түгел, пычак. Минә шушында гына куйган идем.

Асия. Тагын яңалык. Ул кая китсен?!

Эльза. Бәлки ир-атлар алгандыр.

Асия. Алар пычак алмады.

Эльза *(Асиягә игътибар белән карап).* Бир.

Асия. Нәрсә?

Эльза. Пычакны бир.

Асия. Син нәрсә, Эльза?

Эльза. Бир дигәч, бир?

Асия. Миндә түгел ул.

Эльза. Шаярма.

Луиза. Миндә ул, Эльза апа.

Эльза. Синдә?!

Асия. Ул сиңа ник кирәк булды?

Луиза. Алма кисәргә. Аны мин таптым бит, шулай булгач, ул миндә булсын.

Эльза. Кызык кына син. Миңа әйтминитмн алгансың *(пауза).*

**Төнгә әзерләнү дәвам итә.**

Луиза белән мин урта чатырда йоклыйбыз. Ягуар Шахматович белән Асия Бариевна кырыйда. Булат белән Арслан икенче кырыйда. Безнең оборона сызыгы була. Сызыкта — ирләр.

Асия. Безнең оборона сызыгында бүгенге ирләр, шуны да исегездән чыгармагыз.

Луиза. Алай ук борчылмагыз. Сез кинолардны, бер селтәнеп унны еккан ирләрне күзаллагыз. Яки *(зур пауза)* гангстерларны — алар да бит бүгенге ирләр.

Асия. И-и, күгәрченкәем. Яман нният бирсәң, ике ягыма ике пычак кыстырсаң, ике кулыма ике пистолет тоттырсаңмы? Мин дә гангстер! Пычакларын, пистолетларын алсаң, аның хәзерге гангстерларыннан да кем каладыр әле?

**Самолет очып узган тавыш ишетелә, тавыш ерагая, алан караңгылана... Эльза гына күренә.**

Эльза. Кызлар, никтер балачагым исемә төште: Ак карлар... Самолет гүләве. Сугыш еллары... Тышта җил. Ул тәрәзә капкачларын каера. Кыш китмәскә килгән кебек. Тәрәзәләрне томалап ут ала идек. Суыктан өй бүрәнәсе шартлап ярыла. Тәрәзә төпләреннән идәнгә хәтле бозлар салынып төшкән. Күршеләр кердә. Кар шыгырдый. Ул чакларда мин кечкенә кызчык идем. *(Пауза.)* Аннан соң мин җиткән кыз булдым. Ак күлмәк яраттым. Аннан ана булдым... Баламның күзләре кара булды... Аннан соң мин үземнең баламны, тургаемны югалттым. Аны сагынып еладым. Аны сагынып... Карадан киендем... Аны сагынып... Кара күзле курчак сатып алдым. Без кара күзле курчак белән икәү бергә еладык. Аннан соң мин икенче курчак сатып алдым, аннан өченчене, аннан дүртенчене... Ул елларда мин кара күзле ун курчак сатып алдым. Без алар белән бергә елый, сөйләшә, көлешә торган идек. Көннәрдән бер көнне мин аңладым, минем курчакларым — бары тик курчаклар гына. Мин алар белән сөйләшүдән туктадым. Елаудан туктадым. Курчакларны еракка яшереп куйдым. Аларны мин хәзер дә саклыйм. Сирәк кенә, кайчакта гына алып карыйм. Алар чынлап та — курчаклар гына. Шуңа күрә мин еламыйм. Хәзер инде елый да алмыйм. Минә бит нинди мин? Кем соң мин? *(Пауза. Моңланып җыр башлый.)*

Сайрый былбыл, сайрый тургай,—
Баласын җуйган бугай.
Баласын җуйган тургайдай
Ник моңаям мин болай.

Э елыйсы килә... Юк, каен буласым килә... Юк. Юк, юк! Хатын-кыз буласым килә, бары хатын-кыз...

**Эльзаның китүе күренеп кала. Аланга караңгылык урнаша... Тик йолдызлар гына арта. Тагын реактив самолет үткән тавыш кабатлана. Тулы ай чыга. Тынлык... Якты төн. Йолдыз атыла. Тынлык озакка бармый, кинәт кыска гына, ләкин көчле сызгыру тавышы ишетелә. Сызгырулар кабатлана. Чатырдан Арслан чыга, аның артыннан Булат... Арслан Ягуар Шахматович йоклаган чатыр янына килә.**

Арслан. Ягуар Шахматович, Ягуар Шахматович! Чык әле. Кемнәрдер безнең тирәдә йөри бугай.

Булат. Кайдадыр болай гына сызгырыналар булса кирәк.

**Ягуар чыга.**

Ягуар. Сызгырынганнарын мин дә ишеттем. Болай гынадыр.

**Сызгырулар тагы да якындарак кабатлана.**

Булат. Киләләр!

Арслан. Бәйләнсәләр, нык булырга кирәк.

Булат. Нык торырга кирәк. *(Кулына балта ала.)*

Ягуар *(хатын-кызларга)*. Кызлар, Асия Бариевна!

Хатын-кызлар. Ишетәбез, ишетәбез.

Тимер тавышы. Үзем генә барам. Кирәк булсагыз чакырырмын.

Ягуар *(хатын-кызларга)*. Кемнең нинди уй белән йөрүен белеп булмый. Сез барыгыз әле, куаклыкка качып торыгыз. Таралышсак, теге юл буендагы таллыкта очрашырбыз.

Луиза. Тизрәк-тизрәк!

**Хатын-кызларның куаклыкка таба китүе күренеп кала. Ир-атлар янына Тимер килә, ул туктала.**

Тимер. Интеллигентлар. Кызлар белән килдегезме?

Булат. Без хатыннарыбыз белән килдек.

Тимер. Алдама! Сиңа килешми! *(Кесәсенә тыгыла.)*

Ягуар. Без сезне алдарга да, сездән алдатырга да уйламыйбыз.

Тимер *(никтер йомшабрак)*. Балтаңны миңа ыргыт, кырыемнан узып китәр. Жиргә генә куйсаң да ярый. Аның сезгә кирәге юк. *(Кинәт кыюланып.)* Сезнең соңгы учак янып бетте! Атам мин сезне!

Булат. Шаярмагыз!?

Тимер. Балачакта гына шаяра идем. Хатын-кызлар чатырдамы?

Арслан. Анда безнең хатын-кызлар.

Ягуар. Сезгә нәрсә кирәк?

Булат. Нәрсә кирәк?

Тимер. Коньяк кирәк түгел. Хатын-кызларыгызга күз салганда ярар иде дә — ашыгам... Хәзер өчегезне дә атам да китәм. Машина көтеп тора.

Ягуар. Сез ялгышасыз, иптәш.

Арслан. Әйе, әйе, ялгышасыз. *(Өчәүләп әкрен генә артка чигенәләр.)*

**Булатның кулыннан балтасы төшеп китә. Аны жирдән Тимер ала.**

Тимер. Юк! Ялгышмыйм! Минем куллар тимер...

**Шул вакыт шапылдап Тимернең артына нидер төшә. Тимер сискәнеп әйбер төшкән якка карый. Шуны гына көткән сыман өч ир-ат дәррәү урманга кереп югала. Тимер чатырлар янына ашыга. Ул соңгы чатырны караганда, аның артына ук Эльза килеп баса. Тимер Эльзаны күрми, ир-атлар киткән якка бара башлый.**

Эльза. Тукта!

**Тимер тавыш килгән якка борылуга, Эльза аңа кулындагы саллы предмет белән кинәт сугып жибәрә. Тимер өнсез кала, жиргә чалкан барып төшә. Эльза аның кесәләрен капшый, аннан соң бер кулы белән Тимернең кулбашыннан, икенчесе белән чалбарыннан тота да аны жиңел генә йөзтүбән әйләндерә. Арт кесәсен капшый. Аннан урман ягына кычкыра.**

А-си-я! Ягуар Шах-ма-то-вич! Ки-ле-гез! Ү-тер-дем! Мин аны үтердем. Лу-и-за! Булат! Килегез, Арслан, килегез. Мин аны үтердем. Ки-ле-гез!!! Ү-тер-дем!!!

**Эльза кабат Тимер янына килә. Кулына тоткан әйберен ташламаган.**

Ки-ле-гез!

**Аланга Асия килеп җитә. Аңардан әз генә артка калып, Луиза керә.**

Асия. Эльза, күгәрченкәем.

Эльза. Үтердем.

Асия *(җирдә яткан Тимергә карап)*. Хәшәрәт!

Эльза. Нишлибез инде хәзер?

Асия *(Тимергә карап)*. Бандит. Чәчләрен кара, кешегә охшамаган. Ике аяклы хайван. Үз башына котырган ул.

Луиза. Чынлап үлдеме?

Эльза. Әйе... Хәзер мине нишләтәләр инде?!

Асия. Сине нишләтсеннәр. Алгы ягына суктыңмы?

**Луиза аптыраган кыяфәттә бүрәнәгә барып утыра.**

Эльза. Алдынна суктым.

Асия. Яхшы булган. Сине берни дә эшләтмәсләр. Ул һөҗүм итте бит. Син үзеңне якладың. Дусларыңны якладың. Синең кебекләр күбрәк булса, мондыйлар күптән кырылып беткән булыр иде. Кешеләр үз кырларында, үз урманнарында күптән рәхәтләнеп йөри алырлар иде. *(Урман ягына карап ала.)* Дөньясында — ирләре дә юк. *(Жирдә яткан Тимергә яңадан карап.)* Бу юри генә үлгән булып ятмый микән?

Луиза. Кеше үлгән булып юри шулай озак ятмастыр инде. И, әнекәем, ник килдек без бирегә?

Эльза. Юри ятмый ул.

Асия. Терелеп-китеп, алай-болай итмәсен? Әллә үзен әйләндереп, мангаена бәрәрне... Бандит.

**Берәм-берәм ир-атлар да урманнан чыга.**

Асия. Ягуар Шахматович, кайларда югалып йөрисез? Эльза аны сугып үтергән.

Ир-атлар *(артка чигенеп куя)*. Сугы-ып?!

Ягуар *(башын селкеп тора)*. Иптәшләре кая китте икән?

Асия. Иптәшләре булмаган аның. Бул-

салар, сезне куып тоткан булырлар иде.

Эльза. Иптәшләрә юк иде аның. Юри сызгырынган, үзе генә сөйләнгән, куркытыр өчен. Күбәуләр дип белсеннәр дигәндер *(Пауза.)* Үтердем.

Ягуар. Начар булган шул.

Булат. Әйе, начар булган.

Арслан. Яхшы булмаган.

Ягуар. Мин бит сезгә китәргә кушкан идем. Качып кала идек. Яңадан ник әйләнеп килергә?! Йөрер-йөрер дә китәр иде әле.

Булат. Китәр иде.

Арслан. Китми кая барсын ул.

Луиза. Ярар. Булган хәл булган. Үтергән. Кайтыйк та милициягә әйтик. Үзе бәйләнде диярбез. *(Пауза.)* Сезнеңчә фикер йөртсәң *(ир-атларга карап)*, дөньядагы бөтен яхшы кешеләр сарык кебек өерелешеп, йөгерешеп хулиганнардан качып йөрергә тиеш була.

Эльза. Минә да китеп кенә барасы булган икән дә... Сезгә ярдәм кирәктер дип калдым. Ул сезне атәм дип торганда, мин аның артына таяк ыргыттым. Ул таяк тавышына игътибар итәр, шунда сез аны эләктереп алырсыз дип уйлаган идем. *(Пауза.)* Бу бер үзе калды да... Мин аны шушының белән *(кулындагы предметны күрсәтә)*...

**Алан акрынлап яктыра бара.**

Арслан. Ташла әле шуны, Эльза.

Эльза. Ташламыйм. Милициягә күрсәтергә кирәк бит ул.

Асия. Күрсәтәбез, сөйләбез. Без гаепле түгел. Чакырып китермәдек, үзе килде.

Ягуар. Сөйләвен сөйләрбез дә *(пауза)* ул бит бер үзе *(пауза)*. Без күбәү *(пауза)*. Аның шул ягы бар. Закон дигән нәрсә — катлаулы, нечкә механизм.

Булат. Барыбызны да гаепләүләре мөмкин.

Арслан *(авыр сулап куя)*. Бик мөмкин. Ябып куюлары да бар.

Эльза. Кайгырмагыз, ир-атлар! Ул тиздән аңына киләчәк һәм торып басачак.

**Бу сүздән барысы да сискәнеп куя. Луиза утырган урыныннан тора.**

Эльза. Мин аның муен тамырына суктым. Ул вакытлыча гына аңсыз калды.

Ягуар. Эльза, дөрес сөйлисеңме?

Эльза. Хак сүз сөйлим.

Асия. Бөтенләй, торып ук басармы?

Булат. Алайса аны бәйләп куярга кирәк. Иә ул торып сугыша башлар.

Ягуар. Булыр да.

Арслан. Булыр ул мондый хулиганнан.

Луиза. Бәйләргә кирәк, бәйләргә.

Ир-атлар. Бәйләргә кирәк.

**Бау табалар, бәйләргә телиләр.**

Эльза. Кирәкми. Сугышмас, курыкмагыз.

**Ир-атлар аптыраашта.**

Асия. Без барында курыкмагыз, күгәрченнәрем. *(Кулына җирдә яткан балтаны ала.)*

Ягуар. Асия Бариевна. Урынлы шаяру түгел! Хулиган ул аны-моны уйлап тормый. Тагы гауга куптаруы, әллә ни килеп чыгуы бар. Атарга да күп сорамас. Пистолетын алып куйыйк.

Арслан. Булат. Алыйк. Пистолетын алыйк.

**Ир-атлар җирдә яткан Тимергә омтыла.**

Эльза. Мәшәкатьләнмәгез. Мин сездән алда өлгердем.

Арслан. Кая куйдыгыз пистолетын? Бирегез әле... Бир...

Эльза. Пистолеты юк иде.

Ягуар. Юк идемени?!

Булат. Кара син аны, артистны. Ничек оста алдый белә.

**Ул арада Тимер аңына килә башлый.**

Эльза *(Тимер янына барып, аның калын табанлы туфлиенә аяк очы белән генә берничә кат төртеп ала)*. Әй, син кем? Яхшы чакта тор! Югыйсә... Үзенне теге дөньяга ук озатабыз.

**Тимер торып утыра. Муенын уа. Конфликтның нинди ноктада туктап калганын сизеп ала. Барысы да Тимергә карый.**

Арслан *(Тимергә)*. Ычкынырга уйлама, эләктең.

Тимер. Егетләр! Мин бераз ялгыштым. Мин артыграк эчкәнмен. Мин Луиза янына килдем. Ул мине белә.

Луиза. Мин сине белмим.

Тимер. Мин Тимер. Ул белә, белә. Теләсәгез, кыйнагыз мине. *(Тагын үзендә көч сизә башлый.)* Килегез. Үтерегез. Луизаны беркемгә дә бирә алмыйм. Бирмим.

Луиза *(Тимергә якын килә)*. Җүләркәй. Сине кем үтерсен?! *(Ир-атлар ягына ымлап.)* Болар яхшы кешеләр.

Арслан. Без хулиганар түгел.

Булат. Без үтерүчеләр түгел.

Тимер. Һәр төндә Луиза төшемә керә. Ул минеке булырга тиеш.

Луиза *(Тимергә тагы да якыная)*. Танымыйм бит, бәр таныштан әйбәт танышым, Тимерем минем!

Тимер. Яратам мин аны. Мин аны югалтмаска тиеш.

Луиза. *(бармаклары белән Тимернең*

*жиңенә кагыла, аны иркәләп тора.)* Бөркетем... Арсланым!

**Асия балтасын җиргә куя... Эльза барып магнитофон ала. Ир-атлар сәерсенеп тора.**

Т и м е р. Мин Луизадан башка торалмыйм. Аннан башка — мин кеше түгел, исемем Тимер түгел. Куәтем бетсен, малым тузылып бетсен, шәрә калыйм — берсе дә кирәкми. Миңа Луиза кирәк!

Л у и з а *(Тимергә).* Кая, ия төш башыңны *(иркәли, елмая).* Тимерем! Гореллам!

Т и м е р. Без Луизә белән мәңгегә бергә булырга тиеш.

Л у и з а. Буйволым минем. Кем әйтмешли, өйләнәм мин сиңа!

А с и я. Лу-и-за?! *(Балтасын палаткалар ягына ыргыта.)*

Т и м е р. Луизам...

**Барысы да елмаешалар. Урманда машина кычкырткан тавыш ишетелә.**

И р-а т л а р. Коттермәгез, барыгыз.

Т и м е р. Әйдә, Луизә. Мин сине кабат югалтырга куркам.

Л у и з а. Мин дә.

Т и м е р. Чынлапмы?

Л у и з а. Шушы пычак белән ант итәм. *(Пычак чыгара.)*

Т и м е р *(бераз читкә чигенеп).* Ул синең кулга ничек? Кайдан?

Л у и з а. Күктән төште. Күккә китсен. *(Кулындагы пычакны ыргыта.)*

Т и м е р. Луиза, рәхмәт сиңа.

И р-а т л а р. Безгә рәхмәт әйт. Әйе, безгә. Ансат кына котылганың өчен.

Т и м е р. Барыгызга да рәхмәт.

**Машина кычкырта.**

Л у и з а. Әйдә, китәбез.

Э л ь з а. Сабыррак, сабыррак. Без бит бергә — бер төркем булып урманга чыктык. Төркемне урманда таратырга ярамый. *(Тимергә.)* Кичә кич кенә сезнең хакта сөйләшә башлаган идек, сүзебез дә бетмәде... Сез бара торыгыз.

Т и м е р. Минем хакта?

Л у и з а. Тимер... Үзең дә аңлыйсыңдыр, Эльза апа дөрес әйтә. *(Пауза.)* Шунсыз булмый. Бар... бара торыгыз.

Б у л а т. Шулай. Бара торыгыз!

Т и м е р. Бара торыгыз дип. Без бит машина белән.

А с и я *(Тимергә).* Без, күгәрченкәем, кирәк булса, машина белән барганны җәяү куып җитәбез. *(Тагы машина кычкырткан тавыш ишетелә.)* Сезне чакыралар. Барыгыз! Хатын-кызлар белән килешергә кирәк.

Э л ь з а *(ачуланып).* Сезне көтәләр.

И р-а т л а р *(якап).* Барыгыз. Бар. Бар. Булды. Ишетәсезме!

**Тимер куркып кала. Китә.**

А р с л а н *(Тимер күздән югалгач).* Бер генә бирермен... *(Пауза.)*

А с и я *(җитдиләнеп).* Әйдәгез, Ягуар Шахматович, сөйләшеп алыйк. Ачыклыйк.

Я г у а р. Тагын нәрсә ачыкларга?!

А с и я *(Ягуарга).* Дөресен әйт, сез Луиза белән кайчаннан бирле һәм кайда очрашасыз.

Я г у а р *(шаярып).* Күптән, шәһәрдә...

А с и я. Син миңа төгәл әйт. Төшке ял вакытларында очрашып... кайда — икәү йокламыйсыз?

Я г у а р *(җитди).* Ася, ни сөйлисең?

А с и я. Луиза миңа барын да әйтте.

Я г у а р. Нәрсә әйтте?

Л у и з а. Мин Эльза апага да әйттем. Арслан абый белән *(елмая)* шәһәрдә очрашабыз дидем. Ир-атларның кадерле икәнен тоеп карасыннар әле, дидем... Шаярттым.

А р с л а н. Луиза, шулай шаяртырга ярыймыни?

**Пауза.**

А с и я *(Луизага карап).* Шундый сүз белән аның шаярган булуына мин ни өчен хәзер ышанырга тиеш?

Л у и з а. Шаярттым. *(Ике яңагына төшеп торган чәчләрен ике кулы белән тотып вальс көенә әйләнеп китә.)* Шаярттым, шаярттым, шаярттым.

Я г у а р *(Асиягә).* Син дә кеше ышанмаслык сүзгә ышанып торасың. Ул бит — бала гына.

Л у и з а *(кинәт әйләнүеннән туктап).* Ягуар Шахматович, миңа бала дип әйтмәгез.

А с и я. Әнә, әнә. Эльза, кыланмышын гына күр әле син аның.

А р с л а н. Асия Бариевна? Ул шаярткан...

Я г у а р. Шаярткан.

Л у и з а *(тагы вальс көенә әйләнә башлый).* Шаярттым, шаярттым...

Б у л а т. Ул бит шаярткан гына...

Э л ь з а. Җәмәгать, әллә биеп алабызмы?

А с и я. Э ник биергә?

Л у и з а. Була-ат, киләсеңме?

А р с л а н *(Эльза янына килә).* Мөмкинме?

Я г у а р. Э ник биемәскә! *(Асия янына килә.)* Алда әле башланмаган — тулы якшәмбе бар.

**Музыка. Парлап бииләр... Кайдадыр тургай сайрый.**

Э л ь з а. Сез тургайны ишетәсезме? Ишетәсезме? Минем кечкенә тургаемны?

******************

# Шәүкәт Галиев

## Галәмдә әтәч тавышы

*Җирдәге төрле тавышлар язылган кассета, космик аппаратка урнаштырылып, галәмгә җибәрелде. Анда: «Саумысез, сәлам сезгә!» дигән сүзләр дә бар. Максат — тереклек ияләрен эзләү, алар белән элемтә урнаштыру...*

Матбугат хәбәреннән

Кояштан ары, бик ерак
Җисемнәр тарафында,
Кикрикүк дигән тавыш бар
Йолдызлар арасында.

«Исән уяндыңмы, Җир?»—дип,
Хәл белгәндәй һәр иртә,
Гайрәтләнеп кычкыра да
Яңа бер аваз көтә.

Тереклек итеп ятмыймы
Галәмдә берәр җисем —
Үзләре йоклаган булса,
Әтәчләр җавап бирсен!

Төрле телләрдә яңгырый
Җир улы тавышы да:
«Саумысез, сәлам сезгә!»—дип,
Тели ул танышырга.

Җирдә яшәү авазының
Ишетелер күпләре:
Эт өрүе, су шаулавы,
Һәм тагын күк күкрәве.

Галәмдәшләр, туп шартлавын
Без сезгә җибәрмибез,
Дустанә дәшкән аһәңнәр
Яхшырак җитәр, дибез.

Өстәр идем, үзәк өзеп,
Үксеп бала елавын —
Мөмкин түгел, ишеткәннәр
Эндәшмичә чыдавы...

Балалар бөтен галәмдә
Бер төсле елыйдыр ул,
Балалар бөтен галәмгә
Тынычлык сорыйдыр ул!

«Саулармысез, сәлам сезгә!»
Мәңгелектән җисемнәр —
Яктылык еллары белән
Якты еллар килсеннәр.

Тереклекнең югын эзлик,
Ә бары югалмасын —
«Җир кайда?!»—дип, үксез әтәч
Галәмдә еламасын...

## Адашкан арыш белән көнбагыш

Иң җайсыз урында —
Шпаллар кырында
Моңаеп утыра ялгыз арыш,
Башын иеп тора көнбагыш.

«Әй, арыш,
Кая барыш?»
«Нинди сагыш
Каралтты, көнбагыш?»

«Калдык без адашып,
Ялгышып...
Тынчудыр җирләре,
Дегетле җилләре!»
«Югалмадык әле, исән без —
Илдәгечә һаман үсәбез!
Кышлар үтәр әле, чыдарбыз,
Поезд каршыларга чыгарбыз,
Безне алырга бит килерләр?
Сузылып кул бирерләр ич,
Бирерләр?»

Тимер юл өстендә,
Егылмый һич кенә
Җилдә канат кага бер арыш,
Илгә таба карый көнбагыш...

## Зәңгәрнең сарысы

Дулкыннар ярларга
Ашкынып җан ата,
Җир-әнкәм, сиңа дип,
Гәрәбә тарата.

Диңгезнең җимеше
Ялтырый — сап-сары,
Быелгы бал сыман
Өр-яңа, саф сары.

Бик ерак заманда
Кояштан тамган ул —
Сагыз-күз яшьләре
Урманнан калган ул.

Диңгездән гәрәбә —
Зәңгәрнең сарысы,
Зәңгәре — сагыну,
Сарысы — сагышы...

Уемда — туган як,
Йөрим яр буенча.
Җыям мин әнкәмә
Гәрәбә муенса...

## Мәгарә карап йөрибез

Мәгарә карап йөрибез —
Әйтерсең монда һаман
Бүленеп калган да яши
Бик күптән үткән заман.

Мәгарә карап йөрибез —
Тотып бак борынгыны,
Әллә вакыт машинасы
Кирегә борылдымы?

Мәгарә карап йөрибез —
Боз сөңгеләр күтәреп,
Кала безне караңгыдан
Якты көнгә үткәреп.

Мәгарә карап йөрибез —
Күрмәгән ул кояшны.
Атом шартлап, бар дөньяны
Шушы хәлгә куймасмы?..

...Мәгарә карап чыктык без —
Көннең яктысы тулып,
Каршылады тере дөнья
Ышаныч, өмет булып!

## Әпипә

Әп әп-әп, пи-пә-пә,
Бөтерелә дә китә,
Тыпырдап тора бит, ә —
Бөтен илне биетә!
Аякларны уята,
Кулларыңны уйната,
Өлгермисең уйлап та —
Киттең идән буйлата!

Әп әп-әп, пи-пә-пә,
Тиктормас кыз Әпипә,
Белгәннәрне биетә,
Белмәгәнне өйрәтә,
Яшен-картын мәйданга
Чакыра ул барчасын —
Аяклары һаман да
Онытмый татарчасын!

Әп әп-әп, пи-пә-пә,
Карасаң кызык бик тә —
Уңнан да ул — Әпипә,
Сулдан да ул — Әпипә...
Башлар әйләнеп бетә,
Аяк бәйләнеп китә,
Көе һаман җилкетә,
Җирне дә ул селкетә!

Әп әп-әп, пи-пә-пә,
Борынгыдан килеп тә
Әби түгел Әпипә,
Яшь кыз безнең Әпипә!
Тынмас җанда Әпипә,
Кайнар канда Әпипә,
Биетеп тә иртеп
Килер көннәргә китә!

## Мин бит Кояш баласы

Күрдем бармакларымны
Кояшка куйгач кына,
Алсу нур тулы икән —
Мин дә гел Кояш кына!

Кояштай көлеп көн дә
Тау өстендә йөрермен,
Кешеләрне яктыртып
Бар өйләргә керермен.

Бозларны эретермен,
Җылы җил истерермен,
Киң кырларны тутырып
Игеннәр үстерермен.

Каян гына үтсәм дә
Гел яктырып каласы —
Эчем тулы нур гына,
Мин бит Кояш баласы!

## Тылсымлы карандашлар

Яшел карандаштан минем
Урман үсте,
Кызыл карандаштан күчте —
Алма пеште.

Зәңгәр карандаштан тулып
Елга акты,
Көрән карандашым килеп
Юлга ятты.

Күксел карандашым менеп
Күккә тулды,
Сары карандашым көлде —
Кояш булды.

Ап-ак карандашым минем
Якты хыял —
Галәм уртасына очкыч
Ясап куям!

## Дус кирәк

«Аның белән мин урамда
Куышып уйнар идем,
Йөгерешеп арганнан соң
Чирәмдә аунар идем.

Кайчан гына сызгырса да
Тиз килеп җитәр идем,
Капка төпләренә барып,
Чыкканын көтәр идем.

Мин аны саклар идем дә,
Ул мине яклар иде,
Яратып сыйпар иде дә,
Алып кочаклар иде.

Әгәр дус малаем булса,
Рәхәт буласы ничек!» —
Тик аңа каршы килделәр:
«Син бит тәртипле кечек.

Әшәке малайлар белән
Урамда йөрерсеңме,
Ояңа кайтып кермичә,
Кеше колдерерсеңме?!»

...Ә кечек дус эзләп йөри,
Мөлдерәп карый күзгә.
Шундый бер малаем маэмай
Очрамадымы сезгә?

## Муса Җәлилнең кызы Чулпанга килеп җитмәгән хаты

*«...җиңгәч, мин өйгә кайтырмын. Синең туган көнеңне бәйрәм итәрбез. Мин сиңа бик яхшы бүләк бирергә җыенган идем, кайткач бирермен.*

*28 февраль, 1942 ел.»*

Муса Җәлилнең фронтка барганда
кызы Чулпанга язган хатыннан

Кичер, балам, кичер эткәңне,
Мин сүземдә тора алмадым,
Туган көндә була алмадым...
Тик бурычлы булып калмадым —
Җиңү булды сиңа бүләгем,
Мин тыныч көн сиңа теләдем —
Кадерен бел, балам, кадерен!..

Коткәнсеңдер нәни чагыңда,
Үскәч инде үзең аңладың,
Вакытында кайта алмадым,
Тик барыбер читтә калмадым —
Азат илем сиңа бүләгем,
Мин бит сиңа бәхет теләдем —
Кадерен бел, балам, кадерен!..

Сагнуларым калды мәңгегә —
Җырга барсын сала алмадым...
Белеп киттем, якты доньяда
Мәхәббәтем исән калганын —
Газиз әнкәң сиңа бүләгем,
Мин бит сиңа шатлык теләдем —
Кадерен бел, балам, кадерен!..

**Азат Ганиев**

# ГАБДЕЛХАК

ПОВЕСТЬ



Ерак араларга йөри торган автобус ялан кыр уртасында туктап, аннан яшь кенә бер хатын төште. Дүрт-биш яшьлек кызы да бар иде. Кызын автобус ишегеннән күтәреп алып, юл читенә бастырды. Ишектән аңа портфелен, ридикюлен суздылар. Дания аларны да юл читенә куйды. Аның әле багажниктан чемоданнарын аласы бар иде.

Шофер, кабина ишеген бераз ачып, арттан-алдан килүче машиналарны үткәреп җибәрде дә, авыр гәүдәсе белән асфальт юлга җайсыз гына сикереп төште. Руль артында озак утырудан аның тәне оеган, костюмының арткы чабуы гармун күрүге кебек йомарланган иде. Һәр адым тансык булганга, рәхәтлек биргәнгә, ул, бармак очына элгән ачкыч бәйләмен уйната-уйната, ашыкмый гына багажник ягына чыкты. Багажниктан берсеннән-берсе зур һәм шактый авыр ике чемодан алып җиргә куйды.

— Рәхмәт сезгә.

Шофер өлкән яшьләрдә иде инде. Багажник ишеген бикләп билен турайткач, Даниягә ваемсыз гына карап алды. Ләкин Дания караган саен карыйсы килердәй чибәр хатын иде. Затлы өс-башы да аңа карата игътибарлы булуны сорый. Шоферның йокымсыраулы битендә, картлык җыерчыклары арасына кысылып калган күзләрендә елмаюга тартым җылылык хасил булды.

Пассажирларның кайберләре, тукталыштан файдаланып калырга ниятләп булса кирәк, автобустан төшкәли башладылар. Ике егет Даниянең чемоданнарын юлның икенче ягына чыгарып куйды. Каршы яктагы тезмә таулар итәгенә таба чокыр-чакырлы грунт юл төшеп китә иде. Шул юл белән Даниягә әле тагы егерме чакрымлап кайтырга кирәк. Иреннән аерылып, ялгыз карчык — әнисе янына кайтып килеше.

Бераздан автобус, туктап торган җирендә карасу тапллар калдырып, кузгалып китте. Юл чаты калку урында иде. Салкынчарак җил исеп тора. Күк аяз, һава әллә кайларга кадәр үтә күренмәле. Тезмә таулар ягына борылып караугa, Дания шуларның иң якындагысына маңгае белән килеп бәрелгәндәй булды... Тау битендәге һәр таш, һәр ерым, яфракларын коя башлаган һәр каен, усак агачы аерым-ачык күренә. Телсез-өнсез табигатьнең менә шушындый аяусыз чынбарлыгы, салкын битарафлыгы Даниянең мин-минлегенә тия, аның-моңда һичбер

дәхеле юклыкны искәреп читкә тибәрә иде. Юри генә дә түгел, табигать чын-чынлап битараф иде Даниягә карата. Дания үзен кеше өенә ялгыш килеп кергән кебегрәк хис итте, мәгънәсе бигүк ачык булмаган, гомер ахырында үләсе бары исенә төшкәндәге кебек, әллә ниткән бер шомлану күңелен биләп алды.

Мондый хәл, шушыңа охшашлы кичереш кичерергә туры килә — узган гомереңне күздән кичергәндә, үткәннәрдән сабак алып, тормышыңда нидер борылыш ясарга кирәк булганда туа. Син үзеңнең элеккечә яшәү рәвешең белән канәгать түгел, яки синең элеккечә яшәү рәвешең үзе тормыш каршылыгына очраган, синең уй-фикерләрең, чынбарлыкны күзаллавың нәрсәсе беләндер артык беркатлы, һәр даим үзгәреп, яңарып торучы тирәлектә яшәү өчен яраксыз булган. Сиңа шәхес буларак яңа сыйфатларга ия булырга, рухи яктан яңадан туарга кирәк. Шунсыз киләчәктә тулы канлы тормыш белән яши алмаячаксың.

Ләкин синең фикерләвең, чынбарлыкны күзаллавың әле һаман элеккечә. Элекке хәлеңдә калган килеш шул хәлеңне инкарь итәргә, ягъни үзең аша сикереп чыгарга кирәк. Ә бу мөмкин түгел. Менә шунда табигатьнең я ш ә ү к ө ч е дигән могҗизасы күңел түреннән күтәрелеп чыга да сине, синең бәтен барлыгыңны айкап сала. Син әле утырып, басып, ятып тора аласың, тышкы кабыгың исән, ләкин шәхес буларак син инде юк. Үзеңне күпмедер вакытта таркалган хәлдә хис итәсең. Тышкы дөнья белән бәйләнеш өзелә. Күзләрең ачык килеш берни күрмисең. Ихтыяр көче йомшый, я бөтенләй булмый. Ни кушсалар — шуны эшлисең, ни әйтсәләр — шуңа күнәсең. Ләкин бу буйсыну түгел, саклану чарасы. Сиңа комачауламасыннар гына. Ә эчтә гаять киеренке хәрәкәт бара. Үзең дөньядан аерылгансың, ләкин бөтен дөнья синең баш миеңдә: элек алган тәэсирләрең, элек җыйган белемең, фактлар җыелмасы рәвешендә. Бөтенесе исәптә. Бөтенесе синең хәтереңдә гадәттәгегә карaганда күп мәртәбәләргә үткенрәк җанлана. Үзеңнең шушындый хәлеңнән куркып калмаска гына кирәк. Сабыр, җитәрлек кадәр игътибарлы булсаң, мондый хәлдән, кайнар суга чумып-чумып чыккан әкият батыры кебек яшәреп, яңа сыйфатларга ия булып, үзеңә генә түгел, башкалар өчен дә кыйммәтле булырдай рухи хәзинәләргә баеп чыгарга була. Алдыңда дөньяны танып белүнең яңадан-яңа офыклары ачылып китәргә мөмкин. Бары тик сабыр һәм азакка кадәр намуслы булырга гына кирәк.

Әгәр шунда элекке шәхси җимерекләреңне юкә бау белән бәйләштереп, ярым-йорты ташламалар белән котылырга теләсәң, соңыннан канәгатьсезлек, вөҗдан газабы сине йөрәк чиренә китереп терәячәк.

Дания, үзен әзәрлекләүче чынбарлык белән күзгә-күз карашып тормас өчен, иелеп кремплин күлмәгенең итәкләрен сыпыргалады, чемоданнарын бер тирәгәрәк куеп, берсенең ычкынган бәген каптырып маташты. Болары аңа таныш, аңа буйсынулы үз дөньясы иде.

Аерылышуны алай ук авыр кичермәгән кебек иде югыйсә. Гомумән, озын-озак һәм тирән уйларга бирелү аның табигатендә юк. Ә монда әллә никадәрле сорау, тормыш мәсьәләләре дулкын булып өстенә килә. Сытып, изеп үтәргә дә күп сорамас. Хатын үзендә алар белән әвәрә килерлек көч-куәт сизмәде. Бөтенесенә ачуы килеп: «Булган, беткән!» — дип кул селтәде. Тылсымлы таяк белән кизәндеме ни! Үткәндәгеләр җансыз калып кире үз ярларына кайтып төштеләр. «Булган, беткән! — дип кабатлады Дания, котылу чарасы табылуга сөенеп.— Булган, беткән!» Чынбарлыкны алдап, чынбарлыктан да качып була, күрәмсен. Үткәндәгеләр җансыз баганалар рәвешендә катып калдылар. «Булган, беткән!»

Төскә-биткә чибәр кызларның кайсы гына яшьрәк чагында актриса булырга хыялланмый икән? Даниянe дә читләтеп үтмәде бу шаукым. Ләкин ул тиз айныды. Аяклары нәзегрәк икән. Шуның аркасында минч-

юбка заманнарында да озын итәкле күлмәк киеп йөрде. Сәхнәдә чагында тамашачылардан битәр ул үзе шул кимчелеген тоеп аңгырая һәм рольгә кереп китә алмыйча җәфаланып бетә иде. Аннары җырга, биюгә сәләте дә уртача икәнлеге ачыкланды. Уртача инде ул үзеннән өстеннәргә кызыгып, көнләшеп гомер итү дигән сүз.

Кайсы яклап булса да естен чыгасы килү теләге Даниядә чамасыз көчле иде. Бу, бер яктан, аның психикасына бәйле булса, икенче яктан, тормыш-көнкүреш мәшәкатьләрен күралмавыннан, шулардан арынырга теләвеннән иде. Чын-чынлап сләсән, сукыр күздән яшь чыга, диләр. Эзли торгач Дания, ниһаять, үзенең көчле ягын, табигый сәләтен ачыклый алды. Кешене бер күрүдә, аның йөз кыяфәтендәге, үз-үзен тотышындагы, кием-салымындагы үзенчәлекләр аша аның кемлеген, бигрәк тә йомшак якларын чамалый, сизә-тоя ала икән.

Яшьлек хыяллары җимерелеп, тирә-юньгә аеграк күз белән карый башлаган бер чорда Альфред исемле егетне очратты ул. Сәүдә базасында шофер булып эшли, баянда уйный белә. Тыйнак, оялчан. Даниягә үлеп гашыйк. Дания дә аны яратты. Тик егет тәкъдим ясарга кыймыйча, эчтән янып-көеп бик озак йөрергә җыена иде кебек. Дания Альфредларга ешрак килә башлады һәм берсендә куныпук калды. Альфредның этисе күтәрү кранында эшли, әнисе шул ук конторда бухгалтер иде. Квартиралары иркен, өч бүлмәле. Бар да әйбәт, тик акча ягы гына кысанрак. Дания Альфредка сиздерә килде. Һаман шулай барса, бергә тора алулары иксле булачагын да аңлатты. Егетне уй басты. Эшеннән салгалап кайта башлады. Ябыгып, каралып калды. Һәм көтмәгәндә баеп киттеләр. Альфред, лоторея оттым, диде. Үз машиналары белән диңгез буена элдерделәр. Иркенләп кызына гына алмадылар. Шунда диңгез буенда ук, Альфредны кулга алып, биш елга төрмәгә ябып куйдылар. Эшләгән җирендә ниндидер махинацияләр белән акча үзләштергән икән. «Көтәрмен, җаным, көтәрмен, көтәрмен»,— дип елый-елый аерылышты Дания ире белән. Ләкин биш ел аз гомер түгел икән. Берничә ай үтүгә үк Дания моның нәрсә икәнен бик яхшы төшенде.

Даниягә егерме яшь тулып килә. Үзе тол хатын. Хәзер аңа адәм рәтле кешегә кияүгә чыгар өчен диплом кирәк булачак. Дания сәүдә техникумына укырга барып керде. Имтиханнарны җиңел үтте. Яши белгән кешегә студент тормышының да әллә ни кыенлыгы юк икән. Уку еллары үтте дә китте. Шул шәһәрдә үк калырга да җай бар иде. Ләкин Дания, кулына диплом алу белән, Коми ягындагы гомер күрмәгән, колак ишетмәгән икенче бер шәһәргә китеп барды. Ник дисәң, өченче курсларда укыганда бер чытлыгы аңа Донна Жуанна дип кушамат таккан иде. Ягъни, Дон Жуаннан алып, Дания Җәләсваны шулай Донна Жуанна дип үзгәрткән. Шул гамьсез кушаматны адаштырып калдырырга теләде.

Яңа урында әйбәт кенә эш тапты. Аннары Хариска килеп юлыкты. Харис — агач эшкәртү комбинатында баш инженер иде. Өч бүлмәле квартирасы, үз машинасы бар. Дания аны бигүк яратып та бетермәде. Көннәрен дөрес исәпләмичә балага узды да, бичарадан ни чара гына чыкты ул Хариска кияүгә. Теләр-теләмәс башлаган тормышлары торабара бөтенләй ямьсезләнде.

Ә бер көнне Харис эшеннән елмаеп кайтып керде. Иркен бер хәрәкәт белән өс-баш киемнәрен салып чөйгә элде. Гомердә булмаганча Даниягә күңелле, шаян карап залга узды. Аяк атлауларына тикле бүтән, әле Дания белән танышып кына йөргән чагындагыча бәйсез, җиңел. Тик ишләптер йөгереп килеп аягына сарылган Әлфиянс башка көннәрдәгечә күтәреп алмады. Кулын Әлфиянең башына куйды да боегып, уйчанланып калды. Югыйсә, ярата бит ул Әлфиясен. Дания белән әллә нičкләр ачуланышканда да кызына ягымлы була торган иде.

Әлфия үзен күтәртәсе килеп, нәкъ әтисенеке кебек күзләре белән Хариска инәлеп карап тора башлады. Харис кызын күтәреп алды. Кысып кочаклаган килеш идән буенча йөренеп килде, аннары аны диванга утыртып яңадан баягыча күңелле, шаян елмая-елмая Дания каршына килеп басты.

— Шундый хәлләр, Дания,— диде ул. Аның тавышы әллә нинди иде. Салкын битарафлык һәм бары шул гына. Бераз дәшми торганнан соң Харис шул ук тонда: «Донна Жуанна»,—дип өстәде.

Даниянең йөрәге өзелеп төшкәндәй булды. Димәк, адаштырып калдырдым дип уйлаган кушаматы аны барыбер эзләп тапкан!

Харис элек тә көнле иде. Ләкин аның моңарчы көнләве өйдәге ниндидер бер әйбернең үз урынында тормавына ачу килү сымак кына була иде. Ә бу юлы Харисның үз-үзен тотышындагы үзгәрештән Дания югалып, хәтта куркып калды. Шуңадырмы, Харис: «Саклык кенәгәсендәге дүрт меңне синең исемгә күчерәм»,—дигәч, җәнҗалсыз-нисез ипле генә китеп барырга риза булды. Әлбәттә, квартираны да бүлеп алырга мөмкин иде, ләкин миһырбаны килеп: «Ярар инде, Әлфия балигъ булганчы алимент та түлисе бар мескенненң»,— дип, анысына ук бармады.

...Чемодан өстендә бөгелебрәк утырган Әлфия сабырсызланып аякларын бер-берсенә ышкып алды. Кысталган, күрәсең. Дания, шартын китереп, чемоданнар ышыгында аны «тәпи» тотты. Итәгенең җыерылыбрак калган төшләрен сыпырып тигезләгәндә ул, кем беләндер бәхәсләшкәндәй: «Исән булсак, яшәрбез!»— дип куйды.

Алай да машина көтү озакка китте. Дания чемоданнары янына кире менде. Көзгесенә күз салып төзәтенгәләде. Юл йөрү авырлыгы йончыткаммы, әллә көн яктысы артык шәфкатьсез идеме, үзеннән канәгатьсез калды. Кәефе дә кырылды. Шул чак аның янына тормозларын чыелдатып «газик» килеп туктады. Шофер, кабинасыннан чыгып, аның янына килде.

— Дания, авылга кайтасыңдыр, пажалый,— диде.

Колхоз председателе йөртә торган машина иде бу. Шоферы да үз авылларыныкы. Исеме генә хәтереннән чыккан. Капка төпләренә кадәр илтеп куя бит инде бу болай булгач. Кара ничек уңай килүен! Шулай да Дания түгелеп чәчелмичә генә:

— Алып кайтсаң,— диде.

— Апкайтабыз аны, апкайтмаска!

Машинада бүтән кеше юк иде. Чемоданнарын артка ук кертеп урнаштырдылар. Шофер, теленә салынгалап, Даниянe үзе кырыендагы утыргычка утырырга кыстады. Алай итсә, Даниягә кызын алдына алырга туры килә, күлмәге бөгәрләнәчәк иде. Шуңа күрә ул:

— Әлфиянең йокысы килә, юл да бик сикәлтәле, кырыенда тотып утырмыйча булмас,— дип кызы янына кереп утырды. Ә үзе, ачуы килебрәк: «Сезнең шул булыр инде!»— дип уйлады. Хәзер ул ир-атны дошман күрә, барысына ачу саклый, кайчак бөтенесен таптап-изеп үтәсе килә иде.

Машина «әһ!» дигәнче, тезмә таулар итәгенә житеп, Зәй күпереннән чыкты һәм ике тау арасындагы сөзәгрәк урыннан көчәнми генә өскә үрмәли башлады. Шофер егет бая Даниянең кырысланыбрак китүен сизсә дә, бер арада Даниягә борылып, ачык йөз белән:

— Син, Дания, бер үзгәрмәгәнсең. Һаман шул күзнең явын алырдай чибәр икәнсең. Мәктәптә укыганда сиңа бөтенесе гашыйк иде бит. Ачуланмасаң, мин фәкыйрегездә дә бар ие андый гөнаһ,— диде.

Мондый мактау Даниянең күңеленә хуш килде. Шунда ук кәефе күтәрелеп, йөзенә елмаю кунды. Һәм хәзер ул, чыннан да, чибәр иде. «Исеме ничек соң әле бу тел бистәсенең? — дип баш ватты ул.— Бездән

югарырак класста иде. Рафис түгел инде. Рәфкать... юк. Рифкать! Әйе, Рифкать».

Бераздан машина тау өстенә менеп җитеп, коелган яфраклар түшәлгән урман юлыннан китте. Монда юл да тигез. Янып торган мич эче шикелле кояшлы аланнар очраштыргалый.

— Җәй дә үтеп бара. Быел күрми дә калдым җәйне,— диде Дания.— Кара инде син миләшләрне!

Машина килгән шәпкә алан эченә кереп агачлар ышыгында туктады...

*
* *

Капка төбенә председатель «газигы» килеп туктаганда Фатыйма апа ишегалдында кайнаша иде. Кабаланыбрак каршы алырга чыкты. Әлфияне күтәреп алды. Машинадан бүселеп-бүселеп чемоданнар чыга башлагач кына, елмаюы сүрелеп, берьюлы кара коелып төште. Дания вак-төяк портфель, сумка ише нәрсәләрне күтәреп өйгә кереп барышлый, капка төбендә тукталыбрак калган Рифкатька:

— Керт, керт. Өйгә керт,— диде. Калган әйберләрне алырга дип яңадан машина янына чыккач, пышылдап:— Миләшләр калсын. Әни болай да... Ярый, рәхмәт,— диде.

Дүрт почмаклы өй тагы да кечерәя төшкән. Кадагыннан купкан берничә өйалды тактасын әнисе юкә бау белән бәйләп куйган. Дания, күңелсез сөйләшүгә әзер булып, өйгә керде. Әнисе болай да бөтенесен аңлаган, күрәсең, хәл сорашу түгел, кызына күтәрелеп тә карамады.

— Әнинең шул, йөзенә чыгару булыр инде! Ачулан, кычкыр, бик җәлләсәң җыла, тик пажалысты йөзенә чыгарма!

— Синә пычагым да булмас. Хатын-кызның оятсызлыгы хәзер җир күтәрмәслек. Кияүне кызганам мин.

— Кызганам! Кызганам! Әллә мин ташлап кайттыммы?! Үзе!

— Ир-ат түзә-түзә дә бер дуен чыгара ул шулай.

Дания елый-елый керфек буяуларын битенә сылап бетерде.

— Бала куркытып утырма, адәм тәганәсе! Ю ул битләреңне. Капкада кеше бар әнә.

Дания аралык ягына кереп китте. «Ярар, иң кыены шушы ие, узды»,— дип уйлады ул. Аның ирдән аерылып кайтуын кайгыга санап, йөрәгенә якын алырдай бүтән кеше юк. Авыл халкы бераз чәйнәр дә тынар. Аерылышу хәзер гадәти эш «Авылда ук эш булмас та әле, бәлки. Районга барып белешергә инде. Аңынчы Әлфия әбисе янында торып торыр»,— дип уйлады Дания. Күзге янына барышлый тәрәзә төбендә яткан бер хат күзенә чалынды. Ачылмаган. Җәләева Даниягә диелгән. Йомышы төшепме, болай гынамы кергән күрше карчык белән исәнләшеп, хәл-әхвәлләрен сорашкандай иткәч, Дания тәрәзә буендагы урындыкка утырып хатны ачты. Рокыядан икән. Ул хатын белән Дания Казанда кунакханәдә бер бүлмәгә туры килеп, сөйләшеп-танышып киткәннәр иде.

Фатыйма карчык өстәлгә шаулап торган самавыр китереп утыртты. Хат укыйм дип кеше барда почмакта төртелеп утырмас бит инде. Дания хатны куеп чемоданнан сәйлүн чәе, йөзем җимеше, шоколад, конфет ише нәрсәләр алды. Чемодан капкачын ачуга, күбек сыман кабарып киткән мамык шәлне: «Әни, сиңа булыр»,— дип сандык өстенә куйды. Бүләк әйберләр арасында бик матур бизәкле яулык белән күлмәклек материя дә бар иде. Табын янында Дания берни булмаган кебек тыныч,

хәтта күңелле утырды. Карчыклар белән куе-куе ясап берничә чынаяк чәй эчкәннән соң, әлеге укылмаган хатны кулына алды.

«Исәнме, кызый, Дания! Җәйне сез көньякта үткәрә торган халык. Кайткан-киткәндә әнисенә сугылмый калмас дип, шушы адресың белән язарга булдым. Хат язарлык әллә ни сәбәп тә юк югын. Болай эч пошканнан гына.

Мәктәптә хәлләр тынгысызланды әле. Былтыр авылга ирле-хатынлы бер семья күчеп килгән ие. Яшьләр. Хатыны унны гына бетергән. Мәктәп буфетында эшләде. Ире Габделхак исемле. Художник дип тә сөйлиләр. Мокыт кына бер нәрсә шунда. Рәсем, сызым, хезмәт дәресләрен алып бара. Мәктәп мастерскоен ремонтлап шунда чар, пилорамише нәрсәләр көйләде. Директордан кырдыру станогы таптырды, бораулары да бар. Завод цехымыни! Бала-чага балга ябышкан чебен кебек артыннан калмый йөри. Бер заман бөтен мәктәп баласы электр моторы ясарга тотынды. Кайсының сумкасын ачып карама, кансир калае, кайчы, тимерчыбык. Ясаган беренеке әйләнә тагы, кызлар ясаганына тикле әйләнә. Ансы бераз басылган ие, бер заман рәсе: чире кузгалды. Ансы да шул мастерскойда. Тәрәзә пәрдәләре кнупкыга басып кына ачылаябыла. Мольберт, рефлектор дигән әллә нәрсәләре бар. Чирек йомгакларын карыйбыз — өлгереш «выжт!» түбән! Мәктәптә ике отличнигыбыз бар ие, Габделхак шуларга хезмәттән «өч»ле чыгарган. Үгетләп тә карыйбыз. Юк! Үз туксаны туксан. Өйрәнсеннәр, ди. Менә бер заман көтүе-көтүе белән инспектор арты инспектор килә башламасынмы! Казынсаң әллә ниләр чыга бит ул мәктәп тормышында.

Инде быел тагын ниләр күрербез. Хатыны үлгәч, Габделхакны мужыт китәр дип тә уйлаган идек. Китмәде. Дүрт почмаклы иске генә өй сатып алганнар иде, шунда хәзер бер үзе. Җәйге каникулда да беркая бармады. Җенле нәрсә кебек мәктәп мастерскоенда ята. Хатыны балага узган иде. Минингит диме, баш чире белән китте, мескен. Яшь-яшь көе. И-и, бу дөнья! Яшәгән буласың шунда...»

Рокыяның зарлана торган гадәте бар инде анысы. Үзе болай җебегән дә түгел ул. Калын бөдрә чәчле, ирләрчә тупасрак йөз-кыяфәтле таза нык хатын. Беренче сөйләшүдә Дания аныңча булырга тырышып, үзен шулай ук җигелеп-сөрелеп тормыш алып баручы ир хатыны итеп күрсәтте дә, аннары шул рольдән чыга алмады. Рокыя әле булса Даниянe үзенең фикердәше, аны аңлардай берданбер дусы, ахирәте дип белә, күрәсең.

Дания хатны яңабаштан, Габделхак турында язылганнарын әзләпәзләп укый башлады. Авылда яшәүче рәссам! Рокыя аның рәссам булуын «имеш» дип кенә яза язуга. Ләкин бүтән «батырлыкларына» карaганда ул егетнең чын рәссам икәнлеген генә Дания чамалый ала иде. «Иҗат кешесе генә нәрсәгә тотынса шулай кабынып китә,— дип уйлады ул.— Кара инде! Олы юлдан читтә, бәләкәй генә, аулак кына авылда берүзе бер өйдә шундый егет яши! Әкият бит бу!»

Даниянең тегермән ташы кебек әйләнә башлаган уй-хыялларына мөмкин кадәр күбрәк информация кирәк иде. Хатны ул кат-кат укып чыкты. Рокыя азактарак: «Завуч итеп куймагайлары. Директор аны үз итә»,— дип Габделхакны тагын бер телгә алган иде. Ирмәт авылы бөтенләй башка районда. Ераклыгы да байтак. Даниянең Рокыяларда бер булганы бар. Бик ямьле авыл булып хәтерендә калган...

Дания төнне йокысыз үткәрде. Фатыйма карчык, кызының әледән-әле боргаланып куюын үзе йоклап киткәнчегә хәтле ишетеп ятты. «Бу чүбек башка да исәп кердеме әллә?! Ире, баласы өчен хәсрәтләнәме икәнни?!»— дип уйлады. Шуңа күрә иртән кызына йомшаграк булды. Табын янышнан кузгалуга: «Әни, мин районга төшеп эш ягын белешим»,— дип юлга җыена башлавына да сүз әйтмәде.

*
* *

— Исәнме, Рокыя.

— Абау! Дания! Нинди җилләр?!

— Өегезгә барырга уйлаган идем дә, туктале мин әйтәм, бүген-иртәгә укулар башланырга торганда өендә булмас, мәктәптәдер дип туры монда килдем.

— Күргәзмә әсбаплар белән кайнаша идем. Хәзер кайтабыз. Чәй куеп җибәрербез. Аргансындыр. Безнең бит автобустан төшкәч тә өч чакрым җәяү керәсе. Син ничек, берәр яры баруыңмы, кайтышлыймы дигәндәй?

— Туры Ирмәткә килүем. Эшкә урнашырга дип әле җитмәсә.

— Туктале, ә ирең?

— Аерылыштык без, кызый. Әлфия авылда, әбисе янында. Я ничек, кабул итәсезме? Мин буфетчы булып килергә бик риза.

— Югын юк та... Шаяртасыңмы соң, Дания? Шаярганга да охшамыйсың. Кара инде, башларым әйләнеп китте. Әй, булмаганны! Килешерсез әле. Табак-савыт...

— Аннан узган, Рокыя. Булган беткән.

— Белмим, белмим. Сез дә аерылышкач инде! Башыма сыйдыра алмыйм. Соң, аерылышсаң да, син шәһәр тормышына күнеккән, бу җәһәннәм тишегендә тора алырмын дисеңме?

Бу кадәресен уйламаган иде ул. Чыннан да, нишләп Ирмәткә килеп эшкә урнашырга йөри соң әле бу матур апай? Нindiрәк пәрдәгә төреп, ничегрәк аңлатырга? Аерылышкан ирем таба алмасын өчен китеп урнашырга булдым дисәң? Юк, ышандырмый. Рокыя ук ышанмаячак. Ул Харисны белә.

— Харис белән яшәвебез яшәү булмады, Рокыя. Кайчан да бер аерылыша идек. Син инде, Рокыя, кызым барлыгын монда тишмиенчәрәк тор. Шунда берәр егетегез белән танышып китмәмме.

— И чукынмыш, Харис ярамаганны, авыл кешесе ярар инде сиңа, әллә кая.

— Ә теге художник егетегез? Хатыңда язган идең бит.

— Мин аны сиңа мактап язганием сымак.

Дания сөйләшүне уенга борып җибәрергә җай калдырырлык итеп кашын-күзен уйнатып алды.

— Ә миңа шундыйлар ошый да! Ы-ы-ы?!

Аның бу «ы-ы»сында иркә бала назлылыгы да, ана арыслан ертмачлыгы да бар иде. Рокыя, баядан бирле теш арасына кысылып, төртелеп торган «Әстәгыфирулла!»сын, ниһаять, тутырып әйтеп куйды.

— Нәрсә? Әллә бердәнбер ахирәтеңә шул егетне дә кызганып торыр идеңме?

Рокыя оялыбрак елмайган хәлдә кулын селтәп:

— Миңа дисә, ботинкасы-ние белән кабып йот.

Рокыя бу хәлләрнең үзләре өчен шактый отышлы буласын чамалап алган иде инде. Габделхакның күзен-башын әйләндереп Ирмәттән алып ук китсә, начар дисеңмени. Болар барыбер авылда яшисе кешеләр түгел.

— Алайса, Дания, директорның монда чагы. Әнә, мастерской ягына китеп баралар. Габделхак та шундадыр. Бар да сөйләш.

Кем кем, әмма Дания бу эшнең алай тота-каба эшләнмәвен яхшы белә. Анда, берсе бер таныш түгел ир-ат арасына барып керсә, кайсы белән нindiрәк мөнәсәбәттә булырга, кайсы белән ничегрәк сөйләшергә белми аптырап калуы бар.

«Беренче тәэсирдән күп нәрсә тора, беренче тәэсир аяктан егышлы булырга тиеш»,— дип уйлады Дания.

*
* *

Мәктәп мастерскоенда Габделхак берүзе. Тимер тишә торган станокның моторы янып чыккан иде. Запасны эзләп-эзләп тә таба алмадылар. Янып чыккан обмотка чыбыкларын Габделхак үзе урап карарга булды. Шуның эше четрекле эшнең ул җаен да белә, казынырга түземлеге дә җитә. Сүтәргә җайлы булсын өчен башта мичкә тыгып, чыбык арасына каткан буяуларны яндырып алды. Аннары һәр тотамдагы элмәкләрне саный-саный, уралу тәртибен сызымга сыза-сыза иплән кенә сүтте. Бүген менә урап бетереп тә килә инде. Мастерской эче тып-тын. Кайчак кайдадыр сабый бала елаган тавыш ишетелеп куя. Габделхакның колагына ишетелә. Үзе генә калып тыныбрак тордымы — шул хәл. Тумыйча, әнисенең карынында килеш, әнисе белән бергә җир куенына кергән баласы елаган кебек булып колагына ишетелә. Хәзер инде Габделхак моңа гаҗәпләнми дә, курыкмый да, арынырга да теләми. Чөнки ул — аныкы.

Габделхак тоташтан ике-өч сәгать утыра инде. Тәмәке кабызып урыныннан торды, тәрәзә каршына барып басты. Мәктәп тә, мәктәптән аерымрак урнашкан агач мастерской да биегрәк урында. Авыл моннан караганда аста. Чокыр-чакыр арасына, карга оялы дәү-дәү агачлар ышыгына посып утырган өйләр юньләп күренми дә. Шушы ягы белән Ирмәт Габделхакның туган авылы Өндәмгә охшый. Тик Өндәм зуррак. Дүрт-биш мәртәбә зур. Хәзер Гатуф бабасы йортында — кайчандыр гөрләп торган ишле гаилә яшәгән йортта — Сәгыйдә килен берүзе. Кызлары кияүгә китеп беттеләр. Гатуф карт та дөнья куйды. Габделхакның әнисе бер шулай: «Өч яшьлек чагыгызда Гөлчирә дә, син дә авырып киттегез. Сугыштан яраланып кайткан әти икегезне ике кулына тотып, төннәр буе йөреп чыга иде»,— дип сөйләде. Дүрт ел буе сугыш, үлем, вәхшәт эчендә йөреп кайткан Гатуф бабасы бер кулына үзенең төпчек кызын, икенчесенә оныгын күтәргән килеш, караңгы я айлы төндә ишекле-түрле йөреп ниләр уйлады, ниләр кичерде икән? Бәлки, нәкъ менә ул: «Мизгел, шушы хәлеңдә туктал!»— дип әйтерлек дәрәҗәдә бәхетле булгандыр. Габделхакның башына: «Бу истәлекләрне онытып бетермәс борын берәр яры язып куярга кирәк,— дигән уй килде.— Кешегә укытыр өчен түгел. Үзем өчен. Аннары, кайчан да булса, бәлки, улым алып укыр».

Кинәт кенә Хәят исенә төшеп, Габделхакның йөрәге жу-у итеп куйды. Күңелендә әз генә кагылсаң да убылып төшәргә торган җире бар шул аның. «Боларны онытырга ярамый, язып калдырырга кирәк,— дип кабатлады Габделхак үзенә-үзе.— Менә хәзер кем төгәл генә әйтә ала, Гатуф бабай шул чагында бәхетле булганмы, әллә шул чагын менә хәзер мин уйлыйсын чамалап рәхәтлек кичергәнме? Тегесе чын булган хәл, ләкин хәзер юк. Монысы уй гына, минем уемда гына җанлана, ләкин аны мин — тере Габделхак уйлыйм. Ә уйламасам? Я гел оныткан булсам...»

Габделхакның әбисе... Әбисе? Кара инде, исеме ничек дип уйлап торам бит! Хәтер сандыгының йозаклары шулай күгәрә дә башладымы икәнни? Изге җан булып төшләренә керә торган әбисе югыйсә. Бер шулай, рәсем сәнгате училищесында укып йөргәндә, такы-токы, вакытлы-вакытсыз ашауданмы Габделхакның эче авырта торган булып китте. Үтмәс пычак белән кискән кебек авыртынмы авырта. Шунда Габделхак төш күрде. Актан киенгән, озын ябык гәүдәле Мәрхәбә әбисе алан түрендәме, тау битендәме, калкурак җирдә басып тора, имеш. Сүз дәшми. Аягы тирәли төрле үлән, чәчкә һәм бигрәк тә ак эрем күп икән. Әбисе, бер сүз әйтмәсә дә, шул эрем суын эчәргә кирәклеген төшендермәкче була. Кыш урталарында күргән төше хәтеренә нык сеңеп кал-

ды. Яз житеп, шул әрем шытып чыгу белән кайнар суда төнәтмәсен ясап, әчәсе килгән саен алып-алып эчә башлады. Атна-ун көн үтте микән, ярты ел җәфаланган авыртуы әллә булган, әллә юк—басылды куйды. Менә шундый изге җан бит аның Мәрхәбә әбисе. Ә ул...

Габделхак белән Гөлчирә бер яшьтә иделәр. Бергә уйнап үстеләр. Нишләптер Габделхакны һәрвакыт «Гөлчирә исән булса, минем язмышым бөтенләй башкача булыр иде»,— дигән уй әзәрлекли. Бала чагында, бигрәк тә үсмер егет чагында Габделхакны кыерсыттылар шул. Сугыш вакытында, сугыштан соң туган балалар сузылып буйга үсүчән булдылар. Габделхак Тугай авылында шуларның беренчесе иде. Озын буй хәзер генә модада бит ул. Ә ул чакны кимчелек, дөресен генә әйткәндә, гариплек санала иде. Бөтенесе аңа имәнеп, кызганып карый. Өйдә дә, мәктәптә дә, урамда да. Һәр көн, айлар, еллар буе шулай. Өлкәннәр кызгана, үз ишләре «чәлән», «колга» дип үрти. Кыюсыз иде Габделхак. Җитмәсә, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, әллә ни гомер мыек чыкмыйча изаланды. Армиядән кайтканда да, кызлар кебек ап-ак, шоп-шома битле иде. Шуның өстенә зәңгәр күз, кара каш! Кыз дисәң кыз, малай дисәң малай түгел. Күпме кыен күрде шуның аркасында. Раушания белән аңлаша алмыйча йөрүе, Раушаниянең гел уйламаганда бүтән берәүгә кияүгә чыгуы да шуның аркасында булгандыр әле. Гөлчирә исән булса, боларны аңа сөйләр иде, ә Гөлчирә аны аңлар, юатыр, ярдәм итәр иде сыман. Югыйсә хәсрәте дә кысыр хәсрәт кенә булган икән! Моны аңа беренче мәртәбә Ризван исемле бер себер татары әйтте. Ерак көньчыгышка бара торган поездның гомум вагонында урыннары бергә туры килде. Гадәттәгедән зуррак башлы, нык, таза гәүдәле карт иде ул. Күзләре зур-зур алмазлар сыман үтәдән-үтә кисеп карыйлар. Ә Габделхакка ничектер аерым игътибар итә кебек.

— Улым, сиңа ничә яшь?— дип сорады ул, ниһаять.

Габделхак үз-үзенә ачуы килгәнрәк, шул ук вакытта уңайсызланган да кыяфәттә:

— Егерме дүрт,— диде. Армиядән кайткан иде инде ул чакны.

— Син, улым, үзеңнең шулай шөкәтсез булуыңа, яшь чырайлы күренүеңә кимсенгәнгә охшыйсың. Бер дә кимсенмә. Утыз-утыз бишләр тирәсендә генә өлгереп, соңыннан йөз, аннан да озаграк яши торган нәселдән син, бала. Вакыты җиткәч, сакал-мыек та чыгар, тәнең дә тулыланыр, бер дә аптырама,— диде ул.— Киңәш итеп шуны әйтим әле. Ир-егет булыйм дисәң, үзеңне хөрмәт ит; буының ныгып җитмәс борын мәхәббәт маҗаралары белән мавыкма. Бусы бер. Аннан килеп тәнеңә ит кунгач, буының ныгып көч-куәтең арткач, юкка барга әтәчләнеп, сугышып йөрергә кирәкми. Ә инде картлык килеп зәгыйфьләнә төшкәч, комсыз булу бер дә килешми. Зарарлы да.

Аннары ул:

— Әти-әниләрең кемнәр?— дип сорады.

Бу соравында да берәр төрле хикмәт булырга тиешлеген сизеп, Габделхак эчтән җыела төште.

— Әни укытучы булган, әти дә. Аннары буровойда эшләде. Хәзер пенсиядә,— диде.

Сәер карт Габделхакның тагы ни дә булса әйтүен көтебрәк торды. Әйтмәгәч йөзе сүрелә төшеп:

— Әби-бабаларыңны хәтерлисеңме соң?— диде.

— Ике әбием, ике бабам да исән әле минем.

— Ярый, ярый,— диде Ризван карт. Ул һаман да нәрсәдәндер канәгать түгел иде.— Ә тескә, биткә кайсы якка тарткансың?

— Әнигә. Аннары Гатуф бабайның әтисе Гомәр бабайга охшаган, диләр. Гомәр бабайның әти-әнисе, туганнары үләт чире таралган елны үлеп бетеп, ишле, зур гаиләдән берүзе исән калган була. Соңыннан ул Хуҗиәхмәт байда ялчылыкта үскән.

Поездда барганда, бигрәк тә атналар буена сузыла торган ерак юлда йөргәндә кемнәр белән танышмыйсың, ниләр генә сөйләшеп бетермисең. Ризван картка күнегеп, теле языла төшкәч, Габделхак Гомәр бабасының ничек итеп үзенә өй салуын, нигез коруын сөйләп бирде.

— Гомәр бабай эшкә көндәм була, бай ни кушса, шуны җиренә җиткереп үти икән. Җир сөрү, печән чабу, мал-туар карау, тирес түгү кебек авыр эштә йөрсә дә, шалкан кебек ак тәнле, зәңгәр күзле бик матур егет була үзе. Өс-башы юка, алама булган, унсигез-унтугыз яшендә дә яланаяк йөргән. Байга эшләп-эшләп тә мантый алмагач, бердәнбер көнне тота да бу чишмә кырыендагы таудан таш чыгара башлый. Дастуенрак ир-атың да күмәгрәк тотына торган эш бит! «Үзен имгәтеп бетерер инде, мескен»,— дип моны бик кызганалар. Авыз күтәреп көлүчесе дә була. Янәсе: «Маңка малай да өй салсын, башкасы да!» Гомәр бабай аңа-моңа карамый, ашыкмый-кабаланмый, эшнең җаен белеп, вакытында ял да иткәләп эшли дә эшли. Чыгарган ташы көннән-көн арта бара. Хуҗиәхмәт картның олыга-кечегә шәфкатьле, бик сөйкемле бер кызы була. Җиһан исемле. Шул кыз чишмәгә суга килгәндә чиләк төбенә бәлеш катысы, ипи сыныгы яшереп төшә икән. Моны сизгәне сизгән, сизмәгәне белми дә калган. Ялчы булып йөргәндә беркем игътибар итмәгән үсмер егет хәзер йөзек кашы кебек һәркемнең күз алдында, телдән төшми. Әти-әнисенең борынгы болгар каныннан булуын да искә төшерәләр, чыбык очы агайне, кардәшләре дә табыла, кулдан килгәнчә ярдәм дә иткәлиләр. Җәй азакларына дүрт тәрәзәле җыйнак кына өйне төзеп бетерә бу. Агач эшенә дә кулы ята икән, ишек-тәрәзә, түшәмсайгакларын да үзе эшли. Өйне салып бетерә. Инде өйләнергә дә ярый бит. Бара да бу: «Хуҗиәхмәт бабай, менә шундый-шундый хәл,— ди.— Үзем яучы, үзем кияү, кызың Җиһанны сорап килүем»,— ди. Хуҗиәхмәт карт моны болдыр баскычына баскан килеш кенә тыңлап тора. Өйгә кер дип чакырып тору юк. Тыңлап бетерә дә камчы алып әрсез хәерчене ишегалдыннан куып чыгара башлый. Ә Гомәр аны ипләп кенә дилбегә белән арбага бәйләп куя. Аннары Җиһанны алып, авылдан чыгып китәләр. Бүтән авылга барып мулладан никах укыталар. Шуннан соң Хуҗиәхмәт карт боларга зыян итми. «Күрәчәгемдер, шулай язгандыр»,— дип юашлана. Үзләре салган өйдә Гомәр белән Җиһан бик матур гомер итәләр, бер кыз, өч малай үстерәләр.

Шул риваятьне сөйләгәч, Ризван карт һич уйламаганда ачылып, яктырып китте.

— Менә рәхмәт, менә монысы өчен рәхмәт. Үткәннәрне шулай истә тотарга кирәк. Һәр кош-корт, җәнлекнең койрыгы була. Төлке, бүре, карга, күркә, чыпчыкның да койрыгы бар. Шуларны койрыксыз итеп күз алдына китер әле менә. Бик ямьсез хәл килеп чыгар иде. Кешенең көче — аның үткәннәрне хәтерендә тотуы. Үткәндәгеләрне оныткан кеше койрыксыз җәнлек кебек ямьсез була. Кайбер комплекс фермаларда симертелә торган ат, тана, үгезләрнең койрыгын төптән үк кисәләр. Нигә дип беләсең? Көндәмләнә, тизрәк симерә икән ул койрыксыз калгач. Гомәр бабаң турындагы риваятьне сөйләп син, улым, паспортыңны чыгарып күрсәткәннән дә артык булдың. Менә хәзер мин сиңа ышанам. Күңелеңдә саклангап бу матур риваять синең алдагы тормышыңда бик күп ваклыклардан, түбәнлекләрдән саклап калыр.

Ризван картның әйткәннәре дөрескә чыкты. Вакыты житкәч сакалмыегы да үсте. Кырынып кына өлгер хәзер. Буй-сыны да кеше арасында ким-хур булырлык түгел. Ә шуны берәрсе баштарак әйткән булса соң! Тормышта әйбер түгел, кирәкле кешеләр җитмәсә кыен икән.

Габделхак, сүнгән тәмәкесен мич авызына ташлап, янадан эшенә утырды. Моторны җыеп бетереп токка тоташтырып карыйсы килә иде аның. Өйләнерме, юкмы?

— Иске бер электр двигателенең әйләнү-әйләнмәве шулай бик мөһимме синең өчен?

— Ни дисәң дә үзем ясаган әйбер бит. Ток тоташтыргач, җансыз тимер кисәгенең выжылдап әйләнә алуы могҗиза ул бер уйласаң.

— Могҗиза, имеш! Бүтән бер эше булмаса, эт үзенең арт санын яларга тотына. Син дә шул. Бу электр двигателенең әйләнүе кемгә, нәрсәгә кирәк?

— Берничә көннән укулар башлана. Балаларны шушы станокта тимер тишәргә өйрәтәм.

— Хәятнең: «Сезнең эшләгән бөтен эшегез атом бомбаларын камилләштерүгә кайтып кала»,— дигән сүзләрен хәтерлисеңме?

— Мин балаларда матурлык тойгысы тәрбияләргә телим.

— Кирәкмәс әйбер матур булды ни, ямьсез булды ни? Син нәрсәдер үзеңнән үзең яшерергә маташасың. Акылның хәйләкәр дә була алуын беләм мин. Логик таянычын югалтса, ул хәйлә, мәкер, алдашу юлына баса. Син бит рәссам. Синең урының монда түгел. Син башкалар әле әйтергә генә җыенган сүзне әйтергә тиеш. Хәят турындагы картинаны, «Хәвефкә тарыган планетаның бер гүзәле» картинасын нигә эшләп бетермисең?..

— Белмим, тотына алмыйм. Минем колагымда сабый бала елавы. Мин инде утыз икедә. Җитлеккән ир.

— Тәк, тәк. Әһә! Өйләнәсең килә?

— Ә бу көлкеме?

— Нишләп? Алай димим. Бу табигый. Соң шуннан?..

Мастерскойга кемдер кереп киләме, тышкы якта аяк тавышлары ишетелде. Бераздан ишек ачылып, икесе дә эшләпә кигән ике карт: роно мөдире Гомәр Садриевич белән мәктәп директоры Курамшин килеп керделәр. Роно мөдире күзләре белән мастерской эчен айкаган хәлдә, Габделхакка якынрак килде. Мастерской эчендәге станок, верстакларга караган кебек кенә карап алып кул биреп күреште. Курамшин белән Габделхак иртән бер күрешкән иделәр инде. Начальниклар түргә узып, укучылар ясаган төрле механизм, макет, эш кораллары саклана торган шкафны карый башладылар. Гомәр Садриевич чүкеч, кечкенә балта сапларының җиренә җиткезеп шомартылган, төртке-төртке яндырып орнамент бизәкләр төшерелгән һәм үтә күренмәле лак белән ялтыратылган булуына игътибар итте. Сувенир кибетенә куйсаң да кимхур булырлык түгел. Мастерской идәне күптән түгел генә юып чыгарылганмы, чип-чиста һәм аннан яз исе килеп тора иде. Гомумән, мастерской эчендәге һәр әйбердә югары зәвык сиземләнә, кимендә йөз, мең елларга исәпләнелгән, бу заман өчен бераз ятрак тынычлык хөкем сөрә иде. Роно мөдире, моның серенә төшенергә теләгәндәй, электр двигателен җыеп бетереп аңа ток ялгап кайнашкан Габделхакка берничә мәртәбә карап-карап алды. Егетнең өстендә гади тукымадан тегелгән шакмаклы күлмәк, тез башлары агара төшкән джинси чалбар. Дулкынланып кабарып торучы коңгырт-кара чәчләре колак тирәләрен каплап киткән. Җиңнәре бераз сызганулы. Беркемдә, бернәрсәдә гаме юк, үз эше белән мәшгуль. Гомәр Садриевич яшьлеген сагынуга охшаган, көнләшүгә дә тартым бер нәрсә тойды. Арсландай таза, яшь егетнең аулак, караңгы бер авылда менә шулай өнсез-гамьсез ятуы аңа сәер кебек тоела башлады. Мастерскойны ник болай гөл кебек итеп җиһазлаган? Ирмәттән өй дә сатып алган, үз өе белән тора җитмәсә. Өен, әлбәттә, хатыны исән чагында алгандыр. Җитмәсә, Курамшин аны үз урыныма калдырам дип сөйләнә. Гаҗәп, гаҗәп!

Шул чак өстәл өстендәге электр двигателе тоныч кына гүләп әйләнә башлады. Курамшин ашыга төшеп шунда китте.

— Булырлыкмы?— диде ул.

Габделхак токны өзеп, корым, майга буялган кулларын чүпрәккә сөртте. Йөзендә оялчанрак елмаю.

— Бик иске типтагы мотор, мондыйлар хәзер эшләп чыгарылмый икән,— дип аңлатты Курамшин роно мөдиренә. — Эзләп-эзләп тә таба алмаган идек, менә Габделхак үзе урады.

Гомәр Садриевич, тавышын күтәрә төшеп, рәсмирәк тонда:

— Без сине, Габделхак, шушы Ирмәт мәктәбенә завуч итеп билгеләргә диебрәк тора идек. Син үзең моңа ничек карыйсың?— дип сорады.

Габделхак бер мәлгә башын иебрәк торды. Аннары аның ирен читенә сизелер-сизелмәс сәер елмаю кунды.

— Көтелмәгәнрәк тәкъдим, шулаймы?— диде роно мөдире. — Ничек, эшли алырсыңмы?

— Мәктәптә әле икенче елым гына. Мәктәп тормышын белмим, завуч эшен бигрәк тә...

Мастерскойдан чыккач, Гомәр Садриевич берара сүзсез барды. Аннары зарлангандай:

— Аңа шундый эш тәкъдим итеп торалар, ә ул! Кара әле, Сабир, җирнең кайсы катламыннан казып чыгардың бу халыкны?

Курамшинның кәефе күтәренке иде Габделхакның шулаерак җавап бирәсен башта ук сизеп, белеп торса да, чыннан да шулай килеп чыгуы, үзенең ялгышмавына тагы бер кат ышану күңелле иде аңа.

— Ә ул чирәм җирдә дә, БАМда да эшләгән. Элегрәк өч ел Себердә дә яшәгән. Җиде-сигез ел читтә йөргән ул.

— Тукталe, ә ничә яшьтә булырга тиеш ул алайса?

— Утыз икедә.

— Ә мин армиядән генә кайткан, егермеләр тирәсендә генә дип торам тагы.

— Акыл утырткан кеше инде ул. Баштагы мәлләрне мин дә, китәр бу, тормас, дип уйлаган идем. Былтыр укытучылар көнен, яңа мәктәп тә булгач, табын әзерләп, мул итеп үткәргән идек бит. Шунда Габделхак кыюланып китте. Аннары бәхетле чагы иде әле аның. Яңа өйләнешкән чаклары. Син аның хатынын, Хәятне күрмәдең. Ай, чибәр иде! Ай, пар килгәннәр иде! Да-а-а... Шунда Габделхак тост әйтеп, шигырь сыман нәрсә сөйләп ташлады. Шигырь дисәң, шигырь дә түгел, ну шулай да сүзе сүзгә хәтердә калган. Менә тыңла әле, нигә моннан китмәячәген шуннан аңларсың.

Төньяк кешеләренең ни өчен кырыс, сабыр табигатьле булуын аңлыйм мин, чөнки Себер тайгаларының шавын тыңлаганым бар. Рәсүл Гамзатов горурлыгын таныйм, чөнки Кавказ тауларында йөреп, тау елгаларыдай кызу канлы, әмма гадел һәм гаять кунакчыл кешеләрне күргәнем бар. Ә минем туган ягым Идел-Урал арасы. Төньяктагы кебек салкын, көньяктагыча эссе түгел, урта һава. Тукай җырлагандагыча, җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява. Сагындырып кына килә язлары, күкрәп үтә җәйләре. Ә көзләре соң! Алтын көзләре! Туган ягыбызның һәрвакыт үзгәреп, яңарып торучан матурлыгына житәме соң! Якташларым белән, язлар кебек дәртле, җәйләр кебек эшчән, көзләр кебек юмарт, кышлар кебек саф күңелле якташларым белән авыз тутырып бер сөйләшеп утырулары үзе бер гомер икәнне аңлап кайттым мин...

Роно мөдире, мәктәптән кул сузымлык ераклыкта гына алтынланып утырган урманны, каргалары шау-гөр килеп торган авылны ничектер икенче күз белән күрде. Кайдадыр күңел түрендә үк күптән онытылган бер тойгы кузгалып куйды.

*
* *

Габделхак, мастерскойны биклэп, кайтырга чыкты. Ишегалды уртасына житкэндэрэк мэктэп бинасыннан Рокыя Шиһаповна һэм тагы ниндидер хатын-кыз чыкты. Рокыя Шиһаповна баш кагып Габделхак белэн исэнлэшкэндэй итте. Тегесенең күз карашы Габделхакның йөзеннэн шуып кына узды. Яшькелт соры зур-зур күзлэр, кара каш, чегэн хатын-кызларына тартым кара-тут йөзле. Габделхактан ун-унбиш адым алда бара башладылар. Бу очрашу, бу караш, ун-унбиш адымлык бу ара Даниянең төгэл исэбе белэн эшлэнүен Габделхак, элбэттэ, белми иде. Юан, таза гэүдэле Рокыя янында озын итэкле күлмэк кигэн Даниянең нэзек, зифа буй-сыны аеруча отышлы булып күзгэ ташлана. Габделхак телэсэ-телэмэсэ дэ аларның артыннан барырга һэм элеге чибэр затның ымсындырулы йөреш-хэрэкэтен күрергэ мэжбүр. Тиктомалдан адымнарын кызулатып узып китэ алмый бит инде. Болай тагылып бару да уңайсызга эйлэнэ бара. Урамның чирэме тапталмаган, киңрэк төшендэ Каюм карт белэн авыр гэүдэле Кэрим бура бурап ята иде. Быел алтынчы класста укыячак берничэ малай шул тирэдэ йомычка жыеп кайнашалар. Аяклары Габделхакны бура бураучылар янына алып китте.

— Армый эшлэгез!

— Э, Габделхак улым, син икэнсең. Рэхмэт, рэхмэт. Ял итеп кит безнең янда.

Бераз тиле-милерэк Кэрим, каезлый торган бүрэнэгэ балтасын чабып куйды да, Габделхак янына килеп аны татарча көрэш ысулы белэн билennэн элэктереп алды. Лэкин бөтерелеп китеп ни арададыр үзе Габделхакның кочагына килеп керде. Габделхак аны күтэреп, аякларын жирдэн аерды.

— Дөрес түгел. Бу теге, ни, приум. Самбы гына.

Каюм карт тешсез авызын күтэреп бер көлде дэ:

— Приум булмагае чуртым булсын, ситнирлы гэүдэңне күтэреп алалгач булган инде,— диде. Йомычка жыючы малайлар да укытучы абыйлары яклы булып теш агартып алдылар. Кире Кэримнең моңа жене кузгалды.

— Давай, чисны булсын. Кул көрэштерик,— дип, дүрт-биш нирга салынган бураның эчке ягына сикереп төште. Терсэген бүрэнэгэ терэп, яман куэтле кулының бармакларын тырпайтып куйды. Карап торучылар, Габделхак монысына бармас, Кэримнең жиңэсе көн кебек, дип уйлаганнар иде. Э ул бураның бу ягыннан Кэрим каршына барды да, аяк астындагы йомычкаларын эшергэлэп аякларын аерып басты, терсэген бүрэнэгэ терэп, кызларныкы кебек озынча нэзек бармаклы ак кулын Кэримнең учына салды. Кэрим моны минуты-секунды белэн бөгеп куяр сыман иде. Гел уйламаганча килеп чыкты. Башта чыннан да Кэрим кысрыклады, Габделхак карышып кына торды. Аннары Габделхак:

— Я, булдымы? Хэзер мин алдырып карыйм, чыдасаң чыда,— диде дэ бернинди шэфкать-аяу күрсэтмичэ Кэримнең кулын бүрэнэ өстенэ сыгып төшерде.

Кэрим кызарынып-бүртенеп чыккан иде. Жиңелүен танып башын чайкап куйды, аннары көчэнүдэн соң калтыраныбрак калган бармаклары белэн папирус алып кабызды. Каюм карт нидэндер күңелсезлэнеп:

— Шулай, диң, э? Кире Кэримгэ дэ указ табылды диң. Аракы чөмереп, тэмэке суырып көпшэклэнгэнсең шул. Да-а-а. Габделхак чандыр булса да, буыны нык, ызначыт, сеңер таза.

Балта осталары янында беркадэр тегене-моны сөйлэнгэлэп торганнан соң, Габделхак өенэ кайтып китте. Аның йорты, ихатасы — маймыч кына үрчерлек кечкенэ елганың борылганрак төшендэ. Су бакча

артыннан да, бакча кырыйлап килеп өе янынннан да агып уза. Бакчасы унбиш сутый. Яз көне кеше белән бер вакытта бәрәңге утыртты. Үзенен классы укучылары: «Абый, бәрәңгенне утыртышыйк инде!»— дип теңкәсенә тиеп беттеләр. Үзе казып, үзе күзәнәк салып кайнашуын күреп торган күршеләре дә ярдәм итәселәре килеп кергәләделәр. Габделхак аларга күрәген дә, чиләген дә бирмәде. Аның үзенең кулы эшкә ятып тора. Эштән тәм табып эшли. Эш булса Габделхак мәңге яшәргә дә риза булыр, һич авырыксынмас, күңеле кайтмас иде.

Сатып алганда бакча, ишегалларын алабута, кычыткан баскан, йодрык-йодрык зәңгәр башлы шайтан таяклары котырып үскән иде. Арт бакча белән ишегалды арасында башваткыч сыман керсәң чыгып булмаслык бүлемтек-бүлемтек кетәк, сарай, абзар, киртә-коймаларның исәбе-хисабы юк иде. Бөтенесен кисеп, турап утын итеп өеп куйды. Хәзер ихатасы тап-такыр. Такта өйалды, дүрт почмаклы өе белән, соныннан үзе төзегән җыйнак кына утын сарае гына торып калды. Иркен ишегалдын чирәм каплап килә. Хәят утырткан чәчкә түтәлләре быел Габделхакның күңелен сыкратып-җылытып шау чәчәк атты. Хәятне үзенең туган авылына алып кайтып күмделәр. Ни дисәң дә Хәятнең җаны Ирмәткә иялешеп җитмәгән иде бит әле.

Габделхак, форма өчен генә эленгән йозакны ачып, өйгә керде. Түрдә үзе ясаган агач өстәл, тәрәзә буенда караватт. Бүлмә эче ягында аш-су әзерләр өчен киң генә сәке. Мичне дә Габделхак биш коелы итеп үзе чыгарган иде. Биш коелы мичнең җылысы озак саклана. Өйдә, мөгаен, бер кирәкмәс, артык әйбер юктыр. Кыргый кош-корт, җәнлекләр өн, ояларына беркайчан артык әйбер ташымыйлар, купшылап бизәмиләр, флаг-мазар элмиләр. Һәм аңа карап кына сандугач — сандугач, карлыгач — карлыгач, бөркет — бөркет булудан туктыймы. Кешене дә әйбер, байлык кеше итми. Кеше икән инде, ул болай да кеше.

Габделхак коштабак алып бакчага чыкты. Күрәк белән бер төп бәрәңге казып алды. Ике кыяр, берничә помидор, яшел суган өзде. Бакча кырыендагы инешкә басма ясап куйган иде, шунда төшеп яшелчәләрне юып, бәрәңгесен шунда су буенда ук әрчеп яңадан өйгә керде. Өйалды базын ачып, туң май салынган өч литрлы банканы бавыннан тартып чыгарды. Ул баз гына да түгел, тирән таш кое. Төбенә дә таш җәелгән һәм сап-салкын су чыгып тора. Бер бауны тартса тозлаган ит салынган банка чыга, икенчесен тартса — карлыган вареньесы, өченчесен тартса — башкасы. Төшеп-менеп йөрисе түгел. Җәен-кышын өзлексез эшли торган менә дигән суыткыч. Акча да түләмисең, дымбырдамый да.

Габделхак, бер кисәк туң май китеп алып, банканы кире базга төшерде. Өйгә кереп электр плитәсенә таба куйды. Май эреп кызган арада бәрәңге турады. Бәрәңгене ул башта каплап парландырып пешерә, аннары өстен ачып тоз сибеп бераз гына кызартып ала. Суганның исә яшелен дә, башлысын да чи килеш ашау файдалы. Бәрәңге пешкән чакта Габделхак суга барып килде. Кызарып пешеп чыккан бәрәңгене алуга кайнарланып җиткән плитәгә чишмә суы белән чәйнек куйды. Ашказаны белән авырган кеше ризыкны үзе пешереп, үзе әзерләп ашаса бернинди дару кирәкми. Үзең әзерләгәндә ашказаны нинди рәк ризык эшкәртәсен алдан ук белеп, шуңа әзерләнеп тора да җиңел үзләштерә, шуның белән үзен үзе дәвалый. Кыргый җәнлек тә бит корбанын әзерләп, куып тотканда ук ашказаны кирәкле сокларын инде бүлеп чыгара башлаган була.

Табадагы бәрәңгене ашап бетергәч, Габделхак тоз сибеп яшел суган белән берничә помидор ашады. Аннары шикәрсез генә чәй эчте. Тозлы ризык арты баллы әйбер кабарга ярамый. Язва дигән нәрсә, аның уенча, тоз белән баллыны бутап ашаганнан килеп чыга.

Савыт-сабаны юып, өстәлне җыештыргач Габделхак караватка сузылып ятты. Колхоз радиосын борып сөйләтмәкче булган иде дә, кире уйлады.

— Карале, бүген сиңа завуч эшен тәкъдим иттеләр бит.

— Ә миңа нәрсәгә ул?

— Ансы да дөрес. Ә теге, ни, алар мастерскойга кергәндә генә «Беркайда эшләмәсәм»... дип нидер уйлый башлаган идең...

— Соң! Беркайда эшләмәсәм, кем миңа кияүгә чыксын? Рәсем, картина ясауны беркем җитди эш итеп карамый.

— Я, я! Төшенкелеккә бирелмә. Әлегә эшли алмыйсың, кулың бармый икән, ярар, торып торсын.

— Алай гына түгел кебек. Күңелдә нидер төенләнеп маташа.

— Ирмәттә һәр нәрсә Хәятне хәтерләтә. Шуңа авыр сиңа. Китәсеңме соң әллә берәр яры?

— Рәхмәт. Үземнән качып булмасын гына аңлый алам инде. Беркайда да әллә нәрсә юк.

— Күп еллар юл йөреп, күп хәрәкәт итәргә күнеккән организмың тыныч, гадәти яшәүгә күнегеп җитә алмый. Бүген көне буе мастерскойда утырып зарыктың. Әле вакыт бар, урманда йөреп, йөгереп кайт булмаса.

Капка ачылган тавыш ишетеп, Габделхак торып утырды. Бер әби кереп килә. Таныш түгел. Габделхак аның шушы авылныкы булырга тиешлеген генә чамалый алды. Карчык-корчык аңардан үтүк, сәгать, плитә, тегү машинасы ише нәрсәләрен төзәттергәлиләр. Габделхак акча алмый. Карчыклар аның хезмәтен бөтенләй буш итүне килештермичә, ачуланып-ачуланып бер-ике йомырка, банка белән сөт, катык калдырып чыгалар. «Шуның ише йомыш белән йөрүчедер»,— дип уйлады Габделхак.

Әби башта ишекне ачып:

— Өйдәләрме?— дип сорады. Идәнгә күз төшереп алгач, галушын салып өйгә оекчан гына керде.— Исән генә торасыңмы, бәбкәм? Ярар. Йортка дога кылыйк.

Әби мич буендагы урындыкка утырып кулындагы төргәген алдына куйды, күзләрен йомып, онытылып дога укыды.

— Ходай чир, зәхмәт, бәла-казалардан сакласын,— дип амин тотты.

— Тиле сүзен тиз сөйләр, ди, улым, сиңа оекбаш бәйләп китергән идем. Юка наски белән генә йөрисең. Хәзер җир суына. Аягыңа җылы киеп йөр. Аяктан тигән суык үпкәгә менә ул.

Әби баш яулыгына ураган оекбашны сүтеп Габделхакка сузды. Моңсына Габделхак, чыннан да, кыенсына калды.

— Ярарга тиеш. Гәүдәсе зур, аягы да зурдыр дип, зур итеп бәйләдем.

— Рәхмәт, әби.

— Этенеп-төртенеп торган булып күңелемне рәнҗетмәвең өчен үзеңә рәхмәт, бала. Сугыштан кайтмаган Әскатемә охшатам. Шул гына. Башка берни түгел. Ярар, мин кузгалыйм әле.

— Әби, чәй эчмисеңме? Кайнап кына чыккан.

— И-и, балакаем, тәмле телең үзе сый. Ярар, сау бул. Ходай тәгалә тәүфыйкъ, бәхет бирсен.

Габделхак әбине озата чыкты. Аннары бакча яклатып урман юлына төште. Башта атлап кына барды, тора-бара кызулап, болан шикелле эре-эре юыртып, йөгереп китте. Бүген ул туктый алмый озак йөгерде. Йөгерде-йөгерде дә көтмәгәндә урман эченнән ачык урынга килеп чыкты. Авыл кырыендагы калкулык өсте икән. Хәят белән кайчандыр шунда килеп чыккан иделәр. Ирмәтне беренче мәртәбә шушыннан күрделәр. Габделхак җиргә утырды. Бите буйлап яшь ага иде.

Йөзендә үзгәреш юк, йөзе тыныч та кебек, ә кайнар күз яшьләре актылар да актылар. Аңласа аны Хәят кына аңлый ала иде, бәхетле итсә Хәят кына бәхетле итә ала иде.

*
* *

Дания хәзер буфетчы. Аның эше күп түгел. Ул еш кына укытучылар бүлмәсендә Габделхак белән икәүдән-икәү кала. Дания аңардан буфет өчен кирәкле вак-төяк эш эшләвен үтенә, ошатмаган булып, болайрак кирәк иде, дип орынгалап йөри. Бөтенләй түгелеп чәчелә дә алмый, беренче адымны ир-ат ясарга тиеш бит инде. Башта Габделхакның йомшак якларын өйрәнеп, гадәтенчә салкын акыл белән алдын-артын уйлабрак эш итсә, Дания Габделхакка күптән ачкыч тапкан булыр иде, әлбәттә. Ләкин ул беренче күрүдә үк яшь, чибәр, таза егеткә гашыйк булган иде, үзе башын югалткан иде.

Шушы хәлдә берничә ай үтте. Бер-берсенә гашыйк икәнлекләрен үзләре белмәсә дә, башкалар өчен инде бу сер түгел иде. Бу хәлләрдән иң кайгыга калган кеше мәктәп директоры Сабир ага Курамшин булды. Гомергә кеше белән эшләгән, шушы эштә чәч агарткан тәҗрибәле педагогка Даниянең мажара эзләп йөрүче җиңел карашлы буш хатын икәнен аңлау өчен берничә атна җитте. Ләкин егетне бу бәладән йолып калырдай һичбер чара юк. Күзен ачыйм дип, ачыктан-ачык сөйләшеп карыйм дисә, Габделхакны киресенчә аждаһа авызына этеп кертүе бар. Ул бит әлегә Даниянең ниятен белми йөри, белсә үзе дә Даниягә карата тыныч түгел кебек. Авылдан китсен өчен Даниянеэшеннән алу мәсьәләсен дә тиктомалдан кузгатып булмый. Сәбәп юк. Дания «лып» итеп нәкъ үз урынына килеп утырган иде. Ә менә укучылар Даниянеяратмадылар. Габделхакка «гашыйк» булган җиденче, сигезенче класс кызлары хәтта аны дошман күрәләр, Даниянең Габделхак тирәсендә сырпалануын иреннәрен кысып, ачулы караш белән күзәтәләр. Малайлар исә, Курамшин кебек үк, Габделхакның Ирмәттән китеп баруыннан шикләнәләр. Маңгаена язылмаса да авыл халкы кемнең кем икәнен аяк атлавыннан ук чамалый бит ул. Авыл халкы да Даниянеүз итмәде.

Бер көнне ут алгандарак Габделхакның өенә Әшрәф килеп керде. Габделхак дәрес планнары төзергә утырган иде.

— Син миңе кума, Габделхак. Исерек бу димә. Мин сине яратам. Хатынга да әйттем. Тимәгез мин әйтәм Габделхакка! Нимиеш права дидем. Яңа гына икесен дә пыр туздырдым әле. Минем хатынны беләсең инде, Рокыя. Яңа килгән теге буфетчыгыз белән болар шу-шу, ши-ши! Мин йоклаган булып ятам. Әлек тә сизеп йөри идем. Ул хатын сине...— Әшрәф тешләрен кысып кулын өскә күтәрде дә нидер эләктергән кебек бармакларын әкрен генә йомарлап куйды.— Ул хатын сине шуның өчен килгән безнең авылга. Рокыя хат язган булган. Синең турда инде. Ә теге елан...— Әшрәф озак кына сүзсез утырды да айнып киткәндәй булып кинәт кенә:— Аң бул!— дип Габделхакка күтәрелеп карады. Шунда ук елмаеп җибәреп:— Без сиңа кызның менә дигәнен табабыз. Әйе!

Әшрәф тагын нәрсәләрдер сөйләнде-сөйләнде дә ава-түнә чыгып китте.

Шуның белән ул вакыйгаларның табигый агышын тәмам чыгырыннан чыгарды. Икенче көнне Габделхак Даниягә кызыксыныбрак карап алган иде, Даниягә шул җитә калды. Әшрәфнең дулап чыгып китеп Габделхак янына баруын Дания белә иде. Хәзер инде озакка сузудан файда юк, соңгы чарага барырга мәҗбүр иде Дания. Аңа нәрсә югалтасы! Караңгы төшеп кеше аягы басылгач, тыштан күзгә бәрелмәстәй төссезрәк киемнәрен киеп Габделхак өенә китте...

*
* *

Туйны зурдан кубып ясамаска булдылар. Үз-тирә кешеләр белән кечерәк мәҗлес үткәреп алдылар да Даниянең әйбер-чемоданнарын мәктәп атына төяп, Габделхак йортына килен төшерделәр. Дания ягыннан килүче кеше булмады. Габделхакның әти-әнисе, энесе берничә көн кунак булып киттеләр. Шуның белән шау-шу басылды, гадәти яшәеш эзенә төште.

Ир белән хатынның мөнәсәбәтләре тыныч, икесе дә үзләрен бәхетле тоя иделәр. Тормыш үз агымында. Хатын-кызга сусаган Габделхак көннән-көн ешрак елмайды. Дания исә булдыра алганча Габделхакның теләгенә каршы килмәскә тырыша. Хатын-кызның шундый чакта каршы килеп маташуы нинди генә ирнең дә җен ачуларын кузгатуын, ара бозылуга китерүен Дания яхшы аңлый иде. Хатынының әллә никадәрле кимчелекләренә ир кеше күз йомарга мөмкин, ләкин монысына — һичкайчан. Хатын-кызның шуны белмәве аркасында күпме гаилә таркала.

Дания моны аңлый, белә, ләкин Дания белән Габделхак баштан ук аерылышырга дучар ителгән иделәр. Дания мөстәкыйльлеккә, үзенә үзе хуҗа булырга күнеккән. Ул барыбер азакка кадәр түземле, сабыр ир хатыны була алмаячак.

Яңа еллар да үтеп китте. Ел азагында кеше үзен вокзалда сымаграк сизә, яңа елның килүен поезд көткән кебек көтә. Эшлисе эшләре, уйлаган уйлары да «аннары» дигәнгәрәк кайтып кала. Яңа ел үткәч, һәркем теләсә дә, теләмәсә дә алда тулы бер ел барлыгын күз алдына китерә һәм алга планнар кора башлый.

— Габделхак, ниндирәк шәһәргә күчәрбез икән? Зуррагына инде, әйеме? Яшәсәң, шәһәрнең зурысында яшәргә ул.

— Я авылның кечкенәсендә. Без менә кечкенә авылда яшибез.

— И, шушы кетәклектә яшәүне яшәү дисәң!

— Иркенрәк итеп яңа өй салырбыз. Син әле минем нинди өй сала алуымны белмисең. Уңайлы итеп. Бөтенесен үзем эшләячәкмен. Хәзер үк түгел түлке. Бер-ике елдан. Әлегә бала туса да, бер бала белән генә бу өйгә дә сыеп була.

— И! Бер шаярмыйча гына сөйләшә алмыйсың.

Дания моны, чыннан да, Габделхакның шаяртуы гына дип уйлады. Гомергә шушы караңгы авылда яшәүне ул ялгыш та башына китерми иде.

— Әй, шаяруың шаяру түгел. Башымны катырдың инде. Телевизор да юк ичмасам. Күчкәндә уңайсыз булыр, шәһәргә урнашкач алырбыз дибрәк йөри идем, алмый да булмас, пажалый.

— Моңарчы, әйбер алыйк дип тинтерәтмәвеңә, кибеттән юк-бар нәрсә ташымавыңа эчтән сөенеп йөри идем әле, Дания. Берүк бозыла күрмә. Радио бар, кирәк нәрсәләрнең барын әйтеп тора. Ә телевизор өйнең һавасын боза, өй һавасын ионлаштыра бит ул. Киноны кеше белән бергә утырып, клубта зур экраннан карарга аны. Форточка хәтле нәрсәгә төртелеп утыруның ни кызыгы бар?

— Кызыгы! Кызыгы! Тормышның кызыгын аңлаган кебек. Сизеп торам, син чыннан да гомергә шушы авылда калырга ниятлисең бит. Фәлән сум зарплата беләнме?!

— Әйе, Дания, гомергә шушы нигездә яшәячәкбез. Шәһәрнең чиратын, этеш-төртешен яратмыйм мин. Дүрт стена арасына кысылып, әзергә-бәзер шәһәр тормышында яши алмыйм. Берничек тә яши алмыйм. Монысы бер. Икенчедән, син миңа тавышыңны күтәреп сөйләмә. Кем дип беләсең син үзеңне ул кадәр? Өченчедән, күп акча белән нишләмәкче буласың?

*
* *

Дания гомере үтүдән курка иде. Хәзер утызда. Тагы унбиш елдан беркем аңа ымсынып карамаячак. Дөньяда яшәүнең дә кызыгы калмаячак. Елдан-ел яңа сугыш кораллары арта барган бу дөньяда караңгы бер авылда әз-мәз акча эшләп, кызганып гомер итәргәме? Тот капчыгыңны! Балага да узып куйды бит әле җитмәсә. Бу мәхшәр дөньяда тагын бер бәхетсез җан арттырыр хәле юк әле. Дания Габделхакны булган-булмаган йомышлар белән Тугайга әниләре янына кайтарып җибәрде. Хатын-кыз тиктомалдан елмая, назлана башладымы, хәерлегә түгел инде...

Өйдә үзе генә калгач, Дания зур гына арыш капчыгы табып, өйдәге авыррак әйберләрне шуңа тутыра башлады. Үтүк, плитә, балта, чүкеч. Шуннан ары әйбер таба алмады Габделхакның өеннән. Ул әйберләрне кире урыннарына куеп, ишегалдыннан таш ташырга тотынды...

*
* *

Габделхак өенә кайтып килешли урамдагы кешеләрнең үзенә ничектер башкачарак карауларын сизде. Тиз-тиз исәнләшәләр дә, күзенә карамаска тырышып, ашыгып, китеп баралар. Әллә кайдагылары исә аның ягына озаклап-озаклап карап торалар. Ишегалдына керде. Ишекнең бикле булуын күреп: «Дания мәктәптә, күрәсең»,— дип уйлады. Өй эчендәге әйберләр ничектер барысы да үз урыннарыннан бераз күчкән кебек иде. Караватастыннан чыгыбрак торган капчыкны күреп, аны алып карады. Утын сараенда ята торган әйбер. Дания нишләде икән аның белән? Капчык балчыкка буялган. Идәндә дә балчык кисәкләре. Габделхак аптырап ишегалдына чыкты. Утын сараена кереп карады. Барыбер берни аңлый алмады. Ишек төбендәге ташларның барысы да урыннарыннан кузгатылган. Шул вакыт күрше Гыйльмениса апа керде.

— Шулаерак килеп чыкты, үскәнем. Бик борчылма инде, үтәр әле. Хатын-кыз мачы кебек яшәүчән ул. Хатыныңны хәл эчендә скурый белән бульниска алып киттеләр. Уйламаган эшләр булып куя шул кайчак.

«Скурый», «бульнис». Димәк, кире Әлмәткә барырга кирәк. Габделхак шуны гына аңлый алды. Асфальт юлга кадәр өч чакрым җәяү чыгасы бит әле. Авыл башындарак аны бер егет мотоцикл белән куып житте. Үзе үк туктап Габделхакны артына утыртып алып китте. Әлмәттә Габделхак башта кайсы больницага кагылырга белмичә аптырап калды. Нинди чир белән алып киттеләр икән? Аппендицитмы? Йөрәкме, башкасымы? Микрорайондагы больницадан Данияне таба алмады. Шунда ул тиз ярдәм машиналарын чакырту пунктына сугылырга кирәклеген чамалап алды. Кичә кич Ирмәт авылыннан китерелгән авыруны кайсы больницага илтүләрен анда белергә тиешләр бит. Диспетчер хатын Габделхак әйткән исем-фамилияне исемлектән карап төштетөште дә, бармагы бер турда төртелеп, шул турдагы су буе язуны укып чыккач, Габделхакка күтәрелеп:

— Кеме буласыз?— дип сорады.

— Ире.

— Паспортыңны, я язылышу кәгазен алып килдеңме?

Язылышу кәгазе юк иде. Икесе дә, моны кирәкмәс нәрсәгә санап, рәсми язылышмаган иделәр. Паспортын сузды.

— Сезнең хатыныгыз Таһирова Хәят ич.

Телефон шалтырады. Диспетчер трубканы колагында тоткан килеш ниләрдер язып алды.

— Я, нәрсә?
— Җәләева Данияне кайсы больницага салдыгыз?
— Моны бары тик иренә, яки якын туган тиешле кешесенә генә әйтә алам.
— Шул кадәрле үк сер түгелдер бит инде.
— Ярамый, төрле хәлләр килеп чыгарга мөмкин. Бүген дөньяга килмәгәнсездер. Аңларга тиешсез.
Габделхак берни аңламады. Больница тәртипләре аның өчен үзенә бертөрле башка мохит иде. Аның үзенең әле бер дә врач, больница кулына калганы юк. Берәм-берәм шәһәрнең бөтен больницаларын да йөреп чыгудан башка чара калмады. Троллейбуста барганда аңа кайчандыр тулай торакта бергә яшәгән токарь егет Шамил очрады. Шамилгә нәрсә, аның бер кайгысы юк. Шау-гөр килеп исәнләште, сорашырга тотынды. Габделхак:
— Хатынны югалттым әле, малай, скорый белән алып киткәннәр,— дип сөйли башлагач кына:
— Туктале, хәзер,— дип, аны бер тукталышта троллейбустан тартып төшерде.— Күрмисеңмени, бөтенесе колакларын торгызды,— диде ул.— Я, хәзер сөйлә.
Габделхак хәлне тәртибе белән сөйләп биргәч, Шамил:
— Әһә, димәк, ул гинекологическида,— диде.— Кайда икәнен беләсеңме? Өстә ул, парк кырыенда.
— Ә анда нинди авырулар?
Шамил шаркылдап көлеп җибәрде. Аннары аңлатып бирде.
— Ни, малай, элек тә аптырый идем синең кыргыйлыгыңа. Кыйлана гына дип тә уйлыйдырыем. Чыннан да әкәмәт кеше икәнсең, валлаһи. Җәяү генә бар. Моннан якын ул.
Габделхакны ишектән-ишеккә әллә ни гомер тинтерәтеп йөрттеләр. Тагын паспортын карадылар. Барыбер берни белә алмый кайтып китте. Хәзер ул эшнең нәрсәдә икәнен бераз төшенеп килә иде инде. «Әллә нинди дәүләт сере дип уйларсың!»— диде ачуы килеп.
Ике көннән Дания үз аягы белән кайтып керде. Кәгазь кебек ап-ак, хәлсез. Габделхак бер сүз әйтмәде. Бөтен эшне үзе эшләп, Данияне авыруны караган кебек карады. Ләкин хәзер аның күңелендә ярату юк, боларны ул акыл белән генә эшли иде. Дания үзенчә, Габделхакны сындырдым дип аңлады һәм берничә атнадан терелеп элекке хәленә кайту белән «тәрбия» эшен дәвам итәргә булды.
— Габделхак, син шәһәрдә яшәүнең уңайлыкларын яшәп карамаганга гына белмисең. Газы, суы кергән, канализациясе чыгып киткән. Комфорт! Кино-театры, кызыклы кешеләр. Шундый ир белән яшәвемне беркем күрмәгәч, миңа ни кызык?! Аннары урта мәктәбе, югары уку йортлары. Монда бит мәктәп тә сигезьеллык кына. Балаларны кайда укытырбыз?
— Сигез елы да бик житкән,— диде Габделхак сүрән генә. Хәзер инде ул Дания белән үзе арасындагы аерманы күрә башлаган, Данияне нәрсәгә булса да ышандыра алырмын дип өмет итми иде. Хәят кына ул, Габделхакның: «Әйбер өчен яшәмәскә, өйгә яшәү өчен турыдан-туры кирәге булмаган бер әйбер кертмәскә, мал колы булмаска»,— дигән принцибына тиз күнде, хәтта йөрәге белән үк кабул итте. Алар үзләрен кыш көне дә яшел чирәмгә басып йөргән кебек, табигать балалары итеп тоя иделәр. Башкаларның үлеп-егылып баерга тырышулары Габделхак белән Хәяткә көлке иде. Дөньяда алардан бай, алардан бәхетле кеше булмагандыр. Мал колына әйләнгән кеше миллионнар өстендә утырган килеш тә андый бәхетне тоя алмаячагын, чөнки нәкъ шул миллионнар мона киртә булуын, бу хакыйкатьне әлегә икесе генә аңлап яшәүләрен, ләкин иртәме-соңмы башкалар да шуңа киләчәген уйлап бә-

хетле иделәр. Ә Дания моны беркайчан да аңлый алмас. Ул инде азау ярган, аның инде сөяге каткан. Баласын үтерүгә барып житкән хатыннан ни көтәсең? Габделхакның Даниягә үпкәсе зур иде. Үзенең шушы хәлдә дә тыныч булып кала алуына, аек фикер йөртү сәләтен югалтмавына, ачуы килмәвенә Габделхак үзе үк гажәпләнә. Анысы, әлбәттә, ачу килү начар киңәшче. Ачу килгәндә кешенең акылы упкынга убылып төшкән була.

Даниядән баласы булуын Габделхак бик теләгән иде. Ни дисәң дә мәхәббәт — яшәү өчен көрәш бит ул. Табигый сайлау-сайлану аша матурлыкка, камиллеккә, яшәргә сәләтле булуга омтылу. Габделхак белән Даниядән туган бала шул сыйфатларның берәзына ия булмас идемени?

Дания исә Габделхакның күңелендә ниләр ятканын уйлап та бирми, һаман үзенекен тукый иде.

— Дөньяда бер генә яшибез. Әллә минем дә башкалар кебек машинага утырып йөрисем килмиме?

— Үз аягыңа ни булган? Машина алдырып мине машина астында чокчындырып яткырыр идеңме? Аңа бензин кирәк, гараж кирәк, атлаган саен запас часть эзләргә кирәк, машина колы булырга кирәк.

— Колы дигән булып инде. Аны бит әле башта алырга кирәк. Төлке дә йөземне үрелеп алалмагач, пешмәгән ул, дигән, ди.

Өченче көн генә Габделхакка таныш художнигыннан хат килгән иде. «Яңа төзелгән культура сараеның эчке өлешен бизисе бар. Зур эш. Монда синең кул, синең күз кирәк. Язгы каникул вакытында килә алмыйсыңмы?»— дип язган иде. Артык акча мәшәкать, бәла генә китерәчәген уйлап: «Бара алмыйм»,— дип җавап язарга тора иде. Хәзер шуны исенә төшерде дә:

— Акча эшли алмый дисеңме? Ә менә язгы каникул вакытында гына да меңне эшләп кайтсам ни диярсең?

— Әкият.

— Юк, шулай да.

— Булмый.

— Юкка шаярасың син минем белән, Дания.

Габделхак: «Килергә булдым»,— дип хат язып салды. Каникул көннәре якынлашкач, өч көн алданрак җыенып чыгып китте. Биш йөз квадрат метрлы стенага спорт тормышын чагылдырган композиция ясарга кирәк икән. Габделхак эскизны ошатты. Эскизның күңелгә ятуятмавыннан күп нәрсә тора. Күптән мондый зур масштаблы эш алдына килеп басканы юк иде. Шулай озак бүленеп торгангамы, хәзер ничектер элеккегә караганда да үткенрәк күрүен, эшләнәсе эшне башыннан аягына кадәр күңелдән кичерә, тулаем колачлый алуын тоеп, Габделхак дулкынланып, эчтән калтыранып ук куйды. Ярышка чыгасын сизгән чабышкы атмыни. Эшкә ул җене кузгалып тотынды. Эшнең зурлыгыннан шөлләбрәк торган башка художниклар моңа сөенеп бетә алмадылар. Бу эштә иң кыены — эскиздагы рәсемне дөрес пропорцияләрдә стенада сызып, контурын билгеләп чыгу. Габделхак моны тулысы белән үз өстенә алды. Унбиш көн дигәндә ул кулына мең сумлык бер пачка акча тотып өенә кайтты. Дания кабалана төшеп ашарга әзерләргә керешге. Плитәгә чәйнек утыртты. Габделхакның яраткан ашы — тозлы, борычлы котлет кыздырам дип мичкә ягып җибәрде. Гадәти һавалы горурлыгының эзе дә юк. Габделхак аны кызганып куйды. Ләкин күңелендәге җәрәхәте тирән, үпкәсе зур иде шул.

— Менә, Дания, һич алдаусыз мең тәңкә. Ләкин бу акчаның безгә кирәге юк. Мин моны шул сүз өчен генә эшләп кайттым.

Габделхак, пачка кәгазен ертып, тизрәк янып бетсеннәр өчен акчаларны мич эченә сибеп җибәрде.

Дания беренче мәртәбә Габделхакка кызыксынып, күзләрен тутырып карады. Габделхакның әз генә дә калтырану әсәре сизелмәгән озын бармакларына, һичбертөрле шапырынусыз, тыныч, хәтта чак кына сагышлы, ирләрчә кырыс йөзенә карады да катты.

Шушы хәлдән соң алар татурак яшәп киттеләр. Дания Габделхакның мөмкинлекләрен моңарчы бәяләп бетермәгәнлеген, бу кешене кулга ияләштерү өчен нечкәрәк ысуллар кулланырга кирәклеген аңлап алган иде. Анысына инде Дания көчен кызганмас. Һәм Габделхак моңа лаек та бит. Ләкин бу эшне Дания бер үзе генә ерып чыга алмаячак. Аңа ныклы, ышанычлы союзниклар кирәк булачак. Шуңа күрә Дания ялганы, чыны, назы, иркәләве белән өйгә телевизор алып куйды.

Бәлки үзгәрер, мөнә дигән ир булыр. Даниягә әллә никадәрле дөнья рәхәтлекләре бирер. Әлбәттә, хатыны бала тапса, Габделхак бермә-бер йомшар иде. Ләкин әле сындырылмаган килеш аңа ышанып бала таба алмый инде.

Тормыш үзе дә Дания яклы иде. Һич уйламаганда, Габделхакны үз урынына калдырырга җыенып йөрүче Курамшин Сабир ага үлеп китте. Баш миенә кан сауган. Өлкән яшьтәге бу кеше авыл тормышына, җиргә гашыйк булуы белән Габделхакның бер өлеше сыман иде. Гомере булып Габделхак белән якыннанрак танышса, алар, һичшиксез, ныграк дуслашып киткән булырлар иде. Әле шул килеш тә Курамшин Габделхакның ныклы таянычы иде. Хәзер ул юк. Габделхакны директор итеп куймаячаклар, анысын Дания сизенә. Ә алга таба, гомумән, Ирмәттә Габделхакның җирлеген, яшәү мөмкинлеген калдырмау турында кайгырта башларга була.

Һәм, чыннан да, ронода Габделхакны директор итү турында сүз кузгатучы да булмады. Башка бер авылда икесе дә укытучы булып эшләгән яшь кенә бер гаиләне китерделәр. Хәзер яңа директор — Әкрам Хафизович.

*

* *

Җәйге ялны ничек үткәрү турында Дания берничә мәртәбә Габделхакка сүз катып карады. Эштән арынган көе дә матур җәйне Ирмәттә сөрсеп ятамы соң Дания! Аны инде күптән диңгез шавы, таныш диңгез култыгы, яңа романтик бәйләнешләр үзенә тарта. Акча бар. Габделхак принцибы белән юк-барга тотмагангамы, ни гаҗәп, әз-мәз хезмәт хакыннан да меңгә якын акча җыелды. Бер уйласаң, Габделхакта нииндидер дөреслек бар кебек. Дания диңгез буенда ял итү турында тагы бер сүз кузгаткач, Габделхак:

— Син нәрсә, Дания! Котеп алган вакытны әллә кайда үткәрергә! Күреп торасың, картина бетү алдында, бер-ике ай онытылып эшләсәм, тәгәлләрмен дә кебек инде хәзер,— диде.— Әлфияне дә үзебезнең янга алырга вакыт. Ә нигә син Әлфияне минем фамилиягә күчермисең? Шушындый матур җирдә яшәгәндә, диңгез буең бер якта торсын. Җиләк өлгерер, гөмбә. Бу урманнарда нинди гөмбәлекләр барын белмисең әле син.

Габделхакның Әлфияне үз фамилиясенә күчерергә теләвеннән Дания эчтән генә көлеп куйды. Харистан шулкадәр акча килеп торганда, Габделхак фамилиясенә күчерәләрме соң... Ә диңгез буена барасы килми икән, үзенә карый. Габделхак белән барса, үзе теләгәнчә ял итә дә алмас иде. Көнләшеп җанына тияр. Габделхак үзе чит хатыннарга карамый, җүнләп аракы да эчә белми бит ул. Ачы суны ансы бер ир дә рәхәтлектән эчми. Эшендәге, аннан да бигрәк өйдәге низаг, ызгыш-талашлардан һәм бигрәк тә көнчелектән ачу итеп эчә башлый ир-ат. Да-

ния әлегә күрәләтә Габделхакны көнләштерә алмый. Әлегә койрыгы бозга катмаган. Ике дә уйламас, аерып җибәрер, я бүтән берәр нәрсә эшләп ташлар. Габделхактан ни көтәргә буласын Дания белми, ләкин акча яндырганнан соң, аның белән саграк булырга кирәклеген чамалап куйган иде.

Ярар, Габделхак җәйге ялны Ирмәттә үткәрергә уйлый. Акча аның исемендә. Ул, чыннан да, ир. Һәм ышанычлы ир. Нинди очракта да гаиләсен кимсетмәячәгенә, үз-үзен кызганмый әллә нинди бәлаләрдән дә йолып каласына ышанырга була. Ләкин Даниянең үзенең дә саклык кенәгәсендә алты мең акчасы бар. Дания моңарчы бу турыда ялгыш та сүз ычкындырмады. Һәм дөрес эшләгән. Районнан үзенә Казанга барырга кирәк дип язу юнәтеп кайтты. Казанмы, әллә Кара диңгез буемы икәнен үзе карар әле ул...

*
* *

Көньякка элдерүче поездда барганда Дания үзалдына астыртын елмаеп: «Җүләр, урманга утын төяп баралармыни!»— диебрәк уйласа, кояшта каралып, әйбәт ял итүдән һәр күзәнәгендә рәхәт бер талгынлык тоеп кайтып килгәндә исә күңеле йомшарып: «Ярый әле дөньяда Габделхак кебек кешеләр бар. Дөньяның яшәрлеге калмас иде, югыйсә. Әмин Габделхактан үзем теләп качып киттем. Оят, оят! Валлаһи оят!»— дип уйлады.

Ләкин монын, корбанын кабып йоткач, крокодилның яшь агызуы сымаграк вакытлы бер халәт булуын Дания, әлбәттә, үзе үк аңлый иде.

Габделхак өч литрлы банкалар белән унлап банка ак гөмбә тозлап куйган. Кибәргә тезгәннәре дә әллә никадәр. Карлыган, алма, җир җиләге вареньелары кайнаткан. Бәрәңгене утап, ике кат тау-тау итеп күмеп чыккан. Үзе Даниягә карый да ныграк каралган, бергә тора башлаган чордагыча мөстәкыйльләнә, кулдан китә төшкән. Сагынган да кебек, шаяра, көлә. «Югыйсә, аныңча да яшәп була инде»,— дигән уй Даниянең башыннан тагын бер кат чагылып узды.

*
* *

Укулар башланып берничә атна үткәндәрәк, Габделхак янына шәһәрдән кунакка Петр Балашов килеп чыкты. Дания буфетта, өйдә Габделхак үзе генә иде. Сөйләшеп туя алмадылар.

— Ә син, чыннан да үз идеяңә тугрылыклы икәнсең,— диде Балашов өй эчен күздән кичереп.— Үзенең асылын югалтмаган кеше яшәүчән була. Молодец, молодец. Ә мин, беләсең килсә, юри кызыксынып килдем. Союзга алу өчен бирелгән картиналарың кызыксыну уятты.

Монысына Габделхакның йөзе сүрелә төште. Үзе канәгатьләнерлек нәрсә тудыра алмавын ул белә иде. Үзен белгәч, бу нәрсә башкаларга да сер булмаска тиеш. Габделхак Петрның күзләренә караган килеш берәрә сүзсез генә башын чайкап торды. Петр кыенсына төшеп, ләкин Габделхакның үзенә карата таләпчәнлеген хуплап елмайды.

— Нидер тота сине, нидер тулысынча ачылып китәргә комачаулый. Ә союзга алыначаксың. Белеп сөйләвем. Диңгез буенда ял итеп кайтышлый Мәскәүдә булдым. Андагы атмосфера миңа таныш. Үзенчәлегең белән син анда ничектер саф җил сымаграк тәэсир калдыргансың. Союзга алыну анысы, әллә нәрсә түгел, күпмедер күләмдә иҗатыңны тану билгесе генә.

Капка тавышы ишетелде. Дания кайтып килә иде. Дания өйгә кереп кунак белән исәнләшкәндә, Габделхак:

— Хатыным, Дания,— дип таныштырды.

— Ә без танышлар.— диде Петр элеккечә елмая биреп.— Хәтерлисезме, мин киткәндә сез килеп калдыгыз. Мин сезне чегән хатын-кызларына охшатып, чегәннәр дә диңгез буена ял итәргә килер икән,— дип гаҗәпләнеп уйлап куйган идем. Әлбәттә, сез мине искәрмәгәнсездер дә.

Габделхак белән Даниянең күзләре очрашып алды.

— Дания, табын әзерлә,— диде Габделхак. Үзе баздан тузлы кыяр, бер банка тозлаган ак гөмбә алды. Суыткычның уңайлыгына Петрның исе-акылы китте.

— Кар базы принцибында, ләкин чыннан да өйалды идәне астына кирәк. Бердән кыш көне кар басмый, икенчедән, өйалдына чыгып керү генә берни түгел. Ә бу бауларың просто могҗиза! Кайсын тартырга икәнен генә бутамаска, ну аңа кәгазь кисәге язып куярга да була инде. Ә менә бу нәзегрәк бауны тартсаң нәрсә килеп чыга инде?

— Тарт әле, мөгаен, безгә кирәк нәрсәдер,— диде Габделхак көлеп.— Саграк бул, ташка бәрдермә.

Петр:

— Бик җиңел бу,— дип тартып чыгарган иде, салкын суга батырылган ярты литр аракы... Икесе дә рәхәтләнеп көлеп җибәрделәр. Габделхак, Дания кайтканчы пешә торсын дип, казан аскан иде. Дания шуңа биш-алты бәрәңге әрчеп салды. Ул пешкән арада ирләр кетердәп торган ак гөмбә капкалап, беренче рюмканы эчеп куйдылар. Аннары табынга итле шулпа килде.

Петр Габделхакларда кунып, икенче көнне мастерскойга Габделхакның картинасын карарга бардылар.

— Җитди тема,— диде Балашов. Шуннан соң үзе дә ничектер басылып, аз сүзләләнеп калды.— Ярый, Габделхак, мин кузгалыйм,— дип китү ягын кайгырта башлады.

— Бер-икс көн кунак булырга иден.

— Безнең руста: «Хорошего по-малу» дигән әйтем бар. Булды, рәхмәт.

Якшәмбе көн иде бу. Петрны асфальт юлга кадәр озатып куйгач, Габделхак өйгә кайтты. Дания болай да чиста идәнне юарга тотынган.

— Чемоданнарыңны җыя торырга иде. Мин хәзер мәктәп атын җигеп кайтам,— диде Габделхак аңа.

— Нигә?

— Ничек нигә? Элекке фатирыңа илтеп куям.

— Уйлама да, мин синнән китмим. Җайлы. Шулай җиңел генә котылырмын дип уйлыйсың, күрәмсең.

— Әйдә, ямьсезләнмичә генә аерылышыйк. Кассадагы акчаларны да бирәм. Миңа алар кирәкми.

— Миңа да кирәкми.

Габделхак Даниянең чемоданнарын идән уртасына тартып чыгарды.

— Габделхак, зинһар, үземне теләсәң нишләт, чемодан-әйберләремне урамга чыгарып кына атма. Иң кыены шул.

— Әһә, димәк, сине элек тә шулай кугалаганнар. Нишләп син кеше тормышы белән уйныйсың? Сезнең кебекләр кеше рәтеннән ир белән яшәргә итенә. Күпме нерва, күпме гомер бушка сарыф ителә синең кебекләр аркасында. Давай, давай! Җыен!

— Аерылышу алай гына булмый әле ул, җанкисәгем. Башта гариза язарга кирәк.

— Без гаризасыз гына өйләнешкән идек.

— Барыбер, ир белән хатын күпмедер бергә яшәгәч, судка гариза бирелә. Ә моның өчен ике якның да аерылышырга риза булуы да кирәк әле. Ә мин аерылышырга теләмим. Мин сине яратам.

Габделхак шешәдә калган аракыны стаканга салып төбенә хәтле

эчеп куйды. Иөз илле граммлап. Бу инде Габделхак өчен шактый иде. Даниянең эченә жылы йөгерде. Шулай эчкәли башласа...

— Син, Дания, уенга борып маташма,— диде Габделхак сәбәпсезгә елмая башлап.— Минс алдаган кеше минем өчен дөньяда юк инде ул...

*
* *

Көннәрнең берендә төнлә ут чыгып мастерской янып китте. Калкулык өстендә мәһабәт зур факел сыман дөрләп янды ул. Берничә сәгать буена Ирмәт урамнары яп-якты булып торды. Йокысыннан уянып чыккан бар кеше шунда йөгерде. Габделхак, мастерскойның түбәсе убылып караңгы күк йөзенә менләгән очкыннар сибелгәч, өйгә кереп өстен салмыйча гына караватына сузылып ятты. Хәзер алар аерым йоклыйлар. Дания бүлмә эчс ягындагы сәкегә көйләде урынын.

Мастерской белән бергә Габделхакның ясалып бетү алдында торган картинасы, этюднигы, кулы күнеккән жан кебек кисточкалары, әллә никадәрле төслс буяулары янды.

— Инде нишлибез? Хәзер мәктәптә укыта алмаячаксың. Һаман әрсезләнеп шул тирәдә йөрү мәгънәсезлек.

— «Үз теләгем белән» дип гариза язарга туры килә. Башка чара юк.

— Картинаң?

— Кызганыч, әлбәттә. Этюдник, кисточкалар кызганыч. Андый кисточкаларны хәзер табып булмас. Явызлыкка каршы көрәшү өчен рәсем сәнгате бигүк кулай түгел, ахры. Дания кебек дөнья явызларын фаш итәр өчен башка чара, башка төр сәнгать кирәк, ахрысы. Рәсем сәнгате гүзәллек үрнәген генә бирә ала. Ә андый әсәр бар инде. Рафаэль мадоннасы. Рәсем сәнгатенең иң югары ноктасы ул. Икенче андыйны, яки аннан кайтышын ясап маташу мәгънәсезлек. Ә аннан югарыракны ясый алырлык талант миндә юк. Димәк, мин көчле рәссам түгел.

— Вакытлы күңел төшүләр була, үтәр әле.

— Вакытлы түгел бу. Ачы хакыйкать.

*
* *

Габделхак гаражда искс бер комбайн ремонтлап ята. Анда аларга төш вакытында кайнар аш бирәләр. Ул шунда туклана. Колхоз эше сәгатьле түгел. Габделхакның: «Минә үз вакытым иркенрәк калышлы эш булса иде»,— дию€нә каршы председатель үзе үк: «Кирәк чагында, яз, көз кызу эш өстендә сынатмасаң, сине беркем дә бәйләп тотмас»,— диде.

Бүген Габделхак эштән иртәрәк кайтып моржаны «төзәтергә» тотынды. Дания эштән кайтканда ул терсәгеннән корымга батып моржаның мич башы ягын сүтеп алган иде инде. Мич авызыннан карасаң — ишек, бу ягыннан тәрәзә күренә.

«Лып» итеп корымлы урындыкка барып утырган Даниягә ул:

— Бераз төтен чыгара иде бит. Хәзердән карап куймасаң, кыш буе интегергә,— диде.

— Барыбер китмим мин синнән, Габделхак. Син яшәгән жирдә мин дә үлмәм.

— Алтын сүзләр. Ләкин пожардан соң кесә насосының файдасы шуның кадәр генә. Мин сине беләсеңме нишләтәм... Кеше ул — табигать могжизасы. Үтерсә аны табигать кенә үтерергә хаклы. Ә мин сине...

Юкка шаярасың минем белән. Алла юктыр да бәлки, ләкин гөнаһ, хыянәт җәзасыз калырга тиеш түгел. Әйдә, күтәр үкчәңне!

Габделхак мич өстеннән төшеп Дания янына килә башлады. Ул шаярмый иде. Дания шуны аңлап:

— Якын килмә!— дип чырыйлап кычкырып җибәрде.— Ярар, китәм! Китәм!

Дания чемоданнарын ачып, яраксызга әйләнгән әйберләренә бер тын карап торды да, чемодан капкачын шап итеп ябып ишеккә таба атлады. Берара туктап калып Габделхакка борылды. Йөзендә андыймондый кыланусыз чын газап иде.

— Элегрәк кайда идең син?! Нигә мин сине кыз чагымда ук очратмадым?!— диде һәм яңадан бер сүз әйтмичә чыгып китте. Икенче көнне аның Ирмәттән бөтенләйгә китеп баруы беленде.

Ике-өч көн эчендә Габделхак өен нәкъ элекке хәленә китерде. Башта мичен инде чыннан да төзәтеп, сылыйсы җирен сылап, известь белән агартты. Аннары Даниядән калган чемоданны да ватып мич утына ташлады. Тәрәзә пыяласын куйганнан соң өйнең түшәм-стеналарын кайнар су белән сабынлап юды. Идәнне дә кайнар су, ком белән ышкыпышкып юып чыгарды. Өйгә элекке тәртип кайтты. Аның әле бәрәңгесе дә алынмаган иде. Ярый көз озак килде. Кеше инде бәрәңгесен унбишегерме көн элек алып бетереп базларга салып куйдылар. Бакчасында бәрәңге алып кайнашкан Габделхак үзеннән үзе:

— Я, ничек?— дип сорады.

— Ә нәрсә?

— Нәтиҗәдә?

— Нәтиҗәгә иртә әле. Яши генә башлау бу. Юклык куркыныч түгел. Байлык, комфорт куркыныч. Юклык ул күңел хөрлеге генә.

Габделхак өен җыештырган арада базын ыслап куйган иде. Хәзер бәрәңгенең алган берен базга сала барды. Төштән соңрак эштән кайткан ике як күршесе көрәкләрен тотып киртә аркылы Габделхак бакчасына керделәр.

— Син, малай, барыбер көрәк бирмәссең. Менә үзебезнекен алып кердек,— диешеп, башкача рөхсәт-ни сорап тормастан, рәткә басып бәрәңге казырга тотындылар. Чиләгең тотып кергән Гыйльмениса апа да:

— Улым, син юкка киреләнмә. Радиу әнә, иртәгә кар төшә, диде. Бәрәңгең кар астында калмагае,— дип ире казыган бәрәңгеләрне чүпләргә иелде.

Капкадан шулай ук үз көрәген тотып алпамша гәүдәсе белән кире Кәрим килеп керде. Берара сүзсез генә эшләгәннән соң ул:

— Хык!— итеп пырхылдап көлеп алды.— Син, Габделхак, әллә нинди приумнар беләсең икән, ә?— диде.

Башкалар бу тиле-миле ни сөйли дип аптырашып:

— Нинди приум? Нинди приум?— диештеләр.

— Соң! Самбы приумын да белә, мине бөгеп кенә салды. Аннан килеп менә хатын аеру приумы.

Бөтенесе күтәрелеп көлешеп алдылар. Ул арада ишегалдына мәктәптән кайтып килүче җиденче, сигезенче класс укучылары керен тулды.

— Ну моның бәрәңгесе дә тәмле була инде, җир суыгын тойган бәрәңгегә тәм керә бит ул,— диешә-диешә берничә сәгать эчендә Габделхакның бәрәңгесен алып бетереп, базга салып, авызын томалап та куйдылар. Икенче көнне иртән җиргә ап-ак булып кар төшкән иде.

## Рашат Низамиев

# КӨНБАГЫШ

хикәя



Алар көтмәгәндә, уйламаганда дуслаштылар...

Абзар артындагы бакчада бәрәңгеләрнең тишелеп, тернәкләнеп, яфракка узган чагы иде. Аксыл сабак саен учлам-учлам бәреп чыккан яфраклар яшькелт буразна булып киртә койманың аргы башына кадәр сузылган. Чү, монысы нинди үсемлек тагы? Үрдәк борынына охшаш озынча ике яфрак, шуларның нәкъ уртасында — ачылып кына килүче нәни яшел «төенчек». Төенчек эчендә ниләр бар икән соң — моны белү өчен көн саен бакча тирәсендә кайнашырга, таныш түгел үсемлекнең ничек, ни рәвешле яшәвен, сулавын җентекләп күзәтергә туры килде малайга. Бабасыннан сорап, ул аның көнбагыш икәнлеген белде. Менә көнбагыш, күрегез-күр дигәндәй, җәлпәк яфракларын бер-бер артлы кояш иркенә суза башлады. Яфракка сикергән саен биеккә таба үрләде ул, сабагы исә күзгә күренеп үсте, ныгыды, юанайды.

Малай белән көнбагыш көннән-көн дуслаша бардылар. Ничек дуслашмыйсың ди! Беркөн шулай авылның тигәнәккә баткан йолкыш кәҗәсе киртәне ватып кергән иде. Бәхеткә каршы, мөгезле башкисәрдән көнбагышны малай коткарып калды. Икенче көнне, иптәшләре начар сүз әйтеп үртәгәч, ул үзе дә бабасы каршына түгел, көнбагыш янына килеп елады...

Бәрәңгеләр белән ярыша-ярыша үсте көнбагыш, ниндидер тылсым көче белән һаман саен кояшка таба тартылды. Тора-бара хәтта үзенең дустын — Кәрим атлы малайны да узып китте. Иң кызыклысы: сабагының очында әлеге дә баягы төенчек эленеп тора. Ул инде зурайган, йомрыланган. Очлаеп килгән тыгыз тышчалары эчкә таба ятып, укмашып тора. Әнә шул укмашып торган тәлинкәнең уртасында исә сары балкыш төсмерләнә, һәм анда әле күз күрмәгән тагын әллә нинди хикмәтләр бардыр төсле.

Их, бу хикмәтләрнең ачылып китүен тизрәк күрсәң иде!

Малай, әнә шулай хыяллана-хыяллана, ишегалды бакчасына йөгереп керде. Андагы тамашаны күргәч тә — сизгер песи баласы диярсең — адымнарын акрынайтты. Сары төстәге умарта каршына теләсә ничек чабып барырга ярамый шул — бал кортлары усаллаша. Бабасы,

гадәтенчә, битлексез-нисез һәм яланкул килеш умарта оясы янында кәрәз рамнары белән булаша. Оныгы килүенә шатлана да соң ул: әнә, үзенең иләк битлеген алмагач ботагыннан алып тизрәк Кәримгә суза. Чалбар кесәсе яшәсен — кулларны шунда яшерергә мөмкин. Анысы Кәрим болай гына сакланган була, бал кортлары аны сипкелләреннән танымый дисеңме, таный, әллә каян таный!

— Бабай, безнең көнбагыш кайчан чәчәк атачак?

Бабасы соңгы вакытларда оныгының көнозын диярлек көнбагыш тирәсендә әвәрә килүен яхшы белә. Аларның дуслыгын мыек астыннан гына елмаеп, күзәтеп йөри ул. Әлеге сорауның туасын да күптәннән үк чамалап куйган иде.

— Тиздән, улым, тиздән... Бәрәңгеләр чәчәк аткач.

Оныгы, ул көннәрнең кайчанрак җитәсен чамаларга теләгәндәй, соңгы сүзләрне сузып-сузып үзалдына кабатлый: «Бәрәңгеләр чәчәк аткач?..»

Шул вакыт бүкән өстендә утырган малайның тез башына бал корты килеп кунды. Куркамы соң Кәрим, күзләрен тагы да зуррак итеп ачты да челтәрле битлек аша рәхәтләнеп бакча кунагын күзәтте. Чәнчә бармак очы тикле шушы канатбикәнең тәпән тутырып бал бирүе аңлашылмый иде аңа. Ә балының тәмлелеген кара син! Бабасы әйтүенчә, кыр чәчәкләренең елмаюы, юкә агачының хуш исләре дисеңме — һәммәсе, һәммәсе дә сеңгән бит аңарга.

Бал кортының Кәрим белән «исәнләшүе» генә булды, ахры, эшем күп, ашыгам дигәндәй, канатларын җилпеде дә күтәрелеп очып китте.

— Бабай дим, бабай...

— Нәрсә?

— Кортлар балны чынлап та чәчәктән генә җыямы?

— Әйе, чәчәктән генә. Әнә, күрәсеңме, чәчәк балын, чәчәк тузанын умартага ташый алар.

Кәрим, битлеген сак кына күтәрә төшеп, умарта авызына текәлде, ләкин анда керәле-чыгалы кайнашкан канатлыбикәләрдән башка берни күрмәде. Аның уйлавынча, бал кортының һәркайсы үзе белән кечкенә генә кәрҗин кисәге йөртергә тиеш иде шикелле. Аякларында кәрҗингә охшашлы нидер бар барын...

— Бабай, аларның ташыган балы күренми дә. Ә синең агач тәпәнеңә бушатсаң, никадәр кү-ү-үп!

— Әниеңнең карлыган җыйганын күргәнең бар бит.— Киез эшләпәсен төзәткәләп, бабасы серле генә елмая.— Баштарак әле савытның төбе генә күмелә. Бөртекләп җыя торгач, берзаман түбәләмә кабарып, тулып чыга ул. Бал кортлары да шулай, үскәнем. Тырыша торгач, аларның бөртекләп җыйган хәзинәсе дә кәрәздәге күзәнәкләрне мөлдерәмә тутыра. Хәтереңә уеп куй: тырышлык бушка китми ул, балам.

— Үзләре тырышалар, үзләре чагалар? — диде малай, нәрсәнедер исенә төшереп.

— Теләсә кемне чакмый бит алар.

— Ә күрше Габбас абыйны чакты бит, чакты...

Бабасы бу юлы хәйләкәр итеп елмайды:

— Габбас абыең ул көнне «әче су» эчкән булган шул, зәхмәт төшкере. Ә бал кортлары яман ис килгәнне яратмый, чисталыкны, пөхтәлекне генә ярата алар.

Шушы сүзләрдән соң оныгы кинәт үзгәреп, очкынланып китте. Үзе турында уйлый иде ул. Көн саен иртән битен-кулын юа, «Чебурашка» пастасы белән тешләрен чистарта, уйнаганда исә күлмәк-ыштанын ничек тә буямаска тырыша Кәрим. Ул гынамы, битләре агарганчы Тегермән буасының сай җирендә су да коена әле... Менә ни өчен бал кортлары тими икән аңа!

* * *

Җәй патшалык иткән гадәти көннәрнең берендә бабасы таңнан торып сөенче алды:

— Тор, балам, бәрәңгеләр чәчәк аткан...

Йокылы-уяулы Кәримнең күзләре зур булып ачылды. Чыннан да, каршында сөекле бабасы басып тора. Чыннан да, битендәге барлык җыерчыклары белән берьюлы елмая-елмая, ашкынып көткән сөенечле хәбәр алып килгән ул.

Мондый чакта йоклап яту ярыймы соң! Чәчәкле юрган карават янындагы урындыклар өстенә үзеннән-үзе шуып кына төште. Кая инде бит юып маташу, хәтта әнисе бүлгән ашны да ашап тормастан, шундук бакчага атылды малай. Абзар почмагына эләгеп күлмәк җиңе ертылды ертылуын, ләкин бабасы әйткән сөенче янында моның ише нәрсә чүп кенә иде.

Кәрим үз күзләренә үзе ышанмады: бәрәңге бакчасы бер төн эчендә тәмам үзгәргән, яктырып, нурланып киткән иде. Аксыл-шәмәхә төстәге чәчәкләр буразна-буразна булып сибелгән. Һәрберсендә — елмаю, яңа көнне каршылау тантанасы. Аңламассың: әллә кар яуган, әллә инде бакчага төн буе йолдызлар коелган? Җәй көне кар яумый, шуңа күрә аларның төнге йолдызлар булуы бик ихтимал...

Буразналар тулы яктылыкны тамаша кылганнан соң, малай, әлбәттә, дусты каршына килеп басты, аның пәрәмәч тиклем зурайган тәлинкәсенә текәлде. Текәлде дә таң калды! Көнбагышның очында нәп-нәни кояш эленеп тора иде... Әйе, якында — кул сузымы гына җирдә чып-чын, теп-тере кояш балкый! Түм-түгәрәк, чит-читләрендә сары ялкын бии. Туры карасаң, күзләрне камаштыра — әйтерсең, чеккә кояшының утлы балкышы бар аңарда. Гап-гади бер көнбагыш каядыр болытлардан да өстә яшәүче алтын кояшка шул кадәр дә охшаса охшар икән!

Шушы көннән башлап малайның ике кояшы бар иде: берсе — күктә, берсе — бакчада. Кәрим аларның икесен дә бертигез яратты. Күктәгесе болытлар артына кача икән, бакчадагы кояшка карап юаныч тапты ул. Ә инде мендәрдәй кабарынкы болытлар арасыннан «утлы шар» тәгәрәп чыга икән, икеләтә шатлык! Андый чакларда Кәримнең күңелендә якты бәйрәм башлана. Кояш нурларына тотынып ул каядыр өскә, югарыга үрмәли, болытлар өстенә чалкан ята, әнисенең кочагы сыман рәхәт бер дулкында тирбәлә... Дусты көнбагыш белән сөйләшә башладымы, Кәрим һәрвакыт уйчанланып китә, хыялый кешегә әверелә.

— Син кояшка охшагансың.

— Мин бит кояш баласы.

Көнбагыш дәшми тора. Малай сүзне тагын үзе ялгап китә:

— Әгәр йөри белсәң, мин сине Тегермән буасына су керергә алып төшәр идем.

— Рәхмәт. Мин битемне иртәнге чык суларында юам.

— Яңгырны яратасыңмы?

— Яратам. Яңгырдан соң яфракларыма тикле көләчләнеп китә.

— Яфракларың бигрәк дәү.

— Шулайдыр. Синең колакларың шикелле. Алар да минем яфракларым кебек ян-якка тырпаеп тора.

Кәрим басып торган җиреннән колакларына ике куллап ябышуын сизми дә кала! Әнә шулай рәхәтләнеп, онытылып бер-беренә ышанып ихластан сөйләшә алар. Дөресрәге, малай үзенең сорауларына көнбагыш булып җавап кайтара. Аларның аулакта шулай күзгә-күз карап серләшүен биектәге кояш кына ишетәдер, аңлыйдыр шикелле.

Кәрим сизенә килде: кояш белән көнбагыш арасында ниндидер уртаклык, яшерен бәйләнеш бар. Чыннан да шулай икән — бакчадагы дусты кояш әйләнешe уңаена көнозын талгын гына борыла икән ләбаса! Кояш иртән кай яктан чыкса, көнбагыш шул якка таба караган була. Кичләрен ул чуклы-чуклы башын кояш баешы ягына бора... Таң калырлык ачыш иде бу. Көнбагышның җанлы икәнлегенә тәмам ышанды Кәрим, аны иң якын дусты итеп таныды. Сентябрь җиткәч тә беренче класска укырга барачагы хакында озаклап сөйләде, китап-дәфтәрләр турындагы серен дә аның белән уртаклашты. Әнә, ничек бирелеп, башын ия төшеп тыңлый бит ул. Дәү-дәү яфраклары белән Кәримнең кулларына, иңбашларына орынып алгандай итенә: тиздән мәктәпкә барасың, зур кеше буласың, янәсе...

Өлкәннәргә сөйләдең ни, сөйләмәдең ни, алар сине күп вакыт аңлап бетермиләр. Җитмәсә, малайның әти-әнисе көн буе эштә. Сораулар биреп аптыратыр өчен әле дә ярый бабасы бар. Ә инде сөйләшер, серләшер өчен көнбагыштан да яхшы, аңардан да ышанычлы иптәш юк. Алдашмый, үртәшми, кояшка һәм синең күзеңә генә карап тора. Кәримнең кайчак үзенең дә озын буйлы көнбагышка әвереләсе, басып торган җиреннән, нәкъ аныңча итеп, кояш уңаена таба талгын гына борыласы килә башлый. Әмма тылсымлы әверелеш ясарга кулыннан килми аның.

Күр әле, көнбагыш тәлинкәсенең сипкелле өслеге умарта кәрәзенә нык охшаган икән: буй-буй сызылган, рәт-рәт тезелгән эре, сары күзәнәкләр. Чынлап та умарта кәрәзе дип белде, ахры, шул вакыт «Без-з...», «Без-з...» безелдәп, көнбагыш чәчәгенә бал корты килеп кунды. Исәнме, кояшка кунган бал корты?

— Без-з... Без-з...

Шул вакыт бабасының: «Бал корты беркайчан да «мин» дип масаймас, «без» дип кенә сөйләшер»,— дигән хикмәтле сүзләре исенә төште. Канатлыбикәнең ашыкмый, кабаланмый гына һәр күзәнәкне барлап-тикшереп чыгуы малайга могҗизалы тәэсир итте. Борынга бал исе килеп бәрелгәндәй булды. Менә бит, бал корты көнбагышны бер дә чакмый, чөнки аңардан хуш ис бөркелеп тора.

Бабасы ишегалдында тырма теше ясап маташа икән. Кәрим, колын кебек уйнаклап, бабасына якынлашты. Килә-килешкә үк шатлыгын уртаклашырга ашыкты:

— Бабай, көнбагышка бал корты ияләшкән.

— Бик әйбәт, улым, йөри бирсеннәр. Көнбагыш чәчәгендә бал да, умарта җилеме дә мул була.

— Бабакаем, беләсеңме нәрсә... Көнбагыш һәрвакыт кояшка таба борыла икән.

— Әйе, ничә карасаң да көнгә, кояшка баккан булыр.

— Бабай, кояшка таба нигә борыла икән ул?

— Кояш — изге нәрсә, балам. Аңа табынудан да зур эш, саваплы эш юк. Адәм баласы да шулай кояшка карап эш йөртергә тиеш дөньяда. Әнә, әтиең кояшны иртән кырда каршылый, кичен озата. Кояш яктысын яраткан кешенең күңеле чиста була. Өстәлдәге икмәк тә кояштан яралган. Кояш кына исән булсын — калган нәрсәгә юнь табылыр...

*
* *

Августның санаулы көннәре җитте. Бакчадагы бәрәңге сабаклары, үз авырлыгын тоталмыйча, бер-беренә авып, кочаклаштылар. Көнбагыш кына үзенең мәһабәт буй-сынын, җәйге матурлыгын югалтырга теләми иде. Тамыры нык, бозау теледәй кытыршы сабагы һәм яфрак-

лары төнге кырауларга тамчы да бирешми. Әле кайчан гына яшел төенчек хәлендә йомылып яткан боҗрасы инде баеп барган кояш кебек тәмам тулышкан, авырайган, җиргә таба кайтарылып төшкән. Ул элеккечә һаман да горур, ләкин аның башын иебрәк басып торуында ниндидер бер моңсулык, хәвеф бар кебек.

Кәрим беренче сентябрь иртәсенә әзерләнде. Җәй буе бергә-бергә үскән җан дусты, тугры сердәше белән һаман да үзенең барлык сөенечләрен уртаклашып торды ул. Ләкин малайның инде ныгып, тамырланып килгән шатлыгына, мәхәббәтенә көтмәгәндә кул күтәрделәр...

Көнбагыш башын кемдер рәхимсез төстә умырып, аны төптән ук өзеп-каерып алган иде. Көнбагыш сабагының җәрәхәтле ак тәне, яманлыкка шаһит булып, бакча уртасында янып тора. Ап-ак яра шикелле...

Малай өнсез калды, куллары яралы кош канатыдай аска салынып төште. Иртән бәрәңге бакчасына чабып чыкканда әле аның гөнаһсыз күзләрендә ашкыну һәм гаҗәпләнү очкыннары уйный иде. Бу очкыннар кинәт кенә сүнде, төпкә күмелде.

Аның җирдәге кояшын урлаганнар! Кояшка кунган бал корты, син шуны беләсеңме? Кәрим, җавап эзләгәндәй, умарталык ягына борылып карады. Тик шифер түбәле абзар-кура аны алмагач төбендәге умарта оясыннан аерып тора иде.

Малай кабат көнбагышның ап-ак ярасына текәлде.

— Кем тиде сиңа?

— ...

— Кем өзде сине?

— ...

Таланган көнбагыш сөйләшми, ул инде ым белән генә аңлашучы телсезгә әверелгән иде. Иң якын нәрсәңне югалту ачысы күз яшьләре булып бәреп чыкты. Яшеллеген җуярга өлгермәгән бәрәңге яфраклары өстенә беренче нәфрәт тамчылары тәгәрәде.

Күктәге кояш көнбагыш табасын хәтерләтә һәм аны да кемдер сабагыннан менә-менә өзеп алыр шикелле иде бу минутта...

## Нурия Измайлова

### Гомер бу...

Секундлар белән, минутлар белән,
Дошманнар белән һәм дуслар белән,
Сөйгәннәр белән һәм ятлар белән,
Болытлар белән, агачлар белән
Бер танышу бу, бер сүз кушу бу,
Шундук мәңгегә югалтышу бу...

Болытлар килә. Китә мәңгегә —
Яңа болытлар булып әверелә.
Күрешү булмас инде соңыннан —
Бер минуттан соң мин дә мин булмам.
Бер мизгелем дә кайтмас яңадан...

Гел сулыш алу яңа һавадан!
Кабатланмауга ашкыну һаман,
Яңа булу һәм яшь булу һаман!
Газапта ана балалар таба.
Яңару дәрте көч бирә аңа.
Туу — яңару, үлү — яңару.
Картаймау хисе шуңадыр җанда!

Дәртләнеп-ярсып алга ашу бу,
Ә бит мәңгегә бәхилләшү бу!..
Нинди фаҗига! Нинди тантана!
Ах, бар да артта... Ах, бар да алда!
Күпме бәхет бу бәхетсезлектә,
Вакытлылыкта һәм чиксезлектә!
Колачны җәеп алга ашу бу,
Көлеп-елмаеп бәхилләшү бу!..

### Апрель азагы

Тузан кунмаган, бөҗәк тимәгән
Нәни яфраклар, нәни үләннәр.
Сабыйлар сыман гади-серлеләр,
Сабыйлар белгән телдә сөйлиләр.
Пышылдашалар: «пип-пип-пип-пип-пип»,
Сары чебиләр сибелеп китәр күк.
Йөгерә сабыйлар: «әт-тә-тә-тә?»— дип,
Уф, йөрәкләре: «леп-леп-леп-леп-леп»!

Сабый дөньяда нинди бергәлек!—
Олы бер уртак йөрәк тибә күк!
Уртак шатлыклар шуклыкка күчә —
Йөгерә балалар, туктый алмыйча.
Бәхетне эчтә тотасың ничек!
Көлә балалар, кояшны кочып!
Чирәмгә егыла, хәлләр калмыйча,
Көлә балалар, туктый алмыйча.
Ул саф авазлар һавага күчә —
Көлә табигать, туктый алмыйча!
Сабыйлар сыман чылтырап көлә!
Бу — яшәү башы, сабыйлык җирдә.
Шундый аңлашу, шундый бергәлек!—
Олы бер уртак йөрәк тибә күк!

## Минем җәй

Ул кайнар иде,
Ул кайда инде?!
Алда — көз, ә җәй
Ул җанда инде.
Алда вакытта,
Янда вакытта
Булмады җәйне
Күреп калып та,
Назын-шифасын
Файдаланып та,
Туңмаслык итеп
Янып калып та!

Юк! Миндә җәйнең
Ярсу чаклары,
Күкләр күкрәве,
Яшен ташлары!
Юк, көн дә килә
Җәйнең хатлары,
Хатлары саен —
Каен яфрагы,
Яфрагы саен —
Серле әлифба...
...Ә син, көз, миннән
Көләсең юкка!
«Андый әлифба
Буламыни!— дип,
Күргәнең дә юк
Син андыйны!»— дип.
Ә мин ышанам
Булмаганга да,
Күз күрмәс әллә
Ниләр барга да,
Аң җитмәс тирән
Серләр барга да.
...Юкса, ничек җәй
Миңа хат яза?

Күзем күрмәгән
Серле әлифба
Яшәтә мине,
Мине бар итә:
Аңарда — Кояш,
Аңарда — өмет.
«Синең җәй — синдә!»—
Ди ул өзелеп.
Минем җәй — миндә!
Шат һәм яшь калды!
Моңсу күземдә —
Шатлык яшьләре.
Кулымда — көзгә
Яшен ташлары!

## Әбиләр чуагы

Әбиләр чуагы,
Әбиләр чуагы.
Йомгагым чуалды,
Очлары югалды:
Әллә көз, әллә җәй,
Әллә бер төш бары...
Ашкынам, шашынам —
Әллә бер кош бары?..
Очарга, күчәргә
Талпынган мәлләрем,
Тик бүген очмадым,
Кемнедер җәлләдем.
Кыймадым. Уйладым
Кемнеңдер хәлләрен.
Язмышта ялгыш юк —
Мин көзгә бәйләндем.

Уралдым сихерле
Кояшлы челтәргә.
Бу рәхәт халәттән
Көчем юк китәргә.
Бүгенгә мин монда,
Нишләрмен иртәгә?—
Нишләрмен күңелем
Ашканда күкләргә?..
Ямансу җылы бу —
Әбиләр чуагы.

Язмышым соңарып,
Кызганып елмайды.
Көзге наз, соңгы наз
Рухымны чорнады,
Алтынсу бишектә
Тирбәтә уйларны.
Уйларым чуалды,
Очлары югалды...
Әбиләр чуагы,
Әбиләр чуагы...

## Асылыма җитә барам

*— Улыгызның исеме ничек?*
*— Искәндәр.*
*— И-и, бигрәк иске исем кушкансыз икән.*

Урамда сөйләшүдән

Үткәннәргә «искелек» дип
Йөз чытарга ашыгылган.
«Яңа һәрчак искедән шәп»
дип уйланган — яшь булынган!
Безнең буын, безнең гасыр —
Тарих башы дип йөрелгән.
Ә ул — чиксез һәм картлыксыз —
һәркем аңа тормыш өргән:
Сабый булып сафлык биргән,
Даһи булып акыл биргән,
Янып-көеп ялкын биргән,
Хәтер барсын җыеп торган:
Хәтернең тирән җиреннән
Алтын таулар китә күренеп,
Тарихтагы батырларга,
Акылларга һәйкәл кебек.
Күпме бөек затлар киткән
Юлларына җәүһәр сибеп!
Бер бөек хәл, бер бөек эш,
Бер бөек сүз — һәр җәүһәре.
Алда микән күбрәк хикмәт,
Артта микән — белмим әле...
Белмим әле, ни бәядер
Аңланмаган әнкәй сүзе —
«Примитив» дип тыңланган сүз...
Никтер һаман истә үзе.
Истә әнкәй такмаклары,
Әйтеп улымны биетәм.
Әнкәйчә карап торам да
Нәкъ аныңча атлап китәм.
Карыйм әнкәйгә якыннан —
Бездә бер үк караш икән!
Йөз кызартып искә төшә
Караган чак аңа өстән...
Җирдәй иске чынлыкларга
Ачыш ясап барып җитәм.
Шулай тарих акылларын
Тамчы-тамчы йота барам.
Асылыма җитә барам —
Әнкәй булып бетә барам.

**Шәмси Хамматов**

**Касыйм Тәхау**

# ФРОНТОВИК ӘДИПЛӘР

Ялкынлы, дулкынландыргыч шигырьләре, Бөек Ватан сугышының утлы өермәләре эчендә чыныккан лирикасы белән халкыбыз йөрәгендә урын алган Фатих Кәрим ул юлларны 1942 елның 14 апрелендә язган. Аның «Ватаным өчен» дигән шигыре беренче тапкыр «Кызыл Татарстан» газетасында 1942 елның 10 маенда басыла.* Әйтеп үтик: шагыйрьнең дәһшәтле елларда иҗат иткән күп әсәрләре шушы газетада чыкканнар.

Без — Татарстан АССРның үзәк дәүләт архивында. Анда язучыларның, шагыйрьләрнең, Бөек Ватан сугышы кырларыннан «Кызыл Татарстан» редакциясенә шигырьләре, хикәя, очерк, зарисовкалары, фронттан язган хатлары да тупланган.

Кырык еллап архив киштәләрендә сакланган бу кадерле язмалар инде саргая башлаган. Авторларының кайберләре исә, дошман белән батырларча көрәшеп, яу кырында ятып калган. Икенчеләре, сугыштан кайтып, дөнья куйдылар, исәннәре дә — шактый өлкәнәйде. Шунлыктан, еллар үткән саен әлеге кулъязмаларның кыйммәте арткан-нан-арта бара.

Менә Фатих Кәримнең «Дусларга», «Бомба төяп оча самолет», «Мин — гуманист» исемле шигырьләренең архивта сакланган төп нөсхәләре. Автор файдаланган кәгазь, язу рәвеше үк әдипнең кичерешләре, әсәрләрнең нинди шартларда иҗат ителүе турында да сөйлиләр.

Фатих Кәримнең 1942 елның 15 ноябрендә язган бер хатында:

«Язам. Окопта да яздым, сугышта да яздым... «Совет әдәбияты» белән «Кызыл Татарстан»га күп әйберләр җибәрдем... Мин язам да язам. Кирза итекнең кунычын өстәл итеп, шыгрым тулы товарный вагон полный ходка барганда шигырь язарга өйрәнү өчен кичергән елларның күп файдасы булды... Тик менә кәгазь юк. Кәгазьнең кадерен белегез»,— дигән юллар бар.

Фатих Кәримнең архивтагы егермедән артык кулъязмасы белән таныштык. Аларның күбесе тар кәгазь битләренә яки почта открыткасына карандаш белән язылган. Шагыйрьнең кул астында кара да һәрвакыт булмаган, күрәсең.

Фатих Кәрим — Бөек Ватан сугышы елларында иң актив иҗат иткән шагыйрьләрнең берсе. Аның әсәрләре «Кызыл Татарстан» газетасында, «Совет әдәбияты» журналы саннарында дөнья күрә. 1943 елда «Мәхәббәт һәм нәфрәт» исемле шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы, «Разведчик язмалары» исемле повесте, 1944 елны «Моң һәм көч» дигән шигырьләр җыентыгы, 1945 елда «Язгы таңда» повесте китап булып басыла.

Әдипнең «Мәхәббәт һәм нәфрәт» исемле шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы чыгу уңае белән тәнкыйтьче Хәсән Хәйри «Кызыл Татарстан» газетасында: «Фатих Кәрим,— дип яза,— күптән түгел басылып чыккан җыентыгын «Мәхәббәт һәм нәфрәт» дип атаган... Чынлап та, шагыйрьнең бу җыентыгы илебезгә, безгә туган җиребезгә,

халкыбызга чиксез мәхәббәт һәм немец илбасарларына каршы көчле нәфрәт хисе белән сугарылган. Ул совет халкының какшамас бердәмлеге, ныклыгы турында совет сугышчыларының азатлыгы, чәчәк аткан илебезне саклау өчен сугышта батырлыклар күрсәтүләре, дошманга каршы нәфрәт, үч алу ялкыны үсүе хакында хиссиятле, тирән эчтәлекле шигырьләрен яза, «прикладына салып окопларда язган», «туп гөрселдәп торган җирләрдән» сәлам шигырьләрен җибәрә».

Ул — татар совет әдәбиятында тирән эз һәм зур мирас калдырган, әдәбиятыбыз күгендә балкып янган йолдызларның берсе, Һади Такташ, Муса Җәлилләр янәшәсендә торган шагыйрь.

Фатих Кәрим халкыбыз йөрәгендә, әдәбият мәйданының түрендә урын алды. Әхмәт Исхак һәм Абдулла Әхмәткә 1942 елның 9 мартында җибәргән бер хатында да «...мин инде хәзер сездән еракта, ут сызыгында. Менә шуннан сезгә ашыгыбрак язган бер шигырь җибәрәм. Сез аны, ошатсагыз, «Кызыл Татарстан»да басып чыгарыгыз»,— дип яза.

«Кызыл Татарстан» газетасы сугыш елларында Фатих Кәримнең утызга якын әсәрен чыгара.

Фатих Кәрим 1942 елда Смоленск өлкәсендәге «Зайцева Гора» биеклеге өчен барган сугышларда, мина ярчыгы тиеп, каты яралана, госпитальгә озатыла. Ул май — август айларында Казан госпитальләренең берсендә дәвалана, шушы чорда аеруча күп иҗат итә. «Иптәш», «Бомба тәяп оча самолет», «Мин — гуманист», «Кайгың, куанычың» кебек шигырьләре, «Пионерка Гөлчәчәккә хат» поэмасы беренче тапкыр «Кызыл Татарстан» газетасында чыгалар. Әдип бу поэмасын озынча тар кәгазьгә шәмәхә карандаш белән язган.

Казанда дәваланган вакытта ул редакция белән аеруча тыгыз элемтәдә була. Аның Татарстан АССРның үзәк дәүләт архивында сакланган, җаваплы редактор урынбасары Галим Рябковка 1942 елның 20 июнендә язган хаты шул хакта сөйли.

«Сезгә сәлам. Мин Ватан сугышы еллыгына багышланган номерга бер шигырь җибәрәм. Әгәр дә ул сезне канәгатьләндерсә, бер вәгъдәмне үтәгән булам.

Хәзер Англия, Америка белән дуслык союзына каратылган номер өчен шигырь хәзерләү өстендәмен. Аңысын дүшәмбе көн кирәк булса — дүшәмбе көн, сишәмбе көн кирәк булса — сишәмбе көн килеп алырлар. Үзем теләсәм дә бара алмыйм...»

Һәм газетаның 23 июнь (сишәмбе көн) санында Фатих Кәримнең «Бомба тәяп оча самолет» исемле шигыре чыга. Әдип госпитальдә «Пионерка Гөлчәчәккә хат», «Тирән күл» дигән поэмаларын да иҗат иткән. Автор үзенең «Пионерка Гөлчәчәккә хат» исемле поэмасын газетада күрү бәхетенә ирешә алмый. Ул, 1942 елның 20 августына кадәр дәваланып, янә фронтка китә. Бу әсәр исә 30 августта басылып чыга.

Фатих Кәримнең тирән мәгънә һәм бай фикер туплаган шигырьләреннән берсе — «Онытма» исемле әсәре. Ул әдипнең 1979 елда чыккан өч томлыгының I нче томында урнаштырылган. Анда шигырьнең 1942 елның 4 августында язылуы турында искәрмә бирелгән. Чынында исә ул автор тарафыннан шул елның *2* августында иҗат ителгән. Архивтагы кулъязма шуны раслый.

Шагыйрьнең бу әсәрендә колхоз кырларында өлгергән мул игенне вакытында һәм югалтуларсыз җыеп алу турында сүз бара.

Бөек Ватан сугышы елларында тыл фронтны кораллар, азык-төлек һәм киемнәр белән өзлексез тәэмин итте. Фатих Кәримнең «Хәдичә» дигән шигырендә дә (25 октябрь, 1942 ел) гади бер татар кызының сугышчыга перчаткалар җибәрүе тасвирлана. Шагыйрь сөйкемле һәм олы җанлы Хәдичә образын, ул җибәргән бүләкнең сугышчыда ашкынулы хисләр ташкыны тудыруын нечкә лиризм белән гәүдәләндерә.

Ф. Кәрим, Бөек Ватан сугышының төрле участокларында булып, Украинаны, Белоруссияне, Карпатны фашистлардан азат итүдә катнаша. Аның «Днепр ярында», «Днепр дулкыннары», «Без бергә» кебек шигырьләре дә һәркемне дулкынландыра, авторның бөек Җиңүгә тирәннән ышанычын күрсәтеп тора.

1943—1944 елларда Кызыл Армия гитлерчыларга барлык фронтларда көчле һөҗүмнәр ясады, илебезнең күп җирләрен дошманнан азат итте. Бу хәл Фатих Кәрим иҗатына күтәренке рух алып килә. Аның «Кызыл Татарстан»да басылган «Хәнҗәр», «Һөҗүм» шигырьләре — шуңа дәлил.

Нәкъ шушы вакытларда «Фронтовик татарларга татар халкыннан сәлам хаты» языла

һәм ул «Кызыл Татарстан» газетасының 1943 елгы 6 март санында басылып чыга. Хат сугышчыларда фашизмга карата булган нәфрәтне тагын да көчәйтә, Ватан азатлыгы өчен көрәшүчеләрне тиңдәшсез батырлыкка рухландыра. Аңа җавап итеп, фронтлардагы татар сугышчыларының татар халкына хатлары языла, алар да газетада урын ала бара.

Фатих Кәрим дә 1943 елның 31 мартында редакциягә язган хатында «Фронтовик татарларга татар халкыннан сәлам хаты»ны сугышчыларга укуы турында хәбәр итә. «Бу көннәрдә,— дип яза ул,— күп урында татар халкының хатын уку үткәрелде. Бу эшкә мин актив катнаштым. Гомумән, командирларның фикерләре безнең хат турында югары. Алар хатның көчле, әдәби эшләнешле булуын моңа чаклы чыккан хатлардан өстен куялар. Егетләребезгә хат бик көчле тәэсир итә. Хат уку нәтиҗәсендә татар сугышчы егетләр арасында дисциплина һәм сугышчанлык үсүен мин күп кенә командирлардан ишеттем.

Сезгә «Һөҗүм» дигән шигыремне җибәрәм. Мин аны хат уку җыелышында сугышчыларга укыдым. Ошатсагыз, басарсыз...»

Фатих Кәрим 1944 елның октябрь — ноябрь айларында Татарстан Язучылар союзы идарәсенең үтенече белән Казанга кыска вакытлы иҗади командировкага кайта.

Түбәндәге документлар шул хакта сөйли:

«21/X-44 ел.

Жданов исемендәге Ленинград хәрби инженерлык училищесы

Политчасть буенча училище начальнигы урынбасарына

Сезнең училищеда курсант Фатих Вәлиевич Кәримов укый. Ул — татар шагыйре, СССР Язучылар союзы члены. ТАССРның XXV еллыгына әзерләк уңаеннан, Бөек Ватан сугышы геройларының зур образларын тудыру буенча аның яңа иҗади эш планнары бар. Моңардан тыш, Татарстан Язучылар союзы идарәсе Ф. Кәримнең шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итү эшенә керешә, бер томлыгын татар телендә чыгаруны планлаштыра. Шуннан чыгып, Татарстан Язучылар союзы идарәсе Сездән Ф. В. Кәримовка 2—3 айга иҗат отпускасы бирүне һәм аны Татарстан Язучылар союзы карамагына җибәрүне сорый.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе (Г. Кашшаф)»

«4/XI-44 ел.

Казан шәһәре комендантына

Татарстан Язучылар союзы идарәсе Сездән күренекле татар шагыйре, Жданов исемендәге ЛВИУ курсанты иптәш Ф. В. Кәримовның Казан шәһәрендә булу срогын ун көнгә озынайтуыгызны сорый. Иптәш Ф. В. Кәримовның Казанда булуы Ватан сугышы геройкасы темасына язылган һәм ТАССРның 25 еллыгына багышланган әсәрләрен матбугатта бастырып чыгаруга әзерләү һәм тикшерү өчен кирәк.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе (Г. Кашшаф)»

1944—1945 елларда Фатих Кәрим, фронтовик шагыйрь буларак, әсәрләрен Кызыл Армиянең фашист гаскәрләренә җимергечударлар ясаган, гитлерчылардан Көнбатыш Европа илләрен азат иткән һәм дошманны үз оясында дөмбәсләгән шартларда иҗат итә. Шигырьләре дә шушы чор сулышы белән сугарылган. Газетада басылган яки архивта кульъязмасы сакланган «Ачу давылы», «Халык үче», «Безнең урамда», «Казан», «Кемне кызганмыйм», «Немец җирендә», «Оясында» кебек шигырьләре — шундыйлардан.

СССР Оборона министрлыгы үзәк архивындагы документларга караганда, Ф. Кәрим 3 нче Белоруссия фронтындагы сугышларда, Көнчыгыш Пруссияне азат итүдә катнаша. Аның бу чорда күрсәткән батырлыклары турында «Бүләкләү листы»нда мондый юллар теркәлгән:

«Саперлар взводы белән командалык итеп, 1945 елның 21 январенда Гервишкемен районында, Писса елгасы аша күпер салганда, Алленбург шәһәреннән төньяктарак Алле елгасы аша кичү төзегәндә батырлык күрсәтте, ул, дошманның көчле уты астында вакытыннан алда кичүне һәм күперне өлгертеп, шуның белән танкларга, артиллериягә һәм укчы подразделениеләргә уңышлы хәрәкәт ясарга ярдәм итте.

...Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнүгә лаек.
226 нчы аерым сапер батальоны командиры
Майор (Ш а м а н о в).
1945 елның 23 феврале».

Фатих Кәримнең газетада басылган «Немец җирендә» дигән шигыренең ахырына: «Декабрь, 1944, Көнчыгыш Пруссия», дип куелган. Бу әсәр — каһарман шагыйрьнең «Кызыл Татарстан»да басылган соңгы шигыре. Әдип бу юлы да үзенең сугышчан лирикасына тугры булып калган. Ул, авыр сугыш юллары үтеп, фашизм оясына — Берлинга ашыга.

«Оясында» — әдипнең соңгы шигыре. Ул шагыйрьнең һәлак булырына 14 көн кала — 1945 елның 5 февралендә язылган.

Фатих Кәрим гитлерчыларга каршы сугышта батырларча һәлак була. Үлеменнән соң ул икенче орден белән бүләкләнә. «Бүләкләнү листы»на:

«Кече лейтенант Кәримов 1945 елның 11 февралендә Глобунен районында, Пасмар елгасы аша күпер салганда, батырлык күрсәтте,— дип язылган.— Ул саперлар взводы белән командалык иткән хәлдә, дошманның көчле уты астында бозлы суда күпер баганаларын утыртты, шуның белән үзйөрешле артиллериягә хәрәкәт итү өчен булышлык күрсәтте.

Быелның 19 февралендә 37.8 нче биеклекне атакалаганда, кече лейтенант Кәримов батырларча һәлак булды. Үлгәннән соң I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләүгә лаек.
226 нчы аерым сапер батальоны командиры
Майор (Ш а м а н о в).
1945 елның 20 феврале».

Фатих Кәрим ялкынлы иҗатын — якты уй-тойгыларын, ашкынулы омтылышларын изге Ватанына багышлады. Ул «тәвәккәллек, батырлыкка җыр булып калсам иде», дип язды. Аның изге теләге чынга ашты: Фатих Кәрим безнең күңелләрдә сугышчан җырчы буларак мәңге сакланыр.

*
* *

Бөек Ватан сугышы фронтларында батырлык күрсәткән әдипләрдән тагын шагыйрь Нур Баян турында да сөйлисе килә. Ул — татар совет әдәбиятында патриотик әсәрләре белән танылган шагыйрь. Н. Баян лирикасында Һади Такташ традицияләрен дәвам иттерде. Аның иҗатына Муса Җәлил зур бәя бирде. М. Җәлил 1940 елның 7 декабрендә Татарстан язучылар җыелышында сөйләгән докладында:

«Нур Баян — безнең поэзияне «Яңгырлы төн», «Җимерелгән дворец янында» кебек эре поэтик әсәрләре белән баеткан, аеруча политик поэзия жанрын үстерүдә зур хезмәт күрсәткән алдынгы шагыйрьләребездән,— дигән иде.— Нур Баян көчле политик фикерләрне укучыга җитәрлек итеп гади һәм җылы лирика аша бирә ала».

КПСС өлкә комитеты архивында Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Муса Җәлилнең Н. Баянга язган характеристикасы сакланган.

«Иптәш Нур Баян,— дип язылә анда,— партия һәм комсомолның актив работнигы буларак, үзенең иҗатында политик актуаль һәм әһәмиятле проблемаларны тирән тойды һәм үз вакытында яктыртты, шигырьләре белән киң массаны социалистик төзелешкә туплады.

Нур Баянның теле художество ягыннан гади һәм киң массаларга аңлаешлы булуы белән аерылып тора. Бу уңайдан Нур Баян танылган татар совет шагыйре Һади Такташны хәтерләтә...

Нур Баян рус әдәбияты һәм тугандаш халыклар әдәбиятлары классиклары әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итүдә дә күп эшләде. Мәсәлән, Пушкин, Некрасов, Лермонтов, Шевченко, Руставели, Жамбул һ. б.».

Коммунист-шагыйрь гомеренең соңгы көненә кадәр партиябез һәм халкыбызның турылыклы улы булды. Ул, кулына мылтык һәм каләм тотып, Бөек Ватан сугышында дошманга каршы күтәрелде. Янәшәсендә, баш очында снаряд һәм миналар шартлаган хәлдә дә Н. Баян шигырь, очерк, зарисовкалар һәм публицистик мәкаләләр яз-

ды. Аның әсәрләре «Кызыл Татарстан» газетасында беренче булып дөнья күрделәр. Нур Баян да, Фатих Кәрим кебек, Бөек Ватан сугышы елларында поэмалар һәм шигырьләре тупланган «Туган авылым», «Шат җырлар», «Өч беркет» китапларын чыгара.

Ул, фронт газеталарында, рус телендә дә шигырьләр бастыра. Ләкин шагыйрьнең шактый әсәрләре эзсез югалган. Бу хакта ул 1944 елның 2 февралендә Гази Кашшафка язган хатында болай ди: «Миндә соңгы айларда русчага тәрҗемә ителгән шигырьләрем бар иде, подшивкам машинам белән бергә янып китте һәм күп кулъязмаларым һәлак булды, хәерле булсын, барысына да немец гаепле».

Ибраһим Газига җибәргән бер хатында ул: «Йөрәк сызлый. Язасы килә. Ә бомба, снаряд, мина сызгырулары башымдагы барлык уйларны җимереп китәләр»,— дип яза.

Татарстан АССРның үзәк дәүләт архивында шагыйрьнең «Кызыл Татарстан» редакциясенә язган, матбугатта чыкмаган хатлары һәм әсәрләренең кулъязмалары бар. Аның Бөек Ватан сугышы чорында иҗат иткән һәм беренче тапкыр 1941 елның 6 июлендә «Кызыл Татарстан» газетасында басылган «Безнең антыбыз» исемле шигыре күп милләтле совет халкының туган илгә ябырылган фашистларны җиңәчәгенә ышаныч белән сугарылган.

Нур Баян сугышка кадәр дә җыр текстлары язган. Аның сүзләренә композиторларыбыз иҗат иткән җырлар да яңгыраган. Әдип фронтта да бу өлкәдә эшчәнлеген дәвам иттергән. Аның 1941 елның 10 июлендә «Кызыл Татарстан»да басылган «Безнең танкистлар» исемле шигыре — шуңа мисал.

Нур Баянның әсәрләре интернационализм рухында иҗат ителгән. Газетада басылган «... Корыч без сафта» исемле шигыре әнә шуны раслый.

«Кызыл Татарстан» газетасында (1942 ел, 21 январь) басылган «Ленин нәселе» исемле шигырендә әдип, ленинизм байрагы астында совет халкының фашистларны туган илдән куачагына ышанып, партиягә дан җырлый.

Нур Баян журналистика өлкәсендә дә үзен танытты. Ул 1928 елда «Кызыларме-ец» газетасы редакциясендә әдәби сотрудник, 1929—1930 елларда «Колхоз яшьләре» журналының секретаре булып эшли. 1930 елда Чаллы районы газетасы редакторы итеп билгеләнә. Бу эшләр аңа авылдагы яңалыклар белән якыннан танышып барырга ярдәм итә.

Ул, Бөек Ватан сугышының беренче айларында «Кызыл Татарстан» газетасының махсус хәбәрчесе буларак, районнардан редакциягә материаллар җибәреп торган. Аның Калинин районының (хәзерге Актаныш районы) Киров исемендәге һәм «Лена» колхозларыннан җибәргән телеграммасы газетаның 1941 ел, 14 август санында басылып чыккан.

Нур Баян Бөек Ватан сугышы елларында фронтта полк партия оешмасы секретаре, аннары дивизиядә рус телендә чыга торган газета редакторы була. Бу хакта Н. Баян үзе дә Т. Имаметдиновка, Г. Кутуйга, Г. Кашшафка 1942 елның 31 маенда язган бер хатында түбәндәгеләрне хәбәр итә:

«Мин сезгә күптән хат язарга йөрсәм дә, вакыт юклыктан, моңа кадәр яза алмадым. Гафу итегез. Үземнең сәламәтлегем бик яхшы... Дуслар һәм иптәшләр белән тирә-ягым тулы... Командованиедән частьны яхшы оештыруым өчен приказ аша рәхмәт алдым. Үзем редактор булып эшлим. Секретарем — Язучылар союзы члены Михаил Яновский. Әдәби инструкторым — Лозневой дигән политрук. һәрвакыт ярдәмгә килә торган һәм газетага шигырьләр белән катнашучы союз члены Беккер бар (ул клуб начальнигы булып эшли)... Озакламый күптән теләп йөргән урынга китәбез. Ә анда барып, күкрәк белән дошманнарга каршы сугышу — нинди шатлык! Гаять яхшы частька эләгү, командирларның бик яхшы булулары (күбесе сугышта булган кешеләр, часть яхшы сугышчанлыгы өчен гвардия частена әйләнгән) мине шатландыра...

Минем эшем хәзер дә язучылык. Шигырь һәм очеркларым газета саен чыгалар. Шул язучы буларак та мин командованием каршында ихтирам белән файдаланам. Уйлыйм: минем баламны һәм семьямны онытмассыз. Кемнәргә сәлам әйтергә белмим. Бары тик Ибрай Гази һәм М. Әмирләрнең генә армиядә икәнлекләрен беләм. Хат языгыз.

Кайнар сәлам белән Нур».

СССР Оборона министрлыгының үзәк архивында сакланган 78 нче укчы дивизия политбүлеге начальнигы майор Лысогорский Н. Баянга «Бүләкләү лист»ында түбәндәге характеристиканы бирә:

«Нур Галимович Баян — дивизия оешкан вакыттан бирле (1942 елның мае) дивизия газетасы редакторы хезмәтендә. Дивизиянең немец-фашист басып алучыларына каршы сугышчан эшчәнлегендә, Баян «За Родину» газетасын регуляр чыгаруны оештыра, сугышчан заданиеләрне үтәүгә, командирлар һәм сугышчыларның сугышчан батырлыкларын популярлаштыруга бәйле төп мәсьәләләрне газетада һәрвакыт яктыртты. Иптәш Баян, кыюлык күрсәтеп, һәрвакыт частьларда булды, сугышчан хәрби корреспондентлар активы эшен оештырды...

Хөкүмәт бүләге — Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнүгә лаек».

Н. Баян 1943 елның 30 апрелендә Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Фронтовик әдип соңга таба полк командирының политик эшләр буенча урынбасары була. Ул «Кызыл Татарстан» газетасы белән тыгыз элемтәдә тора, әледән-әле редакциягә шигырьләрен, зарисовкаларын һәм публицистик мәкаләләрен җибәреп тора. Татарстан АССРның үзәк дәүләт архивында сакланган, 1942 ел дәвамында язылган «Москва», «Украина кырлары буйлап», «Йөрәктә нәфрәт, ачу ташый», «Майор Әхмәтшин» дигән әсәрләренең кульязмалары — шундыйлардан.

«Украина кырлары буйлап» дигән кульязмада мондый юллар бар: ...Чигебез өстенә кара болыт сыман Гитлер башкисәрләре кереп басканнан соң... синең улларың һәм Ватан сөюче кызларың белән бергәттән, мин дә Кызыл Армия сафына киттем. Мин хәзер шагыйрь дә, сугышчы да...

Соңгы көннәрдә гитлерчы палачлар, шәһәрдә калган ике-өч урам халкын, йорт эченә бикләп, мина белән күтәртәләр. Кая гына карасаң да, Днепропетровск урамында үле гәүдәләр ята.

28 сентябрьдә үзәк урамнарның берсендәге бөтен халыкны гитлерчы бандалар, кырык машинага төяп, еврей каберлегенә илтеп атканнар. Күптән түгел үзәк паркка 15000 ләп халыкны җыйнап, автоматтан ут ачканнар. Бик азлары гына качып үлемнән котыла алганнар.

Бу ерткычлыкларны... немецлар тарафыннан яндырылган завод-фабрикаларны күргәч, йөрәк сызлый, йөрәктә ачу кайный. Гүя мин кан арасында йөзәм, ачы нәфрәт ялкыны астында язам мин бу юлларымны».

Фронтовик әдип 1943 елның 12 октябрендә «Кызыл Татарстан» газетасының җаваплы редакторы Ибраһим Узбековка язган хатында болай хәбәр итә: «Мин сиңа юл истәлекләремне җибәрәм. Сиңа, әлбәттә, хат язу кыендыр, вакыт тапмавың мөмкин. Әгәр вакыт тапсаң, нинди материаллар кирәклеге турында хат яз. Вакыт тапсам, язармын. Әгәр газетада урнаштырмасаң, «Совет әдәбияты» журналына бир. Алар бәлки урнаштырырлар.

Үзем хәзергә сәламәт. Украина буйлап алга барабыз. Немецларны дөмбәслибез. Әгәр кызыксындыра торган булса, Запорожье турында язармын. Җавап көтәм...

P. S. Кабат күчереп торырга вакыт юк, беләсең, окоп шартларында язарга туры килә. Карап басарсыз».

Н. Баян Татарстан Язучылар союзына 1944 елның 26 февралендә җибәргән икенче бер хатында сугышта яралануын хәбәр итә.

«Иптәш секретарь! (Кем икәнен белмим)

Госпитальгә керү уңае белән, авыр булса да, язарга мөмкинлек таптым. Язган ике шигыремне («Хат», «Илем, сиңа») Сезгә җибәрәм. Кайда басарга яраклы табасыз, анысы — сезнең карамакта. Үзем, Румыния аша үтеп, Венгриягә килеп бастым. Берлинга таба барабыз. Адресымны госпитальдән чыккач җибәрәм.

Хәзергә сәлам белән Нур».

Хат почмагына «Җавап язылды. М. Әмир» дигән тамга куелган.

Без Нур Баянның «Майор Әхмәтшин» дигән фронт язмасы белән таныштык. Автор анда элек байда батрак булып эшләгән, Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң югары уку йортында белем алу бәхетенә ирешкән һәм Бөек Ватан сугышында командир булган майор З. Әхмәтшинның яу кырында күрсәткән батырлыгын тасвирлый.

Нур Баян 1942 елның июленнән алып шул ук елның 1 октябрена кадәр — Калинин,

аннары 1943 елның ноябрена хәтле Көньяк-Көнбатыш, шуннан соң 2 нче Украина фронтларында сугыша. Бу хакта аның «Бүләкләү листы»нда да әйтелә: «1944 елның 22 сентябреннән Венгрия территориясендә һөҗүм сугышлары вакытында майор иптәш Баян полкның сугышчан подразделениеләрендә еш булды, үзенең шәхси үрнәге белән сугышчыларны батырлыкларга рухландырды. Мәсәлән, 1944 елның 16 октябренда Береттьо-Уйфалу шәһәре өчен сугышта роталарда булып, шушы шәһәр өчен сугышчыларны атакага алып барды һәм алар белән беренче булып, калага бәреп керде.

...Майор Баян, полк парторгы булганда, кыска вакыт эчендә ВКП(б) члennары һәм членлыкка кандидатларның гомуми санына карата полк партоешмасы 25 процентка үсте.

Майор иптәш Баян хөкүмәт бүләгенә — I дәрәҗә Ватан сугышы орденына тәкъдим итүгә лаеклы.

464 нче укчы полк командиры.

Майор (Савельев).

1944 елның 31 октябре».

Әдип Нур Баян — сугыш елларында подполковник дәрәҗәсенә кадәр үсә. Ул әле Бөек Ватан сугышы башланганчы ук, әдәби эшчәнлеге өчен, «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. Фашистларга каршы көрәштә исә ул I дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнарына һәм медальләргә лаек була. Нур Баян дошманны үз оясына куып керткән көннәрдә — 1945 елның 23 апрелендә Австриядә сугыш Альп тауларында барган чакта батырларча һәлак булды.

Фатих Кәрим һәм Нур Баян — коммунистик идеяләр белән рухланган һәм бөек Җиңүгә тирәннән инанган шагыйрьләр иде. Аларның утлы көннәрдә иҗат иткән әсәрләре әдәбиятыбызның иң якты сәхифәләрен тәшкил итәләр.

................

**БерСОРАУГА — БерЖАВАП**

**Сорау:**

— Соңгы еллар әдәбиятында Сезне нинди сыйфатлар куандыра, ә ниндиләре уйландыра?

**Хатип Госман,** филология фәннәре докторы, профессор:

— Прозада тормыш күренешләренең үзенчәлекләрен нечкәләп күрү, сизү һәм аларның сурәтен сүзгә күчерү осталыгы шактый үсте. Аерым художникларның үзләренә генә хас стиль хасиятләре җитлегә төште. А. Расихның әсәрләре, мәсәлән, кырыс тел белән язылган. Кайчакта ул публицистикага авышып киткәндәй була. Ләкин бу — сурәтле тел. Аның кырыслыгы уңай эш эшли: әсәрнең эчке һавасына киеренкелек кертә, укучыда алда булачак вакыйгаларны тизрәк белергә теләү сабырсызлыгын үстерә. Н. Фәттахның тасвиры — киресенчә. Сабыр. Әсәрен укыганда авторның укучы хыялында туган сурәте уйчан булып, тасвир ителгән кешеләрнең язмышлары турында бик тә хәсрәтләнеп, уйланып утырган рәвештә күз алдына килә. Бу сурәт әсәрнең бөтен барышына кешелекле моң сирпи. Бүтән әдипләрнең стильләрендә дә бик әйбәт сыйфатлар бар...

Теләк әйтү мәсьәләсенә килгәндә, мин болай дияр идем: әсәрләрдә философик хасият тирәнрәк булса иде. Художник үзенең чын байлыгын талант көче белән философик идеяләре тирәнлеге тиң килгәндә генә тулысынча күрсәтә ала. Философик тирәнлек аның эстетик идеалына бөеклек өсти, тормыш күренешләрен гомумиләштергәндә аларны эре күләмнәргә күчереп тасвирлау юлларын ача.

Тукайның 100 еллыгына

# КАЗАНДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ

Нечкәләп баксаң, бу күлнең бар бугай шигърияте,
Бар кеби милләт хыялында аның сиррияте.
Бервакытлар мин сузып анда Кисекбашның җебен,
Бер төшеп мендем, бөтенләй тикшереп, бактым төбен.

Г. Тукай. «Казан вә Кабан арты». 1912.



Татьяна Зуева рәсеме

Мәшһүр Кабан күле

**Рәфыйк Нәфиков,**
тарих фәннәре докторы, профессор

# ТУКАЙНЫҢ ИПТӘШЛӘРЕ ҺӘМ ТАНЫШЛАРЫ

Тукай әдәбиятка 1905 ел белән килеп керде. Төп хәрәкәтләндерүче көче пролетариат булган беренче рус революциясе аның өчен дә азатлык таңы иде. Тукай шул таңның сандугачы, шагыйре булды, революционерлар белән аралашып, үзе дә бу бөек эшкә хәленнән килгәнчә өлеш кертте.

Бу кечкенә генә мәкаләдә без Тукай биографиясенең кайбер мөһим якларына кагылып үтәбез. Тагын да тулырак мәгълүматларны укучы матбугатка әзерләнгән «Тукай һәм аның даирәсе» исемле китаптан табар.

1905 елның ноябренда Уральскида чыга башлаган «Фикер» газетасы сәхифәләрендә татар, казах һәм әзербәйҗан шагыйрьләренең исемнәре еш күренә. Алар арасыннан Тукай әзербәйҗанлы А. Сабир шигырьләрен аерып күрсәтә һәм аның шундый эчтәлекле юлларын китерә:

*Күктән бер фәрештә гаҗәпләнеп әйтәдер:*
*кешеләр, кешеләр!*
*Нигә бу җир йөзен ал каннар каплый,*
*кешеләр!*

Сабирның шигырьләрен эмоциональ, «күңелләр өчен бик кыйммәтледер» дип бәяләп, Тукай авторга яңадан-яңа шигъри уңышлар тели («Фикер», 1906, 19 ноябрь, 43 сан).

Ике татар шагыйрәсе — Газизә Шәрипова һәм Мәһирә Шакирҗанованың газетада чыгыш ясый башлауларына да Тукайның өлеше бик зур. Алар тирән эчтәлекле шигырьләре белән казах хатын-кызларына мөрәҗәгать итәләр («Фикер», 1906, 29 октябрь, 14 декабрь саннары).

Тукай Уральскида Укытучылар институты ачу эшендә зур тырышлык күрсәтә, җәмәгатьчелек вәкилләрен бу мәсьәләгә багышланган җыелышка чакыра.

Вакыф[1] средстволары нәрсәгә сарыф ителә дип, Диния назаратына запрос белән җибәрелгән хатка кул куючы 40 кешенең алтынчысы булып Тукайның фамилиясе теркәлгән («Фикер», 1906, 1 октябрь, 36 сан). 1906 елның 24 сентябрендә язылган бу хатта, җыелган акчаларны һәм шулай ук вакыф малларын ачылачак Укытучылар институты фондына күчерү таләп ителә.

Бу Тукай биографиясенең әлегәчә яктыртылмаган бер сәхифәсе. Гадәттәгечә, ул бу эшкә бөтен күңелен биреп керешә, шигъри талантын да эшкә җигә.

1906 елның 1 октябрендә «Казан» кунакханәсендә булган җыелышны тасвирлаганда, Тукай, булачак Укытучылар институты өчен бер мең сум акча бирәм дип игълан иткән К. Төхфәтуллинның исемен аерып күрсәтә, хулиганлык өчен полиция тарафыннан җыелыштан чыгарылган миллионер Х. Гаделшинны да искә ала, институт ачуны яклап чыккан укытучысы Ә. Сиражетдиновны һәм Гомәр хәлфә Хөсәеновны да онытмый («Фикер», 1906, 6 октябрь, 37 сан). Корреспонденциянең үзәгендә Г. Тукайның Ф. Шәрипов белән Укытучылар институты ачуга каршы чыгып, «безгә иске мәдрәсәләребез дә җитә, башка берни дә кирәкми» дип чыгыш ясаган байгура белән бәрелешен сурәтләү тора. Г. Тукай аңа тирән сарказм аша һәм антик әдәбиятның иң яхшы үрнәкләренә тиңләшерлек җавап бирә:

— Юк, Фатих абый! Безнең ул мәдрәсәләремез генә җитми, башка милләтләрдәге кеби безгә дә 3—4 этажлы мәдрәсәләр кирәк. Син, Фатих, әле күптән түгел генә ярлы идең, син шул ярлылыгым җитәр дип тормадың, кибет ачтың, сәүдә иттең, һәр ничек баерга тырыштың. Инде мәдрәсә ачу хосусына килгәндә җитәр дип әйтәсең, вә хәләнки мөселман кешегә милләт файдасын, үз файдасыннан өстә тотарга кирәк. Юк, җитмәс, җитәр дип әйтмә, безнең мәдрәсәләремез руслар мәдрәсәсе-

[1] Вакыф — берәр кеше яки җәмәгать тарафыннан мәдрәсә, мәчет һ. б. тоту өчен бирелә торган акча яки мал.

нең тәһарәтханәсендән дә шакшырак. Китәбез, алга китәбез, канәгать итмибез бу мәдрәсәләргә: син, Фатих абый, тәрәкъкыйга каршы килмә, әгәр анаң сине тугач та углымның шул буе да җитәр әле дип сине бер карыш озынлыгы тимер сандыкка салып үстерсә, яратыр идеңме?

Җыелыштагы халык алдында «стенага терәлгән» Ф. Шәрипов Укытучылар институты ачу идеясе белән килешергә мәҗбүр була. Тукайның үткен тәнкыйть сүзләренә ул җавап тапмый, ләкин ничек булса да зәһәрен чыгармыйча түзә алмый: «Ярый, ярый алайса, дарелмөгаллимин[1] ачылыр, ләкин ул ачылгач, аның эчендә Габдулла Тукаев шикелле редакциядә хезмәт итүчеләр ятмасыннар»,— дип кычкыра («Фикер», 1906, 6 октябрь, 37 сан).

Гадел һәм туры Тукай газета битләрендә шундый ачыктан-ачык дошман фикерләргә дә урын бирә. Бу факт кәрәшнең нинди кискен төстә барганлыгын сөйли. Монда инде мөгърифәтчелек рухындагы үгет-нәсихәткә урын юк. Безнең алдыбызга шулай ук критик реализм принципларыннан чыгып кына да аңлатып булмый торган тормыш чынбарлыгы килеп баса.

Уральскида Укытучылар институты ачу идеясен күтәреп чыккан егерме яшьлек Тукай, бу мәсьәләне газета битләрендә даими рәвештә яктыртып бара, ачылырга тиешле институт фондына средстволар җыю эшен оештыра, ярдәм сорап башка газета редакцияләренә мөрәҗәгать итә. Бу мәсьәләгә кагылышлы җыелышларга якынтирәдәге авыллардан казахларны да тартырга тырыша, чын күңеленнән шатланып, газета укучыларга, Ф. Хәмидуллинның ачылачак Укытучылар институты өчен «Казан» кунакханәсе бинасының яртысын бирергә булуын хәбәр итә («Фикер», 1906, 15 октябрь, 38 сан).

Тукай биографиясен тулыландыручы яңа фактлар, кайчакта көтелмәгән җирдән табыла. Мәсәлән, В. И. Ленин белән 1887 елның 4(16) декабрь сходкасында катнашкан Казан большевигы В. А. Перимовның Дәүләт думасы депутаты П. Ершов исеменә, Ю. Лапинаның кулга алынуы турында язган хаты, һәм шул уңайдан 31 депутатның Эчке эшләр министрлыгына запросы шагыйрьгә билгеле булган дип кем уйлаган?! Ә бер тарихи факт моңа уңай җавап бирергә мөмкин ди. Чөнки бу запроска кул куючылар арасында Уральск депутаты Недоносков та бар, ә аның отчетын тыңлаучылар арасында Тукай да булган. Димәк, әлеге хакта ул да белгән.

Тукай Хвалын өязе татар крестьяннарының Дума депутаты трудовик С. Аникинга (милләте буенча мордва) мөрәҗәгатен дә белгән ди алабыз. Чөнки бу турыда укытучы большевик В. Серов белән киңәшләшеп телеграмма җибәрүнең инициаторы З. Бәхтияров булган[2]. Ә ул исә В. Бәхтияровның туганы. Мондый фактлар турында «Фикер» газетасында Тукайның дусты Әхмәтсафа Байтирәков язып чыга.

«Таң йолдызы» газетасы редакциясендә политик сәбәпләр аркасында Себергә сөрелгәннәр фондына акча җыялар һәм Петербургка, Недоносков белән бергә запросларга кул куючы Дума депутаты Г. Ульянов исеменә җибәрәләр[3]. Билгеле булганча, Тукай бу газетаның даими укучысы һәм язышучысы иде. Димәк, ул да бу хәлләрдән хәбәрдар булган. Бәлки әле үзе дә аз-мазлап булса да акча җибәргәндер.

Тукай Казанның революцион түгәрәкләрендә катнашучы Б. Каратаевның кардәше, М. Каратаев белән элемтә тоткан[4].

Тукайның танышы, Уральск хәрби реаль училищесының укучысы И. С. Кашкинбаев, социал-демократларның укучылар оешмасына кергән Е. Ларин һәм Бенияминович белән таныш була. Алар белән элеккеге «Уралец» газетасы редакторларының берсе С. Меликовның (Меликянц) улы — М. С. Меликов та аралашкан. И. Кашкинбаев менә шул Меликовлар фатирында яшәгән була[5]. 1910 елда Казан университетының медицина факультеты студенты булган һәм Ямашевлар квартирына килеп йөргән И. Кашкинбаев белән Тукай Казанда да очрашкан.

«Фикер» газетасының 1906 ел 3 сентябрь санында басылган «Уральскида Дума членын вә табигын[6] нагайкалау» дигән корреспонденциянең текст үзенчәлекләрен

---

[1] Дарелмөгаллимин — ирләрдән укытучылар хәзерли торган уку йорты.
[2] Саратов өлкәсе дәүләт архивы, 1 ф, 1 тасв., 7079 эш, 140—141 битләр.
[3] ТАССР үзәк дәүләт архивы, 199 ф, 1 тасв., 2638 эш, 21 б.
[4] Шунда ук, 199 ф, 1 тасв., 7 эш, 57 б.
[5] Октябрь революциясенең үзәк дәүләт архивы, ф. ДП, 1909, 5 эш, 77 бүлек, А бит; 13 бит; ТАССР ҮДА, 199 ф, 1 тасв., 1692 эш, 295 бит
[6] Табигъ — иярүче, бер әүнең артыннан баручы.

һәм шулай ук шагыйрьнең Дума депутаты белән икенче очрашуы турында язарга ышандыруын искә алганда, авторы һичшиксез Тукай булган дип әйтә алабыз.

Рәхимсез чынбарлыкны тасвирлаганда Тукай юмористик алымнардан качмый. 27 августта Уральск халкы нагайканың нәрсә икәнен газеталардан гына түгел, ә үз җилкәләрендә татып белделәр дип хәбәр итә ул. Шагыйрь каләме монда да ачы хакыйкатькә тугрылыклы булып кала. Хәрби губернатор җитәкчелегендәге казаклар, полицейскийлар һәм жандармнар депутатның отчетын тыңларга дип чәйханәгә җыелган халыкны, иң элек бина эчендә, аннары баскычта, шуннан соң урамда кыйнадылар дип хәбәр итә «Фикер» сәхифәләре. Бу кыйнашта патша ялчыларына булышкан өчен 1 сум 20 тиен акча алган һәм шуның белән шапырынган һәртөрле адәм актыклары да катнаша. Мескен «халык» каршылык күрсәтергә уйламый да. Закон буенча «кагылгысыз шәхес» дип исәпләнгән, кыйналган депутатны төрмәгә озаталар.

Бу елларда революцион вакыйгаларга битараф калып булмаган. Революция, В. И. Ленин әйткәнчә, нейтральләрне танымый[1]. Тукай да бу эштән читтә калмаган.

1905 елның 1 маенда Г. Тукай җаеклыларның ял итү урыны — Ханская рощага килә, газета репортажына караганда, бу урын ул көнне ял итүче халык белән тулган була. «Маевка»ны зур кампанияләр, җыр һәм музыка белән үткәрәләр. «Уральский листок» газетасы 1 майны Венада, Будапештта, Цюрихта, Римда, шулай ук Бельгиядә, Германиядә бәйрәм итү турында хәбәр итә. Корреспонденция «1 Май бәйрәме беркайчан да үлмәячәк, бу бәйрәмнең әһәмияте эшчеләр хәрәкәтен рухландыручы идеяләрнең таралуы белән арта барачак» дигән раслау белән тәмамлана («Уральский листок», 1905, 5 май, 33 сан). Шушы ук газета Казанда үткәрелгән 1 Май бәйрәме турында да хәбәр итә («Уральский листок», 1905, 15 май, 36 сан). Бу корреспонденциянең эчтәлеге соңыннан «Пролетарий» газетасында (1905, 17 (3) июнь, 4 сан) дөнья күргән материалларга якын тора.

1905 елның азагында Г. Тукай турыдан-туры социал-демократик өндәмәләр тарату эшенә тартыла. Типографиядә социал-демократларның ячейкасы оештырылган була. Тукай большевиклар белән аралашып, тыелган әдәбият укылган җыелышларда катнашкан. Бу турыда безгә типографиянең элеккеге эшчесе, безнең елларда КПСС члены А. К. Гладышевның сөйләгәне һәм хатта да язганы бар. Шул ук сүзләрне үзенең абыйсы, эшче-большевик Гариф Кальтиевтан ишетеп калган Габдрахман ага Кальтиев та яза[2]. К. Төхфәтуллин истәлекләрендә дә Тукайның большевиклар белән дуслыгы искә алына[3]. Большевиклар чыгыш ясаган митингларда һәм җыелышларда булуын шагыйрь «Фикер»дәге корреспонденцияләрендә үзе дә әйтеп үтә.

Тукай Уральск большевикларыннан кемнәрне белгән соң?

Беренче чиратта ул оста хәреф җыючы, яшьләрнең остазы А. А. Кокановны (1881—1935) күреп белгән, дәресрәге аның белән дустанә мөнәсәбәтләрдә булган. Большевик А. А. Коканов партиянең Таммерфорсс конференциясенә бара, В. И. Ленин белән очраша, эшчеләрне сыйнфый көрәшкә әзерләүдә күп көч куя. Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң ул партия һәм совет эшендә була, берара типография директоры булып та эшли.

Шагыйрь митингларда Н. И. Шилованы да тыңлаган (ул 1981 елда Мәскәүдә үлә, укытучы булып эшләгән).

Стачкалар оештырган өчен берничә тапкыр типографиядән куылган А. М. Сенькин да (1885—1943) большевиклар партиясе члены була. Совет власте елларында ул типографиядә җитәкче постларда эшли. Газетаны версткалаучы (биткә салучы) булып шулай ук большевик П. П. Зуев эшләгән: соңыннан ул бухгалтер була, 1938 елда үлә. Большевик И. Д. Хвостов — шулай ук типографиядә хәреф җыючы булган. А. К. Гладышев мәгълүматларына караганда, ул 1910 елда Оренбургта үлгән.

Ике татар эшчесе — Казаннан килгән Сафа Насыйбуллин һәм уральскилы большевик Гариф Кальтиев (1882—1940) шагыйрьнең якын дуслары булып киталар. Алар татар телендә листовкалар, өндәмәләр бастыруны оештыралар һәм аларны Светколов,

---

[1] Ленин В. И. Әсәрләр. 9 т. 197 б.
[2] Карагыз: Кальтиев А. Первые маевки в Уральске.— «За педагогические кадры» газетасы, Уральск, 1961, 17, 18 саннар; Революция мәктәбендә.— «Социалистик Татарстан», 1961, 21 апрель, 95 сан
[3] Төхфәтуллин К. Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатираләрем. Казан, 1914.

Борнаев кебек сәүдәгәрләрнең тире эшкәртү предприятиеләре эшчеләре арасында тараталар.

Тукай сәүдәгәр Додоновның кирпеч заводында да булган, анда эшләүче рус һәм татар эшчеләренә үзенең журналларын, шулай ук тыелган әдәбият тараткан [1].

Яшь эшчеләр белән бергә Тукай революцион басмаларны шәһәр халкы арасында таратуга да катнаша. Мәсәлән, 1906 елның 20 августында булган митинг вакытында ул А. Гладышев, К. Исаевлар белән бергәләп «Карт вахмистр» листовкасын, «Варшавянка» җырын таратып йөри. Бу листовкаларда революционерлар казакларны һәм солдатларны баш күтәргән эшчеләргә атмаска, «опричниклар» булмаска өндиләр [2].

Тукайның тимер юлда эшләүче большевик танышы Н. А. Покатилов: «Большевиклар тимер юлчылар, механик мастерскойлар, эчәк эшкәртү заводы эшчеләре арасында революцион эш алып бардылар, түгәрәкләр оештырдылар, лекцияләр укыдылар, өндәмәләр, листовкалар тараттылар»,— дип искә ала [3].

Социал-демократ Д. Колотилин белән Тукай һәм К. Төхфәтуллин «Яңа тормыш» исемле газета чыгару турында килешү дә төзиләр. «Фикер» газетасы битләрендә искә алынган социал-демократ М. А. Мандрыкның Пушкин йортында сөйләгән лекцияләрен Тукай да тыңлаган булырга тиеш («Уралец», 1905, 21 октябрь, 217 сан).

Тукай революцион җырларны — пролетариат гимнын, «Варшавянка»ны яратып башкарган. «Уральскида хөррият бәйрәме» мәкаләсендә ул 1906 елның 20 августында булып үткән митингны һәм демонстрацияне тасвирлый, халыкның революцион җырлар башкаруын махсус билгеләп үтә [4]. Революцион җырларның образлылыгы, аларның нигезе чергән иске җәмгыятьне кискен рәвештә кире кагуы шагыйрь күңеленә хуш килә. Тукайның күп кенә үз шигырьләре дә халык җырларына әверелде.

Тукай мәкаләләре царизмның халыкка каршы политикасын фаш итә, буржуаз милләтчелек идеологиясен кире кага.

Туры сүзе өчен дошманнар шагыйрьдән үч алалар, төрлечә эзәрлеклиләр, донослар язалар.

1906 елның 4 маенда кадимче руханиларның куштаннары «Әлгасрел-җәдит» һәм «Фикер» басыла торган типография күршесендәге бинага ут төртәләр. Көн җилле була, ә янгын сүндерү командасы бик соңарып килеп җитә. Көндезге сәгать 3 тән кичке 8 гә кадәр янгын алты йортны ялмап ала. Тукай һәм аның дуслары типографиянең машиналарын, җиһазларын саклап калалар. «Фикер»нең чираттагы саны чыгуы тоткарлана («Фикер», 1906, 8 май, 17 сан).

Шул ук елның июлендә погромчылар типографиягә һөҗүм ясарга уйлыйлар, ләкин эшчеләр бу хәлне булдырмый калалар.

«Бәянелхак» рухландырып торган Уральск карагруһчылары һәм милләтчеләре 1906 елның 15 август төнендә К. Төхфәтуллинның квартирасына бәреп керергә уйлыйлар, аларга редакторны, аның балаларын һәм шулай ук Тукайны үтерергә кушылган була («Фикер», 1906, 18 август, 31 сан).

Реакция алдында баш имәгән Тукай 1907 елның мартында «Әлгасрел-җәдит» журналының 3 санын чыгарып: «...Без бәян итәбез ки «Әлгасрел-җәдит»не... һаман да дәвам иттерәчәкмез. Без Уральск шәһәренең кояшларын сүндереп, халкын караңгыда калдырып адаштырырга кулымызда аз гына бер икътидар [5], тәнемездә җан бар вакытта асла разый булмаячакмыз. Безнең мәйданымыз милләт каһарманнарының мөбарәзәсе [2] өчен ачыктыр. Килсеннәр ул шанлы вә намлы каләмнәрен уйнатсыннар! Әйдәгез, брадәрләр! [4] Языңыз, языйк, таратыйк... нур сачыйк, нурланыйк...» дип язып чыга. («Әлгасрел-җәдит», 1907, 3 сан, 116 бит).

Югарыда кыскача әйтеп үтелгән фактлар Тукай биографиясен шактый тулыландыралар. Алар шулай ук Уральск социал-демократлар оешмасы тарихының кайбер сәхифәләрен дә җанландырып җибәрәләр.

---

[1] А. К. Гладышевның бу юлларның авторына язган хатларыннан (31 декабрь, 1953 ел; 31 январь, 1954 ел), авторда саклана.
[2] А. К. Гладышевның 1954 елның 28 маенда язылган хатыннан: авторда саклана.
[3] Н. А. Покатилов истәлекләре Уральск өлкәсе музеенда саклана.
[4] Тукай Г. Әсәрләр. Дүрт томда. 3 т. Казан, 1976, 151 б.
[5] Икътидар — көч.
[6] Мөбарәзә — бергә-бер чыгып сугышу.
[7] Брадәр — ир туган, дус, иптәш.

*КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы карарларын — тормышка!*

**Камил Фасеев,**
философия фәннәре докторы, профессор

# БОЛГАНЧЫК ДУЛКЫН

## (Капитализмның рухи кризисы)

Узган гасыр уртасында ук, «Коммунистлар партиясе манифесты»нда К. Маркс һәм Ф. Энгельс буржуаз җәмгыятьнең таркала бару процессының һаман тизләнүен билгеләп үтеп, аның һәлакәте котылгысыз булуын, аны социализм белән алыштыру зарурлыгын алдан күрсәткәннәр иде. Шуннан соң үткән вакыт фәнни коммунизмга нигез салучыларның алдан күрүен тулысынча раслады.

Хәзер кешелек алдында торган юл бер генә — социализм. Кешелекнең өчтән бер өлешеннән күбрәге җиңүләр яулап шул юлдан бара. Барлык халыклар да котылгысыз рәвештә шул юлга басачак.

Капиталистик системаның юкка чыгу куркынычыннан, хезмәт ияләренең демократик һәм революцион хәрәкәте үсүдән, социализмның һаман үсә һәм ныгый баруыннан коты алынган буржуазия үзенең какшаган позицияләрен ныгыту, халыкларның социализмга омтылышын буу өчен әллә ниләр кылана. Ачыктан-ачык ирексезләү методларыннан тыш ул хезмәт ияләренә рухи һөҗүм ясау өчен үз кулындагы идеология чараларыннан, шул исәптән яман аты чыккан «массовый» культурадан да киң файдалана.

Капиталистик илләрнең хаким сыйныфлары халыкларның прогрессив үсешендә алдынгы культураның нинди зур роль уйнавын, дөньяга дөрес фәнни карашның рухландыру һәм туплау көче никадәр зур икәнлеген аңлыйлар. Шунлыктан алар демократик культурага каршы барлык чаралар белән көрәшәләр. Культура исеме астында массаларга рухи агу тәкъдим ителә. В. И. Ленин «Артта калган Европа һәм алдынгы Азия» дигән мәкаләсендә әле 1913 елда ук болай дип язган иде: «Цивилизацияле һәм алдынгы Европада, бик нык алга киткән техникалы, бай һәм һәрьяклы культуралы һәм конституцияле Европада, шундый тарихи момент килеп җитте ки, хакимлек итүче буржуазия, үсеп һәм ныгып бара торган пролетариаттан куркып, бөтен артта калган, үлеп бара торган урта гасырчылыкны яклый. Гомерен кичерүче буржуазия, какшый башлаган яллы коллыкны саклап калу өчен, гомерен кичергән һәм кичерүче бөтен көчләр белән берләшә» (Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә. 19 том, 81 бит).

Кайчандыр, феодализмга каршы көрәшкән чорда буржуазия культура прогрессына булышлык иткән булса, хәзер культураның элек булган демократик элементлары турында искә төшерү дә аңарда ярсулы ачу уята. Буржуазиянең экономик һәм политик тәрәкләре антигуманистик характер алгач, ул котылгысыз тирән рухи паралич кичерә. Халыкның да шактый өлеше шушы паралич корбаны булсын — капиталның идарәче даирәләре әнә шуңа омтыла. Шунлыктан хәзерге буржуазиянең культура үсешендәге иң яхшы, иң кыйммәтле бөтен нәрсәне яманлавы, бозып күрсәтүе, үткәндә булган бөтен тискәре, реакцион нәрсәләрне күтәреп чыгуы һич гаҗәп түгел.

АКШта күптәннән инде культурага каршы котырынкы поход игълан ителде. Кеше-

лек Америка реакциясенең 1915 елда мәшһүр пролетариат җырчысы Джо Хиллне үтерүен, танылган опера җырчысы Мэй де Сузаның ачлыктан үлүен бервакытта да гафу итмәс. Капитал сакчылары «чикләнмәгән азатлык иле» дип күрсәтергә тырышкан АКШтан атаклы композитор Ганс Эйслер «рус стилендәге моңлы музыка язган» өчен генә куыла. Анда бөек художник Чарли Чаплинга күп еллар буена көн күрсәтмиләр, аның фильмнарын тыялар, ахыр чиктә Европага күчеп китәргә мәҗбүр итәләр. Җырчы Поль Робсон каһәрләнә һәм өендә бикләнеп утырырга мәҗбүр ителә. 1978 елның ноябрендә Америка властьлары танылган җырчы, актер һәм режиссер, тынычлык һәм гражданлык хокуклары өчен батырларча чыгыш ясаучы Дин Ридны кулга алалар һәм төрмәгә ябалар. «Безнең кулга алыну, дип белдерде Дин Рид, АКШ конституциясе тарафыннан формаль төстә гарантияләнгән, ә чынлыкта властьлар тарафыннан салып таптала торган матбугат, җыелышлар ирегенең, башка ирекләр турындагы сүзләрнең Америкада ни бәягә торуын тагын бер мәртәбә күрсәтте».

Башка капиталистик илләрдә дә алдынгы культура эшлеклеләрен Америкадагы ирек буучылар үрнәгендә һәм катнашында эзәрлеклиләр, юк итәләр. Мәсәлән, Төркия палачлары язучы Сәхәбетдин Алины яшерен рәвештә үтерделәр. Назыйм Хикмәт ун ел төрмәдә газап чикте. Грециядә талантлы шагыйрь Дмитрий Лагос һәм яшь галим Кристос Карамбелас атып үтерелде. Испания фашистлары трибун шагыйрь Гарсия Лорканы үтерделәр. Гватемаланың 27 яшь патриоты белән бергә полиция подвалларында 23 яшьлек шагыйрь Рене Кастильо газаплап үтерелде. Аларның үле гәүдәләрен самолеттан Тын океан суларына ташладылар. Чили хунтасы йөзләгән культура эшлеклеләренең, шул исәптән җырчы Виктор Хара, бөек шагыйрь Пабло Неруданың башына җитте. Көньяк Корея шагыйре, «Лотос» премиясе лауреаты Ким Чжи Ха озак еллар якты күрмичә төрмәдә яткырыла.

Буржуазия культураны табыш алу чарасына әверелдерде, шуңа күрә аны «акча культурасы» дип атыйлар. Романнар, поэмалар, рәсем сәнгате, театр, фән, музыка культура байлыклары итеп түгел, бизнес итеп, акча эшләү чарасы итеп карала. «Капиталистларның культурасы, дип яза М. Горький, алдый торган мәктәп, алдый торган чиркәү, шулай ук алдый торган парламент, алдый һәм яла яга торган пресса, аларның культурасы — эшчеләрне кыйнарга һәм үтерергә хокук бирелгән полиция». Бөек язучының бу сүзләре бүген дә актуальлеген югалтмый.

Империализм ялчылары агуны дәва дип күрсәтмәкче булалар, үзләренең әшәке, күңел кайтаргыч «әсәрләрен» культура дип атауда дәвам итәләр, аларның реакцион асылын яңа форма, яңа «изм»нар белән пәрдәләмәкче булалар, шуларның һәммәсен «массовый культура» дип исемлиләр. Әмма, ничек кенә төс үзгәртмәсеннәр, бу әлеге дә баягы шул иске һәм черек нәрсәнең чагылышы, кайчандыр Герцен бик хаклы рәвештә әйткәнчә, «төсе киткән биттәге сифилитик тапларны яшь егет алсулыгы итеп күрсәтергә» маташу.

Буржуазия рәссамны, язучыны, журналистны, артистны — һәммәсен дә монополияләрнең ялланган колы, реакция хезмәткәрләре итәргә омтыла. Хәзерге капиталистик дөнья К. Маркс һәм Ф. Энгельсның «Коммунистлар партиясе манифесты»нда язган түбәндәге сүзләрен тулысынча раслый: «Буржуазия эшчәнлекнең хәзергә кадәр хөрмәтле дип саналган һәм ниндидер изге нәрсә итеп каралган барлык төрләрен изге нурлардан мәхрүм итте. Врачны, юристны, дин башлыгын, шагыйрьне, фән кешесен ул үзенең түләүле яллы хезмәтчесенә әверелдерде» (К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр, 4 том, 427 бит). Ә моның белән килешергә теләмәүчеләр иҗат итү хокукыннан мәхрүм ителә, эзәрлекләнә.

Реакцион буржуазия, имеш, культура эшлеклеләре, «ирекле», политикага, сыйнфый интересларга «бәйсез» дигән легенда тарата. Әмма бу ялганның фаш ителгәненә биш былтыр инде.

Әсәрләре халыкка барып җитмәгән һәм капиталист әфәнделәргә күңел ачу өчен генә хезмәт иткән композитор, язган нәрсәләрен буржуаз пресса хуҗалары реакция файдасына борып, бозып чыгара торган журналист азат була аламы соң? Коллык һәм эксплуатация законнарына буйсынган бер интеллигент та ирекле була алмый. «Буржуаз язучының, художникның, актрисаның азатлыгы,— дип күрсәтте В. И. Ленин «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» дигән мәкаләсендә,— пәрдәләнгән (яки

риячыл пәрдәләнә торган) бәйлелек, акча капчыгына, сатып алынуга, сәяркәлеккә бәйлелек кенә ул».

Хәзерге Көнбатышның «массовый культурасы», табыш алудан тыш, мәгълүм сыйнфый-политик максатка — бөтен халыкны гамәлдәге капиталистик тәртипләргә карата килешүчәнлек рухында эшкәртүгә юнәлдерелә. Массовый культура сәнгать функцияләрен башкарудан ерак тора. Ул фикер йөртүгә, кичерешкә түгел, иң элек күңел ачуга юнәлеш тота. Ә күңел ачу сүрүенә төрле идея кертеп утыртырга мөмкин. Бу «массовый культура»ның һәм аны тарату чараларының ахыргы максаты — публикага уйларга комачаулау гына түгел, аңарда күп кенә шартлы рефлекслар да булдыру.

Шундый түбән зәвыкка исәпләнгән нәрсәләрнең кайвакытта безнең матбугатка, экранга, сәхнәгә үтеп керүе бигрәк тә түзеп тормаслык хәл. «Культура байлыкларын алмашу буенча чит илләрдән ала торган рухи продукцияне сайлауга җентеклерәк карарга кирәк,— диелде бу уңайдан КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумында.— Эчтәлекле әсәрләр белән рәттән идеясезлек, түбәнлек, художество ягыннан булдыксызлык хас булган фильмнар, пьесалар, басмалар, музыканың безгә килеп эләгүе мәгълүм нәрсә ич. Монда, иптәшләр, безнең өчен беренче урында коммерция түгел, политик караш торырга тиешлеген онытырга ярамый».

Көнбатыш илләрдә, башлыча АКШта «фанатология» дигән нәрсә, ягъни үлем турындагы фән киң таралды. Ул кеше шәхесенең мораль яктан һәм физик үлемен тасвирлаучы әдипләр өчен «теоретик нигез» булып хезмәт итә. Күп кенә университетларда һәм колледжларда үлем идеяләре һәм догматлары Элизабет Кюблер-Россның «Үлем һәм үлү турында» һәм Герман Фейфельның «Үлем төшенчәсе» дигән китаплары буенча өйрәнелә. Миннесота университетында «Үлем социологиясе» дигән темага лекцияләр укучы Роберт Фултон болай дип белдерә: «Бурыч шуннан гыйбарәт: үлемнең яңа перспективасын ачарга кирәк, үлемнең табигый эш икәнлеген күрсәтергә кирәк». Эш шуңа барып җиткән, кайбер студентлар инде табутчыга барып үзләренең буена туры килә торган табут сайлыйлар, үзләрен күмү планнарын төзиләр икән.

Буржуазия, шулар ярдәмендә культурадагы бөтен җанлы нәрсәне, котырган реакция интересларына туры килми торган нәрсәләрне бетерү өчен төрле череп таркалган элементларны — җинаятьчеләрне, гангстерларны, наркоманнары хезмәткә ала. Власть иясе кайчандыр намуслы саналган өлкән художникларны да, эшкәртәләр, сатып алалар, капитал интересларына хезмәт итәргә мәҗбүр итәләр. Мәсәлән, Синклер Льюис, Говард Фаст кебек язучылар империализм лагерена күчтеләр. Үз халкыннан, демократик көчләрдән аерылган бу ренегатлар хурлыкка лаек булдылар.

Англия һәм АКШның китап базарлары Ян Флеминг һәм Микки Спилленның маҗаралы бульвар романнары белән тулды, аларда тупас көч, рәхимсезлек, кешелеккә нәфрәт данлана. Бу романнарның һәм башка шундый китапларның геройлары, пистолетлар, кастетлар, шешәләр белән коралланып, кеше канын агызалар, хатын-кызлар шәраб, акча артыннан куалар. М. Спиллен (АКШ) романнарының исеме дә моны ачык күрсәтә: «Пистолетлар көне», «Зур үтерү», «Минем револьвер өлгер», «Канлы шәфкать», «Үлем ярдәмчеләре».

Америкалы Генри Миллер да әхлаксызлыкны аклап һәм кеше матурлыгын инкяр итеп чыга. Ул Нью-Йорк, Париж һәм Лондон урамнарындагы байбәтчәләр көтеп торучы фәхишәләрне күреп соклана. Порнографиянең дә аргы ягына чыккан хикәяләрне күпләп яза, шуның белән «порнография короле» дигән исемгә дә лаек булды. Миллер кешеләрне тормыш, политика белән кызыксынмаска өнди, чөнки, аның ышандыруынча, «якындагы йөз ел эчендә цивилизацияле дөнья җир йөзеннән юк ителәчәк».

1914 елның 5 июнендә Инесса Армандка язган хатында В. И. Ленин Винниченконың «Аталар васыятьләре» дигән романындагы «ахинея һәм ахмаклык» уңаеннан чиктән тыш нәфрәтләнүен белдерә. «Һәртөрле коточкыч нәрсәләрне күпләп кушу», «бозыклык»та, «сифилис»та, романик явызлык эшләү дә... коточкыч нәрсәләрне сурәтләү, үзеңнең дә, укучының да котын алу, үзеңне дә, аны да миңгерәтү» — Ленин гарипләнгән һәм өметсезлек культурасын шулай бәяли (Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 35 том, 116 бит).

Көнбатыштагы күп кенә әдипләрнең, реакцион буржуазиянең социаль заказын үтәүчеләрнең әсәрләре нәкъ әнә шундый. Реакцияне ныгыту, халык массаларының

иҗат көченә ышанычны бетерү, политикадан, демократия һәм социализм өчен көрәштән күңелләрен кайтару, бөтен бер буынны үз-үзенә, якты киләчәккә ышанмый торган итеп, идеалларсыз итеп үстерү — алар барысы да шул максатка хезмәт итә.

Дөрес, хәзерге буржуаз дөньяда еш кына аек тавышлар да ишетелә, рәсми идеологиягә каршы килә торган, культураны һәм сәнгатьне шакшы оясына әйләндерүгә протест белдерә торган акыллы фикерләр әйтелә. Буржуаз таркалу караңгылыгында реалистик һәм гуманистик культура яктысы җемелдәп куя, чын талантлар күренә. Әмма аларга зур кыенлыклар кичерергә, төрле киртәләрне җиңеп үтәргә туры килә. Әсәрләрен бастыру бик кыен. Аз санлы тиражлар белән генә бастырган хәлдә дә, аларны күрмәмешкә салышалар, таратмыйлар яисә бөтенләйгә тыялар.

Үзенең прогрессив әсәрләре (СССРда рус телендә басылып чыккан «Берра», «Вашингтон, Колумбия округы», «1876») белән танылган Америка язучысы, актив җәмәгать эшлеклесе, буржуаз җәмгыятьнең бозыклыкларын фаш итүче Гор Видал, АКШта һәм СССРда әдипләрнең тоткан урынын һәм ролен чагыштырып, болай дип яза: «Советлар Союзында язучыларга бик җитди карыйлар, ә АКШта аларны, кагыйдә буларак, санга сукмыйлар... Әйтик, сездә халыкның 70 проценты Катаевны яки Евтушенконы китаплары буенча, язучы буларак белә. Безнең язучылар, чын язучылар, чынлыкта беркемгә дә мәгълүм түгел... Әйбәт дигән хәлдә дә китаплары максимум 10 мең данә тираж белән чыга. Ә инде поп-культураның шанслары чагыштыргысыз шәбрәк — каты тышлыкта өч йөз мең чамасы һәм йомшак тышлыкта өч миллионлап» («Литературная газета», 27 октябрь, 1982 ел).

Тормыштагы җитди мәсьәләләрне күтәргән пьесаларга буржуаз сәхнәдә урын табу кыен. Буржуазия акча капчыгының политик исәпләренә һәм интересларына идеясез һәм бигрәк тә сексуаль пьесалар, кием алыштыруга корылган һәртөрле водевильләр бик туры килеп тора. Мистика, уйнаш, мәгънәсе булмаган һәм әшәке көлү, кот алырлык хәлләр — Нью-Йорк, Лондон, Парижның күпчелек театрлары әнә шуңа кайтып кала.

Шунлыктан артистларның да хәлләре кызыгырлык түгел. Аларның күбесе талантларына тиң эш таба алмый, очраклы һәм вакытлы эш белән канәгатьләнергә яисә миллионнарча эшсезләр армиясенә кушылырга мәҗбүр булалар. Мәсәлән, француз актеры Поль Саватье 25 ел дәвамында эшсезлектән интегә.

Буржуазия дөньясындагы музыканың да хәле шуннан яхшырак түгел. Классик моңлы музыканы яратмыйлар. Аның урынын мещаннар күңеленә хуш килә торган, төме һәм аһәңе булмаган «вальслар», «җырлар» алды, вульгар джаз какафониясе колак тондыра. Гарип-формалистик иҗатлары белән хәзерге Америка һәм Көнбатыш Европа композиторлары музыканы сәнгать буларак инкяр итәләр. Алар музыканың җаны булган көйне бетерәләр. Америкада Генри Коуэлл дигән бәндә новатор дип танылды, ә уйлап тапкан нәрсәсе — рояльдә йодрыклар һәм терсәкләр белән уйнау икән.

Көнбатыш Европа илләрендәге һәм АКШтагы күп кенә рәссамнар иҗатында да таркала бару процессы күзәтелә. Нью-Йоркта һәм АКШның башка шәһәрләрендә «абстракт рәсем сәнгате» күргәзмәләре үткәрелә, аларда тормыштан аерылганлыкны девиз итеп куйган рәссамнар гына катнаша. «Әсәрләре» төрле төстәге квадратлардан, түгәрәкләрдән, буй-буй сызыклардан гыйбарәт була. Хәзерге сәнгать тормышны чагылдырырга тиеш түгел дигән фикер киң таралган. Имеш, бу сәнгатьне түбәнәйтә, рәссам кешеләр тормышын тасвирламасын, ә инде кеше рәсемен ясый икән, аның әгъзалары төрлечә бозып сурәтләнсен.

АКШта Джорджия О'Киффны мәшһүр рәссам дип атыйлар. Бу хатын-кыз сөякләр, сексуаль-порнографик картиналар ясый. Вашингтондагы милли галерея аның «әсәрләре» бернечә зал билән тора, анда булганда нормаль кешенең күңеле болганмыйча калмый. Аның «Оча сөяге аша күк чагыла» дигән картинасы сәнгатьнең бөек казанышы дип исәпләнә. Бу цинизм һәм мәгънәсезлек, сәнгатьне тәкәллефсез инкяр итү үрнәге. Галереяда йөргәндә хәзерге сәнгать залларына хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләргә сорау бирдек:

— Бу эч пошыргыч полотноларның мәгънәсе нәрсәдә? Шушылар барысы да сәнгать дип саналамыни?

Җавап мондый булды:

— Әйе, бу — диваналар, наркоманнар сәнгате. Нормаль кеше шундый рәсем ясамас. Ләкин бу «шедеврлар» кирәк, кешеләрне шаккаттыру өчен аларны бик теләп күрсәтәләр. Башта үземнең дә күңел болгана иде. Хәзер инде гадәтләндем, шушында басып торам. Кайда да булса торырга кирәк бит, ашамыйча яшәп булмый.

Иң киң колачлы массакүләм информация чарасы булган телевидение дә хәзерге буржуазия кулында культурага, мәгарифкә һәм сәнгатькә мөнәсәбәтле булган бөтен сыйфатларын югалтты. Ул интеллектка һәм талантка хезмәт итми, ә кешеләрне аңгыраитуга, кешелексезлекне пропагандалау коралына әверелә. Өстәвенә иң камил һәм массовый коралга. Йөз миллионнарча кешеләр бөтен буш вакытларын телевизор каршында утырып үткәрәләр, театр, кино, китапханәләргә йөрмиләр, газета-журналлар, китаплар укымыйлар. Американлылар, мәсәлән, телевизорны уртача көненә 5—6 сәгать карыйлар. Японнар газета-журналларга уртача 33 минут кына вакыт бүләләр, ә телевизорга 3 сәгать 47 минут вакыт бирәләр.

Совет кешеләренә, ди Америка язучысы Гор Видал, Америка телевидениесенең ни икәнлеген аңлау җиңел түгелдер. Нигездә бу ниндидер бер коточкыч нәрсә... безнең массакүләм информация чаралары менә 65 ел инде, бигрәк тә сезнең ил турында, әшәкелекләр сөйлиләр... Без китап укучылар җәмгыяте булудан туктадык, китапның түмән оныттык... АКШтагы гадәти бала телевизор каршында тәүлегенә 6 шар сәгать утыра.

«Совет куркынычы», Совет дәүләтенең, имештер, агрессив һәм террористик политикасы турында тапшырулар бик модага керде.

Лос-Анджелеста, демократик җәмәгатьчелек оештырган кабул итү вакытында бу юлларның авторына, СССРга барып кайткач, эшләре гөрләп бара торган бер бизнесмен белән сөйләшергә туры килде. Гостиницага урнашу белән үк ул Кызыл мәйданга юл тоткан, АКШка төбәлгән танкларны, пушкаларны һәм ракеталарны үз күзе белән күрәсе килгән. Әмма күргә исе-акылы киткән: мәйдан буйлап тыныч кына кешеләр йөри, В. И. Ленин Мавзолеена зур чират тезелгән икән. «Ник бер танк, я ракета булсын! — дип аптырый әңгәмәдәшем.— Ә бит Америка телевидениесе безгә янап торган сугыш кораллары тулы Кызыл мәйданны гел күрсәтеп тора».

АКШтагы һәм башка капиталистик илләрдәге телевизион тапшыруларның күпчелеге янә дә төрле-төрле җинаятьләрне, чәчең үрә торырлык хәлләрне тәмләп тасвирлауга багышлана. Американлы Уилбур Шрамм «Телевидение балаларыбыз тормышында» дигән китабында 100 сәгать телевизион тапшыруларга 12 үтерү, 16 корал кулланып сугышу, 21 атыш, 37 йодрык сугышы, бер үрттан пычак белән кадау, 4 үз-үзеңне үтерү, 4 упкынга егылу, 2 автомобильнең аска тәгәрәве, 2 линч суды, 2 талау һәм башка бик күп шундый хәлләр туры килүен исәпләп чыгарган. Иң күп үтерешләр якшәмбе көннәрендәге балалар тапшыруларына туры килә икән.

Иң куркынычы шунда — шуларны гел карап торган балалар үзләре дә мондый хәлләргә бик ис китмичә карый башлыйлар, шундагы геройларга охшарга телиләр, үзләре дә шулай кыланалар. Гелефильм карый-карый да, бер бала утлы корал алу өчен ата-аналарыннан акча сорый, икенчесе укытучы апасына агулы шоколад «бүләк итә», өченчесе сеңелесен газаплый, дүртенчесе ашка төелгән пыяла сала, бишенчесе банк басу өчен компания оештыру хыялы белән яна...

Әмма «ирекле» капитал дөньясындагы власть ияләрен бу борчымый. Социаль проблемалардан ерак торган, мөстәкыйль фикер йөртергә һәм эш итәргә сәләтсез булган яшь буын, нәрсә белән генә мавыкмасын, аларга бик ярый. Америкада чыга торган «Ньюсуик» журналы 1978 елның мартында болай дип язып чыкты: «Ниһаять, сексуаль революция зәңгәр экранга да үтеп керде». Әйе, телевидение компанияләре, табыш артыннан куып, бернәрсәдән дә тартынып тормыйлар, шул исәптән секс һәм порнографияне ачыктан-ачык күрсәтүне берничә санамыйлар. Телеэкран каршында балалар һәм үсмерләр утыруы турында бик яхшы белеп, АКШта, Англиядә, Италиядә, Франциядә, Япониядә, ГФРда һәм башка күп кенә буржуаз илләрдә сексуаль акт, җенси бозыклык күренешләре тәкъдим итәләр. «Хатын-кыз полицейский», «Семья», «Парк Авеню-79» дигән һ. б. телефильмнар әнә шундый.

Телевизион программалар элементар әдәплелек белән шулкадәр сыешмый, шулкадәр оятсыз һәм төзәтеп торгысыз, алар күп кенә гражданнарда, җәмәгать һәм куль-

тура эшлекләрендә законлы ачу тудырмыйча кала алмый. АКШтагы Бэттл-Крик шәһәре (Мичиган штаты) кешеләре зәңгәр экран аша үтерүләр, секс күренешләре, башка төрле җинаятьләр һәм оятсызлыклар күрсәтүгә карата протестларын шулай белдергәннәр: шәһәрдәге бер мәйданда телевизорларны җыеп өйгәннәр дә, бензин сибеп ут төрткәннәр.

Культура прогрессының куәтле факторы булган матбугат һәм радио да капитал дөньясында байлык җыю, спекуляция чарасына, идея-политик агуга әверелә. Буржуаз матбугат әллә кайчан инде объектив информация һәм мәгариф чарасы булудан туктады. Бу шулкадәр күзгә бәрелеп тора, аны журналистлар һәм рәсми кешеләр үзләре дә инкяр итмиләр.

Бу җәһәттән АКШ оборона министрының информация органнары белән элемтә буенча ярдәмчесе булып эшләгән А. Сильвестерның түбәндәге сүзләре характерлы: «Хөкүмәтнең ялганларга хакы бар... Әгәр дә Штатлардагы берәр рәсми кеше сезгә дөресен сөйләргә җыена дип уйласагыз, сез просто ахмак».

Ә Ак йорт хуҗалары теш агартырга яраткан «матбугат иреге» кайда соң? Дөрес, ул бар, ләкин капитал, империалистик реакция һәм агрессия апологетлары өчен, антикоммунизм, төрле җинаятьләр, кешелексезлек һәм оятсызлык пропагандалаучылар өчен генә. Бераүләр өчен ирек, икенчеләр, үзләрен ишеттерә алмаучылар өчен рухи коллык. Америкада матбугат ирегеи сугышны, расизмны, апартеидны, дөнья халыкларының азатлык көрәшенә һәм тынычлыкны яклауларына, социализм илләренә карата дошманлыкны котырынып пропагандалаудан башка күз алдына китерә алмыйлар.

Көнбатыш илләре колониаль изүдән күптән түгел азат ителгән һәм әле үзләренең бәйсез массакүләм информация чараларын оештыра алмаган илләрдә көчле идеология экспансиясе үткәрүдә дәвам итәләр. Халык күп яшәсә дә, бу илләрдә чыга торган милли газеталарның гомуми тиражы промышленносте үскән капиталистик илләрдә басыла торган газеталар тиражының алтыдан бер өлешен генә тәшкил итә. Үсеп килүче дәүләтләрнең 11 ендә көндәлек газеталар бөтенләй юк, 19 ында берәр генә газета чыга, 35 илдә үз информация агентлыклары юк. Империалистик дәүләтләр һәм эчке реакция көчләре моннан бик оста файдаланалар, көнбатыш, бигрәк тә АКШ агентлыкларының продукциясен киң тараталар.

Хәзерге дөньяда массакүләм информация чараларының роле турындагы мәсьәләгә багышланган халыкара киңәшмәдә (Стокгольм, апрель 1978 ел) Ливиянең Джана агентлыгы генераль директоры Саад Муджибер болай дип белдерде: Көнбатыш информация органнары тарата торган материаллар еш кына чып-чын дезинформация була. Зур, мөһим вакыйгалар турында дәшми калалар, икенче дәрәҗәдәгеләре иң алга куела. ЦРУның Америка һәм башка илләр журналистларын шпионнар итеп яллавын Кушма Штатлар үзләре дә икрарь иттеләр. Шуңа күрә дә, ди С. Муджибер, без Көнбатыш корреспондентларының үз илләребездәге эшчәнлегенә сагаеп карыйбыз.

Америкадагы күпчелек информация чараларының, шул исәптән, матбугат һәм радионың, разведка органнарына һәм хәрби ведомствога буйсынуы, журналистларның яшерен агентлар итеп файдаланылуы киң мәгълүм. Игълан ителгән мәгълүматларга караганда, Американың 200 дән артык журналисты ЦРУ кушуы буенча шпионлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә: разведка белән хезмәттәшлек итүдән баш тартса, корреспондентны урыныннан мәхрүм итәләр. Мәсәлән, «Нью-Йорк таймс»ның Мәскәүдәге корреспонденты В. Филиппс шундый язмышка дучар булды. Англиядә Д. Уэбстер, Швециядә О. Гурич, Мисырда К. Керис, Мәскәүдә С. Джаффе һәм башка күпләр шпион-разведчик буларак фаш ителде.

Монополияләр һәм милитаристик даирәләр интересына хезмәт итә икән, журналист — хөрмәтле. Ә инде, үз «эшчәнлегенең» зыянлы һәм шакшы максатларга хезмәт итүен аңлап, реакциянең казынуларын фаш итәргә теләсә, аны эштән куалар һәм эзәрлеклиләр. АКШ гражданы Филипп Эйджи шундый хәлгә очрады. ЦРУ агенты булып ун ел эшләгәннән соң, ул бу эшчәнлегенең никадәр әшәке икәнлеген таный һәм отставкага чыга. «Коллегаларым һәм мин кылган эшләр,— ди ул,— үтерүләргә һәм ирексезләүгә китерде». Эйджиның үзен шулай тотуы АКШның гына түгел, НАТОга керүче кайбер башка илләр властьларының да ачуын китерде. Аны башта Англиядән, аннары Франциядән (гәрчә, Американың Париждагы илчелегендә, Эйд-

жиның белдерүенә караганда, аның элеккеге 70 коллегасы эшләсә дә) һәм, ниһаять, Голландиядән дә куалар.

Буржуаз матбугат һәм радио объективлык һәм намуслылык төшенчәләре белән бернинди уртаклыгы булмаган методларга таянып эш итәләр. Укучыларны ЦРУ теләгән юнәлешлә эшкәртү өчен ялган хәбәрләр тарату методын алып карыйк. Бу хакта, мәсәлән, «Нью-Йорк таймс» газетасында ачыктан-ачык яздылар: «Сез берәр бәләкәй генә газетада, әйтик, Бангкокта, ЦРУ ярдәмендә нинди дә булса хәбәр урнаштырасыз да, аның берәр зуррак газетада басылуына, ә аннары кайсы да булса чит ил информация агентлыгының, яки, мәсәлән, «Пари-матч» журналының кабатлавына ирешәсез. Чираттагы адым — бу хәбәрнең Рейтер агентлыгы яисә Американың берәр телеграф агентлыгы тарафыннан күтәреп алынуы һәм Кушма Штатларга кире әйләнеп кайтуы турында кайгырту».

Шул рәвешчә «объективлык» пәрдәсе барлыкка китерелә. Берничә басмада һәм радиотапшырулар аша таратылган булгач, халыкка бу уйдырмага ышанудан башка нәрсә калмый. «Массовый кеше», иң өлкән Америка журналистларыннан берсе У. Липиман сүзләре белән әйткәндә, сәбәпләрне аңлату, уйлау, үз фикерен булдыру вазифаларыннан азат ителә, ул әзер стереотиплар кабул итәргә күнегә. Америка идеологларының берсе М. Чукас пропаганданың бурычлары «әйберләрнең реаль хәлен аңларга, тәнкыйди һәм акыл белән фикер йөртергә берниндн сәләте булмаган кеше булдыру» дип саный.

Мәгълүм булганча, Америка диктаты астында Мюнхенда «Азатлык» һәм «Азат Европа» девирсион радиостанцияләре эшли. Аларны эшләтү өчен АКШ елына 103 миллион доллардан артык акча тота. Хәзер аларның директоры постын АКШның элеккеге дәүләт секретаре урынбасары Джеймс Бакли били. 1982 елның октябрендә Сан-Францискодагы экономика клубында чыгыш ясаганда ул болай дип белдерде: «Америка тавышы»ннан үзгә буларак, «Азатлык» һәм «Азат Европа» радиостанцияләренең максаты Америка турында сөйләү түгел, ә полякларга — Польшада, украиннарга — Украинада, эстоннарга Эстониядә нәрсәләр булуы турында информация бирү; шул тәртиптә алар Көнчыгыш Европадагы социалистик илләрнең 6 телендә һәм СССР халыкларының 15 телендә тапшырулар алып баралар.

Тыңлаучылар яңа билгеләнгән директорга мондый сорау бирәләр: ул халыклар үз илләрендә нинди хәлләр барлыгы турында шулкадәр хәбәрдар түгелмени? Бераз уйланып торгач Бакли болай дип белдерә: «Мюнхендагы «информаторларның» эшчәнлеге «журналистиканың гадәти булмаган төре» икән, аларның бурычы «тимер пәрдә артындагы халыкларны» агарту икән.

Ә репортерлар эшенең «үзенә бертөрлелеге» шунда: Ак йортка ярый белергә, ялган һәм яла ярдәмендә социалистик илләрдәге стройны җимерергә омтылып карарга (ничәнче тапкыр инде!) кирәк. Мюнхендагы станцияләрнең устав документларында шулай дип язылган да: «Көнчыгыш Европа блогы илләре эчендә фетнәләр кабызырга һәм аларда социалистик стройны юк итәргә булышу», совет җәмгыятенең «неокапитализмга» күчүенә ярдәм итү. Бу пычрак эшкә элекке Гитлер ялчылары, куллары канга баткан хыянәтчеләр дә тартыла.

Мәгълүм булганча, капитал илләрендә җинаятьчелек бик киң таралган. Ул тукталуга бармый, киресенчә, кызу темплар белән үсә. Идарәче даирәләр аңа каршы көрәшмиләр генә түгел, аңлы рәвештә кешене күрәлмау, әхлаксызлык, цинизм һәм үтерешләр культын пропагандалыйлар. «Массовый культура» дигән нәрсә, сатлык буржуаз матбугат та шуңа хезмәт итә.

Экономик яктан алга киткән буржуаз илләрдәге рәсми газета һәм журналларның беренче битләрендә төрле мәхәббәт маҗаралары, үтерешләр, катастрофалар, туйлар, баллар, үлем җәзалары җентекләп тасвирлана, башка сенсацион хәбәрләр бирелә. Фоторәсемнәрдә бандитизм корбаннарын, әле генә кулга алынган үтерүчеләрне, поезд астына ташланучы хатын-кызларны, үзен тәкъдим итүче чибәрләрне күрәсең. Буржуаз матбугат төрле гангстерлар белән кызыксына. Мәсәлән, атаклы бандит Аль-Капонены күмү, бөтен ил өчен мөһим вакыйга кебек итеп, АКШ матбугатында һәм телевиденниесендә киң яктыртылды. АКШта «Кеше үтереп ничек җәзасыз калырга?» дигән китап 200 мең данә тираж белән басылып чыкты. Аның авторы — урлау һәм талаулар өчен 18 тапкыр кулга алынган Даниэль Эхерн дигән кеше.

Безнең идеология дошманнарыбыз совет гражданнары, бигрәк тә яшьләр арасында әдәбият, сәнгать, матбугат аша төрле идеологик диверсияләр үткәрергә, безгә ят булган карашларын тагарга маташалар. Моңа каршы килешмәүчән көрәш алып бару — бөтен иҗади җәмәгатьчелегебезнең зур бурычы. «Партия фәнне, культураны баета, хезмәт кяләрен нык үскән социализм нормалары һәм принциплары рухында тәрбияләүгә булышлык итә торган бөтен нәрсәне яклый,— диде КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Ю. В. Андропов КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумында.— Ул талантларга, художникның иҗади эзләнүенә, алар эшенең формасына һәм стиленә катнашмастан, саклык һәм ихтирам белән карый. Әмма партия совет сәнгатенең идея эчтәлегенә битараф була алмый. Ул һәрвакыт сәнгатьнең үсешен халык интересларына хезмәт итүгә юнәлдерәчәк».

Халыкның культура дәрәҗәсе үскән саен сәнгатьнең кешеләр акылына йогынтысы көчәя бара. Димәк, сәнгать эшлеклеләре үз кулларындагы куәтле корал халык эшенә, коммунизм эшенә хезмәт итсен өчен тагын да зуррак җаваплылык тоярга тиешләр.

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

Сорау:

— Музыкада «әдәби башлангыч»ның әһәмиятен Сез ничек аңлыйсыз?

**Нәҗип Җиһанов, Социалистик Хезмәт Герое, СССРның халык артисты, композитор:**

— Музыка белән әдәбиятны бер-берсеннән аерып булмый. Тикмәгә генә без көй белән сүзне кошның ике канатына тиңләмибездер. Һәм, гомумән, күп кенә музыкаль жанрлар турыдан-туры каләм осталары белән соавторлыкта язуны таләп итәләр. Кайвакыт әдәби әсәрләр «сүз башлангычы» булмаган «саф» музыка язарга да этәрәләр. Мәсәлән, мин соңгы вакытта бер әсәр укыдым һәм ничектер симфоник поэма язасы килеп китте. Музыка белән әдәбият, димәк, бер-берсен тудырышалар да. Шуңа күрә дә мин язучылар белән иҗади хезмәттәшлектә булуны композиторлык эшчәнлегендә иң кирәкле шартларның берсе итеп саныйм.

Әле дә хәтеремдә: сугышка китеп баручы Җәлил белән чалбар каешымны алмаштым. Әйтерсең, ул үз каешын язучылар белән дуслыкны беркайчан да суытмаска кирәклеген искәртеп торыр өчен калдырган. Васыяткә тугрылыклы булырга тырыштым. Минем өчен Ә. Фәйзи, Ә. Исхак, Х. Туфан, С. Хәким, Г. Бәширов кебек исемнәр аеруча кадерле. Яшьләрне дә мондый дуслыкны олыларга чакырам. Яшьрәк буын вәкилләреннән композитор Ш. Шәрифуллин белән шагыйрь Р. Фәйзуллин дуслыгын хуп күрәм. Әмма яшьләр арасында «әдәби башлангыч»ның әһәмиятен тиешенчә аңлап җиткермәүчеләр дә шактый. Мондый чикләнгәнлек, конкрет әйткәндә, әдәби текстларга талымсызлык, иртәме-соңмы, идея-эстетик ярлылыкка китерә. Композиторлар белән хезмәттәшлек итүче кайбер язучылар да үз эшләренә кайчак җавапсызрак карыйлар, музыкада сүз көче мөмкинлекләреннән тиешенчә файдаланмыйлар.

Бүгенге опера сәнгате проблемалары турында сөйләшкәндә, шагыйрьләрдән еш кына шундый акланулы сүзләр ишетергә туры килә: «Либретто язуга караганда, поэма иҗат итү уңайлырак һәм отышлырак». Шулай да булсын. Әйтик, А. Пушкин да либретто язмаган, әмма аның «Евгений Онегин»ы операга нигез булып яткан. Заман опера таләп итә. Ә безгә сюжетны кайдан табарга? Операга җирлек була алырлык поэмалар да күренми. Мин үзем шундый әсәрне очратсам, шундук эшкә тотыныр идем.

Горурланып кабатлый алабыз: әдәбиятыбыз да зур, музыкабыз да. Шулай ук уртак максатларыбыз да зурдан, бергәләп хәл итәсе мәсьәләләр дә байтак. Ә тугандаш сәнгатьләрне иҗади хезмәттәшлектән башка үстереп булмый.

Казан утлары
АЭС
әдәби пост

## Марат Мостафин

# КИҢӘШЛЕ ЭШ ТАРКАЛМАС

Журнал укучыларына билгеле булганча, Татарстан төзүчеләре 1982 елның февраль аенда яңа зур эш кузгатып җибәрделәр: Кама Аланы янында атом электр станциясе салына башлады. Бу олы бурычны иңнәренә алучылар Зәй ГРЭСен, Түбән Кама нефтехимия берләшмәсен, КамАЗны, Түбән Кама ГЭСен сафка бастырганда шактый тәҗрибә туплаган булсалар да, шактый үзенчәлекле яңа төзелеш аларны да күп нәрсәгә өр-яңадан өйрәнергә мәҗбүр итә. Сүз дә юк, алда башкарылган эшләр бу юлда да, һәм үрнәк, һәм гыйбрәт буларак, ярдәм итәләр. Атом станциясен һәм энергетиклар яшәячәк яңа каланы салырга Зәй, Түбән Кама һәм Брежнев шәһәрләреннән иң оста җитәкчеләр тартылды. Бусы — бер. Икенчедән, бүгенге көннәрдә республикабызның промышленность куәте дә, үткәндәге еллар белән чагыштырганда, күпкә ныгыды. Бу төбәктә бигрәк тә. Монда нык нигезле Түбән Кама территориаль производство комплексы формалашып килә. Мондагы авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче районнарда да заман таләп иткән яңалыклар тормышка ашырыла — шәһәр һәм поселокларга азык-төлек мул килә.

Бу уңайлыклар исә Татарстан атом электр станциясе төзелешендәге эшләрне, һичшиксез, җиңеләйтә төшә, темпларны тизләтергә, хезмәтне интенсивлаштыруга ярдәм итә. Әмма, һәр яңалыкка хас булганча, монда да бик тәҗрибәле җитәкчеләрнең дә чәчен агартырдай кыенлыклар байтак. Аларның күбесе турыдан-туры төзелеш мәшәкатьләренә бәйле. Шулай да бу очракта сүз башка мәсьәләләргә кагылачак.

Инде әйтеп үткәнебезчә, атом станциясе янында утыз-кырык мең кешегә исәпләнгән шәһәр дә салына. Үзеннән-үзе аңлашыла ки, бу хәл якын-тирәдәге колхоз-совхозлар җитештерә торган байлыкка булган ихтыяҗны да арттырачак. Ә икенче яктан, тирәлекнең моңарчы игеннәр шаулап үскән мәйданы кысрыкланып, аның бер өлеше төзелеш хаҗәтләренә бүленә. Өстәвенә, авыл яшьләре төзелеш һәм станция эшенә китеп барачак, авыл хуҗалыгындагы эшче көчләр кимиячәк. КПССның Татарстан өлкә комитеты унберенче пленумында әйтеп үтелгәнчә, республиканың авыл хуҗалыгындагы эшче көчләр, планда таләп ителгәнгә караганда кимрәк.

Казан дәүләт университетының экономик география кафедрасы галимнәре алып барган тикшеренүләргә таянып әйткәндә, Түбән Кама, Брежнев, Алабуга кебек шәһәрләр тирәсендәге авылларда яшьләрнең кимүе аеруча нык сизелә.

Димәк, яңа шәһәрдәге экономик һәм социаль тормышның проекты тирә-як авылларында һичшиксез булачак үзгәрешләрне дә күздә тотып төзелергә тиеш. Кала кешеләренең азык-төлеккә, ялга булган ихтыяҗларын канәгатьләндерүче күрше авылларның хуҗалыгы һәрьяклап камилләшә баруы белән нәкъ менә яңа шәһәр үзе кызыксынырга, моңа ирешү юлларын да үзе ачарга тиеш. Авыллар исә якында заманча салынган зур шәһәр балкып утыруын, аның төбәк өчен культура-тәрбия чыганагына әйләнүен, кирәк чакта, үзендәге куәтләр белән район хуҗалыкларына ярдәмгә дә киләчәген көтәләр, әлбәттә, һәм аңа булышырга әзер торалар.

Яңа калалар белән авыллар арасында шушындый дустанә, бер-берсе өчен файдалы мөнәсәбәтләр урнашсын өчен, беренче чиратта, авыл хуҗалыгындагы эшләрне үзгәртергә туры киләчәк: ит, сөт, йомырка, яшелчә һәм бәрәңге җитештерүне, шәһәр

ихтыяҗына җайлап, специальләштерергә, аларның күләмен арттыру чараларын табарга. Шәһәр кешеләренә ял итү урыннары, тигез юллар, җылы элемтә челтәре булдыруны күздә тотып та, шәһәрнең тирә-ягы мәгълүм күләмдә эшләр башкаруны таләп итә. Атом электр станциясе Чистай һәм Яңа Чишмә районнарына да үзгәреш китерәчәк.

Инде бу яңа төзелешнең авыл хуҗалыгы производствосына кирәкле мәйданны кысрыклау мәсьәләсенә тукталыйк. Бу хәл, гадәттәгечә, кешеләрне шәһәргә күчеп китәргә мәҗбүр итәчәк. Брежнев шәһәрен салганда, мәсәлән, тирә-юнь авыллардагы кешеләр саны ике-өч тапкырга кимегән иде. Мондый шартларда азык-төлеккә булган ихтыяҗны канәгатьләндерү авылдагы эшләрне кискен рәвештә үзгәртеп җибәргәндә генә мөмкин. Шунлыктан атом станциясен, яңа каланы салу белән бергә төбәктәге авыл хуҗалыгы эшләрен тамырдан үзгәртү дә кичекмәстән башланырга тиеш.

Дөрес, илдә кабул ителгән һәм уңышлы гына тормышка ашырылып килүче Азык-төлек программасы да авыл хуҗалыгындагы эшләрне промышленность нигезенә коруны, колхоз-совхозларга техник революцияне кыюрак кертүне алга сөрә. Әмма зур төзелешләр барган яклар өчен бу юнәлештәге эшләрне, гомумсоюз тизлеге белән чагыштырганда, һичшиксез, кызурак алып бару кирәк. Яңа шәһәр бу тирәдәге авыл кешеләрен, бигрәк тә яшьләрне, магнит кебек, үзенә тартачак. Азык-төлек җитештерүче көчләр кимиячәк.

Яңа шәһәрне азык-төлек белән тәэмин итәрлек куәткә ия булсын өчен, мондагы хуҗалыкларның һәр тармагын заманча җиһазландырырга: механикалаштырырга һәм автоматлаштырырга туры киләчәк. Бу максатка исә хуҗалыкара кооперацияләр булдыру, авыл хуҗалыгы эшләрен интеграцияләү аша колхоз-совхозларны специальләштереп кенә ирешергә мөмкин. Хезмәтне, техник яктан әйбәт коралландырып, өр-яңа җирлеккә бастырганда гына авылларда азык-төлек җитештерү артачак.

Хуҗалыкларда автоматлаштырылган һәм механикалаштырылган эре предприятиеләр оештыру өчен, авылларның, әлбәттә, зур булуы хәерле. Ул очракта халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү чараларын яхшырту мәсьәләсен чишү дә, авыл белән шәһәр арасында яшәп килүче аерманы киметү дә җиңелрәк төшә. Эшләрне машиналарга тапшыру исә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә, димәк ки, аны нәтиҗәлерәк итүгә китерә. Шуларны күздә тотып, зур төзелешләр тирәсендәге авылларны эреләндерү, андагы көнкүрешне шәһәрнекенә якынайту һәм хуҗалык итү ысулларын индустрияләштерү өчен этәргеч ролен үти ала.

Кечкенә авылларны нишләтергә соң? Бу сорау әлек-электән үк бик четрекле мәсьәләләрнең үзәгендә тора. Мәгълүм ки, моннан берникадәр еллар элек аларны зур авылларга кушып, күчереп бетерү юнәлешендә дә шактый азапланганнар иде. Әмма нәтиҗә көткән максатка китереп чыгармады. Кечкенә авыл кешеләре ата-ана нигезен ташлауны бик авыр кичерделәр. Алар тирәсендәге җир-су күзәтүчесез-хуҗасыз калды. Йорт-җире тузгытылган гаиләләрнең кайберләре исә, хуҗалыкның зур авылына урнашырга теләмичә, ерак шәһәрләргә үк китеп бардылар. Кыскасы, без көткәннең нәкъ киресе килеп чыкты.

Татарстан АЭСе салына торган төбәктәге вак авылларны ничек үзгәртергә, аларны ничек итеп заманга җайлаштырырга соң? Алар, әлбәттә, бик матур, нәкъ шәһәрдәге уңайлыклары булган йортлар белән тәэмин ителәчәк. Төзүчеләр һәм энергетиклар мондагы Нариман, Поповка, Ачи, Первомайский, Самоновка, Беляхча кебек авылларны үзләренең ял итү урынына әйләндерергә дә каршы килмәсләр иде. Чөнки аларның табигате бик матур, урман-сулары җитәрлек. Юлларын әйбәтләп, яшәү шартларын шәһәрчәләндереп җибәрсәң, ял өчен моннан да шәп урынның һич кирәге юк. Әйтик, көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты ачсаң, анда яңа шәһәр кешеләренең ихтыяҗларын да үти башласаң, бердән, авылның йөзе яктырып китәчәк, икенчедән, шәһәр белән авыллар арасында гаҗәеп күркәм мөнәсәбәт урнашачак.

Тирәннән уйлап, төрле тармактагы белгечләр үзара киңәшеп, отышлы алымнарның да иң отышлысын табып эшли башлаганда, АЭС янындагы авылларның киләчәген бик матур һәм җәмгыять өчен ифрат файдалы иттереп корырга була. Шәрә яланда утыручы шәһәрдән дә яманрак күренешне каян табарсың? Кама Аланы шәһәре исә тирә-яктан бик матур, мул тормышлы авыллар белән уратып алыначак. Алар, барысы бер бөтен тәшкил итеп, республикабызга яңа ямь, көч-куәт, байлык өстәячәкләр.

## Рифат Сверигин

# ТОРМЫШНЫҢ ҮЗЕ КЕБЕК

### АТИЛЛА РАСИХНЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ



Роман кебек олы жанрга мохтаҗлык, сусау бер кайчан да канәгатьләндереп җиткерелмәгән кебек. Проза адымнарын роман масштабы белән үлчәгән елларыбыз бар иде. Бер хакыйкать соңрак аңлашылды: әдәбият, гел без теләгәнчә, бер баскычтан икенчесенә күтәрелә-күтәрелә югарыга таба гына ашмый, аның борылмалы юллары, сикәлтәләре байтак икән. Тормыш белән тыгыз бәйләнештә торып, аны югары гражданлык һәм социаль нормалардан чыгып аңлатырга сәләтле әдипләр генә әлеге жанрда уңыш казана алалар.

Язучы Атилла Расих әнә шундыйлардан. Ул иҗат гомеренең иң зур өлешен романга багышлады — менә утыз ел инде, нигездә, роман язу белән шөгыльләнә. Утыз ел буе язучы белән укучы арасында тормыш, аның шактый катлаулы яклары турында җитди әңгәмә бара. Атилла Расих китапларының күбесе бәхетле язмышка очрады — кызыксынып, яратып укыла торган әсәрләргә әверелде. «Дустым Мансур», «Язгы авазлар», «Ике буйдак», «Каһарманнар юлы», «Сынау» романнары, «Ямашев» трилогиясе әнә шуны раслап торалар.

Алар арасында әдәби эшләнеше, төзелеше, тема-идея бөтенлеге һәм үткенлеге ягыннан аеруча камил әсәр — «Ике буйдак» (1965) романы, проблемасының актуальлеге һәм үткенлеге белән аерылып торган «Язгы авазлар» (1963), тормыш-көнкүреш мөнәсәбәтләре бик тулы сурәтләнгән, күпләребезне уйга калдырырдай «Сынау» романнары... Бу әсәрләргә тормыш мәсьәләләре катлаулы, җитди, чуар, төрле һәм борчулы яклары белән дә килеп керәләр. Язучының геройлары һәр көн, һәр урында үзләре дә сизмәстән, олы сынау — Кеше исемен йөртергә сынау үтәләр. Әле әйтелгәннәр бер «Сынау» романына гына кагылмый, әнә шул тормышчан җитдилек — А. Расих романнарының әһәмиятле сыйфаты.

Шул ук теләк әдипне «Дустым Мансур» һәм «Ямашев» әсәрләрен дә язуга этәргән. Бу ике романны үзара якынайткан як — үткәннәргә бүгенгедән әйләнеп карау омтылышы. Тарихны өйрәнү, бәяләү Атилла Расихка җиңел генә бирелми. Ә сарыф ителгән көч — бихисап. Әсәрләрнең язылу даталарына гына күз салыгыз: «Дустым Мансур» — 1955—1968, «Ямашев» трилогиясе — 1968—1982. Романчының бөтен иҗат чорын шушы ике әсәр иңләп алган түгелме соң?

Атилла Расих — тормышны тарихи үсешендә ачу максаты белән, чынбарлыкның мөһим һәм җитди якларына кыю мөрәҗәгать итүче, иҗат диапазоны шактый киң булган әдипләребезнең берсе. Конфликтларның актуальлеге, тормыш күренешләренең табигыйлеге һәм реальлеге аның иҗатында иң алгы планга куела, романнарының эстетик кыйммәте күбрәк шул сыйфатлар белән билгеләнә. Кагыйдә буларак, А. Расих әсәрләрендә әһәмиятле иҗтимагый мәсьәләләр күтәрелә һәм кыю рәвештә чишелә. Алар көчле гражданлык хисе белән сугарылган булалар һәм чорның алдынгы кешеләренең тормышларын, эшләрен һәм яңалыкның, прогрессив идеяләрнең тантанасын тасвир итәләр.

А. Расихның романчы булып җитешүе һәм танылуы илленче елларга туры килә. Аның бу жанрдагы дебюты «Дустым Мансур» романы булды. Роман яшьлеге социализм төзүнең җанлы чорына туры килгән кешенең чыныгуы, формалашуы һәм социализм идеяләре өчен ныклы көрәшчегә әверелүе турында сөйли. Автор шактый киң таралган классик алымнар белән эш итә — эшче егет Мансурның биографиясе билгеле бер эзлеклелектә, хронологик тәртиптә тәкъдим ителә, характер үсеше дә әнә шулай югарыга таба, бер баскычтан икенчесенә күтәрелә бара.

Герой әсәргә тыйнак, аз сүзле, оялчан яшүсмер буларак килеп керә. Ятим егет — кем үзенә якты чырай күрсәтсә, шуңа сыенырга әзер. Ә тормыш җиңел генә юлга салынмый. Хисами абзыйлары өендә ачлы-туклы яшәп, соңрак, Габделбәрләрдә ялчы булып йөргәннән соң ул гигант төзелешкә барып керә, анда аңа дөрес юл күрсәтүчеләр табыла, егетнең күзләре ачылу, ныгуына үзендәге кайбер күркәм сыйфатлар — намуслылык, эчкерсезлек, туры сүзлелек тә сәбәп була. Ә бу сыйфатларның чыганагы билгеле: вакытсыз үлеп киткән намуслы кешеләр — этисе белән әнисе балага яшьтән нык йогынты ясаган. Эшчеләр сыйныфы Мансурны кеше итә, ул җәмгыятьнең алдынгы кешесе, социализм өчен көрәшче булып җитешә. Бу — бер шәхси биография генә түгел. Мансур үткән юл — миллионнар юлы. Романда язучының конкрет тормыш күренешләрен ышандырырлык итеп, үз буяулары белән сурәтләү сыйфаты ачык күренә.

Әсәрдә хезмәт процессын, хезмәт пафосын сурәтләгән эпизодлар аеруча уңышлы. Күмәк хезмәт, социалистик ярыш, яшьләрнең эшкә, һөнәргә өйрәнүләре турындагы шактый ук профессиональ белем сорый торган бүлекләр дә җанлы һәм мавыктыргыч язылганнар.

Егерменче-утызынчы еллар сулышын, заман куйган мәсьәләләр, чорның көнкүреш штрихлары — болар «Дустым Мансур» романында тасвирланган тарихи чор колоритын ачыграк күз алдына китереп бастырырга ярдәм итәләр. Һәртөрле корткыч элементларның социализм төзелешенә каршы киртә корып маташулары да, яшьләрнең аң-белемгә омтылулары, авыл белән шәһәр арасында икеләнеп йөрүче крестьянның психологик каршылыклары, наданлыкны бетерү өчен көрәш, хатын-кыз эмансипациясе, яшүсмерләргә урамның начар йогынтысы да бар. Бер караганда, композицион катлаулылык һәм проблематик төрлелеккә каршы да чыгып булмый төсле. Чөнки күп планлылык, күп проблемалылык, тормыш күренешләрен киң фронт белән иңләп алу роман жанрының табигый сыйфатларыннан санала. Әмма алынган проблема турында сүз кузгатып үтү генә җитми, аның чишелешен, финалын да ышандырырлык итеп күрсәтү таләп ителә. Әлеге романның кимчелеге дә әнә шунда — күпчелек проблемалар кузгатылып кына кала.

«Дустым Мансур» романындагы проблемалар күплеге төп идеянең тишенчә ачылуына да комачаулык итә. Мәсәлән, ул чор өчен шактый әһәмиятле булса да, хатын-кыз азатлыгы, эмансипациясе мәсьәләсе әсәрнең композицион төзелешенә кире йогынты ясый — вакыйгалар үсешен тоткарлый. Хәдичә, аның әнисе һәм этисе, характер буларак, тиешенчә гәүдәләндерелмиләр. Бу урында язучы куйган проблема характерлар үсешеннән килеп чыкмый, аның ясалмалылыгы, язучы тарафыннан махсус рәвештә кертелүе сизелеп тора. Дөрестән дә, кем ул Хәдичәнең этисе? Ни өчен семья трагедиясе килеп чыккан? Бу турыда өстән-өстән генә әйтеп үтелә. Бу фаҗига укучыга аңлашылып ук җитми, аны тетрәндерә алмый.

Сюжетның кайбер борылышлары әсәрнең ахырына кадәр укучы игътибарын суытмау вазифасын үтиләр. Мәсәлән, Хәдичәнең шәһәрдә шагыйрь белән мавыгуы һәм, бу кешенең кем икәнлеген аңлап, күңеле кайткач, яңадан Мансур белән

очрашуы — укучыны беркадәр киеренкелектә тоту өчен генә кителрелгән ясалма эпизодлардан.

Әнә шулай, «Дустым Мансур» романында авторның күп күзәтүләре үзәк идеягә буйсындырылмыйча, тормыш фактлары һәм күренешләрнең кайберләре әдәбият законнары таләп иткәнчә эшкәртелми генә әсәргә кертелгән иде.

Үзеннән-үзе аңлашыла, «Дустым Мансур» татар романы жанрын бизәп торучы әсәрләр рәтенә күтәрелеп җитә алмады. Атилла Расихның үз әсәрләре арасында да аның урыны бик түрдә түгел. «Язгы авазлар», «Ике буйдак», «Сынау» романнарында исә әдип яңа, югарырак баскычларга күтәреләчәк. Шулай булгач, язучының роман өлкәсендә беренче тәҗрибәсенә болай иркенләп тукталу кирәк идеме? Әйе, кирәк иде. Чөнки әлеге «балалык чирләре» язучы иҗатында әледәнәле үзләрен сиздергәләп торалар, ә мондый күренешләрнең олы, тәҗрибәле Атилла Расих иҗатында да очраштыргалап торуы борчылдыра һәм уйландыра. Әдип иҗатында бик аз урын алуларына карамастан, әлеге кимчелекләр әйбәт уйланылган, олы тема, олы идея, зур шәхесләрне ачардай әсәрләргә дә зыян китерәләр. Әдәби сүз техникасы, иҗат-композиция бөтенлеге законнарын сәнгать сугып бетермәү «Ямашев» трилогиясендә дә сизелеп, әсәрнең әдәби җәмәгатьчелектә тагын да көчлерәк яңгыраш алуына комачаулык итте.

Күренекле татар революционеры, ленинчы Хөсәен Ямашев образын әдәби гәүдәләндерү — үтә кыен һәм җаваплы бурыч. Әгәр моны әдәбиятыбыз алдында торучы, әле һаман да үтәлмәгән олы бурыч — күренекле татар эшлеклеләре образларын иҗат итү эшенең бер өлеше итеп карасак, Атилла Расих тарихи роман традицияләрен үстерүче дә, яңа юл яручы әдип буларак та күз алдына килеп баса.

Татар прозасында тарихи-революцион романның мәгълүм традицияләре бар. Сүз «Безнең көннәр» (Г. Ибраһимов), «Язгы җилләр» (К. Нәҗми), «Онытылмас еллар» (И. Гази), «Тукай» (Ә. Фәйзи), «Гафурлар гаиләсе» (Г. Шәрипова) романнары турында бара. Гафур Коләхметов, Галимҗан Ибраһимов, Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов, Камил Якуб, Шамил Усманов кебек күренекле революционерләр һәм Галиәсгар Камал, Шәриф Камал, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Мирхәйдәр Фәйзи кебек XX йөзнең беренче чирегендә балкыган әдәбият йолдызлары — тарихи шәхесләрнең гүзәл тормышлары күпме яңа буыннар өчен яшәү һәм халыкка хезмәт итү үрнәге булыр иде. Аерым матур мисаллар булса да, әлегә бездә тарихи шәхесләр турында роман, повесть язу ысуллары, принциплары яңа эшләнеп кенә килә. Әдәби үсешнең хәзерге этабында әлеге игелекле эшкә беренчеләрдән булып тотынуы Атилла Расихның кыюлыгы, әдәбият мәйданында егетлеге дип бәяләнергә хаклы. Җәмәгатьчелек әдипнең бу адымын хуплап каршылады — Атилла Расихның иҗади эшчәнлеген Тукай бүләге белән зурлаганда «Ямашев» трилогиясе дә искә алынды.

Шулай да болар тарихи фигураны әдәби планда гәүдәләндерү принципларын кую һәм тормышка ашыру проблемалары хакында җентекләбрәк сөйләшү кирәклеген инкарь итми. Башкача әйткәндә, трилогиянең уңышы нәрсәдә һәм сәнгать камиллегенең югарырак баскычына күтәрелергә аңа ниләр комачаулаган соң?

Әсәрдә инде җитлеккән, тәҗрибәле, үзен бөтенләе белән революциягә багышлаган кешенең олы тормыш юлы сәхифәләре — Хөсәен Ямашевның 1905—1912 еллардагы эшчәнлеге сурәтләнә. Нәкъ шушы чор аның большевик буларак йөзен, хезмәтен, көрәшен яктыртырга зур мөмкинлекләр бирә. Образ киң социаль мохит эчендә, революцион үсеш һәм реакция елларындагы катлаулы элемтәләр, мөнәсәбәтләр аша ачыла. Галимҗан Сәйфетдинов, Гафур Коләхметов, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури кебек шәхесләргә дә әсәрдә байтак урын бирелә. Оренбургта «Урал» газетасын чыгара башлау тарихы драматик кисәкенлеге белән җәлеп итә — ул үзе генә дә җитди һәм мавыктыргыч бер повесть кебек.

Атилла Расих документальлек, тарихилык принцибына нык таяна. Ул укучыны яхшы өйрәнелгән, җентекләп тикшерелгән, бай һәм күп санлы тарихи материаллар белән таныштыра. Тарихи әсәр өчен тарихи фактларның документаль төгәллеге, әлбәттә, төп җирлек, нигез булып санала. Атилла Расих, тарихчы буларак, зур эш башкарган. Билгеле, бу — тарихи фактларның бирелешендә ясә

аларны аңлатуда аерым бәхәсләргә бөтенләй урын калмаслык дигән сүз түгел әле. Шулай да, иҗат процессының әлеге этабындагы кыенлыкларны автор, нигездә, җиңеп чыга алган. Чын кыенлык икенче этапта — гаять бай фактик материалны художество теленә күчергәндә — образларда гәүдәләндергәндә башлана.

Мәгълүм булганча, язучы үз әсәренең темасы, идеясе, максатлары таләп иткәнчә, тормыш күренешләренең тиешлеләрен генә сайлап ала. Атилла Расих исә башка төрлерәк юлдан бара. Тарих материалларыннан ул әсәрдә мөмкин кадәр күбрәк файдаланырга тырыша. Табылган фактларның кайберләре сюжет агышына бик үк ярашып җитмәсә дә, автор аларны әсәрдә файдалану юлларын эзли.

Мәсәлән, Җәгъфәр белән бәйләнештә хаҗга баручылар, мөһаҗирләр маҗаралары җентекләп тасвирлана. Бу — кызыклы һәм оста язылган битләр. Шулай да бу хәлләр-вакыйгалар башка әсәрдән килеп кергән кебек — игътибарны читкә алып китәләр.

Җәгъфәр юлы — принципларына хыянәт иткән, аумакай, адашучан, вак җанлы кешенең тарихы. Җәгъфәр — Хөсәеннең антиподы итеп уйланылган. Дөньяга капма-каршы ике мөнәсәбәттә торучы бу кешеләрне янәшә һәм каршы куеп чагыштыру алымын да бик үк уңышлы диеп булмый. Дөресендә Җәгъфәр Хөсәен Ямашевка каршы торырлык та, аның белән чагыштырырлык та фигура түгел.

Гомумән, Хөсәен һәм Җәгъфәр мөнәсәбәтләре, мөгаен, әсәрнең беренче кисәгендә генә аклана торгандыр. Соңыннан Җәгъфәр Хөсәеннән ераклашканнан-ераклаша. Һәм бу провокаторның хатлары яисә Тукайга матур булып күренергә тырышкан эпизодлары инде укучының сүрелгән игътибарын яңадан тергезергә тырышу кебек кенә тоела.

Хөсәен — Хәдичә мөнәсәбәтләре, һичшиксез, әсәрнең әһәмиятле һәм лирик юнәлешен билгели. Биредә Хөсәеннең иң якын кешесенә карата үтә җылы карашы, йөрәк хисләре гәүдәләнә. Хөсәенгә үзенең изге максатына якынлыгын да ышандырырга, алар өчен дә көрәш алып барырга туры килә. Кешеләр өчен көрәш, марксистик-ленинчыл идеологияне халыкның төрле катлауларына җиткерү эше әсәргә драматизм көче, киеренкелек өсти. Бу юлда югалтулар да, җиңүләр дә очрый. Әсәрдә шул көрәш рухы ачык гәүдәләнә. Турыдан-туры Хөсәен Ямашев йогынтысы, тәрбиясе белән революция эшенә тартылган Фәхретдиннең — пролетарлашып китүче татар крестьяны тибының — тормыш сукмакларын аеруча бер әзлеклелек белән карап, күзәтү игътибарга лаек.

Галимҗан Сәйфетдинов образын да авторның иҗади ачышларыннан берсе итеп билгеләп була. Ул үз сыйфатлары, характер билгеләре белән хәтердә кала. Үтә тәвәккәл, кыю, ләкин революцион дисциплина, конспирация таләпләрен бик үк санга сугып бетермәүче, шулай да үз юлыннан тайпылмыйча баручы революционер күз алдына килеп баса. Икенчедән, аның янәшәсендә ифрат сак конспиратор, иптәшләренең дә, үзенең дә кирәкмәгәндә ут астында калуына юл куймаучы Хөсәен Ямашев фигурасы, аның алымнары, тактикасы ачыграк гәүдәләнә.

Ә менә Ямашев янәшәсендәге Тукай образында андый художество яңалыгы күренми. Атилла Расих бу очракта Тукай турындагы популяр әсәрләр кысасыннан читкә чыкмаган. Шагыйрь бирегә мәгълүм хрестоматик шигырьләрен сөйләү һәм инде һәркемгә таныш тормыш, поэзия фактларын иллюстрацияләү өчен генә катнаштырылган кебек.

Әсәрдә, аерым очракларда, әдәби эпизодка рух, җан өрерлек күренешләргә, сурәт-тасвир кебек элементларга таяну җитми. «Хатыны аны күптәннән борчылып көтә иде,— дип яза А. Расих.— Хөсәен ашыгып баскычтан менде, хатынына бер-ике җылы сүз әйтте, тик өйгә керү белән аштан баш тартып, китап, брошюралар актарырга тотынды». Биредә Хәдичәнең ничек борчылуын да, Хөсәеннең ничек ашыгуын да, әйтелгән бер-ике сүзнең нидән гыйбарәт икәнлеген дә, Хөсәеннең ни рәвешле баш тартуын да, һиһаять, нинди китаплар актарырга тотынуын да язучы башкачарак күрсәтә ала идемә? Әлбәттә, ала иде. Атилла Расих моны эшләмәде һәм образлы күренеш тә туа алмады. Герой нәкъ үзе буларак, кеше буларак күренми калды.

Кызганычка каршы, трилогиядә моңа охшаган мисаллар очраштырып тора-

лар. Художестволы сурәтне инкарь итү әсәрне кабул итүне авырлаштыра, геройларны тәссезләндерә.

Тасвир-сурәтләүдәге саранлык, әдәби образлылыкка игътибарсыз карау, тормыш күренешләрен турыдан-туры әсәр битләренә күчереп утырту — сәнгатьнең җаны булган образлылык категориясе белән хисаплашмау — ахыр чиктә күренекле революционер образының сәнгатьчә гәүдәләнешенә, аның тулы ачылышына сизелерлек комачаулык китергән. Трилогиянең эшләнеше тигез түгел. Әнә шундый әдәби планда эшләнеп бетмәгән бүлекләр, югары зәвык белән, җиренә җиткереп язылган бүлекләр белән аралашып килләләр.

Минем карашымча, әлеге кимчелекләрнең нигезендә, беренче чиратта, зур күләмле әсәрнең сюжет-композиция чикләрен бик үк дөрес билгеләп бетермәү ята. Вакыйга, сюжет тармакларының күплеге, фактлар муллыгы бу очракта баш геройны характер буларак тирәнрәк эшләргә мөмкинлек бирмәгән. Катнашулары бик үк мәҗбүри булмаган персонажларның күплеге гомуми картинаны чуарлый, игътибарны тарата. Болар искә алынса, әсәр, әлбәттә, җыйнаклана, төзекләнә төшәр, аның идея-проблемалары тулырак ачылыр, ә Хөсәен Ямашев образ-характер буларак тирәнәер иде. Моңа ирешеп була. Чөнки, беренчедән, әсәр нык, җитди социаль-политик фундаментка нигезләнгән, икенчедән авторның иң яхшы әсәрләрендә («Ике буйдак», «Язгы авазлар», «Сынау» романнарында) персонажлар саны чикле, сюжет мускулатурасы нык, әдәби чаралар байлыгыннан нәтиҗәлерәк файдаланылган.

Язучы тарафыннан Хөсәен Ямашев фигурасын өйрәнү юлында башкарылган гаять җитди эш, олы хезмәт шуңа лаеклы тәмамланышны да сорый.

Композицион төзеклек, сюжет сызыкларының һәм иҗат алымнарының төп идеяне ачуга максималь рәвештә хезмәт итүе, әнә шул гармониянең бик ачык мисалы — «Ике буйдак» романы.

Әсәр бик ачык беленеп торган ике сюжет сызыгы буенча үсә — аның берсе Рәхим, икенчесе — Заһид линиясе. А. Расихның башка әсәрләрендәге кебек үк «Ике буйдак»та герой тормышының хәлиткеч борылыш ноктасы булган кискен эпизод белән ачылып китә. Рәхим авыр кайгы эчендә — аның хатыны үлгән. Ул бирәдә артык кала алмый, фән дөньясына китеп онытылырга, әлек-әлектән күңеленә тынгылык бирми килгән планын тормышка ашырырга уйлый.

А. Расих геройлары төп максат, төп идеал яктылыгында гына түгел, ә һәртөрле тормыш күренешләре эчендә дә күрсәтеләләр. Көндәлек тормыш мәшәкатьләре, уңайсызлыклары, семья борчулары — берсе дә игътибардан читтә калмый, аларны автор өстән-өстән генә сөйләп узмый. Тормыш куйган проблемалар, һәртөрле кыенлыклар белән көрәш процессы, аларны җиңеп чыгу әсәрнең әһәмиятле сюжет пружинасын тәшкил итә. Әмма тормыш-көнкүреш кыенлыкларын җиңеп, фәнгә бару процессы төп конфликтка ярдәмче роль генә уйный. Әсәрнең төп конфликты фәнгә, дөньяга карашларның бәрелешенә кайтып кала. Рәхим кеше буларак та, галим буларак та, шул конфликт аша ачыла. Шулай итеп реалистик образның табигый бөтенлеге барлыкка килә, характер һәм автор идеясенең тәңгәллегенә ирешелә.

Уңай геройны фәкать алсу буяуларга гына манып, киресен начар итеп күрсәтү алымы А. Расих өчен гомумән чит нәрсә. Рәхимнең антиподы Заһидны һич тә классик явыз типлар рәтенә кертеп булмый. Тырышлыгы, зирәк акылы, тәҗрибәсе аның институттагы урыны, авторитеты ныгуына китерә. Шулай да аның характерындагы уңай сыйфатларның үсеп китүен чикли торган бер фактор бар: Заһид — тормыш агышына үтә ярашучан тип. Принципсызлык, әһәмиятле нәрсәләрдән читләшергә теләү, нәрсә дә булса килеп чыкмагае дип сагаю еллар буе Заһид аңында тамыр җәеп килә һәм аның хаксызлык юлына басуына сәбәп була. Хәлиткеч моментта Рәхим һәм Заһид капма-каршы позициядә калалар. Композицион төзелеш һәм конфликтның иң югары ноктага җитеп чишелешен дә шушы көрәш һәм аның нәтиҗәсе билгели. Шуңысы характерлы: әсәрнең беренче өлешендә бу бәрелешне әзерләрдәй сәбәпләр юк кебек. Алай гына да түгел: Заһид белән Рәхимнең үзара мөнәсәбәтләре иң гади һәм иң яхшы рәвештә булып, башка сюжет җепләреннән әллә ни аерылып та тормый. А. Расих тәфсилләп, зур тү-

землек һәм сабырлык белән әлеге фикер һәм карашларның котылгысыз кискен бәрелешкә алып килүен сурәтли. Конфликт укучының күз алдында әзерләнә, оеша һәм чишелә. Вакыйгалар үсешенең логик тезмәсе, көнкүреш картиналарының тормышчанлыгы характерлар үсешенең кире кагып булмаслык дәлилләнүе — биредә художник кулы гына түгел, ә фактларга һәм марксистик-ленинчыл тәгълиматка таянып эш итә белүче галим кулы да сизелә.

А. Расих вакыйгаларны объектив һәм битараф планда сурәтли. Һәрхәлдә, идея дошманнарына әверелгән Рәхимгә дә, Заһидка да авторның симпатия һәм антипатияләре ачык сизелми. Бу яктан «Ике буйдак» романы Шәриф Камал яратып кулланган объектив сурәтләү алымнарын искә төшерә. («Акчарлаклар» повесте, «Таң атканда», «Матур туганда» романнарындагы кебек). Шулай итеп, укучыга уйланырга, аның интеллектуаль эшчәнлегенә урын кала.

Ике төп образ капма-каршы позицияләрдә калсалар да, аларның берсен тоташ уңай, икенчесен тоташ кире дип санау читен эш. Бу бигрәк тә Заһидка карый. Ул нәфрәттән бигрәк, кызгану хисе уята. Бу образда билгеле күләмдә трагизм билгеләре дә бар. Ул үзенең әйбәтлегенә, намуслы кеше икәнлегенә ышанып йөри. Рәхимне эшкә алганда да, романның беренче өлешендәге башка күп кенә эпизодларда да ул үзен яхшы яктан гына күрсәтә, кешеләргә яхшылык тели. Заһид үзенең эш остасы булып әверелгән, аның төпле фәнни карашлары бар, студентлар да аны ярataлар. Аның өчен яхшы лекция укып чыгу — чын күңел азыгы, шатлык чыганагы. Ул — итагатьле, яхшы мөгамәләдәге кеше, якын кешеләренең кәефләрен бозудан да бик курка. Әмма Заһидның бу сыйфатлары тормышның салмак, әкрен агышлы вакытында гына чагыла. Әгәр кискен момент килеп чыгып, аның үз иминлегенә кагылсалар, мондый чакта Заһид һич икеләнүсез үз интересларын якларга керешә. Нәкъ әнә шундый кискен моментларда аның чын йөзе ачыла. Рәхимгә карата булган мөнәсәбәттә бу бик тә ачык күренә. Заһид электән Рәхимне белә, аны һәр очракта яклап килә. Әмма иң соңгы моментта мәсьәлә Заһидның кафедрадагы эшләре белән бәйләнгәндә — ул фәнне сатучы карьеристларны яклау юлына баса, алар өчен Рәхимнең идеяләрен корбан итә. Фән дөньясында гына түгел, мәхәббәттә дә ул шулай. Моны Заһидның Зөбәрҗәткә һәм Мәдинәгә карата булган мөнәсәбәтләрендә күрергә мөмкин. Бу мөнәсәбәтләр чын мәхәббәт булудан ерак торалар.

«Ике буйдак» күп планлы әсәр түгел, биредә персонажлар саны да чагыштырмача аз. Заһид белән Рәхимнең артык киң булмаган әйләнә-тирәсе, аз-маз белешләре һәм Рәхим белән Иван Ильич арасындагы бәхәскә кагылышлы кешеләр — әсәрдәге персонажлар башлыча менә шулардан гыйбарәт. Аеруча характер буларак иң тулы сурәтләнгәннәре — Рәхим, Мәдинә, Заһид, Зөбәрҗәт. Әдип эпизодик образларны да истә калырлык итеп сурәтли белә. Әсәрнең һәр битеннән фән сулышы, югары уку йорты атмосферасы сизелеп тора. Монда фәнни терминология, тел әйләнмәслек сүзләр артына ышыклану юк, фән дөньясы атмосферасы геройларның рухи халәтләре һәм махсус штрихлар белән дә бик яхшы тасвирлана. Бу яктан А. Расихның язу манерасы күп кенә «технологик» романнар авторларына үрнәк була ала.

Алдан әйткәнебезчә, А. Расих үзенең романнарында укучыны вакыйгалар эченә кинәт алып кереп китә. Романнарның экспозиция өлеше бик кыска, әйләнәтирәне, вакытны, портрет сызыкларын статик рәвештә тасвирлау алымы бу язучыда очрамый диярлек. Кагыйдә буларак, әсәр герой тормышындагы кискен, хәлиткеч эпизод белән ачылып китә. Геройдан нинди дә булса карар кабул итү сорала яисә аның тормышындагы бик әһәмиятле адымны атлаган чагы күрсәтелә. Билгеле инде, мондый эпизодларда геройның эчке хәле, хисләре, фикерләренә зур урын бирелә.

«Аны язгы гөрләвекләр алып китте. Әле күптәнме соң әле алар матур киләчәк турында хыялланганнар иде... Аны үлем тырнагыннан коткарырга тырышып, Рәхим булдыра алырдайның барысын да эшләде. Тик һәммәсе дә юкка гына булды...

Рәхимнең күңелен боздай салкын дәһшәт газабы ялый башлады» [1].

---

[1] Расих А. Ике буйдак. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1965 ел, 3 бит.

Геройның кемлеге һәм аның халәте турында автор әнә шулай беренче юллардан ук сөйли башлый. Болай башлау геройлар хакында информация бирү белән бергә, вакыйгаларның алга таба үсешенә дә ишарәле һәм психологик төсмерләр бирә.

Бу алым «Ике буйдак» романына гына хас нәрсә түгел. «Ямашев» романының экспозиция өлеше дә моңа бик охшаган. Яшь Хәсәен Ямашев беренче тапкыр сөекле этисенең васыятьләре белән үз идеаллары, тормышка карашлары арасында зур упкын булуын тоя. Аның күңелендә кискен әчке көрәш башлана. «Дустым Мансур»да яшь егет беренче тапкыр шәһәргә килә — бу да аның тормышындагы борылыш ноктасы.

«Язгы авазлар»да исә безнең бик күп роман һәм повестьларда булган ситуация — шәһәр белгеченең үз теләге белән авылга эшкә килүе алынган. Бу яктан ул «Күтәрелгән җирәм»не дә хәтерләтә башлый. Хәтта эпизодлар тезмәсендә аваздашлык сизелә. Фәхретдиновның авылга килеп җиткәнче юлда күргәннәре, тәэсирләре Давыдовныкына тартым. Билгеле, А. Расих Шолоховны кабатларга да, аңа ияреpгә дә теләми. Бу охшашлык ничектер ирексездән килеп чыга.

Әмма иң әһәмиятлесе, әлбәттә, бу түгел. Авторның көчле ягы — актуаль проблемаларны күл һәм оста, тормышчан итеп чишә белүендә. «Язгы авазлар» романы илленче еллар өчен аеруча җитди һәм әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрә. А. Расих, татар язучыларының беренчеләреннән буларак, авыл хуҗалыгында туган кыен хәлне нәкъ булганча дөрес итеп тасвирлый. Романның тормышчанлыгын көчәйткән тагын бер үзенчәлек — алдан уйлап куелган бер конфликт тирәсендә генә ыгы-зыгы килмичә, сюжетны чын тормыш ситуацияләре эчендә күрсәтә белү.

Язучы әсәренең башыннан ук куелган төп проблемаларны әзлекле рәвештә үткәрә, ягъни проблемалылык әсәрнең иң әһәмиятле үзәген тәшкил итә, төп идея, тенденцияләр юнәлеше бер генә минутка да онытылмый. Проблемалар догматиклыкны, күз буяучылыкны фаш итүгә яисә терлекләрне саклау мәсьәләсенә генә кайтып калмый, кеше характерларын ачып бирүдә дә зур роль уйный. Әсәрнең сәнгатьчә әһәмияте һәм авторның гражданлык кыюлыгы шуның белән аңлатыла да. «Язгы авазлар» романы — тормышчанлык позицияләреннән килгән очракта гына чын әдәби әсәр барлыкка килүе хакында сөйли торган тагын бер дәлил.

А. Расих романнарының конфликты һәрвакыт иң кардиналь, иң әһәмиятле, башлыча кеше тормышының мәгънәсен хәл итә торган олы мәсьәләләр тирәсенә корыла. Шуның белән бергә, автор тормышта була торган, көн дә очрый торган мәсьәләләрне дә онытмый.

Атилла Расихның «Сынау» романында бүгенге көн геройлары хәрәкәт итә, эш-хезмәтләре, конкүрешләре, рухи дөньялары белән бәйләнештә мәхәббәт, әхлак, гаилә мөнәсәбәтләре яктыртыла. Без эш сөючән, гадел, мөлаем кешеләр — карт профессор Галиәкбәр агай, аның кызы — кошчылык фабрикасында эшләүче сөйкемле Әлфия, фабрикага килгән яшь, тырыш белгеч Фәрит белән танышабыз. Шушы әйбәт, булдыклы, һәркайсы олы бәхеткә лаеклы кешеләрнең шәхси тормышлары бик үк көйле түгел.

Әсәрдәге геройларның һәркайсы җитди әхлак сынаулары алдында кала һәм, әйтергә кирәк, бу сынаулар югалтусыз түгел. Бәхетле финал көтеп утырган укучы да аптырашта кала: сюжет җепләре һич тә ул көткәнчә җыелмый. Якын кешеләренең рухи фаҗигаларын үзенеке итеп тоеп йөрүче Галиәкбәрнең йөрәге бернидә күтәрә алмый: туктап кала. Фәрит өметсезлеккә бирелеп, эчүчелеккә сабыша. Әлфиянең дә күңел яралары тиз генә төзәлмәс кебек. Тик Сафура гына берни булмагандай элеккечә яши бирә. Хәтта этисен җирләргә дә кайтмый.

Автор кара буяуларны мулрак салып җибәргәнме әллә? Юк, әсәрне укыганда андый уйгы кичермисең. Вакыйгалар үсеше дә, геройларның язмышлары да акланган — бу финалга А. Расих безне әзлекле алып килә. Тормыш юлын үткәндә үзебез турында гына түгел, якыннарыбыз, җәмгыять турында уйлыйк, безнең ялгышларыбыз соңыннан башкалар язмышларына тәэсир итми калмый, җиңел тормыш, тормыштагы җиңел адымнар кемнең дә булса драмасына, күңел фаҗигасына әверелә, дип әйтергә тели автор. А. Расих бу әсәрендә дә үз геройларының

гражданлык сыйфатларын да, шәхси сыйфатларын да актыртып бирүгә — тормышчан, ышандырырлык характерлар иҗат итүгә ирешкән.

Кристаллдай саф, яхшы күңелле профессор Галиәкбәр татар әдәбиятында иҗат ителгән фән кешеләре образларының иң матурларыннан берсе.

«Сынау» романы әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну, төрле фикерләр, бәхәсләр уятты. Тик бер нәрсә бәхәссез — яшь буынны югары әхлак нормалары буенча үстерү мәсьәләсенең үтә кискен, җитди куелышы, җәмәгатьчелек игътибарын шул проблемага юнәлдерү ягыннан бу романның әһәмияте бик зур.

А. Расихның сурәтләү принцибы нигезендә укучыга һәрнәрсәне җиткерү, объектив хәбәр итүгә кайтып кала. Тасвир-бизәк чараларын, сәнгатьчә алымнарны А. Расих сирәк куллана. Тел чаралары белән катлаулы психологик-лирик сурәтләр ясау үрнәкләрен аның иҗатында табып булмый диярлек. А. Расих — вакыйгаларны, күренешләрне, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне бер-бер артлы һәм объектив рәвештә сөйләү тарафдары. Конкрет күренешләрне ул артык сүз уйнатмыйча гына, гади рәвештә укучыга җиткерергә тырыша. Вакыйгалар өченче заттан сөйләнә. Ягъни, барын да белеп, барын да күреп, герой-персонажларның эчке уйларын, фикерләрен белеп торучы автор үз исеменнән сөйли. Диалоглар, гадәттә, иң гади формада, күп очракларда автор аңлатмасыннан башка бирелә. Бу хәл персонажларның уйларын сурәтләгәндә дә күренә: уйлар, тәмам эшләнеп, әзерләнеп җиткән рәвешләрендә бәян ителәләр. Персонаж үе янына авторга «дип уйлады» дигән бәйләүче сүзләрне кулланырга гына кала. Шул рәвешчә, кешеләрнең рухи халәте, эчке кичерешләре, шул мизгелдә хәлнең гомуми картинасы укучыга җиткерелеп барыла. Иң беренче планга информация, мәгънәнең тулы бирелеше куела. Авторның фән кешесе булуы, фәнчә рациональ фикер йөртү осталыгы сизелми калмый.

Шул ук вакытта А. Расих фразаларының эчке музыкаль яңгырашы, ритмик нәфислегенә тиешенчә бәя биреп җиткерми кебек. Мондый урыннарда рациональлек, фикерләү формаларын образлылыктан аерып карау ягына өстен кую кире роль уйный — әсәрнең сәнгатьчә көче, эмоциональлеге кими.

Әдәби форма һәм эчтәлекнең үзара гармониясенә ирешелмәгәндә, иң тормышчан, иң җитди проблемаларның да ачылмавы, укучы күңеленә барып җитмәве мөмкин. Бу хакыйкатьне һич тә онытырга ярамый. Нәкъ менә шушы каршылык — идеялелек, проблемалар актуальлеге, тормышчанлыгының кайбер очракларда тиешле әдәби алымнар аша гәүдәләнмәве А. Расих иҗатының үсешенә тоткарлык ясый, һәм, киресенчә, әдәби формага игътибарны арттыра төшкәндә, әсәрләрнең иҗтимагый гражданлык көче тагын да үткенләнер, эмоциональ яңгырашы көчәер иде.

Атилла Расих татар прозасында кыю рәвештә үз юлын салып баручылардан. Аның прозада үз юнәлеше, үз принциплары бар. Принципларга тугрылык һәм ышаныч, дөреслекне яклый һәм кешеләр бәхете өчен көрәшә белү — аның әдәби геройларының да аерылмас сыйфаты. Язучының дөньяга карашы белән уңай геройларының тоткан юлы, позициясе арасындагы тыгыз бәйләнеш җерым-ачык күренеп тора. Атилла Расих заман, тормыш сулышын тоеп яши, әдәбиятка тормышның үзен алып килә һәм шул тормыш күренешләрен әдәби образлар аша укучыга җиткерүнең яңа юлларын эзли.

Библиография

# ҮРНӘК БУЛЫРЛЫК ХЕЗМӘТ

Танылган әдәбият галиме Азат Әхмәдуллинның «Татар драмасы офыклары», «Татар драматургиясе» дигән китаплары бер үк вакытта диярлек дөнья күрде. Берсе — Казанда, икенчесе — Мәскәүдә. Әлеге хезмәтләрнең беренчесе нигездә бүгенге драма мәсьәләләренә багышланган. Билгеле, бүгенгене үткәннән башка күз алдына китереп булмый. Менә шуңа күрә, авторның татар драматургиясе «чишмә башы»н өйрәнүе бик табигый. Китапларның икенчесендә нәкъ менә шушы юнәлештәге эзләнүләр үзәккә алына, һәм күтәрелгән мәсьәләләр социалистик реализм методы формалашу яссылыгында яктыртыла.

Әлеге китапларны берәр төрле эчке сюжет берләштерәме? Андый сюжет бар. Мәкаләләрнең һәрберсендә дә бер уртак принцип сизелә. Сүз бүгенге заман комедиясе турында барамы, бүгенге драманың тенденцияләре һәм перспективалары яки Татар дәүләт академия театрының репертуар политикасы яисә Т. Миңнуллин, Ш. Хөсәенов, А. Гыйләҗев, И. Юзеевның аерым пьесалары хакындамы — автор әледән-әле уңай герой проблемасына әйләнеп кайта.

Кеше шәхесе концепциясе фәнни хезмәтләрнең эчке сюжетын тәшкил итә шикелле. Нәкъ менә шушы концепция мөстәкыйль тикшеренү объектлары — драматургия һәм иҗат методы теориясе мәсьәләләрен табигый рәвештә берләштерә. Яшәешнең социаль мәсьәләләреннән читтәрәк торган кешенең социализм идеяләре өчен көрәшүче иҗтимагый аңлы кешегә әверелүе — А. Әхмәдуллинның тарихи-теоретик хезмәтләрендәге эчке сюжетны хәрәкәткә китерүче үзәк чыганак әнә шуннан гыйбарәт.

«Татар драмасы офыклары» китабында эзлеклелекнең җитенкерәмәве өчен авторны беркем дә гаепләргә ашыкмас, чөнки жанр да бүтән, бурычлар да үзгә. Әмма шушы ике төрле китапта галимнең планы шактый ачык булып күз алдына килә. Иң элек аның үзара мөнәсәбәтләрдә төрле конъюнктураларга, фәндәге узгынчы модалар шаукымына бирелмәүчән икәнлеген билгеләп үтәргә кирәктер. Һәм, әлбәттә, ул, гомуми фән интересларыннан чыгып эш итүче буларак, үзенең эзләнүләре перспективасын ачык итеп күзаллый. Иҗтимагый яктан актив кеше концепциясенең, социалистик реализм методының үзәк проблемаларыннан берсе буларак, уңай герой проблемасына кушылып китүен дә автор нәкъ менә шушы галим планы нигезендә өйрәнүгә ирешә.

Галим планы төшенчәсенә, билгеле, индивидуальлеккә бәйле мәгънә дә салынган. А. Әхмәдуллинның хезмәтләреннән күренгәнчә, галимнең фикер-карашы, симпатия һәм антипатияләре тотрыклы, иҗатчы буларак, аңа җанлылык характерлы. Ә бу сыйфатлар исә китапларның укылышлы булачагына күпмедер дәрәҗәдә ышаныч уята. Югыйсә шундый очраклар да еш була: марксистик-ленинчыл методология ягыннан шактый камил дәрәҗәдәге фәнни хезмәтләр дә кызыксынусыз укыла, чөнки алар ниндидер авыр, «академик» телдә язылганнар. Телнең артык дәрәҗәдәге фәннилеге А. Әхмәдуллин китапларында да чагылып киткәли. Әмма, минем сизүемчә, китапларны күпләр кызыксынып укыр, чөнки хезмәтләрдә, әлеге дә баягы, эзләнүчән иҗатчы, хакыйкатьне ачыклау хакына, теләсә кем белән кайнар бәхәскә керүче полемист күренеп тора. Оппонентлар, әлбәттә, булыр. Кайберәүләрне Г. Камалның татар драматургиясендәге ролен күпмедер киметебрәк күрсәтү дә канәгатьләндермәс. Китапларда, чыннан да, аңа азрак урын бирелгән шикелле. Ә менә Ф. Сәйфи-Казанлы һәм шулай ук Ш. Усманов пьесаларына бирелгән характеристикалар чагыштырмача зуррак килеп чыккан. Һәм Г. Ниязбаевның «Беренче таң» драмасы Г. Коләхметов белән совет дра-

малары арасындагы күпер ролен үти дип раслау да, могаен, кайберәүләрдә бәхәс уятыр.

Театр сөючеләр һәм драматургияне өйрәнүчеләр, гадәттә, мондый китапларны көтеп алалар. Дөресен генә әйткәндә, драматургия турында әлегә азрак языла, журнал мәкаләләре дә сирәгрәк күренә, монографияләр бармак белән генә санарлык. Ә А. Әхмәдуллин «Татар драматургиясе» китабының кереш өлешендә моның кирәсен расларга тырыша. Юк, үткән чорлар драматурглары аерым-аерым, махсус рәвештә җитәрлек өйрәнелмәде әле. (Бүгенгеләре турында әйтеп тә торасы юк.) Әйтик, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Г. Кутуй драматургияләрен махсус өйрәнгәнебез бармы? Минем карашымча, Н. Исәнбәт турындагы монография дә соңлабрак дөнья күрде. Хәер, соң булса да, уң булсын. Татар драматургиясенең үзәк фигураларыннан берсе К. Тинчурин иҗатына багышлап фәнни хезмәт язылса да, ул әле киң катлау укучыларга ирешә алмыйча, ягъни басылмыйча ята. Нигәдер М. Фәйзи турында да монография күренми. Югарыда санап үтелгән кайбер әдипләр хакында аерым мәкаләләрдән ниндидер мәгълүматлар алырга мөмкин, ә менә К. Әмири, Ә. Рахманколый, Ф. Сәйфи-Казанлы һ. б. ларга карата әлегә битарафлык күрсәтелә шикелле.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: Г. Камал, Г. Колахметов, Ф. Бурнаш, Т. Гыйззәт турында кырыгынчы-илленче елларда язылган аерым монографияләрдә анализ җитенкерәми, бүгенге фән дәрәҗәсе биеклегеннән караганда, алар бездә ничектер оптимизм уятмыйлар. Өйрәнү базасыннан, тарихи-теоретик хезмәтнең нигезенә ята торган беренчел материалдан без җитәрлек файдаланмыйбыз һәм бу юнәлештә драматургияләре күпмедер кайтышрак булган кайбер милли республикалардан да калышабыз шикелле. Бу яктан караганда, А. Әхмәдуллин китапларының әһәмияте тагын да арта, һәм, аларны турыдан-туры татар драматургиясе турында гомумиләштерелгән хезмәтләрнең беренчесе итеп исәпләргә мөмкиндер.

Күренеп тора: автор зур аналитик эш башкарган; практик яктан аңа күпчелек татар драматургларының иҗат эволюциясен өйрәнергә туры килгән. Урыны-урыны белән пьесаларның эчтәлеген сөйләп чыгу белән дә мавыгып китү күзәтелгән. Дөрес, тарихи-теоретик хезмәттә иллюстратив материал аналитик башлангычны басып китмәскә тиеш. Әмма монысы да күпмедер аклана. Татар драматургиясе тарихын колачлаган хезмәттә материалларны барлаудан котылып булмыйдыр. Шулай ук Ф. Бурнаш драматургиясенең киң яктыртылуы да, бер караганда, артык гаҗәпләнү уятмый. Тикшеренүче аның иҗаты турында кандидатлык диссертациясе язган. Юк, без Ф. Бурнаш шәхесенең зур итеп күрсәтелүенә каршы килмибез. Элеккерәк елларга караган әзләнү нәтиҗәләренең бүгенге фәнни-теоретик фикерләү күзлегеннән тиешенчә каралмыйча кертелүе генә күңелдә бераз канәгатьсезлек тудыра.

Без А. Әхмәдуллинның шундый фикере белән килешәбез: социалистик реализм методының татар әдәбиятындагы беренче яралгылары Г. Колахметов драматургиясендә күренә башлый. Әлеге язучыны критик реалист итеп, пролетар әдәбиятка нигез салучы итеп санарга мы? Яңа методның башлангычы турында фикер йөрткәндә, Г. Колахметов, һичшиксез, үзәк фигура буларак калка. Автор аның революционер, гражданин, художник буларак кабатланмас шәхес икәнлеген исбатларга омтыла. (Монысы беркемдә дә икеләнү уятмый.) Әмма мәгърифәтчелек драматургиясенә (Г. Ильяси, Ф. Халиди иҗатлары, Г. Камалның беренче әсәрләре) кагылышлы күзәтүнең акцентыннан чыгып карагандa, Г. Колахметовтан пролетар драматургияне түгел, ә татар драматургиясенең барлыкка килү тарихын башлап җибәрергә кирәк дигән фикер аңлашыла. Шулаймы?

Без хаклы рәвештә Г. Камалны татар драматургиясенең атасы итеп саныйбыз. Ә тикшерелә торган хезмәттә ул ничегрәк сурәтләнә? Минем карашымча, аны Ильяси белән Халидидән әллә ни аерып булмый шикелле. Г. Камалның беренче пьесаларындагы сыйфат аерымлыгы әлеге драматурглар иҗаты фонында күрсәтеп бирелми. Хезмәттән күренгәнчә, ул үзенең карашы буенча мәгърифәтче-драматургларның уртасында тора. Камал инде, Халиди кебек, реакционер түгел, Ильяси кебек, әлегә демократ та түгел (?!). Бу фикер дә, минемчә, бәхәсле. Без Г. Камалны, иң беренче чиратта комедиограф итеп беләбез. Әмма комедия, А. Әхмәдуллин фикеренчә, «ранжир» буенча драмадан соң торырга тиешле, икенче төрле әйткәндә, татар драматургиясе Г. Колахметовтан башлана. Янә сорау туа: шулаймы?

«Татар драматургиясе» китабының бе-

ренче, икенче, өченче бүлекләре (хезмәтнең дүрттән өч өлеше) аеруча уңышлы килеп чыккан. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: Г. Коләхметов драматургиясе җентекле, тулы һәм дәлилле тикшерелгән. Яңа күзәтүләр байтак. Әлеге драматург шәхесенең авторны чын мәгънәсендә җәлеп итүе сизелеп тора. «Ике фикер» бигрәк тә яхшы анализланган. Җентекле һәм тирән. Шулай ук Ф. Әмирхан драматургиясенә дә лаеклы бәя бирелгән, художник-психолог иҗатының әһәмиятен киметергә омтылган вульгар социологларның хаксызлыгы кире кагылгысыз дәлилләр белән расланган.

Пьесаларның исемнәре турында фикер йөртү, ачыграк әйткәндә, Г. Коләхметовның «Яшь гомер»ен «Яшьлек» исеме астында күрү шулай ук кызыклы. Мондый очракта пьесаның исеме Ф. Әмирханның «Яшьләре» белән «туганлаша», тема уртаклыгы да ачыграк күренә, Г. Коләхметов белән Ф. Әмирхан пьесаларының әһәмияте арта төшә шикелле.

Драматург М. Фәйзи иҗаты китапта реализмның яңа сыйфат казанышларына ирешүен күрсәтү рәвешендә яктыртылган. Шунысын да әйтергә кирәк: аның совет чоры иҗаты күпмедер идеаллаштырылып бирелә. Бу җәһәттән Б. Гыйззәт «Күпмилләтле совет театры тарихы» исемле хезмәтендә реальрәк караштa тора кебек тоела. Шулай ук А. Әхмәдуллинның да күпчелек фикерләре ышандырырлык итеп әйтелгәннәр.

Иң әһәмиятлесе, революциягә кадәрле татар драматургиясе традицияләренә багышланган беренче бүлектә, кайбер төгәлсезлекләр булуга карамастан, теманың үсеш-хәрәкәте киң итеп ачып бирелә, пролетар әдәбиятта, критик реализм һәм романтизм әдәбиятында социалистик чорның төп иҗат методы тууга китерүче сыйфатларның туктаусыз арта баруы ышандырырлык итеп күрсәтелә.

Методологик яктан караганда, китапның икенче бүлеген, мөгаен, иң камил бүлек итеп исәпләргә мөмкиндер. «Яңа идея-эстетик принциплар эзләү юлында»... Бүлектә Октябрьдан соңгы әдәбиятта социалистик реализм барлыкка килүгә кагылышлы мәсьәләләрнең күтәрелүе аның фәнни кыйммәтен бермә-бер арттыра. Хезмәтнең бу өлешендә драматургия иҗтимагый тормыш, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге бәхәсләр фонында тикшерелә. Ә менә мондый фон башка бүлекләргә бик үк җитенкерәми.

Өченче бүлекнең дә уңышлы яклары шактый. Героик-революцион драма жанры җирлегендә шәхес концепциясе — яңа тормыш, социалистик идеаллар өчен актив көрәшүче шәхес концепциясенең социалистик реализм методына хас яшәеш алуы нәкъ менә шушы бүлектә күрсәтелә, әлеге чор драматургиясенең үзенчәлекләре ачып бирелә. Чыннан да бу елларда язылган әсәрләр яңа дөньяның тууын документаль төстә яктыртулары белән кызыклы. Әйтик, Ш. Усманов, Ф. Сәйфи-Казанлы, Ф. Бурнаш, Г. Ибраһимов һ. б. авторларның драматургиясендә чынбарлык белән аларның сәнгатьчә бирелеше арасындагы аралык шулкадәр «тар» ки, геройның тормыш моделе характерның эстетик гәүдәләнешеннән әллә ни аерылып тормый.

Китапның дүртенче һәм бишенче бүлекләрендә, уңышлы табышлар булуга карамастан, кайбер югалтулар да күзгә ташлана. Авторның комедия жанрына карашы беркадәр әйтеп үтелде инде. Романтик форма һәм жанрларга килгәндә, романтизм төшенчәсен, реалистик метод эчендәге сурәтләү тибы буларак, киңрәк һәм төгәлрәк аңлату сораладыр. Хәер, бу шактый катлаулы мәсьәлә, һәм аны махсус рәвештә өйрәнергә кирәктер. Автор инде болай да юл уңаеннан күп кенә мәсьәләләргә туктала.

Менә без Азат Әхмәдуллинның ике китабын күздән кичердек, татар драматургиясен проблемалы өйрәнү үрнәге белән очраштык. Кабатлап әйтик, драматургия буенча гомумиләштерелгән мондый хезмәтләр моңарчы бездә юк дәрәҗәсендә иде әле. Кайбер бәхәсле фикерләр тудыруга карамастан, әлеге хезмәтне, димәк, татар совет әдәбият белемендәге җитди казаныш итеп бәяләргә хакыбыз бардыр.

**Рәүф ИГЪЛАМОВ.**

# ШИГЪРИ ӘКИЯТ

Олылар өчен дә, балалар өчен дә күп кенә кызыклы әсәрләр иҗат иткән язучы Батулланың рус телендә беренче китабы — «Сын-журавль» басылып чыкты. Анда нәниләр өчен кыска-кыска өч әкият бирелгән. Аларның өчесендә дә җанвар-җәнлекләр тормышы, кош-кортлар дөньясы сурәтләнә. Һәм аларның өчесе дә Батуллага хас поэтик фикерләүгә корылган. Өчесе дә бик кызыксынып укыла.

Әмма шушы китапка исем биргән бер әкияткә — «Торна-малай» әкиятенә аерым тукталасы килә.

Башта әкиятнең эчтәлеген искә төшерик.

Балалары булмаганга кайгырышып гомер итүче карт белән карчыкка торналар бер малай калдырып китә. Ләкин картлар башта аның торналар бүләге булуын белми әле. Малай әкияттәгечә «ай үсәсен көн үсеп», тиз арада үсмер егеткә әйләнә. Ә бер көнне карт аучы-мәргән, улын үз һөнәренә өйрәтергә теләп, аны яланга алып чыга. Әмма, үч иткәндәй, бер киек тә очрамый... Инде кайтып барган чагында гына күк йөзендә торналар көтүе күренә. Шунда карт, улының каршы төшүенә, айваена карамыйча, торналарга ата.

Ядрә көтү башлыгына тия. Һәм нәкъ шул вакыт, карт янәшәсендә басып торган малай торнага әйләнә дә очып китә. Карт ялварып та, гафу үтенеп тә карый. Ләкин малай китә. Ул торналар көтүенең башлыгы урынын алып, күздән югала...

Әкиятнең ахыры әнә шундый үзәк өзгеч моңсу күренеш белән тәмамлана. Әнә шул гаять мәгънәле күренеш хәтергә нык сеңеп кала, озак уйландыра.

Бу әкияттә Батулланың иң әйбәт әкиятләренә хас бер сыйфат ачык гәүдәләнә: әсәр тирән фәлсәфи фикергә корылган, әнә шуңа нигезләнгән. Һәм ул фикер ниндидер эчке мәгънә булып кына калмый — ул фикер әкиятнең башыннан алып ахырына кадәр яшәүче, һәр җөмлә аша сизелеп һәм әкрен-әкрен көчәя килүче тәэсир булып чагыла. Һәркемгә аңлаешлы һәм беркемне дә битараф калдырмаучы тәэсир булып! Алай гына да түгел: уң әсәрнең бөтен тукымасында эрегән хәлдә — шигърият дәрәҗәсендә яши.

Менә әкиятнең үзәге итеп алынган образлы күренеш — метафора. Балалары булмаган карт белән карчыкка торналарның ярдәм итүе, малай калдырып китүе — әсәрдә табигый яшәү хасил ителү дип аңлашыла. Карт белән карчык күңелләре теләгән нәрсәгә, ягъни бүтәннәр кебек яшәүгә — гармониягә ирешәләр. Яшәү гармониясенә!

Әмма, үзенең бәхетсезлегенә күрә, әкияттәге карт бу гармониянең нигезен, чыганагын, тамырын аңламый. Ул уйлап тормыйча — торналарга, димәк, табигатькә, димәк табигый яшәүгә, димәк, үзенең бәхетенә каршы кул күтәрә.

Карт мылтыктан ату белән, аның малаеның, торнага әверелеп, аннан очып китүе — әсәрдә бик тә гыйбрәтле әхлакый сабак булып яңгырый. Әкияттәге карт инде укучы күз алдында торнага гына атмый. Ул үзенең малаена ата, үзенең дәвамчысына ата! Үз тамырына үзе балта чаба!

Кешеләр яшәеше өчен бик тә мөһим булган әнә шундый әхлакый нәтиҗә ясала бирелә. Дөньядагы, табигатьтәге һәр нәрсә нечкә, ләкин нык җепләр аша бербересенә бәйләнгән икән. Гаять тә тыгыз бәйләнгән икән. Табигать белән кеше алар — бербөтен икән. Шуңа күрә кеше торнага дип атса да — ядрә аның үзенә килеп тия икән! Шуңа күрә кеше бик тә игътибарлы булырга тиеш икән! Бигрәк тә кулында мылтык булса...

...Бер әкият белән танышу укучы күңелендә әнә шундый бик җитди уйлар, көчле тойгылар уята!

**Илбарис НАДИРОВ,**
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор секторы мөдире.

**Мирфатих Зәкиев,**
филология фәннәре докторы, профессор

# КАЗАН ТАТАРЛАРЫ НИ ӨЧЕН МАРИЧА — СУАС, УДМУРТЧА — БИГЕР?

Хәзерге казан татарларын Иделнең уң ягындагы марилар — суас (суяс яки сюас) дип, удмуртлар бигер дип атап йөртәләр. Моны галимнәр төрлечә аңлатып караганнар, ләкин лингвистик, археологик, антропологик, этнографик, мифологик һәм башка төр тарихи фактларга бердәй дәрәҗәдә туры килерлек аңлату таба алмаганнар. Шуңа күрә бу атамаларның кулланылу тарихын халык тарихына бәйләп өйрәнү һаман актуаль булып кала.

Алдан ук әйтеп куярга кирәк: халыкның этник тарихын (килеп чыгышын) аңлата торган теориягә, әгәр дә ул дөрес булса, бер генә тарихи (археологик, этнографик, антропологик, лингвистик, мифологик һ. б.) факт та каршы килмәскә тиеш. Менә шуны истә тоткан хәлдә, суас һәм бигер сүзләренең ерак тарихтан китергән хәбәрләрен эзләп карыйк.

XX йөзнең беренче чирегендә казан татарларында татар этнонимы (халык исеме) үзатама буларак ныклап урнашып җитә. Моңарчы казан татарларында казан кешесе, казанлы (рус елъязмаларында: казанцы) этнонимы бик озак яши, аңа кадәр болгар этнонимы шактый нык таралган була. Ни өчен казан татарларының күршеләре — мариларда һәм удмуртларда бу этнонимнар кабул ителмәгән, ни өчен алар хәзерге казан татарларын суас һәм бигер этнонимнары белән атыйлар? Бәлки суас сүзе марича, бигер сүзе — удмуртча билгеле бер мәгънә белдерәдер, бәлки аларның берсе — мари, икенчесе удмурт теле сүзләредер? Юк икән. Галимнәр суас һәм бигер сүзләренең марича да, удмуртча да булмавын исбатлаганнар. Димәк, бу сүзләр казан татарларын формалаштыруда катнашкан кабиләләрнең кайчандыр үзатамалары булганнар.

Билгеле булганча, болгарларда гарәп алфавитына нигезләнгән язу X йөздән башлана, XIII йөздән кабер ташларына язу активлаша, ләкин бу язмаларда суас сүзе дә, бигер сүзе дә теркәлмәгән, ә болгар һәм суар этнонимнары берничә язмада очрый. Димәк, Урта Идел буенда язу кулланыла башлаган чорда болгар һәм суар этнонимнары шактый рәсмиләшә, ә бигер һәм суас этнонимнарын куллану сирәгәя бара, аларны башлыча күршеләр (марилар һәм удмуртлар) кулланалар һәм хәзерге көнгә кадәр саклап киләләр.

Әйтелгәннәр түбәндәге нәтиҗәгә килергә мөмкинлек бирә: димәк, хәзерге казан татарларының элегрәк казан кешесе, аннан да алда болгар дип аталган өлеше борынгы чорда суас һәм бигер исемнәрен йөрткән җирле кабиләләргә болгарлар кушылу юлы белән оешкан. Ягъни болгарлар килгәнчегә кадәр, Урта Идел буйларында борынгы угро-фин кабиләләре белән янәшә төрки телле суаслар һәм бигерләр яшәгән. VII йөзнең соңгы чирегеннән башлап, бирегә Төньяк Кавказ, Азов тирәлә

---

Мәкалә фикер алышу тәртибендә басыла.

реннән хәзәрләр тарафыннан куылган болгарлар күченә башлаган. (Ә хәзәрләрнең үзләрен Каспий диңгезе һәм Кавказ тирәләреннән гарәп яулары кысрыклап чыгарган). Урта Идел — Кама тирәләрендә VIII йөз ахырларында болгарлар шактый күбәйгәннәр, элекке традиция буенча X йөздә Болгар дәүләте төзегәннәр. Бу дәүләткә болгарлар үзләре, җирле төрки кабиләләрдән бигерләр, суаслар, суарлар (бәлки суарлар да бу чорда Кама буенда инде җирле халык булганнардыр), мишәрләр һ. б., җирле угро-фин кабиләләреннән марилар, удмуртлар, мордва-эрзялар һ. б., шулай ук марилар һәм суаслар аралашуыннан формалашкан суасла марилар (хәзерге чувашларның борынгы бабалары) тулысынча яки өлешчә кергәннәр. Болгар дәүләте составына тулысынча яки тулысынча дип әйтерлек кереп калганнары соңга таба болгарлашып киткәннәр, болгар этнонимына да күнегә башлаганнар, ләкин алар үзләренең элекке атамаларын да югалтып бетермәгәннәр, күрше халыклар да аларны саклаган. Шундый этнонимнарга суас һәм бигер сүзләре дә карый.

* * *

Суас этнонимы хәзер Тау ягы, Иделнең уң ягы марилары гына кулланыла. Элегрәк, мәсәлән, XVIII йөздә һәм аннан да алдарак, бу этноним болын як (Иделнең сул ягы) мариларында да кулланылган булса кирәк, чөнки XVIII йөздә Казан губернасындагы халыкларны махсус өйрәнгән (димәк, беренче чиратта Иделнең сул ягындагы марилар белән танышкан) Г. Ф. Миллер үзенең «Описание живущих в Казанской губернии языческих народов» дигән китабында татарларны гомумән мариларның (чирмешләрнең) суас дип атаулары турында яза. Соңга таба Казан тирәсендә яшәгән болын марилары суас урынына әкренләп татар сүзен кабул итәләр.

Суас сүзенең этимологиясенә килгәндә, бу турыда төрле фикерләр әйтелгән. Ләкин аларның берсен дә хәзергә дөрес дип танырлык түгел. Безнең уебызча, суас сүзе үзенең төзелеше белән төрки этнонимнары системасына ятышлы, шуңа күрә аны су-ас дип таркату дөрес булыр. Андагы су тамыры суасларның су, елга белән бәйләнешле булуларын күрсәтә. Суар һәм болгар (болыг — шулай ук су, елга дигән мәгънәне белдерә) кабиләләре дә елга, су белән бәйләнешле булганнар. Суасның икенче өлеше ас, эр сүзенә синоним буларак, төрки кабиләләрне атау өчен кулланыла торган бик борынгы сүз дип санала ала.

Дөрес, хәзерге рәсми әдәбиятта ас (асы, асе, аз, яс) сүзе — иран телле кабиләләрнең этнонимы дип таныла. Асларны борынгы грек тарихчыларының кайберләре (Птолемей — б. э. II йөзе) сармат кабиләсе дип, кайберләре (Стефан Византиец — б. э. VI йөзе) скиф кабиләсе дип санаганнар. Бәхәсле булса да, скиф һәм сарматлар иран телле дип танылганлыктан, кайбер галимнәр асларны да автоматик рәвештә иран телле булган дип уйлыйлар[1]. Хәзерге көндә скифларның да, сарматларның да төрле телдә сөйләүче күп кабиләләрдән торган булуы ачык исбатланган. Шуңа күрә скифны һәм сарматны бары иран телле булган дип әйтү ни дәрәҗәдә ялгыш булса, ас (яс) кабиләләрен дә иран телле дип тану шул кадәр үк хата санала ала. Асларны иран телле осетиннар белән тиңлиләр. Янәсе, осетиннар башта үзләрен ас дип йөрткәннәр, соңыннан карачайларны ас дип атаганнар. Ләкин тарихта бер генә халыкның да үз исемен башкаларга биргәне очрамый.

Ас сүзенең төрки телдә сөйләүче кабиләләргә карата кулланылуын исбатлау өчен фактлар гаҗәеп күп. Беренчедән, әле генә әйтелгәнчә, карачайларны һәм балкарларны осетиннар гомер-гомергә асы (асе) дип атыйлар. Икенчедән, борынгы рун язмаларында аз (ас, яс) дигән кабиләләрнең, кыргызлар белән бергәләп, түрк дигән кабиләләр янында яшәүләре хәбәр ителә. В. В. Бартольд, борынгы төрки рун язмаларына таянып, ас (яс, аз) дигән кабиләләрне кыргызларның һәм түргешләрнең бер тармагы булган дип саный. Мәхмүт Кашгари азкеш(е) дигән төрки кабиләсенең булуы турында яза. XI йөзнең башында яшәгән Әл-Бируни алан һәм асларның телләрен хорезм һәм печенег (бәҗәнәк) телләренә якын дип белдерә. Бируниның чордашы булган борынгы рус тәрҗемәчесе (ул Иосиф Флавий тарафыннан б. э. 90 елларында язылган «История Иудейской войны» китабын тәрҗемә итә) алан сүзен ас дип

[1] Карагыз: Абаев В. И. «Скифо-сарматские наречия». — «Основы иранского языкознания». «Древнеиранские языки» китабында. М., 1979, 281 бит.

ала һәм асларның теле печенег теленнән туган ди[1]. Рус елъязмаларында Святославның хәзәрләргә 965 елны яу чабуы һәм хәзәрләрне, ясларны, косогларны җиңүе турында әйтелгән. Бу хәбәрне Ибн Хаукаль язмасы белән туры китереп, күп кенә галимнәр Святослав походын Идел буендагы хәзәрләргә, болгарларга һәм бортасларга ясалган поход булган дип уйлыйлар. Венгр галиме Ерней да шул ук фикерне куәтли: руслар җиңгәч, Болгардан Венгриягә яс дип атала торган мөселманнар күченделәр дип яза. С. М. Шпилевский XII йөздә яшәгән рус кнәзе Андрей Боголюбскийның хатыны болгар булган ди[2], ә В. Н. Татищев А. Боголюбскийның хатынын «княжня яская» дип атый, үзен (Боголюбскийны) 1175 елда хатынының туганы (шурин) Кәчек дигән кеше үтергән дип хәбәр итә[3]. Бу хәбәрләр яс(ас) исеменең болгарларга карата кулланылуы турында сөйли.

Шуңа карамастан, күп кенә галимнәр Святослав һөҗүм иткән һәм җиңгән хәзәр, яс, косог дигән этник төркемнәрдән яс һәм косогларны аерып алалар да аларны иран телле дип игълан итәләр. Ас — осетин, ә косок исә черкес белән тиңләштерелә. Чөнки ясларны борынгы язучылар аланнар белән тиңлиләр, ә аланнарны тулысынча иран телле дип санау традициягә кергән. Ләкин шул ук вакытта аланнарның төрки телле кабиләләрдән торулары турында да хәбәрләр бик күп, мәсәлән, карачай-балкарлар үзләрен гомер-гомергә алан дип атыйлар, аларны менгрел һәм ногайлар да алан дип йөртәләр. Косог этнонимын төркичә казак сүзеннән ераклаштырырга тырышсалар да, ул кыргыз-кайсаклар аркылы барыбер кайсак-казак сүзенә барып тоташа; аннан соң рус тарихында хәзәрләрнең күпләп рус казакларында әйләнеп, казак исемен алулары да юкка түгел: хәзәрнең икенче исеме — косок — казак булган дип уйларга да нигез бар, димәк, косок — төрки этноним, төрки телле кабиләләрне атау өчен кулланылган.

Ас (яс, асы, әсе) этнонимы белән төрки телле кабиләләрнең аталуын тагын түбәндәге фактлар да раслый. В. В. Бартольд әсәрләрен басарга әзерләүче В. Ромадин, «Бадаи ат-таварих» (XVII йөз) әсәрендә кыргызларны ас дип атауга таянып, кыргыз һәм хакас этнонимнарының соңгы өлеше ас (аз) сүзеннән тора дип белдерә. Моңа өстәп, бортас этнонимында да ас сүзенең булуын әйтергә мөмкин.

Ас тамыры тагын язгыр (Кашгарича, угыз кабиләсе), ясыр (төркмән кабиләсе), язык (сармат кабиләсе) этнонимнары составында да бар. Бу очракта аның төрки телле кабиләләрне белдерүе турында шикләнмәскә мөмкин.

Шулай итеп Птолемейдан ук төрле язмаларга кереп килгән ас (яс, асэн, эсе) сүзе төрки телле кабиләләрне атау өчен ар (ир, эр) сүзе белән параллель кулланыла торган этноним дип танылырга тиеш. Асны иран телле диючеләр аның мәгънәсен авестина телендәге асу (тиз, быстрый) сүзеннән чыккан диләр, ләкин ул төркичә ана (башкорт. әсә) яки ата сүзенә (чув. аса, ача) барып тоташа булса кирәк.

Ас сүзенең төрки кабиләләрне атау өчен шулай киң таралган булуы тагын бер фикергә этәрә. Мәгълүм булганча, Скандинавия халыкларының борынгы иҗатларында — сагаларда мифологик ас (алла) турында сүз алып барыла. Кайбер галимнәр бу ас сүзен Азиядән килеп кергән һәм азия сүзенең тамыры да шул ас сүзеннән ясалган диләр. Ас сүзенең без белгән географиясе генә дә бу фикернең нигезсез булмавы турында сөйли.

Шулай итеп суас сүзе, төрки тел этнонимы буларак, суар, болгар атамалары кебек үк, үзенең чыгышын я тормышын су белән бәйләгән кабиләләрне атау өчен кулланыла, су кешеләре дигән мәгънәне аңлата.

Суас сүзе марийларда, этноним буларак, суас формасында — казан татарларын, суасла мари формасында чувашларны атау өчен кулланыла. Шуңа күрә суас этнонимы кулланылышын тикшергән барлык галимнәр татар тарихына да, чуваш тарихына да мөрәҗәгать иткәннәр.

Марийларның татарларны — суас, чувашларны суасла мари дип атаулары, барлык тарихи фактларны логик дөрес тәртипкә китереп караганда, түбәндәге тарихи-этник нәтиҗәне ясарга мөмкинлек бирә.

Хәзерге казан татарлары, башка халыклар кебек үк, бик зур үсеш юлы үткән-

[1] Кляшторный С. Г. Древнетюркские рунические памятники. М., 1964. 174—175 битләр.
[2] Шпилевский С. М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. Казань, 1877. 115 б.
[3] Татищев В. Н. История Российская. Т. I. М.—Л. 1962. 375 б.

нәр, бик күп компонентлардан кушылып формалашканнар, шуңа күрә төрле чорда төрле этноним йөрткәннәр. Татар исеме XIX йөз ахырында XX йөз башында гына ныклап кереп урнаша, аңа кадәр казан кешесе (казанлы), болгар этнонимнары актив кулланылган. Ә марилар ул халыкны һаман суас дип атыйлар. Димәк, шул аңлашыла: хәзерге казан татарларын формалаштыруда катнашкан иң борынгы кабиләләрнең берсе (иң көчлесе янсә мариларга күрше булганы) суас дигән исемне йөрткән. Суасларның бер өлеше марилар белән аралашып яшәгәннәр һәм хәзерге чувашларның борынгы бабалары шулар кушылуыннан формалашкан. Шуңа күрә суас белән кушылмаган марилар аларны суасла мари (суастай мари, суаслашкан мари, суаслы мари) дип атаганнар һәм атыйлар. Суасларның мари белән кушылмаган өлеше, ягъни татар халкын төзүдә катнашкан өлеше, үзләренең мари белән кушылган тел кардәшләрен суас дип атап йөрткәннәр, чөнки суас һәм мари кушылып оешкан халык арасында суаслар күбрәк булган: моның шулай икәнлеген аларның теле дә раслый, суасла мари (чуваш) теле гадәти төрки тел белән мари теле арасында торса да, анда төркилек өстенлек итә, төп төзелеше буенча ул — төрки. Билгеле, суасларның соңыннан болгарлар белән кушылган өлеше дә гасырлар буе күрше кабиләләр, шул исәптән, угро-фин телле мариларның борынгы бабалары белән дә аралашмыйча, «чиста» килеш кенә яшәмәгәннәрдер. Шуңа күрә суас телендә әле суас һәм маридан суасла мари оешканчы ук, суасла мари (ягъни чуваш) характерлы сүзләр булып, алар соңыннан болгар белән кушылгач та үзен сиздереп, болгар эпиграфикасының гадәти төрки теленә үзенчәлекле колорит бирдергәннәрдер.

Суас һәм мари кушылмасында суаслар өстенлек алганлыктан, бу кушылмадагы марилар да үзләренә суас этнонимын кабул итәргә мәҗбүр булганнар, ләкин алар су сүзеннән ясалган суас этнонимын башта үзләренең элекке угро-фин телләренә тәрҗемә итеп кулланганнар: үзләрен ведь дип атаганнар. Ведь угро-финча су мәгънәсен бирә. Чувашларны (суасла мариларны) борынгы русларның — веда дип, мордваларның элгрәк — вьедена, хәзер ветьке дип атаулары суасла мариларның мари өлешеннән алынган булырга тиеш. Соңга таба суасла мари бер халык булып формалашып җиткәч, аларда суастан килә торган суас этнонимы берегеп калган һәм ул соңыннан чуаш формасын алган: тарихта суас сүзенең чуаш сүзенә күчеп җитмәгән суэшь яки чуас формалары да теркәлеп калган.

Суасларның марилар белән кушылмаган өлеше, ягъни чувашларны формалаштыруда катнашмаган өлеше, соңыннан болгар дәүләтендә кала, болгарлар белән аралаша һәм билгеле бервакытка дәүләт исемен — болгар сүзен этноним итеп кабул итә, ләкин үзенең элекке суас этнонимын да онытып бетерми. Татарларның Казан өязендәге ясак, имана түләп торган элекке бабалары әле XVII йөздә дә үзләрен суас (диалекталь әйтелешләре: сюась, чюас, сюэшь, чюашь) дип йөрткәннәр булса кирәк, чөнки «Писцовая книга»ларда аларны «ясачные чюваши» дип язганнар. Ясак түләүдән котылып, хөкүмәткә хезмәткә күчкәч, ясак түләүче бу чувашларны (чюасларны) «служилые татары» («йомышлы татарлар») дип йөртә башлаганнар. Күрәсең, җирле сюас этнонимы социаль яктан түбәнрәк катлауны атау өчен, ә Алтын Урда аркылы килгән татар этнонимы социаль яктан югарырак баскычта торган кешеләрне атау өчен кулланылган. Димәк, татар сүзе социаль авторитет та казанган, шуңа күрә ул соңгы чиктә халыкның үз атамасы булып урнашуга да ирешкән. Ләкин мариларга гомер-гомергә күрше булган суаслар, кайчандыр болгар, казан кешесе атамаларын алып онытсалар да, ахыр чиктә татар этнонимын үзатама итеп беркетсәләр дә, күрше марилар өчен алар барыбер суас булып калганнар. Менә шунлыктан марилар татарларны суас дип атыйлар да инде. Ә суасларның марилар белән кушылган өлеше үзләрен суас (чуаш-чуваш) дип атасалар да, марилар өчен алар суасла мари булып калганнар.

Суасла марилар (чувашлар) Болгар дәүләте составына нигездә керми калалар, анда кергән өлеше болгарлаша. Нәкъ менә Болгар дәүләтенә кермәгәнлектән, чувашлар антропологик яктан да, этнографик яктан да, тел ягыннан да болгар үзенчәлекләрен үзләштермәгәннәр.

Шулай итеп, хәзерге чуваш халкы белән татар халкы арасындагы этник уртаклык болгар чорына түгел, болгар формалашканчы булган чорга карый. Бу нәтиҗә суас

этнонимы кулланылышы белән генә түгел, этнографик, археологик, антропологик, мифологик, эпиграфик фактлар белән дә раслана, аларга каршы килми.

• • •

Бигер этнонимы турында да шактый күп язылган, хәзерге татарларны удмуртларның бигер дип, тарихи хезмәтләрдә болгар дип атауларыннан чыгып, күп галимнәр бигер сүзен болгар сүзенең үзгәргән варианты дип аңлаталар. Ләкин аның болгар сүзеннән үзгәргән булуын бернинди фонетик закончалык белән аңлатмыйлар, чөнки аңлату мөмкин түгел. Шуңа күрә бигернең этимологиясен гомуми төрки һәм Идел-Кама буенда очрый торган башка этнонимнар системасына салып ачарга омтылу дөресрәк булыр.

Бу система схемасы белән якын килсәк, бигер этнонимын ике өлештән тора дип карый алабыз: бик-эр. Икенче өлештәге эр төркиләрнең иң борынгы «кешеләр» дигән сүзенә туры килә. Беренче өлешендәге биг (биек, бәк, би) тамыры төрки телдә нык, таза, бай, хуҗа, башлык, ир, бөек, батыр (крепкий, прочный, зажиточный, хозяин, герой, муж, супруг, правитель, вождь, господин) мәгънәләрендә кулланыла. Кыскасы, үзен бу тирәләргә хуҗа итеп сизгән бай, бөек (биек, бик) кешеләр үзләрен бигер (бик-ир) дип атый башлап, шул этнонимга әйләнеп, күрше удмуртларга да кергән һәм аларда бүгенге көнгә кадәр сакланып калган. Болгарлар күплэп килеп, Болгар дәүләте төзелгәч, бигер кабиләсе, суас кабиләсенең марилар белән кушылмаган өлеше белән һәм тагын башка җирле кабиләләр белән бергә, болгар халкын формалаштыруда да катнашкан, әкренләп болгар этнонимын, соңыннан казан кешесе, ниһаять татар этнонимын да кабул иткән. Ә күрше удмуртлар аларны бигер дип атауны гасырдан гасырга күчереп дәвам иткәннәр.

Бигер этнонимындагы бик сүзенең синонимнары буларак төрки телләрдә һәм диалектларда би, ийе, ийә иде сүзләре йөри. Би сүзе олы, зур, бөек, бай мәгънәләрен белдерә (чагыштыр: биата, зурәти, олэтәй, биана, зуринә, бий, бикә). Би тамыры күплек кушымчасы белән бергә шушы мәгънәләрдә этноним ясауда да катнаша: биләр, аның башка диалекталь әйтелеше — байлар. Биләр этнонимы Идел буе болгарлары белән яши торган кабиләләр арасында белер-билер-биләр формаларында бик күп чыганакларга теркәлгән, ә байлар дигән кабиләләрнең эзе татарлар арасында бүгенге көнгә кадәр югалмаган. Биләр шәһәрен төзүчеләр дә шул биләр кабиләләре булганнар.

Кайбер тарихи язмаларда Биләр шәһәрен һәм кабиләләрен Бүләр дип аталган шәһәр яки кабиләләр белән тиңләштереп йөртәләр, ләкин Биләрне Бүләргә тиңләү дөрес булмаска тиеш. Чөнки Биләр шәһәре һәм кабиләләре әнә шул биләр (бай, бөек кешеләр) исеме белән бәйләнгән булса, Бүләр шәһәре һәм кабиләләре башка булып, аларның исеме дә бүлү тамырыннан ясалган булса кирәк. Бу фикерне исбатлау өчен, С. М. Шпилевский теркәп калдырган Бюлюмер дигән шәһәрнең булуын искә төшерергә була. Бу исем шәһәрне бүлем кешеләр яки бүленеп чыккан кешеләр салганын күрсәтеп тора. Бүлем ирләр (Бюлюмер) булгач, бүлирләр (бүләрләр) дә булырга тиеш. Тарихчылар Идел буендагы Булымер авылының шул элекке Бюлюмер шәһәрчегенә туры килүен билгелиләр. Биләр һәм бүләр (бүлемәр) этнонимнарының төрле мәгънәдәге төрле сүзләрдән ясалган булуы да Бүләр (Бүлүмәр, Бүлүмәт) һәм Биләр шәһәрчекләренең бер үк түгеллеген күрсәтә булса кирәк.

Урта Идел һәм Кама буйларында халыкны ар (эр, ир) сүзе белән атау гадәти булган: биек-әр, су-ар, болг-ар, мишә-әр һ. б. Шулай булгач, ар сүзе бик тамырына гына түгел (бигәр), би тамырына да кушылып йөргәндер дип уйларга ныклы нигез бар, ягъни би (бөек, бай) кабиләләрен би-ләр (богатые, великие) дип тә, би-әр (богатые люди, великие люди) дип тә атаган булырга тиешләр. Хәзерге Кукмара районындагы Биер поселогының исемендә шул кабилә атамасы сакланган булуы бик мөмкин.

Бигер этнонимының бик сүзеннән ясалган һәм бик тамырының би дигән синонимы да булуын искә алып, без бигер — биләр — биар этнонимнарының бер үк мәгънәдә йөрүен белдек һәм алар бер үк кабиләләрне атаган булырга тиешләр дигән караш үткәрдек. Бигерләр (биләр, биар) болгарлар килгәнче үк Урта Идел-Кама буйларында яшәгән җирле төрки кабиләләр булырга тиеш дидек. Алар болгарлар

составында башта болгар халкын, аннан соң казан кешесен, аннан соң казан татарын формалаштыруда катнашып, шул этнонимнарны алмаштырып торсалар да, күршеләре— удмуртлар аларны һаман бигер дип атауларында дәвам итәләр.

Ә бигер (биләр, биар) кабиләләре, болгарлар килгәнче, Идел буенда күпме яшәгәннәр? Бу сорауга җавап бирү өчен, борынгы грек язмаларына мөрәҗәгать итәргә туры килә. Безнең эрага кадәр V йөздә беренче зур тарихи хезмәт язган һәм шуңа күрә «тарихның атасы» дип йөртелә торган Геродот, скифлар турында сөйләгәндә, Идел буйларында иирки дигән кабиләләр, алардан көнчыгышта башкарак телдә сөйләүче, ләкин скифча киенүче, понтик (буын-тык?) дигән агачның җимешеннән асхи (аскы яки асы) сөзеп ашаучы аргиппи дигән кабиләләр яши дип яза. Геродот хезмәтләрен өйрәнүче күп кенә галимнәр аргиппиларны төрки кабиләләр булырга тиеш дип саныйлар, башкортларның борынгы бабаларына тиңлиләр. Ииркиләр (грекча ииркәй формасындарак языла) шулай ук җирле кабиләләр дип санала, аларны я мажар (венгер, мәгълүм булганча, тарихта венгер-мадьяр тарихы мишәр тарихы белән бик нык буталган), я төрки кабиләләргә якынайталар [1].

Этнонимик төзелеш ягыннан караганда, аргиппеи сүзе төркичә ар (ир, кешеләр) һәм грекча гиппос (ат) тамырларыннан торса кирәк. Геродотның кабиләләр исемен грекчага тәрҗемә итеп бирү гадәте бар. Мәсәлән, Ихтиофаги дигән кабилә исеме грекча балык ашаучы була, меланхлены дигән скиф этнонимы грекча кара җиләнле мәгънәсен бирә. Аргиппеи сүзен дә Геродот скифлардан сораштырып, аның мәгънәсен аңларга тырышып, грек сүзен кушып ясаган булырга тиеш. Тагын кемнәр яши дип сорагач, Геродотка әр-атлар дип җавап бирелсә һәм аның икенче өлеше ат (грекча гиппос) дип аңлатылган булса, Геродотның әр-ат сүзеннән әргиппос — аргиппой сүзен ясавы бик реаль күренә. Аргиппеиләрне иран телле дип исбатларга тырышучылар да аны «белоконные» дип тәрҗемә итәләр.

Иирки кабиләләренә килгәндә, Геродот әйтүенчә, алар ау белән көн күргәннәр, урманда яшәгәннәр, һәр аучының аты, эте булган, башта җәнлеккә уктан ата, аннан соң эт белән ул җәнлекне куып тота торган булганнар. Иирки этнонимы Ийи-ирк(әй) дип таркатыла ала һәм аның мәгънәсе биг-ер (бийегәр, би-әр, би-ләр) этнонимы эчтәлегенә туры килә. Ийе (ийә) төркичә хуҗа, яхшы, бөек, бай мәгънәләрен белдерә, борынгы телдә аның иде (хуҗа, таңре, алла) варианты да очрый. Ир сүзенең борынгы һәм хәзерге төрки телләрдә ирк, иркәк дигән вариантлары да бар. Димәк, иирк этнонимы ийи-ирк өлешләреннән тора һәм эчтәлеге ягыннан шул ук бигер (биар, биләр) этнонимнарына туры килә. Шуңа күрә иирк, биар, биләр, бигер сүзләре бер үк кабиләләрне атау өчен кулланылган дип уйларга була. Геродот чорында бу этноним вариантларының иирки формасы күбрәк кулланылган.

Әйтелгәннәрдән түбәндәге нәтиҗә чыга: хәзерге казан татарларын формалаштыруда катнашкан күп кабиләләрнең берсе — бигерләр б. э. кадәр VIII—VII нче йөзләрдә (Геродот шул чор турында яза) Идел-Кама буйларында яшәгәннәр. Димәк, хәзерге фәндә бик нык таралган һәм һәрбер халыкны кайдандыр килгән дип кенә аңлата торган (миграцион) теориянең дөреслеге шик тудыра. Һәрбер халыкны бары кайдандыр килгән дип кенә аңлату әле хайваннар дөньясыннан килә торган психологиясенә— туган җирне сагыну (җирсү), аны ташламау, кайда гына йөрсә дә, анда әйләнеп кайту психологиясенә дә каршы килә. Шуңа күрә теге яки бу халык формалашуын тикшергәндә, миграцион теориягә түгел, ә автохтонлык теориясенә таяну дөресрәк булырга тиеш.

Бигер, биләр, биар этнонимнары бер тамырдан ясалганнар, бер үк кабиләләрне атаганнар, ләкин аларның төрлесе төрле дәрәҗәдә, төрле җирләрдә сакланып калганнар: бигер — удмуртларда, биләр — рус, гарәп-фарсы чыганакларында, җирле топонимикада; биар — топонимикада һәм, кайбер галимнәрнең әйтүенә караганда, Скандинавия халыкларының беренче тарихи сөйләкләрендә (сагаларда) сакланган. Соңгы очракны ачыклау этник тарих өчен аеруча кызыклы.

Мәгълүм булганча, борынгы исландларда тарихи хикәяләрне (сагаларны-сөйләкләрне) телдән-телгә сөйләп, буыннан-буынга күчереп килгәннәр. Язу барлыкка килгәч, ул сагалар язма рәвештә дә тарала башлаганнар. Хәзерге көнгә XII—XIV йөз-

---

[1] Геродот. История. Л., 1972, 519 б.

ләрдә язып алынган сагалар килеп җиткәннәр. Менә шул сагаларның күбесендә әкияттәге кебек бай, бөек ил — Биарм (Биармланд) турында сүз алып барыла.

Биарм сүзенең Пермь шәһәре исеменә бик якын булуыннан чыгып, галимнәр башта ук Биарм дигән бөек, бай илне хәзерге Пермь шәһәре урнашкан җирдә булган, пермь сүзе дә шуннан калган дип игълан итәләр. Ләкин әле XIX йөздә үк моңа нигезле каршы чыгучылар күп була. Мәсәлән, Биармия проблемасын махсус тикшергән С. К. Кузнецов Пермьның Биармия була алмавын кире кагылмаслык фактлар белән исбатлап күрсәтә[1]. Аныңча, сагаларда Биармия кимендә дүртәү. Аларда Биармия а) я теле фин теленә якын дип, финнар белән тәңгәл куела, б) я Норвегиянең төньягында дип күрсәтелә, в) я гомумән билгесез җирдә фантастик ил буларак сурәтләнә, г) я Новгород җирләре тирәсендә дип алына.

Тагын да элгәрәк, 1878 елда ук Н. И. Золотницкий Биармия илен Болгар иле белән тиңли[2]. Аныңча, Биармия иленең атамасы биар (би-әр) сүзеннән килә, биар сүзе (биек-ер, бөек ил) сүзеннән г авазы төшеп калгач ясалган. Үз чиратында, бигер, биләр, буләр, булемәр, болгар, мургар — бер үк сүзнең төрле формалары һәм алар барысы да болгарларны (аныңча, чувашларны) атау өчен кулланылганнар. Җиңгән татарларның исемен алгач та, болгарларны удмуртлар бигер дип атап йөрталәр, ди ул һәм ялгыша. Чыннан да удмуртлар болгарларны бигер дигән булсалар һәм болгардан чуваш формалашкан булса, алар хәзер, һичшиксез, чувашларны бигер диярләр иде. Ә удмуртлар татарларны бигер дип йөртәләр. Димәк, Золотницкийча да болгарлардан чуваш түгел, ә татар формалашкан булып чыга.

Н. И. Золотницкий пермь сүзен дә биардан чыгара. Аныңча, хәзерге Пермь тирәләре дә болгар җирләре булганнар һәм болгарның башка бер атамасы булган биар, коми телендәге му (җир, өлкә) сүзе белән бергә, биарму, ягъни Пермь атамасын тудырган.

Соңгы елларда Биармияне Ак диңгезгә коя торган Төньяк Двина тамагы тирәләреннән эзләргә кирәк, Биармиянең халкы кареллар булгандыр дигән фикер шактый нык тарала башлады. Ләкин галимнәрне бер нәрсә борчый: монда да, Пермь тирәләрендәге кебек үк бай, бөек илнең булуын археологик, этнографик һәм тарихи фактлар раслый алмый.

Безнең уебызча, барлык тарихи фактлар мәсьәләне түбәндәгечә куярга мөмкинлек бирә. Иң элек шуны истә тотарга кирәк: Биармия дигән бай, бөек ил башта сагага, борынгы исландлар күргән, аралашкан реаль ил буларак, килеп керә. Соңга таба аның турындагы хәбәр телдән-телгә күчеп, әкиятләштерелә, соңрак сагаларга халык иҗатына хас рәвештә хыялый детальләр белән баетылып, башка илләр, башка җирләр белән бутап кертелә. Шуңа күрә сагалардагы Биармияне башка тарихи-лингвистик фактлар ярдәмендә генә ачыклап була.

Болгар, Биләр, Бюлюмәр шәһәрләре бер үк түгелләр, дидек, шуның кебек үк, болгар, биләр, буләр кабиләләре дә бер үк түгелләр, бу атамалар да төрле сүздән ясалган. Югарыда әйткәнебезчә, бигер, биәр, биләр сүзләре бөек, бай мәгънәсендәге бер үк биек-би тамырыннан ясалганнар; бай, бөек кешеләр (байлар, бийләр) дигән кабиләләрне атыйлар. Булемәр, буләр кабиләләре — үзенә, болгар кабиләләре үзенә башкалар. Боларны шул чорның тарихи истәлекләре бутамыйлар, аерып күрсәтәләр; тик XIX—XX йөздәге кайбер галимнәр генә аларны аера белмиләр.

Сагаларда теркәлгән бөек, бай Биарм иле Болгарга да, Бюлюмәргә дә туры килми, ә болгарлар килеп, Болгар дәүләте төзегәнче үк Кама буйларында яшәгән биар (бигер, биләр) кабиләләре иленә тәңгәл килә. Биарлар үзләрен бай (би), көчле, бөек, хуҗа кешеләр дип юкка гына атамаганнардыр. Алар төрле җирләргә барып чыкканнар, башка кабиләләр белән төрле сату-алу һәм хәрби мөнәсәбәтләргә кергәннәр. Шундый мөнәсәбәтләрнең берсе Скандинавия халыклары белән урнашкан.

Бер яктан исландлар, Балтик диңгезенә, Ак диңгезгә коя торган елгалар буйлап югарыга күтәрелеп, икенче яктан биарлар төньяк-көнбатышка, төньякка барып чыгып, үзара төрле дәрәҗәдә аралашкан булырга мөмкин. 922 елда гарәп илчелеге секретарена — Ибн-Фазланга Болгар патшасы болай дип сөйли: бездән өч ай бар-

[1] Кузнецов С. К. К вопросу о Биармии.— «Этнографическое обозрение», 1905, № 2, 3. 1906, М., 59 б.
[2] Золотницкий Н. И. Лингвистическая заметка о названиях Булгар, Биляр и Моркваши. Казань, 1884, 46—48 б.

саң, уйсу-вису дигән халык бар, аларда төн бер сәгатьтән дә кыска. Димәк, Болгар дәүләтендәге халыклар — биарлар (биләрләр) төньякка ак төннәр булган җиргә барып йөргәннәр. Висү шул ук исландларның исеме булырга мөмкин: ис-ланд (ис иле).

Югарыда әйтелгән хезмәтендә С. К. Кузнецов әйткәнчә, сагалардагы Биармланд мәсьәләсен махсус тикшерүче чит ил һәм рус галимнәренең күбесе Биармияне Болгар-Биләр иле белән бәйлиләр. Сагаларга таянып, алар Скандинавия викингларының Биармия белән аралашуы IX йөз уртасыннан алып XIII йөзнең икенче чирегенә кадәр дәвам иткән дип саныйлар (94 б.), Биармиянең 1236 елда Чыңгыз хан тарафыннан җимерелүе, соңыннан рус патшасына буйсынуы турында язалар. С. К. Кузнецов Биармиянең Пермь түгел, ә Болгар-Биләр булуын исбатлый. Болгар-Биләрне монгол-татар яулары җимергәч, алардан Төньякка металл әйберләре керү дә туктала дип хәбәр итә (87 б.). Сагаларда русларның биарлар белән бергәләп исландларга каршы сугышы сурәтләнә. Рус кнәзе Бурислав (Святополк), исландлар җиңгәч, Биармиягә кача, төркиләр иленә эләгә, өч атнадан соң Новгород тирәсендә күренә. Бу эпизодны галимнәр аңлашылмаучылык диләр. Ләкин Биармияне Биләр дип уйласак, барысы да үз урынына утыра. Биләр җирләрендә төркиләр булган, биләрләр дә үзләрен элекке гомуми исемнәре белән төрек дип атаганнардыр. Кайбер тарихчылар биарларны печенеглар белән дә тиңлиләр, ә печенег сүзе ул Европа халыкларында гомумән көнчыгыш кабиләләрне атау өчен кулланыла (шунда ук, 45 б.).

Скиф чорыннан ук калган гадәт буенча төрки кабиләләрдә, изгеләр каберенә агачтан я таштан балбал (сын) ясап куеп, шуңа табыну гадәте була. Бу Идел-Кама буе төркиләрендә дә очрый, димәк, биәр кабиләләрендә дә ул гадәт булган. Скандинавия сагаларының берсендә Биармиядәге шундый бер агач балбал турында сүз бара. Аның муенында кыйммәтле муенса, тезендә тәңкәләр тутырылган савыт, янында табынучылар тарафыннан тәңкә катыш балчык ташлаудан барлыкка килгән курган. Скандинавиядән килгән кешеләр шул савыттан һәм курганнан тәңкәләр җыеп алалар [1]. Бу хәбәр дә Биармияне Биләр иле белән тиңләргә мөмкинлек бирә.

Сагаларның берсендә Биармия алласы Юмала дип бирелә. Бу хәбәр соңрак кареллардан алынган булса кирәк, чөнки аларда мәҗүси чагында ук алланы юмала дип атаганнар, дин кергәч, дини алланы да Юмала дип йөртәләр. Юмала сүзе Урал-алтай чоры сүзе булып, карелларда алла мәгънәсендә, хәзерге татарларда тынычландыру, юату, иркәләү мәгънәсендә сакланган булырга да мөмкин. Мәҗүси алланың бурычы чыннан да юмалау, тынычландыру, юату, иркәләүдән гыйбарәт. Юмалаучы илаһи көчне исландлар биар (биләр) кабиләләреннән ишетүләре дә реаль. Бәлки шул ук балбалны да биарлар юмала дип таныштырганнардыр. Димәк, сагалардагы Биармландны Биләр (Биар) иле белән тиңләү өчен фактлар бик күп.

Биар сүзенең биарм формасы алуына килгәндә, ул түбәндәгечәрәк булырга тиеш. Биарлар исландларга үзләре турында сөйләгәндә, биар сүзенә тартым кушымчасы кушып, биарым дип әйтә торган булганнар. Хәзер дә без ил генә түгел, ә илем дибез; туган җир генә түгел, ә туган җирем; авыл гына түгел, ә авылым дибез һ. б. Биарлар биарым сүзен исландларга тәрҗемә итеп, аңлатып та күрсәткәннәр: биарым, ягъни бөек, бай халкым, бөек, бай илем (ил һәм халык гадәттә бер исем белән атала), шуннан сагаларга Бөек Биармланд (ланд — ил) дигән ил турында мәгълүмат кереп калган. Шулай итеп биар сүзе сагаларда биарм формасында урнашкан. Бу — биарм сүзенең бер якка таралуы.

Биар сүзе икенче якка да таралган. Биарлар Каманың югары агымында яшәгән кабиләләргә дә үзләрен шулай ук биар яки биарм дип таныштырганнар. Анда биарлар күбәйгәч, бу җирләрне дә Биарм дип атау башланган, соңыннан шул җирләрдә үсеп чыккан шәһәргә дә Пермь дип исем кушылган. Пермь исеме хәтта шул җирләрдә яшәүче угро-фин кабиләләренә — коми-зыряннарга да күчерелгән. Руслар аларны пермяклар дип атый башлаганнар. Ә комилар үзләрен һәм җирләрен бер вакытта да пермь сүзе белән атамаганнар, үзләрен — коми, илләрен Коми отир дип йөрткәннәр.

Биәрләрнең үзәк шәһәрләре Биләр дип аталган. Соңгы елларда А. Х. Халиков

---

[1] Соболевский А. Древняя Пермь. К вопросу о Биармии. — Известия общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. т. XXXIV, в. 3—4, 1929, 25 б.

тарафыннан үткәрелгән археологик эзләнүләр күрсәткәнчә, Биләр шәһәре чыннан да бөек шәһәр дип атарлык дәрәҗәдә бай, бөек булган, Болгар шәһәрләреннән алдарак чәчәк аткан, Биләрне монгол-татар яулары гына җимергән. Биләр шәһәре һәм аның җирләрендә бигер (биләр, биәр) дигән халыклар Болгар дәүләте составында да аерымрак яшәгәннәр. Монгол-татар яулары җимергәч, Биләр торгызылмаган, Алтын-Урда чорында Болгар шәһәре генә билгеле дәрәҗәдә үсә алган, Болгар дәүләте үзенә җирле суасларны, биарларны (биләрне, бигерләрне), тәмтезләрне, эскелеләрне, суарларны, башкорт кабиләләрен, суасла мариларны, җирле угро-фин кабиләләрен ныклап буйсындыруга ирешә алган. Биарлар Алтын Урдага буйсынган Болгар дәүләте чорында да төньяк, төньяк-көнбатыш халыклары белән араларын өзмәгәннәр. Сагаларда сакланган мәгълүматларга караганда, монгол-татар яуларыннан качкан биарлар Норвегиягә киләләр, Малангер култыгы тирәләренә урнашалар, христиан динен кабул итәләр. (Кузнецов С. К. Күрсәтелгән хезмәт, 47 б.)

Казан татарларын мариларның — суас, удмуртларның бигер дип атауларыннан чыга торган мондый тарихи-этник нәтиҗәләр этнографик, археологик, мифологик, лингвистик фактларның берсенә дә каршы килми. Кайчакта «Әгәр Биармия Биләр булса, ул гарәп язмаларына керер иде, ләкин кермәгән»,— дип аптырап калалар. Монда да аптырарлык урын юк. Биарлар гарәп язмаларында биләр (белер) формасында теркәлгәннәр.

Халыклар үз күршеләренең этнонимнарын бик борынгыдан саклап киләләр икән. Шуңа күрә халыкта сакланган этноним язмада сакланган сүз кебек үк ышанычлы тарихи чыганак була ала. Бу яктан татарларның күршеләрдә сакланган суас, бигер этнонимнары, чувашларның суасла мари этнонимнары безнең тарихта аеруча әһәмиятле.

БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

Сорау:

— Язучыларга карата күңелегездә йөргән иң зур теләгегезне әйтмәссезме?

**Илһам Шакиров, РСФСРның халык артисты:**

— Әгәр башка берәр җырчыга шушы сорауны бирсәләр, бәлки, ул болай җавап бирер иде: «Тарихка керерлек музыка сәнгате шәхесләре турында роман һәм повестьлар язылса икән!» Мин алай әйтергә ашыкмыйм әле. Чөнки язып карамадылар түгел, яздылар. Әмма әдипләр музыка мәсьәләсендә сайрак эш йөртәләр, ә музыка белгечләре безгә каләм осталыгы җитенкерәми. Әйтик, атаклы «Шүрәле»се белән татар музыкасын бөтен дөньяга таныткан Фәрит Яруллин турында булсын иде чын профессиональ югарылыкта язылган бер роман. (Истәлекләр түгел.) Әмма менә шул язар дип атап әйтердәй кешене табып булмый. Әхмәт Фәйзиләрне сагынырга кала.

Бәләкәй чакта ишеткән бер җыр хәтеремдә:

Кәтринбүрдә үскән бөдрә тал,
Чит җирләргә чыгып гыйбрәт ал...

Заманында безнең як кешеләре Кәтринбүр (элекке Екатеринбург, хәзерге Свердловск), ягъни Урал якларына барып, авыр эшләр эшләп, дөнья күреп, күп гыйбрәтләр алып кайтканнар. Бу уңайдан язучыларга шуны әйтергә телим: тормышны тиешенчә өйрәнмичә язылган әсәр укучыны һичбер вакытта да ышандыра алмый. Ни өчен Нәкый Исәнбәт, аркасына биштәр асып, күп мәртәбәләр ил гизгән? Шулай ук Шәриф Камал да «тормыш географиясе»н армый-талмый өйрәнгән. Ә тормышта гыйбрәтле язмышлар, кызыклы хәлләр бихисап. Менә шул мохитта, үз геройларың арасында яшәп карасаң гына зур ышандыру көченә ия әсәр язып буладыр дип уйлыйм.

Шагыйрьләргә дә тормыштагы иҗтимагый-социаль мәсьәләләр турында тирәнрәк уйланырга иде. Ниндидер ачышы, үзенә күрә «уйлап табу»ы булмаган шигырь беркемне дә кызыксындырмый. Парижга барып, Эйфель манарасын күрүеңне язудан ни файда?! Хәзер, шөкер, шагыйрьләребез күп, яшьләребез дә үсеп килә. Әмма кайберләре артык вак темалар тирәсендә чуалалар.

Чын кеше образын гәүдәләндерү җиңел түгелдер. («Чын» сүзенә ышандыручанлык мәгънәсен дә салып әйтәм.) Ә тормыш чынлыгына ирешү өчен тормышның үзендә кайнау таләп ителә.

# Гөлшат Кутуева

## ЯКТЫ ХАТИРӘ

Иң кадерле хатирәләрнең барысын да үзенә сыйдыра алса икән бала көннәре...

Ерак еллар аша балачагым ишегән шакыйм. Комлев урамындагы артык зур булмаган бер катлы агач йорт. Ул чагында бу йортта өч гаилә торды. Өйнең ике бүлмәсе безнеке иде. Берсе — зур-зур ике тәрәзәле бүлмә, икенчесе, кечкенәрәге — әтинең эш бүлмәсе.

Бу өйдә минем балачак һәм үсмер елларым үтте, монда безнең әтиебез яшәде һәм эшләде... Ниһаять, унбиш елдан соң яңадан Казанга әйләнеп кайткач, беренче эшем итеп әлек яшәгән йортыбызга юнәлдем. Квартирабызның җанга газиз стеналарын тагын бер күрәсем килгән иде. Ләкин, өйдә беркем дә булмады ахрысы, миңа җавап бирмәделәр.

Без ул вакытта уртача тормышта яшәдек. Өебездә һичнинди артык әйбер дә юк: һәрнәрсә гади һәм кирәкле. Бары бер абажур гына бүлмәбезгә матурлык өсти. Аның якты, җылы нурлары үзенә бер төрле җыйнаклык бирә. Күп кеше шулай яши төсле. Кешеләр әйбер турында да азрак уйлыйлар кебек иде. Бүгенге кебек кызыктырырлык матур йорт җиһазлары да юк иде әле ул вакытларда... Казан үзе дә хәзер танымаслык булып үзгәрде. Элек шәһәребез Арча кыры белән тәмамлана иде. Уңайлыклары булган күп катлы йортлар да аз салынды. Хәзер Казан урамнарында чана яки арбага җигелгән атларның тояк тавышлары да, чыбыркы чыжылдавы да ишетелми. Ә болар ул чагында нинди гадәти иде.

Безнең ишегалдында үндүрт гаилә яши. Күршеләребез киң күңелләр, беркайчан да ызгыш-талаш булмый иде. Җәйге кичләрдә җыйналып кайгы-шатлыкларыбызны уртаклашабыз. Безнең гаиләне кешеләр аеруча якын итәләр. Әниебез тәүлекнең теләсә кайсы вакытында врач ярдәме күрсәтергә әзер; кайгысын уртаклашырга яки киңәш белән килгән кешене юатырга әтиебез һәрчак җылы сүз таба.

Мин әтиемне бик ярата идем. Аның йөз чалымнары әле дә күз алдымда. Шуңадырмы, мин аны бернинди кимчелекләрсез, садә кеше итеп тоя идем. Минем хәтер түремдә ул шулай сакланган.

Әтиебез масаюны, мактануны яратмый иде, безне дә шундый итеп күрергә теләде дип уйлыйм. Әле дә онытa алмыйм, мине Толстой һәм Б. Галактионов (хәзерге Горький урамы) чатындагы җидееллык мәктәпкә беренче класска укырга биргәч, гарьлегемнән күземә яшьләр килде. Ә бит ул мәктәптән ерак та түгел, юл аша гына 19 нчы мәктәп тә бар иде. Безнең урам һәм ишегалды малай-кызлары шул мәктәпкә йөрделәр. Бу мәктәпләрдә белем алучылар бер-берсеннән шактый аерылып торалар. Әтиемнең ни өчен шулай эшләвен мин соңрак, үсә төшкәч аңладым.

Кайбер ата-аналарның үз балаларын әлеге мәктәпкә извозчикка утыртып алып килүләрен әтиебез бер дә яратмаган, шуңа күрә ул безне бу ямьсез күренештән сакларга теләгән. Ләкин ул вакытларда мин боларның берсен дә аңламаганмын, тоймаганмын; дус кызларым янында үземне иң мөһим, кызыклы нәрсәдән мәхрүм калган кеше кебек хис итә идем. Әтиебез шушы гади мәктәптә белем алуыбызны да мавыктыргыч итәргә тырыша. Белеме буенча педагог буларак, ул балалар күңелен нечкә тоемлый. Мәктәп тормышында ул актив катнашты. Бервакыт опера һәм балет театры балетмейстеры Гай Таһировны алып килде. Мәктәптә хореография түгәрәге оештырды.

Ул вакытларда әти авиация техникумында рус теле һәм әдәбиятын укыта иде. Кичләрен студентларның дәфтәрен тикшергәндә мин аның өстәленең бер почмагына урнашып карап торырга яраган. Ул үз укучыларының уңышларына балаларча куана да, җитешсезлекләренә кайгыра да белә.

Аның эш планнары язылган калын дәфтәргә күз салырга да ярата идем. Беренче битендә язылган сүзләр әле дә хәтеремдә:

Судьба проказница — шалунья
Определила так сама:
Всем глупым — счастье от безумья,
Всем умным — горе от ума.

Студентлар аны яраталар. Бер көнне барысы бергә Аккош күленә киттеләр. Әти мине дә үзе белән алды. Ял итәргә туктагач, кешеләрнең үзара мөнәсәбәте, кешедәге кыйммәтле сыйфатлар турында көтелмәгән сөйләшү булып алды. Студентлар әтинең фикерләрен, тормыштан китергән мисалларын тын да алмый тыңладылар.

Безнең гаиләдә матур әдәбият зур игътибар үзәгендә торды. Безнең үз китапханәбез юк, шулай да әти этажеркага үзенең яраткан китапларын җыеп куйган иде. Яхшы китап алып кайтса: «Кызыклы һәм файдалы булыр, укы әле», дип тәкъдим итәр. Берчак шулай мин, әтине йоклый дип уйлап, ярамаган китап белән шактый мавыгып киткәнмен. Китабымны диванда калдырып, берничә минутка бүлмәдән чыктым. Мин әйләнеп кергәндә, ул әти кулында иде инде. Берничә битен актарып чыгып:

— Сиңа шушының белән узган вакытың кызганыч түгелме? — дигәч, мин бик нык оялдым.

Өебездә Маяковский шигырьләре еш яңгырый иде. Әти бу шагыйрьне бик ярата, хәтта аның белән очрашкан да. Бу мәхәббәт миңа да күчкән. Маяковский шигырьләре белән бәйле бер көлкеле вакыйганы хәтерлим. Әти ниндидер концерт өчен «Җәй көне дачада Владимир Маяковский белән булган гадәттән тыш маҗаралар» дигән чыгыш әзерли. Һәм миннән үзенең чалбарын үтүкләвемне сорады. Мин бар тырышлыгымны куеп стрелкалар ясадым. Әти концерттан кайткач стрелкаларымны чалбарның ян-якларына ясаганымны белдем. Ә әти йөзләрчә тамашачы алдында шушы кыяфәттә басып торган. Оятымнан нишләргә дә белмәдем, ә ул минем ялгышымнан тик елмайды гына.

Әтиебез язу өстәле янында кара төнгә кадәр эшләп утырырга ярата. Бөтен өй йоклый, бары бер почмакта өстәл лампасы яктысында әтинең иелгән гәүдәсе генә чалымлана. Кулында куе чәйле шул ук бер стакан. Ул аны маңгай тирәсенә дә китерә. Күрәсең, башы авырткандыр яки шулай яхшырак уйлангандыр.

Әтиебез театрны ихлас ярата иде. Театр өчен яза иде. Татар дәүләт академия театрында ул үз кеше иде. Күп кенә сәнгатькәрләр гаиләбездә еш булды. Алар — Галия Булатова белән режиссер Сарымсаков, ирле-хатынлы Ключаревлар, Әбҗәлиловлар, филармония артисткасы Мәһинур Шәриповалар. Ләкин безгә еш килә торган һәм яраткан кунагыбыз күренекле артистка Фатыйма Ильская иде. Ул әтинең пьесаларында уйный һәм иҗади бәйләнеш аларны дуслаштырган. Һәрвакыт шат, көләч, матур бу артистка да безне бик якын итә. Ул үзенең килүе белән безгә ниндидер җанлылык, шатлык китерә. Мин шул вакытларда ук бу ягымлы кешеләргә сокланып карый идем. Һәм тормышымны сәнгатькә багышлау турында хыялландым. Ләкин, кыюсызлыгым аркасында, бу теләк тормышка ашмый калды. Актриса була алмавымны аңлагач, мин театрда кем булып эшләргә дә риза идем.

Әтиемнең туганнары белән үзара мөнәсәбәтләре бик ошый. Алар бергә җыелу үзе бәйрәм. Күбесенчә, Җиһанша абыйның кунакчыл йортында җыелалар. Безне, балаларын да, үзләре белән алалар. Бәлки шуңа да без, туганнан туганнар, бер-беребезгә бик якын, туганлык җепләрен сизә идек... Алар өстәл артында җырлап утырырга яраталар, бигрәк тә Җиһанша абый бик мавыгып җырлый. «Кара урман», «Шәл бәйләдем» — аның иң яраткан җырлары. Әтиебез исә, Ковалева башкаруында грузин җырлары «Сулико» һәм «Страдание»ны ярата иде.

Ә әбиебез (әтинең әнисе) нинди иде безнең! Туксан яшендә булуына карамастан, һәрвакыт шат күңелле, ә иң әһәмиятлесе, рифмага салып сөйләргә ярата иде.

Әтиебез йомшак холыклы, ярдәмчел кеше иде. Мин моны үзем дә тойдым. Әни миңа карата рәхимсезрәк булган чакларда мин, кухняга чыгып, кайнар яшьләргә манчылганда, әти битараф кала алмый. Янына килә, башымнан сыйпый һәм миңа да шуннан соң җиңелрәк булып китә.

Әтиебез төгәл һәм вәгъдәсен үтәүче кеше иде. Ул безнең белән шәһәр буйлап, аның тарихын сөйләп йөрергә ярата. Арып хәлдән тайгач, өйгә кайтканчы, мороже-

ное сатып алып, бер бакчага кереп ял итәбез. Бирелә безнең яраткан эскәмиябез бар. Шундый һавада йөрүләр безгә бик кадерле иде.

Бөек Ватан сугышы башланган көнне иртән без әти белән Юдино ягына, җәй көне тору өчен дача карарга бара идек. Бу коточкыч хәбәрне поездда ишеттек.

Шәһәребезгә эвакуацияләнгән кешеләр килгәч һәм аларга торыр урын кирәк булгач, әтиебез беренче булып ике бүлмәбезнең берсен алырга тәкъдим итте. Сугыш елларында анда Ленинградтан килгән гаилә яшәде. Казанга яралыларны да китерә башладылар. Кайбер йортларны госпиталь иттеләр. Ә без, балалар, яралыларның хәлен җиңеләйтергә тырыштык. Казанка елгасы буеннан чәчәкләр өзеп госпитальгә алып килә идек. Яралылар өчен кечкенә концертлар да куйдык, өйләренә хатлар яздык. Ә әтиебез (кулында броне булган хәлдә) бу вакытта, фронтка җибәрүләрен сорап, военкомат бусагасын таптый иде.

Ниһаять, әтиебез фронтка китәргә рөхсәт алды. Аның кәефе күтәрелде. Рөхсәт алганчы ул, таза-сау булып та фронтка китә алмавына газаплана иде. Свердлов урамындагы хәрби комиссариат ишегалдында, солдат киеме кигән хәлдә, гомерлеккә күңелләребезгә сеңеп калды әтиебез... Без еладык, ә ул безне тынычландырырга тырышты. Аның кәефе яхшы һәм үзе дә бик канәгать иде.

Ул фронтка гади солдат булып китте. Һәм шуннан соң газаплы хат көтүләр башланды. Почтальонның килү вакытын минутлап санайбыз. Аны зур өметләр һәм яшерен курку белән көтәбез. Хатлар регуляр рәвештә килеп торды. Вакыт-вакыт өзелеп тә куя иде. Миңа, өлкән бала буларак, әти аерым хат язарга да онытмый. Хатларында ничек яшәвем белән кызыксына, Эсмеральда һәм Рөстәмне тәрбияләүдә әниемә ярдәм итүне сорый. Аны минем киләчәк язмышым борчый иде. Бу вакытта мин инде унынчы класста укыйм. Сугыш та тәмамлануга таба бара. Укуны дәвам итү турында уйларга кирәк. Математика белән дус булмасам да, гуманитар фәннәрне яхшы беләм. Әтием минем хыялымны белми иде, шулай да гуманитар фәннәр юлын сайларга киңәш итте. Мин чынлап та Казан университетының тарих-филология факультетын тәмамлап, 32 ел буе мәктәптә балаларга белем бирдем.

Яшәү шартлары кыен. Карточкага бирелгән азык-төлек кенә җитми. Без продуктлар табу өчен төрле юллар эзләдек. Бервакыт, ишегалдыбыздан берничә кеше, Арча янындагы бер колхозга бәрәңгесе алынган басудан калган бәрәңге казырга бардык. Һәркем чиләген тутырды... Икенче бер вакыт исә әйберләрне бәрәңгегә алмаштырырга бардык. Соңрак безгә яшелчә бакчасы өчен Атлашкинодан участок та бирделәр.

1944 елның җәендә әтиебез берничә көнгә генә Казанга кайтып китте. Бу вакытта ул «Кызыл йолдыз» исемле фронт газетасында хезмәт итә иде. Үзенең кайтуы белән ул безнең өйгә күпме шатлык алып керде! Фронтовик буларак аның белән сөйләшергә теләүчеләр өчен дә ишегебез һәрчак ачык булды. Бу көннәрдә мин дә күбрәк аның янында булырга тырыштым. Свияжск янындагы элекке монастырь бинасына урнашкан балалар санаториясенә — Рөстәм белән Эсмеральда янына да бергә бардык. Ләкин аның белән булган вакыт шулкадәр дә кыска тоелды. Яңадан саубуллашу, түземсезлек белән хатлар көтү, шомлану, шомлану...

Сугыш алдыннан гына әти кешелеккә кию өчен костюм тектерде. Әтинең яңа костюмына барыбыз да бик сөендек. Кыен сугыш елларында әтиебез үзенең хатларында костюмны сатып, акчасына ашамлык алырга куша иде. Әниебез ул костюмны озак саклады һәм бары тик иң кыен хәлдә генә (трамвайда мин бөтен азык-төлек карточкаларын югалткан идем) сатарга булды.

Талчукта сату өчен әни аны бер танышына бирде, ә мине аңа ияртеп җибәрде. Мин күңелемнән сатып алучы табылмаса ярар иде, дип теләдем. Без костюмны җәеп җибәрүгә кызыл битле ир-ат аны эләктереп тә алды. Аңа костюмны биргәндә мин үксе-үксе еладым. Әйтерсең лә мин әтине ятларга бирәм. Өйгә кайтып җиткәнче тынычлана алмадым. Костюмны сатканнан соң, әтиебез өчен тагын да ныграк шомландык. Хатлары да озак килми торды.

Аның соңгы хаты санитар поездында язылган. Күрәсең, хәле бик авыр булгандыр. Шулай да ул безнең күңелне күтәрергә тырышкан. Аның соңгы сүзләрен әле дә хәтерлим: «Минем өчен борчылмагыз, мин йөз яшькә кадәр яшим».

Әй 42 яшендә безне ятим калдырды.

Әниебез җәйгә Бәкер санаториясенә баш врач булып киткән иде. Энем белән сеңлем дә аның белән, ә мин кечке әшче яшьләр мәктәбенең унынчы классы өчен имтиханнар тапшырдым. Сугыш та тәмам. Халык күңел ача. Ә безнең әлеге хаттан соң беркинди дә хәбәр алганыбыз юк. Йөрәкләрне шомлы хис били. Кинәт... Пушкин урамындагы военкоматка чакыру китерделәр. Һәм мин шунда киттем. Нигәдер, хәрби комиссариат хезмәткәренең һәр соравы мине ярсытты. Ул миннән бертуктамый нияләрдер сораша, ә минем башта бер генә уй: «Нигә чакырдыгыз?». Торган саен кайгы килүен ачыграк тоя бардым. Һәм менә миңгерәткеч хәбәр — әтиебезнең Польша госпитальләренең берсендә үлеп калу хәбәре! Шушы кайгы кәгазен кулларыма кысып, күз яшьләремә буыла-буыла урамга чыктым һәм кая барырга белми, ташташтай катып калдым. Өйдә беркем дә юк. Җиһанша абый эшләгән җиргә киттем. Иң авыр минутларымда аңа йөгерә идем, чөнки аны әтиебез бик якын итә иде.

Тәрәзәдән минем елаудан шешенгән йөземне һәм кулымдагы кәгазьне күреп алып, ул барысын да аңлаган. Мин кергәндә, хәле авыраеп, урын өстендә иде инде. Аннан мин әнине эш буенча дип чакырту өчен шәһәр сәламәтлек саклау бүлегенә юнәлдем. Әнине алырга санитар самолеты җибәрделәр. Мәктәптә имтиханнар бетмәгән әле. Миңа әзерләнергә кирәк, ә күзләрдән яшь китми, тамакка төер тыгыла. Иң кадерле, якын кешем — әтием башка беркайчан да кайтмас инде.

Әни кайтуына өебезгә күп кенә туганнар, танышларыбыз җыелды. Бу, шулай тиеш булса да, минем ачуымны китерде. Әни бернәрсә дә белми иде әле. Бу очракта безнең үзебезне генә калдырулары яхшырак булыр иде дип уйладым. Ә әни исә өйгә кайтканда инде барысын да белгән. Трамвайда аңа җырчы Усман Әлмиев очрап, кайгысын уртаклашкан.

Әниебез энемә һәм сеңлемә бу кайгы турында хәбәр итү өчен санитар самолет белән мине Бәкергә озатты, ә үзе шәһәрдә калды. Сугышка кадәр әти белән без Бәкердә ял иткән идек. Әти ул чакта үзенең радикулитын дәвалады. Бер тау башында әти вак ташлардан урак һәм чүкеч сурәте ясаган иде. Тугыз яшьлек Рөстәмне шушы тау янына алып килдем дә әтиебезнең үлеме турында әйттем. Ул тыела алмыйча бик озак елады. Мин аны тынычландырмадым, башыннан гына сыйпадым. Соңрак сеңлемә әйттем. Ул савыт-саба сөртеп тора иде. Кулындагы тәлинкәсе төшеп ватылды. Кайгы, күп кенә совет кешеләренең өенә кергән кебек, безнең гаиләгә дә әнә шулай килде. Ләкин шунысы гына бар: безгә ул сугыш беткәч, үлем турында уйламыйча, киләчәк турында якты хыяллар белән яши башлагач килде...

................

**Лоренс Блинов,**
композитор

# МУЗЫКА: СӘЛӘТ БӨРЕЛӘРЕ НИЧЕК АЧЫЛА

Балаларның күңеле үтә күренмәле. Әмма без аларның эч йөзендәге үзгәрүчән чалымнарны кайчак күреп җиткерә алмыйбыз. Барысын да вакыт җитмәүгә сылтыйбыз. Ә үзебезнең битарафлыкны бик үк танырга теләмибез.

Киләчәктә үзенең кем булачагын бала алдан ук сиздертә. Тик менә аның сәләт бөреләрен кайвакыт күрмәмешкә салышабыз шикелле. Дөресрәге, без дәвамчы-варисларыбызның киләчәген үзебезчә күз алдына китерергә тырышабыз. Әйтик, бала геолог булырга хыяллана, ә без аның аяк һәм кулын пианинога «бәйләп» куябыз, яки аңа алдан ук врач халаты кидерәбез. Табигать тарафыннан тудырылган сәләт бөреләре ачылмыйча, талантка әверелә алмыйча кала. Бу үзенә күрә бер җинаять түгелме?

Балаларны без үтәли күрәбез, әмма алар үзләренең музыкаль сәләтләрен бөтен барлыклары белән ачып салырга бик үк ашыкмыйлар. Мондый яралгылар шактый эчтә яшерелгән, һәм без аларга карата аеруча сак мөнәсәбәттә торырга тиешле. Сабыр булыйк. Ашыкмыйк. Бөренең ачылу мизгелен көтик, әмма аны күздән ычкындырмыйк. Мондый чакта аңа кичекмәстән игътибар итү сорала. Баланың үз-үзен ачарга омтылуына без хуплау белән җавап бирергә тиешбез. Мактау сүзләрен кызганмыйк. Кылган эше безгә ошыймы-ошамыймы — бу очракта анысы бик үк мөһим түгел. Баланың күңелен күтәрик. Ә тәнкыйтьләргә без болай да булдырабыз. Рахманиновча әйткәндә, художникка да өч кенә нәрсә кирәк: мактау, мактау һәм мактау. Иҗат чаткылары күренә башлаганда, безнең тарафтан балага аеруча игътибарлы булу таләп ителә. Мондый чакта авызыбыздан: «Сабыр ит! Вакытым юк! Юк-бар белән мине борчыма!» — кебек сүзләр ычкына күрмәсен. Әгәр аны үпкәләтсәң, бала үзенчә нәтиҗә ясый һәм хәтта иң якыннарына да «кирәк булмаган» мавыгуга кул селтәргә мөмкин. Ә инде аны яңадан шушы эшкә җәлеп итү бик тә кыен.

Атаклы педагог Януш Корчак «Мин яңадан балачагыма кайткач» исемле китабында болай дип яза: «Сез әйтәсез: «Балалар безне талчыктыра». Сез хаклы. Сез аңлатасыз: «Аларның аңлау дәрәҗәләренә төшәргә кирәк. Төшәргә, иелергә...» Ялгышасыз.

Без моннан арымыйбыз. Ә аларның хис-кичерешләр дәрәҗәсенә күтәрелүдән арыйбыз.

Күтәрелергә, аяк очларына басарга, үрелергә.

Балаларны үпкәләтмәс өчен».

Һәм тагын өстәп әйтик: күздән ычкындырмаска. Талантның уяна башлавын үз вакытында күреп алырга! Үзем шаһит булганым бар: талант бөресе бик тә иртә күренә башларга мөмкин. Әмма аның реаль мөмкинлекләрен алдан күрәзәләп булмый. Кайчак шундый хәл дә күзәтелгәли: без баланың гадәти мавыгуын талант яралгысы уянуга исәплибез. Ә ул мавыгу «узгынчы» булып чыга. Әгәр дә инде баланың теге яки бу эш белән кызыксынуы озын гомерле булса, әле уйлап карарга мөмкиндер. Монда да саклык сорала. Кайчак өлкәннәрнең балалардагы иҗат мөмкинлекләренә саксыз мөнәсәбәте, иртә ачылган талантларын «эшкә җигү» тискәре нәтиҗәләргә китерә. Талант бит ул, без кабатларга ратканча, халык байлыгы, һәм аның туу-үсү

шаһитләренә (бигрәк тә ата-аналарга) гаять зур җаваплылык йөкләнә: 1) талант ялкынын сүндермәскә; 2) аны вакытыннан элек «эксплуатацияләүгә» юл куймаска.

Мөмкинлекләре күзгә бәрелеп торса да, баланың киләчәктә кем буласын бер генә белгеч тә, бер генә педагог та алдан кистереп әйтә алмый. Дөрес, бала күңелендәгесен күрә белергә дә үзенә бер талант кирәк. Шулай да безнең һәммәбез дә балаларның талант яралгыларын дөрес юнәлештә үстерү өчен үзеннән ярдәм күрсәтә ала. Әһәмиятлеңе икенчел мәсьәләләрдән аера белергә өйрәтү — өлкәннәрнең изге бурычы.

Күренекле пианист һәм педагог Иосиф Гофман бер интервьюда мондый уй-фикере белән уртаклашкан иде: «Яшь пианист иң беренче чиратта клавиатураны чиста тотарга тиеш. Сәнгатькә хезмәт итүне ул клавишаларны чиста эш өчен әзерләүдән башласын. Әлеге процедура психикага уңай йогынты ясый: шапшак клавиатурада уйнап, югары эстетик нәтиҗәләргә ирешеп булмый».

Чисталык... Бу — дөньяга аяк баскан бала өчен бик тә кирәкле сыйфат. Ә иҗат омтылышында исә кешенең рухи чисталыгы турыдан-туры чагылыш таба. Һәм кешелеклелек сыйфатларын чисталыктан аерып булмый. Әйтик, ихласлылыкның нигезендә чисталык ятмыймыни?! Намуслылыкның асылын да рухи чисталык билгели бит.

Сәнгатьне өйрәнү тормыш сәнгатен үз-үзеңне һәм кешеләр арасындагы үз урыныңны аңлау сәнгатен, кешеләр белән аралашу һәм дөньяны танып-белү сәнгатен өйрәнүдән башлана. Һәм монда, әлеге дә баягы, үзара мөнәсәбәтләр сафлыгы таләп ителә. Ә бу сыйфатларны балаларда мөмкин кадәр иртәрәк тәрбияләү хәерле. Билгеле, мондый тәрбия бирүнең төрле юллары бар, һәм аларны, шәхси үзенчәлекләргә карап, төрлечә куллана белергә кирәк. Әмма иң мөһим шартларның берсе — үз баланы аңларга омтылу. Менә шул очракта гына ул безне аңлар һәм, гомумән, без үзара аңлашуга ирешербез, «Кайчан да бер шуны аңларсыңмы?» яки «Бер үк нәрсәне күпме кабатларга була!» дигән сүзләрнең кирәге дә калмас. Ә инде аңа үз иркебезне көчләп таксак, аны үзебезчә «программалаштырсак», без баланы беркайчан да аңлый алмабыз.

Баладагы кайбер җитешсезлекләр дә тора-бара уңай сыйфатларга әверелергә мөмкин: үзсүзлелек-үҗәтлек — принципиальлеккә, дуамаллык — тәвәккәллек-кыюлыкка... Менә шуңа күрә, баланы аңлый белергә, аның белән «ордым-бәрдем» кыланмаска тырышыйк. Бу очракта җәза бирү юлы белән генә алдырып булмый. Үзенең эчке көчләрен ачу өчен, баланың ирекле булуы зарур. Без аңа нәкъ менә шушы юнәлештә ярдәм итәргә тиешбез. Аны үзебез теләгән үрнәккә ияртергә, үзебез теләгән кысага кертергә омтылу соңгы исәптә уңай нәтиҗәгә китермәячәк. Табигать тарафыннан салынган потенцияләрне бала үзе ачарга омтылсын. Һәм без аңа ярдәм итик. Менә шундый шартларда гына талант яралгысын саклап кала алырбыз.

Башкаларны аңлау ачкычы шәхестәге «мин»нең иң тирән катламнарында яшерелгән. Талант бөреләре дә күңелнең нәкъ менә шундый төпкелләрендә барлыкка киләдер. Башка кешеләрнең күңел күзендә үзеңне күрә белү — үз асылыңны билгеләүдә һәм үзара аңлашуда гаять әһәмиятле сыйфат. Һәм мондый сыйфатны балада кече яшьтән үк тәрбияләү сорала. Бала үзенең эчке авазын тыңлый белергә, эчке хакыйкать авазына колак салырга өйрәнсен. Аны «үз-үзенә бикләнгәнлек»тә гаепләргә ашыкмыйк. Үзе өйрәнсен, ә без аңа ышаныйк. Мөстәкыйльлек — талант формалашуның иң беренче шартларыннан санала бит.

Балалардагы музыкаль сәләтне билгеләүнең нинди юллары һәм ысуллары бар? Бик тирәндә тибеп яткан мондый чишмәләрне ачу ата-аналарга бик үк ансат бирелми. Иң яхшысы — белгечләргә мөрәҗәгать итү. Ә менә баланың музыкага мәхәббәте көчәя баруын һәркем күрә ала, һәм, алай гына да түгел, моны сизмәү — гафу ителмәслек эш. Музыка белән, теге яки бу уен коралы белән кызыксыну, гадәттә, ата-аналарны баланың табигый мөмкинлекләрен ачыкларга этәрә, тәҗрибәле музыка педагогларыннан киңәш сорарга мәҗбүр итә.

Шәхси күзәтүләрем һәм, гомумән, тормыш шуны күрсәтә: музыка белән якыннан кызыксыну теге яки бу уен коралы булган гаиләләрдә, ягъни күпмедер дәрәҗәдә «музыкаль гаилә»дәге балаларда ешрак барлыкка килә. Әмма шунысын да онытмыйк: магнитофон яки радиоалгыч ярату гына балаларның музыкага мөнәсәбәтләрен дөрес итеп ачыкларга нигез бирә алмый әле.

Балаларда сәламәт зәвык тәрбияләү (моның өчен халыкчан сәнгать төп җирлек булып кала) — аларны «музыка урманы»нда адашмаудан һәм хәтта антимузыкаль күренешләрдән йолып калу дигән сүз. Ә мондый тәрбиягә коры сүз, дидактика белән генә ирешеп булмый. Баланы кызыксындырырга, мавыктырырга кирәк, ул үз ачышларын үзе ясасын. Шул ук вакытта аны күз уңыннан да ычкындырмаска.

Менә көткән вакыт килеп җитә. Бала күңел теләгәнен сайлап ала — музыка мәктәбендә укый башлый. Тәрбия эшенең күп өлеше (ә бәлки, төп өлеше) белгечләр җилкәсенә күчерелә. Иң беренче чиратта бала үз фикерен музыка сәнгате чаралары ярдәмендә белдерү техникасына өйрәнә. Монысы мөһим. Әмма аңа хис-эмоцияләрен кешеләргә аңлаешлы телгә күчерергә, сәнгатькә хезмәт итәргә хәзерләнүдә өлкәннәрнең ярдәм итүе тагын да мөһимрәк. Иң әһәмиятлесе: бу эш югары әхлаклылык, гражданлык сыйфатлары тәрбияләү белән бергә алып барылырга тиеш. Әле иртәрәк, дия күрмәгез, соңгаруыгыз мөмкин.

Баланың музыкаль сәләт бөреләре күзгә күренеп ачыла бара. Әмма аны, кабатлап әйтик, киләчәктә талант итеп күрергә ашыкмыйк. Тик шунысы ачык: баланың яшьтән үк мөстәкыйль рәвештә иҗади фикерләргә өйрәнүе аңа киләчәктә тормышны тирәнрәк аңларга һәм, гомуми, иҗади хезмәт уңышларына ирешергә ярдәм итәчәк.

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

**Сорау:**

— Режиссерлык мөмкинлекләрегезне тулырак ачар өчен Сезгә кайсы драматурглар ныграк ярдәм итте һәм шушы уңайдан язучыларга нинди теләкләр белдерәсез?

**Марсель Сәлимҗанов**, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры, РСФСРның халык артисты:

— Мин үзем ачкан саен ачыла баручы, үзенең мәгънәви серлелеген беркайчан да җуймаучы драматургларны яратарак төшәм. Ничектер өч драматург, төгәлрәк әйткәндә, К. Тинчурин, Н. Исәнбәт, Т. Миңнуллин пьесаларын күбрәк куярга туры килде. Ни өчен? Бу хакта еш уйланам. Минемчә, әлеге драматургларны бер уртак сыйфат берләштерә: алар иҗатында чын мәгънәсендәге әдәбият чагылыш таба. Өчесе дә җирдә нык басып торалар. Чын реалистлар. Тел осталары, стилистлар, заман ритмын һәм музыкасын нечкәләп тоя белүчеләр. Әмма алар берберләреннән аерылып та торалар, үз-үзләрен дә кабатламыйлар. Һәм шунысы әһәмиятле: әлеге драматурглар тарафыннан иҗат ителгән әсәрләрдә аерым «урын» мәсьәләләре түгел, ә гомумкешелек проблемалары күтәрелә. Менә шуңа күрә мондый пьесаларны 10—15 елдан соң да рәхәтләнеп куярга була. Алар ачкан саен яңа яктан ачыла баралар.

«Нәрсә турында язарга?» Кайбер авторлар миңа әнә шундый сорау да биргәлиләр, актуаль тема, хәтта мин күрергә (ә ул язарга) теләгән әсәрнең конфликтын тәкъдим итүемне сорыйлар. Иҗат эшенә мондый карашны мин аңлый алмыйм. Язарга тема беткәнме? Халкыбыз биографиясенә генә күз салыйк. Казанда Совет власте урнаштыруга багышланган берәр яхшы пьеса бармы? Татар халкының тарихи шәхесләрен сәхнәгә үзләренә лаеклы рәвештә күтәрдекме? Ә гражданнар сугышы геройларын, коллективлашу чоры фидакарьләрен?! Бүгенге авыл темасы да «вакансияле» булып кала бирә. Шулай ук нефть темасы буенча да «Монда тудык, монда үстек» кебек пьесаларны тагын да язарга буладыр. Ә тынычлык темасын онытырга хакыбыз бармы? Әхлак проблемасының актуальлеге хәзер арттаннан-арта бара, һәм ул һәрбер әсәрдә дә күпмедер дәрәҗәдә күтәрелергә тиештер... Кыскасы, нәрсә турында язарга кирәклеген драматургка теге яки бу режиссер түгел, ә тормыш үзе күрсәтә. Дөрес, без дә аңа бу юнәлештә төрлечә ярдәм итәргә, аны театр коллективының бер әгъзасы итеп танырга бурычлы.

# МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВКА 50 ЯШЬ

*Калəм үгрəн, калəм сине изгегə тартыр,*
*Калəм берлə кайда барсаң — гыйззəтең артыр.*

*Халкыбыз гасырлар буена əнə шулай калəмгə дан җырлаган, аның кодрəтле көчкə ия булуына инанган. Ə калəм тотып илгə эш күрсəткəн ир-егетлəргə аның ихтирамы тагын да арткан.*



*Менə шундый тылсымлы калəмгə ия булып, илебез халыкларының төрле теллəрендə йөздəн артык мəкалə-рецензиялəр, халкыбызның катлаулы тарихын, əдəби җəүһəрлəрен тəфсилле тикшергəн җитди монографиялəр, фəнни-популяр əсəрлəр иҗат иткəн олы галимебез — тарихчы, əдəбият белгече һəм язучы, тарих фəннəре докторы, профессор Миркасыйм Габделəхəт улы Госмановка 50 яшь тулды. Илле яшьлек ир-егетне олы галим дип атау беркадəр сəеррəк тə яңгырарга мөмкин. Лəкин калəм иялəренə бəянең яшəгəн елларына карап түгел, ə эшлəгəн эшлəренə карап бирелгəнлеген онытмыйк!*

*Миркасыйм Госмановның беренче зур фəнни хезмəте — «XVII—XVIII гасыр татар тарихы чыганаклары» дигəн китабы (1972 ел) республикабызның фəн, культура җəмəгатьчелегендə зур кызыксыну уятты. Бу хезмəте белəн галим төрки-татар тарихы чыганакларын хəзерге заман талəплəре югарылыгында, чын-чыннан фəнни нигезгə салып өйрəнүнең яңа этабын башлап җибəрде. Шушы өлкəдə фəнни тикшеренүлəрен дəвам итеп, ул 1979 елда төрки-татар тарихының феодализм чоры документаль чыганакларын тикшерүгə багышланган «XIV—XVI гасыр Җучи Улусының ярлыкаш актлары» исемле зур монографиясен дөньяга чыгарды. Үзəк матбугатта югары бəя алган бу хезмəт халыкара фəнни җəмəгатьчелектə дə яңгыраш тапты. Күп кенə иллəрнең тюркологлары бу хезмəткə еш мөрəҗəгать итəлəр, шушы китапның материалы һəм нəтиҗəлəренə таянып язылган яңа хезмəтлəр дə чыкты. Узган ел гына ЮНЕСКО тарафыннан Парижда чыгарыла торган «Яңалыклар» информацион бюллетенендə Миркасыйм Госмановның болгар-татар язма поэзиясенə нигез салучы мəшһүр шагыйрь Кол Галигə багышланган мəкалəсе басылып чыкты.*

*Халкыбызның иҗтимагый фикер тарихында тирəн эз калдырган шəхеслəр Ш. Мəрҗани, Г. Кандалый, Х. Фəезханов, М. Акмулла, Р. Фəхретдиневлəрнең тормыш юлларын һəм əдəби-гыйльми мирасын тикшерү — галимнең җиң сызганып эшли торган*

*өлкәләренең берсе. Бу фикер ияләре турындагы тирән эчтәлекле һәм яңа документаль чыганакларга нигезләнеп язылган хезмәтләрендә Миркасыйм Госманов үзен киң эрудицияле, принципиаль, кыю фикерле галим итеп танытты.*

*Миркасыйм Госманов әдәби тәнкыйть, публицистика, әдәбият белеме, текстология, тәрҗемә һәм балалар әдәбияты өлкәләрендә дә актив эшли. Педагог буларак балалар өчен тарих фәнен популярлаштыру юнәлешендә нәтиҗәле эшләп, «Серле балбал» (1973), «Таулар, үзәннәр илендә сәяхәт» (1977) исемле әсәрләр иҗат итте.*

*Миркасыйм Госманов гыйльми-әдәби эшчәнлегенең башлангыч чорыннан ук халкыбызның кульязма мирасын җыю, барлау, аларны өйрәнеп, әһәмиятлеләрен дөньяга чыгару юнәлешендә зур һәм нәтиҗәле эш алып бара. Ул 1963 елдан алып Казан дәүләт университетының Археографик экспедициясенә җитәкчелек итә, ә 1969 елда СССР Фәннәр академиясенең Археография комиссиясе члены итеп сайлана. Егерме елдан артык вакыт эчендә илебезнең татарлар яши торган төбәкләрендә ул җитәкләгән экспедиция тарафыннан биш меңнән артык кульязма, документаль чыганаклар җыелып университетның фәнни китапханәсенә тапшырылган. Татар халкының тарихы, фольклор һәм әдәби мирасы һ. б. күп кенә проблемаларны өйрәнгәндә бу кульязма байлык төп чыганакларның бер өлеше булып тора. Аларның шактый зур өлешен борынгы татар әдәбияты һәм халык авыз иҗаты әсәрләре тәшкил итә. Бу ядкарьләрне эзлекле рәвештә тикшерү, өйрәнү галимне әдәбият тарихына һәм борынгы кульязмаларның текстологиясенә караган кызыклы күзәтүләр, мөһим ачышлар ясауга китерә. Яңа гына дөнья күргән «Каурый каләм эзеннән» исемле хезмәте әнә шул тикшеренүләрнең гүзәл нәтиҗәсе буларак барлыкка килде. Галимнең бу юнәлештәге эшчәнлеге чын фәнни фидакарьлек дип бәяләнергә хаклы.*

*Журналыбызның актив авторы, галим һәм язучы Миркасыйм Госмановны кайнар котлыйбыз һәм аңа яңадан-яңа иҗади уңышлар телибез.*

## Миркасыйм Госманов

# ЯЗМА МИРАСЫБЫЗНЫҢ КҮТӘРЕЛӘСЕ КАТЛАМНАРЫ

Язма традициябез һәм язма әдәби мирасыбызның тарихи тормышыбыздагы урыны һәм күләме, нигезе һәм әһәмияте мәсьәләсе — катлаулы һәм зур проблема. Аны азмы-күпме дәрәҗәдә хәл кылыр өчен бер мәкалә генә түгел, бәлки зур монография дә җитмәячәк. Шуңа күрә бу кечкенә мәкаләмдә мин аның бер махсус өлешенә — язма мирасыбызның конкрет, хәтта үтә «тар» бер мәсьәләсенә генә тукталуны бурыч итеп куям. Ләкин, күренер ки, шул «тар» өлкәнең хосусиятләрен әтрафлап аңлаганда гына без «татар язма культурасы» дигән катлаулы һәм бай күренешнең тормыштагы урынын тарихи, иҗтимагый әһәмиятен фәнни дөрес аңлау, димәк, гадел аңлату мөмкинлегенә ирешәчәкбез.

Мәсьәләне болай кискенләштереп куюның икенче бер сәбәбе дә бар. «Труд» газетасының 1983 ел, 3 сентябрь санында «Бер кешегә дөнья халыкларының һәммәсе белән дә аңлаша алу өчен ничә тел белергә кирәк?»— дигән сорауга җавап бирелә. Тел белеме фәненең казанышларына таянып фикер йөртүче галим — филология фәннәре кандидаты Л. Александров түбәндәге нәтиҗәне чыгара: «...Хәзерге лингвистларның күпчелеге мондый фикергә килделәр: 14 тел. Алар: рус, инглиз, кытай, француз, немец, испан, гарәп, япон, португал, итальян, татар, һинд, урду, бенгали телләреннән гыйбарәт. Шушы телләрдә кешелекнең өчтән ике өлеше сөйләшә. Әлбәттә, бу һәр очраган кеше белән әңгәмәләшә аласыз дигән сүз түгел, әмма сезне җир шарының теләсә кайсы ноктасында да аңлый алачаклар».

Минем өчен, татар язма теленең Урта гасырларда ук шактый илләр һәм төрле кавемнәр өчен аралашу теле — халыкара функциональ дипломатик тел бурычын үтә-

гәнлеген күпсанлы документлар нигезендә электән үк белгәнгә, бу хәбәр гадәти констатация шикелле генә яңгырады. Шулай да мин үземне беркадәре уңайсызрак та сизә башладым: мондый фәнни объектив һәм күптән үк мәгълүм фактларны халыкка җиткереп торуда, аларның табигатен, сәбәп һәм нәтиҗәләрен гыйльми дөрес аңлатуда, шундый дөрес информация нигезендә тәрбия эшләрен яңа биеклекләргә күтәрүдә без, тарихчылар, җитәрлек дәрәҗәдә актив һәм намуслы эшлибезме соң? Өстәвенә, әдәби мирас, язма әдәби традиция дигән катлаулы күренеш, хәтта үтә катлаулы «организм» хакында да без күбрәк берьяклы һәм тар фикер йөртәбез түгелме соң? Әйтик, моңарчы язма мәдәниятебез хакында сөйләгәндә, иң беренче чиратта бары әдәби истәлекләр тирәсендә генә бөтерелеп калмадыкмы? Ә әдәби әсәрләр тусын, яшәсен һәм киң таралсын өчен гомумән язма культура дигән колачы күпкә киңрәк зур тарихи процессның башка төрле-төрле тармаклары да булырга тиештер бит!

Әйе, әдәби мирасыбызның күләмен, чамасын, анық тарихи урыны һәм әһәмиятен дөрес аңлар, төгәл иңләр өчен гомумән язма культура дигән киңрәк, катлаулырак күренешне дә тирәнрәк белергә тиешбез. Бу инде билгеле бер әдәби телнең тормыштагы төрле сфераларда да яшәешен, функциясен, таралу колачын, ул таралуның күләм-даирәсен, активлыгын, яшәешкә сәләтлелеген күпьяклап, җентекләп өйрәнү дигән сүз. Шушы яссылыктан чыгып карагында, язма культура дигән зур күренешнең «эш кәгазьләре» дигән тармагына да тиешле игътибар итәргә бурычлыбыз.

Әмма «эш кәгазьләре»— эш йөртү культурасы дигән нәрсә үзе дә катлаулы, бай өлкә ул. һәм аңа караган материалларның — документаль истәлекләрнең дә төрләре гаҗәп күп. Әйтик, манифестлар, указлар, дәүләтләр яисә хосусый шәхесләр ара килешем актлары, дипломатик хатлар, рәсми һәм шәхси хатлар, таныклык грамоталары, боерыклар, сату-алу договорлары, васыятьнамәләр, вакыфнамәләр, никях һәм аерылышу кәгазьләре, метрик язмалар, мирас бүлү актлары, бурычка бирү-алу документлары, гаризалар, үтенечләр, шикаятьнамәләр, хәбәрләр, доносләр, докладлар, рапортлар һ. б. һ. б. Бездә кайбер төр документларның тел-стиль үзенчәлекләрен өйрәнү буенча ирешелгән конкрет казанышларны (бигрәк тә Ф. Фәсиев, Ф. Хисамова хезмәтләрен һәм тагын бер-ике иптәшнең аерым күзәтүләрен) исәпкә алмаганда, документаль истәлекләребез, бигрәк тә хосусый төр документларыбызның күпчелеге, тарихи чыганак буларак, тиешенчә тикшерелмәгән әле.

Әйтелгәннәрне исәпкә алып, мин татарча эш кәгазьләре, татарча документлар дигән күптармаклы өлкәнең бер юнәлешенә генә караганнарын игътибар үзәгенә куярга булдым. Ул рус-көнчыгыш мөнәсәбәтләре тарихына нисбәтле татарча документлар мәсьәләсе. Чөнки татарча эш кәгазьләре йөртү культурасының үсешендә, яшәешендә элекке Россия дәүләте җуелмаслык тирән эз калдырып, татар әдәби теленең таралыш географиясе киңәюгә дә көчле тәэсир ясаган.

## «Елга башында»

Русларның борынгы бабаларының төрки халыклар белән якыннан танышуы, аралашуы безнең эраның башына ук барып тоташа. Үзәк Азиядән чыккан төркиләрнең беренче дулкыннары Көнчыгыш Европага дүртенче гасырның икенче яртысында ук бәреп керә. Мәсәлән, «халыкларның бөек күченеше» процессында «пәйда булган» хун-гун кавемнәре составында төркиләрнең өлеше шактый иде.

Алардан соң заманы өчен шактый зур дәүләт оештырган аварлар да нигездә төркиләрдән иде. Бире таба борынгы русларның төркиләр белән төрле өлкәләрдәге мөнәсәбәтләре тагы да төгәлрәк чалымлана.

X һәм XIII йөз башларында Киев Русе дәүләтенең төрле төрки кабиләләрдән көньяктагы күршеләре бәҗәнәкләр, угызлар, куманнар, кыпчаклар, көнчыгышта исә болгарлар белән янә дә тыгызрак политик һәм сәүдә-экономик мөнәсәбәтләргә керүе тарихта бик мәгълүм. Хәрби бәрелешләр дә аз булмаган. Билгеле булганча, халыклар, дәүләтләр арасындагы сугышлар ул тыныч мөнәсәбәтләрнең дәвамы гына, әмма, икърар ителгәнчә, сәламәт, нормаль түгел, бәлки зарарлы һәм гарип «дәвамы». Шул

ук вакытта тыныч мөнәсәбәтләр генә түгел, хәрби бәрелешләр дә сүз-тел чаралары ярдәмендә аралашу һәм аңлашудан, әйтик, каршы якның ниятен, серләрен аңларга теләүдән башка бара алмый. Тыныч мөнәсәбәтләр хөкем сөргән чорларда исә, аңлашырга теләү тагын да кирәк колач җәя. Менә шушы закончалыкны, һәм аны раслаган фактлардан чыгып, күренекле совет галиме, академик А. Н. Кононов үзенең соңгы фундаменталь хезмәтләренең берсендә X—XI гасырларда ук борынгы русь князьләре даирәсендә төркичә телләрне яхшы белү, хәтта мәгълүм дәрәҗәдә «ике-теллелек» күренешенең дә таралган булу фикерен алга сөрә. Моңа дәлил итеп, ул, сәүдә-экономик, хәрби-политик мөнәсәбәтләрдән тыш, хакимлек сөрүче даирәләр арасындагы бәхәссез кан кардәшлеге мәсьәләсенә дә киң тукталa[1]. Шул чордагы төрки халыклар арасында Киев шәһәренең «Манкирмән» дигән төркичә махсус исеме булу факты да[2], әлеге шәһәрдә ул халык вәкилләренең еш булгалавы, хәтта андагы славяннар белән аралашып яшәве хакында сөйләсә кирәк. Шуңа күрә дә, борынгы рус теленә төрки элементлар күпләп керүнең өченче мөһим этабын тюркологлар шушы дәвергә нисбәт итәләр.

Бу чорда да тел алмашу процессы берьяклы гына бара алмаган, әлбәттә. Рус князьләре генә түгел, төркиләрнең җитәкчеләре дә икенче тарафның уй-ниятен, фикерен белергә мохтаҗ булган, шуңа күрә академик Кононов рус чынбарлыгы өчен ихтимал дип исәпләгән русча-төркичә «икетеллелекнең» әлеге Манкирмәннән тышта һәм читтә яшәгән төркиләр арасында билгеле бер күләмдә хөкем сөргәнлеге артык шик тудырмый торган мәсьәлә.

Гадәти очрашу һәм аңлашудан тыш, руслар белән борынгы «европалы» төркиләр арасында — конфликт һәм сугышларның диалекталь киресе буларак — дипломатик сөйләшүләр, килешүләр, шул килешүләрне договор кыяфәтенә китереп кәгазьгә теркәү фактлары да аз түгел иде. Рус елъязмаларында бәҗәнәк һәм кыпчак ханнарының хөкүмәтләр арасындагы дипломатик килешүләрне бозулары еш күрсәтелүе шушы фикеребезне тулысынча куәтләсә кирәк.

Рус дәүләте белән Болгар патшалыгы арасында да мөнәсәбәтләр әзлекле һәм шактый катлаулы булган. Хәрби бәрелешләрне солых договорлары очлаган; килешем актлары исә, кайбер характерлы детальләрне мәңгеләштереп, кәгазьгә беркетелгән. Шундыйларның иң күренеклесе мисалында «Повесть временных лет» елъязмасында тасвирланган, үзенең мең еллык юбилеена җиткән 985 елгы мәшһүр договорны, олуг князь Владимир белән болгар патшасы Мөхәммәт арасында «таш суда йөзгәнче, колмак суга батканчы» гамәлдә калсын дип ант итешеп төзелгән солых килешемен күрсәтергә кирәк. Характерлы һәм уникаль образларның рус елъязмасында сакланып калуы аның ике дәүләт арасында төзелгән махсус юридик документта теркәлгән булуыннан, димәк, елъязмачының игътибарын шул сыйфатлары белән җәлеп итүеннән килә. Ә дәүләтләр арасындагы политик килешем, мәгълүм булганча, сөйләшүче һәр ике тараф өчен дә аңлаешлы телдә — ике телдә төзелгән чакта гына ул дипломатик договор көченә, димәк, сәяси һәм иҗтимагый документ кыйммәтенә ия була ала. Теләсә нинди юридик документ шундый эчтәлеккә ия булганда гына тарихка кереп кала.

Болгар һәм рус мөнәсәбәтләрендә нинди тел һәм язуның гамәлдә булганлыгы артык бәхәс тудырмый торган мәсьәлә. Чөнки договорның олуг князь Владимир аңлаган, шул аңлавына нигезләнеп кул куйган вариантының язуы һәм теле хакында әле исеме аталган елъязманың сыйфаты төгәл мәгълүмат бирә. Болгар патшасы укып үз имзасын куйган нөсхәнең гарәп язуы ярдәмендә беркетелгән булуы бернинди шик тудырмый: 922 елны ислам динен рәсми дәүләт дине сыйфатында кабул иткән болгарлар X гасырның башыннан ук үз таңкаләрен гарәпчә монументаль куфи язуы белән сугалар иде. Димәк, бездә гасырыбызның 30 нчы елларына кадәр рәсми кулланышта булган әлеге хәрефләр «колмаклы-ташлы» килешем төзелгән чакта ук халык массаларына азмы-күпме дәрәҗәдә таныш булып өлгергән иде. Шуңа күрә әлеге килешемнең болгар версиясе гарәп хәрефләре нигезендә төркичә-болгарча язылган булуы әллә ни шик тудырмый.

[1] Кононов А. Н. История изучения тюркских языков в России. Дооктябрьский период. Тулыландырылган, төзәтелгән икенче басма. Л., 1982, 13—24 битләр.
[2] Шунда ук, 20 бит.

Әгәр борынгы Рус дәүләте белән болгарлар арасында моннан соң да әллә ничә договор төзелүен, моннан тыш та дипломатик язышуларның гамәлдә булуын игътибарга алсак, болгарлар һәм руслар арасындагы элемтәләрдә рус-төрки тел бәйләнешенең урынын, чама һәм күләмен шактый төгәл күзалларга мөмкин. Һәрхәлдә, ике дәүләт арасындагы төрле килешемнәрнең өлъязмаларда барган саен ешрак телгә алынуы, аннары сәүдә-экономик мөнәсәбәтләрнең дә биргә таба көчәя төшүе (сатуалу эше исә төрле килешем төзүләрне, язу ярдәмендә исәп-хисап алып баруны аерата таләп итә!) русларда да, болгар җирендә дә күршеләренең телләрен яхшы белүгә ихтыяҗны арттырган гына. Әгәр тарихыбызның шушы үзенчәлекле хосусиятен төгәл аңламасак, ягъни болгар чоры рус-төрки тел бәйләнешләренең ихтимал колачын исәпкә алмасак, моннан соңгы дәвер рус-төрки тел контактларының да, гомумән Көнчыгыш Европадагы төркичә әдәби һәм рәсми дипломатик телнең үзенчәлекле тарихын да гыйльми дөрес аңлау мөмкинлегеннән мәхрүм калыр идек.

Әлбәттә, кыпчак һәм болгар чоры рус-төрки тел мөнәсәбәтләре хакында сөйләгән чакта, чама хисен дә онытырга ярамый: аерым фактларны абсолютлаштыру, аларның әһәмиятен артык киңәйтеп, яки күпертеп күрсәтү тарихны бозуга илтер иде.

## Традицияләр үзгәрү чорында

XIII гасыр башындагы монгол ханнары яулап алулары нәтиҗәсендә Азия һәм Көнчыгыш Европада барлыкка килгән хәрби-политик үзгәрүләр хакында безгә мәктәп дәресләреннән үк мәгълүм. Бу яулап алулар, монгол армиясенең өлкәләрдән өлкәләргә узулары белән генә чикләнмичә, әлеге регионда яшәгән төрле халыкларны мәҗбүри рәвештә җир-ватан алмаштыртуы, шул рәвешчә политик-административ кына түгел, бәлки этно-географик үзгәрүләрне барлыкка китерү белән дә характерлы иде. Шуңа күрә Көнчыгыш Европага килгән Батү хан армиясе составында (яулап алуны оештырган ханнардан сугыш хәрәкәтенә мәҗбүри җәлеп ителгән халык массаларын аерып карарга кирәк!) төрки телле халыкларның өлеше зур иде.

XIII—XV гасырларда бөтен Евразиядә киң таралган төрки-татар әдәби теленең барлыкка килеп үсүендә дә, төп сәбәп сыйфатында шул ук социаль-политик факторларны күрсәтергә кирәк. Әгәр чыңгызыйларның беренче буыны ук, фәндә киң мәгълүм булганча, уйгур укытучылары тарафыннан тәрбияләнгәнлеген искә төшерсәк, әлеге нәтиҗә тагы да көчәя төшә. Көнчыгыш Европага килгән монголларның төркиләшеп бетүләре сәбәбен тарихчылар моңарчы шулайрак аңлаттылар да инде.

Әмма бу аңлату фактик җәһәттән шактый дөрес булса да, ул барыбер мәсьәләнең бер ягын гына чагылдыра. Җучи Улусы монголларының чагыштырмача тиз арада этник җәһәттән төркиләшеп бетүләренә моңарчы әйтелә килгәнчә уйгур тәэсире генә төп сәбәп түгел, бәлки хәзерге казах сахраларындагы халыклар белән Идел буендагы, Куман-кыпчак далаларындагы төркиләрнең дә тәэсирләре аз булмаган.

Әгәр әүвәлге дәверләрдә монгол хакимнәре чыннан да укый-яза белә торган кадрларны башлыча уйгурлардан туплаган булсалар, Җучи Улусы оешып яткан һәм оешып беткән вакытларда андыйларны җирле төркиләр арасыннан да алганнар. Чөнки һәр буын яңарган саен укый-яза белә торган кадрларны гел ерак Үзәк Азиядәге уйгурлардан гына куплап чакыртып торганнар дип уйлау нихәтле примитив һәм нигезсез булса, Алтын Урда администрациясе җирле халыктан чыккан кадрларга бөтенләй таянмаган дип аңлау да шундый ук дәрәҗәдә мантыйксызлыкка кайтып калыр иде.

Кыскасы, Җучи Улусының халык составы буенча төрки ил икәнлеге элементар хакыйкать булса, аның шулай төрки ил булып формалашуында бу якларда электән үк яшәгән кавемнәрнең урынын, ролен танымау әлеге хакыйкатькә хилафлык китерер иде. Шуңа күрә XIII—XIV йөзләрдә яңарып формалашкан, киң колач җәйгән кыпчак нигезле төркичәне — төрки-татар әдәби телен өр-яңадан туган күренеш дип түгел, бәлки Көнчыгыш Европадагы электән килә торган әдәби традициянең кайбер этник һәм мәдәни компонентлар исәбенә яңарган варианты, яңа этабы дип карарга да нигез җитәрлек.

Көнчыгыш Европадагы электән хөкем сөреп килгән җирле төрки телләрне Җучи

Улусы төзелгән чакта кайбер этник һәм мәдәни традицияләр исәбенә баеды дип әйтү дә коры дәгъва түгел. Яулап алучыларның бу якларга башка төрки кабиләләрне дә күпләп китерүләре реаль булса, монголлар белән бергә «хан язуы» сыйфатында уйгур язуының килүе, рәсми язу рәвешендә шактый киң таралуы да кире каккысыз факт: дәүләт башлыгы хан исеменнән игълан ителә торган рәсми актлар — ярлыклар, ягъни указлар, карарлар элегрәк (якынча XIV гасырның урталарына хәтле) шул язу белән язылып, тәңкәләргә сугылган «легендалар» — акчаның рәсми таныклыгы да XIV гасырның ахырына кадәр шул уйгур хәрефләре белән төркичә башкарылган.

Җучи Улусы төзелгән һәм көчле дәүләт булып яшәгән гасырларда, мәгълүм булганча, таркау рус князьлекләре шул империягә карата вассал бәйлелектә торалар. Рус князьлекләрендә баскаклар хан казнасы файдасына ясак-салым җыялар; ясак җыюны тәртипкә салыр өчен 1257 елда ук бөтен Русьта халык санын исәпкә алу оештырыла. Менә шушы халык санын исәпкә алуда да, аннары башка эшләр буенча документлар язуда да урда түрәләре уйгур язуы нигезендәге төрки телдән файдаланалар. Моның шулай икәнлеген 1572—1575 елларда төзелгән рус дәүләте архивы тасвирламасыннан күрергә мөмкин. Мәсәлән, Мәскәү патшалары архивының иң борынгы катламнарын үз күзе белән күргән рус чиновнигы «148-тартмадагы» кәгазьләр турында болай язып куйган: «дефтери старые от Батья (Батыя — М. Г.) и от иных царей; переводу им нет — нихто перевести не умеет»[1]. Сүз, һичшиксез, уйгур язулы төркичә документлар хакында бара, чөнки әлеге тасвирлама төзелгән чорда Мәскәүдә гарәп хәрефләре белән татарча язылган документларны укучы һәм аңлаучы, шулардан төгәл тәрҗемәләр эшләүче тылмачлар җитәрлек булган.

## «Йомышлы татарлар»

Әле генә искә алынган тасвирламадан күренгәнчә, Мәскәү князьләре архивында соңгы чор Алтын Урдадан, аннары Әстерхан, Нугай Урдасы, Казан һәм Кырымнан килгән дипломатик документлар әрҗә-әрҗәсе белән җыелган икән. Әйтик, анда 1572—1575 елларда барлыгы якынча 250 әрҗә («короб, ящик») документ булган булса, шуларның утыз сигезендә, ягъни 15 процентында, әлеге дәүләтләрдән килгән язулар сакланган[2]. Шул 38 әрҗәнең нәкъ егермесендә йөздән артык документның татарча оригиналда булуын беләбез. Чөнки тасвирлама төзүчеләр һәр конкрет документ хакында диярлек «по-татарски», «татарским письмом», «бесерменским письмом», яисә «переводу им нет» яки «с переводом» дип, әлеге төрки телле, гарәп язулы хатларның лингвистик, график сыйфатларын шактый эзлекле рәвештә күрсәтә барганнар.

Өстәвенә, мондый документларның күпчелеге дәүләт башлыклары исеменнән бирелгән шартнамәләр («шертные грамоты») ише ике ил арасындагы договорлардан торган. Андыйларны татар ханлыкларында, кагыйдә буларак, гел татарча язганнар, чөнки, шартнамәне биргән чакта Коръән өстендә ант итү гадәте дә хөкем сөргән. Шуңа күрә дә Мәскәү патшасының архивында махсус Коръән дә сакланган: «да куран татарский, на чом приводят татар к шерти; да грамоты татарским письмом»[3].

Рус-көнчыгыш язышуында төрки-татар язма теленнән Мәскәү патшаларының актив файдалануы безгә кадәр русча күчермәләрдә генә килеп җиткән, «столбцы» дип атала торган күп санлы копия кнәгәләреннән дә күренә. Мәсәлән, 1474—1505 һәм 1508—1521 еллардан калган бер төркем документлар арасында 220 хатның шул елларда ук Мәскәүдә татарчадан тәрҗемә ителгәнлеген беләбез[4]. Шулай ук Мәскәү князьләре кәнсәләрендә, рус җирләре бәйсезлеккә чыкканнан соң да русча һәм татарчаны яхшы белгән тәрҗемәчеләр, тылмачлар күпләп эшләгәннәр икән. Мондый махсус чиновниклар арасында рус кешеләре белән бергә дин алмаштырган яисә мөселман татарлар да шактый булган. Соңгыларын ул вакытларда «йомышлы татарлар», «үз татарларыбыз» («служилые татары», «свои татары») дип атаганнар. Шундыйларның арасыннан олуг князьнең җаваплы эшләрен үтәүче, озак еллар

---

[1] Описи Царского архива XVI века и архива Посольского приказа 1614 года. М., 1960, 32 бит.

[2] Описи Царского архива..., №№ 12—16, 22—25, 31—39, 48—52, 65, 70, 72, 86, 88, 89, 94, 101, 105, 106, 135, 139, 145, 148, 201, 218.

[3] Описи Царского архива..., № 218.

[4] Сборник Русского исторического общества. Памятники дипломатических сношений Древней России с державами иностранными, 41 һәм 95 томнар, СПб., 1884—1895.

дәвамында «йомышта» торучы зур чиновниклар да җитлегеп чыккан. Мисалга XV йөз ахыры һәм XVI гасыр башында актив эшләгән Әбләз бахшины күрсәтеп була[1]. Кайбер махсус тикшеренүләр күрсәткәнчә, киләчәктә рус патшасының Илчелек приказында рәсми рәвештә төзеләчәк махсус «Татар кәнсәләренә» нигез салучыларның берсе шушы Әбләз бахши булганга охшый. Аның чорында башкарылган тәрҗемәләрнең гаять төгәл булулары да характерлы. Мондый хәл, рус кәнсәләрендәге тылмачларның татарчаны яхшы белүеннән тыш, рус дәүләтенең дипломатиясе башында торучы эре түрәләрнең дә, җөмләдән олуг кнәзьләрнең дә (бигрәк тә Иван Өченче һәм Василий Өченченең) татарчадан хәбәрдар булуы белән дә аңлатылса кирәк.

Рус кнәзьләренең төркичә белгән булулары бер дә гаҗәпләнерлек яңалык түгел, бәлки ул күптән мәгълүм «искелек» кенә. Әгәр һәр мөһим мәсьәләне хәл кылыр өчен гел Урдага чапкан, туган илләре интересларын сату исәбенә Сарай ханнарыннан төрле дәрәҗәләр алган XIII—XIV йөз хаин кнәзьләрнең үз сюзереннары белән аларның телендә сөйләшергә тырышулары һәм шулай булдырулары берниндн шик тудырмаса, татарчаны яхшы белү бәйсезлеккә ирешкәч тә шактый дәвам итә. Мәсәлән, 1462—1505 елларда олуг кнәзь тәхетендә утырган Иван Өченченең үз акчаларына «Мәскәү акчасы будыр. Ибан» дип татарча язу сугуы гына түгел, бәлки аңардан элекке олуг кнәзьләрнең дә русча төзелгән васыятьнамәләргә «болай уң күрдек», «алтмышта янбар айында» дип татарча резолюцияләр салулары[2] безнең әлеге фикеребезне артыгы белән раслый. Хәтта булачак Иван Грозныйның да яшь чагында Мәскәүгә килүче татар аксөякләре белән шуларның телендә сөйләшүенә дә ишарәләр бар[3].

Бу чор Мәскәүдә татарчаның ят телләрдән булмавы икенче характердагы фактлар белән дә раслана. Мәсәлән, XV—XVI йөзләрдә Казан, Әстерхан һәм Касимнан килеп «йомышка кергән» күпсанлы бәк-мирзалардан тыш, Мәскәүдә «икмәк-тоз һәм якты йөз» тапкан хан-солтаннар да аз булмаган. Аларның кайберләре дин алмаштырып, икенчеләре мөселман килеш кала биреп, Мәскәү патшалары даирәсендә югары дәрәҗәләргә дә ирешкәннәр. Шундыйларның берничәсен генә күрсәтик. Мәсәлән, Казан ханы Ибраһимның улы Ходайкол (шул вакытта Казанда тәхеттә утырган Мөхәммәт-Әминнең бертуганы), 1505 елны Петр исеме алып христиан диненә күчкәч, хатыны бала тапмаган олуг кнәзь Василий Өченче аны үзенең бертуган сеңлесенә өйләндерә һәм рәсми рәвештә Мәскәү тәхетенә варис итеп билгели. Тик Петр озак яшәми: 1523 елны үлеп китә. Моннан соң Василий яшь хатынга өйләнергә мәҗбүр була һәм аңардан булачак Иван Дүртенче туа[4].

Тәхет тирәсендә көчле көрәшләр барган вакытта Иван Дүртенче Алтын Урда ханы Әхмәтнең оныгы, Шаһгалинең турун туганы Бикбулат солтанның угылы Саин Булатны үзенә якын тарта һәм, «хан» дигән дәрәҗә биреп, аңар Касим шәһәрен бүләк итә. Турылыклы вассал сыйфатында гел Иван тирәсендә бөтерелгән Саин Булат 1573 елны христиан диненә күчеп, Симеон дигән исем ала. 1575 елны, астындагы тәхет тагын калтырый башлагач, Иван Грозный, үз улы Иванны (Бишенчене!) патшалык мирасыннан мәхрүм итү нияте белән (ата-бала арасында көчле ызгышлар туа), әлеге Саин-Симеонны «Бөтен Русьның олуг кнәзе», ягъни тәхет варисы итеп билгели. Ул хәтта Мәскәү тәхетендә бер ел чамасы утырып та ала[5].

Татарча истәлекләргә багышланган мәкаләдә тәхет тирәсендәге ызгышлар дөньясына кереп китүдән гаҗәпләнелмәсен. Чөнки, беренчедән, рәсми документлар тарихын дәүләт һәм власть ияләре язмышыннан аерып алу мөмкин булмаса, андый эш кәгазьләренең тел үзенчәлеген югары даирәләрдән башка карау да тарихилыкны бозуга илтер иде.

---

[1] Сборник Русского исторического общества.., 75, 78, 87, 120, 122, 147 ... 322 һ. б. битләр. Әбләз—Габделгазиз исеменнән үзгәргән булырга охшый; «бахши» дип, хан кәнсәләрендәге секретарь чиновникларны атаганнар.

[2] Савельев П. С. Монеты джучидов, джагатаидов... обращенные в Золотой Орде в эпоху Токтамыша. СПб, 1857, 154 б.; Усманов М. А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV—XVI вв. Казань, 1979, 112—113 битләр.

[3] Кононов А. Н. Күрсәтелгән хезмәт, 12 бит.

[4] Зимин А. А. Иван Грозный и Симеон Бекбулатович в 1575 г.— Китапта: Из истории Татарии. Сб., IV, Казань, 1970, 145—147 битләр.

[5] Зимин А. А. Күрсәтелгән хезмәт, 141—142, 148—158 битләр.

Икенчедән, XV—XVII йөзләрдә Мәскәүдә бәк-мирза, хан-солтан ише аксөякләрнең туган-тумачалары, иш-яраннары белән кубәүләп яшәве, дәүләт-административ эшләренә җәлеп ителүе рус-көнчыгыш мөнәсәбәтләрендәге татар теленең тагы да активлашуын тәэмин иткән, әлбәттә. Чөнки Урда ханнарыннан бәйлелек чоры рус кинязьләрендә татар теле позициясен көчәйтүгә китергән булса, XV—XVII гасырлардагы иске Рәсәйдәге үзенчәлекле «рус-татар симбиозы» (сыйнфый-политик хезмәттәшлек көрәшеше) әлеге традициянең дәвамлылыгын, хәтта көчәюен тәэмин иткән. Бер үк вакытта әлеге хәлне исәпкә алу «йомышлы татарлар» дигән социаль категориянең кадрлар мәсьәләсен хәл кылудагы урынын да ачыграк күрергә ярдәм итә. Чөнки Илчелек приказы составында ике гасырдан артык вакыт рәсми бүлек сыйфатында эшләп килгән «Татар кәнсәләре»нең кадрлары шул «йомышлы татарлар»дан, нигездә традицион тугрылыгы белән танылган Касим, Романов, Темников татарларыннан һәм башка төбәк мишәрләреннән җәлеп ителә иде. «Татар кәнсәләре»ндә нәтиҗәле эшләгән кайбер тылмач һәм тәрҗемәчеләрнең дәүләттән җир биләмәләре алулары да билгеле.[1]

Күп кенә йомышлы татарларның XV—XVIII гасырларда рус дәүләте илчелеге составында чит илләргә баруы, кайбер очракларда илчелеккә җитәкчелек итүләре дә мәгълүм. Мәсәлән, ерак Һиндстанга 1675 елны җибәрелгән илчелекнең башлыгы Мөхәммәт Йосыф Касимов, Казагыстанны Россиягә тыныч юл белән кушуга дипломатик өлеш керткән касимле Котлымөхәммәт мирза Тәвкилев һ. б. шундыйлардан иде.

Шушы фактларны күз уңында тоткан академик В. В. Бартольд «рус хезмәтендә торган татарларның рус-көнчыгыш мөнәсәбәтендә» шәрык телләре буенча «үзәр тәрҗемәче кадрлар» булуын, дәүләткә файдалы хезмәт итүен махсус билгеләп уза[2]. Дөрес, мөхтәрәм галимнең гадел хөкеме кайбер яклары белән төгәлләп төшүгә дә мохтаҗ, чөнки аның мәсьәләне бары XVII—XVIII йөзләр белән чикләп куюы, югарыдагы материаллардан күренгәнчә, бай чынбарлыкка туры килеп бетми. Чынлыкта XVII—XVIII йөзләр Илчелек приказында татар йомышлыларының иң актив эшләгән чоры гына иде.

## Архивлар шаһитлеге

XVI гасырның икенче яртысында, Идел буе төгәле белән Мәскәүгә кушылып, күпмилләтле дәүләт оешкач, Россиянең халыкара мөнәсәбәтләрдәге активлыгы тагы да көчәеп, төрле көнчыгыш илләре белән элемтәләрне ныгытуга ихтыяҗы арткач, алар белән нинди телләрдә язышу мәсьәләсе дә алга баса. Әлбәттә, иң элек Җучи Улусы империясе чорында Үзәк Азиядән алып Балтик диңгезенә кадәрге араларда функциональ телләрнең берсенә әверелгән, югарыдагы фактлардан күренгәнчә, Мәскәүнең үзендә дә яхшы мәгълүм булган татар, дөресрәге, «төрки-татар» язма теленә мөрәҗәгать ителә.

Чит илләргә җибәреләсе патша грамоталары, табигый ки, иң элек русча төзеләләр, аннары Илчелек приказында йомышлы тылмачлар тарафыннан тәрҗемә ителәләр — Мәскәүдән менә шул русча оригинал белән тигез хокуктагы татарча дубликат бергә китәләр. Элек Кырым һәм Төркиялләр белән язышуда сыналган мондый алым күп кенә мөселман дәүләтләре белән бәйләнешләр башланган чорда да актив кулланыла, мәсәлән, XVI һәм XVII йөзләрдә Бохара, Үргәнеч хөкемдарларына, аннары Иран шаһлары белән Һиндстан падишаларына шундый ике телле грамоталар җибәрелә. Аларның кайбер үрнәкләре басылып та чыккан инде[3].

Үз грамоталарын ике телдә җибәрү тәҗрибәсен рус патшалары мөселман булмаган илләрнең хөкемдарларына карата да кулланганнар. Мәсәлән, калмык тайшаларына, монгол нуйаннарына күндерелгән русча грамоталар да ике телдә язылып, аларның татарчалары адресатлар өчен аңлаешлырак булган[4]. Төркиләргә территориаль

[1] Бу хакта тулырак мәгълүматларны карагыз: Белокуров С. А. О Посольском приказе. М., 1906; Веселовский Н. Н. Татарское влияние на русский посольский церемониал в Московский период русской истории. СПб., 1911.

[2] Бартольд В. В. Сочинения, т. IX, М., 1877, 372—373 битләр.

[3] Материалы по истории Узбекской, Таджикской и Туркменской ССР, I кисәк, Л., 1932; 418, 432, 449 һ. б. битләр; Русско-индийские отношения в XVII в. М., 1958, 363—365 битләр.

[4] Усманов М. А. Новый документ о Степане Разине (татарский перевод неизвестной грамоты Алексея Михайловича). — Китапта: Вопросы историографии и источниковедения, IV җыентык, Казан, 1969, 321—328 битләр; Чимит-Доржиев Ш. Б. Неопубликованные письма монгольских (ойротских) ханов как источник по русско-монгольским отношениям XVII века. — Труды Томского гос. университета им. В. В. Куйбышева, т. 150, Томск, 1961, 96 бит.

яктан якын, шуңа күрә руслар белән дә иртәрәк танышкан калмык һәм монгол җитәкчеләренә генә түгел, бәлки дипломатик мөнәсәбәтләр чагыштырмача соңрак урнашкан Кытай императорлары белән башлап язышканда да Мәскәү грамоталары русча, латинча һәм татарча өч параллель текстта җибәрелгән[1]; аларга каршы язылган җаваплар дә башта богдыхан сараендагы уйгур чиновниклары тарафыннан төркичә төзелгәннәр.

Рус дәүләтенең кайбер ерак күршеләре белән дипломатик бәйләнешләрына караган татар телендәге документларның саны, шулай итеп, дисталәп исәпләнсә (мондый бәйләнешларның чагыштырмача эпизодик тестә барган булуын да онытмыйк), аның якын күршеләре, җөмләдән, тора-бара үз составына кергән илләр, халыклар белән элемтәсенә караганнары йөзәрләп, хәтта меңәрләп санала. Әйтик, Төньяк Кавказдагы кайбер төрки һәм төрки булмаган халыкларның җитәкчеләре белән язышканда да патша хөкүмәте чиновниклары татар теленә еш мөрәҗәгать иткәннәр икән. Мәскәүдәге Борынгы актлар архивындагы шундый истәлекләрнең саны йөздән артса (БАҮДА: 101, 104, 116, 121, 129 һ. б. фондларда), Махачкаладагы Дагыстан АССРның үзәк дәүләт архивындагы 379 фондта 3500 (өч мең биш йөз)дән артык төрле төрки телләрдәге документлар саклана. Чечен кабиләләре тарафыннан Россиягә ирекле рәвештә кушылу теләгән игълан итеп язылган рәсми мөрәҗәгатьнең дә татар әдәби теле тәэсирендәге төркичәдә төзелгән булуы характерлы[2]. Димак, балкар, карачай, нугай һәм комыклар белән рус администрациясенең төрки-татарча язышуы бер дә гаҗәпләнерлек түгел икән.

Казах ханнарының Россия составына ирекле керүләрен игълан иткән рәсми документлар шулай ук татарча төзелгән[3]. Әгәр ул документларның кайберләре Котлымөхәммәт мирза Тәвкилев илчелегендә казах сахраларына барып чыккан кешеләр тарафыннан язылганлыгы ачык күренеп торса, патша администрациясе аннан соң да рус-казах язышуларында татар тылмачларыннан актив файдалана, хәтта казах ханнарына, бәк-солтаннарына эш кәгазьләре йөртүче писерләр сыйфатында татар муллаларын көчләп тагалар, чөнки әлеге «муллалар» бер уңайдан патша администрациясенең «ышанычлы кешеләре» булалар[4]. Шуңа күрә XVIII һәм XIX гасыр рус-казах мөнәсәбәтләренә караган документларның саны да меңәрләп исәпләнә.

Башкорт старшиналары һәм биләренең «эшләрен» йөртсен өчен патша хөкүмәте аларга татар-мишәрләрдән махсус писерләр билгеләп, аларны кайбер салымнан азат иткән[5]. Бер уңайдан җир дә алу өчен андыйларның һәммәсе диярлек башкорт булып язылалар; шулар арасыннан соңрак Бикчуриннар, Диваевлар, Ибраһимовлар кебек «башкорт укымышлылары» сыйфатында дан казанган күренекле кешеләр, эре чиновниклар чыккан. Шуңа күрә хәзер башкорт галимнәре «төрки» дип атап, шул рәвешчә үзләренә якын итә торган меңләгән-меңләгән татарча документлар барлыкка килгән[6].

Россиянең көнчыгыштагы административ тормышында татар теле тоткан шушы объектив статусны, аның рус булмаган халыклар арасындагы коммуникатив сыйфатын яхшы тойган Е. И. Пугачев та үз өндәмәләрен, татарлар, башкортлар, казахлар һәм калмыклар арасына шул телдә язып тарата, соңгылары исә «мужик патшасының» бу башлангычын күтәреп ала һәм аз вакыт эчендә үзләре дә шул телдә төзелгән документлар тудыра.

Әгәр шул рәвешчә илебез архивларында сакланып калган төркичә һәм татарча документларны барлап, аларның язылу, җыелу тарихларын ачыклап тикшерә башласак, сүз күпкә китәр иде. Әмма шушы әйтелгән кадәресе дә йомгак ясар өчен ышанычлы җирлек була ала.

---

[1] БАҮДА, 62 фонд, 1 тасв., 1 кисак. 141 кагазь. Пекинга мондый өч телдәге грамоталар 1654 һәм 1674 елларда җибәрелә.

[2] Карагыз: Кушева Е. Н., Усманов М. А. К вопросу об общественном строе вайнахов (Письмо 1675 г. Шибутского джамаата царю Алексею Михайловичу).— Советская этнография, 1978, № 6, 99—104 битлар.

[3] Казахско-русские отношения в XVII—XVIII веках. Сборник документов и материалов. Алма-Ата, 1961, 14—28, 35—39, 45 һ. б. битлар.

[4] Тумашева Д. Г., Усманов М. А., Хисамова Ф. М. Об особенностях развития старотатарской деловой письменности.— Советская тюркология, 1977, № 3, 52—55 битлар.

[5] Полное собрание законов Российской империи. Собрание первое. XXVII том, икенче басма, 1 бүлек, № 26456, 479 бит.

[6] Бу хакта карагыз: Фасеев Ф. С. Старотатарская деловая письменность. Казань, 1961, 16—39 битлар.

# Кыскача йомгак

Көнчыгыш Европа регионында төрки телләрнең, бигрәк тә төрки-татар теленең киң таралу фактын, гадәттә, XIII—XV йөзләрдәге, ягъни Җучи Улусы (Алтын Урда) чорындагы хәлләргә бәйләп аңлатырга тырышалар. Китерелгән материаллардан күренгәнчә, бу процесс монгол яулап алуларына кадәрге дәверләргә барып тоташа икән. Шуңа күрә Алтын Урда чорында формалашкан, киң таралган язма телне буш җирдә туган күренеш дип түгел, бәлки элгәргедән килә торган традициянең яңа этник компонентлар исәбенә үзгәреп, көчәеп дәвам итүе дип аңларга кирәк.

XIII—XV гасыр төрки-татар язма теленең киң таралуы, кайбер күрше илләрдә халыкара функциональ телләрнең берсенә әверелүе мәсьәләсенә килсәк, моны рәсми эш кәгазьләре йөртү культурасының этник («милли») факторларга гына түгел, бәлки беренче чиратта иҗтимагый-политик сәбәпләргә барып тоташуы белән аңлату дөресрәк булыр иде.

XIII—XV йөзләрдә шул рәвешчә формалашып, таралып һәм ныгып өлгергән әдәби теленең соңрак, азмы-күпме дәрәҗәдә үзгәреп, татар милли язма теленә килеп ялгануы исә хаким культураның аерылгысыз өлеше булган язма традициянең иң элек конкрет социаль-иҗтимагый һәм сәяси факторларга бәйләнгәнлеген раслый.

Җучи Улусы чорындагы төрки телнең таралу сферасы, функциональ сыйфаты иске татар теленә күчүе соңгысының рус-көнчыгыш мөнәсәбәтләрендәге ролен, урынын билгеләгән. Үз нәүбәтендә Рус дәүләтенең бу юнәлештәге политикасы татар язма теленең таралыш географиясе тагы да киңәюгә китергән. Шуңа күрә XVII—XVIII, хәтта XIX гасырлардагы татар теле таралышын бары татар кешеләренең теләкләре нәтиҗәсе дип түгел, ә Россия дәүләте администрациясенең үзенчәлекле һәм каршылыклы политикасы тәэсирендә барлыкка килгән күренеш сыйфатында да бәяләргә кирәк. Каршылыклы дип әйтүнең сәбәбе шунда ки, дин-идеология өлкәсендәге татарларның мәдәни потенциалын, аларның башкаларга тәэсирен киметергә, хәтта аны җимерергә омтылган патша хөкүмәте, дөньяви-административ юнәлештәге чаралары белән объектив рәвештә татар рухи культурасының бер өлеше булган язма традициянең ныгуына булышлык күрсәткән. Шуңа күрә дә XIX гасырның икенче яртысындагы миссионерларның кайберләре, мәсәлән, Ильминский һәм Смирнов ишеләре, патша хөкүмәте администрациясен «сукырлыкта» гаепләп сөрән салдылар. Әмма форсат узылган, «җен чүлмәктән ычкынган» иде...

XIX йөзнең уртасы һәм икенче яртысында татар җирлегендә барлыкка килгән, формалашкан мәгърифәтчелек идеологиясенең, шул рух белән сугарылган басма сүзнең — китапларның киң таралуы, бигрәк тә XX гасыр башы татарча вакытлы матбугатның тиз арада бөтен Россия көнчыгышында диярлек колач җәюе, бер сүз белән әйткәндә, чөй өстенә казык кына булган иде.

Шулай итеп, татар язма һәм әдәби традициясенең кайбер тармаклары милли җирлек кысаларыннан чыгып китеп, киңрәк сфераларга таралуы тарихи объектив сәбәпләр белән шактый төгәл һәм документаль эзлекле аңлатыла икән. Бу хәл исә, беренчедән, татар теле хакында әйтелгән кайбер фикерләрнең коры дәгъва түгеллеген раслаcard, икенчедән, форма-рәвеше буенча татарча язгыраган күпсанлы документларның эчтәлек җәһәтеннән гомум рус-көнчыгыш тарихына да, кайбер тугандаш һәм ватандаш халыкларның ерак һәм якын узганнарына да караулары хакында сөйли. Шуңа күрә мондый төр документларны тар милли интереслардан гына түгел, ә киңрәк планда — гомум Россия халыклары тарихы югарылыгыннан да торып өйрәнергә кирәк.

## Әхмәт Исхак

### Автобус белән Трамвай вагоны

мәсәл

Зур гына бер урамда
Кызыл ут алдында туктап торганда
Күзе төшеп Трамвай вагонына,
Килеп аның янына,
Әйткән бик ыспай бер Автобус:
— Эх, якын дус!
Күргән саен хәлегезне
Кызганам мин сезне:
Басасыз да таң иртәдән шушы юлга,
Шуннан бирле
Борыла алмый уңга яки сулга
Көн буе чабасыз арлы да бирле.
Хезмәт күрсәтә торып көн дә
Миллионнарча шәһәр халкына,
Зарланмыйча бер дә
Яшисез бердәнбер хезмәт хакына.
Ошамый миңа сезнең бу эшегез:
Юк бернинди өстәмә төшемегез.
Кара син менә безгә,
Ягъни автомашиналарга:
Бара алабыз теләгән җиребезгә
Һәм теләгән арага.
Борылабыз, теләсәк — уңга,
Теләсәк — сулга.
Аз керми төшеме дә кулга.
Ала алсаң син без алган төшемне,
Тишмәс иде ул синең дә эчеңне!..
Шунда
Торган килеш үзенең юлында,
Горурлык белән карап аңарга,
Әйткән Трамвай вагоны:
— Үзем сайладым мин бу туры юлны,
Хәрам кәсепне яратмаганга.
Намуслы хезмәтнең юлы
Булырга тиеш һәрвакыт туры.
Ә инде әйтсәм дөресен генә
Баерга теләп дәүләт исәбенә,

Сез төрле якка борып юлыгызны,
Аның кесәсенә тыгасыз кулыгызны.
Ә бит намуслы һәр кеше
Караклык дип атый мондый эшне.
Ә каракның юлы
Беркайчан да булмый туры.
Димәк,
Безне кызганудан бигрәк,
Чикләү өчен кәкре юлыгызны,
Кыскартырга кирәк
Сезнең кулыгызны!

* * *

Шуны әйтим, укучым, колагыңа:
Язылганнар бу мәсәлдә
Кагыла дип уйламагыз, һәрхәлдә,
Бары тик автобусларга гына.

## Басыйр Рафиков

### Начальникны көткәндә

«Унау берне көтми»,— диләр.
Көттерә икән нужа...
Көтмичә кая барырсың,
Ул берәү булса — хуҗа?

Күпме бергә торып, бүгенгәчә
Аңлый алмыйм шуны, Сәлмән күрше:
Авызыңда ничек тату яши
Лыгырдык тел белән акыл теше?

«Эшем», диеп, «Эшлим», диеп,
Тел белән йомгак сүтә.
Кырган «эшен» сөйли-сөйли
Эш сәгатьләре үтә.

*Троицк шәһәре.*

## Склероз

Мирсәй Әмир халык алдында үзенең «Склероз» исемле хикәясен укый икән. Хикәянең азагына җиткәч, автор туктап, нидер эзли башлый. Бик озак эзләгәннән соң:

— Ни югалттың, Мирсәяф абый? — дип сорыйлар моңардан.

— Һәй, хикәямнең соңгы битен өйдә онытып калдырганмын! — ди язучы.— Менә бит ул хәтерсезлек... әлеге склероз бәласе...

## Чынлап үтерсә!

Трагик Мөхтәр Мутин гайрәтле актер булган, дип сөйлиләр. Ул — Отеллоны, Галимә Ибраһимова Дездемонаны уйный икән. Көнчелектән акылын җуяр дәрәҗәгә җиткән Отелло-Мутиннан Галимә Ибраһимова чынлап курка торган була. Үтереш сәхнәсендә Отелло Дездемонаны буарга килә. Мутинның күзләрен кан баскан, ирен кырыйларында күбек, тавышы калтырый, куллары янаулы тырпайган. Галимә Ибраһимова сәхнәдән чыгып йөгерә яза. Аның куркуын күреп, Мөхтәр Мутин артисткага гына ишетелерлек итеп:

— Курыкма, Галимә, курыкма! — дип юата, тынычландыра.

Дездемонаны буганда Мутинның бармаклары Галимә апаның муенына тияр-тимәс кенә кагыла торган була.

## Бишбалта арасында

Сәйдәш егет чагында ашыгып сөйләргә ярата торган бер кыз белән танышкан икән. Чираттагы очрашуда Сәйдәш кызны трамвай тукталышына кадәр озата бара. Трамвай килеп туктый. Кыз күтәрмәгә сикереп менә. Трамвай кузгалып китә.

— Кайда, кайчан күрешәбез? — дип кычкыра Сәйдәш.

Кыз трамвай бусагасына баскан килеш китеп бара, үзе:

— Бишбалта арасында, Бишбалта арасында! — дип кычкыра.

Икенче көнне Сәйдәш киез итек, тун киеп, Бишбалта белән шәһәр арасындагы күтәртелгән юлга китә. Бер сәгать йөри бу Бишбалта белән Казан арасында, ике сәгать... Көн буе кызны көтә. Катып-туңып бетә, кыз килми.

Яңадан очрашкач, кыз Сәйдәшкә үпкә белдерә:

— Салих, нигә килмәдең, мин сине бер сәгать буе көттем! — ди.

— Син үзең килмәдең,— ди Сәйдәш.— Мин сине көн озын көттем.

— Кайда көттең? — дип сорый кыз.

— Бишбалта арасында! — ди Сәйдәш.

Кыз рәхәтләнеп көлеп җибәрә.

— Бишбалта арасында? Мин сиңа элеккеге шул урында, биш-алты арасында, дидем бит.

*«Кызыклы хәлләр»не журнал өчен Р. Батулла әзерләде.*


*Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары*



## Фәрит Гыйльми

Фәрит Гыйльметдин улы Гыйльметдинов 1947 елның 14 апрелендә Мөслим районының Үрәзмәт авылында туган. 1970 елда Казан дәүләт университетын тәмамлагач, Совет Армиясендә офицер булып хезмәт итә, аннары Әлмәттә төрле оешмаларда эшли. КПСС члены.

1981 елда яшь язучының «Урсай тау итәгендә» исемле повесте аерым китап булып басылды. Шулай ук аның «Елганың борылган төшендә» повесте да «Казан утлары» битләрендә дөнья күрде.



## Камил Кәримов

Камил Әдһәм улы Кәримов 1950 елның 1 июлендә Питрәч районының Шәле авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, туган авылында эшкә кала. 1971 елда Ростов-на-Дону шәһәрендә техник белем ала, су скважиналары бораулаучысы булып эшли. 1980 елда Казан дәүләт культура институтын тәмамлый. Бүгенге көндә К. Кәримов — «Идел» альманахы редакторы. КПСС члены. К. Кәримовның «Үндүрт яшьтә» дигән беренче хикәяләр җыентыгы 1981 елда басылып чыкты. Быел аның «Бәхетле кеше» исемле китабы дөнья күрәчәк.



## Салих Маннапов

Салих Маннапов (Мөдәррис Харис улы Вәлиев) 1953 елның 30 маенда Әлки районының Яңа Камка авылында туа. 1976 елда Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң, «Татарстан яшьләре» газетасында әдәби хезмәткәр һәм бүлек мөдире, 1979 елдан «Казан утлары» журналында өлкән редактор булып эшли. Хәзерге көндә ул — «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре. КПСС члены.

1984 елда яшь тәнкыйтьченең «Сезгә ышанам» исемле беренче китабы дөнья күрде.

# *Культура тормышы көндәлеге*

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Татарстан Язучылар союзының чираттагы партия җыелышында татар әдәбиятында очерк һәм публицистика жанрының торышы мәсьәләләре тикшерелде. Көн тәртибендәге мәсьәлә буенча очеркист М. Зарипов чыгыш ясады. Фикер алышуда ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Ф. Миннуллин, партия бюросы секретаре Р. Мөхәммәдиев, язучылар Р. Мостафин, Р. Ишморат, Б. Камалов һәм башкалар катнашты.

## КОЛ ГАЛИГӘ БАГЫШЛАНГАН ТАНТАНА

19 мартта Мәскәүдә, язучыларның А. А. Фадеев исемендәге Үзәк йортында болгар-татар язма поэзиясенә нигез салучы, мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» поэмасының авторы Кол Галинең тууына 800 ел тулуга багышланган тантаналы кичә үткәрелде.

Кичәне кереш сүз белән СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре А. С. Иванов ачты. «Әгәр без, төрле милләт вәкилләре, «Кыйссаи Йосыф» авторы бөек Кол Галине искә алу өчен нәкъ менә бирелә, Ватаныбыз башкаласы Мәскәүдә җыелганбыз икән,— диде ул,— моның тирән социаль һәм гуманистик мәгънәсе бар. Бу — Коммунистлар партиясенең милли политикасы тантанасын, совет державасы халыкларының реаль, куәтле, какшамас дуслыгын күрсәтә».

Тантаналы кичәдә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары, филология фәннәре докторы М. Х. Хәсәнов шагыйрь Кол Гали һәм аның үлемсез әсәре турында доклад белән чыкты.

РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре М. М. Годенко, СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты Г. И. Ломидзе, филология фәннәре докторы Г. Хөсәенов (Уфа), РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь С. Хаким, язучы С. Н. Иванов (Ленинград), ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов кичәдә чыгыш ясап, Кол Гали иҗатының интернациональ әһәмияте турында сөйләделәр.

Кичә Татарстан сәнгать осталарының концерты белән тәмамланды. Анда «Кыйссаи Йосыф» поэмасыннан өзекләр укылды, татар халык көйләре һәм композиторларыбыз әсәрләре башкарылды.

Кичәдә КПСС Үзәк Комитетының культура бүлеге мөдире урынбасары А. А. Беляев, КПСС Үзәк Комитетының сектор мөдире В. А. Степанов, КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе С. В. Михалков, СССР Язучылар союзы идарәсе секретарьлары Е. А. Исаев, Ю. И. Суровцев, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретарьлары Н. К. Доризо һәм М. М. Колосов катнашты.

## «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ПОЭМАСЫНЫҢ ЯҢА БАСМАСЫН ТИКШЕРҮ

27 мартта Татарстан Язучылар союзында галимнәр, язучылар һәм нәшрият хезмәткәрләре катнашында Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының яңа басмасын (Татарстан китап нәшрияты, 1984) тикшерүгә багышланган җыелыш булды. Тәнкыйть секциясе инициативасы белән оештырылган бу җыелышны секция председателе Ф. Мусин ачты. Филология фәннәре кандидаты Ш. Абилов хезмәтнең фәнни һәм практик әһәмияте, басманың текстологик һәм художество-полиграфик эшләнеше турында сөйләде. Фикер алышуларда Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Шәрәфетдинов, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, философия фәннәре докторы Я. Абдуллин, филология фәннәре докторлары Н. Юзиев, Х. Госман, тарих фәннәре докторы М. Госманов, язучылар Н. Фәттах, Р. Мостафин, рәссам Б. Урманче, филология фәннәре кадидатлары Н. Хисамов, М. Гайнетдинов катнашты. Чыгыш ясаучылар Кол Галинең бөек «Кыйссаи Йосыф» әсәренең яңа басмасын югары бәяләделәр, аның мәдәни тормышыбыздагы зур әһәмиятен билгеләп үттеләр, әдәби мирасыбызны өйрәнү һәм дөньяга чыгару буенча алда торган бурычлар турында фикер алыштылар.

## ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫ

12 мартта Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында татар әдәбияты классигы Шәриф Камалның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Кичәне кереш сүз белән ТАССР культура министры И. Н. Алиев ачты. Ш. Камалның тормыш һәм иҗат юлы турында ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов сөйләде.

Кичәдә КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

# ТАБИГАТЬТӘ ЗАМАН ЧАГЫЛА

Индустриаль пейзаж... Шушы сүзләрне әйтүгә РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Николай Кузнецов күз алдына килә. Бу табигый, чөнки республикабызда мондый төр пейзажның тууы нәкъ менә аның исеме белән бәйле. Ватанызбызның индустриаль куәтен табигать җирлегендә гармонияле рәвештә күрсәтә алу Николай Дмитриевичның үзенчәлекле иҗат осталыгын билгели. Үзенең лирик, героик-эпик полотноларында ул Ватан образын нәкъ менә индустриаль пейзажчы буларак гәүдәләндерә. Темалар берничә сериягә берләштерелә. Әйтик, аның илленче елларда иҗат ителгән «Мәскәү. Өченче чакрым», «Зур станциядә», «Юлга да яз килде» һ. б. шундый беренче полотнолары тимер юл темасына багышланган. Ә аннары «хезмәтчел Идел» турында серия туа: «Казан — биш диңгез порты», «Су юлы ачылыр алдыннан»...

Пейзаж жанрының индустриаль төре замана үзгәрешләренә аеруча сизгер булуны таләп итә, чөнки илебез индустриясе күзгә күренеп үзгәрә тора. Әлеге таләпне тирәнтен аңлаган Н. Кузнецов та «алгы сызык»тан торып иҗат итәргә омтылды һәм гомеренең соңгы ун елында республикабызның индустриаль йөзен сурәтләүдә, төгәлрәк әйткәндә, нефть химиясе, автомобиль төзелеше темасын күтәрүдә аеруча зур уңышларга ирешә. Мәсәлән, «Киләчәк силуэтлары», «Нефть чыккан якларда», «Индустриаль пейзаж» кебек картиналар халкыбызның хезмәт батырлыгы турында сөйләүче сынлы сәнгать телендә язылган елъязма буларак кабул ителә.

Пейзаж цикллары арасында Казанга багышланганнары шулай ук рәссамның уңышлы әсәрләреннән санала. Елдан-ел яшәрә баручы борынгы шәһәрнең урамнары, мәйданнары, күперләре, парклары полотноларда нәкъ менә индустриаль пейзаж остасы Кузнецов кулы белән кабатланмас рәвештә гәүдәләнгән.

...Кремль итәгендәге иңкүлектә язгы кояш нурларына коенып утыручы агачлар, әйтерсең, «тубыклары»на кадәр җәелгән кар суында үзләренең сылу гәүдәләренә карап хозурланалар. Анда-монда «кар утраучыклар» күренгәли. Ябалдашларга үтә күренмәле көмешсыман җир буы сарылган. Мәһабәт агач кәүсәләре арасыннан Казан Кремле күренеп тора. Алтынсу-зәңгәр тоннар гаммасы, композициянең тын ритмы борынгы корылманың бөеклеген ачу өчен бик отышлы файдаланылган. Һәм шул рәвешле автор Татарстан башкаласы символына әверелгән архитектур образның гармонияле ирешкән... Табигатьтә язгы уяну бара... Үткәннәргә яз аша карау көнендә оптимизм хисләре уята.

Диләрә САДЫЙКОВА,
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.

Тышлыкның дүртенче битендә: Татарстанның халык артисткасы Римма Ибраһимова.

Р. МАНСУРОВ фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)